Академия наук Республики Татарстан
Институт языка, литературы и искусства
имени Г.Ибрагимова

# Галиасгар Камал

## Сочинения

В трех томах

Том 1

Пьесы

*Издание второе,
исправленное и
дополненное*

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ
ИЗДАТЕЛЬСТВО
2010

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г.Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

# Галиәсгар Камал

## Әсәрләр
Өч томда

1 том

Пьесалар

*Төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басма*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2010

УДК 821.512.145-2 : 1
ББК 84(2Рос=Тат)-6 : 5
К22

Редколлегия:
*З.Р.Вәлиева, К.М.Миңнуллин, Д.С.Шакиров, А.Г.Әхмәдуллин (баш мөхәррир), З.З.Рәмиев.*

Текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүчеләр:
*Бәян Гыйззәт, Зөфәр Рәмиев, Фатыйма Ибраһимова, Әнисә Алиева, Мәгъсүм Хәбибуллин, Малик Хәйруллин*

**Камал, Г.Г.**

К22 Әсәрләр : 3 томда / Галиәсгар Камал. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010.
ISBN 978-5-298-01900-2
1 т. : пьесалар / текст., иск. һәм аңл. әзерл. Б.Гыйззәт, З.Рәмиев, Ф.Ибраһимова, Ә.Алиева, М.Хәбибуллин, М.Хәйруллин. – Төз. һәм тулыл. 2 нче басма. – 2010. – 366 б.
ISBN 978-5-298-01901-9

Татар халкының классик язучысы, драматург Галиәсгар Камал әсәрләренең бу томында әдипнең 1917 елга кадәр язылган сәхнә әсәрләре урын алды.

УДК 821.512.145-2 : 1
ББК 84(2Рос=Тат)-6 : 5

ISBN 978-5-298-01901-9 (1 т.)
ISBN 978-5-298-01900-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2010



## РЕДКОЛЛЕГИЯДӘН

Галиәсгар Камал (1879–1933) – татар әдәбияты классигы, талантлы драматург, үзенчәлекле шагыйрь, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе. Ул гаять зур иҗади мирас калдырган. Драматургиябезгә керткән зур өлеше өчен Г.Тукай аны «татарның Островские» дип атаган. Әдип 30 дан артык сәхнә әсәре, йөздән артык шигырь-поэма, хикәя, публицистик һәм тәнкыйди мәкалә язган; ул күпсанлы пьесалар тәрҗемә иткән, матбугатыбыз тарихында күренекле роль уйнаган газета-журналларны оештырган һәм аларны җитәкләгән, театр сәнгатебезнең аякка басып килгән чорында режиссер һәм артист буларак та, сәхнәне бизәүче сыйфатында да хезмәт куйган. Аның иҗат җимешләре бүген дә үзкыйммәтен саклый. Аерым пьесаларының һаман да сәхнәләрдә уйналуы, дәреслекләрдә төпле урын алуы, татар сәхнә сәнгатенең флагманы булган театрның аның исемен йөртүе (Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры), әсәрләренең басыла торуы шул хакта сөйли.

Г.Камалның кат-кат басылган әсәрләре, җыентыклары арасында аның 100 еллык юбилеена атап чыгарылган 3 томлык «Әсәрләр»е (1 нче том – 1978, 2 нче том – 1979, 3 нче том – 1982) бу зур мирасны иңләп алуы, тиешенчә фәнни-текстологик эшләнүе белән аерылып тора. Үз вакытында аны туплап, басмага әзерләп, фәнни яктан да, текстологик эшкәртүдә дә көчләрен кызганмаган Б.Гыйззәт, Н.Ханзафаров, Г.Шәрәфетдинов, Н.Юзиев һ.б.ларны куйган хезмәтләре өчен рәхмәт хисе белән искә алырга, басманы сыйфатлы итеп хәзерләп чыгаруга зур өлеш керткән нәшрият редакторы Р.Даутовның хезмәтен аерым билгеләп үтәргә кирәк.

Һәм менә Г.Камалның тууына 130 ел тулу уңае белән аның яңартылган, тулыландырылган басмасын чыгару ихтыяҗы туды. Билгеле, аның нигезен язучының 100 еллыгына атап чыгарылган 3 томлык «Әсәрләр»е тәшкил итә. Әмма ул томнарда совет идеологиясе тәэсире астында әдипнең иҗатына анализ һәм бәяләр бирүдә берьяклылыклар, кайбер ялгышлыклар киткән; мөһим әсәрләр, язмалар күз уңаеннан читтә калган. Аларның бер өлеше яңа басмада урын алды.

Әдип мирасының томнарга бүлеп бирелеше үзгәрешсез калдырылды:

1 нче том сәхнә әсәрләрен (кайберләре вариантлары белән) үз эченә ала.

2 нче томда совет чорында язылган пьесалар һәм инсценировкалар, эстрада әсәрләре аерым, шигърият аерым бүлек итеп бирелә.

3 нче томда язучының хикәяләре, әдәби һәм театр тәнкыйтенә, публицистикага караган мәкаләләре, чыгышлары, рецензияләре, истәлекләре, хатлары урын ала. Бу томдагы әсәрләрнең, мәкалә-рецензияләрнең, язмаларның библиографиясе, һәр томда урнаштырылган искәрмә һәм аңлатмалар басманың фәннилек дәрәҗәсен күтәрә, аның бәясен арттыра гына.

## БӘХЕТСЕЗ ЕГЕТ

*Драма 5 пәрдәдә*

УЙНАУЧЫЛАР:

Кәрим – Казан бае, иске фикерле, уртача буйлы, сакалы агара башлаган.
Җәмилә – Кәримнең хатыны.
Закир – Кәримнең улы, тәүфикъсыз, 22 яшьләрендә.
Мансур – Кәримнең агасы, ак сакаллы.
Гали – бер сәүдәгәр, сары сакаллы, уртача буйлы, 40 яшьләрдә.
Камилә – Кәримнең асравы, 18 яшьләрендә.
Мәгъри – сүз йөртүче бер карчык.
Сәгыйть Сабитов – Уфада бер бай, яхшы гына фикерле.
Гайшә – Сәгыйтьнең кызы, 17 яшендә, гимназистка.
Әхмәт – Сәгыйтьнең улы, 20 дә, гимназист.
Мәрьям – Сәгыйтьнең хатыны, 40 яшьләрендә.
Асрау – Сәгыйтьнең асравы, яшүсмер кыз.
Камали – Закирның иптәш жулигы, кырма сакаллы, 30 яшьләрендә.
Васька, Кәмәй, Калакай, Мортый, Дәүли, Шестерка – жуликлар.
Гайни – Закирның мәгъшукасы.
Биби – бер карчык.
Чит кешеләр, городовойлар һәм бер околодочный.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Кәрим йортының залы; уң тарафта – диван, аның алдында зур өстәл, аның өстендә чынаяк, чәйнек вә башка чәй әсбаблары; сул тарафта – бер кантор өстәле, тәрәзә араларында – көзгеләр, стена буенда – урындыклар, бере уң тарафта вә бере урталыкта ике ишек. Урталыктагы ишек янында бер шкаф. Мебельләр бераз бай сымак. Җәмилә утырган.

### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Җәмилә ялгыз.

Җәмилә (*үз-үзенә елаган тавыш белән*). Әй Ходаем! Ата-анасына игелеге тияр дип өмет итеп, баланы үстер

инде. Ике көннән бирле кайтканы юк. Белмим, кайда йөри торгандыр? Моннан элек тә, бер мәртәбә шулай югалып, әллә нинди начар урыннарда йөреп, өч көндә йөз тәңкәдән артык акча бетереп кайткан иде. Атасы белән минем башыма хәсрәткә генә туган бала инде. Ул баладан ни-нәрсә өмет итмәк кирәк, анда нинди хәер булсын инде?! Мондый баланың булганыннан булмаганы мең өлеш артык. Аһ!.. Күрәсемә каршы булган бала икән шул. Авырлы вакытымда ук аның юньле бала булмаслыгы төшемә кергән иде. Төшемдә бер дуңгыз баласын күтәреп, кочаклап йөргәнемне күргән идем, шул вакытта ук җиде газизләр рухына җиде ясин чыгып багышларга дип суфи абзыйга сәдака да җибәрткән идем, кабул булмады шул. Атасы монда, карт башы белән, дөнья көтеп йөри. Ә аның һичбер исендә дә юк. Мисез шул, мисез! Мие чермәгән булса, ата-анасының бераз кадерен белгән булыр иде. Белмим, кемгә охшап бу кадәр мисез, гакылсыз булгандыр бу! Атасы никадәр акчалар, никадәр расхутлар тотып аны укытты. Аның өчен тоткан акчалар һәм чиккән мәшәкатьләр тау кадәр булды. Тукта, яхшы булсын, тукта, укымышлы булсын, балабызны яхшы укытсын дип, хәлфәсен ашка чакырулар кирәкме?! Атна саен мунча ягып чакыру кирәкме?! Аның өчен атасы һичбер нәрсәсен дә кызганмады инде. Өйгә кайтып керде исә: «Нихәл, Закир сабакка бардымы? Сабагын белеп кайтканмы?» – дип, һәр көн җентекләп тикшереп торадыр иде. Мин дә гомеремә, һичбер вакытта кулымнан килгән яхшылыгымны кызганмадым. Кайсы вакытларда: «Башым авырта», – дип, сабакка бармый калгалыйдыр иде. Шул вакытларда да, атасы каты кеше булганга күрә, тукта, ормасын, сукмасын дип, бармаган булса да: «Барды», – дип яклап каладыр идем. Мин аңа нинди яхшылыклар итмәдем?! Тукта, баланың күңеле төшмәсен, тукта, баланың кәефе кырылмасын дип, җаны теләгән нәрсәләрен алып ашасын дип, атасына белгертмичә акчалар бирәдер идем бит. Ул шуларның да кадерен белмәде. Соңыннан исенә төшәр әле төшүен, әмма ул чагында кайгыруның файдасы булмас. И Алла! Үзе теләсә ни эшләсен иде шунда, аның өчен без монда кеше арасында бәднам булырга кирәк. Берсекөнгә әле менә Әхмәтҗан хаҗилардан бүләк багарга чакырганнар. Бармый калсаң, бер дә ярамый: якын кеше, үпкәләүләре ихтимал. Барсаң, тагы оят, кешенең күзе синдә генә була. (*Бераз торып.*) Бала күңелне йом-

---

Бәднам булу – яман аты чыгу.

шата! Атасы никадәр каты күңелле кеше, шулай да булса кызгана. «Бүген кешеләр җибәртеп кайтарырга кирәк, табып булмас микән?» – дип чыгып киткән иде, ни эшләгәндер. (*Бераз торып.*) Уһ Алла!.. Нихәлләр булыр икән инде? Минем өчен дә, атасы өчен дә үкенечкә туган бер бала инде бу. Моның өчен йөрәгемнең җәрәхәтләнгәнен, моның өчен эчемнең көйгәнен бер Ходай үзе генә белә. Ичмаса, атасы табып кайтса, бераз йөрәгемә ял булыр иде. (*Тавышын арттырыбрак.*) И Алла! И Илаһым! Үзең инсаф бир! (*Җылый, яулык почмагы белән күзләрен каплый. Диванның аркасына егыла. Аз вакыт тынычлык.*)

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Җ ә м и л ә, М ә г ъ р и.

**Ишекнең тышкы тарафында ике хатынның кычкырышкан авазлары ишетелә. Сүзләре аңлашылмый.**

Җ ә м и л ә (*акрын гына торып*). И Алла! Бу асраулар да җик күрсәттеләр. Тагы нигә даулашалар икән инде? (*Күзләрен сөртә-сөртә ишеккә таба китә; ишеккә барып җитмәстән, кулына бер төенчек тоткан Мәгъри кычкырып керә.*)

М ә г ъ р и. Һи, мәхәббәтсезләр! Дәргяһтан сөрелгән нәрсәләр, килмешәкләр!

Җ ә м и л ә. Исәнме, Мәгъри абыстай, кемгә ул кадәр ачуланасың?

М ә г ъ р и. Исәнме, кызым Җәмилә, ачуымнан исәнлек-саулык сорашырга да оныткანмын. Байларыннан артык бугазларын киереп, җикеренеп кычкыралар. Керергә рөхсәт юк, ди, абзый өйгә ят кеше кертмәскә кушты, ди. Мин ят кеше булырга, Кәрим ул минем үз улым шикелле, мин аны менә мондый вакыттан бирле беләм. (*Кулы белән бер кечкенә бала күрсәткән шикелле күрсәтә.*) Абау, абау! Бу асрау дигән нәрсәләрдә һич оят юк. Булдыра алсалар, байларына кече хатынлыкка барырлар иде...

Җ ә м и л ә. Йә, Мәгърифә абыстай! Юкка үзеңне-үзең борчыма. Әйдә, менә монда утыр. (*Диванны күрсәтә.*) Дога кылырга да оныттык.

**Мәгъри – диванга, Җәмилә урындыкка утырып, дога кылалар.**

Исәнме, Мәгъри абыстай! Исән-сау йөрисезме?

---

Д ә р г я һ т а н  с ө р е л г ә н – «каргыш төшкән» мәгънәсендә.

М ә г ъ р и. Аллага шөкер, кызым, Аллага шөкер, дусишләрнең хәер-догалары аркасында бик сәламәт йөрим. Салкын тигәнмедер, нидәндер бераз тыннарым гына бетеп тора. Шәмсеҗиһан бикәләргә куркулык коярга барган идем дә, шуннан кайтышлый «тукта, кереп хәлләрен белеп чыгармын, ни эшләп торалар» икән дип кергән идем.

Җ ә м и л ә. Бик рәхмәт исегезгә төшереп керүегезгә.

М ә г ъ р и (*һич илтифат итмичә, үз сүзендә дәвам итәрәк*). Аларның да шул, сезнеке шикелле, күзе-башы алакайган бер асраулары бар. Шул асраулары беркөн тәрәзәгә мәче ыргыткан. «Бик курыктым, бер дә котымконым калмады, бөтенләй, бер дә хәлем юк, аякларымның тәмам җегәрләре бетте», – ди. «Тез буыннарым калтырап тора», – ди. Чәршәмбе йомыркасы өшкереп бирдем, чалпу да әйләндереп алдым[1]. (*Бераз торып.*) Бикә – бик юмарт, бик чибәр, бик уңган кеше. «Менә, Мәгъри абыстай, өеңдә эчәрсең», – дип, ярты кадак чәй, утыз тиен сәдака биреп җибәрде. Менә бу башымдагы шәлемне дә шул Шәмсеҗиһан бикә биргән иде.

Җ ә м и л ә. Шулай шул, бик әйбәт, бик ачык йөзле кеше, бик кешене таный торган кеше. Һәркемгә ал да гөл!

М ә г ъ р и. Шулай, шулай, бик һәйбәт, бик кечелекле кеше. (*Җәмиләгә карап.*) Кара!.. Күрүем дә юк, Җәмиләм җаным! Ул күзләреңә ни булган? Зәхмәт кагылдымы әллә югыйсә? Төсләрең дә бик үзгәргән.

Җ ә м и л ә. Юк, бернәрсә дә...

М ә г ъ р и. Юк дип әйтә күрмә, төсләрең тәмам үзгәргән. Алла сакласын зәхмәт кагылудан. Бер дә уйнарга ярамый. Үзеңне-үзең сылап-сыйпап йөрмәсәң, авыруың бик тиз буласы. Бер дә кичектерә күрмә, ният укырга[2] да бар, әле бүген үземнең дә җиде ният укыйсым бар. Кеше өстендә сырхау бик күп. Чынлап, Җәмилә, уен түгел. Мунчага да кер. Себерке суына да утыр. Алла боерса, бик зур файдасы тияр. Күзләреңә дә чүпрәкне ак серкәгә чылатып яп...

Җ ә м и л ә. Мәгъри абыстай, юкка борчылма, бернәрсәм дә юк, бая сез Камилә белән кычкырышкан тавышка йөрәгем кузгалып китте.

М ә г ъ р и. Һи, йөзе кара нәрсә, мәхәббәтсез! Ишектән килеп керүемә бәйләнде. Шуңар шул курыккансыздыр инде. Бер дә калдыра күрмә, куркулык койдыр. Менә иртәгә үзем дә килеп коеп китәрмен. Асраулар, йөзе каралар, бик тәртипсез булалар.

Камилә ишекне әкрен генә ачып керә.

Шәмсеҗиһан бикәне дә шул асраулары гына куркытып харап иткәннәр. Бернәрсә булдисә, күзләре тәмам аташлана. Кызым, асраулардан бик саклана күр, алар бик явыз булалар. Шакир байның да әнә бер асравы, тәмам башын-күзен әйләндереп бетереп, кече хатынлыкка...

К а м и л ә. Абыстай...

Җ ә м и л ә (*борылып*). Нәрсә?

М ә г ъ р и (*үзалдына*). Абау, мәхәббәтсез! Үзе тыңлап тора икән тагы.

К а м и л ә. Чәй хәзерләгән идем, эчәсезме?

Җ ә м и л ә. Чәеңне ник бу якка хәзерләмәдең? Кунак бар вакытта бу якка хәзерләргә дип мин сиңа ничә мәртәбә әйткән бит инде.

К а м и л ә. Абзый кайтыр вакыт җиткәнгә күрә...

Җ ә м и л ә (*Мәгърига*). Әйдә, Мәгъри астай, чәй эчәргә. (*Камиләгә кычкырып.*) Менә урындыкларның тузанын сөрт! Кушмыйча һичбер эшне дә эшли белмисез!

М ә г ъ р и. Кара әле, Җәмилә, минем бер дә чәй эчәсем килмидер иде. (*Урыныннан тора башлый.*) Әле Шәмсеҗиһан бикәдән дә хәзер генә чәй эчеп чыккан идем.

Шул арада Камилә чыгып китә.

Аннан чыккач, Вәли бай Мәфтухасына да кереп чыктым, ул да, айга-вайга карамыйча, чәй эчертте.

Җ ә м и л ә. Йә, әйдә, иш янына куш булыр, бер-икене эчәрбез әле.

Икесе дә аяк өстендә.

М ә г ъ р и (*әкрен генә*). Бая сүземне әйтеп бетерә алмадым.

Ишеккә таба баралар.

Теге дуңгыз тыңлап тора икән. Шул Шакир бай асравын, ахры, кече хатынлыкка алган шул.

Чыгып китәләр.
Сценада тын.

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

К а м и л ә ялгыз.

К а м и л ә (*кулына сөлге тотып, ишектән керә, ишекне бик дикъкатьләп яба. Көзге, урындык вә башка нәрсәләрне сөртә-сөртә, үзалдына сөйли*). Мәхәббәтсез

карчык, абыстайны әгъвәләр өчен ничек дип сөйләшеп яткан була бит! Шундый картка бармасам, ир беткән иде, ди. Пош-пош килеп, кибәк ашаган сыер шикелле мышкылдап йөри. Аның байлыгына бик исем китә; байлыкны Алла бирүче. Кәрим абзый да абыстайны алган чагында әллә нинди бай булмаган. Вәли байда самавыр куеп торган бер малай булган. Бәхетебез булса, безгә дә булыр әле. (*Көзге сөртергә тотына.*) Бераз зурайгач, кибетче булып торган. Шуннан баеган да киткән! (*Көзгегә карап, яулыкларын, кашларын төзәтергә тотына.*) Минем кай җирем абыстайдан ким дә, Гаптерахманнан абзыйның кай җире артык. Гаптерахман да – кибетче, абзый да кибетче булган. Уф! (*Урындыкка утыра.*) Чынлап, Гаптерахман мине алыр микән? (*Бераз исәпләп.*) Алыр! Ник алмасын? Гаптерахман да мине ярата, мин дә Гаптерахманны яратам! Шулай булгач, ник алмасын? «Тиздән яучы җибәрәм, абзыйдан сине сорыйм», – дип, беркөннәрдә үзе әйтте. «Сине алгач та, мин абзыйдан – байдан чыгам, үземнән кибет ачам, фатирга чыгып торырбыз», – ди. «Бик күңелле булыр», – ди. Чынлап, бик күңелле булыр иде шул, монда инде абыстайның тиргәвеннән дә тәмам туеп беттем, һәр көн орыш та талаш, аз гына бернәрсә булыр хәл юк, хәзер тиргәргә тотына, һич әйтмәгән сүз калдырмый, «Һи, җебегән нәрсәләр, миегез чергән нәрсәләр», – ди. Бу арада инде тагын бигрәк арттырды. Закир ачуын бездән ала. Әйтерсең аны без котыртып аздырган. (*Урыныннан торып, сөртергә тотына.*) Алай да инде, ул да кылмаган усаллыкларын калдырмады. Беркөнне, йомыш тапкан булып, аш өенә кергән. «Камилә, син бик матур бит», – ди. «Әнидән сине хатынлыкка алырга сорыйм», – ди. «Барасыңмы?» – ди. Әҗәткана! Өйгә керер хәле юк, суган исе белән бөтен өйне аңкыта. Сасып, тынчып йөри. Абыстай тагы шуны сизми, һаман аны яклаган була. Беркөнне мин кашык-аяк юып торганда, кергән дә миңа кулын сузып маташкан була. Эссе сулы мунчаланы алдым да битенә – чалт! (*Сөлге белән селтәп күрсәтә.*) Малаең борылды да чыкты да китте. Бигрәк мәхәббәтсез нәрсә инде. Авызында һичбер җүнле сүз юк. Бай улларына бер дә охшамаган, нәкъ жулик шикелле. Хәер, жулигын да жулик инде. Беркөннәрдә абзыйның йөз тәңкә акчасын урлап чыгып, өч көн, кайтмыйча, әллә кайларда эчеп йөрде. Әле менә тагын, өченче көн инде, кайтканы юк. Ахры, тагын берәр җирдән

---

Әгъвәләү – котырту.
Әҗәткана – мыскыллау сүзе.

сыптыргандыр. Абзый да – бик җебегән авыз. Шунда, кайтып кергәч, бер сүз дә эндәшмәде: «Алла үзе хәерле тәүфикъ бирсен инде», – ди. Ник шунда тәмам эт итеп салып измәм! Мин булсам, тәннәрен боргычлап-боргычлап чеметеп алыр идем. (*Кулы белән боргычлап күрсәтә.*) Абзый үзе йомшак; абзый да, абыстай да, мыр-мыр-мыр килеп, сүз эндәшергә дә котлары чыгып торалар. Мин, Алла боерса, балам булса, бер дә алай булмам. Ничек итеп тота белермен! (*Көзгегә килеп карый, бизәнә, күлмәк кесәсенә кулын тыгып, ирен помадасы ала. Иреннәрен буйый. Әле бер җирен, әле бер җирен көзгедән боргалана-боргалана карый.*) Гаптерахман мине алмаска, – минем бер килмәгән җирем дә юк. Беркөнне Гажби, минем ачуым килсен дип: «Гаптерахман, «мин гомеремдә асрау кыз алмыйм, бай кызы алам, миңа теләгән җиремнән бай кызларын бирәләр, дип әйтә», – ди. Бай дигәч тә бик исләре киткән, берсенең дә миннән артык җирләре юк. Кулларыннан бер тиенлек эш килми, көне-төне: «Әһик-мөһик! Әни, башым авырта (*мыскыл иткән тавыш белән, нечкә генә итеп сузып-сузып, борыннарын сузып, маңгайларын җыерып сөйли*), әни, тышка чыгасым килә! Әни, минем бу калфагым искергән! Әни, миңа гармун итәкле күлмәк тектерик», – дип кыланып, (*гайрәт белән*) аналарына иркәләнгән булып яталар. Косарсың килешләренә! Кеше ашаган аш ярамый, кеше кигән кием ярамый.

Звонок шалтырый.

Ә үзләренең кулларыннан бер тиенлек тә эш килми! (*Ишеккә таба бара-бара.*) Берсенең дә бездән артык җирләре юк. Мин үземне аларның кырыгына да алышмам! (*Чыгып китә.*)

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

К ә р и м, К а м и л ә, соңра Җ ә м и л ә.
К ә р и м ишектән килеп керә, аның артыннан К а м и л ә.

К ә р и м. Уф, уф! (*Өстеннән җиләнен сала.*) Камилә, абыстаң кайда?

К а м и л ә. Теге якта, чәй эчәләр.

К ә р и м. Кем бар анда?

К а м и л ә. Мәгъри әби.

К ә р и м (*ачуланган тавыш белән*). Ә? (*Җиләне белән бүреген Камиләгә бирә.*) Мә, менә боларны алып куй. (*Камилә ала.*) Кем бар дисең?

Камилә. Мәгъри әби.

Кәрим. Мин сезгә ничә мәртәбә әйттем: «Өйгә ят кеше кертмәгез», – дип.

Камилә. Мин кертмәскә тырышкан идем дә, тыңламады.

Кәрим. Бар, абыстаңа әйт, монда керсен.

Камилә чыгып китә.

Кәрим (*үзалдына*). Төрле яктан канымны эчәләр. Базарга чыксаң, йә мәчет, йә мәдрәсә салдырырга дип, акча сорап, теңкәмне кортып бетерәләр. Каян чыкты бу яңа укытулары да?! Бүген берсе килгән. (*Урындыкка утыра. Кесәсеннән яулыгын алып, маңгайларын сөртә.*) «Безнең күрше авылга Гали бай мәдрәсә салдырды, ысулы җәдит белән укыталар. Бар авыл баласы шунда китеп, харап булып бетәләр инде. Кәрим абзый, зинһар, шунда безнең авылга да бер мәдрәсә салып бир. Без дә укытыйк, балалар ысулы җәдиткә китеп харап булмасыннар», – ди. Моңарчы ысулы җәдитләр килеп акча сораганда: «Күзегезгә кырып салырга бер тиен бакыр да бирмим. Балаларны әллә нинди укытулар белән диннән чыгарып бетерәсез», – дип куалап чыгарадыр идем. Инде хәзер, болары килеп, гаҗиз итә башладылар. Мужиклар: «Ник балаларыбызны укытмыйсыз, күрше авыл мулласы укыта. Сез укытмасагыз, анда илтеп бирәбез», – дип әйтәләр, ди. Кайдан чыгардылар шул укуларын да! Шул уку чыкканнан бирле бөтенләй азып бетәләр. Менә, ягъни мәсәлән, безнең Закир укыды. Ә менә хәзер нишләп йөри? Кеше сүзенә карап, укыткан булып йөрдем... «Закир инде бик укымышлы булды», – диделәр. Әллә нинди калын-калын китаплар күтәреп йөрде. «Мохтасар»лар, «Сәгълүк»ләр укыды. Менә хәзер нинди тәүфикъсыз булып йөри. Менә үзем, Аллага шөкер, бернәрсә дә укымадым. Шулай да булса, әле нинди чибәр көн итеп торам. Байда да тордым, приказчик та булдым, язуына да өйрәндем. Әдрисен булсын, тилиграмын булсын, шытырдатып язам. Уф, бик эссе! Тәрәзне дә ачмаганнар. (*Тәрәзә янына барып ача да башын тыгып карана.*) Галәви! Син нишлисең анда?

Тыштан аңланмаслык бер тавыш ишетелә.

Ә! Ярый. Көрән алашаны дагалаттыңмы?

---

«Мохтасар», «Сәгълүк» – иске мәдрәсәләрдә укылган дини китап исемнәре.

Янә бер тавыш.

Ярый, ничә тиен алды?

Тавыш.

Ник алай кыйммәт birдең? Иван Фидрычта дагалатырга кирәк иде.

Тавыш.

Кашучлап бетергәч, трантаска җигеп куй! (*Тәрәзәдән башын ала.*) Һәр яктан талыйлар! Һәр яктан талыйлар! Пуф! Кара инде син аларның үнәрсезлекләрен! Җитмеш тиенлек җиргә бер сум егерме тиен әрәм иткән бит! Пуф! Шунда, бер-ике адым җиргә – Иван Фидрычка барырга иренгән бит! Пуф! (*Яндагы ишеккә таба бара.*) Пуф! Болар кайда югалдылар инде тагын? (*Ишекне яртылай ачып.*) Сиңа әйтәм! Кайда югалып беттегез инде сез? Ник монда кермисең?

Җәмилә (*тыштан*). Хәзер керәм. (*Ишектән кереп.*) Нихәл, Закирны тапмадыгызмы?

Кәрим. И, кадалып китсен шунда! Өлгерерсең әле. Пуф! Кая, тизрәк самавыр китерсеннәр, бар әйт!

Җәмилә (*ишекне яртылай ачып*). Камилә! Кая, абзаңа самавыр керт, тиз бул!

Кәрим. Бик эссе. Тирләп үлә яздым. Тәрәзәне дә ачып, бераз сулу алдырмагансыз. (*Диванга килеп «Пуф!» итеп утыра, яулык белән битләрен, маңгайларын, муеннарын актарып-актарып сөртә.*)

Җәмилә чәй хәзерли.

Ул Мәгъри карчык ни эшкә килгән?

Җәмилә. Юк, болай гына килгән. «Шәмсеҗиһан бикәләргә килгән идем дә, ди, шуннан узышлый гына, тукта, боларның да хәлләрен белеп чыгыйм дип кердем», – ди. «Закирның алай күңелсез йөргәнен ишетеп бик хафаландым», – ди, Хуҗа Баһаветдин исеменә ният бирергә кушты.

Кәрим. Һе!

Җәмилә. Бик һәйбәт, бик ипле карчык!

Кәрим. И, бик ипле!

Җәмилә. Чынлап, атасы, Закирны эзләтеп карамадыгызмы?

Кәрим. Карадым каравын да бит, карау белән генә аны кайдан табасың?

Камилә самавырны китереп куя.

Җ ә м и л ә. Мин баядан бирле үземнең кайда утырганымны да белмәдем. (*Самавыр янынарак урындык алып килеп утыра.*) Уйлый-уйлый әллә нинди уйларга төштем; бераз җылап та алдым. Бала булгач, начар булса да, кызганыла икән. Ахыры ни булып калыр инде. (*Җылый башлый.*) Мондый эшләр аслан... нәселебездә... булганы юк иде... Аллаһы Тәгалә үзе... инсаф бирмәсә... кешенең үгетләве белән генә... булмый икән! (*Җылый, яулыгы белән күзен сөртә.*)

К ә р и м. Юкка кайгырырга ярамый. Аның өчен кайгырып һич файда чыкмый. Ана сөте белән кермәгән – тана сөте белән кермәс; аңа биргән үгетне бер эткә бирсәң, ул да бераз әдәпләнер иде. Үзенә калса, шулай булып йөрүе бик килешә дип белә торгандыр. Андый эшкә керешкән кеше һичбер вакытта да кеше була алмый инде ул. Андый эш белән эштән чыгып, бар малыннан аерылып, ахырында адәм мәсхәрәсе булып, сәдакага йөреп үлгән кешенең очы-кырые юк.

Җ ә м и л ә. Ансы шулай шулаен да, алай булса да, бала булгач кызганыла икән. (*Бераз тын, чәй эчәләр.*) Соң син аның турысында бер хәбәр дә ишетмәдеңме?

К ә р и м. Ишеттем. Гаптерахман күреп калган. Үзенең йөри торган нәрсәсе булса кирәк, бер бәдбәхет, эштән чыккан нәрсә белән извозчикка утырып, поезд китәр алдыннан вокзалга таба киткәннәр. Ул нәрсәсе бер-бер җиргә китә торгандыр. Шул этен озаткач, кайтмас микән инде?

Җ ә м и л ә (*башын селкеп*). И Илаһым! И Илаһым! Үзең сабырлык бир! Бу эттән күргән җәфаларымны, бу эт аркасында чиккән хәсрәтләремне Ходай үзе генә белә. Без үзебез дә шул йомшак авыз, күптән тотып өйләндерәсе генә бар иде. Әле эшкә кереп җитсен, аннан ары да әллә кайда китмәс, дип, бу көнгә кадәр торгыздык. Кеше хәзер барысы да, яше тулып җитәр-җитмәс борын, улларын өйләндерәләр. Без авызыбызны ачып карап тордык. Күптән вакыт иде.

К ә р и м. Хәер, ансы бар. Атта гаеп булган шикелле, тәртәдә дә бераз гаеп юк түгел. Шулай да булса, инде хәзер эш узды. Үлгәннән соң тәүбә юк, дигәннәр. Хәзер, аңар ышанып, яхшы җирдән кызны ничек бирсеннәр? Начар җирдән алсаң, һаман да шул этлегендә булыр, рәткә килмәс.

Кыңгырау шалтырый.

Җ ә м и л ә. Кем бар икән?

---

А с л а н – бер дә.

Кәрим. Белмим.

Җәмилә. Хәерлегә генә булса ярар иде, эчем жу итеп китте. (*Урыныннан торып, ян ишеккә барып.*) Камилә, кайда син? Бар, әнә ишектә кеше бар, чыгып ач!

Камилә чыгып ишек ача. Бераздан, бик кызуланып, Мансур килеп керә.

Мансур. Әссәламегаләйкем!

Кәрим (*урыныннан торып*). Вәгаләйкемәссәлам! Әйдә, абый, менә монда утырыгыз.

Җәмилә. Әйдә, югарыдан!

Мансур. Юк, утырмыйм, тик сезгә хәбәр бирергә генә керүем.

Кәрим } (*икесе бергә*). Нинди хәбәр?
Җәмилә } Нәрсә?

Мансур. Закир теге күтләге белән Өфегә киткән!

Кәрим. Ә?!

Җәмилә. Һай, йөзе кара икән! Ярабби Ходаем, башы гына бетсен!

Мансур. Менә Әхмәтнең кибетчесе Ситдыйк күреп калган. «Өфегә кадәр билет алдылар» ди.

Кәрим. Ах, йөзе кара икән! Чын-чын эт икән.

Җәмилә. Булмас, ышанмыйм, китмәс, ялгыш әйтә торгандыр. Ул кадәр ерак барырга акча кайдан алсын?

Кәрим. Этлеккә калгач, ансын гына табар. Ни эшләргә кирәк инде моны?

Өчесе дә фикердә.

Мансур. Менә ни эшләргә кирәк! Өфедәге Сәгыйть Сабитов синең белешең бит!

Кәрим. Әйе.

Мансур. Шуңар тилиграм бирергә кирәк. Ул аны күрер дә яхшылык белән генә кайтырга кушар. Әгәр яхшылык белән кайтмаса, ятап белән дә кайтармый хәлең булмас.

Кәрим. Әйе шул, ә?! Шулай итәргә кирәк! Минем инде зиһенем дә таралып бетте. Бернәрсәне дә исәпли алмыйм.

Җәмилә. Соң син үзең Өфегә барсаң, ничек булыр икән? Сабитовны бай кеше диләр аны, ул аның артыннан йөрмәс бит?

Мансур. Ник йөрмәсен?

Кәрим. Йөрер, йөрми хәле юк. Дуслыкны шундый вакытта да күрсәтмәгәч, кайчан күрсәтер. Артыннан аның

---

Ятап (этап) белән кайтару – тотып кайтару.

үзенең йөрүе һич хаҗәт түгел: кибетчеләренә генә кушар. Миңа хәзер анда барып йөрергә туры килми. Бердән, расхут чыга, икенчедән, хәзер сату вакыты, эш кала. Әгәр табылмаса, аннан соң барырга да вакыт бар. Шуннан яхшысы юк. Хәзер тилиграм языйм да җибәрим. (*Конторка янына барып, язарга утыра, бер кисәк кәгазь ала.*)

Мансур урындыкка утыра, Җәмилә чынаяк җыярга тотына.

Кәрим (*каләм белән бер-ике мәртәбә кәгазьгә сызып, Җәмиләгә*). Сиңа әйтәм, бу кара савытының карасы кибеп беткән. Бераз самавырдан су агызып бирче.

Җәмилә. Кая, китер! (*Кара савытын барып алып, самавыр борыныннан су агызып илтеп бирә.*)

Кәрим (*бер-ике мәртәбә янә сызып*). Бу каләмнең очы череп, сынып беткән. Кая, икенче бер каләм юкмы?

Җәмилә. Күргәнем юк. Өйгә каләм кайтканы юк ич!

Кәрим (*Мансурга*). Абый, кая синең хәрендәшең генә юкмы?

Мансур. Ә? (*Кесәләрен капшап.*) Юк! Әй, менә бу кесәдә юк микән? Юктыр, ахры, бер кыска гына хәрендәш бар иде дә барын, өйдә калган булырга кирәк.

Кәрим. Йә, ярар инде шунда. Язуы танылса, җитәр! (*Мәшәкатьләнеп язу язып бетергәч, торып, Мансурга.*) Менә, абый, яздым. «Өфе. Сәгыйть Сабитов. Ишчи мая малчик. Если найдуш на мая лафка тилиграм давай». Ярый бит инде шулай булгач?

Мансур. Ярый, ярый, бик ярый, тульке «малчик» урынына «сын» дип куймыйсыңмы?

Кәрим. Юк, кирәк түгел, килмәгән җире булса, пышталиун үзе төзәтер әле. Мин хәзер базарга чыгам, син дә чыгасыңмы?

Мансур. Чыгам!

Кәрим (*тәрәзәгә барып, башын тыгып*). Кара әле! Галәви! Галәви! Ат китер! (*Тыштан бер тавыш килә; Кәрим, тәрәзәгә башын тыгып.*) Кем ул? Ә, Гали, синмени? Әйдә! Менә хәзер ишек ачарлар. (*Башын тәрәзәдән алып, Җәмиләгә.*) Бар, әйт, чыгып ачсын.

Җәмилә икенче бүлмәгә чыгып китә. Камилә чыгып ишек ача, Гали килеп керә.

Гали. Әссәламегаләйкем!

Кәрим.<br>Мансур. } Вәгаләйкемәссәлам!

Гали. Вакытсыз килдем, чыгарга торасыз икән.

Кәрим. Юк, зарар юк.

Г а л и. Сезгә бер кечкенә йомыш белән генә килгән идем.

К ә р и м. Нинди йомыш?

Г а л и. Сез улыгыз Закирга миннән акча барып алырга үзегез кушкан идегезме?

К ә р и м. Әллә сездән акча алдымы?

Г а л и. Кичә ул миннән, сезнең пичәтегез басылган бер язу белән килеп, өч йөз тәңкә акча алып китте. Бер, шикләнеп, бирмәскә дә уйлаган идем дә, сезнең пичәтегез булганга, ышанып биреп җибәрдем. Менә кәгазе! (*Кәгазен чыгарып күрсәтә.*)

М а н с у р. Ах, инсафсыз!

К ә р и м (*Мансурга*). Менә күрдегезме инде? (*Үзалдына.*) И Алла! Бу бала аркасында тагы ниләр күрермен икән инде! (*Галигә карап.*) Гали, сез кайгырмагыз. Әйдә, бергә кибеткә чыгыйк та шунда бирермен.

Чыгып китәләр.

Җ ә м и л ә (*ишектән кереп*). Башы гына бетсен йөзе караның! Ярабби, тончыкса гына ярар иде. (*Диванга килеп утыра.*) Җәрәхәтләдең, бала, йөрәгемне җәрәхәтләдең! Нинди гөнаһ шомлыкларым булды икән? Ярабби! Үзең коткар!! (*Җылый. Өстәлгә йөзе берлә каплана.*)

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәгыйть Сабитовның йортында зур зал, йорт әсбаблары мөкәммәл, бер тарафта – тәрәзәләр, икенче тарафта – ике ишек, каршыда – арка. Арканың аргы тарафы – коридор. Бер тарафы парадныйга, икенче тарафы йорт эченә китә, тәрәзә тарафында һәм ишеккә таба тарафларда ике диван, диваннарның алдында өстәлләр; һәр ике диванның ике тарафында да икешәр йомшак креслолар, стена буйларында стуллар. Бик мөзәйян бер зал. Гайшә бер креслога утырган. Өстәл өстендә ачык бер китап тора. Ә х м ә т, брюка кесәсенә кулын тыгып, озын-озын атлап йөри.

### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Г а й ш ә, Ә х м ә т.

Г а й ш ә. Абый, син, әйтсәм әйтим инде, бик артык консерватор.

---

М ө к ә м м ә л – тулы, җитеш.
М ө з ә й я н – зиннәтле.

Ә х м ә т (*бераз кәефе китеп*). Мин вәкыйгъны сөйлим. Дөрес, мин – либерал: яңаның яхшысын кабул итәм, булмаса – юк. Искенең дә арасында яхшылары була. Радикал булган булып, һәммә искене утка ягып бетерер хәлем юк.

Г а й ш ә (*чыраен сытып*). Синеңчә инде, алайса, ирләрнең хатыннарын шул рәвешчә кысып, дөнья йөзен күрсәтмичә, өйләренә ябып җәберләп асраулары яхшылык икән?

Ә х м ә т (*ачуланыбрак*). Кем әйтә сиңа яхшылык дип? Мин һичбер андый сүз әйткәнем юк; мин үзем дә хатын-кызга мөсават теләүчеләрдән, шулай булса да, һәр хакта ирләр белән мөсави булдылар дип, өйләрен ташлап, иренең, хатынының – барысының да урамда булуын тели алмыйм. Кем булса да, өйдә торырга бер кеше кирәктер бит? Бөтенләй өйләрен йозаклап чыгып, һәммә кешенең дә урамда гомер итүен син дә теләми торгансыңдыр бит?

Г а й ш ә (*салкын гына*). Юк!

Ә х м ә т (*бераз йомшап*). Соң, алай булгач, дәхи дә ни кирәк? Ир кеше ашарларына, эчәрләренә, көн итәрләренә кирәк булган нәрсәләрне хәзерләү өчен базарга чыгып сату итә. Яисә бер-бер җирдә ялланып хезмәт итә, тырыша. Хатын өйдә, дәрәҗәсенә карап, ашын пешерә, өен җыештыра, баласын карый. Синеңчә, әгәр мөсават булса, хатыннар сату итеп, ирләр өйдә аш пешереп, балалар карап утырырга тиешле идемени?

Г а й ш ә (*ачуланып*). Абый, бер дә минем сүземне аңламыйсың! Һаман үз сүзеңне сөйлисең дә сөйлисең. Дөньяда мөсават әллә ничә тарафтан була. Син әйткән нәрсәләр алар шулай. Бу турыда синең сүзең бик дөрес: хезмәт, мәшәкатьләрне бүлешкәндә, шул син әйткән рәвештә булырга бик тиеш. Хатын кеше балаларның анасы булганлыктан, аларның балаларын үзләре тәрбияләүләре бик яхшы. Әмма аннан башкаларында ничек? Менә җөмләдән берсе: ир кеше хатынын яратмаса, тота да аера да җибәрә, икенчене ала. Икенчесен яратмаса, аны да җибәреп, өченчене ала. Шулай итеп, меңгә кадәр алырга юлы бар. Хатыннар яратсалар да, яратмасалар да, әгәр ирләре җибәрмәсә, үлгәнчегә кадәр газап эчендә яшәп, авыруга сабышып, дөньядан китәргә кирәк. Ул гына да түгел, ирләр арасында шундыйлары бар: үзе азып-тузып, эшлексезләнеп йөри дә, (*гайрәт белән*) аның өстенә хатынының кул

---

В ә к ы й г ъ – булган хәл.
М ө с а в а т – тигезлек.
Д ә х и – тагын.

көче белән мәшәкатьләнеп тапкан акчасына карап ята. Аның белән генә дә калмый, эчәренә акча сорап, бирмәсә, кыйнап, бичараны гаҗиз итеп бетерә. Мескен, бичара хатын, иренең, балаларының ашарларына, өсләренә киярләренә хәзерләргә мәҗбүр булу өстенә, йорт хезмәтләрен итеп, балаларын тәрбияләп торып, хайван, ерткыч иренең кылган җәзаларына, җәфаларына чыдап, газап чигәргә кирәк була. Бу газаплардан котылыйм дисә, иреннән аерылып китәргә хакы юк. Никадәр тырышса да, залим, ерткыч иренең тырнакларыннан котылырга, аның кармакларыннан ычкынырга чарасы юк. Залим ире хатынының актык канын эчеп бетереп, гүргә кергәнчегә кадәр бара. Йә, әйт инде, шушы булдымы гадәләт, шушы булдымы инсаният! Хатыннар һәрбер хокукларында мөсави булмыенча торып, мондый җәберләрдән, мондый золымнардан аслан котылу ихтималлары юк.

Ә х м ә т (*бераз йомшап*). Бу сүзең дөрес.

Г а й ш ә (*һәмишә дәвам итәрәк*). Мескен, бичара хатын, иреннән тәмам гаҗиз булгач, аерыла алмам микән дип, хәзрәт янына бара. Хәзрәт тә ир кеше: хатынның – бичараның хәлен белми. «Юк белән йөрмә, бар кайт, ирең ярата торып, аерылырга йөрү яхшы эш түгел. Сабыр итәргә кирәк, әҗере күп булыр», – дип, кире кайтарып җибәрә. Бичара хатын, иренең золымына чыдый алмыенча, янә хәзрәткә бара. Бик аптыратып бетергәч, хәзрәт тә хатынның ирен чакыртып сөйли. Ире: «Минем аера торган хатыным юк! Без бик әйбәт торабыз. Китәсе килә икән, менә фәләнчә йөз тәңкә акча бирсен дә аерылсын да китсен», – дидер. Бичара, мескен, күнлекне көнгә мең бәла белән авыштырып тора торган ул хатын ул кадәр акчаны кайдан тапсын? Чарасыз яңадан шул зверь белән тора башлый. «Тәкъдир шулайдыр инде, түзми һич чараң юк», – ди дә кала. Ахырында, һәлак булып, дөньяны ташлап китә.

Ә х м ә т (*йомшаклык белән*). Дөрес шул, Гайшә, синең сүзең дә бик туры. Менә мин берникадәр кешеләрне беләм: шул кешеләрне карасаң, һичбер эшләгән эшләре күренми. Базар чатына яисә олы урамда бер урам чатына көне буе сөяләләр дә торалар. Бар эшләре – узганбарганнан көлеп, гаеп итеп калу. Үзләренең һичбер ва-

---

Г а д ә л ә т – гаделлек.
И н с а н и я т – кешелеклелек (гуманизм).
М ө с а в и – тигез.
Һ ә м и ш ә – һаман.
З в е р ь – ерткыч хайван.

кытта бер тиенлек эшләгәннәре юк, бер тиенлек сату иткәннәре юк, һичбер җирдән бер тиен көмеш килерлек даходлары юк. Шулай да дөньяда торалар. Кайсының хатыны җөйче, кайсыныкы калпакчы. Болары, шуларның тапкан акчаларын ашап, үгез булып яталар.

Г а й ш ә (*галибанә*). Ә! Менә шулай шул! Мин шуның өчен дә, мөсават кирәк, дип әйтәм дә.

Ә х м ә т (*җитди*). Ул кадәресе шулай! Фәкыйрь-фөкарәнең хатыннарының мәҗбүр икәнлегендә һич шик тә юк! Ә менә безнең байларның, бераз чибәррәк көн күрүче кешеләрнең хатыннары бөтенләй моның киресенчә: ирләренең муеннарына тәмам менеп атланганнар да ирләрен авызлыклап, боргычлап алганнар. Үзләре ничек теләде, шулай йөртәләр. Үзләренең ни йорт-җирне караудан, ни бала тәрбияләүдән, ни башкача йорт кирәкләреннән – һичберсеннән хәбәрләре юк. Кыскасын гына әйткәндә, бөтенләй чеп-чи наданнар; шулай була торып та, ирләрен үз әмерләре белән йөртергә тырышалар. Бар эшләре – һәмишә ясану да киенү, кунакка йөрү дә кунак сыйлау. Ирләренең бар тапкан малларын һич кирәкмәскә җилгә сарыф кылдырып бетерәләр. Бар маллары хатыннарының күлмәкләренә, калфакларына, дәхи, белмим, әллә нинди чаршау шикелле чачаклы-чуклы киемнәренә, әллә нинди эленке-салынкы чүпрәкләренә кереп беткәнгә күрә, ирләренең яхшы урыннарга, җәмәгать эшләренә сарыф итәргә бер тиен акчалары да булмый. Хатыннары да, гәрчә үзләре башка эшләр хакында бик надан булсалар да, мондый җәмгыять-фәлән шикелле эшләр үзләренең нәфесләренә каршы бик олы дошман идекен бик яхшы беләләр. Шуның өчен мондый җәмгыятьләргә ирләрен җибәрмәскә, андый җирләргә ирләренең акчаларын сарыф кылдырмаска бар куәтләрен сарыф итәләр.

Г а й ш ә. Абый, син инде бигрәк арттырып җибәрә башладың.

Ә х м ә т. Бер дә арттырмыйм. Менә сиңа кирәк булса, бер мисал күз алдында: Кәрим абзый белән Җәмилә абыстайның хәлләрен бик яхшы беләсең. Йә әйт, үзләренең мәгыйшәтләре файдасына шул Җәмилә абыстайның иренә нинди ярдәм күрсәткәне бар? Әйтүләренә караганда, Кәрим абзый тырышкан, ничек тә булса үзенең бетмәстөкәнмәс тырышлыгы аркасында бераз мал җыйган. Җәмилә абыстай ул җыйган малны көне-төне үзенең һич

---

Г а л и б а н ә – җиңүче рәвешендә.

М ә г ы й ш ә т – тормыш, көнкүреш.

кирәкмәгән тәкәллефләренә тарата барган. Ире бераз каршырак торса, тоткан да кычкырышкан. Бер эшне генә үзе дигәнчә эшләмәсә, атналар, айлар буенча ирен тиргәгән, сүккән. Чөнки аның аннан башка һичбер эше, һичбер кайгысы булмаган. Ире дә, сүздән туеп гаҗиз булгач, аның күрсәткән юлы буенча, машина шикелле, тик йөри биргән. Гайшә! Мин синнән бер нәрсә сорыйм: мөкяфәт дигән нәрсәнең хезмәт бәрабәрендә генә булганлыгын, шаять, инкяр кылмый торгансыңдыр бит?

Гайшә (*суык кына*). Юк!

Әхмәт. Йә әйт инде алай булса, Кәрим абзыйның шулкадәр юмартлыкларына каршы Җәмилә абыстай нинди хезмәт күрсәтте?

Гайшә. Белмим!

Әхмәт. Син белмәсәң, мин бик яхшы беләм: аның кылган хезмәте, аның Кәрим абзыйга каршы биргән бүләге – уллары Закир. Кәрим абзый никадәр мәшәкатьләр чиккән, никадәр авырлыкларны күтәргән, тырышкан. Аңа каршы Җәмилә абыстай Закирны үзенең белгәне рәвешчә тәрбия иткән. Закирның бу әхлаксызлыклары, бу тәрбиясезлекләре, бу фасикълыклары – бар да Җәмилә абыстайдан, бар да аның бала тәрбия кыла алмавыннан.

Гайшә. Йә, абый, җитәр лә инде. Бер сөйли башласаң, бөтенләй үз-үзеңне тыя алмыйсың, кызып китәсең. Бу арада сораганым да юк, ул Закир дигәнне табалармы инде бер-бер, юкмы?

Әхмәт. Кайдан тапсыннар! Тапсалар, ай ярымнан бирле монда ятмаслар иде. Чистый туеп беттем инде үзләреннән: төсләрен дә күрәсем килми. Карчыгы бигрәк мәхәббәтсез. Җен шикелле күрәм шуны. Кайчан гына күрсә, һаман минем шушы чәчемә бәйләнә.

Гайшә. Чү, җитәр, әнә үзе дә чыгып килә.

Әхмәт (*үзалдына*). Һи-и, мәхәббәтсез!

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әүвәлгеләр һәм Җәмилә.

Җәмилә (*акрын гына ишектән чыгып, урталыкка килеп*). Әле болар ятмаганнар икән. Гайшә, сәгать күпме икән инде?

---

Тәкәллеф – кыланышу, арттыру.
Мөкяфәт – бүләк.
Фасикълык – бозыклык.

Г а й ш ә (*урыныннан торып*). Әйдә, Җәмилә абыстай, урындыкка утыр. (*Урын күрсәтә.*)

Ә х м ә т (*сәгатен карап*). Сәгать 12 нче чирек булган.

Җ ә м и л ә. Бик соңга калдылар. Аллага тапшырдым инде. Сезнең шәһәрдә кич белән, шаять, тынычлыктыр? Талаулар, кеше үтерүләр булмый торгандыр бит?

Ә х м ә т. Бик тынычлык. Тынычлык булмаганда да куркырлык түгел: Гайнулла абзыйлар алар моннан ерак җирдә түгел. Аннан ары, алар бит ат белән кайталар.

Җ ә м и л ә. Шулай да инде, бик озак тордылар. Кәрим абзагыз ул бик сүз ярата торган кеше. Сүзгә керешеп киткәндер дә тик изелеп утыра торгандыр. Гайшә, сез соң әле ни эшләп утырасыз, ник ятмыйсыз?

Г а й ш ә. Безнең иртәге өчен сабак хәзерлисебез бар.

Җ ә м и л ә. Нинди сабак? Урыс сабагымы?

Г а й ш ә. Әйе.

Җ ә м и л ә. Пычагыма кирәк урыс сабагы. Урыс сабагы сабакмыни ул? Аны укып, синең бафка буласың юк. Әхмәтнең тагы зимләмир буласы юк. Бер дә килешми инде ул, урыс төсле булып, чәч үстереп йөрергә. Әхмәт, сиңа әйтәм, атаңның ничек эче пошмый ул кадәр чәчеңне үстереп йөрүеңә? Синең атаң урынында Кәрим абзаң булса иде, бер минут та тотмас иде. Хәзер кырдырып ташлар иде. Закирның да аз гына җитүле була башлады исә, бик коры тотып, хәзер алдыра.

Ә х м ә т (*ачуланып*). Җәмилә абыстай, сез бик юк нәрсәләргә бәйләнәсез. Мин чәчемне озын йөртсәм, ни зарар да, кыска йөртсәм, аннан сезгә ни файда! Закир шул чәчен алдырып йөрткәнгә шулай бик тәүфикълы булдымыни?

Г а й ш ә (*үзалдына*). Бар икән, Ходаем, тагы кычкырышалар инде. (*Кычкырып, Әхмәткә.*) Абый, зинһар, куй инде!

Җ ә м и л ә. Алай дип, син үзеңнең тәүфикълылыгың белән масайма, синең башың яшь әле, дөньяда төрле хәлләр булып китә. Закир да гомер буена алай тәүфикъсыз булып йөрмәс әле. Яшь кешедә андый хәлләр була торган эшләр алар.

Звонок шалтырый.

Менә, Алла боерса, Закирны табарбыз да, өйгә алып кайтып өйләндерербез, тәүфикъланыр.

---

Б а ф к а – бабка, рус хатын-кызы.

Г а й ш ә. Звонок шалтыраттылар. Әтиләр кайтты бугай. (*Бирге ишектән кереп китә.*)

Җ ә м и л ә. Хуш, сау булыгыз. Алай олы кешенең күңелен калдырмыйлар аны. (*Чыгып китә.*)

### ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

С ә г ы й т ь, К ә р и м һәм Ә х м ә т.

С ә г ы й т ь (*парадный тарафындагы а́ркадан Кәрим белән керә*). Гайнулла абзый ул бик кунак сыйлаучан, бик мәрт кеше. Мин Гайнулла абзыйны бик яратам...

Урындыкларга утыралар.

К ә р и м. Мин Гайнулланы ул кадәр белмим, әмма ахун хәзрәт күңелемә бик ошады. Бик ачык йөзле, кешегә бик илтифат итүчән, мәҗлеси бик хозур кеше икән. Мөфти хәзрәт әллә ничек миңа ул кадәр ошап бетмәде. Муллаларга баш кеше булгач, гыйлемлеккә гыйлем кешедер дә инде, ләкин, алай да булса, бер дә гыйлем кеше кыяфәте юк. Чапаны да, чалмасы да әллә ничек үзенә бик килешеп беткән төсле түгел. Безнең шәһәрдә, мин гласный булып торган чакта, шунда Думда писерменәрсәме булып торган бер карт морза бар иде, һәрвакыт сакалын кырып йөри торган иде. Мин үзенә ничә мәртәбә: «Гомәр абзый, инде син картайган, болай сакалыңны кырып йөрү бер дә килешми», – ди торган идем. Шулай да булса, тыңламыйдыр иде.

Ә х м ә т (*үзалдына*). Бар икән сакал үстерү дә чәч, мыек китәртү.

К ә р и м (*сүзендә дәвам итә*). Соңыннан ул, бик картайганга күрә, писерлегеннән төште. Хикмәт син, Алла бәндәсенә тәүфикъ бирсә бирә икән. Шул карт, писерлектән төшкәч, бик тәүфикъланды. Сакалларын үстереп җибәрде, мыекларын кыскартты. Бары тик тәмәкесен генә ташлый алмады. Хәзер шул кеше чапан-чалма киеп мәчеткә йөри. Шулай да булса, морза булып картайгангамыдыр, нидәндер, чалмасы белән чапаны әллә ничек үзенә бер дә килешми. Мөфти хәзрәтнең өстендә дә чалма белән чапан нәкъ шул кешенеке шикелле тора.

С ә г ы й т ь (*сәгатен алып карый да*). Гаҗәп түгел, читтән килгән кешегә, бәлки, шулай күренә торгандыр. Безнең инде күз өйрәнеп беткән. Ансы-монсы күренми.

---

Д у м д а – Думада.

Сәгать унике булып бара икән, минем иртәгә иртәрәк торып пристенгә ябага сдавайт итәргә төшәсем бар иде. Миңа рөхсәт бирегез инде, ятарга кирәк булыр. (*Урыныннан тора.*)

Кәрим. Ә, кем, Сәгыйть, теге Гыйбадулла бая Закирны кайда күрдем дигән иде әле?

Сәгыйть. Нижгарудта.

Кәрим. Ә, ул нинди җир соң инде ул? Бу Сабрания тирәсендәме?

Сәгыйть. Безнең Уфада бер җир инде ул. Сабрания тирәсендә булмаса да, бик ерак түгел.

Кәрим (*Әхмәткә карап*). Ә, кем, Әхмәт, әле безнең бер шатлыгыбыз бар. Закир табылып тора әле. Ничек соң, этиең әйтте бит әле, шул җирдә бер номерда тора, ди. Иртәгә, Алла боерса, синең белән шунда барып эзләп кайтыйк әле!

Әхмәт. Белмим, булыр микән, безнең шул иртәгә мәктәптә дәресләр башлана.

Сәгыйть. Зарар юк, ул эшендә булсын. Мин иртәгә сезгә эзләшергә кеше табып бирермен, приказчиклардан берәрсе сезнең белән барырлар. Ярый, хуш, мин ятам инде.

Кәрим. Хуш, хуш. Мин дә ятам инде. Хуш, Әхмәт, син дә.

Икесе дә кереп китәләр.

Әхмәт (*халыкка карап*). Халыкның чәч-мыекларын, чапан-чалмаларын тикшергәнче, үзеңнең борын астыңны гына тикшерсәң, мең мәртәбә артык булыр иде. (*Кереп китә.*)

Бераздан а́рканың аргы тарафыннан бер асрау чыгып, залдагы утларны сүндереп кереп китә. Сәхнәдә тынычлык һәм караңгы. Бераздан соң тәрәзәдән төшкән шәүләнең яктысында а́рка янындагы бер тәрәзәнең ачылганлыгы, тәрәзәдән ике кешенең акрынлык белән генә кергәнлеге күренә. Ике кеше, акрын гына үрмәләп, залны бер кат карап әйләнгәч, а́рканың өй эченә таба киткән тарафына кереп югалалар. Бераздан шул ук кешеләр, култык астына нәрсәләр кыстырып чыгып, тәрәзәдән качалар. Тәрәзә ачык кала. Урамда «Тот! Тот!» дигән сүзләр, свисток тавышлары ишетелә. Кыңгырау бик озак шалтырый башлый. Кешеләр, шаушу килеп, тәрәзә янына җыелалар, башларын тыгып карыйлар. Сәгыйть, аның хатыны Мәрьям, Кәрим, Җәмилә, Гайшә, Әхмәт һәм асрау тавышка йөгерешеп чыгалар. Асрау кулына лампа тоткан, һәркайсы бер кат киемнәрен чишенгәннәр. Тәрәзәдән халык кычкыра: «Өегезгә карак керде, куа киттеләр».

Сәгыйть. Ә?

---

Нижгаруд (Нижний город) – шәһәрнең түбән өлеше.

Ә х м ә т
М ә р ь я м
К ә р и м
Җ ә м и л ә
Г а й ш ә
} (*һәммәсе бергә*).
Ничә кеше?
Харап булдык!
Карагыз!
Ай Алла!
Тоттылармы?

Т ы ш т а н I т а в ы ш. Икәү!

Т ы ш т а н II т а в ы ш. Юк, бер генә.

Т ы ш т а н III т а в ы ш. Ике, ике, үзем күрдем.

Т ы ш т а н IV т а в ы ш. Култык астында шкатулкасы бар.

С ә г ы й т ь. Ә? (*Тиз генә йөгереп кереп китә.*)

Мәрьям дә аның артыннан кереп китә. Бераздан әйләнеп чыгалар.

С ә г ы й т ь. Акча шкатулкасын алганнар.

М ә р ь я м. Шкафтан минем брушкаларымны да алганнар.

К ә р и м. Күпме?

С ә г ы й т ь
М ә р ь я м
} (*икесе бергә*). Биш йөздән артык. Сигез!

Тышта тавыш куәтләнә.

К ә р и м. Палитсиягә барырга кирәк! Куарга кирәк!

С ә г ы й т ь. Ие шул, әйдәгез!

Чыга башлыйлар.

П ә р д ә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бик начар, тәбәнәк таш өй. Юешлектән диварлары каралган. Өйнең эчендә бар җиһазы – бер кушетка, зур гына бер иске такта өстәл, берничә буялмаган такта урындыклар. Түрдә бер ишек. Сул тарафта бер тәрәзә. Уң тарафта почмакта иске калай умывальник, түрдә, сул тарафта почмакта, кушетка янына өстәл куелган. Әтрафында урындыклар, өстәлнең өстенә иске гәзит кәгазьләре ябылган, аның өстендә берсе бушаган, берсе ярты гына калган кызыл башлы казенка бутылкалары, аның әтрафында кайсы зур, кайсы кечкенә стаканнар, бер-ике чынаяк чокырлары, күмәч-икмәк кисәкләре, йомырка һәм вобла балык кабыклары, берничә йомырка, арчып куелган воблалар. З а к и р берлә барысы с и г е з ж у л и к; кайсы кушеткага, кайсы урындыкларга утырганнар, җырлашып эчәләр. Байтак исергәннәр. Пәрдә күтәрелә.

Ә т р а ф – тирә-юнь.
К а з е н к а – кибеттән алган аракы.

БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Закирдан башка җиде кеше бергә җырлыйлар.

Кояш чыга да, бата да,
Төрмәм мәңге караңгы.
Көннәр, төннәр зобанилар,
И.........х!
Тәрәзәмне караулый.

Караулагыз теләгәнчә,
Мин барыбер кача алмыйм.
Бик шат качар идем дә шул,
И.........х!
Богавымны ача алмыйм.

Их сез, богаулар, богаулар,
Сез – тимер зобанилар.
Сезнең тырнаклар аякны,
И.........х!
Рәхимсез сызгалыйлар*.

Закир (*чырайларын сытып*). Куегыз шул пүчтәк җыруларыгызны, пажалысты! Тотасыз да «а...! ва...!» дип акырырга, бакырырга тотынасыз. Җырмыни ул?

Җидесе бердән. Ха, ха, ха, ха, ха!

Дәүли. Җырламагыз, бай углының кәефе китә. (*Урыныннан торып, Закирның җилкәсенә сугып.*) Ах ты, мальчишка!Ниләр сөйләп яткан була бит! Имеш, ул бай углы. Да, бай углы. Мин дә Чиләбедән берәүнең биш йөз тәңкәсен эләктереп качкач, монда бай углы булып фарсит итеп йөргән идем. (*Мыскыл итеп җырлый.*)

И бай углы, бай углы, якаларың каюлы;
Чыксаң – атың җигүле, ятсаң – урның җәюле.

Җидесе бердән. Ха, ха, ха, ха, ха!

Закир. Ну җитәр, пажалысты! Утырсагыз, яхшы гына утырыгыз. Утырмасагыз, әйдә, вон!

Җидесе бердән. Ха, ха, ха, ха, ха!

Калакай. Кара безнең бай улын, нинди гайрәт ора. Ах, килмешәк, килмешәк! Өфегә килүенә кайчан да, дөньяга килүенә кайчан? Ай, Казан жулигы! Тиз генә безне куып чыгармакчы була.

Камали белән Закирдан башкалары. Ха, ха, ха, ха!

---

*Бәетнең мөхәррире Максим Горький. Мөтәрҗиме Сәгыйть әфәнде Рәмиевтер. – *Г.Камал искәр.*

К а м а л и (*торып, бутылкадан стаканнарга сала-сала*). Ну, будет, пажалысты, күп җикеренмәгез. Әйдә, күтәрегез стаканнарыгызны. (*Кулына стаканны алып.*)

Айкап җибәр, чайкап җибәр
Шул казакның камчысын.
Мине белсәң, мине сөйсәң,
Эч калдырмый тамчысын.

Һ ә м м ә с е  б е р д ә н. Ур-ра! (*Эчәләр.*)

В а с ь к а (*зур бер шпилька шикелле тимерне өстәлгә сугып, ярты-йорты татарча*). Их! Бар иде безнеке яшь чаклар! Мин когда-то бервакытны Самарда тордым. Анда безнеке бер атаман бар. Бик злой человек был, аны төрмәгә алты елга посадили. Вот бу штуканы, төрмәгә киткәндә, ул миңа подарил. Слышь ты, бу ведь простой тимер түгел, сез моны ни думайте, што бу простой тимер. Нет, брат, бу простой түгел, моны замокның арасына тыгып каерасын да, замок сейчас, моментально – шарт! Бервакыт мин качып барганда, артымнан бер караульщик килеп җитте дә вот моннан, затылкадан мине поймал. Мин сразу әйләндем дә янагына мунын белән «тчик» берне бирдем, караульщик моментально умер!

Һ ә м м ә с е  б е р д ә н. Ну-у-у! Не может быть?

В а с ь к а (*күзләрен акайтып*). Право, валлаги, честное слово, менә моментально зигылды.

К а л а к а й. Ха, ха, ха, ха, ха! Ну, брат Васька! Алай да ярманы ярасың соң.

В а с ь к а (*бик җитди*). Честное слово, шулай, моментально зигылды.

К ә м ә й. Ну бит ул егылгандыр да, үлмәгәндер.

В а с ь к а. Кто его знает. Может, үлгәндер. Мин аны карап тормадым, тиз генә бежал.

Һ ә м м ә с е  б е р д ә н. Ха, ха, ха, ха, ха!

К а л а к а й. Ну, фчутки маладис, Васька!

Д ә ү л и (*бутылкаларны тотып карап*). Ну давай тагын бер бутылка алдырыгыз әле. Монда бернәрсә дә калмаган.

К ә м ә й. Әнә бай углына әйтегез, Казан жулигы, акчасы күптер әле, алдырсын.

К а л а к а й
Д ә ү л и
В а с ь к а
} Ну, әй, бай улы! Алдыр әле тагын берне?!

М о р т ы й. Әй, казанский сын купца, мы таргуем лафкуй, сирный спичка биз канса, вчәкуй трәпкуй!

Закир һич эндәшми, икенче якка карап утыра.

К а м а л и. Закир, йә, тагын берне алдыр әле?!

З а к и р. Ничек итеп алдырыйм? Акча юк.

Васька, кушеткага сузылып ятып, «Җизнәкәй» көе белән «үрдәк оча, каз джүгерә, зизнәкәй» дип җырлый башлый. Башкалар аның кыланганын карап көлешәләр.

К а м а л и (*килеп, Закирның кулыннан тотып, бер тарафка алып китеп, акрын гына*). Ну, тагын берне алдырт әле?

З а к и р. Ни белән алдырыйм, миндә акча юк.

К а м а л и. Ә кичәге акча кая?

З а к и р. Аңа минем тигәнем юк, әле аны ачмаган. Син боларны ничек булса да чыгарып җибәр дә, аннан ары бүлешербез.

К а м а л и. Ну, ярый алай булса, мин хәзер аларны чыгарам. (*Жуликлар янына барып.*) Ну, рибәта! Әйдә моннан китәбез.

Д ә ү л и. Тукта әле, ул кадәр ашыгып кайда барасың? Бай улы «тагын берне алдырам» ди ич.

З а к и р. Ни белән алдырыйм, минем бер тиен дә акчам юк.

К а л а к а й. Алдалый. Аның акчасы күп, мин ишеттем инде. Ул Казаннан берәүнең биш мең тәңкәсен пешереп килгән, ди.

К а м а л и. Йә, җитәр! Күп лыгырдама инде! Аның барасы җире бар. Әйдә, үзем мин сезгә бер бөтенне алып эчертәм. Әйдә, чыгыйк моннан!

Д ә ү л и. Ну, әйдә алай булса! Минем өчен фчуравна. Што монда эчтек, што анда. (*Тора.*)

К а л а к а й. Васька, әйдә китәбез казенкага, Камали, бер бөтенне алам, ди.

В а с ь к а. Што же! Әйдә!

Бары да торып чыга башлыйлар. Кәмәй байтак исергән, ава-түнә бара.

К а л а к а й (*Кәмәйнең муеныннан кочаклап*). Их, брат! Какуй син жулик. Бер-ике стакан белән бөтенләй исергәнсең.

Васька «Җизнәкәй»не җырлый башлый, башкалары да аңа кушылалар. Чыгып китәләр.

К а м а л и (*яңадан борылып кереп, Закирга*). Мин хәзер киләм, өйдән чыкмый тор.

З а к и р. Ярар.

Камали чыгып китә.

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

З а к и р ялгыз.

З а к и р (*ишеккә чирканыч карау белән карап*). Аһ, бу йөзе каралардан ничек итеп тиз генә котыласы? Боларның бу кадәр җирәнеч кыяфәтләренә карап, ничек итеп түзеп торырга кирәк? Йөзләрен күрүгә, бөтен әгъзаларым эсселе-суыклы булып, бөтенләй чытырдап китә. Ни эшләмәк кирәк? Ашарга, эчәргә, кияргә һичбер тиен акча юк. Алырга урын дисәң, ансы күптән юк. Ихтыярлы-ихтыярсыз алар белән бергә буласың. Минем болай булуыма Гайни генә сәбәп булды. (*Тәмәкесен кабызып, кушеткага барып ята.*) Әгәр ул мине монда алып килгән булмаса, мин бу хәлләргә төшмәгән булыр идем. Казанда торган вакытта, кеше өенә кереп, нәрсәдер урларга хаҗәт юк иде. Кибеттән дә, әнидән дә расходка җитәрлек акча табып буладыр иде. Урламаганда, монда акча кемнән аласың да кемнән сорыйсың? Һичбер белгән-күргән кеше юк. Булганда да, алардан алу ихтималы юк. Хәзер минем монда килгәнгә инде ике ай булды. Бу вакытка кадәр минем югалган хәбәремне һәркем ишеткәндер. Ах, йөзе кара Гайни! Мине тәмам харап итте бит! Хәер лә, анда да гаеп юк. Ул мине монда көчләп алып килмәде. Мин үзем бит аңар ияреп килдем. Ну, ияреп килдем. Аның өчен мин гаеплеме? Мин ни эшләп гаепле булыйм? (*Торып йөри башлый.*) Мин аны яраткан, мәхәббәтем төшкән, гашыйк булган һәм артыннан ияргән дә килгән. Юк! Моның өчен мин бер дә гаепле түгел. Ә соң моның өчен ул да гаепле түгел, мин дә гаепле түгел, башкалар да гаепле түгел дә, кем генә гаепле? Әтиме? Юк! Әниме? Юк! Соң кем гаепле? Кем дә булса бу турыда бер кеше гаепле булырга тиеш бит инде? Ахрысы, минем болай йөрүем, бу начар өйләрдә торуым, кеше өенә карак булып керүем бик яхшы эш түгел бит. Әгәр дә бу эш хакында мин үзем гаепле булсам, моннан котылырга миңа бер юл табарга кирәк. Аны ничек итеп табасы? «Ни булса булыр» дип, әллә Гайнине ташлап кайтып китим микән? Әмма ничек итеп кайтырга кирәк. Акча кайдан алырга? Без кичә шкатулка урладык. Моның эчендә акча бардыр, дидек. Әле ачып караган юк. Аның эчендә акча бармыдыр, ул да мәгълүм түгел. Ничек тә булса, аны тизрәк ачып карыйсы иде. Әгәр эченнән яхшы гына җитәрлек акча чыкса, һичбер нәрсәгә карамыйм, тотам да кайтып китәм. (*Кушетка янына барып чүгәләп, аның астындагы чемоданны тартып чыгара. Аны ачып, эчендәге тимер шкатулканы алып селкеп карый. Колагына китереп тыңлый.*) Эчендә

кәгазьләр кыштырдый кыштырдавын, белмим, акчамыдыр, түгелмедер? Акча гына булса ярар иде. Камали да тизрәк килмәде. Ватып карар идек. (*Шкатулканы чемоданга яңадан салып, кушетка астына тыгып куя, яңадан йөри башлый.*) Уф! Туйдым. Тәмам тую белән туйдым бу тормыштан. Бая бит үзләре минем сыем белән сыйланалар, аның өстенә үземне, оялмыйча, нинди хурлыйлар. Ни эшләмәк кирәк, берни дә эшләр хәл юк шул. Бер мәртәбә кулларына эләккәч, котылуы бик читен.

Ишектән Камали килеп керә.

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Закир, Камали.

Камали (*ишектән керә-керә*). Тегеләрдән көчкә котылдым. Бөтенне алып бирдем дә, алар акырыныпҗикеренеп эчә калдылар, мин монда килдем. Ну, хәзер ни эшлибез? Давай, бүләбез! (*Кушеткага килеп утыра.*)

Закир. Соң син ни эшләп кичә килмәдең? Мин монда төн буенча йоклый алмадым. Кайчан гына килеп тотарлар икән дип яттым.

Камали. Кайда ул монда килү, өйгә дә көчкә генә кайтып җиттем. Чүт-чүт килеп тотмадылар. Арттан ике урамга чаклы куып килделәр. Әле ярый урамда фонарьлар юк иде. Караңгы булганга күрә, күздән югалттылар. Ул вакытта ничек килмәкче буласың?

Закир. Әле ярый синең кулыңда бернәрсә дә юк иде. Минем кулда бит шкатулка, ул ярты потлап бар, арт урамга кадәр йөгердем. Аннан монда кадәр ике чакрым бар. Килә-килә җан тирләрем чыгып бетте.

Камали. Җә, аны сөйләп торуда күп файда юк, әйдә давай, бүләбез.

Закир. Син брушкаларны ни эшләттең?

Камали. Ни эшләтим, өйдә тик тора, сатмаган әле. Аларның бары берсе генә алтын, калганнары бар да пүчтәк нәрсәләр, һәммәсе дә калай гына.

Закир. Ну, алдама, пажалысты. Бигрәк ач күзле булмакчы буласың.

Камали (*ачуланып*). Нәрсәсе ач күзле? Ышанмасаң, китереп күрсәтермен. Бары да исән. Берсен дә ашаганым юк. Әйдә, күп сөйләшеп торма. Кайда, китер шкатулканы, минем эшем бар, мин хәзер китәм. Китер, ачабыз.

З а к и р (*торып, чемоданны ачып, шкатулканы алып*). Моны ничек ачабыз? Синдә ачкыч бармы?

К а м а л и. Какуй син жулик, тотабыз да ватабыз.

З а к и р. Ни белән ватасың, миндә бернәрсә дә юк.

К а м а л и. Таптың аптырарлык нәрсә. (*Шкатулканы алып, идәнгә ыргытып бәрә.*) Каналия, бик таза икән, тукта, мин балта алып керим.

Чыгып китә.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

З а к и р ялгыз.

З а к и р. Ну, эт кешеләр соң болар. Һич оялмый да бит, күзеңә чекерәйтеп карап ялганлый. «Брушканың берсе генә алтын, калганнары бар да калай», – ди. Әгәр үз күзем белән күрмәсәм, ышанган да булыр идем. Мин үзем бит шырпы яндырып карадым. Өчесе брлиант ташлы брушкалар иде. Калганнары да бары да алтын, иң арзан сатканда да – барысы җиде-сигез йөз тәңкә торырлык бар. Брлиант күргән кеше булмасам, бер хәер иде. Ну, чорт с ним, шкатулка эчендә юлга җитәрлек акча чыкса, ник кадалып китми шунда. Мин гомер буена алар белән торачак кеше түгел. Тиз генә кайтам да китәм. Шулай да булса, саклык өчен янга коралны алып куярга кирәк. *(Чемоданнан, барып, револьверын алып, кесәсенә салып, урындыкка утыра.)*

Бераздан ишектән, балта күтәреп, К а м а л и керә.

## БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Янә К а м а л и, З а к и р.

К а м а л и (*балтаны күрсәтеп*). Вот аны ача торган нәрсә. (*Шкатулканы идәнгә куеп, берничә мәртәбә балта белән суга, шкатулка ачыла. Тиз генә шкатулка эченнән шактый калын йөзәр сум итеп төргән кәгазь акчаларны кесәсенә йомарлап тыгып, шкатулка төбендә калган берничә кәгазь акча белән шкатулканы Закирга таба сузып.*) Мә, ал! Сиңа!

З а к и р (*гаять ачу белән*). Шаярма!!!

К а м а л и (*тиз генә шкатулканы өстәлгә куеп, балтаны күтәреп*). Акырма! Менә башыңа! Биргәнне ал! (*Чыгарга тели.*)

З а к и р (*тиз генә револьверын алып, Камалига таба төзәп*). Стой! Миннән тиз генә котыла алмассың! Куй балтаңны! Куй өстәлгә бар акчаны!

К а м а л и (*каушап*). Бетте, бетте, мә, мә, мә! (*Өстәлгә бер кисәк акча куя.*)

З а к и р (*һаман револьверын төзәгән көенчә*). Тагын куй! Куй барын да! Бүлеп бирәм!

К а м а л и. Мә, мә, мә! Барын да, миңа акчаң кирәкми! (*Өстәлгә барын да куя.*)

З а к и р (*һаман револьверын төзәгән көенчә өстәл янына килеп, акчаның яртысын ала да*). Әнә ал үз акчаңны да, әйдә, вон!

К а м а л и (*килеп акчаны ала да*). Бик исең киткән икән, безнең аның шикелле акчаны гына күргәнебез бар, тагы кирәк булырбыз әле. (*Ачуланып чыгып китә.*)

З а к и р. Җәһәннәмнең аръягына кадәр! (*Барып ишекне бикли.*)

### АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

З а к и р ялгыз.

З а к и р (*револьверын кесәсенә тыгып, идән буенча йөрергә тотына*). Ах, йөзе кара, оятсыз! Ниләр кыланмакчы була бит. Мине никадәр хурлыкларга төшереп, кеше өенә таларга алып баруы гына җитмәгән, мине куркытып, бар акчаны алып китмәкче була бит. Юк! Алай тиз генә алдый алмассың! (*Күкрәгенә сугып.*) Бу алай сезнең шикелле жуликларга гына алдата торган кеше түгел! Моны Закир диләр. Гайрәтне күргәч, үзенең дә коты очты, йомшады малай! Акчаны чыгарып бирергә өлгерә алмый. (*Кесәсеннән акчаны чыгарып карый.*) Һу, монда биш мәртәбә Казанга кайтып килерлек акча бар! Ну, монда бер минут та артык торырга ярамый, тиз генә сызарга кирәк. *(Әйберләрен җыя башлый. Янә туктап.)* Ах! Шул Гайни йөзе караны бер дә күңелдән чыгарып булмый, үзе болай бик матур да төсле түгел. Әллә кай төшләрен яратам шуның. Белмим, ник бу кадәр ярата торганмындыр? Киткәнче әллә тагын янына бер мәртәбә барып кайтыйм микән? Минем белән яңадан Казанга кайтырга риза булмасмы? Әллә ник бер дә шуннан аерыласым килми. Белмим, ни өчендер бер дә үзеннән мәхәббәтем суынмый. Монда торырга да инде хәзер миңа ярамый. Бу жуликлар ничек тә миңа көн күрсәтмәсләр. Тукта, тагын бер мәртәбә янына барып карыйм. Үзем белән бергә яңадан Казанга кайтырга димләп карармын, ялынырмын. Бәлки, сүземне тыңлар. Ялынып-ялварулары-

ма карамаса, аннан соң мине сөймәгәнлеге тәмам мәгълүм булыр, кайтып китәрмен. Барам да, әгәр сүземне тыңласа – иртәгә бергә, тыңламаса – үзем генә кайтырмын да китәрмен. (*Өстен киенә, кесәсеннән акчасын алып кушетка астына кыстыра да револьверын, алып, чемоданга куя башлый.*) Юк, моны үзем белән бергә алыйм әле. Камали бик ачуланып чыгып китте. Юлда бер-бер җирдә мине туры китерер өчен саклап торуы ихтимал. Бәлки, кирәк булыр әле. (*Кесәсенә яңадан тыгып, пальтосын бераз төзәткәләп.*) Ну, киттем инде. Минем сүземне, әлбәттә, тыңлар. Иртәгә Казанга бергә китәрбез. Их! Җитә күңелле көннәр! (*Чыгып китә.*)

Пәрдә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Уртачарак кына бер өй. Түрдә вә сул тарафта ике тәрәзә. Бүлмә ишеге тарафында бер такта диван, бер-ике урындык, бер өстәл. Уң тарафта ике тәрәзә арасында бер көзге, аның алдында челтәрле ак эскәтер ябылган бер өстәл. Өстәл өстендә бер шкатулка, бер-ике ислемай шешәсе, пудра савыты. Кич. Диван янындагы өстәл өстендә – шарлы, көзге янындагы өстәлдә – җиделе лампалар. Пәрдә күтәрелгәндә, Гайни диванга бик киерелеп, тәкәбберләнеп утырган, кулы белән өстәл өстенә япкан чачаклы эскәтернең чачакларын бөтергәләп утыра. Аның каршысына урындыкка, беләгенә шәлен салган көенчә, Биби карчык утырган. Гайнинең өстендә тар гына йон күлмәк, башында энҗеле калфак, Бибинең өстендә ике кат итәкле ситсы күлмәк, иске хәтфә камзул, башында яулык.

### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гайни белән Биби.

Гайни. Биби абыстай, әле минем сиңа әйткәнем юк бит: мин жидка бер сак тектерергә бирдем. «Берсекөнгә өлгерер», – диде. Бик матур буласы. Трикасының матурлыгын күрсәң, исең дә китәр, сыек зәңгәр төсле, аршыны җиде сум утыз тиен тора. (*Иңбашларын күрсәтеп.*) Бу төшләренә бик матур гержава шикелле нәрсәләр тоткан буласы. Бай марҗаларында күргәнең бардыр бит, бик матур саклар киеп йөриләр. Нәкъ менә шуларныкы күк. Берсекөнгә кил, яме? Шуны киеп, Нәфисәләргә барып кайтырбыз.

---

Гержава – кружева, челтәр.

Б и б и. Алайса, бигрәк матур була икән, алай да инде бер дә килмәгән җирең калмый. Ул кадәр осталыкны Казаннан өйрәнеп кайткансыңдыр инде. Андагы хатын-кызлар шулай бик киенеп йөриләр, ди.

Г а й н и. Шулай шул. Андагы киенүләргә искитәрлек инде. Алай да андагы бай хатыннары бер дә киенүнең кимен куймыйлар. Хатыннарын киендерә-киендерә бөлеп беткән кешеләрнең очы-кырые юк. Җөйчеләрнең һичбер буш вакытларын табып булмый. Кайсына гына барсаң да: «Эш бик күп, һич җитешеп булмый», – дип зарланалар. Бервакытны иптәш кызым Нәгыймә белән аршыны дүрт тәңкәгә икебезгә пар тирәкле асыл алган идек, шуны тектерер өчен бер көн эчендә биш җөйчегә җиттек, «эшебез күп» дип, һичберсе дә алмадылар. Берсе әйтә: «Киләсе кече атнага Локман хаҗиның как-төш мәҗлесе булачак, узган атнаны егерме сигез ат белән килен төшерделәр. Шул «как-төш мәҗлесенә кодача булып барырга кирәк» дип, Вафа хаҗилардан биш асыл күлмәк керттеләр. Әле бары икесен генә тегеп бетердем, тагын өч күлмәк тегәсем бар әле», – ди. Бүтәннәре дә шулай ук. Кайсы: «Фәлән көнгә Нәгыйм байда бүләк багу мәҗлесе булачак. Шуңа өлгертергә алган эшләрем бар», – ди. Кайсы: «Әллә кем байлар шушы арада килен сөя баралар[3]. Шуңа өлгертергә ике хәтфә күлмәк бирделәр», – ди. Шулай итеп, көне буе йөреп бер күлмәк тегүче таба алмадык.

Б и б и (*бик гаҗәпсенеп*). Йа-а... Бар икән киенү! Ул кадәр үк булмас ла инде?! Син дә бераз арттыра торгансыңдыр?

Г а й н и (*җитди*). Дөрес[е] шулай. Әйтсәм, ышанмассың менә! Шунда бер җөйче әйтте, хәтеремнән чыккан, бер ел эчендә йөз иллеләп асыл күлмәк тектем, дидеме, әллә йөз кырыкмы, диде. Андагы бай хатыннарының киенүенә һич чама да юк инде. Баераклары бер кигән күлмәкне икенче кияргә хурланалар. Шулай да булса, үзләренә ирләренең бер дә исе китми. Менә дигән тәкъвалары да фатирга бирәрне алып...

Б и б и. Алайса, алар катында безнең мондагы бай хатыннарының киемнәре чүп урынына да тормый торгандыр?

Г а й н и. Кая ул! Мондагыларны авызга да алып сөйләргә ярамый. Безнең мондагы бай хатыннарының киемнәре киеммени ул? Безнең мондагы бай хатыннарының бар киемнәре аларның бер калфакларына да тор-

---

Т ә к ъ в а – изге, суфи, диндар.

мый. Мыскалын егермешәр тәңкәгә алып, егермешәр мыскалдан калфаклар эшләтәләр. Исең китеп, шаккатып карап торырсың.

Б и б и. Әле мин беркөнне Рабиганың киемнәрен күреп шаккаткан идем. Алайса, ул да алар янында чүп кенәдер.

Г а й н и. Син кайсы Рабиганы әйтәсең, теге Әмәти Рабигасынмы?

Б и б и. Әйе.

Г а й н и. Ник, ул хәзер мондамыни?

Б и б и. Күптән кайтты инде ул. Аның Казаннан кайтканына хәзер биш ай бардыр инде. Аны Чүпрәк Гали улы Саттар сөяркә итеп тота бит. Алай да Рабига, үзен печә, ди, соң. Беркөн ямщик белән кайтканын күреп исем китте. Киенгән, ясанган, бөтенләй үрәгә каткан. Әйтерсең бер купис хатынымыни?!

Г а й н и. Мин дә шулай киенергә бик яратам. Исмәгыйль килсә, аңа бер сары батинкә алдырыйм әле. Бу батинкәм искергән; тагын бер батинкәм бар барын да, анысын яратмыйм. Әллә нинди прастуй төстә.

Б и б и. Карале, ә, кем, Гайни! Исмәгыйль дигәч, исемә төште. Менә син, ә, картаюым җиткән, ахры, онытып китәрмен икән. Миңа бая Исмәгыйль очраган иде. Бүген монда, сиңа киләм, диде. Миңа кереп әйтергә кушты. «Гайни», – ди дә үлә дә китә инде. Бөтенләй авызыннан сулары килә. Ә, шуны да әйтим әле: Исмәгыйльне аталары өйләндермәкче булалар, ди. Рәхим байның кызына яучы йөртәләр икән. Яхшы кара: өйләнгәч, беразга синең кулыңа эләкмәс. Кулыңа төшкәндә имеп кал, мине дә буш калдырмассың. Өйләнгәч, атасыннан чиерткән акчаларын сиңа бик яудырмас. Мин һаман синең өчен тырышып йөрим әле. Тагын бер-ике егет кулыма төшәр төслерәк тора.

Г а й н и. Исмәгыйльнең атасы байлыкка байдыр инде аның. Әллә кулына акча бик төшмиме икән? Бик саранланып маташа. Бик тиз генә чишенеп бетми. Минем өчен әүвәлрәк Закир яхшы иде. Бар тапканын китереп аударадыр иде. Соңгы көннәрдә атасы касса янына якын китерми башлады. Хәзер инде эттән дә ярлы булып калды.

Б и б и. Әле ул Закир мондамыни?

Г а й н и. Монда булмый, кая китсен! Бер тиенгә мохтаҗ булып йөри. Казанда вакытта акчасы беткәч, качып котылыйм дип, монда килдем. Алай да котыла алмадым. Дегет лагуны шикелле, артымнан калмыйча, тик тагылып йөри: «Миңа бар, сине хатынлыкка алам», – ди.

Б и б и. Соң, ник бармыйсың? Алай бик яраткач, бару кирәк иде!

Г а й н и. Барам менә! Мин аның нәрсәсенә кызыгып барыйм? Акчасы дисәң – акчасы юк, кыяфәте дисәң – кыяфәте юк. Бигрәк сөйкемсез нәрсә. Мин аның белән йөрсәм дә, акчасы өчен генә йөрдем.

Б и б и. Сүз бозау имезер, дигәннәр. Утыра торгач, бик озак утырып киттем. Ярый, хуш, кайтыйм инде. Чәй дә эчертмәдең.

Г а й н и. Чынлап, Биби астай, исемдә дә юк. Утыр әле, самавыр куям, чәй эчеп китәрсең. Хәйри өйдә юкка күрә, самавыр куярга иренеп утырадыр идем.

Б и б и. Юк, юри генә әйтәм, бер дә эчәсем килми, кайтам инде. Бик кичкә калдым. Хәйриең кайда китте соң?

Г а й н и. Бер-ике көннән бирле бер дә рәте юк, эчеп йөри. Бая кайтып, баш төзәтергә дип, акча алып чыгып киткән иде, шуннан бирле кайтканы юк.

Б и б и. Ярый, хуш, кызым! Матурлыгың бар вакытта, яшь чагында үзеңнең кадереңне белеп кал: картайгач, илтифат итүче булмас. (*Урыныннан торып, шәлен бөркәнә.*)

Г а й н и (*урыныннан торып*). Йа, Биби астай, осталыгың!

Б и б и. Бер дә уйнап әйтмим, чынлап әйтәм: мин күпне күргән инде. Ирләргә бер дә ышанма. Ирләр алар яшь чагында гына ялманып йөрергә яраталар. Картайгач, аннан ары йөзеңә дә әйләнеп карамыйлар. Ярый, хуш, сау бул! (*Чыга.*)

Г а й н и. Хуш, Биби астай! (*Озата чыгып китә.*)

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Г а й н и ялгыз.

Г а й н и *(ишектән җылмаеп, көлә-көлә кереп, бармакларын шартлатып).* «Ләллә, әлләли, лилә, лилилә». *(«Кек уок»ны көйли, биегән шикеллерәк кылана. Бүлмәне бер мәртәбә әйләнеп, көләч йөз белән.)* Һһ! (*Көзге каршысына килеп, калфагын төзәтә, чәчләрен сыпыра, бизәнә.*) Иһи, һи, һи! Чынлап, Биби әби әйтсә дә, әйтмәсә дә, бик чибәр бит? Мине нинди бай уллары да яратыр; бай кызларының да бер дә артык җирләре юк: авызларын җәлпәйтәләр дә шулай итеп изелеп торалар. (*Мыскыл итеп күрсәтә.*) Биби әбидән сорамадым: «Исмәгыйльнең аласы кызы нинди нәрсә?» – дип. Ул да шул бер изелгән арыш боламыгыдыр әле, бер дә артык җирләре булмас. Мин бай кызларын бик күп күргән инде. Берсенең дә искитәрлек җирләре юк, Казанда вакытта кызлар җыенына гармун

уйнарга дип чакыралар иде. Шул чагында бигрәк аерымачык күрәдер идем. Үзләре башларына энҗеле калфаклар кигән булалар. Никадәр алтын-көмеш нәрсәләр тагалар. Шулай да тәмам изелеп, җебеп утыралар. Андый булгач, ирләре аларны ничек яратсын? Ирләр алар куштан булганны ярата.

Ишек шалтырый.

Әһә, Исмәгыйль килеп тә җитте. Аның кагуына охшый. Ул шулай акрын гына, йомшак кына итеп, оялып кына кага. Эш пеште. Бүген батинкә алырга акча сорыйм. Иртәгә брушка алдырам. Мин дә бай кызлары шикелле киенергә тотынам. (*Чыгып китә.*)

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Г а й н и белән З а к и р.

Г а й н и (*Закирның артыннан ишектән кереп, ачуланып*). Бу вакытсыз вакытта кем йөри икән дисәм, син икәнсең әле.

З а к и р (*йомшак кына*). Ник, вакыт әле шулкадәр үк соңмыни?

Г а й н и (*арты белән илтифатсыз гына торып*). Вакытның күпме икәнен беләсең килсә, сәгатеңне кара.

З а к и р (*үзалдына*). Бик карар идем дә, күптән очты шул инде ул. (*Гайнигә.*) Башка вакытларда моннан да соң килә торган идем, бер сүз дә әйтми торган идең бит.

Г а й н и (*ачуланып йөрергә тотынып*). Ул вакытларда әйтмәгән булсам, менә хәзер әйтәм, алай миңа вакытлы-вакытсыз килеп борчып йөрмә! (*Үз-үзенә.*) Ничек итеп моннан тиз генә котыласы?

З а к и р (*үз-үзенә*). Моңа бүген әллә нәрсә булган. Әллә бер-бер кеше мине яманлады микән? (*Гайнигә.*) Гайни, сиңа бүген ни булды, ә? Әллә миннән күңелең суындымы?

Г а й н и (*һаман ачуланып*). Суынды шул, суыну гына түгел, тәмам килешләреңнән туеп беттем инде.

З а к и р (*аптырап*). Гайни, зинһар, әйтсәнә, минем кай җиремне килештермисең? Мин сиңа алай миннән туярлык ни эш эшләгәнем бар?

Г а й н и (*һаман ачуланып*). Ник туймыйм? Иртә кеше тормас борын да син килеп керәсең. Кеше яткач та син йөрисең.

З а к и р (*ялынган кыяфәттә*). Гайни, зинһар, алай ачуланма әле, мин хәзер сиңа бер шатлык хәбәр әйтергә килдем.

Г а й н и (*ачуланган көенчә*). Нинди хәбәр?!

З а к и р (*һаман бик йомшаклык белән*). Хәбәр дип, хәбәр дә түгел инде. Мин Казанга кайтмакчы булам.

Г а й н и (*бераз ачылып*). Чынлапмы?

З а к и р. Чынлап кайтам, сине дә үзем белән бергә алып кайтырга дип, сиңа әйтергә килдем.

Г а й н и (*янә ачуланып*). Кемгә?

З а к и р. Сиңа.

Г а й н и. Тапкан икәнсең кайтачак кеше, кайтты, ди, кайтмый ни! Яхшы түгел. Синең артыңнан ияреп йөрергә кирәк!

З а к и р (*тәмам ялынган тавыш белән*). Гайни!!! (*Гайнинең кулын тотмакчы була.*)

Г а й н и (*кулын тартып алып*). Кит аннан, кит! Миңа кул якма, кайтасың булса, Казаныңа кайт та чәнчел, кадал!

Ишек шакылдаткан тавыш ишетелә.

Минем гомеремдә кайтасым да юк һәм синең белән торасым да юк!

З а к и р (*янә ялынган тавыш белән*). Гайни!

Гайни ишектән дулап чыгып китә. Закир кулларын сузган көенчә кала.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

З а к и р ялгыз.

З а к и р (*өмидсезлек илә урындыкка килеп утырып*). Ух! Инде нишләмәк кирәк! Бу хатын-кызлар ник бу кадәр тәкәббер булалар икән? Ни өчен кешенең хәле начар икәнлекне күреп, бераз шәфкать кылмыйлар икән? Һи! Әгәр Гайни белсә иде минем йөрәгемдә нинди мәхәббәт ялкыннары кайнаганын, әгәр белсә иде минем үзе өчен җанымны фида кылырга хәзер икәнемне! Нишләмәк кирәк, белеп җиткерә алмый шул.

Ишекнең аргы ягыннан акрын гына сөйләшкән бер ир кеше тавышы ишетелә.

(*Закир кинәттән сискәнеп китеп, күзләрен зурайтып ачып.*) Бу нинди ир кеше тавышы, әллә юк исә чыннан Гайни миннән күңелен суытканмы? Әллә Гайни башка бер кешегә мәхәббәт куйганмы? Мөмкин түгел, ышанмыйм. (*Урыныннан торып, ишек янына килә.*) Гайни

миңа һичбер вакыт хыянәт кылмас. (*Ишеккә колагын куя, бераз тыңлап, кинәттән төсләрен үзгәртеп.*) Ә? «Исмәгыйль җаным?» – бу ни дигән сүз? Һич мөмкин түгел. Гайни миннән башка кешене сөймәскә тиешле һәм сөймәс! Мин моңа ышанмыйм. (*Яңадан колагын куя, яңадан сискәнеп.*) Ах! Харап булдым! Алдандым! Алдандым! Гайни мине сөя дип алдандым. (*Бик кызуланып, йөрәгенә чыдый алмыйча йөри башлый.*) Бу вакытка кадәр мине алдап кына йөргән икән! Юк исә нинди авыз белән әйтмәк кирәк сөйгән кешене «дуңгыз» дип? Ни эшлим инде? Ах! Бу йөзе караны ни эшлим? Тәмам бар гәүдәмне ботарлап ташлыйсым килә. (*Якаларын тарта.*) Ах! Алдандым, алдандым! Тәмам алдану белән алдандым! (*Яңадан ишеккә килә. Тыңлый, яңадан дәхи дә артыграк агарып.*) Ах! Ах! Ах! (*Күкрәген тотып.*) Ах! Ни эшлим? (*Урындыкка утырып.*) Өмидем тәмам бушка китте бит! Оялмыйлар да! Чут-чут үбешәләр. (*Гайрәт белән урыныннан торып.*) Юк! Минем моңа тәхәммел кылыр хәлем юк! Ул Исмәгыйль дигәне кем булса да булсын, әлбәттә, үтерәм! Минем белән минем бөтен җаным шикелле сөйгән кеше арасына килеп кермәсен! (*Револьверын ала.*) Мин аңар җәзасын татытыйм әле! (*Ишеккә таба бара.*) Юк! (*Ишеккә килгәч, туктый.*) Монда ул кеше гаепле түгел, мәхәббәте төшкән дә килгән. Монда гаепле кеше – Гайни! Йөзе кара, падлис! Ул бит бу вакытка кадәр: «Мин сине сөям», – дип, мине алдалап йөрүче. Әле хәзер ул кешегә әйтә: «Исмәгыйль җаным! Бер-бер җиргә генә барып тор, Закир дуңгызны гына озатыйм, аннан ары керерсең», – ди. Хәзер серләр тәмам мәгълүм булды. Мине эштән чыгаручы, мине юлдан чыгаручы шушы фахишә Гайни икән. Мин бу көнгә кадәр аның ялганлап, алдалап сөйләгән сүзләренә, үзен гыйффәтле итеп күрсәткән кыланышларына алданып йөргән икәнмен. Баштан бирле миндә асла мәхәббәте булмаган, бары тик акчамны алыр өчен генә минем башыма җиткән икән. Минем башыма җиткән шикелле, инде хәзер ул кешенең башына җитмәкче, аның кесәләрен бушатмакчы була торгандыр. Юк! Хәзер алай бушаттырмабыз инде. Син безнең башка җиткәнче, тиздән без синең башыңа җитәрбез! (*Револьверын кесәсенә тыга.*) Ах, ана дуңгыз! Әллә кем булган булып, күкрәкләрен киереп сөйләп яткан була бит. Косарсың килешенә. Хәзер капкынга төштең инде! Бик тиз

---

Тәхәммел кылу – чыдау.
Гыйффәтле – саф, намуслы.
Асла – бер дә.

генә миннән котыла алмассың! Мин бүген сине җәһәннәмгә җибәрмичә моннан китмәм. Ах, йөзе кара!..

Ишектән бик җиңелләеп Г а й н и керә.

## БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Г а й н и белән З а к и р.

З а к и р (*ачуын яшерергә тырышып, шулай да булса, бераз калтыранганрак тавыш белән*). Ни булды сиңа, йөзләрең бик ачылган?

Г а й н и (*ачуланып*). Ник, монда син бар дип, әллә көлми дә торыйммы? Җыларлык эш булганы юк әле.

З а к и р (*ямьсезрәк итеп*). Кемең килгән анда, яңа белешләреңме?

Г а й н и (*һәмишә ачулы*). Кем булсын, әни. Син барга күрә кермәде. Күршеләргә кереп китте. Бар кеше дә синең шикелле рөхсәтсез кеше өенә басып кермиләр.

З а к и р (*аяк тибеп*). Ялганлама! Йөзең кара, бәдбәхет! Әни дип ялганлап яткан буласың тагы, килгән анаң! Кем килгәнен белмидер идем, ди.

Г а й н и. Белсәң, бик исем китә! Йә, бар! Күп сөйләп торма монда, үкчәңне күтәр! Моннан соң следең дә булмасын! Кешене хатының дип белдеңмени? Сүгеп яткан буласың! Бар моннан, вон! Бер минут та торма!

З а к и р (*бармакларын селкеп*). Мине куа алмассың, падлис! Беләсеңме, син миңа ничә мең тәңкәгә төштең? Ә хәзер, минем акчам беткәч, минем урыныма өеңә икенче кешеләр китерә башладыңмыни инде?

Г а й н и. Җикеренмә миңа! Минем үз йортым! Синең өең түгел. Үз йортым булгач, миңа теләсә кем килер, теләсә кем китәр. Анда синең эшең булмасын! Бар чык моннан! Бар, бар, бар! (*Закирны төрткәли.*)

З а к и р (*ачуын арттырып*). Якма кулыңны! Сөйлисе сүзең булса, болай гына сөйләш, мине алай бик тиз генә төрткәләп чыгара алмассың. Син бит, йөзең кара, миңа монда никадәр акчалар тоттырып китерүче!

Г а й н и (*мыскыл итеп*). Харап икән!

З а к и р. Син бит, падлис: «Өфедә минем этиләр бар, анда баргач, сиңа барырмын, шунда никах укытырбыз», – дип, мине алдалап алып килүче.

Г а й н и. Мин алдамадым сине, син үзең дегет лагуны шикелле тагылып йөрүче. Сиңа соң эт барсынмыни? Синең шикелле күмерче чирмешләр монда бетмәгән. Мин, сиңа барганчы, күмерче чирмешкә барырмын!

З а к и р (*Гайнигә таба гайрәт белән килеп*). Нәрсә?..

Г а й н и (*артка таба чигенеп*). Килмә кеше өстенә! Куркытырмын дип белә торгансыңдыр? Мин синең шикелле жуликларны бик күп күргән! Йә, бар! Бар! Күп телеңә салынып торма, яхшылык белән чыкмасаң, мин сине ничек чыгарырга белермен. Ятап белән кайтасың килә торгандыр!

З а к и р. Кычкырма миңа! Кулыңнан килсә, бар, чыгар!

Г а й н и. Чыгарырмын шул!

З а к и р. Чыгарырсың!

Г а й н и. Чыгарырга калгач, сүземдә торырмын, чыгарырмын. (*Ишеккә таба бармакчы булып, бер атлый.*)

З а к и р (*тиз генә ишеккә аркылы төшеп*). Стой! Мин сине җәһәннәмгә җибәрмичә, синең башыңа җитмичә моннан чыкмыйм!

Г а й н и (*ачуланып*). Хәзерләгәннәр иде ди сиңа баш! Җитмисеңме? (*Тәрәзәгә таба бармакчы була.*)

З а к и р (*артыннан барып җитеп, кулыннан тотып, идән уртасына таба җилтерәтеп җибәреп*). Бәдбәхет! Үз башым бетсә бетәр! Син бәдбәхетнең дә башы бетсен! (*Револьверын чыгара.*)

Г а й н и (*бик ачы аваз белән*). Караул!

Револьвер шартлый, Гайни «аһ!» дип егыла, Закир, йөгереп, ишеккә бара, бер аягын тышка атлый, яңадан кире чигенеп, йөгереп, бүлмә ишегеннән кереп китә; чалтыр-чалтыр итеп пыяла ватылганлыгы ишетелә.

П ә р д ә.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Закирның бүлмәсе. Икенде-ахшам арасы. Пәрдә күтәрелгәндә, сәхнәдә бер кеше дә юк.

### БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

К ә р и м белән Җ ә м и л ә.
К ә р и м белән Җ ә м и л ә акрын гына, як-якларына карана-карана, ишектән керәләр.

Җ ә м и л ә (*акрын гына*). Ярабби Ходаем! Үзеңә тапшырдым!

К ә р и м. Монда бер кеше дә юк, ахры.

Җ ә м и л ә (*өстәлгә таба килеп*). Атасы! Без монда ялгыш кергәнбездер, ахры.

К ә р и м. Юк, ялгыш булмаска кирәк, мин урыстан сорадым. Шунда тора, диде.

Җ ә м и л ә. Син алай дияр идең дә, атасы, (*өстәлгә төртеп күрсәтеп*) менә бу нәрсәләр бер дә Закирныкы булырга охшамый: әллә никадәр стаканнар җыелган – без ялгыш кергәнбездер. Закир шулкадәр үк эшләр кылыр микәнни?

К ә р и м. Белмим, әнкәсе, белмим, ул кадәр эшләрне кылмаска тиеш иде дә бит, әмма нихәл итмәк кирәк, – безнең бәхетсезлегебезгә каршы, шулай булган инде.

Җ ә м и л ә (*бер урындыкка утырып*). И бала, бала! Тәмам харап булган икәнсең. (*Битләрен яулык белән каплап.*) Синең аркаңда тагы да нинди хурлыклар күрәсебез бар икән? Йа Алла! Миңа бу кадәр хурлыкларны күрсәткәнче, мине бу рәвештә рисвай иткәнче, җанымны гына алсаң, мең өлеш артык булган булыр иде. И Аллам! Бала аркасында нинди хурлыклар күрәм бит! Мондый халык арасында йөзебезне кара кылырлык рисвайлыклар, мондый начарлыклар бөтен нәселебездә дә һичбер вакытта ишетелгәне дә, күрелгәне дә юк иде.

К ә р и м (*бер урындыкка утырып*). И Алла! (*Башын түбән салып утыра.*)

Җ ә м и л ә (*өстәлдәге чуалып яткан нәрсәләргә карап*). Кара инде бу хурлыкларны?! Кара инде бу рисвайлыкларны?! И Раббым?! Бу бала аркасында миңа тагын да нинди хәсрәтләр күрсәтәчәк! (*Җылый.*)

К ә р и м (*бераз тынычландыру нияте белән*). Анасы, юкка күз яшьләреңне түгеп, үзеңне-үзең борчыма. Беткән, булган эш, син җылаганга карап кына кире кайтмый инде ул. «Алла үзе инсаф бирсен», – диген. Ходайдан тәүфикъ сорарга кирәк. Тәкъдир шулай булгандыр инде. Түзми һичбер чара юк. Әгәр кешене яхшы итү безнең кулдан килә торган булса иде, без инде аны алтыннан ясап куйган булыр идек. Ни эшләмәк кирәк соң, ихтыяр безнең кулда түгел. Коры җылау белән генә эш бетми, Алла үзе тугры юлга салсын, Алла үзе инсаф бирсен, Алла үзе тәүфикъ бирсен дип, Ходайдан телә.

Җ ә м и л ә (*һәмишә җылаган тавыш белән*). И атасы! Син бер дә белмисең минем хәлемне. Минем ул бала өчен түккән күз яшьләрем, ул бала өчен теләгән теләкләрем, ул бала өчен биргән нәзер-ниязларым бер Ходайның үзенә

---

Н ә з е р - н и я з – дога кылырга сорап бирелгән әйбер, акча.

генә мәгълүм. И бала! Җәрәхәтлисең минем йөрәгемне! Шул баланы уйлый-уйлый йөрәгемә кан савып бетте инде. Бичараның, начар өйләрдә торгач, ашау-эчүенең, кигән киемнәренең дә рәте юктыр инде. Мескен, бигрәк бәхетсез бала икән шул. И бала, бала! (*Җылый.*)

Кәрим. Җылама, анасы, җылама! Син җылаганга гына карап төзәлмәс инде. Үзе дә бер дә аңлы, фәһемле, кеше сүзен тыңлый торган бала түгел икән. Аның өчен хафаланып һичбер файда чыкмас. «Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән кермәс», – дигәннәр. Аңа биргән үгетне бер эткә бирсәң, ул да бераз инсафка килер иде. Моның асла колагына да керми, тыңламый да. Әгәр аның башында бераз гына мие булса, үзе дә белергә тиеш. Безнең аңар бер-бер каты сүз әйткәнебез бармы, йә булмаса безнең аңар бер-бер төрле кимчелек китергәнебез бармы? Юк бит.

Җәмилә. Кая ул инде андый кимчелек китерү?! Кулдан килгән кадәр ата-ана ул һәрвакытта баланы кеше арасында кеше итеп күрсәтергә тырыша.

Кәрим. Җә, хуш, әйт инде, моның болай итеп йөрүе килешәме? Җә, карап кара инде, монда ул нинди рәхәт күрә ала? Өйдә бит аның ашарына хәзер, эчәренә хәзер, өстенә-башына, ни кием дисә, шул хәзер, утырып йөрим дисә, ат хәзер. Шулкадәр нигъмәтләрне ташлап, мондый сасы, караңгы, тынчык бер җирдә яту ярыймы инде аңар? Әгәр яхшы гына йөрсә, ашап-эчеп, исереп, эштән чыгып йөрмәсә, без бит инде аны күптән тотып өйләндергән булыр идек. Бик чибәр җирләрдән кыз биргән булырлар иде.

Җәмилә. Бирәләр иде шул. Менә Хәлим хаҗилар ике куллап кызларын бирергә торалар иде.

Кәрим. Шул шул. Анда бер дә баш юк шул. Мие черегән аның. Аны хәзер шул инде бик яхшы басып, эшкә кушып, өстеннән каравыл тормыйча, һичбер рәткә килә торган түгел. Алып кайтып, инде аны бик ныклап эшкә кушарга кирәк.

Җәмилә. Бу соң үзе кайда китте икән? Кайтмый. Көн дә тәмам караңгыланып бетте. Монда утыруы да куркыныч. Мондый җирдә, Алла сакласын, акчаңны талап, үзеңне суеп ташлаулары да ихтимал. Бер дә җүнле җир булырга охшамый бу.

---

Фәһемле – зиһенле, төшенә торган.

К ә р и м. Моның җүнле җир түгел икәнлеге күз алдында инде, сөйләп тә торасы юк.

Җ ә м и л ә. Юк, уен түгел, атасы, китик без моннан. Мин бик курка да башладым. Аллаһы Тәгалә хәвефеннән-хәтәреннән үзе сакласын.

К ә р и м. Китәрбез китүен дә, тагын яңадан кайчан килербез соң монда? Ничек тә булса, инде аны алып, тизрәк Казанга кайтып китәргә кирәк. Юк исә инде кешедән дә оят. Ай ярымнан бирле кеше өстеннән ашап ятуы бик күңелле эш түгел. Сәгыйтьнең йөзенә карарга да ояла башладым инде.

Җ ә м и л ә. Хәзергә кайтып торыйк та, бераздан соң, яныбызга иптәш алып, яңадан килербез.

К ә р и м. Ярый алайса, шулай итик. (*Чыга башлыйлар.*)

Җ ә м и л ә (*түшәмнәргә, диварларга карап*). Йа Раббым, Ходаем! Үзең сакла! Мондый урыннарны дошманыма да насыйп итмә. И Раббым! Үзеңә тапшырдым. Бигрәк зиндан төсле күренә. Әллә ни эшләп йөрәкләрем бик сикерә, бер-бер хәл генә булмаса ярар иде.

Чыгып китәләр. Сәхнәдә тынычлык вә караңгылык, берничә дәкыйка буш.

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

К а м а л и ялгыз.

К а м а л и (*ишектән акрын гына кереп, як-ягына карап*). Аһа! Безнең матур егет ишеген дә бикләргә оныткан. Бигрәк яхшы булды. Кулына акча төшкәч тә, өлгерә алмый, малай! Гайние янына йөгерә-йөгерә бара. Бер кергәч, тиз генә чыга алмас әле. Түлке, белмим, акчасын монда калдырды микән? Бик аңгыра түгел ул. Бар акчасын да берьюлы тотып бетермәс. Беразын монда калдыргандыр әле. (*Эзләнә.*) Түлке кая куеп калдырды икән? Бик караңгы. Бернәрсә дә күреп булмый. Теге брушкаларны ике йөз тәңкәгә биеттем. Бик яхшы булды. Бераз кутить итәрлек эш бар. Түлке хәзер ярамый әле. (*Һаман эзләнә.*) Шайтан нәрсә! Бик нык яшергән булырга охшый. Фчуравна мин ул акчаны барыбер анда калдыр-

Д ә к ы й к а – минут.
Ф ч у р а в н а (все равно) – барыбер.

мам. Казан жулигы, монда килеп, алай безнең Өфе акчалары белән мутайт итмәсен әле. Мальчишка, күтләк артыннан ияреп, ата-анасын ташлап, байлыкларының кадерен белмичә, монда килеп йөри. Безнең, ичмаса, һичбер торыр урыныбыз юк, якын күрә торган бер агай-энебез юк. Кулга акча төшкәндә, рәхәтләнеп тибеп, бераз күңел юатып калмасак, башка һичбер шатланыр урыныбыз юк. Безнең күргән кадерсезлекләрне бер эт тә күрмәс. Безнең күргән кыенлыкларга адәм түгел, эт тә чыдамас. Аз гына нәрсә белән тотылып әләктең исә, чистый изеп бетергәнче үзеңне кыйныйлар. Әле тик бары шул инде, көне-төне эчеп, исереп йөрү аркасында гына үз-үзеңне белешмичә йөрисең. (*Чемоданны актарып бетерә.*) Моның эчендә дә юк. Кайда булса да башка бербер җиргә куйган булырга кирәк. Ну, дуңгыз нәрсә соң үзе дә, этнең эте инде. Револьверын да үзе белән бергә алып киткән. Бая чистый котымны алды бит. Үтерә икән дип торам. (*Һаман карана.*) Кая гына куйган соң бу нәгълэт жулик? Һичбер җирдә дә юк. Киемнәрен үзе киенеп киткән. Өстәл асларында да, бер җирдә дә күренми. Бик явыз нәрсә булырга охшый. Яхшы булса, шулкадәр йорт-җир, шулкадәр малны ташлап, монда килеп, жулик булып йөрмәс иде. Булсын иде минем атамның шундый маллары! Мин рәхәтләнеп дөньяда торыр идем. Мондый кыен арасына һичбер вакытта да килеп кермәс идем. Бу, Алла сакласын, акча өчен атасын да үтерер. Бик башсыз нәрсә, катр китүдән дә һич курка торган түгел. (*Кушетканың асларын кармаланып.*) Чү-чү, чү! Монда бер төргәк нәрсә бар. (*Тартып чыгарып, бик шатланып.*) Аһа! Пеште! Акча! Бары да монда. Үзе белән бер тиенен дә алмаган. Ну Казан жулигы! Бая мине «атам» дип куркытып алган булган идең. Менә моннан соң эзлә инде мине! (*Акчаны кесәсенә салып.*) Мин моның белән генә дә калдырмам әле. Хәзер барам да полициягә хәбәр итәм. Бу никадәр мине күрсәтергә тырышса да, барыбер ышанмаслар. «Кичә Сабитовның өенә кергән каракның берсе шул», – диярмен. Асыл кош аягыннан тотылды. Мине куркытып акча алырга белгән, ә шкатулкасын юк итәргә күңеленә дә килмәгән. Син бая мине куркыткан идең, менә инде мин хәзер сине куркытып карыйм. Дөньяның ачысын-төчесен, таш капчык эченә кереп, син дә татып кара әле. (*Акрын гына чыгып китә.*)

Берничә дәкыйка тынычлык.

АКТЫК МӘҖЛЕС

Әүвәл Закир, соңра Кәрим, Җәмилә, Сәгыйть, ике городовой, надзиратель һәм шаһитлар.

Закир (*бик кызуланып ишектән кереп, ишекне бикләп, урындыкка килеп утыра*). Ух! Бетте башым! (*Бераз тын.*) Мин ни эшләдем? (*Янә бераз тын.*) Мин ни өчен Гайнине үтердем? (*Бераз тын, урынынан сикереп тора.*) Мин ни өчен дип бу Гайнине үтердем? Ни өчен, моны үтереп, башыма бәла алдым? Ах! Кан! Кан! Кан! Күз алдымда әллә нинди каннар күренә! Ни өчен мин бу кадәр акылсыз булдым?! Аны үтереп, миңа нинди файда булды?! Миңа хыянәт кылганлыгы өчен аннан ачуымны алдыммы? Юк! Һич файда юк! Бары тик шул бер фахишәне үтереп, үземне гомерлек бер кайгыга, гомерлек бер хәсрәткә, гомерлек бер газапка гына салдым! Миңа хыянәт кылган икән, андый сөйгәненә хыянәт кылучы фахишәләр дөньяда бер генәмени? Андый хыянәтче дөньяда бер Гайни генәмени?! Хуш, хыянәт кылды, ни булды? Миңа ташларга да чыгып китәргә иде. Акрын-акрын ачуларым басылыр, ихласым кайтыр, рәхәтләнеп, тынычлап өемә кайтып киткән булыр идем. (*Бераз торып.*) Әле соң мин тагын нәрсә көтеп монда торам? Үземне килеп тотканнарын көтеп тораммыни? Ник бу кадәр мин акылсыз? Аһ, йөзе кара! Минем бөтен зиһеннәремнең астын өстенә китерде. Әле минем өмидләрем бөтенләй бетәр дәрәҗәгә килеп җиткәне юк бит. Тиз генә качып китсәм, бәлки, котылырмын? (*Тиз генә барып чемоданын кушетка астыннан тартып чыгара.*) Тфү! Чурт! Бөтенләй акылымнан шашам бугай, ахрысы. (*Чемоданын кулыннан ташлап.*) Төнлә бу чемодан белән кая барыйм мин? Миңа ни эшкә ул чемодан! (*Кушетка астын кармап.*) Ах! Харап булдым! Моннан акчаны алганнар! (*Тиз генә йөгереп барып, лампа кабыза башлый. Куллары да дерелди.*) Әгәр акчамны да урлаган булсалар, нихәл итәрмен? Кая барырмын? Кая качармын?! (*Лампаны яндырып, өстәл өстенә китереп куя. Кушетканың астын актара башлый.*) Ух Алла! Йөрәгем сикерә! Харап булдым! (*Кушетканың өстеннән мендәрләрне алып ыргытып ташлый. Кушетканы аудара, һәр җирен кызуланып-кызуланып карый.*) Юк! Юк! Бер җирендә дә юк! (*Чемоданын актара башлый.*) Юк инде, юк! Ничә кат эзләсәң дә, юк! (*Чемодан эчендәге бар нәрсәләрен таратып ташлый.*) Ах, йөзе кара! Наверно, бу Камали эшедер? Башка һичбер ке-

шенеке булмас. (*Өстәл янына килеп, бер бутылканы тотып.*) Бу эшләр, бу бәлаләр бары да сезнең аркагызда килде. (*Ачу белән идәнгә ыргытып бәрә. Икенчесен кулына алып.*) Сез нәҗесләрнең шомлыгы аркасында мондый бәхетсезлекләргә очрадым. Сез минем күзгә Гайнине матур итеп күрсәттегез. (*Бәреп вата.*) Ах! Бетте башым! (*Урындыкка лап итеп утыра. Терсәкләре белән өстәлгә таяна. Башын ике учы эченә ала, кямил өмидсезлек белән.*) И Алла! Уф! Бары да үз гөнаһым шомлыгы. Әгәр өемдә генә ятсам, начар эшләргә катышмаган булсам, атам-анамның биргән үгет-нәсихәтләрен тотсам, мондый бәлаләргә дучар булмаган булыр идем. Шул фахишә артыннан йөреп, мондый бәлаләргә очрадым. Аһ! Аһ!.. Шул эт өчен үземне катрга җибәрсәләр, нихәл итәрмен? Гомер буенча шундый хурлыкта, шундый рисвайлыкта, шундый газапта мәшәкать чиккәнче, үлүең меңмең өлеш артык! Моннан соң кая инде миңа әти-әниләремне күрү?! Ул җәннәт шикелле матур өйләребезне күрү?! Кая инде ул дус-ишләрне күреп, рәхәтләнеп, шатланышып гомер итүләр?! Бары да бетте! И, гомер буена бер пот авырлыгында әйбер дә күтәрмичә үскән мескен кулларым! И, җәяү йөрергә дә авырсына торган кадерле, тәрбияле аякларым! Авыр зынҗырлар салып, җирләр казыткан вакытларда ничек сез чыдарсыз? Бу хурлыкларга ничек итеп түзәрсез? Минем башыма килгән бу хәлләрне башка кешеләр күрсәләр иде, башка кешеләр белсәләр иде, мондый начар эшләргә аслан якын да бармаслар иде. Рәхәтлек белән уздырган көннәрем, мәсгуд булып кичергән гомерләрем, төш эчендә күргән шикелле генә, күз алларыма килеп-килеп китә. Шул өч көнлек дөнья ләззәтләренә алданып, нинди хурлыкларга төштем бит?! Кыяматкә кадәр һәрбер кешенең авызында минем начар исемем булачак. Моннан да зур дөньяда тагы нинди оят бар инде? Моннан тотып алып китеп, судта хөкем иткән чакларында, ата-анамның вә башка кешеләрнең гыйффәтле, абруйлы йөзләренә ничек итеп оялмыйча карарга батырчылык кыла алырмын? Юк! (*Урыныннан сикереп тора. Револьверын кесәсеннән ала.*) Мондый хурлыкларга, мондый рисвайлыкларга, мондый

---

Н ә җ е с – шакшы.
К я м и л – бөтенләй.
З ы н җ ы р – чылбыр, богау.
М ә с г у д – бәхет.

оятларга, мондый газапларга һич чыдар хәлем юк! Барыбер, болай да инде минем башым беткән! Ничә еллар газаплар чигеп үлгәнче, хәзер үлим! (*Атылмакчы була. Кулын яңадан төшереп.*) Ай! Җан дигән нәрсә бик кадерле! Бер дә тиз генә үләсе килми. Юк, артын исәпләмичә, тиз генә үзеңне һәлак итәргә ярамый. Бәлки, белмәсләр әле, котылырсың. Килеп тота башласалар да, өлгерерсең. (*Тагын урындыкка килеп утыра.*) И Алла! Нихәл итәрмен инде?! Бу төнне ничек уздырырмын! Карасана, зинһар, бу йортның каралыгын! Моның зинданнан кай җире аермасы бар? Бу зиндан гына да түгел, бу – кабер бу, кабер!

Бик каты ишек тартыла. Закир, электрик белән хәрәкәт кылган шикелле, ялт итеп урыныннан сикереп тора. Эндәшми. Ишек янә тартыла.

Закир (*калтыраган тавыш белән*). Хту там?

Тыштан тавыш. Атаприте, увидете!

Закир (*тиз генә револьверын кулга алып, ярты тавыш белән янә*). Хту там?

Тыштан тавыш (*гайрәт белән*). Атапри! Скариа!

Ишекне ватарга башлыйлар.

Закир (*тәмам калтырап*). Харап булдым! Актык минутым! Актык сулуларым!

Ишекне ваткан тавыш һаман арта бара.

(*Закир йөгереп тәрәзәгә таба бара. Барып җиткәч, кинәттән кире чигеп.*) Ах! Анда да полиция! Башкача... чарам... юк!.. Әткәй! Әнкәй! Хуш! Мин... киттем!

Револьвер шартлый. Закир егыла. Ишек ачыла, надзиратель, ике шаһит, ике городовой килеп керәләр.

Надзиратель (*Закирның гәүдәсе янына килеп*). Их! Бедняк, бедняк!

Городовойның берсе (*әйберләрне актарырга тотынып, акча шкатулкасын кулына тотып*). Ваше благородие?! (*Кулын сузган көенчә тора.*)

Ишектән Кәрим, Җәмилә, Сәгыйть килеп керәләр. Җәмилә, Закирның үлеп ятканын күреп, бик ачы аваз белән: «Аһ, балам!» – дип кычкыра, һушы китеп егыла башлый. Надзиратель, бер городовой аны урындыкка утырталар. Аңы бетә.

Сәгыйть (*икенче городовойның кулында шкатулканы күреп, акрын гына*). И мескен! И бичара! Безнең өйгә кергән дә шул икән!

Кәрим (*Закирның гәүдәсе янына тезләнеп, бер кулын үзенең кулына алып, бер җиңе белән күзләрен сөртеп*). И бала, бала! Тәүфикъсызлык аркасында үзеңне дә, безне дә харап иттең!

Сәгыйть (*халыкка таба карап*). Дөньяда баланы бигрәк ата-ананың тәрбия кыла белмәве харап итә!!!

Пәрдә.

# БЕРЕНЧЕ ТЕАТР

*Комедия 1 пәрдәдә*

УЙНАУЧЫЛАР:

Хәмзә бай – иске фикерле Казан бае; башында ак бүрек, яшел кәләпүш, өстендә намаз туны, аның эченнән бишмәт, эченнән кыска җиңле камзул кигән, чалбар балагын ак тасма белән бәйләгән.
Гафифә – Хәмзә байның кызы.
Вәли – Хәмзә байның кияве.
Хәбибрахман – Хәмзә байның улы, аңгыра.
Факиһә – Хәбибрахманның хатыны.
Биби – Хәмзә байның асравы, аңгыра кыз.
Фатих – Хәмзә байның кибетчесе.

Вакыйга Казанда, Хәмзә байның өендә.

Бай сымак бер өй. Ике якта икешәр ишек. Түрдә тәрәзәләр, тәрәзә арасында көзге. Стена буенда урындыклар. Сул тарафта бер диван. Аның алдында өстәл. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә Вәли күренә; өстенә пальтосын кигән, кулына таяк тоткан, күңеле бик шат, өйнең бер башыннан бер башына кызу-кызу атлап йөри.

Вәли (*кычкырып*). Гафифә! Гафифә!

Гафифә (*бүлмәдән, сузыбрак*). Әү!

Вәли. Буласыңмы инде?

Гафифә. Хәзер булам.

Вәли. Тизрәк бул! (*Халыкка таба карап.*) Гафифә дисәң Гафифә: бер җиргә бара башладың исә, кеше күрә дип коты чыга. Аның каршында ир кеше дигән сүз ерткыч җанвар дигән сүз белән икесе бертигез. Бары мин генә ул кадәр куркынычлы җанвар түгел. Башта миннән дә коты очты. Кияү булып кергәч, куркуыннан, куян шикелле, бер почмакка посып тик тора. Соңыннан, минем тарафтан шул яшенә җиткәнгә кадәр ата-анасыннан да ишетмәгән тәмле, татлы сүзләрне ишеткәч кенә, бераз җайланды. (*Ян ишеккә барып, ишеккә башын тыгып.*) Һи! Әле тиз генә буласың юк икән. Зинһар, тизрәк була күр! Әгәр каенатай кайтып керсә, аннан ары харап эш. Ничек итсә итәр, гомердә театрга җибәрмәс. (*Башын бүлмә ишегеннән алып, халыкка таба карап, куллары*

*белән хатын-кыз битенә пудра сөрткән төсле итеп күрсәтеп, бераз көлебрәк.*) Бизәнә: мич акшарлаган шикелле итеп, битләрен буяп маташа. Шулай да булса, үзенә килешеп тора тагын. Уйлап карагыз, әгәр мин шулай итеп битләремне буйый торган булсам, һич килешмәс иде бит! Онга төшкән таракан төсле булыр идем. Безнең бер асрау бар, йөзе менә нәкъ чуенның ундүртенче кичәсе төсле кап-кара. Беркөнне шул асрау, абыстайлары өйдә юк чагында, барган да минем Гафифәнең пудырларын алып ягынган; бөтенләй менә, бигайниһи, бер ком гарәбенең битен акбурга буяган төсле булган. Көлешә-көлешә алҗып беттек. (*Бик җитди.*) Беләсезме? Ул бит пудыр күп кешегә килешми, хосусән ирләргә бер дә килешми. Ә менә минем бер таныш егетем бар – Әхмәтҗан, ул һәр көнне өчәр мәртәбә сакалларын китәреп, пудырлар сөртеп йөри. Аңа килешә. Миңа бер дә килешми. Ул шул инде аксөяк нәселдән яратылган. Ә безнең нәрсә, без бит мужик! Безнең бабай сука сукалап үскән. Эти, чабата киеп, 12 яшендә калага килгән. Безнең шикелле кара икмәк ашап үскән кешегә кая инде ул ак сөякле булу? Ак кына түгел, миңа карасы да килешми. Бервакыт, хатын: «Бик матур була», – дигәч, котырынып, шушы мыегымны карага буяган идем. Ничә көннәргә кадәр кеше күзенә күренергә оялып яттым. Җитмәсә тагын, мыекка сөртәм дигәндә, битләрне буяп бетердем. Ә аның карасы тәннән һич китми икән... Тумыштан матур булып тумагач, спайланган булып маташу белән генә булмый инде ул. (*Ян ишеккә карый, төсләрен бозып.*) Ул нишләвең инде ул? Мин монда кайчаннан бирле, кайчан киенеп бетерә инде, дип көтеп торам.

Гафифә (*бүлмәдән*). Җә, ярар ла, хәзер булам, пудыр матур төшмәгән.

Вәли. Тизрәк бул инде, зинһар! (*Башын бүлмәдән алып, ишекне ябып, халыкка таба карап.*) Менә сиңа кирәк булса, мин инде өстемә пальтоларымны кигәнгә бер сәгать булды. Ә ул әле һаман пудыр ягынып бетерә алмый; пудыр ямьсез төште дип, яңадан битен юып ята. Әле ярый, көзге ямьсез күрсәтә дип, көзгене бәреп ватмаган.

Уң як ишектән кулына поднос белән чынаяклар күтәреп чыгып, Биби узып бара.

Вәли (*Бибине күреп*). Әй, Биби, тукта әле!

---

Бигайниһи – нәкъ үзе.
Хосусән – бигрәк тә.

Б и б и (*борылып карап*). Нәрсә дисең?

В ә л и. Кара әле, ә!..

Б и б и. Карыйм ич инде!

В ә л и. Менә нәрсә...

Б и б и. Белмим, нинди нәрсәдер.

В ә л и. Тфү, чорт! Сөйләп бетергәнне көт!

Б и б и. Йә, көтәм.

В ә л и. Менә нәрсә...

Б и б и. Белмим!

В ә л и (*ачуланып*). Тыңлап тор дим мин сиңа!

Б и б и. Тыңлыйм ич!

В ә л и. Тыңласаң, шул: менә без хәзер театрга китәбез...

Б и б и. Кая?

В ә л и. Театрга!

Б и б и. Нәрсә төятергә?

В ә л и. Баш төятергә.

Б и б и. Нинди баш?!

В ә л и. Атаң башы! Мин сиңа төятергә димим, театрга дим, аңладыңмы, театрга дим!

Б и б и. Йә, аңладым инде, театрга, ул нинди җир соң?

В ә л и. Анысы сиңа кирәк түгел. Без киткәч, каенатай кайтыр, ул сорар безне: «Кайда киттеләр?» – дип. Син аңа әйт: «Кодаларга киттеләр», – дип. «Театрга киттеләр», – дип әйтмә!

Б и б и. Сорамаса нишләрмен?

В ә л и. Тик торырсың!

Б и б и. Ярый. (*Кереп китә башлый.*)

В ә л и. Тукта әле!

Биби туктый.

Син, аңгыра нәрсә, рәтләп әйтә дә белмәссең әле.

Б и б и. Нишләп белмәскә!

В ә л и. Йә, әйтеп кара әле, ничек дип әйтерсең икән.

Б и б и. «Вәли җизниләр тиатрга китмәделәр, кодаларга киттеләр», – диярмен.

В ә л и (*ачуланып*). Иштең ишәк чумарын! Мин сиңа алай дип әйттеммени?

Б и б и. Соң ничек дидең?

В ә л и. Мин сиңа: «Театрга киттеләр», – дип әйтмә, «Кодаларга киттеләр», – дип әйт, дидем.

Б и б и. Мин дә бит «киттеләр» димәдем.

В ә л и. Фу, җәфа икәнсең, кайдан башыма бәла алдым! Менә, син яхшы тыңла: әгәр дә каенатай безне: «Кая киттеләр?» – дип сораса, «Кодаларга киттеләр», – диген. Башка сүз әйтмә, бар, юлыңда бул!

Б и б и. Ярый. (*Кереп китә.*)

В ә л и (*үз-үзенә*). Менә бәла өстенә бәла. Мин үзем дә җүләр: миңа ни эшкә кирәк иде аңар театр дип сөйләп торырга? Мин аңар дөрес әйтәмме?

Ишектән Гафифә килеп чыга.

(*Аңа карап.*) Нихәл, буласыңмы инде?

Г а ф и ф ә. Хәзер булам инде. Нәрсәгә шаулашасыз икән дип карарга гына чыккан идем.

В ә л и. Әнә шул, бар ич әле, бер адәм имгәге Биби, шуңа сүз аңлата алмыйча аптырап беттем. «Без хәзер театрга барабыз» дигән идем, «нәрсә төятергә» дип, миннән сорап ята.

Г а ф и ф ә. Ул һәрвакыт шулай, һич аңламый ул. Мин аны беркөннәрне Гарифәләргә җибәрдем. «Абыстай, Гарифәнең алдырган кислатасы юк микән, бик күңелләрем болганып тора, үзебездә судысы бар барын да, ирләр өйдә вакытта кислата алдырырга онытылган» дип әйтте, дип сора дигән идем, барган да, «Абыстай, киез каталарын биреп торсыннар ла» дип сорап, миңа кислата урынына киез ката күтәреп кайткан. Гарифәдән шулкадәр оялдым, бөтенләй менә җир тишегенә кererлек булдым.

В ә л и. Йә, ярар, аларын башка вакытта сөйләшербез, театрга барырга соңга калабыз, бар, тизрәк бул!

Г а ф и ф ә. Хәзер булам. Ә, ни, синнән шуны гына сорыйм дигән идем. Ул театрда кеше күп булыр микән?

В ә л и. Һу! Күп булмыймы соң! Беләсең бит, бүген мөселманча театрның беренче башлана торган көне. Шулай булгач инде, анда бөтен шәһәр халкы агылыр.

Г а ф и ф ә (*борыннарын җыерып, иркәләнгән бала кыяфәтендә*). Әй! Әем! Алай булгач, мин бармыйм ла, анда кеше күп булгач, мин оялам.

В ә л и (*үз-үзенә*). Менә сиңа кирәк булса! (*Алдына карап, башын бераз кашып.*) Ничек булыр икән соң? Юк, минемчә, әле бу көн кеше ул кадәр үк күп булмас. Күбесенең картлары җибәрмәс. Кайсы берсе кеше сөйләүдән куркып калыр.

Г а ф и ф ә (*янә әүвәлгечә*). Алай булгач, без дә бармыйк: мин дә кеше сөйләүдән куркам. Әти белсә, ул да ачуланыр.

В ә л и (*бик тирән уйга калып, башын күтәреп, халыкка таба карап*). Уттан котылдым, инде суга төштем. Моннан инде ничек котылырга? (*Гафифәгә карап.*) Мин бит инде, анда барырга дип, билет та алып кайткан идем.

Г а ф и ф ә. Кайтсаң ни! Бармый калган булгач, акчаңны кире кайтарып алырсың.

В ә л и. Бер алган булгач, кире кайтармыйлар шул инде аны.

Г а ф и ф ә. Теләсәң ни эшлә, мин барырга куркам!

В ә л и. Анда ерткыч җанварлар юк, сине ашамаслар.

Г а ф и ф ә. Ашамасалар да, мин бармыйм, кирәкми.

В ә л и. Юк инде, бармый калырга ярамый, барабыз! Ул бит бик күңелле була. Үзеңнең дә көлә-көлә эчләрең катып бетәр.

Г а ф и ф ә. Андый көлкеләрне ат кәмитендә дә бик күп күргән инде. Монда да әллә нинди артык җире булмас, кирәкми, мин бармыйм.

В ә л и. Ихтыярың, теләсәң ни эшлә, барасың килмәсә, көчләмим, мин үзем генә барам.

Г а ф и ф ә. Ә, ярар менә, барыр идең бугай, кара син аны, анда ялгыз гына кызлар карарга бармакчы була. Җибәрәмме соң мин сине, Алла боерса, гомеремдә ялгыз җибәрмим!

В ә л и. Теләсәң ни эшлә, мин бармыйча калмыйм. Син бармыйсың икән, мин үзем генә тотам да барам! Хуш, сау бул, мин киттем. (*Чыга башлый.*)

Г а ф и ф ә (*тиз генә Вәлинең артыннан барып тотып*). Җә, җә, бетте. Мин юри генә әйттем. Әйдә, мин дә барам.

В ә л и (*кире кайтып*). Ну, әйдә алайса, барсаң, тизрәк киен!

Г а ф и ф ә. Хәзер киенәм. (*Бүлмәгә таба бара башлый. Соңра янә борылып.*) Кара әле, анда өскә киенгән көенчә генә утыралармы?

В ә л и. Юк, салып утыралар.

Г а ф и ф ә. Әй! Алай булгач, бик читен икән. Кирәкми, бармыйбыз.

В ә л и. Бармыйбыз дип сөйләмә, мин барам, киттем алайса. (*Чыга башлый.*)

Г а ф и ф ә. Барам, барам!!

В ә л и (*мыскыл итеп*). «Барам, барам!» Ә үзе һаман терәлеп тора. (*Сәгатен чыгарып карап.*) Син, шулай итеп маташып, мине уеннан калдырмакчы була торгансыңдыр, ахры. Уен башланырга бары ярты гына сәгать калган.

Г а ф и ф ә. Мин хәзер булам. Өстемә күлмәк кенә киям.

В ә л и. Ну, бар, зинһар, тизрәк бул.

Г а ф и ф ә (*ишектән керә башлый да, янә борылып*). Нинди күлмәгемне киим икән, асылмы, җонмы?

В ә л и (*үз-үзенә*). Асыласың килсә, асыл инде. (*Гафифәгә.*) Зинһар, мине йөдәтмә. Эстәдең ни ки: асылмы, җонмы, сатинмы, батисмы, ситсымы – минем өчен бар да бер.

---

Э с т ә д е ң н и к и – теләсәң ни ки.

Г а ф и ф ә. Ярый алайса, мин зәңгәр асылымны киям. (*Китә башлый.*)

В ә л и. Әй, юк, тукта әле, зәңгәр асылыңны кимә, нинди булса да берәр җон күлмәгеңне ки. Сезнең андый чачаклы-чуклы карават чаршавы шикелле асыл күлмәкләрегез белән кешегә көлкегә калыр хәлем юк. Без анда бүләк багарга[1] бармыйбыз, уен карарга барабыз.

Г а ф и ф ә. Алай булгач, нинди җон күлмәгемне киим?

В ә л и. Теләгәнеңне ки.

Г а ф и ф ә. Теге гармун итәкле кызыл җон күлмәгем ничек булыр?

В ә л и. Шәп булыр.

Г а ф и ф ә. Аның шул буе озын булган. Чәнчелеп беткән җөйче, шулкадәр әйттем: «Факиһәнеке төсле матур булсын, яхшы итеп тек», – дип. Бозып кына бирде. Юкка гына дүрт тәңкә акча әрәм иттем. Моннан ары, Алла боерса, гомердә ул хатынга тектермәм.

В ә л и. Ярый, шулай итәрсең. Бар, тизрәк бул.

Г а ф и ф ә. Соң кайсын киим?

В ә л и. Башкасын.

Г а ф и ф ә. Теге, буйга буф бөргән сирый күлмәгемне киимме?

В ә л и. Ки.

Г а ф и ф ә. Ул да шул бик килешеп бетми, чабулары бик тар булган.

В ә л и. Алайса, бүтәнне ки.

Г а ф и ф ә. Ал җон күлмәгем ничек булыр?

В ә л и. Бик ал булыр.

Г а ф и ф ә. Кызылы?

В ә л и. Бик кызыл булыр.

Г а ф и ф ә. Яшеле?

В ә л и. Бик яшел.

Г а ф и ф ә. Соң нindине киим?

В ә л и. Матурракны.

Г а ф и ф ә. Теге шикалат төсле, тоташ буйлы, бантикле күлмәгемне кисәм ничек булыр?

В ә л и (*шатланган булып*). Һу! Менә, менә, эзли торгач таптың, ахры, бик һәйбәт булыр. Үзе шикалат төсле дә булгач, бигрәк шәп була инде ул. Чөнки шикалат бик тәмле нәрсә.

Г а ф и ф ә. Мин аны кияр идем киюен дә, аның шул җиңнәре сак жиң[2]. Килешмәс. Үзең дә, ичмаса, бер кеше төсле чибәр күлмәклек алып биргәнең дә юк. Бер җиргә бара башладың исә, киеп барырлык һичбер җүнле, матур күлмәгем юк.

В ә л и. Соң бит аны хәзер генә тегеп булмый лабаса. Уф Алла! Бар икән кылану, ансы да ярамый, монсы да

ярамый, белмим, боларга нәрсә генә ярый торгандыр, чәнчелеп бетегез шунда. Сезне көтеп, уеннан калыр хәлем юк. (*Чыгып китә башлый.*)

Гафифә (*артыннан барып җитеп, Вәлинең җиңеннән тотып, ялынган рәвештә*). Җә инде! Ни эшләвең инде ул? Торасың да, чыгып китәм дип куркыта башлыйсың. Мин сиңа бармыйм дип әйтмим ич! Әйткәч, ни була соң инде? Мин синнән әллә нәрсә сорамыйм бит, бары тик нинди күлмәгемне киим дип кенә сорыйм.

Вәли. Мин сиңа әйттем бит инде. Теләсәң нәрсә ки, дип. Миңа дисәң, бөтенләй бернәрсә дә кимә.

Гафифә. Соң шулай диген аны. Яхшылап кына сораганда, тотасың да ачулана башлыйсың. Алай булгач, ярый торган булса, мин бернәрсә дә кимим, шушы өстемдәге күлмәгем белән генә барам.

Вәли (*йөзләре яктырып*). Һай, бәрәкалла! Бик яхшы булыр, бар. Зинһар, тизрәк. Өстеңә генә ки дә хәзер китәбез.

Гафифә ашыгып кереп китә.

Уф Алла, җаным чыга язды. (*Ишеккә барып карап.*) Яңадан тагы бер-бер нәрсә тапкан булып чыга күрмәсен, – ә, юк икән. (*Ишекне яба.*) Киенә икән, ахырында мең бәла белән көчкә җиңдем. Бу үзенә күрә инде кечкенә генә, бармак башы кадәр генә булса да бер революция булды. Ярый, ни булса да булды, минем максудым булды. (*Кулларын угалап.*) Их, хозур! Хәзер театрга китәбез. (*Таягын ике кулының бармак очлары белән генә тотып, сүз арасында төрле шатланган һәм мәсхәрә кылган кыяфәтләргә кереп җырлый.*)

Бүген театр була, траттата, траттата!
Шатлыктан күңлем тула, траттата, траттата!
Картның кәефе бик китә, уйуйуй, уйуйуй!
Уйнаучыларны тетә, уйуйуй, уйуйуй!
Барам мин театрга, траттата, траттата!
Хатыным белән бергә, траттата, траттата!
Каенатай кайтып кергәч, уйуйуй, уйуйуй!
Безнең киткәнне күргәч, уйуйуй, уйуйуй!
Ачуланса да курыкмыйм, траттата, траттата!
Барыбер сүзен тотмыйм, траттата, траттата!
Кайтып кергәчтен тузар, уйуйуй, уйуйуй!
Бөтен кәефне бозар, уйуйуй, уйуйуй!
Бозса бозар кәефне, траттата, траттата!
Хәзергә мин кәефле, траттата, траттата!

---

Максуд – теләк.

Г а ф и ф ә (*ишектән өстенә киенгән көенчә чыгып*). Йа, бар икән Ходаем, тагы нәрсә җүләрләнәсең инде? Әллә син дә кәмиттә паяз булмакчы буласыңмы?

В ә л и. Әһә! Булдыңмы әле син, аппагым? Әйдә алайса, киттек инде, былбылым!

Гафифәнең култыгыннан култыклап, чыгып китәләр. Сәхнә буш кала. Бераздан, бик кызуланып, уң як ишектән Ф а к и һ ә килеп чыга.

Ф а к и һ ә (*як-ягына карап*). Монда да юк! Болар кая киткәннәр? (*Ишекне ачып кычкыра.*) Биби! Биби!

Б и б и чыга.

Син беләсеңме?..

Б и б и. Беләм!

Ф а к и һ ә. Беләсең икән, әйт алайса: кая киттеләр җизниләр?

Б и б и. Алар, син сорасаң, ничек дип әйтергә икәнен миңа әйтмәделәр.

Ф а к и һ ә. Соң ничек дип кенә әйттеләр?

Б и б и. Абзый сораса, кодаларга киттеләр, дип әйтерсең, диделәр.

Ф а к и һ ә. Ә башка кеше сораса?

Б и б и. Башка кеше кем сорасын? Фатих абый сораган иде дә, мин аңар әйтмәдем.

Ф а к и һ ә. Менә мин сорыйм.

Б и б и. Син башка кешемени?

Ф а к и һ ә. Йә, әйт инде, кая киттеләр?

Б и б и. Әй лә, әйтмим!

Ф а к и һ ә. Театргамы?

Б и б и. Ә! Үзе дә белә икән. Аны сиңа кем әйтте?

Ф а к и һ ә. Йә, бар. Алдыңа кара, эшеңне эшлә...

Биби кереп китә.

Шул шул, театрга киткәннәр. Мин үзем дә сизгән идем аны сизүен. Җизни ул безнеке шикелле җебегән авыз түгел. Исенә бернәрсә төште исә, хәзер, шул минут ук эшли дә ала. Безнеке генә ул тегермән ташы шикелле, һич кузгатыр хәл юк. Тукта әле, мин дә алып барды-рыйм әле. Кеше барган җирдән мин генә ни эшләп калып торырга соң? (*Бик кызуланып, сул як ишеккә кереп китә.*)

Сәхнә бераз буш тора. Бераздан, кычкырышып, Х ә б и б р а х м а н белән килеп чыгалар.

---

К ә м и т т ә п а я з (паяц) – циркта уенчы, клоун, шамакай.

Х ә б и б р а х м а н (*кулларын селтәп*). Бармыйм дигәч, бармыйм инде! Иң әүвәл мин аның, ул театрның кайда икәнен белмим.

Ф а к и һ ә (*мыскыл итеп, бармакларын бөкләп санарга керешә*). Бу булды бер!

Х ә б и б р а х м а н. Икенчеләй, кайдан керәсен, ничек керәсен белмим.

Ф а к и һ ә. Ике, өч.

Х ә б и б р а х м а н. Анда кергәч тә, нинди урынга утырырга?

Ф а к и һ ә. Шуның белән була дүрт! Зинһар, ичмаса инде, эчеңдәге бар серләреңне сөйләп бетереп, кешене көлдермә; кеше ишетсә, «моның белгән нәрсәсе бар микән?» ди башларлар. Кеше җаен тапканны, без генә табарбыз әле.

Х ә б и б р а х м а н. Кирәкми, бармыйбыз; мин куркам.

Ф а к и һ ә. Чү, чү, тагы куркуыңнан җыгылып китә күрмә! Шулкадәр зур гәүдәң белән «куркам» дип әйтергә сиңа кешедән оят!

Х ә б и б р а х м а н. Кирәкми, бармыйм!

Ф а к и һ ә. Нинди бармаган да нинди нитмәгән! Кеше барган җирдән без генә калып торырга! Әйдә, әйдә, барабыз! Җизниләр әле алар үткән атнаны плашкигә[3] дә чыктылар. Без анда да авызыбызны күтәреп калдык, кияве белән кызы барган булгач, эткәй дә бер сүз дә әйтә алмас. Әйдә, тотабыз да барабыз. Нәрсәгә соң без генә ул кадәр куркып торырга!

Х ә б и б р а х м а н. Бармыйм дигәч, бармыйм инде.

Ф а к и һ ә (*юмаларга керешеп*). Җә инде, дим! Барыйксана инде! Харап булган икән! Гомеремә бер мәртәбә бер җиргә барыйк дигәнмен икән инде, шуны да тыңламыйсың. Эткәйдән куркып торырга син кечкенә сабый бала түгел ич инде!

Хәбибрахман эндәшми.

Җә, дим инде, нигә эндәшмисең? Орышса, кайткач бер орышыр да бетәр. Аның өчен сине ашый алмас бит ул. Әгәр дә бик каты дулый башласа, һич булмаганда, мин үзем аны көчләп алып бардым диярмен. Орышса, мине орышыр, сине орышмас.

Х ә б и б р а х м а н (*башын кашып*). Белмим шул, ничек булыр икән? Минем үземнең дә бер күрәсем килә килүен ул театр дигән нәрсәне. Әле мин син җөдәтерсең дип әйтмәгән идем, Гайнулла җизнинең кияве Габдрәхимнәр дә барабыз дигәннәр иде.

Ф а к и һ ә. Соң алай булгач, тагын ни кирәк инде? Кеше бармый торган җирмени ул? Кеше баргач, бергә-бергә күңелле дә булыр. Әйдә, өстеңә киен дә, барабыз. Мин дә хәзер киенеп чыгам. (*Кызуланып, уң як ишеккә кереп китә.*)

Х ә б и б р а х м а н (*ишеккә таба карап, үз-үзенә*). Мин әле барам дип әйтеп бетерергә дә өлгерә алмадым, ә ул киенергә дә кереп китте. Нишләргә икән инде, шулай ук барырга туры килер микәнни? Әти орышмас микән? Без чыгып киткәнче кайтып керсә генә ярар иде. Бармый калыр идек. Хатын ул әтинең гадәте начар икәнне белми. Беркөнне Гали хаҗи Гаптерахманы белән чәйгә кергән өчен дә колагымны шулай итеп борып алды. (*Борып күрсәтә.*) Күзләремнән утлар күренде. Аны кешегә сөйләп йөреп булмый. «Әти колакны борды», – дип, хатынга әйтсәң, хатын хәзер ул: «Һәй, нәни бәби! Шул башың белән колагыңны бордырып торасыңмы?» – дип мыскыл итәргә тотына. (*Кесәсен капшап.*) Барабыз баруын да, әле кесәдә барырлык акча бар микән? (*Портмонетын алып, акчаларын өстәлгә бушатып саный.*) Унбиш тиен дә унбиш тиен – утыз тиен, тагын унбиш тиен, була кырык биш тиен. Тагын биш тиен, булды илле тиен; илле тиен дә егерме тиен, була җитмеш тиен. Тагын илле тиен. (*Бармаклары белән исәпләргә керешеп.*) Йөз, йөз ун, йөз егерме, булды бер сум да егерме тиен. Бусы өч тәңкә, барысы була... (*Яңадан исәпләп.*) Ике, өч, дүрт, дүрт сум да егерме тиен. (*Портмонетына сала.*) Өч тәңкәсенә билет алсак, каладыр бер сум егерме тиен. Анысы барырга-кайтырга булса, хәер, җитә икән җитүен, түлке бер дә барасы килми шул. Ичмаса, әти дә кайтмады. Әллә бармыйм микән? Ничек итеп бармый калырга? Ә, булды. Менә монда качып утырам да әти кайткач кына торып чыгам. (*Диван башына барып посып утыра.*)

Ф а к и һ ә килеп чыга.

Ф а к и һ ә (*үз-үзенә*). Әле һаман теге уҗым бозавы киенеп чыга алмаган икән. Нишләп тора икән инде тагын? (*Сул як ишеккә кереп китә.*)

Х ә б и б р а х м а н (*башын бераз күтәреп карап, бик шатланып*). Аллага шөкер, котылдым, күрмәде. Әти кайтыр инде.

Ф а к и һ ә (*ишектән чыгып*). Анда юк, әллә кая киткән, шундый чакларда анасы кыйнамасын дип качкан балалар шикелле кача торган гадәте бар иде, бер-бер җирдә качып тормыймы?

Әзләргә тотына. Почмакта тора торган кресло артларын карый; Хәбибрахман бу вакытта, балалар шикелле, башын әчкә яшерә. Факиһә килеп күрә дә, акрын гына көлеп, диванның икенче башына барып, аягы белән идәнгә тибеп кычкыра.

Һәй, бәдбәхет! Күсе бар!

Хәбибрахман. Һай! (*Сискәнеп сикереп тора.*)

Факиһә (*мөстәһзианә көлеп*). Һа, һа, һа! Анда син бар идеңмени? Мин белмәдем. Ул кадәр куркытмаган булыр идем. Анда ни эшләп утырасың?

Хәбибрахман (*ни әйтергә дә аптырап торып*). Акчам төште. Шуны аладыр идем.

Факиһә. Нинди акча?

Хәбибрахман. Менә театрга барырга акча җитә микән дип санап торадыр идем дә, берсе төшеп китте.

Факиһә. Шул гомердән бирле әле өстеңә киенмичә акча санап тордыңмы?

Хәбибрахман. Мин хәзер киенәм. Башыма бүрек киям дә тунымны гына киям. (*Кереп китә.*)

Факиһә (*кычкырып кала*). Кара аны, анда да кәнәфи башына акчаңны төшермә, анда да күсе булыр. (*Көзге каршына килеп, шәлләрен, калфакларын төзәтә башлап.*) Ну, ир соң! Ир димәсәң, хәтере калырлык бар. (*Ишеккә карап.*) Биби! Биби!

Биби чыга.

Әткәй безне «кая киттеләр» дип сораса, «кодаларга киттеләр» диген.

Биби. Ник, анда җизниләр киттеләр бит. Сез дә шунда барасызмыни?

Факиһә. Без театрга барабыз, әмма син шулай дип әйт.

Биби. Ярый, әйтермен. Бая җизни, син әйтә белмәссең, дип, мине яңадан әйттереп карап маташа.

Факиһә. Әйтә белдеңме соң?

Биби. Ник белмәскә, белдем.

Факиһә. Йә әле, тагын әйтеп кара. Безне кая киттеләр диярсең икән?

Биби. Әллә белмәс дип beләсеңме? Мин инде аны Фатих абыйдан күптән өйрәнеп куйдым. «Театрга киттеләр» диярмен.

Факиһә. Һи, аңгыра! Җебегән авыз! Мин сиңа шулай дип әйтергә куштыммыни?

Биби. Ник, үзең әйттең ич, «җизниләр кодаларга кит-

---

Мөстәһзианә – мыскыллап.

теләр, сез дә шунда барасызмы?» дигәч, «юк, без театрга барабыз» дип...

Ф а к и һ ә. Күп телеңә салынма. Яхшы тыңла. Әгәр дә эткәй сораса «кая киттеләр?» дип, «кодаларга киттеләр» диген.

Б и б и. Ярый, ярый, аңладым, «икесе дә шунда киттеләр» диярмен.

Ф а к и һ ә. Кая?

Б и б и. Кодаларга.

Ф а к и һ ә. Бар, эшеңдә бул!

Биби кереп китә. Х ә б и б р а х м а н тунының югары төймәсен төймәли-төймәли чыга.

Х ә б и б р а х м а н. Әйдә, булдым.

Ф а к и һ ә. Әйдә, әйдә, булсаң, тизрәк атла аягыңны. (*Ишектән чыкканда, Хәбибрахманның аркасыннан этә.*)

Х ә б и б р а х м а н. Тукта! Төрткәләмә инде ул кадәр! Чыгам ич.

Чыгып китәләр. Сәхнә буш кала. Бераздан Ф а т и х килеп керә.

Ф а т и х (*як-ягына каранып*). Абзый кая икән соң әле? Кеше бәйрәм итә дә итә, мин дә бераз бәйрәм итеп аласы иде. Һәммә кеше йөри дә йөри, мин генә тик ябылып ятам, миңа ни бәйрәм юк, ни җомга юк. Бәйрәм булды исә, ишек төбе сакла. Көне буе байга килгән бер кешене өйгә алып кер дә чәй эчерт, җомга булды исә, ишегалдында утын яр да кар көрә! Юк инде, булмас болай итеп. Эһем, эһем! (*Тамак кыра.*) Әллә бөтенләй өйдә дә юкмы? (*Ишекләрне карана.*)

Б и б и. Эһем, эһем! (*Ишектән чыга.*) Нәрсәгә тамак кырып йөргән буласың?

Ф а т и х. Абзый өйдәме?

Б и б и. Өйдә.

Ф а т и х. Ни эшли?

Б и б и. Тире җыеп, күн эшли.

Ф а т и х. Йә, шаярма әле, чынлап әйт әле, өйдәме?

Б и б и. Ни эшкә ул сиңа?

Ф а т и х. Кирәк.

Б и б и. Әүвәле әйт ни эшкә икәнен, аннан соң әйтәм.

Ф а т и х. Йә, әйт инде, шаярма.

Б и б и. Нәрсә бирәсең, әйтәм.

Ф а т и х (*шаярып*). Әйтсәң, сине үземә хатынлыкка алырмын.

Б и б и. Һи, мәхәббәтсез!

Ф а т и х. Мәхәббәтсез? Мин нишләп мәхәббәтсез бу-

лыйм? Кара бу мыекларны! (*Мыекларын борып күрсәтә.*) Кызларның калфак чугына ярарлык.

Б и б и. Йә, күп телеңә салынып торма монда, бар, чык!

Ф а т и х. Ник, шулай ук мине яратмыйсыңмыни? Мин сине әле абзыйдан сорарга дип менгән идем, анда ялгыз гына күңелсез.

Б и б и (*боргаланып*). Һай, конарсыз!

Ф а т и х. Кызларның шул булыр инде аларның, алар һәрвакыт шулай һавалы булалар. Кызлар алар, яшь чагындарак, патшага барам мин, дип торалар да, ди, аннан ары, санатка[4], дип әйтәләр, ди; ул да эләкмәгәч, актыгында, солдат булса да ярар, дип әйтәләр, ди.

Б и б и. Йә, йә, бар, мыскыл итмә! Бар, чык! Абзый кайтыр, абыстай да хәзер менәр.

Ф а т и х. Күптән син шуны әйтерләр, мин синнән баядан бирле: «Абзый өйдәме?» – дип сорыйм ич. Өйдә булмаса, хуш, сау бул. (*Чыгып китә.*)

Б и б и (*үз-үзенә*). Ялганлый торгандыр ла ул, мине алдар өчен генә, юри генә әйтә. (*Кереп китә.*)

Бераздан Х ә м з ә  б а й кайтып керә. Күрмичә, ишек төбенә җәеп куйган паласка сөртенә.

Х ә м з ә (*кычкырып*). Гөнаһ шомлыклары! Аяк астына әллә нәрсә җәеп куйганнар. Мал кадерен белмиләр. Тыштан килеп кергәч, күзлек парлана да бернәрсә дә күреп булмый. (*Күзлеген сөртә.*) Беркөн мәдрәсәгә кергәч тә, әчелектәге башмакларга сөртенеп, лаканга егылган идем. (*Ишек янындагы урындыкка утырып.*) Әй, кая, кайсыгыз бар анда? Аякны тартыгыз әле.

Б и б и килеп чыга.

Кая, кил, нәрсә терәлеп торасың, тарт аякны!

Биби салдыра башлый.

Чү, чү, чү, карап тарт! Мәсихемне[5] бозма! Абыстаң кая?

Биби киез итекнең берсен салдыра.

Б и б и. Аш өендә.

Х ә м з ә. Нишли анда?

Б и б и. Аш пешерә.

Х ә м з ә. Ник, килен кая?

Б и б и. Алар Хәбибрахман абый белән ни... ни... әй... кодаларга киттеләр.

Х ә м з ә. Ныграк тарт! Кулың чергән мәллә?

---

Ә ч е л е к – мәдрәсәдәге чишенү бүлмәсе.

Биби, кинәттән тартып җибәреп, Хәмзәне егып төшерә.

Һай, бәдбәхет! Күзең чыккан нәрсә! Бар, кит, күземә күренмә!

Биби кереп китә. Хәмзә, мәшәкатьләнеп, аягын салып бетерә.

Башка кеше булса, мин аңар кирәген биргән булыр идем булуын, әллә ничек, кыз балага сугарга ул кадәр кул барып җитми. (*Тунын салып, чөйгә элеп куя.*) Бүген иртә белән чәч алучыга кергән идем, бөтенләй ишегеннән керер хәл юк. Җыен кызыл авыз кибетчеләр тулган. Байларына бөтенләй әйләнеп тә карамыйлар, чәч алучысы да һич санга санамый: «Хаҗи, син әле башка көнне дә керерсең, син бай кеше, һәрвакытта да вакытың бар; болар бит бай кешесе, җомга көннән башка вакытта вакытлары булмый», – дип, авызын җырып тик тора. (*Чалбар балагын җыеп бәйләп куйган тасмаларын чишә.*) Алары да шул кибетчеләр яклы. Аларга кибетчеләр яклы булмыйча ярыймы соң? Кибетчеләр бит аларга унар, унбишәр тиенләп яудыралар. Аларга бай акчасы кызганычмыни... Биби, Биби!

Ишектән Биби чыга.

Биби. Нәрсә дисез, абзый?

Хәмзә. Бар әле, берәрсенә әйт әле, мәдрәсәдәге Коръән укый торган шәкертне чакырып чыксыннар. «Абзый чәч алырга чакыра» дисеннәр.

Биби. Нинди мәче алырга?

Хәмзә. Һай, аңгыра, җебегән нәрсә! Мин сиңа мәче алырга дидеммени? Чәч алырга, дим! Чәч! (*Үз чәчен тарткалап.*) Менә, менә шушыны алырга, дим!

Биби чыгып китә.

Бу кадәр аңгыра булырлар икән. Җыен аңгыра безгә җыелган. Беркөн Хәбибрахманга: «Бар, агач базарына Хисмәткә бар да аны тизрәк монда алып кайт», – дип җибәргән идем, барган да бер зур кисмәк алып кайткан. Менә бу сакалымны шулар гына агартып бетерделәр инде. Әле ярый хәзергә үзем исән әле. Үзем үлгәч, болар дөньяда ничек итеп көн күрерләр?

Биби ишектән килеп чыга да тик тора.

(*Аңа карап.*) Нихәл, нишләп терәлеп торасың анда?

Биби. Абзый, Миннебай абзыйга әйткән идем: «Коръән укый торган шәкертне алып чык», – дип, «Нинди шәкерт

ул, мәдрәсәдәге шәкертләр алар бар да Коръән укыйлар, анда Әфтияк укучы юк», – ди.

Хәмзә (*аяк тибеп*). Һай, ахмаклар! Әрәмтамаклар! Бар, тизрәк чыгып әйт, мәчеттә Коръән укый торган шәкертне – Гайфулланы чакырып чыксын!

Биби. Икесен дә чакырсынмы?

Хәмзә. Нинди икесен дә?!

Биби. Коръән укучыны да, Гайфулланы да?

Хәмзә. Үләм инде мин сезнең белән, җәфаланып үләм! Аңгыра! Соң шул Коръән укучы шәкерт белән Гайфулла икесе дә бер ләбаса инде! Бар тизрәк! Гөнаһ шомлыгы!

Биби чыгып китә.

Менә инде син сөйләш алар белән. И Алла! И Алла! Ахры инде дөньяда акыллы кеше үк калмагандыр. Ничә елдан бирле өйрәтеп тә, игә-чигә китерер хәл юк. Һәр көн шулай башымны катырып бетерәләр. Тукта инде, әүвәл тизрәк чәчемне алдырыйм да, аннан соң, тәһарәт алып, вирдләремне укырмын. (*Ишеккә таба борылып.*) Әй! Кая сез? Башымны чылатырга сабын, су бирегез. (*Ишектән кереп китә.*)

Бераздан чынаяк, подនослар күтәреп Биби керә.

Биби. Үзләре җүнләп йомыш куша белмиләр дә кешене орышалар. (*Чәй урыны хәзерли, өстәлнең почмагына самавыр подносы, аның янына зәңгәр эмалированный пласкательный[6] куя.*) Көне-төне эшлисең дә эшлисең, аның өстенә тагын һәр көн – орыш та талаш. Миңа дисәләр, кырык чөйләре кырылып бетсен шунда. Хәбибрахман абыйларның да, Гафифә апаларның да театрга киткәннәрен әйтәм. Мине генә орышмасын әле, аларны да орышсын.

Ишектән Хәмзә килеп чыга, башын тәмам сабын белән күперткән. Бер кулына яшел кәләпүшен, бер кулына күзлеген тоткан.

Хәмзә. Бар, миңа муенга салырга эскәтер китер!

Биби чыгып китә. Хәмзә, өстәл янына килеп, пласкательный янына кәләпүшен, аның янына күзлеген куя. Биби бер каралган кызыл эскәтер китереп бирә.

(*Бибигә карап.*) Кая, миңа урындык бир әле. (*Кызыл эскәтерне муенына бәйли. Биби урындыкны китереп бирә.*

---

Вирд – дога.

*Янә Бибигә карап.*) Бар әле, теге якта камут тартмасында минем плитувам бардыр, шуны монда китер.

Биби чыгып китә.

(*Хәмзә урындыкка утыра.*) Заманалар бозылды. Әле менә бүген теге урыс сымак нәрсәләр театр уйнап, динне мәсхәрә кылмакчы булып йөриләр икән. Шуны булдырмаска йөреп, бүген ясигъга[7] бара алмый калдым. «Уйнатмагыз, рөхсәт юк!» – дип, Җамали үндергә әйткән идек, ул: «Минем эшем түгел, пристефкә үзенә әйтегез», – диде. Пристефне өйдә туры китереп булмады, галавага менгән идек, ул да алар яклы булырга кирәк: «Минем эшем түгел, сез палисәмистергә барыгыз», – диде. Аңа барган идек, бакзалга киткән. Губирнаторга да барган идек, бутишник: «Ул бу вакытта кеше кертми, иртәгә сәгать уникедә киленеңез», – диде. Шулай итеп, ахрысы, бәдбәхетләрне туктатып булмады. Алла боерса, икенче вакыт уйнатмабыз әле, пристефне алдан ук күреп куярбыз.

Ишектән Биби килеп керә.

(*Аңа карап.*) Нихәл, булдымы?

Биби. Менә, булды. (*Бритваны өстәлгә китереп куя.*) Коръән укучы шәкерт өйдә юк, ди, иптәшләре белән театрга киткән, ди.

Хәмзә (*ачуланып*). Ходай орган икән! Йөзләре генә кара булсын, бар, чакыр монда Фатихны!

Биби. Фатих абый ул син кайтканчы ук чыгып китте.

Хәмзә. Кая?

Биби. Шунда китте.

Хәмзә (*ачуы тагын да кабарып*). Кая шунда?

Биби. Шунда инде, театрга китте.

Хәмзә. Ә? Театрга? Кемнән сорап китте?

Биби. Берәүдән дә сорамады. Вәли кияүләр белән Хәбибрахманнар да киткәч, мин генә нишләп калыйм, диде дә китте.

Хәмзә (*тәмам алакаеп*). Ә? Ни дисең? Вәли кияү дә китте дисеңме?

Биби. Китте.

Хәмзә урыныннан сикереп тора.

Хәмзә. Хәбибрахман да киттеме? (*Бибинең өстенә бара.*)

---

Плитува (бритва) – пәке.

Б и б и (*кире чигенеп*). Китте.

Х ә м з ә (*яңадан өстенә барып*). Гафифә?! Факиһә?!

Б и б и (*яңадан кире чигенеп*). Алар да киттеләр.

Хәмзә кулларын йомарлап, иреннәрен тешләп, «эм-м-м-м!» дип, Бибинең өстенә килә башлый, Биби чыгып кача.

Х ә м з ә (*Биби чыгып киткәч, халыкка таба карап, кулларын сузып*). Йә, әйтегез инде, зинһар, нишләтим инде боларны? (*Гайрәтләнеп.*) Юк! Боларны болай гына калдырырга ярамый, йөзе караларны! Барам да якаларыннан тотып, өстерәп алып кайтам. (*Тиз генә өстәл янына килә дә пласкательныйны алып кия. Аны ыргытып бәрә дә.*) Тфү, чурт! (*Кәләпүшен алып кия. Аны да тиз генә ала да.*) Һай, йөзе каралар икән! Акылымнан шаштырасыз инде! (*Тиз генә эскәтерне муеныннан тартып алып, башын сөртә-сөртә, киемнәргә таба бара.*) Мин сезгә бирим әле кирәгегезне! (*Өстенә кия башлый, кычкыра.*) Кая киез ката? Китерегез тизрәк, ә, менә монда икән! Йөзе караларны! (*Ашыгып-ашыгып кия.*) Бәдбәхетләрне, муены астына килгәннәрне!.. (*Чыгып китә.*)

П ә р д ә т ө ш ә.

## БҮЛӘК ӨЧЕН

*Комедия 1 пәрдәдә*

УЙНАУЧЫЛАР:

Ә х м ә т җ а н – Казан бае, 45 яшьләрендә.
Х ә м и д ә – Әхмәтҗанның хатыны, 45 яшьләрендә.
Г а б д у л л а җ а н – Әхмәтҗанның углы, 22 яшьләрендә.
М ә х ү п җ а м а л – яучы хатын, 60 яшьләрендә.
Б ә д р и җ а м а л – асрау.

Казанда, Әхмәтҗан байның өендә. Өй җиһазлары иске заман нәрсәләре белән кара-катыш. Стенада рамкалы язулар. Пәрдә ачылганда, Ә х м ә т җ а н белән Х ә м и д ә күренә. Габдуллаҗанны өйләндерү хакында киңәш итәләр.

БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ә х м ә т җ а н, Х ә м и д ә.

Ә х м ә т җ а н. Теләсәң нәрсә диген, хатын, мин бер дә төшенмим.

Х ә м и д ә. Бер дә төшенәсе-нитәсе юк, кызы менә дигән кыз. Ул матур, ул сылу, күрсәң – исең китәр. (*Урта бармагын күрсәтеп.*) Урта бармак шикелле бер кыз инде.

Ә х м ә т җ а н. Тукта әле, хатын, мин тагы да төшенмәдем; үзең әйтәсең: «Бик матур, бик сылу», – дип, ә үзең тагы әйтәсең: «Урта бармагың төсле», – дип. Синең урта бармагың төсле буынтыклы-буынтыклы булса, бер дә матур булмый инде ул.

Х ә м и д ә. Җә, ярар инде. Мыскыл итеп утырган булма. Бар кеше дә синең шикелле итеп сөйләшә белми. Син генә ул бик матур итеп сөйләшәсең. Алай мыскыл итмә. Урта бармак шикелле дигәнне яратмасаң, шәм шикелле инде алайса.

Ә х м ә т җ а н. Монысы инде тагы да начар булды. Шәм шикелле иелми-бөгелми торган, үрәгә каткан нәрсә булгач, безгә бер дә мәгъкуль кеше түгел икән. Ул, алай

М ә г ъ к у л ь – лаек, яраклы.

булгач, мине дә, сине дә, Габдуллаҗанны да искә-санга алмас.

Хәмидә. Бар икән, Ходаем! Мине һаман мыскыл итәсең, мин сиңа чынлап сөйлим, ә син һаман миннән көләсең.

Әхмәтҗан. Бер дә көлмим, бары тик син «шәм шикелле» дигәч, иелми-бөгелми торган бер кыздыр дип кенә әйтәм.

Хәмидә. Юк, юк, атасы, бик чибәр, бик әйбәт кыз, бөтенләй менә, каймак шикелле бер кыз инде.

Әхмәтҗан. Чәйгә салып эчәргә дә яраклы икән алайса.

Хәмидә. Тагын көләргә тотындың инде! Каймак дигәнне яратмасаң инде алайса, кәләвә шикелле, бал шикелле, кәнфит, прәннек шикелле.

Әхмәтҗан. Хатын, инде алай булгач, мин бернәрсә дә әйтә алмыйм. Ул кадәр баллы нәрсә булгач, бик төче нәрсә булып, безне бөтенләй үтләтеп бетермәсә ярар иде дип куркам.

Хәмидә. Бер дә хафаланма, атасы, килешерләр әле, Габдуллаҗан да бик яратыр. Менә үзебез бит әле егерме биш елдан бирле бик әйбәт, бик килешеп торабыз.

Әхмәтҗан. Торса бит, син алай кәнфит шикелле баллы гына түгел идең, синең әчкелтем-төчкелтем чакларың да бик күп буладыр иде. Син бит кайсы вакытта керән, гәрчитсә шикелле әче булып, бөтенләй күзләремнән яшьләр китерә торган идең.

Хәмидә. Ансы өчен бер дә хафаланма, дөнья булгач, аларның да әче вакытлары булыр әле. Озак торгач, бал да чымырдап әчи, безнең Габдуллаҗан үзе дә әче суганнан бер дә ким булмас.

Әхмәтҗан. Җә, сүзем бетте инде алайса, үзегез Габдуллаҗан белән теләсәгез ничек килешегез. Әле тик беркөннәрдә үзең, Хәйриләрдән аштан кайткач: «Хисаминың кызын күрдем, бигрәк конарсыз нәрсә икән – үзе озын, үзе чыра шикелле, шадра, авызы кыек, чепи күзле, кәкре аяклы, шулай да булса, тагын әллә кем булган булып, бүксәсен киереп утырган була», – дип сөйләгән идең. Үзең шулай дип сөйләгәнгә күрә генә, безгә муафикъ кеше булмас дип куркам.

Хәмидә. Юк, юк, атасы, бер дә курыкма! Бик әйбәт, бик сылу, бик уңган, җиләк шикелле бер кыз. Эшкәкешкә дә оста, бик булган, бик чибәр, бик купшы, ди.

---

Муафикъ – яраклы.

Вәгъдә бирнәсенә дә, кәбен бирнәсенә[1] дә, актык бирнәгә дә чачагы-чугы белән бик әйбәт, калын ука тирәкле асыл бирмәкче булалар, ди. Безгә дигән намазлыкларын да, кияүгә дигән аякчу, намазлыклар белән бергә, моннан үрнәкләр җибәреп, иллешәр тәңкәгә Мәскәүдән эшләтеп китерткәннәр, ди. Вәгъдәгә дә өч төрле как-төш бирәчәкләр, ди. Кияүгә дигән кәләпүшне мыскалы егерме бишәр тәңкәлек кырык мыскал энҗедән эшләтәчәкләр, ди. Кияүгә булачак сәгатьне Хисами кода үзе...

Ә х м ә т җ а н. Тукта әле, Хисами безгә әле кода булып җитмәгән.

Х ә м и д ә. Җә, ярар ла, җураган җуш килә, диләр. Кода булачакка күрә авызыма шулай туры килеп торадыр инде. Нәрсә әйтәдер идем соң, ә, әйе, кияүгә дигән сәгатьне Хисами кода үзе...

Ә х м ә т җ а н. Хисами кода түгел!

Х ә м и д ә. Ярар ла инде, Хисами бай үзе Мәскәүгә барып, ике йөз тәңкәгә алып кайткан, ди. Ул чипүшкәсен күрсәң, менә бөтенләй искитәрлек, ди. Әсма кодагый...

Ә х м ә т җ а н. Тфү! Әсма да кодагый түгел бит әле.

Х ә м и д ә. Җә, җә, Әсмабикә...

Ә х м ә т җ а н. Кичә генә «курнус Әсма» дип йөриләр иде әле, хәзер инде бүген бикә дә булып җиткән.

Х ә м и д ә. Бикә булмый ни, бикә шул! Әсмабикә кияүгә берлиант кашлы йөзек тә алдырып бирмәкче була, ди.

Ә х м ә т җ а н. Уф, тыңлап торып та арып беттем инде.

Х ә м и д ә. Арырсың да шул, ул кадәр күп нәрсә биргәч. Син үзең әле Газизәне биргән вакытта гомердә Хисами кода...

Ә х м ә т җ а н. Кода түгел, дим!

Х ә м и д ә. Хисами бай шикелле итеп бирә алмассың.

Ә х м ә т җ а н (*халыкка карап*). Бай, имеш, Мәскәү малы белән кибетен тутыргач та, хатын аны бай дип белә тагын.

Х ә м и д ә (*сүзендә дәвам итеп*). Карават чаршаулары да плүштән булачак. Караватын да Хисами кода, әй, ялгыш әйтәм, Хисами бай, Мәкәрҗәгә барганда, йөз егерме тәңкәгә алып кайткан. Ул савыт-саба, урын-җир, түшәкястык, сөлге, эскәтер, тастымал, намазлык, чаршауларның бер дә иге-чиге юк, ди.

Ә х м ә т җ а н (*халыкка карап*). Тәмам бер талчук кибете ачарлык бар икән.

---

[1] Ч и п ү ш к ә (цепочка) – сәгать чылбыры.

Х ә м и д ә (*сүзендә дәвам итеп*). Ун сандык нәрсә мал белән дың тулы, ди. Хисами кода... әй, тфү, Хисами бай приданны да бик яхшы итеп хәзерләтмәкче була, ди. «Кызларым байлыгым бар вакытта рәхәтләнеп калсыннар, һәммә җирләрен җитеш итеп бирәм, үз исәнлегемдә урнашып калсыннар», – дип әйтә, ди. Ун табынлык савыт-саба алган.

Ә х м ә т җ а н (*халыкка карап*). Әүвәлгеләре мануфактур кибете булган иде, инде монысы белән чынаяк кибете ачарга мөмкин булачак.

Х ә м и д ә (*сүзендә дәвам итеп*). Чәнечке, пычаклары – һәммәсе дә көмеш саплы булачак. Самавыры, чәйнекләре, куфи савытлары бары да көмештән.

Ә х м ә т җ а н (*халыкка карап*). Йа Алла, башым катты инде.

Х ә м и д ә (*сүзендә дәвам итеп*). Гуркә шкафы бик зур, бик һәйбәт, кызыл агачтан ясалган, ике дүжинә урындыклары, көзгеләре – һәркайсы кызыл агачтан, ди. Ике өстәл, туритский диван, кәнәфи белән йомшак эскәмияләр...

Ә х м ә т җ а н (*халыкка карап*). Йа Алла, кайчан гына туктар икән!

Х ә м и д ә (*сүзендә дәвам итеп*). Гелдируплар, кантур өстәлләре дә бирәчәк, ди. Ул шарлы лампаларының матурлыгына бер дә чама юк, ди. Ләгән-комганнары һәммәсе никелдән булачак, ди. Тагы көмеш...

Ә х м ә т җ а н. Уф! Йә, зинһар, җитәр инде, тыңлап торып та арып беттем. Ул әйткән нәрсәләрнең бары да булса, зур кибет ачарлык мал булыр. Без аны кайда куеп бетерербез? Ул нәрсәләрне куярга аңар үзенә бер йорт салырга кирәк булыр.

Х ә м и д ә. Аның өчен бер дә кайгырма, малы булгач, куярга урыны табылыр. Хисами кода...

Ә х м ә т җ а н. Кода түгел әле!

Х ә м и д ә. Ялгыш әйтәм. Хисами бай Габдуллаҗанны бик яраткан, ди. Шуңа күрә бер сүз дә әйтмиенчә бирмәкче була, ди.

Ә х м ә т җ а н. Йә, ярар, хәерле булсын. Әнә үзең теләсәң ничек итеп Габдуллаҗанны күндер дә, ул үзе риза булса, алырбыз. Габдуллаҗанны чакырт та үзең сөйләш. (*Чыгып китә.*)

---

Г е л д и р у п – гардероб. – *Г.Камал искәр.*

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Х ә м и д ә ялгыз, үзалдына сөйләнә.

Х ә м и д ә. Безнең өйдә бер дә акыллы кеше юк. Шулкадәр бай кеше «кызымны бирәм» дип торган чакта, сакалыңны салпырайтып, «мин белмим» дип утыр, имеш. «Кыз матур түгел», – диләр. Аның матурлыгы пычагымамыни? «Мәхәббәт җәмал теләмәс», мәхәббәтләре генә булсын. Үзебез әле менә егерме биш елдан бирле торабыз. «Син ямьсез» дип, урамга чыгарып ташлаган кеше юк. Матур да булса, буе-сыны да кешенеке төсле булса, андый бай кешеләр, шулкадәр бүләкләр бирә-бирә, кызларын безгә этеп-төртеп бирмәсләр иде. Баланы егерме ел үстереп тә, бер җүнле, яхшы бирнә дә киеп калмагач, дөньяда торганың ни дә, тормаганың ни! Әнә Гыйльми Бәдриенең кызы бик чибәр дә бит, матурлыгына карап аны алып булмый. Аларның җүнле бирнә бирәселәре дә юк, күп булса бер асыл бирнә бирерләр. Кодагый булган кешенең ашлы-сулы, бай булганы күңелле. Улыңны өйләндереп тә, бер рәхәтләнеп кунакка йөреп калмагач, дөньяның ни рәхәте бар, дөнья ике килми ул.

Ишектән, кулына бер китап тотып, Г а б д у л л а җ а н килеп чыга.

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Х ә м и д ә, Г а б д у л л а җ а н.

Г а б д у л л а җ а н. Әни, аш тиз буламы? Минем учителгә барасым бар.

Х ә м и д ә (*артына борылып карап*). Әйдә, кил әле монда, учителгә барырга аннан ары да өлгерерсең. Урыс сабагы укып йөрергә син кечкенә бала түгел инде. Кил әле, утыр менә монда, без сине хәзер өйләндермәкче булабыз.

Г а б д у л л а җ а н. Кемне?

Х ә м и д ә. Сине.

Г а б д у л л а җ а н. Кит аннан, мин өйләнмим! (*Чыга башлый.*)

Х ә м и д ә. Тукта, кайда барасың? Мин бит сиңа уйнап сөйләмим, син бит инде бала түгел.

Г а б д у л л а җ а н. Әле беркөн генә үзең Гыйльми Бәдриләреннән яучы килгәч: «Әле улыбыз бик яшь, бала гына әле, өйләндермибез», – дигән идең.

Х ә м и д ә. Йә, күп телеңә салынып торма, кил, утыр!

---

Җ ә м а л – матурлык.

Менә хәзер яучы киләчәк, вәгъдә куеп җибәрәбез. Атаң да бик мәгъкуль күрде.

Габдуллаҗан. Кемнән киләчәк?

Хәмидә. Хисами байдан, Хисами бай сине күреп бик яраткан да сиңа бик зур придан белән кызын бирмәкче булган.

Габдуллаҗан. Мин ул кызны бер дә күргәнем юк бит.

Хәмидә. Җүләр, кызны күреп алалармыни аны? Менә мине дә атаң күреп алмады.

Габдуллаҗан. Мин беркөн «Өйләнү» дигән бер китап укыдым. Анда алачак кызның ни төстә икәнен, холкын-фигылен белеп алырга кушкан.

Хәмидә. Куй ул юк сүзләреңне, бетмәс андый сезнең такмаза китапларыгыз. Син шуны әйт: ризамы, юкмы?

Габдуллаҗан. Тукта әле, әни, ул кыз соң нинди, ни төстә, буе-сыны ничек, матурмы?

Хәмидә. Ансын бер дә тикшереп торасы юк, кыз бик һәйбәт, бик матур.

Габдуллаҗан. Буе озынмы?

Хәмидә. Озын, озын, бик озын, бик зифа!

Габдуллаҗан. Мин укыган китапта хатынның буе иреннән бераз кыскарак булсын дигән.

Хәмидә. Озын дигәч тә, синең шикелле үк озын түгел инде. Синнән бераз кыскарак булыр. (*Халыкка карап.*) Озын булса ни зарар? Баскыч куеп менмәс әле, торырлар шунда.

Габдуллаҗан. Кашы ни төсле, карамы?

Хәмидә. Һәммә кешенең дә кашы кара булып бетми инде. Кара булмаса да, бик матур, бик нечкә. Кара кирәк булса – буярсыз. Бу чагында инде кашны гына түгел, чәчне дә буяп йөриләр.

Габдуллаҗан. Төскә ничек, түгәрәк битлеме?

Хәмидә. Җә инде, күп сөйләнеп торма, адәм фәрештә булмый. Кеше кешедән артык булмас. Мәхәббәтегез генә булсын, мәхәббәтегез булса, хур кызыннан да артык булыр. Син бигрәк менә, нәрсәләр бирәләр, дип сора. Сиңа дигән чикмәнлекнең аршынын унике тәңкәдән алганнар, ди. Кәләпүшләре кырык мыскал энҗедән эшләнгән булачак, ди. Алтын сәгатьләрен ике йөз тәңкәгә алганнар, ди. Сиңа бик һәйбәт берлиант йөзек бирәчәкләр, ди. Ул башка приданнарының исәбе дә юк, ди.

Әхмәтҗан килеп керә.

Әнә атаң да кереп килә. (*Шыпырт кына.*) Күп терәлеп торма, тизрәк «риза» диген.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ә х м ә т җ а н, Х ә м и д ә, Г а б д у л л а җ а н.

Ә х м ә т җ а н. Нихәл, килешәсезме?

Х ә м и д ә. Килештек, килештек, Габдуллаҗан да «риза» ди.

Г а б д у л л а җ а н. Әле мин... мин риза дип әйтеп бетермәдем ич.

Х ә м и д ә. Ул ни дигән сүз тагын? Риза, риза, атасы, бик риза. Ата-анасы риза булган кешегә риза булмаска, ул ни дигән сүз?

Ә х м ә т җ а н. Тукта әле, сиңа әйтәм, ата-анасы риза дип, эшне бетереп куйма әле син. Әле бит минем дә риза булып җиткәнем юк. Бая мин әле аларның нәрсә сорыйсыларын да белеп бетерә алмадым. Алар мәһәргә нәрсә сорыйлар соң?

Г а б д у л л а җ а н. Әле мин дә сорашып бетерә алмадым, ул кыз ни төсле соң?

Х ә м и д ә (*Габдуллаҗанга*). Тик тор син, атаң алдында әдәпсезләнеп сорап торма! Синең шикелле җүләргә ярамаган тагын! Кыз кыз булыр инде, фәрештә булмас. (*Әхмәтҗанга.*) Инде дус-иш арасында оятка калырлык итеп биреп булмас. Үзләре шулкадәр зурлый торып та, бик кечкенә итеп җибәрергә ярамас.

Ә х м ә т җ а н. Бик күп акча чыгып, кыйммәткә төшәрлек булса, нишләрбез?

Г а б д у л л а җ а н. Бик ямьсез, бик аңгыра булып, аяклы каза булырлык булса, мин нишләрмен?

Х ә м и д ә (*Габдуллаҗанга*). Каза, каза! Син үзең әле аяклы каза: күп лыгырдап торма! (*Әхмәтҗанга.*) Инде, акча күп чыга дип, улыңны өйләндерми тора алмассың, хәлдән килгән кадәрле тырышырсың. Дус-иш арасында биткә оят китерерлек итмәссең. Күп дип әйтергә, алар әллә нәрсә сорамыйлар: эче-тышы, әйләнәсе белән камзуллык чатма, аннан соң хәзерге заманча булсын дип, бер озын сак. Егерме биш мыскалдан калфак – анысын инде егерме мыскалдан эшләтсәң дә ярар, – аннан ары ике зур сандык. Аннан кала бер аксыл сирый җефәкле, чите каймасыз мамык шәл белән яхшы ише бер җефәк шәл, кырык мыскал энҗедән бер муен энҗесе. Аннан ары бер көзге сорыйлар. Көзгесе арты шкафлы булсын, хәзер инде баганалы көзгенең мудысы бетте, дип әйтәләр, ди.

Ә х м ә т җ а н (*халыкка карап*). Монысы әле аның баласы, мичтә калгандыр анасы. (*Хәмидәгә.*) Ничек тә шул дүрт-биш мең тәңкәсез котылып булмас.

Х ә м и д ә. Нинди дүрт-биш мең тәңкә? Булса тагы, әлхәмделиллаһи, аңар гына чыдарлык хәлебез бар әле.

Ә х м ә т җ а н (*халыкка карап*). Ул инде, мөгаен, кибеттәге малның барысы да минеке дип белә торгандыр.

Х ә м и д ә (*сүзендә дәвам итеп*). Мин башка вакытта үзем дә сине борчымыйм. Вакытлы-вакытсыз әйбер сорап җөдәткәнем юк, асыл күлмәкләрем саргаеп, саташып беткән. Шулай да синнән асыл күлмәк алып бир дип сораганым юк.

Г а б д у л л а җ а н (*халыкка карап*). Алдалый, валлаһи, алдалый, ышанмагыз, сандыкта һич киелмәгән биш-алты асыл күлмәге череп ята.

Ә х м ә т җ а н. Бөләр хәлем юк, улымны өйләндерәм дип, бар сумамнан язар хәлем юк. Дүрт-биш мең тәңкә тотып өйләндерергә минем хәлемнән килми. Безгә нигә ярамаган уртачарак кеше? Тотарбыз да Гыйльми Бәдриенең кызын алырбыз. Аның кызы укымышлы да, төскә дә матур, диләр.

Г а б д у л л а җ а н (*үзалдына*). Менә монысы өчен этигә рәхмәт!

Х ә м и д ә. Алды ди, алмый ни, ул хәерчеләрнең кызларын алып торырга кирәк! Аның анасы дөньяда бер ямьсез хатын. Кияү йөртергә бер җүнле атлары да юк. Аларның бирнәгә биргән асылларының да үтәсеннән көн күренерлек булыр. Аның шикелле сидрәп беткән асыллар минем үземдә дә бетәсе юк.

Ә х м ә т җ а н. Кызны бит синең өчен алмыйбыз. Менә Габдуллаҗан ни әйтер? (*Габдуллаҗанга карап.*) Габдуллаҗан, син кайсын алырга риза? Хисами кызынмы, Бәдри кызынмы?

Г а б д у л л а җ а н. Бәдри кызын.

Х ә м и д ә (*йодрык күрсәтеп*). Оятсыз, атаң алдында «Бәдри кызын» дип әйтеп торырга ничек оялмыйсың? Әбәү, оятсыз!

Ә х м ә т җ а н. Соң ничек дип әйтсен, «Хисами кызын алам» дип әйтсенмени?

Х ә м и д ә. Алай дип әйтсә бер хәер, аларның, ичмаса, кешеләре кеше төсле. Мин ул Бәдринең хатынын гомеремдә дә «кодагый» дип әйтәсем юк.

Ә х м ә т җ а н. Кодагый дип әйтмәсәң, башкача әйтерсең, аннан безгә ни зарар?

Х ә м и д ә. Монысы да тагы, улы белән бер яклы булган булып, миннән көлеп маташа. (*Габдуллаҗанга.*) Җә, әйт тизрәк, Хисами кызына ризамы?

Г а б д у л л а җ а н. Мин аны белмим бит.

М ә х ү п җ а м а л керә.

Х ә м и д ә (*тиз генә урыныннан сикереп торып, Әхмәтҗанга карап, кашларын җимереп, күз кыса, аннан, Габдуллаҗанга барып, акрын гына*). Кара аны, минем сүздән чыгасы булма, «риза» диген.

## БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ә ү в ә л г е л ә р һәм М ә х ү п җ а м а л.

М ә х ү п. Исәнмесез!

Х ә м и д ә (*каршына барып, Мәхүпнең башыннан чапанын алып*). Мәхүпҗамал абыстай, исән-сау килдеңме? Әйдә, түргә уз! (*Ишек янына барып.*) Бәдриҗамал! Кая, самавыр куеп җибәр!

М ә х ү п. Хәмидә, бер дә мәшәкатьләнмәгез, минем бер дә эчәсем килми, әле Әсмабикәләрдән килешем, аларда бик озаклап чәй эчтем. Инде, Алла боерса, алар эшне башларга торалар. Сездән вәгъдә алуга гына эшләре тереләп тора. Мин сезнең нәрсәләр бирмәкче булганыгызны аларга барып сөйләдем, бик яраттылар. Хәмидә кодагый ул...

Ә х м ә т җ а н. Әле Хәмидәнең кодагый булып җиткәне юк.

Х ә м и д ә. Җә, зинһар, кешенең сүзен бүлмә әле. Кодагый булмыйча, нәрсә булсын соң? Кызын биргәч, билгеле, кодагый кодагый була инде. Җә, җә, Мәхүпҗамал абыстай, сөйлә, аңар карама! Ул әле бүген кире ягы белән торган.

М ә х ү п. Әсма кодагыең әйтә...

Ә х м ә т җ а н. Әсма да кодагый түгел әле.

Г а б д у л л а җ а н (*үз-үзенә*). Һәм булмас та, Алла боерса, теләсәләр нишләсеннәр, мин аны алмыйм!

Х ә м и д ә. Җә, җитәр инде, зинһар, әллә тилердеңме инде югыйсә?

М ә х ү п. Җә, аның дигәненчә булсын инде алайса, Әсмабикә әйтә: «Хәмидә ул бик булган, бик мәнле кеше, Алла боерса, кеше арасында битебезгә оят китермәс әле», – ди. Әле соң сез инде нинди киңәштә торасыз? Кичәге вәгъдәгездән, шаять, кайтмагансыздыр бит? Мин инде, Алла боерса, иртәгә вәгъдә бүләге итәргә килермен. Бүген шуны кереп белешеп чыгыйм дидем.

Ә х м ә т җ а н. Ул ничек «кичәге вәгъдә»? Мин бит әле бу эшне бүген генә белдем.

Г а б д у л л а җ а н. Мин дә хәзер генә ишеттем.

М ә х ү п. Ничек ул алай?

Х ә м и д ә. Җә, сөйлиләр шунда, вәгъдәбез вәгъдә инде, Мәхүпҗамал абыстай.

Ә х м ә т җ а н. Юк әле, анасы, син алай димә! Мин ул кадәр зурдан кубып, күп акчалар чыгарырга риза түгел.

Г а б д у л л а җ а н. Мин бөтенләй кызны алырга да риза түгел.

М ә х ү п. Сөбханалла, әстәгъфирулла! Бу ни дигән сүз! Сез мине алай итеп кеше алдында көлкегә калдыра күрмәгез. Мин инде аларга тәмам вәгъдә куеп килдем.

Ә х м ә т җ а н. Мин вәгъдә-мәгъдәне белмим. Ул кадәр күп мәһәр сорый торган булсалар, мин колак сөенчесе алышырга риза түгел.

Г а б д у л л а җ а н. Мин андый белмәгән кызны алмыйм.

Х ә м и д ә. Мужик шикелле, тупас итеп, «колак сөенчесе» дип сөйләмә инде, «вәгъдә бүләге» диген. Алабыз, Алла боерса, алабыз. Хәерле сәгатьтә булсын. Син дә, Габдуллаҗан, олы кешеләр алдында алай әдәпсезләнеп торма. Менә кияү булып кергәч күрерсең. Ул вакытта аны син күрмичә, әллә кем күрмәс. Кызны кияүгә күрсәтеп бирмиләр.

М ә х ү п. Шулай шул, кызны инде аны кияүгә биргәндә күрсәтеп бирмиләр. (*Халыкка карап.*) Күрсәтерлек урыны булмагач, нәрсәсен күрсәтсеннәр!

Г а б д у л л а җ а н. Мәхүпҗамал абыстай, мин бит аны бер дә белмим. Чибәрме соң ул кыз?

М ә х ү п. Чибәр, улым, бик чибәр. (*Халыкка карап.*) Күрсәң, гайрәтең чигәр.

Г а б д у л л а җ а н. Укыган кызмы соң ул?

М ә х ү п. Укыган, улым, укыган, бик зур укыган. (*Халыкка карап.*) Әлифне таяк дип тә белми, миңа аның нигә кирәге бар? Бары тик эш кенә булсын да, үземә тиешле сәдака-хәерне генә күбрәк алыйм.

Х ә м и д ә. Мин ул кызны кече-кечедән беләм. Бик инсафлы, бик бастырынкы, бик чибәр бала, укымышы да зур, диләр, бик озак укыды.

М ә х ү п (*халыкка карап*). Бу җүләр дә инде, минем шикелле, бүләккә кызыгып, кызның начар икәнен белә торып, бергәләшеп мактый.

Г а б д у л л а җ а н. Урысча да укыганмы?

М ә х ү п. Урысча да... Әһем, әһем...

Х ә м и д ә. Укыган, укыган, бик яхшы укыган. Атасы өйләренә марҗа китертеп укыткан. Укымаган булса тагын, алгач, менә үзең укытырсың.

М ә х ү п (*халыкка карап*). Бу миңа караганда да ял-

ганларга остарак икән. Ул кадәресен әйтергә минем телем бармаган иде.

Хәмидә. Шул инде менә, алайса, Мәхүпҗамал абыстай, иртәгә вәгъдә бүләге алышырбыз, диген.

Габдуллаҗан. Мин әле һаман риза булып җиткәнем юк.

Әхмәтҗан. Мин дә күп акча тотарга риза түгел!

Хәмидә. Җә, җә, Мәхүпҗамал абыстай, аларның сүзләренә карама, риза, риза, иртәгә алардан да вәгъдә бүләге китерерсең, бер-ике көннән үк иҗабе кабул[2] итәрбез.

Мәхүп. Алар инде күптән хәзер, намазлык, чолгауларны күптән хәзерләп куйганнар. Ходай боерса, вәгъдә бирнәләрен дә бик һәйбәт итәчәкләр, сиңа күлмәклек җон, кияүгә...

Хәмидә (*урыныннан сикереп торып*). Нәрсә дисең?

Мәхүп. Сиңа күлмәклек җон, кияүгә...

Хәмидә. Күлмәклек асыл диген!

Мәхүп. Ялган булмасын, миңа күлмәклек җон дип әйттеләр. Хәтта, ялгыш булмасын дип, кайтарып-кайтарып сорадым, җон, диде.

Хәмидә (*авызын бүлтәйтеп, бик ачу белән, бер торып, бер утырып*). Ишкәннәр икән, вәгъдә бүләгендә үк алай итеп мыскыл иткәч, башкаларында алар тагын да изәрләр. Җон бирнә киярлек булгач, Хисами кызын алалар иде, ди. Аның карачкы шикелле кызын алмасам, дөньяда кыз беткән иде, ди.

Габдуллаҗан (*үзалдына*). Аллага шөкер, әни үзе дә кызның «күркәм» сыйфатларын саный башлады.

Әхмәтҗан (*үзалдына*). Ходайга шөкер, кыйммәтле туйдан котылам, ахры.

Хәмидә (*сүзендә дәвам итә*). Аның тилиграм баганасы шикелле озын, шадра, кыек авызлы, кәкре аяклы кызын алмасам да, дөньяда киленсез калмам әле.

Габдуллаҗан (*үзалдына кулларын уып, шатланып*). Шөкер, эшләр уңайлана.

Хәмидә (*сүзендә дәвам итеп*). Аның селте көянтәсе шикелле сыгылып төшкән кызына җефәк шикелле улымны әрәм итәмме соң мин!

Габдуллаҗан.<br>
Әхмәтҗан. } Һәй, бәрәкаллаһ!

Бәдриҗамал (*ишектән кереп*). Мәхүп абыстай, сезне Хисами байларның асравы чакыра, монда гына чыгып керсен әле, ди.

Мәхүп чыгып китә.

## АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Әүвәлгеләр, соңра Мәхүп.

Хәмидә (*сүзендә дәвам итеп*). Бай дигәч тә, бик исләре киткән, аның кеше чыкмаган өрәк шикелле кызын, бүләге дә булмагач, шайтаным ала. Улым, син дә бер дә хафаланма! Алла боерса, менә дигән кыз алырбыз.

Габдуллаҗан (*Хәмидә янына килеп*). Юк, әни, бер дә хафаланмыйм, бәлки булмый калганына шатланам гына...

Әхмәтҗан (*Хәмидәнең аркасыннан сөеп*). Хатын, акча күп чыкмаганлыгы өчен мин дә бик шатланам.

Хәмидә. Шулай булмый ни, аларның колга шикелле озын, шадра, төссез, ямьсез, кыек авызлы, кәкре аяклы кызларына, бүләге дә булмагач, эт барсынмыни? Аңгыралар, эш башламас борын ук үзләренең мәнсезлекләрен белдерделәр, мәнсезләр, эштән чыккан шыр тилеләр!

Мәхүп (*ишектән ашыгып кереп*). Менә син, ә, харап булдым бит, ялгышлык белән харап булдым бит! Әсмабикә, үзенең каушавыннан зиһеннәре таралып, сиңа күлмәклек җон дип сөйләп җибәргән. Җон түгел икән, чачагы-чугы белән күлмәклек ука тирәкле асыл икән. Әле асравын шуны әйтергә җибәргән. Кодагый, зинһар, гаеп итә күрмәсен, үземнең зиһенсезлегем белән бик зур оятлы булдым, кодагый, зинһар, үпкәли күрмәсен, дигән.

Әхмәтҗан (*кулларын җилпеп*). Очты инде ул кодагый булулар. (*Көлә.*)

Габдуллаҗан (*нос ясап, мыскыл итеп*). Үтүт инде хәзер кодагый булырга! (*Көлә.*)

Хәмидә (*уынгалап*). Менә син, ә, мин дә ашыгычлыгым белән ачуланып ташладым, оятлы булдым, оятлы булдым. (*Ялынганрак кыяфәттә.*) Карагыз әле, атасы, улым, әле дә эш узмаган бит, мин ул сүзләрне ачуымнан гына ялгыш сөйләп җибәрдем. Кодагый бик мәнле, бик һәйбәт кеше, эшнең җаен бик белә торган кеше, кыз да ямьсез түгел, бик сөйкемле кыз...

Габдуллаҗан. Кодагыең эшнең җаен белсә, мин дә бик яхшы белдем инде. Син, үзеңә асыл бирнәләр килсен өчен, минем башымны колга, тилиграм баганасы, белмим, тагын әллә нәрсә шикелле озын, ямьсез, шадра, кыек авызлы, кәкре аяклы бер кызга бәйләмәкче булган икәнсең. Юк инде, хәзер торып тор, ул эшләр бик тиз генә эләкмәс! Хуш, сау булыгыз! (*Ишекне бик каты ябып чыгып китә.*)

Әхмәтҗан. Рәхмәт, анасы, рәхмәт, мине дә күп акча тотудан коткардың. (*Чыгып китә.*)

Х ә м и д ә (*югары карап, олылаган тавыш белән*). Әй Раббым, нинди гөнаһ шомлыкларым булды икән? Тәмам булган эшне тараттым.

М ә х ү п (*халыкка карап, җылаган тавыш белән*). Монда иң бәхетсез кеше мин! (*Хәмидәне төртеп күрсәтеп.*) Шушы җүләрнең тиктормас теле аркасында ничә күлмәкләрдән, илле-алтмыш тәңкә сәдака-хәер акчаларыннан коры калдым.

П ә р д ә  т ө ш ә.

# УЙНАШ

*Драма 3 пәрдәдә*

ДРАМАДА ТАСВИР ИТЕЛГӘН ӘШХАС:

Әнвәр – яшь, фасикъ татар бае.
Әхмәтҗан – урта хәлле, ярмарка йөрүче татар.
Сәрбиҗамал – Әхмәтҗанның хатыны.
Мөгълифә – явыз карчык.
Фәтхерахман – маклер.
Әптери – хулиганрак татар.
Хәзрәт – уртача яшьле.
Сафа, Әхмәди – шаһитлар.
Кеше – шәһәрдән узып баручы кеше.
Исерек татар – юан корсаклы бер татар.
Хозяин – зур сакаллы, кызыл борынлы рус.
Интеллигент, студентлар, курсистка һәм халык.

Вакыйга шәһәрдә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шәһәр бакчасы. Көндез. Каршы тарафта – эскәмияләр. Ара-тирә ерактан граммофон тавышлары ишетелә. Пәрдә күтәрелгәндә, сәхнәдә һичкем юк. Бераздан парлы вә ялгыз кешеләр йөрештергәлиләр. Бер тарафтан Фәтхерахман, икенче тарафтан бер Кеше килеп чыгалар.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кеше вә Фәтхерахман.

Фәтхерахман (*Кешене туктатып*). Исәнме, агайэне!

Кеше (*туктап*). Аллага шөкер, ни йомыш, абзый?

Фәтхерахман. Күз күргән, таныган кеше төсле күренәсең, нихәл, ни эшләп йөрисең? Кош тотарга чыктыңмыни? И-һи-һи!

---

Фасикъ – бозык.

К е ш е. Ничек «кош тотарга»?

Ф ә т х е р а х м а н. И-һи-һи! Аңламаганга салынган буласың тагын. Беләбез инде без сезнең шикелле егетләрне. Утыр әле менә монда.

Утыралар.

К е ш е. Чынлап, абзый, аңлый алмадым, мин бит, абзый, мондагы кеше түгел. Мин чит җир кешесе, әле Макариягә барырга дип Пермьнән киләдер идем дә, пароход пристендә озак торачак булганга күрә, шәһәрегезне карап, күреп чыгыйм дип кергән идем.

Ф ә т х е р а х м а н. Алай булса, хәер, сүзем бетте. Мин сине кош тотарга чыккансыңдыр дип уйлаган идем.

К е ш е. Мин әле һаман аңлый алмадым, ул кош тоту дигән сүз нинди сүз соң ул?

Ф ә т х е р а х м а н. И-һи-һи! Чит җир кешесе булгач, аңламассың да шул. Беләсең бит, хәзер Макария өсте, һи-һи-һи! Макария өстендә безнең бакчаларда матур асыл кошлар бик күп була. И-һи-һи-һи! Менә синең шикелле матур егетләр шул асыл кошларны эләктерергә бакчага чыгалар. Аңладыңмы инде, и-һи-һи-һи! Ие, менә шул инде алайса, аңласаң.

К е ш е. Ул асыл кошлар Макария вакытында гына кайдан киләләр соң алар?

Ф ә т х е р а х м а н. Кайдан килсеннәр, ояларыннан чыгалар. Ияләре Макариягә киткәч, оялары ачык кала да, шуннан очып чыгалар.

К е ш е. Абзый, мин һаман да аңламадым. Нинди оядан чыгалар?

Ф ә т х е р а х м а н. Яхшы, ярый, аңламасаң, хәерле булсын инде алайса. Мин сине юлыңнан туктаттым бугай, пароходка төшәргә соңга кала торгансыңдыр, йә, ярый, хуш, сау бул, мин монда бераз утырам әле.

К е ш е (*урыныннан торып*). Ярый, хуш, сау булыгыз, сез үзегез дә шул, кош тотарга чыктыгызмыни?

Ф ә т х е р а х м а н. Ие, без кош тотучыларны тотарга чыктык, ярый, хуш, бар, юлыңнан калма.

К е ш е (*читкә карап*). Шпион икән, белдем. Тизрәк таярга кирәк. (*Күздән югала.*)

Ф ә т х е р а х м а н (*артыннан карап калып*). Мәгънәсез кеше икән, аңгыра нәрсә икән, вәземләп сөйләгәннең дә мәгънәсен белми. «Сез үзегез шул, кош тотарга чыктыгызмыни?!» – ди. Аңгыра, без сезнең шикелле кош то-

---

В ә з е м л ә п – «үлчәп, җиренә җиткереп» мәгънәсендә. Дөресе – вәзенләп.

тарга йөрүчеләрнең үзләрен дә яхшы гына капкынга эләктерәбез. Узган ел яхшы гына тәти кошлар тозакка эләккәннәр иде. «Шәһәргә даныңны чыгарам» дип куркытып – егетеннән; «егет белән йөргәнеңне ирең дә әйтәм, хат язып җибәрәм» дип, хатынынан шактый гына кубарган идем. Һәм, чыннан да, әгәр икесе дә йөзәр сум тамызган булмасалар, чынлап та кеше арасына исемнәрен чыгарачак идем, ярый әле биреп котылдылар. Миңа: «Син ник бу елларны Макариягә бармыйсың?» – диләр. Һе, тик торып ике йөз тәңкә акча төшерерлек булганда, пычагымамыни миңа Макария? Кадерен белгән кешегә безнең Макария өсте үзе бер ярмарка ул.

Бер тарафтан Әптери килеп чыга. Бераз исерек.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Фәтхерахман, Әптери, студент һәм Әнвәр.

Әптери (*Фәтхерахман янына килеп утырып*). Ни хәл, иптәш, эшләр барамы? Ай-яй, сез беркөннәрне теге казакъларны нык утырткансыз соң, ә? Миңа Нигъми сөйләде.

Фәтхерахман (*кашларын җыерып, ачуланып*). Нинди казакъларны?

Әптери. Беләм лә инде, миннән яшергән буласың тагы, мин белдем инде, подвалчы Җамалыйлар белән бергәләп, казакъларның ике йөз потлап куй маен сеңдергәнсез. Маладис, иптәш, шулай кирәк. Ну, кая әле, иптәш, баш бик авырта, ярты-лык кына бир әле, казакъның куй маен бераз гына җуып алыйк әле!

Фәтхерахман. Күзеңә кырып салырга сукыр бер тиен дә юк. Булмас, юкка маташма, авызыңны җырып, күп сөйләшеп йөрсәң, кирәгеңне алырсың.

Әптери. Беләм, беләм, бик ышанам. Ну, иптәш, билләһи, яртылык бир әле, баш авыртканга чыдар хәл юк.

Фәтхерахман. Кит аннан, йөрмә монда, чит кәпик тә юк, булмас.

Ике студент белән бер барышня узып баралар.

Әптери. Кара теге нәләтләрне, икесенә бер мәткәне ияртkәннәр. Урыс булулары җиткән инде, төртенәселәре генә калган.

---

Чит кәпик тә – чирек тиен дә.

Студент. Нахал, подлец! Хулиган!

Күздән югалалар.

Әптери. Ә-ә-ә, ачуыгыз киләмени! Мөселманны мыскыл итеп йөрмәссез! (*Фәтхерахманга.*) Мин аларны таныйм, кырган башлар алар, ә үзләре, студент булган булып, мөселманны мыскыл итеп, урысча киенгән булып, мәткәләр белән йөриләр. Ну инде, иптәш, билләһи, тегеләргә дә бик ачуым килде, кая, бир әле, иптәш, яртыны гына сындырып килим әле.

Интеллигент узып бара.

(*Әптери, урыныннан сикереп торып, интеллигентның җиңенә ябышып.*) Тр-р-р! Менә, менә нәкъ үзе!

Интеллигент (*куркып китеп, читкә тартылырга ният итеп*). Нәрсә?

Әптери. Кая, морза, баш авырта, яртыны сындырыйм әле.

Интеллигент. Нахал, собака! (*Тиз генә китә башлый.*)

Фәтхерахман, утырган урыныннан торып китеп, күздән югала.

Әптери. Ну, алай булса, бер тәмәке генә бир.

Интеллигент. Хулиган! (*Кача башлый.*)

Әптери (*яңадан, җиңнәрен тартып*). Давай егерме тиен. Ату...

Интеллигент. Городовой!!

Әптери кача башлый. Интеллигент тиз генә күздән югала.

Әптери (*мәкруһ тавыш белән, мыскыл итеп*). Городовой! Тапканнар кычкырырга бер сүз. Ну, киреләр соң шул җәдитләр[1]. Һичберсеннән бер тиен алыр хәл юк. Үзләре генә киерелеп, киенеп, үрәгә катып йөрсеннәр, имеш. Бер эләгерсез әле. (*Як-ягына каранып.*) Ах, каналия, Фәтхи дә качкан. (*Килеп утыра.*) Кем булса да берәү килеп эләгер әле. Ах, жулик Фәтхи, ә! Качып та өлгергән бит! Шунда бер атна элек кенә бер казакъның мең тәңкәлек куй маен подвалчы Җамалый белә бергәләп япканнар. Ә үзләренең товарищларына шуннан тиен дә өлеш чыгарырга кулларыннан килми. Эләгерләр әле, акчасыз фатирга кергәннәрен сизми дә калырлар. (*Телләрен чыгарып, кулларын угалап.*) Әһә-һә-һә, рәт була! Әнвәр абый

---

Мәкруһ – ямьсез, үчекләгән.

килә. Эш пеште! Ахутага чыккан. Ул бер дә кызганмый инде, никадәр теләсәң, шулкадәр яудыра. Түлке җаен гына белергә кирәк. (*Әнвәр килеп керә.*) Әнвәр абый, нихәл? Исән генә йөрисеңме?

Әнвәр (*илтифатсыз гына*). Исән булмасам, доктор булмакчы идеңме?

Әптери. Әнвәр абый, бүген сиңа бик шәп рәтләр бар!

Әнвәр (*юлыннан туктамыйча гына*). Нинди рәт?

Әптери. Бераздан малларның бик эспижиләре буласы.

Әнвәр. Нинди маллар?

Әптери. Була инде, була, бик шәпләре була. Түлке, Әнвәр абый, баш бик авырта, бер егерме тиен генә бир әле, яртыны гына сындырып килим әле. Аннан ары әйтермен.

Әнвәр. Янымда вак акчам юк.

Әптери. Әнвәр абый, дим, зинһар, бир әле, вак акчаң булмаса, алмаштырырмын, бер тәңкәлегең булса да бир. Җир йотсын менә, эчеп бетермим, яртыны гына алам да калганын үзеңә кире кайтарып бирәм.

Әнвәр (*бара-бара*). Йөдәтмә әле, хәзергә вак юк, бер тәңкәлегем дә юк, башка бервакыт бирермен әле. (*Кереп китә.*)

Әптери артыннан калмыйча кереп китә. «Ясәнә инде, Әнвәр абый, егерме тиен генә бирсәнә инде» дигән сүзләре ишетелә. Сәхнә бераз буш тора. Бераздан Сәрбиҗамал белән Мөгълифә карчык килеп керәләр.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәрбиҗамал, Мөгълифә.

Мөгълифә (*эскәмияләрне күрсәтеп*). Әйдә, кызым, менә монда бераз утырып торыйк, ул хәзер килеп җитәр инде.

Сәрбиҗамал (*як-ягына каранып, ялынган тавыш белән*). Әби, зинһар, утырмыйк ла, әллә нишләп бик куркам, кеше күрер. Зинһар, бүгенгә кайтып торыйк ла, икенче бер көнне килербез.

Мөгълифә (*эскәмиягә утырып, каты гына тавыш белән*). Әйдә, утыр инде, нәрсә кыланган буласың тагы. Бүре түгел бит ул, сине ашамас. Икенче көн чыгып йөрергә минем үземнең эшем дә җитәрлек – башымнан ашкан. Әйдә утыр, карышып торма, курыккан ди, курыкмый ни,

---

Эспижи – свежий.

кемнән куркасың? Синең куркырлык кемең бар? Әллә шул җебегән арыш боламыгыннан куркып торасыңмы?

Сәрбиҗамал. Кеше-фәлән күреп, үзенә әйтсәләр, җанымны чыгарганчы кыйнап, изеп ташлар бит!

Мөгълифә (*ачуланып, күзләрен алакайтып карап*). Куйсана, зинһар, юк сүзләреңне, кыйнады ди, кыйнамый ни, шул арыш боламыгыннан куркып торсаң. Әллә шул мәми авызны яратып торган буласыңмы?

Сәрбиҗамал. Яратмасам да, әби, бу бик зур оят эш бит, кеше күзенә нихәл итеп күренерсең. Кеше арасына исемем чыкса, нишләрмен? (*Урындыкка утырып җылый башлый.*)

Мөгълифә (*бераз йомшаграк тавыш белән*). Сәрби җаным, ул ни кылануың инде ул? Ул бит бер дә андыймондый егет түгел. Сезнең ике арадагы гына эшне кеше кайдан белсен? Кеше белсә, ни булган тагын? Ул бит сине мыскыл итәр өчен йөрми. Беркөн ул сине ирең белән багунда барганда күргән дә, шул көннән бирле тәмам сиңа гашыйк булган. «Әби, ди, зинһар, ди, беркөн, ди, Әхмәтҗанның хатынын багунда күрдем, бигрәк матур икән, иренә бөтенләй әрәм икән, и, әби, әгәр ул минем хатыным булса, мин аны башыннан аягына кадәр алтын-көмешкә чумдырыр идем, гомер буена киендереп-ясандырып, бик рәхәт итеп тотар идем. Шуны күргәннән бирле һичбер ашаганым аш түгел, йөргәнем көн түгел, башым тәмам диванага сабышып бетте инде, ди. Әби, зинһар, ди, ничек итсәк ит, шул хатынны миңа алып бир, шуны минем хатыным итсәң, яхшылыгыңны гомерем буена онытмам», – ди. Мин дә, шул сүзне ишеткәч, зур кешенең сүзе аяк астында калмасын дип, кулымнан килгән кадәр тырыштым. Иң әүвәл ничек итеп булса да синең белән белешләндем, аннан соң, бу ирен ярата микән, юк микән дип, синең җаяңне тартып карадым. Ирең белән бик тату тормаганлыгыңны белгәч, аннан соң, базып, сиңа серне сөйләдем. Монда һичбер курка торган эш юк. Менә үзе белән бер күреп сөйләшегез дә, Мәкәрҗә кайткач, иреңнән аерылырсың.

Сәрбиҗамал. Әби, соң ул, мин аерылгач, мине алмый калмас микән?

Мөгълифә. Куй, зинһар, андый юк сүзләреңне сөйли күрмә. Андый алдау-җолдаулар булырлык булганда, мин соң, олы башымны кече итеп, андый юк-бар эшләргә катышып йөримме? Аллам сакласын андый юк-бар эшләргә катышырга! Күзләреңне тизрәк сөрт, кызым, җылаганың-

---

Багун – биредә «трамвай» мәгънәсендә.

ны күрә күрмәсен, ул андый эшләрне һич яратмый. Әнә килә. (*Борынын сөрткән булып, яулык чыгарып болгый.*) Менә үзе килсен дә, икегез бергә, ничек итеп аерылу, ничек итеп туй ясау турысында сөйләшерсез. Боерган булса, бик бәхетле, бик бай булырсың. Бай хатыны булып дыйшлаларда гына утырып йөрерсең. Кызым, бер дә хафаланма. Син утырып тор, кызым, мин Әнвәрне каршы алыйм. (*Урынынnan торып, каршы бара.*)

Әнвәр килеп керә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мөгълифә, Сәрбиҗамал, Әнвәр, соңра Фәтхерахман.

Мөгълифә (*Әнвәрне бер читкә тартып*). Әнә сиңа мал, танысаң, ал. Түлке бер дә җылаганына, сыктаганына карап торма. Ул оялчанлыгыннан гына шулай иткән булып маташа. Йомшак торма, үзе ул сине бик ярата. Күптән бирле сиңа күзе кызып йөргән. Бары тик курыкканлыгыннан гына серен чыгара алмаган. Сине бик ярата. Син дә: «Алам, ирең нән тик тизрәк аерыл гына», – диген. Монысы минем үземә дә бик кыйммәткә төште. Шәп нәрсә, тик кадерен генә бел. Артыннан, кулга төшерә алмыйча, нәкъ бер атна йөрдем.

Әнвәр. Матурмы соң үзе?

Мөгълифә. Әй, аңгыра ябалак, матур булмагач, мин сиңа китерәмме соң аны? Суырып йотарлык инде. Үзең дә гомерең буена аерыла алмассың. Нәкъ яшь чебеш шикелле. Йә, күп сөйләнеп торма, кашын инде тизрәк, минем эшләрем бар, мин икегезне генә калдырам да китәм.

Әнвәр, бишлек кәгазь чыгарып, Мөгълифәнең кулына кыстыра.

(*Акчаны карап.*) Бу ни дигән эшең бу? Моның өчен генә бер атна буе йөрергә әллә мине дивана дип белдеңме? Аз дигәндә бер илле тәңкә дә булмагач, мин аның артыннан эш калдырып йөримме соң!

Сәрбиҗамал (*үзалдына*). Ярабби Ходаем, хәерле генә була күрсен. Йөрәкләрем бөтенләй сикерә. Мине алдамасалар гына ярар иде, әллә нинди яшерен сүзләр сөйләшәләр бугай.

Әнвәр. Мә инде алайса! (*Берникадәр кәгазь акчалар чыгарып, Мөгълифәнең учына кыстыра.*)

---

Дыйшла – «пар атлар» мәгънәсендә.

М ө г ъ л и ф ә. Ярый, игелеген күр. Әйдә, икегезне күрештерим.

Сәрбиҗамал янына баралар.

Әйдә, углым, оялма, оялма, әй бәбкәм, песи баласы шикелле посып кына, оялып кына тора. Кызым, син дә оялма, күрешегез, күреш!

Ф ә т х е р а х м а н, килеп, бер агач артына посып тыңлап тора.

Ә н в ә р (*акрын гына*). Исәнмесез! (*Утыра.*)

С ә р б и җ а м а л (*кулын биреп, оялып кына*). Исәнме!

М ө г ъ л и ф ә. Углым Әнвәр, кызым Сәрби, монда ачыкта, кеше күз алдында күрешү уңайсыздыр, барыгыз, бәбкәләрем, барыгыз, бар, тегендәрәк барып, биситкәгә кереп утырыгыз. Шунда сөйләшерсез, кеше дә күрмәс, уңай булыр. Барыгыз, балаларым, бар! Мин монда сез килгәнче көтеп утырырмын.

Ә н в ә р (*урыныннан торып, бик көлеп карап*). Әйдәгез, җаным, биситкәгә кереп утырыйк.

Сәрби урыныннан тора. Әнвәр Сәрбиҗамалның култыгыннан җитәкләп алып кереп китә. Сәрбиҗамал бик кайгылы сурәттә генә башын иеп бара. Күздән югалалар.

М ө г ъ л и ф ә (*тегеләр күздән югалгач, як-ягына каранып, кесәсеннән акчасын чыгарып карап*). Әй саран дуңгыз, нинди матурны китереп тә, бары утыз гына тәңкә биргән. Тагы кулга төшәр әле, ул вакытта ничек итеп сыгарга кирәклеген белермен әле. (*Кереп китә башлый.*)

Ф ә т х е р а х м а н (*агач артыннан чыгып*). Мөгълифә!

М ө г ъ л и ф ә (*борылып карап*). Нәрсә-ә-ә?

Ф ә т х е р а х м а н. Миңа да өлеш.

М ө г ъ л и ф ә. Нинди өлеш?

Ф ә т х е р а х м а н. Йә, күп телеңә салынма, ату хәзер эшеңне бозам.

М ө г ъ л и ф ә. Бирде ди өлеш, бирми ни, артыннан ун көн йөреп, бөтенләе бары ун тәңкә бирде, тагы сиңа аннан да өлеш чыгарып бирергә кирәк. Өлеш аласың килсә, артыннан үзең йөрерсең.

Ф ә т х е р а х м а н. Кара аны, эләгерсең әле, онытма!

М ө г ъ л и ф ә (*мыскыл итеп карап, авызларын бүлтәйтеп үчекләп*). Алла, харап иттең, мине куркытмакчы булган булып маташа. Чуртым курка синнән! (*Кереп китә.*)

Ф ә т х е р а х м а н. Ярый, вакыты туры килер әле. Бирмәсәң бирмәссең. Мин кайдан алырга юлын үзем табармын. Хатынын таныдым, Әхмәтҗан хатыны. Ике йөз тәңкәсез кулдан ычкындырмам. (*Чыгып китә.*)

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

**Әхмәтҗанның йорты. Уң якта – тәрәзәләр. Түрдә – өйалдына чыга торган, сулда икенче бүлмәгә чыга торган ишекләр, йорт җиһазы уртача гына. Кич. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә кеше юк.**

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мөгълифә, Сәрбиҗамал.

Сәрбиҗамал (*Мөгълифә белән ишектән керә-керә*). Кич белән бу вакытта кем йөри икән дип, курка-курка гына чыгып барадыр идем, син икәнсең. Бу арада, беркөннән бирле, әллә нишләп бик курка башладым. Әйдә чишен. Кунарга килгәнсеңдер бит?

Мөгълифә. Исән-сау торасыңмы, кызым? Кунарга килмәдем. Кунарга килмәсәм дә, сиңа бераз иптәш булырмын. Бай хатыны булгач, курка башлагансыңдыр шул. Элгәре бер дә курыкмыйдыр идең.

Сәрбиҗамал. Беркөннән бирле бигрәк курка башладым. Бигрәк теге, бакчага чыккан көннән бирле куркам. Ул көн син үзең көтеп торам дип вәгъдә куйдың, ә үзең әллә кайда югалгансың.

Мөгълифә. И-һи-һи-һи! Шулай булгандыр шул. Мин ул көнне сезне көттем, көттем, көттем дә, болар инде, ахры, бер-берсенең күңеленә бигрәк охшап киттеләр бугай, ахры, болар мине бөтенләй онытып та бетерделәр бугай, кичкә дә калам, дидем дә, кайттым да киттем. Абау, абау, бәгърем, сөбханалла! Машалла! Күз генә тия күрмәсен! Беркөнгегә караганда бөтенләй тулыланып, көрәеп, тагы да матурланып киткәнсең, ирләр сокланмаслык та түгел шул!

Сәрбиҗамал. Әй, Мөгълифә абыстай, бигрәк арттырып җибәрәсең лә инде.

Мөгълифә. И-һи-һи! Минем сүзгә ышанмасаң, әнә көзгегә кара. Матур кешеләр һәрвакытта да шулай инде алар, синең шикелле кыйланган булалар. Матур булмасаң, Әнвәр шикелле бай кешенең күзе сиңа төшәр идеме соң? Бәхетең бар икән инде, бәхетең. Юк исә Әнвәр шикелле егеткә гомердә бара алмас идең. Ул үзе генә сорамый, сораса, аңар байларның менә дигәннәре дә кызларын бирергә хәзер сызганып торалар. Әле соң хәлләрегез ничек? Беркөннән соң әллә ничә тапкыр күрешкәнсездер инде?

Сәрбиҗамал. Юк, күрешкәнебез юк.

Мөгълифә. Алдалый торгансыңдыр әле, әллә кайчан күрешкәнсездер инде. Ул көннән бирле күрешми тора торган кешеләр сезме соң ул?

С ә р б и җ а м а л. Чынлап, күрешкәнебез юк. Күрешкән булсак, аны инде синнән яшереп тормас идем.

М ө г ъ л и ф ә. Җүри генә әйтәм, җүри генә. Сине сынар өчен генә әйтәм. Миннән яшертен генә эш йөртеп, яучылыктан мине калдырмасыннар, дим.

С ә р б и җ а м а л. Әй, зинһар, юк сүзне сөйли күрмә, эш була калса, боерган булса, сине читкә какмыйбыз инде; булсын гына инде, аннан соң сине бөтенләй башыңнан малга күмәрбез.

М ө г ъ л и ф ә (*читкә карап*). Акылсыз, шуңар барам дип ышанып йөри икән әле!

С ә р б и җ а м а л (*сүзендә дәвам итә*). Әйе, менә шунысы читен: монысыннан ничек итеп котылырбыз?

М ө г ъ л и ф ә (*читкә карап*). Котылырсың, котылу гына түгел, чәнчелдереп җибәрерләр әле!

С ә р б и җ а м а л (*дәвам итә*). Ничә көннән бирле инде һаман шуны уйлап йөрим, һич очына чыга алмыйм.

М ө г ъ л и ф ә. Һи, аңар гына эш калса, ул берни дә түгел. Аның юлларын табу бик ансат. Тик мине сәдакаңнан гына буш калдырма. Үзем һәммәсен табып бирермен.

С ә р б и җ а м а л. Нинди юллар бар?

М ө г ъ л и ф ә. Һи, бик күп.

С ә р б и җ а м а л. Шулай да, әби, әйт әле.

М ө г ъ л и ф ә. Әле ирең кайтырга бик күп вакыт бар. Ул кайтканчы әле әллә нинди юллар табып булыр. Иң элек менә, ирең кайтып кергәч тә, бер дә эндәшмә, сөйләшмә. Аның белән күрешмә, шуннан соң ул сиңа ялына башлар, сиңа алып кайткан бүләкләрен күрсәтә башлар. Син берсенә дә илтифат итмә. Бүләкләрен атып-атып ташла. Самавырын куйма, ашын пешермә. Якын килә башласа кач; шулай итеп җәфалагач, аннан ары, бик каты гына иттереп: «Аер мине!» – дип, өстенә җикеренеп кычкыр. Шуннан соң ул синнән аерылуның сәбәпләрен сорый башлар. Аннан соң син аңар бәйләнә башларсың: «Син минем өстемнән өйләнгән икәнсең, яшь хатын алган икәнсең, син ярминкәләргә шул хатыныңны алып йөрисең икән», – дип бәйләнерсең.

С ә р б и җ а м а л. Алар бар да ялган сылтаулар гына була ич, ул аңар карап кына аермас бит.

М ө г ъ л и ф ә. Ялган булса да, бик шәп ялган ул. Аның өстенә без: «Ирең өйләнде, ярминкәгә шул хатынын алып барды, менә фәлән кешене алды», – дип, бер ялган хат язарбыз да, шуны күрсәтеп бәйләнерсең. Аннан ары...

С ә р б и җ а м а л. Кара әле, Мөгълифә абыстай, хат дигәч исемә төште, бая да мин: «Мин бу арада куркам», – дип

сөйли башлаган идем, син икенче сүзләргә кереп китеп, сүземне бүлдердең. Беркөнне шул бакчадан курка-курка гына кайтып киләдер идем, ишек төбенә килеп җитеп, ишектән генә керим дисәм, өй почмагыннан бер кеше килеп чыкты. «Матур абыстай, синдә бер йомышым бар иде», – ди. Карасам, Әҗми Фәтхие икән. «Эшегезне сиздем, йөз тәңкә бирмәсәң, бүген үк иреңә хат язам», – ди.

Мөгълифә. Җә, җә?

Сәрбиҗамал. Мин куркуымнан ни эшләремне дә белмәдем. Тиз генә ишегемне яптым да бикләдем. Ул әллә нинди әшәке сүзләр белән сүгенеп бераз торды да китте. Шул көннән бирле кичкә керсәм... бөтенләй... (*Ишек шакылдаталар.*) Һай! Тагы әллә кем бар, харап булдык.

Мөгълифә. Курыкма, курыкма, кызым, беркем дә түгелдер ул, Әнвәрдер. Бар, ишегеңне ач! Мин сүзгә мавыкланып, әйтергә дә оныткнмын. Мине ул монда хәбәр итәргә җибәргән иде, бүген килмәкче булган иде.

Сәрбиҗамал. Ай Алла, харап булдык! Ник бер дә әйтмәдең? Кеше күрсә, нишләрбез? Мин дә мунча пәрие шикелле ич. Өстемә күлмәк тә кимәгән!

Мөгълифә. Зарар юк, зарар юк, матур булгач, киенмәсәң дә ярый ул. Айга күлмәк киертмиләр. Бар, тизрәк чыгып ач!

Сәрбиҗамал чыгып китә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мөгълифә ялгыз.

Мөгълифә (*үзалдына сөйли*). Дурак, хатыннардан бигрәк ирләре дурак. Шундый матур хатынны өйләрендә ялгыз калдырып, ярминкәгә китеп йөриләр. Бу йөзе кара Әнвәре тагын аңа караганда да биш битәр дурак. Дөньяда моның кадәр дә хатыннан туймас, гакылсыз дурак булмас инде. Никахлап алган өч хатыны бар, хатыннары берсе-берсеннән чибәр. Аның өстенә тагын ике нәрсәне фатирда тота. Ул гына җитмәгән тагы, алар өстенә кеше хатыннары белән йөри. Бар акчасын хатын-кыз артыннан йөрүгә таратып бетерә инде. Сатуда һичбер йомышы юк, кибетчеләре зар җылыйлар: «Кассадан акчаны ала да чыга да китә, чыга да китә, болай булса, кибеттәге маллар бик озакка бармас», – диләр. Ә моның анда-монда эше юк, бары тик аңар матур хатын гына булсын, аннан соң һич күзенә ак-кара күренми. Бу дурагы тагын шуңар «ала» дип тик алданып йөри. Әхмәтҗаны нинди

чибәр, нинди булдыклы егет, шул җитмәгән, имеш, ул бай түгел. Аңар бай булсын, имеш, ул байга барып, бай хатыны булып, ризиновыйларга утырып йөри... Йөрерсең, иреңнән аерылгач, кара җәяүгә калганыңны сизми дә калырсың әле. Миңа бары да бер. Миңа кем күбрәк акча бирсә, шул ярый. Башка җирдән килерлек урының булмагач, әллә ни эшләп булмый. (*Ишеккә борылып карап.*) Әле һаман кермиләр. Һе, килешкәннәр. Якты көннәр сирәк була ул. Бик озак рәхәтләнә алмассыз әле. Фәтхигә акча төрткән булмасагыз, ул сезне бик тыныч тотмас. Аждаһа шикелле ул, алар үлән астыннан ут йөртә торган халык.

Ишектән Әнвәр белән Сәрбиҗамал керәләр.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәрбиҗамал, Әнвәр һәм Мөгълифә.

Мөгълифә. Йа, кияү белән кыз бигрәк сагынышканнар икән. Мин инде әллә болар бөтенләй югалдылар микән дип торам.

Әнвәр. Матур кыз димләгәч, шулай була ул. (*Сәрбиҗамалга.*) Менә сиңа бүләк итеп бер алтын алка алып килдем. (*Бирә.*)

Сәрбиҗамал. Бигрәк матур икән. Кашы моның нәрсә, әллә берлиантмы?

Әнвәр. Ие, берлиант, синең өчен өч йөз тәңкәгә заказ койдырып алдым.

Мөгълифә (*читкә карап*). Ие, берлиант белән икесе янәшә магазинда торганнар. (*Әнвәргә карап.*) Сәрбигә вәгъдә бүләге итеп китергәнсеңдер инде аны?

Әнвәр. Ие, вәгъдә бүләге итеп китердем.

Мөгълифә. Соң миңа, яучы кешегә, бүләк итеп нәрсә китердең?

Әнвәр. Сиңа, насыйп булса, эш тәмам булгач. (*Читкә карап.*) Туймады бу абҗур карчык та, кайчан гына чыгып китәр.

Мөгълифә (*читкә карап*). Моннан артык эш тәмам булу тагы нинди булыр инде, белмим. (*Тегеләргә карап.*) Шулай инде, шаять, буш итмәссез әле. Сәрби, син дә буш итмәссең, җәме?

Сәрбиҗамал. Ярар, ярар, Мөгълифә абыстай, бер дә буш итмәм, насыйп булса. (*Әнвәргә карап.*) Әле син

---

Ризиновый – резин тәгәрмәчле тарантас.

килер алдыннан гына тегеннән ничек аерылырга дип хәйләләр корып торадыр идек. Син килеп ишек каккач, бөтенләй куркып, сискәнеп киттем. Йөзе кара, беркөн Фәтхи акча сорап котымны алды.

Әнвәр. Нинди Фәтхи?

Сәрбиҗамал. Әнә теге Әҗми Фәтхие, маклер.

Әнвәр. Ах, йөзе кара икән, синнән дә сорадымыни?

Сәрбиҗамал. Сорады. Бирмәсәң, иреңә хат язам дип куркытты.

Әнвәр (*үзалдына*). Эшләр чуалды инде алайса! (*Кычкырып.*) Икенче көнне ул миннән дә сораган иде. Мин бирмәдем.

Сәрбиҗамал. Мин дә бирмәдем.

Бик каты ишек кагалар.

Ах, харап булдык, әллә кем бар!

Һәммәсе дә аяк өстенә сикереп торалар. Мөгълифә шәлен бөркәнә башлый. Әнвәр качарга урын эзли.

Әнвәр. Мөгаен, Фәтхидер. Мине кыйнатырга кешеләр алып килгәндер.

Мөгълифә. Җаным! Зинһар, мине генә чыгарып җибәрә күрегез.

Ишек бик каты шалтырый.

Ишек артыннан тавыш. Сәрби! Ач ишекне, бәдбәхет! Ач!

Сәрбиҗамал. Харап булдык! Нихәл итим! Әхмәтҗан!

Әнвәр. Әхмәтҗан?!

Мөгълифә. Әхмәтҗан?!

Өчесе дә катып калалар. Ишек бик каты шалтырый.

Тавыш. Ач, бәдбәхет! Ач! Җимереп керәм!

Мөгълифә. Мин кая гына качыйм?

Әнвәр. Мин кая барыйм?

Сәрбиҗамал. Мин ни эшлим, кая барыйм?

Өчесе дә качарга урын эзлиләр, ишекне вата башлыйлар. Әнвәр, качарга башка урын таба алмыйча, тәрәзәдән сикереп, аралыкка төшә. Ишек ватыла. Әхмәтҗан белән Фәтхерахман кереп киләләр.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Әхмәтҗан, Фәтхерахман, Мөгълифә, Сәрбиҗамал.

Әхмәтҗан (*ишектән кереп, акырып*). Һе... бәдбәхет! (*Сәрбиҗамал янына килә, кизәнә.*)

Фәтхерахман, Мөгълифәгә карап, истиһза кылып көлә.

Кая, бәдбәхет? Кая куйдың? Кая яшердең? (*Борылып, Мөгълифә өстенә йодрыкларын йомарлап килә, тешләрен кысып.*) Һе... бәд... бә... хетләр!!! Берсе шулмы?

Фәтхерахман. Шул, шул.

Мөгълифә. Мин иптәшкә генә кил...

Әхмәтҗан. Һе... йөзең... ка... ра!! Бар, чык моннан.

Мөгълифә чыга башлый.

Юк, чыгарма! Бар! Бас шунда! (*Җилтерәтеп илтеп, почмакка бастырып куя. Сәрбиҗамал янына барып.*) Һи, бәдбәхет! Һи, йөзең кара! Кая яшердең? Тап тизрәк!

Сәрбиҗамал, куркып, икенче почмакка поса. Әхмәтҗан һәммә җирне актара, эзли, Фәтхерахман да эзләшә. Таба алмыйлар.

Әхмәтҗан. Бар, Фәтхи, син бер шаһит алып кил. Аннан бер ямшек тә алып кил. Мин мулланы алып киләм. (*Сәрбиҗамалга карап.*) Кузгалма урыныңнан! (*Мөгълифәгә карап.*) Бәдбәхет! Җәһәннәмлек!

Чыгып китәләр.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәрбиҗамал, Мөгълифә һәм Әнвәр.

Сәрбиҗамал белән Мөгълифә, бер-берсенә карашып, бераз тик торалар. Тәрәзәдән Әнвәрнең башы күренә. Бераздан Әнвәр, тәрәзәдән сикереп кереп, ишеккә таба йөгерә. Мөгълифә дә ишеккә таба атыла. Сәрбиҗамал, торган урыныннан йөгереп килеп, ишеккә аркылы төшә.

Сәрбиҗамал (*буылган тавыш белән*). Юк! Чыкма... гыз!

Әнвәр. Мин...

Мөгълифә. Мин...

Сәрбиҗамал. Ул мине... үтерер! Һай!!! (*Һушы китеп егыла.*)

Әнвәр. Бу... Бу... ни хәл?

Мөгълифә. Харап булды! Әйдә тизрәк.

Икәүләп, күтәреп, диванга китереп салалар.

Әнвәр. Су... су! Бар тизрәк, салкын су китер!

Мөгълифә икенче бүлмәдән йөгереп, су китереп бирә, Әнвәр су бөрки.

---

Истиһза кылып – мәсхәрәләп.

М ө г ъ л и ф ә. Ах! Харап булдык. Минем түзәр хәлем юк. Мин китәм. (*Чыгып бара.*)

Ә н в ә р (*Мөгълифәне кулыннан тартып алып килә*). Качма! Чыкма! Син монда тор, мин чыгам! (*Чыга башлый.*)

М ө г ъ л и ф ә. Юк! Син дә чыкма! Үзең харап иттең, үзең янында тор!

Ә н в ә р. Мин харап итмәдем, син, ләгънәт, харап иттең. Мине дә син, ләгънәт, харап иттең. Котырттың. (*Чыга башлый.*)

М ө г ъ л и ф ә (*җиңенә барып асылынып*). Җибәрмим!.. Чыкма!.. Качсаң, артыңнан каравыл кычкырам!

Ә н в ә р (*әйләнеп килеп*). Һи, падлис!

М ө г ъ л и ф ә. Син үзең падлис!

Сәрби бераз акылга килә башлый. Авыр-авыр сулый, ишек артыннан тавыш ишетелә. Әнвәр, тиз генә тәрәзәдән чыгып, аралыкка кача. Мөгълифә әүвәлге почмагына барып поса. Ишектән Ф ә т х е р а х м а н керә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ә ү в ә л г е л ә р, Ф ә т х е р а х м а н, Ә х м ә д и, С а ф а, х ә з р ә т һәм Ә х м ә т җ а н.

Ф ә т х е р а х м а н (*ишектән кереп, як-ягына каранып, Мөгълифәгә карап*). Нихәл, асыл кошлар, яхшы эләктегезме? Шулай ул, асыл кош аягыннан эләгә, ди, ул. Кара теге чибәр кызны! Һушыннан тайган булып ята. Йөз тәңкәңне кызганган булган идең. Сезнең шикелләләрнең шулай итеп һушларын җибәрәләр аның. Нихәл, карчык, ник бер дә эндәшмисең, ник терәлеп каттың? Әллә Әнвәрнең акчалары тамагыңа утырдымы?

М ө г ъ л и ф ә. Дуңгыз! Җир бит! (*Чыгып китә башлый.*)

Ф ә т х е р а х м а н (*җилкәсеннән барып тотып*). Чү, чү, чү, сабыр ит бераз, алай, башын ал да саламына ут төрт, дип чыгып китмиләр аны. Бераз көтеп тор әле. Туйны күреп китәрсең!

Ә х м ә д и белән С а ф а керәләр.

Ә х м ә д и.
С а ф а. } Әссәламегаләйкем!

Ф ә т х е р а х м а н. Вәгаләйкемәссәлам! Әйдәгез.

Ә х м ә д и. Әхмәтҗан абзый кайда?

Ф ә т х е р а х м а н. Хәзер килер, менә аңарчы бу җанварларны тамаша кыла торыгыз.

Ә х м ә д и. Монысы нинди карчык соң моның?

Ф ә т х е р а х м а н. Шул инде, теге, Әнвәргә кош тотып бирүче. Әнә тегесе асыл кош, чибәр бит, ә?

М ө г ъ л и ф ә. Нәгъләт!

Ф ә т х е р а х м а н. Дулама, дулама, «сыер дуласа, аттан яман була» ди. Бая сез керер алдыннан дулап, чыгып китә башлаган иде, көчкә генә тотып калдым.

Х ә з р ә т белән Ә х м ә т җ а н керәләр.

Х ә з р ә т. Әссәламегаләйкем!

Ә х м ә т җ а н. Вәгаләйкемәссәлам! Әйдә, хәзрәт, менә моннан. (*Диванны күрсәтә.*) Кит, оятсыз! Кит моннан, әдәпсез! (*Сәрбине кулыннан җитәкләп алып ташлый.*)

Сәрби, хәлсезләнеп, абына-сөртенә, икенче урындыкка барып утыра.

Х ә з р ә т. Чү, чү, мулла Әхмәтҗан, алай холыксызланма, алай кыланма, ярамый. Шәригать алай кыланырга әйтмәгән. «Яхшылык белән тотыгыз, тотмасагыз – җибәрегез» дигән. Яратмыйсың икән, орма, сукма, аер да җибәр.

Ә х м ә т җ а н. Аерам, җибәрәм, хәзрәт, җибәрәм. Җәһәннәмгә кадәр китсен! Бар, син, кем, Вафа, әй, Сафа, бар, ямшекләр алып кил, хәзер үк төяп алып китсеннәр.

С а ф а. Ямшекләр күптән килгәннәр, көтеп торалар.

Х ә з р ә т. Син алай кызуланма, мулла Әхмәтҗан. «Ашыккан ашка пешкән, сабыр иткән морадына җиткән». Ашыгу – шайтан фигыле. Бәлки, хатыныңның һичбер гөнаһсы да юктыр.

Ә х м ә т җ а н. Нинди булмаган, хәзрәт. Әнә бер шайтаны күз алдында ук тора. (*Мөгълифәгә төртеп күрсәтә.*) Әнә шул нәгъләт төшкән, шул каһәр суккан карчык аздырган.

Х ә з р ә т. Алай дип әйтмә син, мулла Әхмәтҗан, бәлки, ифтирадыр.

Ә х м ә т җ а н. Түгел, хәзрәт, түгел, көн шикелле беләм, ялган түгел.

Х ә з р ә т. Кайдан беләсең? Үзең күрдеңмени? Әллә күргән кеше бармы?

Ә х м ә т җ а н. Бар, хәзрәт, бар, бөтен дөнья белгән, бөтен дөнья күргән! Бөтен шәһәргә исемебез таралып беткән. Харап булдык инде, хәзрәт, харап булдык! Дус-дошман арасында рисвай булдык.

---

И ф т и р а – ялган, яла.

Хәзрәт. Ул кадәр кемнәр күргән соң?

Әхмәтҗан. Әнә анысын Фәтхерахманнан сорагыз. Минем телем дә бармый.

Хәзрәт. Ә, кем, Фәтхерахман, сез шулай күрдегезмени?

Фәтхерахман. Күрдек, хәзрәт.

Хәзрәт. Кемнәр күрде?

Фәтхерахман. Без күрдек.

Хәзрәт. Ничә кеше?

Фәтхерахман. Без үзебез генә күрдек.

Хәзрәт. Сез үзегез ничә кеше?

Фәтхерахман. Бер генә кеше.

Хәзрәт. Бер генә кеше шаһит булырга җитми. Сез аларны кай урында, ни рәвештә күрдегез?

Фәтхерахман. Мин моннан берничә көн элек шәһәр бакчасына менгән идем. Шунда менә бу карчык белән менә бу хатын...

Сәрбиҗамал. Аһ! (*Җылый башлый һәм ахырга кадәр бертуктаусыз – бер акрынлап, бер кычкырып җылый.*)

Әхмәтҗан. Йә, җитәр, хәзрәт, сөйләтмә. Яз тизрәк, зинһар, кенәгәңә яз, йөрәгем бозыла.

Хәзрәт. Алай дип әйтмә син. Безгә белергә кирәк.

Әхмәтҗан. Кирәк түгел, хәзрәт, кирәк түгел. Барыбер мин инде аны ансыз да аерам.

Хәзрәт. Хәерле булсын инде алайса. Шәригатьтә талакның берничә төрлесе бар. Ягъни мәсәлән, талакый хәсән[2] бар, бидгый[3] бар, кайсы белән аерасыз?

Әхмәтҗан. Туп-туры аерам, һәммәсе белән дә аерам. Менә бу хатын миннән талак, талак, талак!

Хәзрәт. Тукта әле, мулла кем, ничә талак белән талак кылдың?

Әхмәтҗан. Мең талак белән, мең!

Хәзрәт. Алай дип әйтмә. Митрикәгә мең дип язып булмый. Аның иң күбе өч талак.

Әхмәтҗан. Ярый, ярый, сезнеңчә булсын. Өч талак, алайса.

Хәзрәт. Мәһәре бирелгәнме? Гыйддәт нәфәкаләре[4] биреләчәкме?

Әхмәтҗан. Биреләчәк, биреләчәк. Барысы да биреләчәк. Тик тизрәк күземнән генә югалсын. Әнә һәммә нәрсәсен хәзер үк төясен дә алып китсен!

Хәзрәт. Ярый алай булса. (*Яза.*) Әйдәгез, шаһитлар, кул куегыз әле. (*Кул куялар.*) Ярый, тәмам булды, инде

мин кайтам. (*Әхмәтҗан сәдака бирә.*) Ярый, Аллаһы әкбәр. Хәерлегә булсын. (*Чыга башлый.*) Ә, онытып китәрмен икән, митрикә акчасы алмаганмын, утыз тиен бирегез әле. Аны бездән Сабрания бер дә калдырмый сорап ала.

Ә х м ә т җ а н. Мә, хәзрәт, мә.

Х ә з р ә т. Ярый, хуш, сау булыгыз! (*Чыга башлый.*)

Ә х м ә т җ а н. Туктагыз әле, хәзрәт, чыкмый торыгыз, үз күз алдыгызда бар нәрсәсен төяп алып китсен. Соңыннан миңа бәласе булмасын. Әйдә, Фәтхи, Сафа, Әхмәди, барыгыз, нәрсәләрен чыгарыгыз. (*Мөгълифә белән Сәрбиҗамалга.*) Барыгыз, бар, вон өемнән!

Нәрсәләрне ташыйлар.

М ө г ъ л и ф ә (*Сәрбиҗамал янына килеп*). Әйдә, Сәрби җаным, бәгырем, китик моннан!

Ә х м ә т җ а н. Һи, йөзе каралар, җәһәннәмлекләр.

Х ә з р ә т. Чү, мулла Әхмәтҗан, алай каты әйтмә.

Ә х м ә т җ а н. Ничек итеп әйтмәскә кирәк, хәзрәт, йөрәгемә кан урнаштыралар бит!

Мөгълифә Сәрбиҗамалның башына шәлен бөркәтеп, култыклап алып чыга. Сәрби кызганыч тавыш белән җылап, абына-абына чыгып китәләр.

Ә х м ә т җ а н. Каһәр сукканнар, бәдбәхетләр, ләгыйньнәр, мәңгелек игелек күрмәгез!

Бөтен нәрсәләрне ташып бетерәләр.

Х ә з р ә т. Хуш инде, мулла Әхмәтҗан, мин китим, Алла сабырлык бирсен.

Ә х м ә т җ а н. Хуш, хәзрәт, хуш! (*Озата.*)

Ишектән Ф ә т х е р а х м а н керә.

Уф Алла! Көчкә котылдым. Менә син, бәдбәхетләр, ә! Әле ярый син яхшылык итеп хат яздың. Әгәр син белдермәгән булсаң, гомерем буена белмичә, шул урам себеркесе белән гомеремне уздырган булыр идем бит. Синең хатыңны алгач, хафамнан өч көн эчендә ун еллык картайдым. Рәхмәт, Фәтхерахман, сиңа рәхмәт. Мине зур бәладән коткардың, сине ничек кенә итеп сыйлыйм икән инде.

---

С а б р а н и я – Духовное собрание, дини идарә.

Ф ә т х е р а х м а н. Юк, Әхмәтҗан, кирәкми, мин сыйлану өчен йә булмаса акча өчен бу эшне эшләмәдем. Бары тик аларның йөз каралыклары дөньяга чыксын дип, Алла ризасы өчен эшләдем.

Ә х м ә т җ а н. Рәхмәт, Фәтхерахман, рәхмәт.

Ә н в ә р тәрәзәдән сикереп кереп, ишектән йөгереп чыгып китә.

Ә х м ә т җ а н (*Әнвәрне күреп*). Һай, йөзе кара, бәдбәхет!

Ф ә т х е р а х м а н. Тот! Сип!

Артыннан куа чыгалар.

П ә р д ә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәрбиҗамалның квартиры. Уртача гына итеп җыештырылган. Ике якта тәрәзә. Пәрдә ачылганда, С ә р б и җ а м а л чәчен тарап утыра.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

С ә р б и җ а м а л ялгыз.

С ә р б и җ а м а л (*үзалдына сөйли*). Аерылганыма ничә көннәр булды, һичбер якты дөнья күргәнем юк. Аяк атлап урамга чыксам, кем генә күрсә, артымнан бармак белән төртеп күрсәтеп, мине сөйләп калалар. Хәзер мине кешегә исәпләүчеләр дә калмады. Аш-су күргән дусишләрем бары да миннән качып беттеләр, һәммәсе кырын күз белән карыйлар. Мине мәҗлескә чакыруны зур гөнаһ дип beлəлəр. Мөгълифә белән Әнвәрдән башка бусагамны атлап кергән кеше юк. Мондый авыр көннәр, хәзерге шикелле куркыныч кичләр башымнан үтәчәген белгән булсам, урынымнан да кузгалмаган булыр идем. Бу эшкә Мөгълифә генә сәбәпче булды. Әнвәргә барырга ул котыртты. Кем белә, бәлки, мин, Әнвәргә баргач, бәхетле дә булырмын. Әмма хәзергесе бик күңелсез. Иртә торам, тирә-як тып-тын. Өйдә миннән башка бер җан иясе дә юк. Күңелгә әллә нинди авырлык килә. Бөтен гәүдәмә таш таккан шикелле була. Тегендә дә барыбер ялгыз идем, шулай булса да, нindiдер күңелдә бер җиңеллек бар иде. Арып-талып көнне уздырасың, аның өстенә, кичкә кергәч, күзгә һичбер йокы керми. Башка әллә нинди уйлар төшә. Күз аллары бер яктыра, киләчәктә бик зур шатлыклар, әллә нинди рәхәтләр булыр төсле тоела. Соңыннан бер

караңгылана, бөтен дөньяны кара болыт каплап алган төсле була. Бөтен яткан урыннарым белән әллә кайда, түбәнгә таба, җир астына, караңгыга төшеп киткән шикелле булам. Шулай итеп азаплана торгач, көчкә генә йокыга китәсең. Анда да һич рәхәт юк. Анда да әллә нинди куркынычлар.

Ишек шалтырый.

(*Сәрбиҗамал тузгыган чәче өстеннән яулыгын бәйли.*) Кем икән бу? Йә Әнвәр, йә Мөгълифәдер. Башка кеше минем ишек тирәсенә килми. (*Ишек ачарга чыгып китә. Өйалдыннан.*) Нихәл, абзый, ни йомыш?

Тыштан тавыш. Йомыш белән килдем, өйгә кергәч әйтермен.

Сәрбиҗамал (*ишектән керә-керә*). Кем соң син? Миндә нинди йомышың бар?

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәрбиҗамал, Исерек татар.

Исерек татар. Кемлегемне кергәч күрерсең әле, андый-мондый кеше түгел, кызлар өчен уңайлы кеше. (*Түргә таба уза башлый.*)

Сәрбиҗамал (*тартынып, куркып*). Нинди кызлар?

Исерек татар. Җә, җә, назланган булма инде, беләбез лә инде, йә, китер әле алтыны, сагынып килдем.

Сәрбиҗамал (*куркып*). Абзый, ул ни дигән сүз? Нинди алты? Минем... минем... бер тиен дә акчам юк.

Исерек татар. Мә, мә акча, бездә акча күп... Менә акча... Әллә пирут бирмәсә ала алмам дип куркасыңмы, бездә акча бер букча, мә ал, мә пирут ал акчаңны! Китер алтыны!.. (*Өстәлгә акчаларын ыргытып бәрә. Җырлый башлый.*)

Әйдә, дуслар, утырыйк,
Өстәл өстен тутырыйк;
Фани дөнья ике килмәс,
Уйнап-көлеп утырыйк.

Сәрбиҗамал (*бигрәк куркып*). Абзый, зинһар, чыксана. Мин ул алты дигән сүзләреңне белмим.

Исерек татар. Ха, ха, ха!.. Аңладым инде, аңладым. Исерек, исерек. Исерек булса да белә ул. Ярый,

ярый. Мә ал, ал. Теләгәнеңне китер, синең өчен жәл түгел. Мә, ал акчаңны, теләгән кадәр ал. Теләсәң нәрсә китер. Партвинмы, кәньякмы, шампанскимы – минем өчен бары да бер. (*Бер уч акча чыгарып сала.*) Безгә акча жәл түгел, без акчаны тапмыйбыз, акча безне таба.

Сәрбиҗамал. Абзый, сез ялгыш кергән... мин... мин... Мин андый кеше түгел...

Исерек татар. Беләбез, беләбез кем икәнеңне, әнә шул белгән өчен дә китсен акча. Безгә акча нипачум. Җә инде, нәрсә тагын торасың, әйдә, бер күңелле генә итеп утырыйк әле. (*Торып, Сәрбиҗамалга таба бара башлый.*)

Сәрбиҗамал (*читкә тартылып*). Зинһар, чык яхшылык белән, каравыл кычкырам.

Исерек татар. Юк, юк. Кычкырма, чыгам. Мин сиңа тимим. Әйдә, болай гына утырыйк.

Сәрбиҗамал. Зинһар, чыгыгыз, мин андый кеше түгел, мин ир хатыны.

Исерек татар. Ха-ха-ха! Ир хатыны! Ирең инде үтүт. Әнә кая калды. (*Еракка кулын селтәп күрсәтә.*)

Сәрбиҗамал. Булсын. Анысы булмаса, минем хәзер икенче ирем бар.

Исерек татар. Беләм, беләм, Әнвәреңне дә беләм, син Әнвәрнең сөяркәсе икәнне дә беләм. Шул белгәнгә күрә килдем дә.

Сәрбиҗамал (*гайрәткә килеп*). Ялганлама, бар чык моннан.

Исерек татар. Әнвәр сөяркәң булмыйча, әллә иреңме?

Сәрбиҗамал. Ирем шул.

Исерек татар. Ха-ха-ха!.. Әле ул кайчаннан бирле ирең булды?

Сәрбиҗамал. Теләсә кайчаннан бирле, бар чык моннан!

Исерек татар. Ха-ха-ха!.. Никахыгызны кем укыды?

Сәрбиҗамал. Анда синең эшең юк. Укымаган булса, укырлар әле, сине чакырмаслар.

Исерек татар. Укырлар, укырлар. Дүрт хатын өстенә бишенчегә укырлар. Синең өчен яңа шәригать чыгарырлар.

Сәрбиҗамал. Ялганлама, аның хатыны дүрт түгел.

Исерек татар. Ярар, киленне килгәч күрербез. Ах, каналия, ә, ничек эләктергән икән дигән идем. Ул шулай икән. Ярый, минем өчен бар да бер. Бишенчегә генә түгел, алтынчыга, җиденчегә алсын. (*Өстәлдән акчаларын җыеп, кесәсенә салып.*) Ярый, гөлсылу, хуш, сау бул.

Утыртмасаң утыртмассың. Акчаны куярга урын табылыр. Әнвәрең озакка бармас. Аннан соң да безгә калмый, әллә кая китмәссең әле. (*Чыгып китә.*)

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәрбиҗамал ялгыз.

Сәрбиҗамал (*килеп, өстәл янына утырып*). Уф Алла! (*Йөрәген тотып.*) Йөрәкләрем сикерә, нихәл итим? Йөзе кара, йөрәкләремне тәмам кубарды. Хур булдым. Әгәр аның сөйләгән сүзләре дөрес булса, нихәл итәрмен? Әй Раббым! Кеше сүзенә алданып харап булдым. Чынлап та, әгәр Әнвәр алмаса, нихәл итәрмен? Әй Раббым! Хәерлегә генә кыл! Урынымнан кузгаласым гына калмаган икән. Алдандым, кеше сүзенә карап алдандым. (*Җылый. Бераз торып.*) Юк, ул исерек, йөзе кара, алдалый, Әнвәрнең хатыны юк! Аны, мөгаен, Әхмәтҗан, котыртып, мине мыскыл иттерер өчен керткән. Юк. Мин сөяркә түгел, мин, мин... Уйнашчы да түгел. Мин... Мин... (*Җылый.*)

Ишектән Хозяин керә.

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәрбиҗамал, Хозяин.

Хозяин (*ишектән кереп*). Нихәл, кызым, бик сәламәт кенә торасыңмы?

Сәрбиҗамал (*сискәнеп китеп, битен яулыгы белән каплап*). Аh, харап булдым, тагын берсе керде.

Хозяин. Качма, кызым, качма, мин бит татар түгел качарга.

Сәрбиҗамал. Ни кирәк сезгә?

Хозяин. Ни кирәк? Бернәрсә дә кирәкми. Мин бит бу йортның хозяины. Менә әле квартирантканың хәлен белеп чыгарга дип кердем.

Сәрбиҗамал (*суык кына*). Ярый, бик яхшы, белсәгез.

Хозяин. Кызым, син кергәндә әйткән идең, «мин портниха» дип. Мин шуның өчен сиңа квартирны арзан биргән идем. Ә сез бире, квартирга, кешеләр китерәсез икән. Хәзер бит, беләсегез, полиция бик строгий. Андый

секретный барны белсәләр, штрафовать итәләр. Мин алай булганда квартирда тота алмыйм. Минем йортым – честный йорт. Минем йортта андый эш булмасын. А то, чыгыгыз!

Сәрбиҗамал (*төсләре бозылып*). Хозяин, мин андый кеше түгел, мин чисный хатын. Ул кеше монда мине мыскыл итәргә генә кергән.

Хозяин. Ай-һай, алай булыр микән?

Сәрбиҗамал. Ул минем белгән, таныган кешем түгел. Ул үзе туп-туры өйгә басты да керде.

Хозяин. Эһем! Ул сезне белмәгәч, туп-туры ничек сметь итеп керсен? Ну ярый. Вот менә сезгә шул, моннан соң өегезгә андый кеше китерә торган булсагыз, квартирны бушатыгыз. Хушыгыз. (*Чыгып китә.*)

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәрбиҗамал ялгыз.

Сәрбиҗамал. Әй Раббым! Нихәл итим, күз алдымнан әллә нинди кара нәрсәләр очып йөри. Һәммәсе дә әллә нинди мин белмәгән, мин ишетмәгән сүзләр сөйлиләр. Куркам, әллә нигә куркам. Бу эшләрнең ахыры бер дә хәер булмас төсле күренә. Кешеләре әллә нинди куркыныч, сүзләре әллә нинди ямьсез. Әнвәр тиз генә никах укытса, тиз генә бу пычрак көннәрдән котылсам... Һи Алла! (*Җылый.*) Ичмаса, Мөгълифә карчык та килми. Хәер, килсә дә, аннан да бер тиен дә файда юк. Конарсыз карчык. Күзләре үк әллә нинди куркыныч. Йөзенең өстендә каралар уйнап тора.

Ишек кагалар.

Кем ул анда?

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Мөгълифә, Сәрбиҗамал.

Мөгълифә (*ишектән кереп*). Мин, кызым, мин. Кешенең әллә нинди вакытыдыр дип, базып кермичә тордым.

Сәрбиҗамал. Әйдә, хуш киләсең, минем нинди вакытсыз вакытым булсын? Минем ишеккә кем килсен?

Мөгълифә. Кем дисеңме? Һи, синең шикелле чибәр кызлар янына кемнәр килмәс? Килмәсә, үзең китерәсең

килми торгандыр. Юк исә синең бусагаңа килеп тезләнүчеләр күп булыр иде. Әле менә бүген генә Әптерәшит бай, мине күреп: «Зинһар, Мөгълифә әби, шул матур кызың белән мине бер генә күрештерсәнә, ни алсаң да ал, ни сорасаң да сора», – диде.

Сәрбиҗамал (*төсләрен бозып*). Мөгълифә әби, ул ни дигән сүзең инде тагын?

Мөгълифә. Ни дигән сүз булсын, матур кешегә кеше кызыкмыймыни? Әнвәр кызыкканны, башка кеше дә кызыгыр. Аның бер дә гаебе юк. Әптерәшитнең аның акчасы Әнвәрнекенә караганда да күбрәк. Ул бик мулдан ычкындыра. Әнвәр шикелле саран бака түгел.

Сәрбиҗамал (*үзалдына*). Аһ! Монысы да әллә ниләр сөйли. Бәдбәхетләр! (*Мөгълифәгә.*) Әби! Куй ул юк сүзләреңне, уйнап сөйлисеңме ул сүзләреңне, чынлапмы?

Мөгълифә. Бер дә уйнап сөйләмим, уйлап сөйлим. Нигә аңар ул кадәр шаккаттың? Әллә аны бер дә дөньяда булмый торган эш дип белдеңме?

Сәрбиҗамал (*карынкы тавыш белән*). Булмас!

Мөгълифә. Булмас ди, Әнвәр матур кызга кавышырга яратканны, Әптерәшит тә яратыр. Әптерәшит тә Әнвәрдән бер дә ким егет түгел.

Сәрбиҗамал. Әби, дим, зинһар, дип әйтәм, шаярып сөйләшеп кәефемне бозма әле, ансыз да инде бүген кәефем җитәрлек бозылды. Күз алларым караңгыланып тора. Башымның авыртканына, әйләнгәненә һич чыдар хәл юк.

Мөгълифә. Пахмиләдер. Берәрне җибәрсәң, хәзер бетәр.

Сәрбиҗамал (*ачуланып, күзләрен алакайтып карап*). Нәрсә дисең?

Мөгълифә. Юк, әйтмим. Салкын тигәндер, дим. Берәр капсүл хин кабып җибәрсәң, хәзер төзәлеп китәр, дим.

Сәрбиҗамал. Әллә нинди сүз әйтәсең дип куркып киттем. Әллә нишләп кәефләрем китеп, эчләрем пошып тора.

Мөгълифә. Әй, куйсана юк сүзләреңне, япь-яшь башың белән эч пошуы дигән нәрсә буласы, имеш. Пошса, ялгызга поша торгандыр. Менә Әптерәшит белән дә белешләнсәң, бик күңелле булыр; бер дә эчең пошмас. Тик ике яктан да имеп ятарсың.

Сәрбиҗамал (*ачуланып*). Нәрсә дисең? Әллә, оял-

мыйча, юк исә миңа ир өстеннән ир тотарга кушасыңмы?

М ө г ъ л и ф ә. Нинди ир? Ireңнән аерылдың ич инде!

С ә р б и җ а м а л. Ник, Әнвәр ир түгелмени?

М ө г ъ л и ф ә. Әхмәтҗаның ир түгел идемени?

С ә р б и җ а м а л (*һаман ачуланып*). Зинһар, әби, ачуымны китермә... мин бит... Әхмәтҗанны яратмыйдыр идем.

М ө г ъ л и ф ә. Әнвәрне яратасыңмы?

С ә р б и җ а м а л. Яратам шул, яратмасам, аның өчен иремнән аерылмас идем.

М ө г ъ л и ф ә (*мыскыл иткән тавыш белән*). Әнвәр дә сине яратамы? Әллә ни сине яратып, хатынлыкка да алып куймасын тагын!

С ә р б и җ а м а л (*җыларга якын тавыш илә ачуланып*). Нәрсәгә миннән мыскыл итеп көләсең? Әллә алмас дип беләсеңме?

М ө г ъ л и ф ә (*һаман да истиһза итеп*). Кем белә, бәлки, алыр да, синең өчен, бәлки, хатыннарын да аерыр.

С ә р б и җ а м а л (*каушый төшеп*). Нинди хатыннарын?

М ө г ъ л и ф ә. Нинди хатыннарын булсын, синең шикелле үк ике аяклы, ике куллы хатыннарын.

С ә р б и җ а м а л (*гаять ачуланып һәм каушап*). Булмас, ышанмыйм!.. Син... син... ялганлыйсың!

М ө г ъ л и ф ә. Ышанма, ышанма, бер дә ышанма. Синең миңа ышануың һич кирәк түгел. (*Урыныннан торып, ишеккә таба борыла башлый.*) Бүген ышанмасаң, иртәгә, берсекөнгә, ул көнне дә ышанмасаң, аның икенче көненә ышанырсың әле.

С ә р б и җ а м а л (*кычкырып җылый башлап*). Ник... син... алай булгач... белә торып, мине... харап... иттең!.. (*Җылый.*)

М ө г ъ л и ф ә (*явыз карау белән карап*). Һе, менә тагы иске авыздан яңа сүз, мин ни эшләп сине харап итим?

С ә р б и җ а м а л (*җылаган һәм карынкы тавыш белән, аяк тибеп*). Син, йөзе кара!.. Син, бәдбәхет!.. Син харап иттең! Син котыртмасаң, мин аерылмыйдыр идем.

М ө г ъ л и ф ә. Тагы да юкмы? Күңелсезгә күлмәк киертмиләр. Һи, сөрелгән нәрсә! Мине җылап куркытмакчы була. Куркалар иде ди синең җылавыңнан.

С ә р б и җ а м а л. Бәдбәхет! Дәҗҗал! Убырлы карчык! Чык моннан, бар! Вон! (*Диванга килеп егыла. Җылый.*)

Мөгълифә. Чыгам, чыгам. Кумасаң да чыгам. Ачыккач, үзең үк чакырып китерерсең әле. Авызыңа салган сары майны хәзер йота белмәсәң, соңыннан үзең үк телләреңне салындырып, җалманып, эзләп йөрерсең әле. Кискән икмәк кире ябышмый ул. Бер сөрелгәч, әллә кайда китә алмассың. (*Тавышын үзгәртеп, истиһза кылып.*) Җылама, кызым, җылама, юри генә әйттем. Кирәк булганда, мине ташлама, чакырт. Әптерәшиттән чибәрләрен дә табып бирермен. Хуш, кызым, сау бул. (*Истиһза кылып көлә.*) Һи-һи-һи! (*Чыгып китә.*)

Сәрбиҗамал. Бәдбәхет, убыр! Дәҗҗал! (*Диванга капланып җылый.*)

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәрбиҗамал ялгыз.

Сәрбиҗамал. Аһ! Нихәл итим, кая гына барыйм? Харап булдым, һай, йөрәгем! Нихәл итеп бу хурлыкларга түзим? (*Җылый.*) Һай, бәдбәхет карчык! Башыма шул гына җитте! Мин... мин... шул көнгә калдыммыни? Булмас, булмас! Мин бу хурлыкка түзә алмыйм. Үләм, бетәм! Әтием, әнием! Аһ, беттем, беттем! (*Диванга егыла. Җылый.*)

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Әнвәр, Сәрбиҗамал.
Әнвәр ишектән килеп керә, исерек.

Сәрбиҗамал (*сискәнеп*). Аһ! Ән...вәр!..

Әнвәр (*кулларын җәеп*). Нихәл, җаным! Мине сагындыңмы? Кил, матурым, кил, күрешик. (*Кочакламакчы була.*)

Сәрбиҗамал (*кулларын этеп*). Кит, кагылма, булмас...

Әнвәр. Ни булды сиңа, җаным, ә? Әллә үпкәләдеңме, ә? Әллә мин озак килми торганга, ташлады дип белеп, үпкәләдеңме, ә? Кил, җаным, кил, күрешик. (*Кочакламакчы була.*)

Сәрбиҗамал. Кит!.. Зинһар, кит!..

Әнвәр. Чү, чү, ни булды сиңа, ә? Иһи-һи-һи! Сәрби миңа үпкәләгән. Сәрби, Сәрби, үпкәләмә. Менә сиңа бүләк

алып килдем. (*Кесәсеннән бер тартма чыгарып, Сәрбиҗамалга суза.*)

Сәрби (*тартманы бәреп төшереп*). Юк, кирәкми...

Әнвәр (*тартманы идәннән алып, өстәл өстенә куеп*). Ярый, ярый, алма, үпкәң беткәч алырсың, синең әле әллә нәрсәгә кәефең киткән. Ә, тукта, менә миндә бер дару бар, кәефне бик яхшы китерә. (*Өстәлгә бер шешә коньяк чыгарып куя.*) Менә монсы авыз тәмлеләтергә кәмфит. (*Бер тартма конфет чыгарып куя.*) Менә бу кәефне бик яхшылата, кая, үзеңә дә бер стакан бир әле, эчеп җибәрик. Кәефең килсен.

Сәрбиҗамал. Әнвәр!..

Әнвәр. Нәрсә дисең, җаным? (*Янына килеп, кочакламакчы була.*)

Сәрбиҗамал (*төртеп җибәреп*). Килмә, зинһар, тимә... Әнвәр... Әйт, дөресен әйт?..

Әнвәр. Нәрсәнең дөресен?

Сәрбиҗамал. Синең... синең... ничә хатының бар?

Әнвәр. Һи! Юкка борчыласың икән. Куй әле, зинһар, юк сүзләреңне. Әйдә, утыр әле. Менә бу шәп нәрсәне берәрне җибәрик әле. (*Шешәдән стаканга сала.*)

Сәрбиҗамал (*гаять каушап*). Әнвәр, дим, җаным... Әйт... Зинһар, әйт...

Әнвәр (*илтифатка алмаган булып, өстәл янына утырып*). Әйдә, дим, эчик әле. Андый юк-бар сүзләр ни эшкә кирәк?

Сәрбиҗамал. Зинһар, дим, Әнвәр... Әйт! Зинһар, әйт! Ничә хатының бар?

Әнвәр (*бөтенләй икенче якка карап утырып, кулын селтәп*). Кит, зинһар, юк-бар сүз белән башымны ватма.

Сәрбиҗамал. Зинһар, әйт, Алла хакы өчен әйт, әллә... ничәме?

Әнвәр. Әллә ничәме? Нишләп әллә ничә булсын? Йә инде, зинһар, әйдә, күңелле генә утырыйк әле.

Сәрбиҗамал. Ходай өчен әйт, ничә?

Әнвәр эндәшми.

Бер генәме?

Әнвәр эндәшми.

Әллә икәүме?.. Өчәүме?.. Мине аласыңмы?.. Кайчан аласың?

Әнвәр һаман эндәшми.

Әллә... әллә... бөтенләй алдалап кына... йөрисеңме? (*Җылый.*)

Әнвәр (*стаканны алып эчеп*). Нигә җылыйсың?.. Әллә алмасам, сине ташлармын дип куркасыңмы? Минем сине генә туйдырырлык хәлем бар. Менә акча! Хатыным өч булса да...

Сәрбиҗамал (*күзләрен зур итеп ачып, аяныч кыяфәттә*). Өч булса да?.. Ах, харап булдым! Дөрес икән. Алдандым, алдандым, беттем! (*Җылый.*)

Әнвәр. Нәрсәсе алданган? Мин сине алдамам. Әнвәр диләр мине. Минем гомеремдә һичбер хатынны алдалаганым юк. Һәммәсен дә ал да гөл итеп тотам.

Сәрбиҗамал. Әнвәр... Соң син мине алырлык булмагач, ник аерттың? Ник аерттың? Ник мине харап иттең?

Әнвәр. Ничек мин аерттым? Ничек мин харап иттем? Сине бит ирең үзе аерды.

Сәрбиҗамал. Алмаслык булгач, ник алдадың?

Әнвәр. Мин бер дә алдамадым. Үзең яраттың. Үзең әйттердең. Үзең күрештең.

Сәрбиҗамал (*урыныннан торып*). Ничек? Мин яраттым? Мин әйттердем?

Әнвәр. Ник, Мөгълифә аркылы үзең әйттердең бит!

Сәрбиҗамал. Ходайдан бераз курык! Алла сакласын, мин ят иргә кеше кушып әйттерергә!

Әнвәр. Әллә мин әйттердемме?

Сәрбиҗамал. Әллә танмакчы да буласыңмы?

Әнвәр. Әллә миңа бәла да такмакчы буласыңмы? Миңа хатын бетмәгән, кеше хатынына яучы җибәреп йөрергә!

Сәрбиҗамал (*ачуланып*). Алдама!

Әнвәр. Бер дә алдамыйм, миңа хатын кытлыгы булганы юк. Син әйттердең, мин кабул иттем.

Сәрбиҗамал. Ялган!

Әнвәр. Ялган булса, хәерле булсын. Риза булсаң, бергә шулай торырбыз.

Сәрбиҗамал. Ничек?

Әнвәр. Ничек булсын, менә шулай, хәзергечә.

Сәрбиҗамал. Әллә миңа уйнаш итеп торырга кушасыңмы? Әллә мине уйнашчың итеп тотмакчы буласыңмы?

Әнвәр. Ә ничек кирәк соң сиңа? Әллә сине тагы бишенчегә алыйммы?

Сәрбиҗамал (*тәмам хәлдән таеп*). Булмас. Мин, үлсәм үләрмен... уйнашчы булып тормам!

Әнвәр. Булмасаң, хәерле булсын. Миңа тагы табылыр.

С ә р б и җ а м а л. Сез... бәдбәхет... икән.

Ә н в ә р. Анысы кемдер.

С ә р б и җ а м а л. Алдаучы, ялганчы, каһәр төшкән... кешеләр икәнсез!

Ә н в ә р. Очень может быть!

С ә р б и җ а м а л. Моннан... соң... минем... өемә... аяк та... басма!..

Ә н в ә р (*урыныннан торып*). Кирәге дә юк. Дөньяда чибәр син генә түгел! (*Тартманы кесәсенә сала.*) Алай бик чәпчемә.

С ә р б и җ а м а л. Алланың каһәре төшсен сезгә... җир йотсын... сезне!.. (*Җылый, диванга егыла.*)

Ә н в ә р. Чәнчел, кадал! (*Күкрәгенә сугып.*) Бу кесәдә акча бетмичә, дөньяда кыз бетмәс! (*Ишекне каты ябып чыгып китә.*)

С ә р б и җ а м а л. Аһ, аһ, аһ, аһ! (*Егыла, тавышы бетә.*)

Бүлмә караңгылана. Тышта күк күкрәгән тавышлар ишетелә. Яшен яшьни.

## АКТЫК МӘНЗАРӘ

Тышта бик каты күк күкри... С ә р б и җ а м а л, урыныннан сикереп торып, бер кулын әллә кая таба сузып, чәчләре тузгыган хәлдә «аһ!» дип кычкырып, бер почмакка барып поса. Яшен һаман ялтырап китә. Сәрбиҗамал, әллә нәрсәдән куркып, кире-кире чигенә. Каршы тарафта, диварда, Әхмәтҗанның хыялы заһир була. Сәрбиҗамал, куркып, икенче почмакка поса. Куллары белән күзләрен каплый. Ачы аваз белән: «Әйем, әйем, кирәкми! Сукма! Кыйнама! Бармыйм, мин түгел, һай!» – дип иңгерәеп төшә. Шул хәлдә бераз торгач, сикереп торып, кулларын җәеп: «Әхмәтҗан! Кил! Кил! Барам! Киләм! Барам!» – дип, идәнгә сузылып егыла. Әхмәтҗанның сурәте югала. Җил сызгыра. Яшен яшьни, күк күкри, шыбырдап яңгыр ява башлый.

П ә р д ә.

---

Х ы я л ы з а һ и р б у л а – сурәте күренә.

# БАНКРОТ

*Пьеса 3 пәрдәдә*

ӘШХАС:

Сираҗетдин Туктагаев – заһирдә бик суфи күренә торган сәүдәгәр.
Гөлҗиһан – Сираҗетдинның хатыны.
Җамалетдин Туктагаев, Камалетдин Туктагаев – Сираҗетдинның бертуган карендәшләре.
Хәдичә – Сираҗетдиннарга белеш тол хатын.
Нәгыймә – им-том итеп йөри торган карчык.
«Туганым» – Гөлҗиһанның карендәш тиешле кешесе.
Гарифә, Мәликә – кунаклар.
Мөхәммәтҗан 1 нче, Закир – кибетчеләр.
Мөхәммәтҗан 2 нче – кибетче малай.
Гарәфи – Сираҗетдинның юлдашы.
Хәмди, Мәрфуга, Гайниҗамал – асраулар.
Доктор һәм Москва доверенныйлары.

Вакыйга Казанда.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сираҗетдин Туктагаевның йорты. Яхшы итеп җыештырылган, бай сымак бер өй. Сул якта кантор өстәле, аның янында бер шкаф, уң тарафта диван, өстәл, креслолар. Стена буенда урындыклар, көзгеләр, ике тарафта һәм түрдә ишекләр, ике як янда тәрәзәләр. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә бер кеше дә юк.

БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Сираҗетдин ялгыз.

Сираҗетдин (*ишектән бик кызуланып кереп, якягына карап*). Бик яхшы булды әле, бер кеше дә юк

---

Заһирдә бик суфи – тыштан бик изге.

икән. (*Өстеннән намаз тунын салып ташлап.*) Бер дә шаулама, эшләрнең һәммәсе дә минем файдага баралар әле. (*Кесәсеннән бер гәзитә чыгарып.*) Менә бүген дә бик шәп хәбәрләр язганнар әле. (*Укый.*) «Астраханнан менеп килә торган «Кавказ – Меркурий» пароходының беренче классында килә торган юлчы – Тарабаров исемле бер бай – өстенә-башына бик яхшы киенгән бер кеше белән белешләнгән. Аның белән берничә мәртәбәләр чәйләр эчеп һәм бергә ашап килгәннәр. Кич белән чәй эчкән вакытта, теге кеше Тарабаровның стаканына йоклата торган дару салып эчерткән. Тарабаровның һушы китеп егылгач, янында алып бара торган унбиш мең сум акчасын алып, өстеннән каютын бикләп, үзе бер пристаньда төшеп калган». Шәп иткән бит, ә, Тарабаров йоклаган диген, ә? Йоклаган шул, йоклаган. Бигрәк аңгыра нәрсә икән. Хәзерге заманда шулкадәр күп акчаны үзең белән бергә юлга алып чыгарга ярыймы соң! Җүләр нәрсә, аны алдан сандыкка салып, кладавайга бикләп китәргә ярамаган икән. Кладавайга бикләп киткән булса, бер дә югалмас иде. Җүләр икән шул, җүләр. Җүләрне чәчеп үстермиләр аны, ул үзе үсә. Ну ярый, бик шәп булды әле, бу да бик шәп. Ярый, үземезчә гәзитәләр чыгуның файдасын быел ук күрдем. Үземезчә гәзитәләр чыкмаса, мин әле ул фикерне кайдан уйлап чыгара алыр идем? (*Гәзитәне шкаф астына куя да, аннан бер кочак гәзитә чыгарып.*) Менә алар монда никадәр! Боларның һәммәсендә дә шундый хәбәрләр тулып ята. Мин аларның монда талаучылары бер дә тотылмаганнарын гына сайлап җыеп куйдым. Миңа аның талаучылары тотылганнарының кирәге дә юк. Мине талыйсылары да юк, һәм минем үз янымда акча йөртәсем дә юк. Янымда акча йөртергә мин җүләр түгел. (*Гәзитәләрне тыгып куеп.*) Барыгыз әле, сез шунда ятып торыгыз әле. Сез минем өчен бик кадерле нәрсәләр. Сез миңа никадәр зур гакыл бирдегез. Сез биргән гакылны шайтан үзе дә эзләп таба алмас. Коры көе генә, турыдан-туры гына зарар иттем, кеше өстендә алачакларым бик күп китте-фәлән дип кенә шартлап[1] булмый. Алай итеп кенә мәскәүләргә сумына ун-унбиш тиен генә биреп булмый. Аның мудасы да беткән, ышанмыйлар да. Ә болай булганда үзләренең дә күзләре алакаер. Биргәнне тизрәк алып калырга тырышырлар. Ну, болай монда вакыт уздырып, озаклап торырга ярамый, тизрәк банкыга барырга кирәк. (*Шкаф астыннан бер кечкенә саквояжны чыгарып һәм аңа берничә төргәк кәгазьләрне салып.*) Барыгыз әле, сез шунда ятып торыгыз. Сезнең һәрберегез бишәр йөз сумнан – барысы 49

мең тәңкә акча, ди. Ну, инде вакыт җитә. (*Сәгатен чыгарып карап.*) Сәгать унбер булган, озакламый пуезга төшәргә вакыт җитә. Сиңа әйтәм, сиңа әйтәм! Кая, син, бире кил әле!

### ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

С и р а җ е т д и н, Г ө л җ и һ а н.

Г ө л җ и һ а н (*ишектән кереп*). Ай Алла, син кайткансың да икән. Мин белми дә торам. Теге якта, сиңа юлга булыр дип, кәтлит пешереп ятадыр идем.

С и р а җ е т д и н. Мин хәзер банкыга барам, аннан акча алып кайтам, пуезга төшәргә вакыт җитә, син нәрсәләрне тизрәк хәзерләп куй.

Г ө л җ и һ а н. Хәзерлә дип, мин әллә нәрсәләр хәзерләмим; юлга чәй, шикәр, ике алма бәлеше, бер табак сумса, бер тавык гөбәдиясе, ике чебеш хәзерләдем. Аннан ары – менә хәзер кәтлит пешерәм. Шулар җитәр бит?

С и р а җ е т д и н. Ярар, җитәр. Комган белән чәйнекне онытма. Юк исә юлда бик уңайсыз була. Аннан соң теге бохар намазлыгын да куй.

Г ө л җ и һ а н. Ә, кара әле, хәтеремдә дә юк икән, намазлык дигәч исемә төште, анда сиңа ничә пар күлмәк кирәк булыр?

С и р а җ е т д и н. Мин анда бик озак тормыйм, куй шунда бер-икене. (*Контор өстәленең тартмасын актара.*)

Г ө л җ и һ а н. Мин өч пар күлмәк, ике сөлге, бер пар эскәтер, ике пар аяк чолгавы, өч тастымал куйдым. Шулар җитәр бит?

С и р а җ е т д и н. Ярар, җитәр. Ләкин тизрәк хәзерлә. Мин хәзер кайтам, мин кайтуга һәммә нәрсә дә хәзер булып торсын. (*Бер кечкенә дәфтәрне тартмадан алып, кесәсенә салып, өстенә киенә дә кечкенә саквояжны алып чыга башлый.*)

Г ө л җ и һ а н. Берәр калай савыт белән варинья дә куйыйммы?

С и р а җ е т д и н. Ансы булмаса да ярар. (*Чыгып китә.*)

### ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Г ө л җ и һ а н ялгыз.

Г ө л җ и һ а н. Әй, харап булдым, сорарга да оныттым. (*Ишеккә тиз генә барып, ишекне ачып.*) Кара әле, сиңа әйтәм, нинди көрпәне куйыйм, зурнымы, кечкенәнеме?

Юрган куйыйммы, адиялмы? (*Ишекне ябып.*) Йә, ярар инде, ишетмәде. Әле онытмаска кирәк, Мәскәү өстендә[2] бер-ике табын хатыннар уздырып алырга кирәк. Инде мәҗлес уздырмаганга әллә никадәр булды. Мәкәрҗә өстеннән бирле бер табын да мәҗлес уздырганым юк. Гыймран хаҗи Газизәсе Мәскәү өстендә сигез табын хатыннар уздырды. Безнекенең һаман ужуы бетми, «уздырырсың әле» ди. Мәскәүдә анда әйбер бик арзан була, ди. Беркөннәрдә Гыймран хаҗи Газизәгә ике йөз илле тәңкәгә бик киң ике алтын беләзек алып кайткан, күрсәң, матурлыгына исең китәр. Мин дә бер брушка алып кайтырга әйтим әле.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан, Хәдичә.

Гөлҗиһан. Әйдүк, Хәдичә абыстай, хуш киләсең!

Хәдичә. Исәнме, Гөлҗиһан, исән генә торасызмы?

Гөлҗиһан. Аллага шөкер. Әйдә, Хәдичә абыстай, түрдән уз.

Берсе диванга, берсе креслога утырып, дога кылалар.

Хәдичә. Әйтүең-нитүең юк, синең Сираҗетдиның Мәскәүгә бара икән ич.

Гөлҗиһан. Әйе шул, хәзер озакламыйча бакзалга төшә.

Хәдичә. Мин дә шуны ишетеп, китеп-нитеп бармасын дип, ашыга-ашыга килдем. Аңа әйтеп җибәрәсе йомышларым бар иде.

Гөлҗиһан. Нинди йомыш?

Хәдичә. Нинди йомыш дип инде, әллә нинди зур йомыш түгел. Без Мәргубәнең кызы Фатыйманы кияүгә бирмәкче булабыз бит. Минзәлә кайткач, туйларыбыз буласы. Шуңа бер пар чиккән өстәл эскәтере, дүрт намазлык, аннан соң берничә пар аяк чолгаулары кирәк буласы иде. Шуларны барган юлы Сираҗетдин Мәскәүдән алып кайтып бирмәс микән дип килгән идем.

Гөлҗиһан. Алып кайтыр, ник алып кайтмасын? Бик авыр хезмәт түгел ич ул.

Хәдичә. Зинһар инде, алайса, бер юлга, сүз тыңлап кына, шуларны алып кайтып бирсен инде. Менә шуңа дип илле тәңкә акча да алып килгән идем. Җитмәслек булса, тагы үз яныннан бераз кушып булса да алып кайта күрсен. Кайткач исәпләшербез. Зинһар инде, яхшы-

ны ала күрсен, кеше арасында оятка калырлык була күрмәсен. Безнең үзебезнең барып алырга ир-атыбыз да юк. Әле инде алтын сәгатьне дә моннан гына алмакчы булдык.

Гөлҗиһан (*акчаны алып*). Ярар, әйтермен, алып кайтыр. Нәрсәләр, нәрсәләр кирәк дигән идең әле?

Хәдичә. Нәрсәләр икәнен менә яздырып алып килгән идем. (*Бер кәгазь чыгарып бирә.*) Зинһар инде, тыңлый күрсен!

Гөлҗиһан. Яхшы, яхшы, алып кайтыр.

Хәдичә. Хуш, Гөлҗиһан, сәламәт булып торыгыз, Аллаһы Тәгалә хәерле сәфәрләр бирсен!

Гөлҗиһан. Хәзер китәргә ашыга, шуның өчен инде сине хәзер утыр дип тә кыстый алмыйм.

Хәдичә. Юк, юк, кирәк түгел, юк сүзне сөйли күрмә. Утырган вакыт та булыр әле. Мәскәү өстендә, Алла бирсә, үзең рәхим ит. Ярый, хуш, сау бул! (*Чыгып китә.*)

Гөлҗиһан. Хуш! (*Озатып кала.*)

## БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан ялгыз.

Гөлҗиһан. Намазлык димәктән, үземнең дә хәтеремә килмичә тора икән әле, үзебез өчен дә чиккән постау эскәтерләр кирәк иде. Бер дә хәтерем юк шул. Ишек чаршаулык яхшы плүш тә әйтермен дигән идем. Беркөннәрне Мәңгәр Йосыфларның ишек чаршауларын күреп исем китте. Мәскәүдән алып кайтканнар. Бөтенләй менә, алтынлаган нәрсә төсле, җалык-җалык итеп, ялтырап тора. Ул кәнәфиләрен, урындыкларын күрсәң, исең китәр, һәммәсен бер очтан хәзерләгәннәр. Беркөн үзенә әйткән идем: «Без дә шундыйны алыйк», – дип. «Тукта, байыйк әле, баегач алып кайтырмын», – ди. Без кайчан баербыз әле, баеганчы көтеп торсаң, ул вакытта тагын әллә нинди матурлары килеп чыгар.

Асрау (*ишектән кереп*). Абыстай, Нәгыймә әби килгән, монда гына чыгып керсен әле, ди.

Гөлҗиһан. Ярар, хәзер чыга, диген.

Асрау чыгып китә.

Мәскәү өстендә тамыр кайнаттырып эчә торган идем. Шуны кайнатып бирергә дип килгәндер әле. (*Чыгып китә.*)

## АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

С и р а җ е т д и н ялгыз.

С и р а җ е т д и н (*ишектән кызуланып кайтып кереп, өстен чишенеп ташлап*). Һәммәсе дә мин теләгәнчә булды. Барысына да бишәр йөз сумлык акчалар алдым. «Андый акчалар ни эшкә кирәк соң алар?» – диләр. «Акчаны үзем белән алып барам, шуның өчен кирәк», – дигән булам. Фидыр Иваныч әйтә: «Ай-һай, Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович, хата кыласың икән. Хәзерге заманнарда акчаны үзең белән йөртү апасны бит, пирават белән генә җибәрергә кирәк иде», – ди. (*Өстәл тартмасыннан әллә нәрсә эзли.*) «Ничава, дим, Алла кушмаган эш булмас», – дим. «Мин бит мөселман кеше», – дим. «Мөселман кеше ул андый юк-бар эштән курыкмый», – дим. Миңа нигә куркырга? Аны кладавайдагы тимер сандыктан кем килеп урлый ала? (*Өстәл тартмасыннан ачкыч алып, саквояжны шкафка куеп, кесәләрендәге акчаларны бераз чыгарып, яңадан тыгып куеп.*) Әйдәгез әле сез, акчалар, мин кайтканчы кладавайда бик һәйбәтләп, тынычлап кына ятып торыгыз әле. Эшне төзәтергә, бәлки, сез артыгы белән җитеп торырсыз. (*Чыгып китә.*)

## ҖИДЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Г ө л җ и һ а н, Н ә г ы й м ә.

Н ә г ы й м ә. Мин Сираҗетдинны киткәндер дип белгән идем, ялгыш иртәрәк килгәнмен икән.

Г ө л җ и һ а н. Килсәң ни булган, син аннан кача торган кеше түгел бит.

Н ә г ы й м ә. Әйе шул, кызым, ә Сираҗетдин бит ул минем балам шикелле кеше. Рәхмәт инде аңа, мине һичбер вакытта да хәтереннән чыгармый. Зәкятыннан[3] да, нәзер-ниязларыннан[4] да һичбер вакыт коры калдырмый. Әле узган Мәскәүгә баруында да: «Мә, әби, Хуҗа Баһаветдин[5] рухына багышлап дога кылырсың», – дип, илле тиен сәдака биреп киткән иде. Җылый-җылый хәер-догалар кылдым, рәхмәт яусын инде аңа. Дәүләтенең дөнья вә ахирәт игелеген күрсен. Мин һәрвакыт догада гына торам. Безнең шикелле ятим карчыкларны зурлаган өчен инде аны Алла үзе зурласын.

Г ө л җ и һ а н. Амин!

Н ә г ы й м ә. Кызым, инде «сәдака бирде» дигәч тә, мин аны болай гына әйтәм. Син тагы, «бүген дә шулай

сәдака өмет итеп килгән икән» дип уйлый күрмә. Аннан-моннан әйтүем түгел. Инде моңа кадәр биргәннәреңдә Алла үзе кабул итсен.

Асрау керә.

Асрау. Абыстай, син ул чебешләрне кайсы кәрзинкәгә салырга дип әйткән идең?

Гөлҗиһан. Кайсы кәрзинкәгә булсын, капкачлы түгәрәк кәрзинкәгә. Кеше әйткәнне яхшылап колагыгыз белән тыңламыйсыз да, аннан ары тик миегез череп йөри. Күлмәкләрне хәзерләдеңме?

Асрау. Юк әле.

Гөлҗиһан. Һи, аңгыра нәрсәләр! Хәзер бит абзаң кайтыр вакыт җиткән. Бакзалга төшәргә кызуланып йөри. Үзең карамасаң, бер эшне дә җүнләп эшләүче кеше юк. Нәгыймә абыстай, син бераз утырып тор әле, мин чыгып шул нәрсәләрне генә рәтләп керим әле.

Нәгыймә. Ярар, кызым, бар, бар. Минем өчен эшеңнән кала күрмә.

Гөлҗиһан чыгып китә.

## СИГЕЗЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Нәгыймә ялгыз.

Нәгыймә. Биргән кешегә Алла бәхетне учлап биргән. Бирмәгәнгә бер тиен дә юк. Әле мин белгәндә генә Сираҗи кышкы суыкта бер кат юка бишмәт белән калтырап туңып йөри торган бер кибетче малай иде. Аз арада гына нинди баеды да китте. Әүвәлге йорты да нинди яхшы һәйбәт йорт иде. Базарга йөрергә ерак дип, ансын сатты. Хәзер инде Сираҗи зур пулатлы бай булды. Хәзер инде Сираҗиның ялтыраган көмеш көпчәкле ризиновыйларда киерелеп утырып йөргәнен күрсәң, танымассың да. Ризиновыйларның көпчәкләре җылык-җылык итеп тора. Карарга күз чагыла. Ризиновыйның шиннәре бүрәнә җуанлыгы бар. Мескен Сәлимә генә бу рәхәтләрне күп күрә алмады. Үлеп китте. Берәү үлә, икенчеләре көн күрә. Ни эшләмәк кирәк соң, әҗәлдән котылып калыр хәл юк шул. Берәүнең бәхетенә икенче кеше керә алмый. Яшь хатын бәхете инде. Бичара Сәлимә бик яхшы хатын иде. Килгән саен учлап-учлап чәй-шикәрләр биреп җибәрәдер иде. Куркулыкларны[6] да бик еш койдырадыр иде. Хәер, әле Гөлҗиһан да минем өчен файдасыз түгел.

Әледән-әле тамырлар кайнаттырып ала. Тукта әле, мин тагы бу якта утырып, авызымны ачып юл сәдакасыннан колак кагып калмыйм. Сираҗи китеп-нитеп бармасын. Чыгыйм әле. (*Чыгып китә.*)

### ТУГЫЗЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Сираҗетдин, Гөлҗиһан, соңра Нәгыймә.

Сираҗетдин (*ишектән кереп, язу өстәле янына барып, кечкенә дәфтәрне өстәл тартмасына салып*). Инде эш тәмам булды. (*Ишек янына барып.*) Кара әле, сиңа әйтәм. Бире кара әле.

Гөлҗиһан керә.

Нихәл, нәрсәләрне хәзерләп бетердегезме? Миңа китәргә вакыт.

Гөлҗиһан. Хәзерләдем.

Сираҗетдин. Бик яхшы, алай булса. Кая, миңа бик яхшы таза аякчулар китер әле.

Гөлҗиһан. Ни эшлисең ул аякчулар белән? Мин кичә генә ак аякчулар биргән идем бит.

Сираҗетдин. Бар әле син, тизрәк китер. Пуезга соңга калам. Ни эшкә икәнен соңыннан күрерсең.

Гөлҗиһан чыгып китә.

Эшне шулай итеп бик ныгытып пешереп эшләргә кирәк. Бер дә кеше шикләнерлек булмасын. (*Шкафтан саквояжны алып.*) Менә болар инде акчалар, ди. Аларны югалмасын өчен бик яхшылап балтырларга чорнарга кирәк. (*Аякларын чишенә башлый.*) Бераз йөрәк сикерә сикерүен дә, шулай да булса серне бирергә ярамый. Нык торырга кирәк. (*Каты гына итеп тамагын кырып, киемнәрен төзәтеп, үзенә канәгатьле бер кеше кыяфәте биреп куя.*) Менә шулай. Бер дә серне бирмә, нык тор.

Гөлҗиһан керә.

Гөлҗиһан. Менә аякчулар китердем. Бу аякчуларың да ак ич әле.

Сираҗетдин. Мин сиңа әйттем бит, соңыннан аңларсың дип. Менә бу кәгазьләр акча булыр. Боларда кырык тугыз мең тәңкә, аңладыңмы? Кырык тугыз мең, кырык тугыз мең тәңкә акча бар.

Гөлҗиһан. И Ходаем! Кая әле? (*Бер төргәкне алып, ачып карамакчы була.*)

С и р а җ е т д и н. Чү-чү-чү! Тия күрмә! Мин аларны бик ыспайлап юка итеп төреп куйдым. Чуалтма. (*Төргәкле кәгазьләрне ала. Халыкка карап.*) Бөтенләй эшне боза язды. (*Гөлҗиһанга.*) Менә аларны шушылай итеп, бик һәйбәтләп читек балтырына батырабыз. (*Төргәкләрне, икешәр-икешәр итеп, балтырларының ике ягына куеп, аякчу белән чорный башлый.*) Бар, син, кара әле, ишекләр яхшы ябылганмы? Анда ишек ярыгыннан карап торучылар булмасын!

Г ө л җ и һ а н (*ишекләрне барып карап*). Юк, бернәрсә дә юк, һәммәсе дә бик яхшы ябылган. Кара әле, сиңа әйтәм, соң ул акчаларыңны читек балтырыннан төшереп югалтып, харап булмассыңмы? Әллә ни эшләп күңелем шикләнә. Шул сакваяжга гына салсаң, тагы да яхшырак булмасмы? Бу сакваяжның биге дә бар.

С и р а җ е т д и н. Һи, хатын, хатын, синең бер дә башың йөрми икән. Соң шул сакваяжны урласалар? Ул вакытта ни эшләрсең? Ул бит кечкенә нәрсә, күтәрерләр дә алып чыгып китәрләр. Ә син акчадан колак кагып калырсың.

Г ө л җ и һ а н. Хәер, инде ансын үзең беләсең. Шулай да ул кадәр күп акчаны читек балтырына гына кую, әллә ничек, бик куркынычлы шикелле тоела.

С и р а җ е т д и н. Тәкъдирдә язылмаган булса, бернәрсә дә булмас. Бая банкыда Фидыр Иванич та шулай дип әйткән иде. Мин әйттем: «Мин мөселман кеше, тәкъдиргә ышанам», – дидем. «Ето, – дидем, – судба, – дидем. – Судбада язылмаса, бернәрсә дә булмас», – дидем. Фидыр Иванич башын селкеп, бик гаҗәпләнеп калды. (*Киеп бетерә.*) Нихәл, бик җуан булмадымы? Тыштан бик беленеп тормыймы?

Г ө л җ и һ а н. Юк, алай зарарлы түгел, бик беленми.

С и р а җ е т д и н. Кая инде алайса, әйберләрне чыгарсыннар. Пуезга төшәргә вакыт, Закирны дәшсеннәр, әйберләрне күтәреп чыгарыр. Кара әле, син минем акчаны читек балтырына батырганны бер кешегә дә сөйли күрмә. Бу чагында бер дә кешегә ышаныр хәл юк.

Г ө л җ и һ а н. Алла үзе сакласын. Кешегә сөйләргә мин җүләр түгел.

С и р а җ е т д и н. Бар әйт, тизрәк нәрсәләрне чыгарсыннар!

Г ө л җ и һ а н (*ишекне ачып*). Кая, абзагызның багажларын чыгарыгыз!

Ишектән А с р а у белән З а к и р багажларны күтәреп керәләр.

З а к и р. Абзый, менә шулай итеп бәйләгән идем, ярармы?

С и р а җ е т д и н (*нәрсәләрне карап*). Ярар, яхшы бәйләгән. (*Гөлҗиһанга.*) Кирәкле нәрсәләрнең барысы да хәзерләнгәнме?

Г ө л җ и һ а н. Хәзерләнгән, хәзерләнгән. Бер мендәр, көрпә, адиял куйдым. Комганны менә бу капчыкка тыктым. Өч пар күлмәк, ике сөлге, өч тастымал, бер пар аякчу, намазлык, кичке күлмәк, һәммәсен дә куйдым...

С и р а җ е т д и н. Чәйнек, чынаяк?

Г ө л җ и һ а н. Куйдым, куйдым, аларын да куйдым. Бер пычак, балкашык, тоз – һәммәсен дә куйдым. Юлга ашарга унике кәтлит, ике алма бәлеше, бер табак сумса, бер тавык гөбәдиясе, ике чебеш хәзерләдем. Менә алары бу кәрзинкәдә булыр. Чәй-шикәрләр дә шунда. Бер савыт белән варинья дә куйдым. Юл йөргәндә ашалыр әле, әрәм булмас.

С и р а җ е т д и н. Ярый, бик яхшы. Закир, бар син тизрәк әйберләрне атка чыгарып сал.

Закир күтәреп чыгып китә.

Йә, әйдә, Аллага тапшырдым инде, дога кылыйк. Өйгә яхшы күз-колак була күр. Кибетчеләр, абзый өйдә юк дип, иркенләп йөрмәсеннәр. Вакытында кайтып, вакытында кибеткә чыксыннар. Кич белән капканы бикләтеп, ачкычны үз яныңа ал. Кич белән чыгып йөрмәсеннәр.

Г ө л җ и һ а н. Ярый, Алла боерса.

С и р а җ е т д и н. Йә, ярый, башка йомыш-юл юкмы инде?

Г ө л җ и һ а н. Ә, хәтеремдә дә юк икән, онытып кала яздым. Бая Хәдичә абыстай килгән иде. Мәргубә кызы Фатыйманы кияүгә бирмәкче булалар икән. Минзәлә кайткач, туйлары буласы, ди. Шуңа эскәтерләр, намазлыклар, тагын әллә нәрсәләр кирәк буласы икән. «Зинһар, Сираҗетдин шул йомышларны гына йомышлап кайтсын ла», – дип, илле тәңкә акча калдырып киткән иде, менә акчасы, менә язуы.

С и р а җ е т д и н (*халыкка карап*). Ишкән икән! Мине чынлап та Мәскәүгә бара дип белә торганнардыр. (*Чырайларын сытып.*) Алар артыннан йөрергә минем эшем беткәнмени? Минем үз эшләрем дә күп. Башка кеше тапмаганнар икән.

Г ө л җ и һ а н. Әманәт җан саклар, ди. Бер юлга гына тыңларсың инде. Мин аңа алып кайтыр дип ышандырып калдым.

С и р а җ е т д и н. Ярар, хәерле булсын инде. Вакытым булса, алып кайтсам кайтырмын тагы.

Г ө л җ и һ а н. Аннан соң, тагы шуны да әйтермен дигән идем. Мәскәүдә анда нәрсә бик очсыз була, ди. Барган көе шуннан бер-ике генә чиккән постау эскәтер белән ишек чаршавы өчен яхшы плүш алып кайтсаң, бик һәйбәт булыр иде. Плүш чаршау бик матур була икән. Беркөн Мәңгәр Йосыфларда күргән идем, алар Мәскәүдән алып кайтканнар икән. Бик матур, кәнәфиләрен, урындыкларын да – һәммәсен бер очтан шуның белән тышлатканнар.

С и р а җ е т д и н. Яхшы, ярый, вакыт тисә, алып кайтырмын.

Г ө л җ и һ а н. Әле шуны да әйтермен дигән идем: Гыймран хаҗи Газизәгә бик һәйбәт, бик киң алтын беләзекләр алып кайткан икән. Минем беләзекләрем күп; юньле, яхшы брушкаларым гына юк. Шунда бер барган көенчә яхшырак бер брушка да алып кайт.

С и р а җ е т д и н. Яхшы, ярый, вакыт тисә, алып кайтырмын. Йә, дога кылыйк инде, пуезга соңга калам.

Г ө л җ и һ а н. Йә, ярый.

Дога кылырга утыралар.

Н ә г ы й м ә (*акрынлап ишектән кереп*). Ярабби Ходаем, тәүфикълы, тәлигале гомерләр насыйп ит. Байлык, шатлык белән көн күрергә, шатлык, рәхәтлек белән йөреп кайтырга насыйп булсын. (*Урындыкка утыра.*)

Дога кылалар.

С и р а җ е т д и н. Исәнме, Нәгыймә абыстай! Син монда идеңмени?

Н ә г ы й м ә. Әйе, улым, монда. Син Мәскәүгә китә дигәч, күрешеп калыйм дидем.

С и р а җ е т д и н (*кесәсеннән бер көмеш акча чыгарып биреп*). Яхшы, Нәгыймә абыстай. Хәер-фатихада булыгыз инде.

Н ә г ы й м ә. Рәхмәт, улым, рәхмәт. Сәламәтлек, шатлык, куанычлык белән күрешергә насыйп булсын. Бай бул, улым! Баеп кайт. Минем шикелле ятим карчыкларны куандырган өчен, сине Алла үзе куандырсын.

С и р а җ е т д и н. Хуш инде, әби, хуш, Гөлҗиһан. (*Гөлҗиһан белән күрешә.*)

Н ә г ы й м ә. Хуш, улым, хуш. Исән-сау йөреп кайт.

Сираҗетдин чыгып китә, Гөлҗиһан озата чыга.

---

Т ә л и г а л е – бәхетле.

## УНЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Н ә г ы й м ә, соңра Г ө л җ и һ а н, соңра а с р а у л а р.

Н ә г ы й м ә (*кесәсеннән акчасын алып карап*). Ярый, ярый, хәерле сәфәр булсын. Бөтенне яудырган икән. Ахры, бу араларда файданы яхшы итә башлагандыр. Гөлҗиһан керсен дә инде, аннан ары акрынлап кайтырмын. Бәлки, тамыр кайнатырга акча да бирер әле.

Гөлҗиһан, кереп, тәрәзә саен карый.

Нихәл, кызым, озаттыңмы? Ярый инде, сәламәтлектә, шатлыкта йөреп кайтсын.

Г ө л җ и һ а н (*тәрәзәдән башын алып*). Киттеләр. Мәскәү өстендә дүрт-биш табын хатыннар уздырып алырмын дигән идем. Үзеннән сорап калырга аз гына хәтеремнән чыкмаган, озата чыккач, өйалдында гына исемә төште.

Н ә г ы й м ә. Яхшы, яхшы, кызым, бик яхшы. Шулай байлыгыгызның кадерен белеп калыгыз. Хуш, сау бул, кызым, кайтыйм инде.

Г ө л җ и һ а н. Тукта, китми тор, чәй эчәрбез. Ашны берсекөнгә үк уздырып алам. Асрауларга өйләрне җыештырырга гына кушыйм да, аннан ары чәй эчәрбез. Гайниҗамал, Мәрфуга, Хәмди! Керегез әле монда.

А с р а у л а р керәләр.

А с р а у л а р. Нәрсә, абыстай, ни дисез?

Г ө л җ и һ а н. Менә абзагыз сезгә юл сәдакасы биреп калдырды. (*Бирә.*) Хәмди, син теге бүлмәгә безгә чәй хәзерлә. Мәрфуга, син аш пешерүче хатынга бар. «Абыстай берсекөнгә биш табын гына хатыннар уздырам, бүген үк хәзерләшергә килсен, дип әйтте», – диген. Син, Гайниҗамал, кибеткә төш тә Мөхәммәтҗанга әйт: хәзер биш табынлык запискә язып менгерсен. Аннан кайтышлый Бәдри Мәфтухасына төшеп әйт: өйләр җыештырышырга килсен. Бар, тиз булыгыз. Аннан ары менә бу якларны җыештыра башларсыз. Барыгыз! Аңладыгызмы?

А с р а у л а р. Аңладык, аңладык. (*Чыгып китәләр.*)

Г ө л җ и һ а н. Әйдә, Нәгыймә абыстай, теге якка, чәй эчәрбез. Аннан сиңа тамыр кайнатырга акча да биреп җибәрермен. Берсекөнгә ашка син дә килерсең. Онытма, яме!

Н ә г ы й м ә. Ярар, кызым, ярар. (*Тора башлый.*) Алла! Ай! Билләрем авырта. Картлык.

Чыга башлыйлар.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Беренче пәрдәдәге зал. Ак эскәтерләр ябылган өстәлләр хәзерләнгән. Түрдәге сәгать икенче ярты булган.

### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Нәгыймә ялгыз.

Нәгыймә (*ишектән чирекле шешә белән саргылт төстә сыек бернәрсә күтәреп кереп*). Уф Алла, арып беттем. (*Шешәне урындыкка куеп, башыннан шәлен сала.*) Бүгенге мәҗлескә килгәнче тизрәк өлгерсен дип алып килдем. (*Шешәне селкетеп.*) Йөзе кара, бер дә күбекләнми. Тизрәк әчесен, тизрәк төнәсен дип, трахтир сырасын ике шешә итеп салган идем, алай да әле әчеп җитмәгән. Монысы кыйммәткә төште: егерме тиенгә тамыр алдым, ике шешә трахтир сырасы, ярты кадак шикәр салдым. Мин кайнаткан тамырны бай хатыннары бик яраталар: «Синең кулың бик шифалы, әчеп җибәргәч тә, бөтен тамырларга китә, тәмам изелдереп йоклата», – диләр. Трахтир сырасын күбрәк салсаң, аның өстенә актан да бераз тамызсаң, йоклату гына түгел, җырлатыр да ул. (*Шешәне алып.*) Тукта әле, моны кая булса да бер җиргә яшереп куярга кирәк. Йә кунаклары-ниләре килеп күрерләр. Бай хатыннары алар бер дә серләрен кешегә сиздерәселәре килми. (*Шешәне диван астына яшереп.*) Аларның баш ярылса – бүрек эчендә, кул сынса – җиң эчендә була. (*Икенче ишектән чыгып китә.*)

### ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан белән «Туганым».

Гөлҗиһан (*«Туганым» белән ишектән кереп*). Туганым, зинһар инде, син булыша күр. Бер дә күз-колак булырлык, булышырлык кешем юк. Син, зинһар инде, шунда рәтләп, кунакларны карап утырта күр. Гарифә кодагый түбәнгә кала күрмәсен. Бик үпкәчән, бик гаепчән кеше. Түбәнгә калдырсаң, күзенә күренгән бер кешене дә калдырмас, һәммәсенә сөйләп йөрер. Аны менә бу табынга, түргә утыртырсың.

«Туганым». Ярар, ярар.

Гөлҗиһан. Аннан ары, аның менә бу ягына Гариф хаҗи хатыны Мәликәне утыртырсың. Аларның икесенең бер-берсе белән серләре бик килешә.

«Т у г а н ы м». Һи, алар бер-берсен күрсәләр, бер дә сөйләшеп туя алмыйлар, икесе дә нәкъ тел бистәсе.

Г ө л җ и һ а н. Шулай шул, икесе бергә килсәләр, бөтен шәһәрдәге кешене элеп алалар да селкеп салалар. Шуның өчен бер дә аларның теленә керәсем килми. Алар менә шунда утырырлар.

«Т у г а н ы м». Ярар.

Г ө л җ и һ а н. Гарифә кодагыйның бу ягына Хаммат Әхмәтҗанының хатыны Хәдичә кодачаны утыртырсың. Монысына Гәчтинни Салих хатыны Рәбиганы утыртсаң да ярар. Әптери Хәйрулласының хатыны менә монда, түбән утырыр.

«Т у г а н ы м». Ярар, ярар.

Г ө л җ и һ а н. Әнимай Ибрае, Самавар Кәрим, Кылтын Гарәфи, Чатан Хафиз хатыны шикелле бертөрлерәк кешеләрне теге якка табынга утыртырсың; аларга өстәл булмаса да ярар. Үзләре дә әллә кем түгел әле. Әнимай Ибраеның хатынын бөтенләй чакырмыйм да дигән идем әле, үзенә кардәш тигәнгә күрә, чакырмый калырга яхшысынмадым. Беркөннәрдә кызлар җыены җыйган, шунда, күршедә тора торып, мине утыртып калдырган. Бөтенләй менә җен ачуларым чыкты.

«Т у г а н ы м». Тумачи җиңгине кайда утыртыйм?

Г ө л җ и һ а н. Тумачи җиңгиләр, Апакъ абыстайлар – алар үз кеше. Алар урын булса, теге якка утырырлар, урын булмаса, тагы калып та торырлар. Соңыннан утырырлар. Камилә туганым да теге якка табынга утырыр. И валлаһи, бу асрауларга ышансаң, һичбер эшне юньләп эшләмиләр. Кара инде бу урындыкларны, чат тузан. Өй җыештыруларының һичбер элә-танагы юк. (*Ишекне ачып.*) Хәмди, кая, миңа бер кара сөлгеме, чүпрәкме бир!

«Т у г а н ы м». Фатыйма тудыкъ кайда утырыр?

Г ө л җ и һ а н. Фатыйма тудыкъ? Һә! Борын астыннан китеп торыр әле. Мин аны чакырмадым.

«Т у г а н ы м». Ни эшләп?

Г ө л җ и һ а н. Теле бик озын, шуның өчен.

А с р а у сөлге кертеп бирә.

(*Асраугa.*) Сезнең, ахры, инде бөтенләй күзегез үк чыккандыр. Күзегез чыккан булмаса, менә бу тузаннарны күрер идегез. Бар, эшеңдә бул! Шәрифә остабикәгә ат җибәрсеннәр.

Х ә м д и. Ярый. (*Чыгып китә.*)

Г ө л җ и һ а н (*тузаннарны сөрткәләп, сүзендә дәвам итә.*) Беркөнне Нәгыймә абыстайга дөньяга килмәгән сүзләр сөйләп җибәргән. Мине бөтенләй эреткән дә череткән:

бичара Сиражи бик бәхетсез икән, бәхетле булса, ул бер дә Гөлҗиһанны ала торган егет түгел иде, ди икән. Мине, Сәлимә үлгәч, үзе өфү-төфүләр китереп, яучы җибәреп, Сираҗига ялынып барды, ди икән. Гөлҗиһан ул Сәлимә туганымның кисеп ташлаган тырнагына да торырлык түгел, өфү-төфүләр итеп-итеп, ярап тора инде шунда, дип әйтә, ди. Аллам сакласын, ашым-суымны аңар әрәм итәргә. Гомерем буена, Алла боерса, мин аны бусагамнан да атлатмам!

«Т у г а н ы м». Аның инде бер дә теле-теше тимәгән кешесе юк. Кемне күрсә, шуңа бәйләнә. Шуңа күрә үзе дә кибеп, корып беткән инде. Им-том белән генә тора. Алар былтыр Уша Башына җыенга кайтканнар иде, шунда салып куйган җирендә бөтилеген онытып калдырган. Аны Фәхри абзыйның хатыны алып актарып караган. Эчендә бер дә юк нәрсә юк, ди: төргәк-төргәк чәчләр, җылан мүгезләре, һөдһед тиреләре – һәммәсе дә бар, ди.

Х ә м д и (*ишектән кереп*). Абыстай, Гаян остабикәнең асравы кергән, аларның ашлары бүген микән, иртәгә микән, дип әйтә, ди.

Г ө л җ и һ а н. Син нәрсә дидең?

Х ә м д и. Бүген, дидем. Миңа биргән запискәләрендә иртәгә дип язылган, Гыймади муллаларга биргән запискәләрендә бүген дип язылган, дип әйтә, ди.

Г ө л җ и һ а н. Ул ни дигән эш икән, туганым, әгәр дөрес булса, харап булдык. Әгәр бүтән кешеләргә дә шулай дип язылган булса, хур булдык! Ул нинди эш икән! Мөхәммәтҗан мондамы?

Х ә м д и. Монда. Әле генә өндәүдән йөреп кайтты.

Г ө л җ и һ а н. Бар, әйт, монда керсен.

Асрау чыгып китә.

Үзең карамасаң, һичбер эшнең рәте юк. Кара инде монда, табынга тоз савыты да куймаганнар. Туганым, бар, син генә чыгып, тоз савыты гына алып керсәнә. Алакайган күзләр, шуны да күрмиләр.

«Т у г а н ы м». Ярый. Тоз савытларыгыз кай төштә?

Г ө л җ и һ а н. Шунда асраулардан сорарсың, бирерләр.

«Туганым» чыга башлый.

Ай Алла! Харап булдык! Күзләре чыккан нәрсәләр, бу табынга тишек эскәтер җәйгәннәр. Шулкадәр әйтеп, кулларына тоттырып бирдем, «бу тишек эскәтерне остабикәләр табынына җәясе» дип. Сүзне һич колаклары белән тыңламыйлар. Туганым, зинһар, тиз генә монысын да

алмаштырып җәя күр! И Ходаем, кунаклар килер вакыт җиткән, безнең табыннар да хәзерләнеп җитмәгән. И Раббым! Үтте үзәгемә шул асраулар!

Тәлинкәләрне алып, эскәтерне җыялар. «Туганым» эскәтерне күтәреп чыгып китә.

### ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Г ө л җ и һ а н, М ө х ә м м ә т җ а н, «Т у г а н ы м».

М ө х ә м м ә т җ а н (*ишектән кереп*). Нихәл, абыстай, ни йомыш?

Г ө л җ и һ а н. Бирермен, өшегән авыз, сиңа йомышыңны! Күзең чыккан нәрсә! Ни эшләп Гаян остабикәнең запискәсенә «дүшәмбе көн» дип яздың?

М ө х ә м м ә т җ а н. Юк, абыстай, алай дип язмадым, «якшәмбе» дип яздым. Гаян остабикә ул үзе язу танымый.

Г ө л җ и һ а н. Ялганлама миңа, остабикә кеше ни эшләп язу танымасын.

М ө х ә м м ә т җ а н. Абыстай, валлаһи, танымый менә, билләһи, танымый. Кичә мин запискәне биргәч тә: «Син теге, лимунчы Гыйлаҗиләрдән килдеңмени?» – ди. «Абыстаң исәнме? Кечкенәләре исәнме?» – ди. Мин әйтәм: «Юк, абыстай, безнең бай хатынының баласы юк, аның баласы булмый», – дидем. «Мин лимунчы Гыйлаҗи малае түгел», – дидем.

Г ө л җ и һ а н (*ачуланып*). Нәрсә? Кит моннан, йөзең кара, бар, тиз чык! Мин сине, абзаңа әйтеп, типкәләтеп чыгарырмын.

Мөхәммәтҗан чыгып китә.

Кара син аны?! Көчегенә кадәр: «Абыстайның баласы булмый аның», – дип, очраган бер кеше саен сөйләп йөри бит! Мин телләрегезне бик тиз кыскартырмын. Ул аны зурлары авызыннан ишетеп сөйли торгандыр әле. Мин аларны коры тотармын. Абзаларына әйтеп, һәммәсен дә кибеттән кудырып чыгарттырырмын.

«Т у г а н ы м» (*ишектән кереп*). Туганым! Монда гына чыгып кер әле, харап булдык! Оятлы булдык! Кунаклар килер вакыт җиткән, безнең аш артыннан утыртырга бламажи да хәзерләнмәгән.

Г ө л җ и һ а н. Ә, ни дисең? Ай Алла, туганым! Ул нинди сүз? Харап булдык!

Чыгып китәләр. Зал бераз буш тора.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Хәмди ялгыз.

Х ә м д и (*кулына эскәтер белән тоз савыты күтәреп, көлә-көлә*). И билләһи, кызык соң тегендә. Абыстай тетә тегендә безне тиргәп. Мине тирги, Мәрфуганы тирги, аш пешерүчене тирги. Аш артыннан утыртырга бламажи пешерелмәгән, ди. Аның өчен без гаеплемени? Йөрмәссең түшеңне киереп, калфакларыңны кәкрәйтеп! Үзенең кулыннан бер эш килми, кешене тиргәгән була. Бая тагы: «Безнең абыстайның баласы булмый», – дигән өчен кибетче малайны куып, тиргәп чыгарган. Аның баласы булмаганга безнең нинди гаебебез бар? «Баласы булмый» дип әйтүче кеше без түгел. Абзый үзе беркөннәрдә кибеттә, кантур бүлмәсендә, Сафа абзыйга сөйләп утырган: «Минем хатынның баласы булмый, шуның өчен бер дә мәхәббәтем юк, әгәр эшләрем яхшы барса, Мәскәү кайткач монысын аерып, аның урынына икенче бер, бала китерә торган кыз алам, өйләнәм», – дигән. Закир аны ишек артыннан тыңлап торган да Мөхәммәтҗанга әйткән. Мөхәммәтҗан миңа әйтте: «Безнең абыстай бала китерми икән, абзый аны яратмый икән, аны аерып икенче бер яшь хатын алмакчы була икән», – диде. Ә абыстай монда беркөннәрне, Мәкәрҗә өстендә, абзый өйдә юк вакытта, Нәгыймә әби чүлмәк салырга килгән чакта, абзыйны гаепләп утырды: «Аның баласы булмый», – диде. Аларның берсенә дә ышаныр хәл юк. (*Чыгып китә.*)

## БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гарифә белән Мәликә.

Г а р и ф ә (*Мәликә белән ишектән кереп, түргә утырып*). Син ишеттеңме? Алар анда нәрсә пыш-пыш сөйләшәләр?

М ә л и к ә. Юк, мин ишетмәдем. Мин кергәч, шып туктадылар.

Г а р и ф ә. Мин кергәч тә шулай иттеләр. Әллә нәрсә «бламажи» дигән сүзләрен генә ишетеп калдым. Йә бламажилары оемагандыр әле. Йә җилемен аз салганнардыр.

М ә л и к ә. Бламажилары оемаган дигәннән, исемә төште, беркөннәрне мин чүпче Әхмәтләргә ашка барган идем, үрдәк бөккәннәре бер дә пешмәгән, авызга алгысыз чи иде, бөтенләй лычкылдап тора.

Г а р и ф ә. Андый була ул, әнә беркөнне мин читекче Таҗиларга чәйгә барган идем. Кабарткан паштитлары менә нәкъ такта шикелле булган. Бөтенләй менә үзе такта шикелле, үзе ике куллап сындырып булмаслык каты булган иде.

М ә л и к ә. Читекче Таҗи дигәннән, исемә төште әле, аларның бер шадра кызлары бар иде. Ончы Шакир улына кияүгә биргәннәр иде, ишеткәнең бармы, чибәр торалар микән?

Г а р и ф ә. Белмим, чибәрдер, сорашканым юк, каенанасының сүзен бер дә тыңламый, диләр иде.

М ә л и к ә. Каенанасының сүзен бер дә тыңламый дигәннән, исемә төште әле, син ишетмәдеңме, тегүче Әхмәдулла хатынын аерган дигәннәр иде, чын сүз микән?

Г а р и ф ә. Чын булырга кирәк, беркөнне югары урамга кибеткә чыкканда күргән идем, кулына кәрзинкә күтәреп, бәрәңге алып йөридер иде.

М ә л и к ә. Бәрәңге димәктән, безнең дә кәбестә тозлыйсы бар иде әле, алдырырга һич җитешә алганым юк. Сез тозладыгызмы әле?

Г а р и ф ә. Тозладык, алма белән карбыз да тозладык. Кәбестәләр бик һәйбәт туры килде.

М ә л и к ә. Кавын тозламадыгызмыни?

Г а р и ф ә. Пудвалчы Әхмәтләр кавынны үзебез җибәрттерербез дигәннәр иде дә, ужулары җитмәде. Карбызлар көпшәкләнеп бетәр дип көтмәдек.

М ә л и к ә. Ул пудвалчы Әхмәтнең улы аталарын ташлап чыгып киткән дигәннәр иде, дөрес булды микән?

Г а р и ф ә. Дөрес. Аларның астында фатирда торган ямшекнең бер кызы бар икән. «Шул кызны алам», – дип әйткән, ди. Аталары алырга риза булмагач, ташлап чыгып киткән, ди.

М ә л и к ә. Ул башы белән чыгып кая бара инде ул? Алар инде бөтен нәселләре белән шулай булып чыктылар. Әхмәтнең энесе дә аның җүнле җирдән өйләнмәде. Нигъмәтҗан кучернең кызын ябыштырып чыгарды.

Г а р и ф ә. Хәзер инде кыз ябыштырып чыгару бер җола булып китте. Әле менә шул көннәрдә генә итче Вәлинең кызы тулчукчы Сабир улына ябышып чыккан, ди.

М ә л и к ә. Ай Алла, ул шулаймыни? Миңа тагы аны беркөнне Хәмидә «үзләре алдылар» дип сөйләгән булды.

Г а р и ф ә. Алдылар, алмый ни! Кызлары ябышып чыкмаса, Вәлиләр кызларын үзләре риза булып тулчукчыга бирерләр идеме соң? Вәлиләр алар бай кешеләр бит.

М ә л и к ә. И, бай булсалар да инде, бер дә затлы кешеләр түгел. Хатыны бөтенләй чирмеш әкәе төсле нәрсә.

Г а р и ф ә. Чирмеш әкәе дигәннән, шуны әйтим әле, теге бүрекче Гобәйдулладан калган Мәфтуха үзләрендә торган Хәйретдингә кече хатынлыкка бара, ди.

М ә л и к ә. Чынлапмы? И адәм көлкесе, адәм көлкесе! Мөгаен, аларның араларында элек тә берәр эш булгандыр. Юк исә аның хатынын, балаларын кан-яшь җылатып барып йөрмәс иде.

Г а р и ф ә. Йөрмәс дип, Әхмәтҗан бай хатыны карт башы белән үзләрендә торган яшь-яшь егеткә бармадымыни?

М ә л и к ә. Барса да инде, аның эше икенче, аның акчасы да күп, аннан соң ул Әхмәтҗан байны яратып та тормады.

Г а р и ф ә. Ә соң Фазлый хатыны?

М ә л и к ә. Шәмсенисаны әйтәсеңме?

Г а р и ф ә. Әйе.

М ә л и к ә. Ә, ул чибәр, бик матур бит! Аның әле бер дә яшь кызлардан аермасы юк. Аннан соң бит ул хатын өстеннән дә бармады.

Г а р и ф ә. Бармаса да инде, мыек чыкмаган яшь-яшь егеткә баруы оят.

М ә л и к ә. Оят димәктән, кара әле, син ишеттеңме, теге Галләм, кызын марҗага җибәреп, кул эше өйрәттергән була, ди. Ничек кешедән оялмый икән?

Г а р и ф ә. Алар марҗадан гына өйрәттерәләр әле, ул хатын кеше. Әле менә Миңнебай Фатихы өйләренә бер шәкерт китертә, ди. Кызын шул шәкерт көн саен килеп укытып йөри, ди. Фатих үзе, сакалын салпайтып, шуның укытканын карап утыра, ди. «Остабикәләр бик надан, бер дә укыта белмиләр», – дип әйтә, ди. Алладан курыкмасалар да, бераз бәндәдән оялырга кирәк иде.

## АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Җ а м а л и, Г ө л җ и һ а н, К а м а л и.

М ө х ә м м ә т җ а н (*ишектән сулу кабып йөгереп кереп*). Абыстай! Абыстай! Әй, монда юк икән. Җамали абзый кереп килә: «Бик кирәкле йомышым бар, хатын-кызлар бер читкә китеп торсыннар», – ди.

Г а р и ф ә. Һи, мәхәббәтсез, тапкан икән йомыш йомышларга вакыт!

Чыгып китәләр.

Җ а м а л и (*ишектән кереп, әрле-бирле йөгергәләп, ишекләр саен барып*). Килен! Килен!

Г ө л җ и һ а н (*ишектән кереп*). Нәрсә, абзый, ни бар?

Җ а м а л и (*сулуы кабып*). Килен!.. Мин... мин... Сезгә... Уф!..

Г ө л җ и һ а н (*каушап*). Нәрсә бар? Нәрсә?

Җ а м а л и. Сираҗетдин... Сираҗетдинны... Талаганнар!

Г ө л җ и һ а н (*урындыкка егылып*). Аһ! Харап булдык! Читек балтыры!

Җ а м а л и. Әйе, әйе, читек балтыры... Менә тилиграм... Сираҗетдинның читек балтырыннан акчасын алганнар!

Г ө л җ и һ а н. Аһ!.. Кырык тугыз мең!

Җ а м а л и. Ни дисең? Кырык тугыз мең? Кырык тугыз мең дисеңме?

Г ө л җ и һ а н (*авыр сулап*). Әйе... Кырык... тугыз... мең!

Җ а м а л и. Читек балтырында кырык тугыз меңме?

Г ө л җ и һ а н. Әйе!

Җ а м а л и. Булмас!

Г ө л җ и һ а н. Үзем, үзем күрдем.

Җ а м а л и. Алай булса, харап булдык! Малайның башы бетте! Читек балтырында кырык тугыз мең диген, ә! Әйтеп адәм ышанмаслык сүз! Ах, җүләр, җүләр! Читек балтырында кырык тугыз мең! (*Урындыкка утыра, бераз аптырап тора.*)

Г ө л җ и һ а н. Үзем күрдем, бишәр йөзлек иде.

Җ а м а л и. Ах, җүләр, җүләр, соң, читек балтырында кырык тугыз мең тәңкә акча йөртергә ярыймы?! Ах, җүләр, җүләр, шыр тиле икән!

К а м а л и (*ишектән кереп*). Абый, абый!

Җ а м а л и. Ах, җүләр, җүләр! Читек балтырында кырык тугыз мең!

К а м а л и. Нәрсә дисең?

Җ а м а л и. Кырык тугыз мең!

Г ө л җ и һ а н. Ах! Читек балтыры!

К а м а л и. Нинди читек балтыры? Нинди кырык тугыз мең?

Җ а м а л и. Сираҗиның читек балтыры!.. Сираҗиның кырык тугыз мең сумы!..

К а м а л и. Читек балтыры ни эшләгән?

Җ а м а л и. Талаганнар.

К а м а л и. Читек балтырынмы?

Җ а м а л и. Кырык тугыз мең сумын!

К а м а л и. Ни дисең?

Җ а м а л и. Менә тилиграм...

К а м а л и. Мин укый белмим.

Җамали. Мин дә белмим, Вәли укыды.

Камали. Нәрсә ди, ни эшләгән ди?

Җамали. Ни эшләсен, Сираҗиның читек балтырыннан кырык тугыз мең сум акчасын талап алганнар, ди.

Камали. Кайда?

Җамали. Пуезда.

Камали. Ә үзе?

Җамали. Үзе... үзе... килен, акылдан шашкан, ди!

Гөлҗиһан. Аһ!

Камали. Ә?

Җамали. Акылдан шашкан, ди. Бүлнискә җибәргәннәр, ди.

Гөлҗиһан. Аһ!

Камали. Соң, соң, ни эшлимез?

Гөлҗиһан. Аһ!

Җамали. Белмим!

Камали. Үзе кайда ди?

Җамали. Бүлнистә, ди.

Камали. Анысын беләм. Үзе кайда ди, кайсы шәһәрдә ди?

Җамали. Анысын белмим, менә монда язган, мә, кара.

Камали. Мин дә белмим. Анысын да Вәли белер.

Җамали. Ие, ул белер шул.

Камали. Алай булгач, аны аннан алып кайтырга кирәк.

Җамали. Ие шул.

Камали. Бүген үк китәргә кирәк.

Җамали. Бүген үк.

Камали. Ие, бүген үк. Бүген, пуез белән. Әйдә, тизрәк китик. Тилиграмны Вәлигә укытыйк та, бүген үк китик.

Җамали. Шулай дисеңме, бүген үк дисеңме? Башым әйләнә, бернәрсә дә белмим. Ах, җүләр, җүләр! Читек балтырында кырык тугыз мең сум! Әйтергә генә ансат, кырык тугыз мең сум!

Камали. Әйдә, абый, әйдә, кичекмик, китик. (*Җамалины җитәкли.*)

Җамали. Шулай дисеңме? Минем башым бер дә йөрми.

Камали. Шулай дим. Әйдә, китик. Килен, хуш, сау бул. Без Сираҗины алып кайтабыз.

Чыгалар.

Гөлҗиһан. Хуш!

### ҖИДЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан, «Туганым», Хәмди, Нәгыймә, Гарифә һәм Мәликә.

Гөлҗиһан. Аһ, харап булдык! Читек балтыры! Кырык тугыз мең сум! Туганым! Туганым! Ни эшлик? Кырык тугыз мең сум! Бөлдек, беттек! Инде ни эшлим? Мәҗлес! Бламажи! Кунаклар! Хәмди! Мәрфуга! Гайниҗамал! Мөхәммәтҗан! Барыгыз, бар!

«Туганым», Хәмди, Нәгыймә, Гарифә һәм Мәликә керәләр.

Һәммәсе бердән. Нихәл, ни булды? Нәрсә бар?

Гөлҗиһан. Барыгыз, бар! Йөгерегез! Кунакларга әйтегез! Килмәсеннәр. Мәҗлес бетте! Бөлдек, харап булдык! Һай, читек балтыры! Һай, кырык тугыз мең сум! Барыгыз, бар! Бламажи да кирәк түгел, бернәрсә дә кирәк түгел, мәҗлес тә юк! Ах, харап булдык, Сираҗиның читек балтырыннан кырык тугыз мең сум акчасын урлаганнар. Ух! Үләм! Бетәм!

Егыла, Нәгыймәдән башкасы Гөлҗиһан янына җыелалар.

Нәгыймә (*бер читкә тайпылып*). Ай Алла, харап булдым! Бәхетсезлек! Дүрт-биш тәңкә чиертә дип торганда гына, харап булдым! Ичмаса ясаган тамыр әрәмгә китмәсен, кемгә булса да икенче бер кешегә бирермен. (*Диван артыннан чирекле шешәне алып, шәле астына кыстырып, аяк очлары белән генә басып, артына борылып карый-карый чыгып китә.*)

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук зал. Залда күп үзгәреш юк. Өстәлләр җыелган.

### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Җамали, Камали, Сираҗетдин һәм Гөлҗиһан. Җамали белән Камали Сираҗетдинны җитәкләп килеп керәләр.

Җамали. Килен, килен!.. Әйдә, Камали, булыш әле, менә шунда гына утыртыйк!

Сираҗетдинны бер эскәмиягә утырталар. Сираҗетдин, дивана кеше төсле, тирә-ягына ялт-йолт карап утыра. Ишектән Гөлҗиһан килеп керә.

Җ а м а л и. Килен, мин сезгә ничә мәртәбә әйттем, Сираҗетдинны яхшы саклагыз, өйдән чыгып китмәсен, дип. Ул бит үзен бер дә белешми. Әле менә хәзер, трамвай дип белеп, утын төягән вагуннар өстенә менеп утырган да киткән. Хәмидуллалар җитәкләп китерделәр. Ул бит бернәрсә дә белми.

Г ө л җ и һ а н. Абзый, мин ни эшләтим соң инде аны, аны бит бер дә җиңеп булмый. Бәреп җибәрә дә чыга да китә.

С и р а җ е т д и н (*урынынан сикереп тора да почмакта, өстәл өстендә тора торган граммофон янына барып бора башлый. Бер колагына кулын куеп*). Палисә, палисиски! Палисиски!

Җ а м а л и, К а м а л и (*урыннарыннан сикереп торып, Сираҗетдинның ике кулыннан тотып*). Чү, чү, ни эшлисең?

С и р а җ е т д и н. Палисиски! Каравыл! Талыйлар!

Җ а м а л и. Һай, бичара!

К а м а л и. Чү, энем, чү, монда бер кеше дә юк, бер кеше дә!

С и р а җ е т д и н (*читек балтырларын тотып карап*). Таладылар! Таладылар! (*Ике кулы белән чигәләрен тотып, икенче якка таба китә. Аннан тагы җәһәтләп китеп, ишектән чыга башлый.*)

Җ а м а л и, К а м а л и (*Сираҗетдинны барып тотып*). Чү, Сираҗетдин, чү, бернәрсә дә юк, бернәрсә дә! Кил, урыныңа утыр! (*Урындыкка утырталар.*)

Җ а м а л и. Менә, агай, эш! Моны ни эшләтергә инде?

К а м а л и. Сумашушныйга менгерсәк ничек булыр икән? Ул монда киленнәрне дә борчып бетерер. Төнлә белән ялангач көенчә чыгып китеп, белешмичә, әллә кайларга китеп, суга барып төшүе ихтимал.

С и р а җ е т д и н (*халыкка таба карап, үзалдына*). Төшәр, төшәр, суга төшәргә мин җүләрмени? Болар инде мине чын-чыннан җүләр дип беләләр.

Г ө л җ и һ а н. Абзый, шул, мин дә шунсыннан куркам. Бөтенләй төн йокыларым качып бетте инде. Аз гына бернәрсә кыштырдый башлады исә, ул чыгып китә торгандыр дип котым оча.

Җ а м а л и. Менә инде Мәскәү давиринныйлары гына килеп килешеп китсеннәр, аннан соң сумашушныйга менгерсәк менгерербез.

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Тотарсыз капчыгыгызны! Алар килеп киткәч, ничек йөрергә икәнлеген мин үзем дә бик яхшы белермен.

К а м а л и. Алар соң әле ни диләр?

Җ а м а л и. Бернәрсә дә әйтмиләр, кибеттәге кенәгәләрне карадылар. «Сезнең бу кенәгәләрегезне чурт үзе килсә дә аңлый алмас», – диләр.

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Аны шул алар төшенсен дип язмыйлар.

К а м а л и. Соң син нәрсә дидең?

Җ а м а л и. Нәрсә дип әйтим, мин дә шул бернәрсә дә аңлый алмыйм, үзе булса, бик яхшы аңлар иде дә бит, хәзер исән түгел, гакылдан шашкан, дидем.

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Шашкан гакылдан, шашмый ни! Мин сезнең үзегезне гакылдан шаштырырмын әле.

К а м а л и. Соң тагы нәрсә диделәр?

Җ а м а л и. Бүген без аны барып карыйк әле, үзебез белән бер доктор да алып барырбыз, ул аның гакылдан шашканмы, юкмы икәнлеген карар, диделәр.

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Ә менә монысы гына бераз күңелгә ятып бетмәде. Әгәр ул минем җүләр түгел икәнлекне белсә, эш харап. Тукта әле. Алар килгәнче, җүләрлекне ныклап күрсәтергә өйрәнә торырга кирәк. (*Аякларын бөкләп, өстәл өстенә менеп утыра.*)

К а м а л и. Чү, чү, Сираҗетдин, ни эшлисең?

Җ а м а л и. Тимә, тимә, утырсын. Тик утырсын.

К а м а л и. Ярый алайса. Хуш, тагы нәрсәләр дип әйтәләр дидең, докторга күрсәтербез, дип әйтәләр дисеңме?

Җ а м а л и. Әйе, докторга күрсәтербез, ди. Әгәр дә доктор авыру дип әйтсә, бераз скитке ясап булса да килешербез, диләр. Кибеттәге малларны да бер кат карап чыктылар. Малы бик аз калган икән, диләр.

К а м а л и. Соң син нәрсә дидең?

Җ а м а л и. Нәрсә дип әйтим, бары шунда инде, дидем. Менә бит сезгә бирергә дип малны акчага алмаштырып бетергән иде дә, хәзер инде акчасыз да, малсыз да калган, дидем.

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Бер дә хафаланмагыз, акча ерак түгел, кладавайда гына. Ачкычы менә монда, кесәдә генә.

Г ө л җ и һ а н. Соң инде, абзый, без шулай бер тиенсез бөлеп калырбыз микәнни? И Ходаем! Бар икән күрәселәребез! (*Җылый.*)

К а м а л и. Хафаланма, килен, хафаланма, Алла язмаган эш булмас, Сираҗетдинның болай булуы безнең өчен дә бер дә күңелле түгел.

Г ө л җ и һ а н. И Ходаем, күңелле генә итеп аш уздырам дип йөргәндә генә, бөтен эшләр чуалды да китте.

К а м а л и. Килен, анысы бик зур эш түгел, Сираҗетдин терелсә, бар да булыр әле.

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Эшне бетергәч, ничек фарсит итәргә кирәклеген Сираҗетдинның үзе дә бик яхшы белер әле. (*Өстәл өстеннән сикереп төшеп, кулына лампа алып, ишеккә таба бара башлап.*) Ахмак нәрсәләр, йөзе каралар, кладавай ишеген ачык калдырганнар.

К а м а л и. Чү, зинһар, чү, һәммәсен бикләгәннәр!

Сираҗетдин һаман чыгарга маташа.

Җ а м а л и. И бичара, бөтенләй коты очып, куркып беткән.

Камали белән Җамали Сираҗетдинның кулыннан тотып чыгармаска тырышалар.

С и р а җ е т д и н. Талыйлар, талыйлар! Тотыгыз!

Җ а м а л и (*һаман да кулыннан җибәрмичә*). Юк, Сираҗетдин, юк! Бернәрсә дә юк!

С и р а җ е т д и н. Талыйлар! Әнә йозагын ваталар! (*Ишектән чыгып китә.*)

Аның белән бергә Җамали белән Камали да чыгып китәләр.

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Г ө л җ и һ а н ялгыз.

Г ө л җ и һ а н. И Раббым, и Раббым, тәмам харап булдык! Эштән чыктык! Фатыйма тудыкъ инде миннән авызын җырып көләр. Нинди генә матур иттереп аш уздырам дип торганда гына харап булдык. Әле менә кибетне дә пичәтләгәннәр, ди. Урам кибетеннән акча сорыйлар. Акча чыгармасагыз, бер тиенлек тә әйбер бирмибез, дип әйтәләр, ди. Итче дә бүген ит бирмичә керткән. Аласыз да аласыз, акча бирүне белмисез, сез җүләрне туйдырырга мин ялланып керешмәгән, дип әйтә, ди. Асрауларның да берсенә дә бер сүз әйтер хәл юк, хәзер үзеңнән битәр биш өлеш артык итеп кычкырырга торалар. Кичәгенәк Гайниҗамал: «Торасың да кычкырасың, торасың да кычкырасың, мин җүләр кешенең хатыны түгел, мин кычкырмасаң да аңлыйм. Кычкырырга беләсез, ә өскә-башка ясарга белмисез, менә алъяпкычларым тузып беткән, кычкырганчы бер алъяпкычлык алып бир», – ди. Хәзер инде күчерләренә кадәр мыскыл итә башладылар. Кичә тудыкъларга барырга ат җигәргә кушкан идем: «Әллә, абыстай, син дә инде акылга җиңеләя башладыңмы? Чыгасыз

да утырасыз, бер эшсезгә чабасыз, ул атларның аяклары тимер түгел бит көне буена чабып йөрергә», – ди. Белмим инде мин, ни эшләргә дә аптырадым. Сираҗины җүләр дип әйтер идем, кеше юк чагында үзалдына әллә нәрсәләр хисаплый, әллә нәрсәләрне шутка сала. Мин килә башладым исә, «таларга киләсең» дип кычкырынырга тотына. И Аллам, харап булдык шул, харап булдык. Бламажи пешерелми онытылып калган дигәч тә, әллә нәрсәгә эчләрем жу итеп киткән иде. Күрәчәгебезгә каршы булган икән шул.

Ишектән Нәгыймә карчык килеп керә.

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан, Нәгыймә.

Гөлҗиһан. Әйдә, хуш киләсең, Нәгыймә абыстай, килүең-китүең юк.

Нәгыймә. Исәнме, кызым Гөлҗиһан, исәнме! Кешенең борчулы вакытында һаман-һаман килеп кешене борчып йөреп булмый шул. Нихәл әле, кызым, ниләр эшләп торасыз? Исән-сау гына торасыңмы? Хафалана торгансыңдыр, ахры, ябыгып киткәнсең.

Гөлҗиһан. И Нәгыймә абыстай! Ничек итеп хафаланмаска кирәк? Инде Мәскәү бүләкләре кайта дип көтеп торганда гына, ирең шулай җүләрләнеп кайткач, ничек итеп хафаланмассың! Ичмасам акчасын алдырмый гына кайткан булса, тагын да бер хәл иде. Әле ярый көн күреп торырга сумабыз бар дип торыр идең. Әле әнә мәскәүләр килеп кибетне дә пичәтләгәннәр, ди. «Сираҗины докторга күрсәтәбез. Әгәр чын-чыннан җүләр булса, аз белән дә килешермез», – дип әйтәләр, ди. Ул инде соң, җүләр булмаса, урамда утын төягән вагуннарга утырып йөрер идеме?

Нәгыймә. Әйе шул, әйе шул, кызым, бер дә акыллы кешенең эше түгел инде. Әле менә беркөн, теге, беләсең ич Хәмди Мәфтухасын, шуның Әсма атлы бер кызы бар. Шул кыз урамнан узып бара икән. Сираҗетдин шуның каршысына барган да: «Син кем кызы, бик матур кыз икәнсең, мин сине үземә кече хатынлыкка алам», – дип юлыннан туктаткан. Ул аны анасына кайтып сөйләгән. Анасы тагын, җүләр нәрсә, шул сүзгә ышана калган:

---

Шутка (счетка) салу – исәпләү.

«Бай кеше бит, сораса, ни эшләп бирмәскә, бирәм, һәйбәт, яхшы атларга утырып рәхәтләнеп йөрер», – ди. Мин әйтәм: «И җүләр, җүләр, шул сүзгә ышандыңмы? Ул бит хәзер акылдан шашкан, белешеп әйтми ул, аның хатыны Гөлҗиһан синең Әсмаңнан мең өлеш артык, синең йөз Әсмаңны бәреп егар», – дим.

Гөлҗиһан. Кайсы Хәмди Мәфтухасы инде ул?

Нәгыймә. Ай Алла, син Хәмди Мәфтухасын белмәскә, менә тагы, алар бит синең этиләрең күршесендә, Чүпрә Йосыф йортында, түбән өйдә фатир торганнар иде.

Гөлҗиһан. Ай, әҗәткана, шулмыни? Сираҗины башларына чәйнәп яксыннар, җүләр белән тормасам, миңа ир бетмәгән! Ачуымны китерсәләр, иртәгә үк аерылып китәрмен. Тәмам туеп беттем инде. Беркөнне карап утырды-утырды да: «Әйдә, гармун алып уйнап җибәр әле», – ди. Мин тагы, җүләр, аның сүзенә ышанып, чынлап әйтә дип белеп, уйнарга гына тотынган идем: «Әйдәле, җырлап та җибәр», – ди. Мин җырламагач, тотынды биергә, тотынды биергә, мин, куркып, гармунны ташладым, ул һаман бии дә бии. Тәмам арып, башлары-күзләре әйләнеп бетте. Чәнчелеп китсен Сираҗилары, башларына чәйнәп яксыннар! Шул җүләргә бирмәсәләр, кызларына урын таба алмаганнар икән.

Нәгыймә. Мин шуны әйтәм: «Юкка җүләрләнеп, үзегездән кеше көлдереп, алай итеп йөри күрмәгез», – дим.

Гөлҗиһан. Бирсеннәр, минем бер сүзем дә юк. Гомеремдә мин аннан нинди рәхәт күрдем?

Нәгыймә. Анысы шулайдыр да инде, шулай да булса, иргә бер баргач, шунда торган яхшы. Әле соң ни эшләп торасыз? Бераз өшкертеп-төкертеп караганыгыз юкмы? Бәлки, Алла кушса, сәламәтләнеп тә китәр иде. Әле менә сезгә шуны әйтим дип килгән идем. Нурый хаҗиларга читтән бер ишан килгән, ди. Сулышы бик шифалы, өшкерткән кеше бер дә сәламәтләнми калмый, ди. Әле менә әллә кемнең хатыны шуңа өшкерткән генә икән, бик зур файда күргән, ди.

Гөлҗиһан. Мин бер дә хәзер ни эшләргә дә белмим инде. Әле менә бүген мәскәүләр белән килешмәкче булып йөриләр. Шулар белән килешеп, эшләр уңайга китсә, тагы ни булса да, ул булыр иде.

Ишектән Җамали, Камали, Сираҗетдин, Закир һәм Мөхәммәтҗан килеп керәләр. Сираҗетдинны урындыкка утырталар.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан, Нәгыймә, Җамали, Камали, Сираҗетдин, Закир һәм Мөхәммәтҗан.

Җамали. Закир, Мөхәммәтҗан, сез шунда Сираҗетдинны яхшы гына каравыллап утырыгыз, бер җиргә дә чыгып китмәсен. Килен, сез дә бераз күз-колак булыгыз. Әйдә, Камали, без кибеткә төшик. Анда теге давиринныйлар безне көтеп тора торганнардыр. Аларны монда алып килербез. Гарәфигә дә әйттерергә кирәк, ул да килсен, ул аның юлда ничек таланганын күргән кеше, бәлки, файдасы тияр.

Чыгып китәләр.

Гөлҗиһан (*урындыкта башын артка таба салып, йоклаган төсле утырган Сираҗетдинны күрсәтеп*). Әнә инде, Нәгыймә абыстай, аның хәле шул инде. Йә ул шулай башын артка сала да изелеп йоклый, йә тора да пыр тузып өй эчендә йөгергәләп йөри, йә булмаса өстәл өстенә менеп утыра да әллә ниләр мыгырдап укырга тотына. Менә инде көне буе шуны саклап утыр, әгәр гомер буена шул җүләрлегендә булса, аның белән ничек торырсың?

Сираҗетдин (*үзалдына*). Тормассың, тормассың бер дә. Тизрәк эшем генә бетсен, мин аннан ары сине типкәләп ишегемнән чыгарып җибәрермен.

Нәгыймә. Шулайдыр шул, Гөлҗиһан, шулайдыр. Бу килешкә булганда, хәлең бик яхшы түгел; ичмасам, байлыгы бар вакытта шулай булган булса бер хәл иде. Байлыгы бар дип чыдап торыр идең; син яшь кеше, балаң-чагаң юк, бер дә хафаланмас идең. Әле менә теге җүләр Йосыф хатыны акча белән калды да нинди чибәр яшь кешегә барды.

Сираҗетдин (*үзалдына*). Күрәсезме, карчык нинди яхшы киңәшләр бирә! Калдырдылар ди сезгә акча, капчыгыгызны тотмыйсызмы?!

Закир (*үзалдына*). Итәрсең аны җүләр, үз файдасына килгәндә ул бер дә җүләр түгел! Беркөнне миңа алмаштырырга дип егерме биш тәңкәлек акча биргән иде, шул вакытта мин, бераз батырып калыйм әле дип, бер өчлекне кесәгә яшергән идем, хәзер сизде. «Кая акча? Талыйлар!» – дип, каравыл кычкыра башлады.

Мөхәммәтҗан (*үзалдына*). Акчасы булгач, баргандыр шул, акчасы булса, абыстайны алудан мин дә качмас идем. Мин дә бит бик чибәр егет. (*Мыекларын боргалап төзәтенеп куя.*) Абыстай карт кеше түгел, акчасы бул-

гач, аның белән торырга мөмкин. Матур булмаса да, акчасы булгач, ярап торыр иде.

Гөлҗиһан. Нәгыймә абыстай, зинһар, акрынрак сөйли күр. Йә үзе ишетер, тегендә тегеләр дә тыңлап торалар, үзе ул, дивана булса да, сөйләгән сүзне бик тиз ишетә. Әйдә, без теге якка чыгып, бераз сөйләшеп утырыйк. (*Закир белән Мөхәммәтҗанга карап.*) Сез монда абзагызны саклап утырыгыз.

Закир (*Мөхәммәтҗан янына барып утырып*). Ни хәл, Мөхәммәтҗан? Кичә бит минем ай тулды. Беләсеңме, миңа акча кирәк. Жалунияне аласы иде. Бу җүләрне көтеп торсаң, монда жалуния алганчы сакалың агарыр.

Мөхәммәтҗан. Минем үземнең дә жалуния алганым юк. Кичә Җамали абзыйдан сораган идем, сезнең ябык кибетегез өчен мин нишләп сезгә жалуния түләп торыйм, абзагыздан сорагыз, ди.

Закир. Ә соң мин кайдан алыйм?

Мөхәммәтҗан. Белмим.

Закир. Җамали абзыйдан сорыйм да, әгәр ул бирмәсә, ташлыйм да чыгып китәм.

Мөхәммәтҗан. Теләсәң ни эшлә, мин сине тотып тора алмыйм.

Тик утыралар.

Сираҗетдин (*үзалдына*). Тимә әле, минем бу җүләр булып кыйлануның бик күп файдасы булды, мине җүләр дип фараз кылып, һәммәсе дә үзләренең серләрен яшермичә сөйлиләр. Хатынның да, кибетчеләрнең дә, күчерләрнең дә – һәммәсенең серләре мәгълүм булды. Тизрәк эшләрем генә бетсен, аннан ары мин сезнең барыгызны да ничек итеп өреп чыгарырга белермен. Инде теге мәскәүләр тиз килеп җитәрләр. Алар күзенә җүләррәк булып күренү өчен алданрак юллар эзләп куярга кирәк. Әгәр доктор чын-чыннан да җүләр дип шаһитлык бирсә, эшне озакка сузмаслар, тиз килешерләр. Аны ничек тә булса кулга алырга кирәк, докторлары нинди кеше икән? Аңа бер биш йөзлекне сузмый туры килмәс. Эшнең башы шунда. Аннан гына эшне бозарга ярамый. Әгәр биш йөздән дә ким бирсәң, бәлки, ул риза булмас. Абыйлар бик йомшак маташмасалар ярар иде. Сумына ун тиеннән артык бер дә бирергә ярамый. Кибеттә малы бик аз икән, дип әйтәләр, ди. Аз булмый, анда икенче кеше исемендәге вывиска астындагы кибеткә мал төямичә, пила чүбе тутырмаган. Алар барысы да мал.

Ишектән Мәскәү доверенныйлары керә башлыйлар.

Уф! Килеп тә җиттеләр. Ничек тә булса серне сиздермәскә кирәк.

Җамали. Әйдә, Васили Димитрич, әйдә, пожалысты, пожалысты.

Доверенныйлардан дүрт кеше, доктор, Җамали, Камали һәм Гарәфи килеп керәләр.

## БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әүвәлгеләр, дүрт доверенный, доктор, Җамали, Камали, Гарәфи һәм Сираҗетдин.

Җамали (*доверенныйларга*). Пажалти, пажалти, менә моннан утырыгыз. (*Урын күрсәтә.*)

Василий Дмитриевич. Тукта әле, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, әүвәле Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович белән күрешергә кирәк. (*Сираҗетдин янына килә.*) Здраствуйте, Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович!

Сираҗетдин (*алдына гына карап утырган урыныннан сискәнеп сикереп торып*). Каравыл! Талыйлар! (*Ишеккә таба бара башлый.*)

Закир.<br>Мөхәммәтҗан. } Тукта, абзый, тукта! (*Урынына китереп утырталар.*)

Василий Дмитриевич (*куркып, артка чигенеп утырып*). Кызганыч, бичара, куркыныч.

Икенче доверенный. Бөтенләй төсләре дә үзгәргән.

Сираҗетдин (*үзалдына*). Үзгәрерсең, уен түгел ул, кырык тугыз мең тәңкә диләр аны!

Җамали. Бар, Мөхәммәтҗан, әйт әле, чәй китерсеннәр.

Бер доверенный. Юк, юк, кирәк түгел. Без эшебезне генә эшлик тә китәрбез.

Сираҗетдин (*үзалдына*). Шаулама, бу беренчесе яхшы чыкты әле, малайларыңның куркудан котлары чыкты. (*Сикереп өстәл өстенә менеп утыра.*)

Бер доверенный. Карагыз әле, тагы әллә ни эшли.

Камали. Юк, зарар юк, ул һаман шулай.

Доверенный. Ах, бичара!

Сираҗетдин (*үзалдына*). Күрсәтермен әле мин сезгә бичараларыгызны!

Василий Дмитриевич. Ну, менә без хәзер барыбыз да җыелган чак. Сез тагын бер сөйләгез әле, вакыйга ничек-ничек булган?

Сираҗетдин (*үзалдына*). Беләләр алар вакыйганы! Аны сез миннән сорасагыз, мин әйтер идем ничек булга-

нын. (*Урыныннан сикереп торып, ишеккә таба бара башлый. Утырган кешеләргә күзләрен зурайтып ачып карый.*)

Закир белән Мөхәммәтҗан барып тотып, яңадан урынына китереп утырталар.

Бер доверенный. Нишләп ул һаман тынычсызлана?

Камали. Юк, зарар юк, ул һаман шулай.

Василий Дмитриевич. Ну, ярый, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, сез сөйләгез әле, эш ничек булган?

Сираҗетдин (*үзалдына*). Берничек тә булмаган.

Җамали. Менә ничек булган. Ул безгә сөйләнеп йөргән иде: «Мин фәләнчә көн Мәскәүгә барам», – дип. Мин аңа әйттем: «Тукта, бераз сабыр ит, бергә барырбыз», – дип. Ул әйтте: «Юк, мин хәзер барам, кибеттә мал бик аз калды. Күп нәрсәләрнең төрләре беткән», – дип. Шуннан соң мин дә бер сүз әйтмәдем, ул да китеп барды. Ул акчасын үз янында алып киткән икән, минем аннан да хәбәрем булмады.

Сираҗетдин (*үзалдына*). Китәр, китәр, үз янында алып китәр! Үз янымда алып китәргә мин дурак түгел!

Җамали. Хәтта мин аның күпме акча алып киткәнен дә белмәдем. Соңыннан, «Сираҗетдин таланды» дип, менә Гарәфидән тилиграм килгәч, киленнән ишеттем, «кырык тугыз мең» диде.

Сираҗетдин (*үзалдына*). Бик дөрес, шулай, кырык тугыз мең.

Василий Дмитриевич. Киленегез аны кайдан белгән? Үзе әйткәнме?

Җамали. Юк, үзе әйтмәгән. Ул чыгар алдыннан аягын чишенеп, кәгазь акчаларны балтырына чорнап, аягын киенгән.

Сираҗетдин (*үзалдына*). Анысы дөрес, кәгазьләрне балтырына чорнап киенгән.

Василий Дмитриевич. Киленегез мондамы? Аннан да сорап карасак, ничек булыр?

Камали. Юк, ярамый, хатын кешегә ирләргә күренергә шәригать ни вилит!

Җамали. Сорасыннар, сорасыннар, безгә кеше хакы бер тиен дә кирәкми, сорасыннар.

Сираҗетдин (*үзалдына*). Дөрес, дөрес, бер тиеннәре дә кирәкми!

Җамали. Бар әле, Мөхәммәтҗан, абыстаңны монда чакыр, хәзер генә чыгып керсен әле.

Гөлҗиһан керә.

### АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Б а ш к а л а р һәм Г ө л җ и һ а н.

Җ а м а л и (*Гөлҗиһанга*). Менә, килен, болар Мәскәүдән килгән давиринныйлар, синнән сорамакчы булалар.

Г ө л җ и һ а н. Нәрсәне?

К а м а л и. Сиражетдинның акчасын.

Г ө л җ и һ а н. Нинди акчасын?

Җ а м а л и. Югалткан акчасын.

Г ө л җ и һ а н. Аны ничек миннән сорыйлар, мин аны кайдан алып бирим?

В а с и л и й Д м и т р и е в и ч. Туктагыз әле сез, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, сез сорый белмисез. Менә нәрсә, абыстай: сез Сиражетдин Гыйлаҗетдиновичның үзе белән акча алып киткәнен белдегезме?

Г ө л җ и һ а н. Белдем.

В а с и л и й Д м и т р и е в и ч. Ул аны кайсы кесәсенә салып алып китте?

Г ө л җ и һ а н. Бер кесәсенә дә салмады. Иң әүвәл менә шушы төшкә утырды да аякларын чишенде. Аннан соң кырык тугыз мең тәңкә акчасын дүрткә бүлде дә аякларының як-якларына, балтырларына куйды да киенде.

В а с и л и й Д м и т р и е в и ч. Сез ул акчаларның нинди икәнлекләрен күрдегезме?

Г ө л җ и һ а н. Күрдем.

В а с и л и й Д м и т р и е в и ч. Нинди акчалар иде?

Г ө л җ и һ а н. Бишәр йөзлек.

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Күрдең, пычак, ул вакытта инде ул акчалар күптән кладавайда яталар иде.

В а с и л и й Д м и т р и е в и ч. Ул акчаларны ул кайдан алып чолгады?

Г ө л җ и һ а н. Сумкадан алып чорнады. Банкыдан алып кайтты да аягын чишенеп чорнады.

В а с и л и й Д м и т р и е в и ч. Аягын киенгәч, өйдә озак тордымы?

Г ө л җ и һ а н. Юк, озак тормады. Аягын киенде дә, атка утырып, вакзалга төшеп китте.

В а с и л и й Д м и т р и е в и ч (*башка доверенныйларга карап*). Әфәнделәр, сез дә берәр нәрсә сорап карамыйсызмы?

Д о в е р е н н ы й л а р. Юк.

В а с и л и й Д м и т р и е в и ч. Ярый, абыстай, рәхмәт. Башка сорый торган сүз юк.

Гөлҗиһан чыгып китә.

## ҖИДЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһаннан башкалар.

Василий Дмитриевич (*башка доверенныйларны бер читкә тартып*). Ну, әфәнделәр, сез ни дисез? Минемчә, боларның әйткән сүзләре дөрес шикелле күренә. Банкның кассиры да һәммәсе бишәр йөз тәңкәлек акчалар бирдем дигән иде.

Бер доверенный. Минемчә дә дөрес.

Икенче доверенный. Мин дә бер дә шикләнергә урын күрмим. (*Һәммәсе дә килеп утыралар.*)

Василий Дмитриевич. Ну, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, сүзегезне сөйләп бетерегез, аннан соң ни булган?

Җамали. Аннан соң ни булганын мин бик яхшы белмим. Менә бу Гарәфи аның белән бер пуезда барган кеше, эшне ул бик яхшы белә. Безгә тилиграмны да ул бирде.

Василий Дмитриевич. Алай икән, бик яхшы. Алай булса, сез, Гарәфи әфәнде, эшнең ничек булганын безгә сөйләп бирегез әле...

Гарәфи. Без аның белән вакзалдан кузгалып киттек. Юлда бик яхшы бардык.

Сираҗетдин (*үзалдына*). Бик дөрес, хәтта пирасаткага төшкәндә бергә пирәшләдек[7] тә.

Гарәфи. Соңыннан Мәскәүгә барып җитәргә берничә станса калгач...

Сираҗетдин (*үзалдына*). Әйе, берничә станса калгач.

Гарәфи. Сираҗетдин: «Мин тышка чыгып керим әле», – дип, тышка чыгып китте. Төн караңгы иде...

Сираҗетдин (*үзалдына*). Дөрес, караңгы иде.

Гарәфи. Пуез да бик шәп барадыр иде. Ул чыгып бераз торгач, пуез бер стансага туктады, аннан да кузгалып китте...

Сираҗетдин (*үзалдына*). Анысы да дөрес.

Гарәфи. Шуннан соң мин, тынычсызланып, Сираҗетдинны эзләргә чыктым. Бәдрәфне барып төртеп карадым, бәдрәф бикле иде...

Сираҗетдин (*үзалдына*). Монысы да дөрес.

Гарәфи. Бәдрәф янында бер-ике кеше көтеп торалар, бәдрәфтәге кешене «озак торды» дип сүгәләр иде...

Сираҗетдин (*үзалдына*). Анысы да дөрес. Хәтта ишекне дөбердәтеп аптыратып бетерделәр.

Гарәфи. Шул вакытта бер кандуктыр узып барадыр иде, аңа жалуба бирделәр...

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Анысын да ишеттем.

Г а р ә ф и. Кандуктыр: «Стансада торганда, икенче кандуктыр бикләп куйгандыр аны», – дип ачып керде...

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Уф! Иң читен җиренә килеп җиттеләр.

Г а р ә ф и. Бервакытны ачып керсәк... ни күзебез белән күрик, Сираҗетдинның башыннан бүрекләре, кәләпүшләре төшкән...

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Дөрес.

Г а р ә ф и. Аякларын салдырганнар...

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Анысын үзем салдым.

Г а р ә ф и. Казакиларын, камзулларын чишкәннәр...

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Аларын да үзем чиштем.

Г а р ә ф и. Бернәрсә белмичә һушы китеп ята...

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Әйе, белмәмешкә салынып яттым.

Г а р ә ф и. Моны күргәч тә, минем йөрәкләрем гөп итеп китте, кандуктыр да: «Кенәзне талаганнар!..» – диде.

С и р а җ е т д и н (*сикереп торып*). Каравыл! Тотыгыз! Тот! (*Ишеккә таба йөгерә.*)

Һәммәсе урыныннан сикереп торалар. Сираҗетдинны барып тоталар.

Каравыл! Талыйлар!

Җ а м а л и<br>
К а м а л и (*беравыздан*). Җибәрмәгез, җибәрмә!<br>
Г а р ә ф и

Сираҗи, Сираҗи, бернәрсә юк, утыр! Утыртыгыз! (*Урындыкка китереп утырталар.*)

С и р а җ е т д и н. Каравыл! Талыйлар! (*Урындыкка егылып, изелеп төшә.*)

Д о в е р е н н ы й л а р. Доктор, доктор әфәнде, ярдәм итегез, карагыз.

Д о к т о р килә.

Д о к т о р. Рәхим итеп, бер чүпрәкне салкын суга манып китерегез әле. Бераз хәл алдырырга кирәк булыр. Аннан соң тамырларын карарбыз.

Сулы чүпрәкне китерәләр.

(*Сулы чүпрәкне маңгаена куеп.*) Шул килешкә бераз гына торып хәл алсын әле, сез, зинһар, бераз читкәрәк китеп торыгыз, яңадан күзен ачып җибәреп, сездән курыкмасын.

Читкә китәләр.

(*Бераз торып.*) Менә инде хәзер тамырларын карап ка-

рыйк. (*Сиражетдинның асылынып торган кулын кулына ала.*)

Шул арада Сиражетдин бик кечкенә итеп бөкләнгән биш йөзлекне докторның кулына кыстыра.

(*Ул, биш йөзлеккә күзен төшереп, үзалдына.*) Һа, алай икән, эш сизелде, бик шәп акылдан шашкан икән. Ярый, миңа барыбер. (*Кесәсеннән сәгать алган булып, биш йөзлекне кесәсенә тыга. Тамырын тотып бераз карагannан соң.*) Эш бу яктан бик өмитле түгел, тамыр бик еш тибә. (*Күкрәкләрен тыңлый.*) Монда да хәл бик яхшы түгел. Йә әле, башкача тәҗрибә кыйлып карыйк. (*Кесәсеннән бер нәрсә алып, кулларына, битләренә төртеп карап.*) Дөрес. (*Доверенныйларга әйләнеп карап.*) Әфәнделәр, эш бик өмитле түгел, гакылына бик зур хәләл килгән. Әгәр дә бик зур, хәтта харикыльгадә бер вакыйга булып, шул вакыйганы күргәндә кинәттән гакылына килмәсә, дәва белән генә терелтергә зур өмит күренми. Менә бу чүпрәкне алып куегыз әле. Хәзер күзен бераз ача башлады. Инде миңа тагын бер стакан салкын су китереп бирегез, шуны эчерткәч, бераз хәл алыр. Аннан соң мин сезгә бер дару язып бирермен. Шул даруны эчерткәч, ул тынычсызлануыннан бераз тукталыр. Шулай да булса, әфәнделәр, бөтенләй терелүенә өмит бик аз.

## СИГЕЗЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан һәм башкалар.

Гөлҗиһан (*ишектән җылап кереп*). Доктор әфәнде, мин нихәл итәрмен, кая барырмын?

Доктор. Тс, тс! Тавышыгызны чыгармагыз! Авыру янында җылаган тавыш чыгарырга ярамый, ул аның кәефен генә боза.

Гөлҗиһан, күзен яулык берлә каплап, акрын гына җылый.

Белмәссең, бәлки, Ходадан вәгъдә җитсә, терелеп тә китәр. Дөньяда төрле вакыйгалар була. Менә бервакыт шундый бер кеше акылыннан шашкан, ничә еллар үзен-үзе белмичә йөргән. Бервакыт шуларның йортлары яна башлаган. Ул кешенең алты-җиде яшендә кечкенә кыз баласына ут кабынырга якынлашкач, бала бик каты, ачы аваз

---

Хәләл – зарар.
Харикыльгадә – гадәттән тыш.

белән кычкырып җибәргән дә, шул тавышка теге кеше йокысыннан уяныл китеп, коточкыч пожарны күреп, кыз баланы кочагына алган да, ут эченнән йөгереп чыгып, баланы янудан коткарган һәм үзе дә яңадан акылына килгән.

Җамали. Хода безгә дә шулай ярдәм бирсә иде.

Камали. Илаһым, үзең ярдәм бир!

Гөлҗиһан. И Раббым, Ходаем!

Тынычлык.

Василий Дмитриевич. Доктор әфәнде, алайса, сез Сираҗетдин әфәнденең акылына зарар килү хак дисез?

Доктор. Анда һичбер шик-шөбһә юк.

Василий Дмитриевич (*доверенныйларга карап*). Алай булгач, әфәнделәр, безгә эшкә керешергә вакыт. Сез ни дисез?

Сираҗетдин (*күзләрен бераз ачып, үзалдына*). Йа Алла, эшләр бераз җиңеләя, иң авырлары узды. Акча төрткәч, докторың эреде. Шайтан да эзләп таба алмаслык ялганнарны ялганлый!

Доверенныйлар. Без дә шуны уйлап торадыр идек, без дә шул фаразда.

Гөлҗиһан чыгып китә.

## ТУГЫЗЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһаннан башкалар.

Василий Дмитриевич. Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, соң сез нинди фаразда?

Җамали. Без нинди фаразда булыйк?

Василий Дмитриевич. Доктор әфәнде әйтә, Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович акылга килерлек түгел, ди. Шулай булгач, инде ул моннан соң сату итә алмас. Кибеттәге бар малын, йортларын сатарга кирәк тә, шуның белән бурычларын түләргә кирәк.

Сираҗетдин (*үзалдына*). Ай-яй, начар сүз әйтте.

Җамали (*аптырап китеп*). Ул ни дигән сүз? Ничә еллардан бирле бер тиен калдырмый түләп килгән фирманы шулай итеп тар-мар итмәкче буласызмы?

Василий Дмитриевич. Ә соң сез ни эшләмәкче буласыз?

Җамали. Менә сезнең белән килешсәк, агай-эне икебездән беребезне апикун итеп куярбыз да әүвәлгечә сату итә бирербез.

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Менә монысы яхшы сүз.

В а с и л и й  Д м и т р и е в и ч. Соң сез ничек итеп килешмәкче буласыз?

Җ а м а л и. Белмим, ничек килешергә?

В а с и л и й  Д м и т р и е в и ч. Соң сез күпме бирмәкче буласыз?

Җ а м а л и. Белмим.

В а с и л и й  Д м и т р и е в и ч. Илле процент бирәсезме?

Җ а м а л и. Ул ни дигән сүз? Аның йорты залук, кибетендә малы юк, акчасы урланган.

В а с и л и й  Д м и т р и е в и ч. Анысын һәммәсен дә беләбез.

Җ а м а л и. Шулай булгач, ни өчен илле прасинт сорыйсыз? Аның кибетендәге бар малын сатып бетерсәгез дә ун прасинттан артык җыя алмассыз.

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Монысы өчен абыйга рәхмәт.

В а с и л и й  Д м и т р и е в и ч. Соң күпме бирмәкче буласыз?

Җ а м а л и. Күпме дип, ун прасинт бирербез. Аны да инде тик, барган көенә фирманың эше туктамасын дип кенә бирәбез.

В а с и л и й  Д м и т р и е в и ч. Алай бик аз. (*Доверенныйларга карап.*) Әйдәгез әле, монда килегез.

Бер читкә китәләр.

Ну, сез ни дисез?

Үзара шыпыртлап бераз киңәшәләр. Янәдән килеп утырып.

Ну, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, менә нәрсә, унбиш процент бирерсез. Аннан да ким булганда, иптәшләр риза булмыйлар.

Җ а м а л и. Ихтыярыгыз, без артык бирә алмыйбыз. Ничә еллардан бирле килгән фирманы бетерәсез икән, хәерле булсын.

В а с и л и й  Д м и т р и е в и ч. Алай булса, менә нәрсә: ун процентның һәммәсен дә иртәгә биреп бетерергә кулыгыздан подписка бирәсезме?

Җ а м а л и (*Камалига карап*). Камали, синдә иртәгә алты мең тәңкәләп акча булырмы? Калган яртысын мин табам.

К а м а л и. Яхшы, ярар, булыр.

В а с и л и й  Д м и т р и е в и ч. Димәк, алай булгач, риза буласыз?

Җ а м а л и. Риза.

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Эш пешә.

В а с и л и й  Д м и т р и е в и ч. Ну, доверенныйлар, сез дә ризамы?

Д о в е р е н н ы й л а р. Риза, риза!

В а с и л и й  Д м и т р и е в и ч. Алай булса, мин актны язам. (*Яза.*) Менә сезгә үзебезнең йөз егерме мең сум алачагыбыз бәрабәренә унике мең сум алырга риза булганлыгыбызга распискалар. Рәхим итеп, һәммәгез дә шуңа кул куегыз!

Куялар.

Яхшы, инде алай булса, менә, менә монысы сезгә. Ә менә монысы безгә. (*Кесәсенә тыга.*) Яхшы, хәерле сәгатьтә булсын.

Кул бирешәләр.

Ну, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, инде эш бетергәнлекнең сые сездән.

Җ а м а л и. Әйдәгез, рәхим итегез, барабыз.

Б е р  д о в е р е н н ы й. Ә Сираҗетдин Гыйлаҗетдиновичны тәбрик итәргә кирәк.

В а с и л и й  Д м и т р и е в и ч. Юк, ярамый.

Җ а м а л и. Әйдәгез.

Чыга башлыйлар.

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Ух, эш пеште! Бер көн эчендә йөз дә сигез мең тәңкә файда!

Д о к т о р. Әфәнделәр, сезгә бер сүзем бар. Әгәр дә минем сүземне тотсагыз, хәзерге көндә ике кешегә сез бик зур файда китерә аласыз. Бердән, сез авыруны терелтә аласыз, икенчедән, миңа бик зур шөһрәт була.

Д о в е р е н н ы й л а р. Ничек итеп?

Д о к т о р. Менә ничек итеп: бая мин сезгә сөйләгән идем бит, харикыльгадә бер эш булса, диваналарның терелүе ихтимал дип.

Д о в е р е н н ы й л а р. Ие.

Д о к т о р. Менә хәзер минем башыма бер фикер килде. Сезнең кайсыгызда булса да дүрт данә бишәр йөз сумлык акчалар бардыр бит?

Д о в е р е н н ы й л а р. Бар, миндә дә бар.

Җ а м а л и.<br>К а м а л и. } Миндә дә бар.

С и р а җ е т д и н (*үзалдына, шатланып*). Аңладым, аңладым, бу доктор түгел икән, шайтан икән! Яңадан бер биш йөзлекне тамызмый туры килмәс. Дәртен белгән – дәрманын белер, диләр, бик дөрес сүз.

Доктор. Булса, китерегез монда акчаларыгызны.

Бирәләр.

Хәзер миңа калын-калын итеп дүрткә бүлеп төргән чуар кәгазьләр бирегез.

Җамали. Хәзер китерәм. (*Чыгып китә.*)

Камали да өстәл асларыннан кәгазьләр эзли башлый.

Василий Дмитриевич. Сез ни эшләмәкче буласыз? Мин аңламыйм.

Доктор. Бераз гына сабыр итегез, хәзер күрерсез.

Кәгазьләрне китереп бирәләр.

Менә аларны шушылай итеп төрик.

Төрәләр.

Хуш, сез, әфәнделәр, менә бу почмакка килеп, бер дә дәшми-тынмый гына тик торыгыз.

Тегеләр почмакка китәләр. Доктор, тышкы ягыннан бишәр йөзлек акча белән төргән кәгазьләрне икешәр-икешәр ике кулына тотып, аларны югары күтәреп, акрынлап, аяк очлары белән генә басып, Сираҗетдиннең артына килә. Соңра кинәттән, аяк тибеп, бик каты аваз белән: «Сираҗетдин!» – дип кычкыра. Сираҗетдин, сискәнеп, аяк өстенә баса. Акчаларны карап тора. Соңра көлеп җибәреп: «Акчам! Акчам!» – дип, кулларын суза.

Доктор (*акчаны биреп*). Мә, ал акчаларыңны! Монда кырык тугыз мең тәңкә! Акчаң табылды!

Сираҗетдин, акчаларны алып, контор өстәленә йөгерә. Өстәл эченә салып бикләп, ачкычны ала.

Доктор (*халыкка карап*). Ну, каналия, нинди оста эшли, артист кына буласы бар! (*Сираҗетдин янына бара. Бер кулы белән Җамалига ишарә кыла.*)

Җамали килә.

Сираҗетдин әфәнде, бу кем? Бу абзаң, күрешегез.

Сираҗетдин (*Җамалига карап*). Абый!

Җамали. Исәнме, энем! Исән кайттыңмы?

Камали. Исәнме, энем!

Сираҗетдин. Исәнме!

Доктор. Хатынын чакырыгыз!

Җамали. Исән-сау кайттыңмы, энем?

Сираҗетдин. Ә?

Җамали. Исәнме, дим!

Д о к т о р. Менә болар агаларың, таныйсыңмы?
С и р а җ е т д и н. Таныйм.
Д о к т о р. Танысаң, күреш.

Сираҗетдин күрешә. Г ө л җ и һ а н керә.

## УНЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Г ө л җ и һ а н һәм б а ш к а л а р.

Д о к т о р. Менә монысы кем?
С и р а җ е т д и н. Гөлҗиһан?
Д о к т о р. Күрешегез.

Күрешәләр.

Йә, инде утырыгыз.

Дүртесе дә утыралар.

Йә, менә инде тыңлап торыгыз, Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович! Әнә сезнең кырык тугыз мең тәңкә акчагыз, сез ул акчаны Мәскәү юлында югалттыгыз.

С и р а җ е т д и н (*сикереп торып*). Ә?

Д о к т о р. Утыр, утыр, менә инде хәзер ул акчалар табылды.

С и р а җ е т д и н. Сез кем?

Д о к т о р. Мин – доктор.

С и р а җ е т д и н. Хуш?!

Д о к т о р. Хәзер инде син терелдең.

С и р а җ е т д и н. Мин авырмадым!

Д о к т о р. Ярый авырмасаң. (*Халыкка карап.*) Авырмаганлыгың бик мәгълүм. (*Сираҗетдинга.*) Ярый, хуш инде! Мин китәм.

С и р а җ е т д и н (*урыныннан торып*). Ярый, хуш! Ә болар кемнәр? Ә, Василий Дмитриевич, уһу-у, исәнме! Миңа ник әйтмисез, исәнме! Һа, сез дә исәнме! Акчага дип килдегезме? Менә хәзер сезгә акча бирәм. (*Өстәл астын барып ача башлый.)*

Доверенныйлар шаркылдап көлеп җибәрәләр.

В а с и л и й Д м и т р и е в и ч. Юк, Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович, кирәк түгел. Бирерсез әле. Әйдә, без сине сыйланырга алып барабыз. Шунда сөйләшербез.

С и р а җ е т д и н. Ярар, барам, бар, чыга торыгыз. Кая, Гөлҗиһан, бүрек белән яңа киемнәрне китер.

Һәммәсе дә чыгып китәләр. Доктор кала.

(*Докторга.*) Аңладым, аңладым. Сезгә тагын биш йөз. Мин хәзер чыгам.

Доктор чыга.

Ә менә монда икән җиләп. (*Киенә.*) Эш пеште! Бер минут эчендә йөз дә сигез мең сум файда! Хатынны җибәрәм, яшь хатын алам, йорт салам, афтамабил алам! Типтерәм дөньясында! (*Чыгып китә.*)

Гөлҗиһан (*ишектән сөйләнеп керә*). Бүрекләрең бу яктадыр, ахры. Ай Алла, чыгып та киткән, күрми дә калдым. Үзе дә терелде! Байлыгыбыз да үзебезгә калды. Кунакка барам, кунакка чакырам, мәҗлес уздырам! Янсын дошманнарның йөрәге!

Пәрдә.

# БЕЗНЕҢ ШӘҺӘРНЕҢ СЕРЛӘРЕ

*Мәнзарә 5 пәрдәдә*

ӘШХАС:

Себер бае – шәһәргә өйләнергә килгән, 35 яшьләр чамасында, мәгърифәтле бер кеше.
Яучы – аңа кыз димләргә йөрүче, маклер сымак бер ысул кадимче.
Сәркәтиб – уртача яшьләрдә, русчадан яхшы мәгълүматлы кеше.
Фатих, Насыйр, Касыйм, Садрый – җәмгыяте хәйрия идарәсендә әгъзалар.
Дежурный – клуб старшиналарыннан берәү.
Сакчы, Кара казакилы, Серый киемле, Гариф, Кәрим – клуб әгъзалары.
Шкафчы – ысул кадимчеләр башлыгы.

Дирижер, рассказчы, карт, халык, членнар вә башкалар.

## БЕРЕНЧЕ МӘНЗАРӘ

**Җәмгыяте хәйриядә**

Җәмгыяте хәйриянең залы. Урталыкта өстәл. Өстәл өстенә кәгазьләр, кара савыты, звонок һәм башка язу әсбаблары куелган. Пәрдә ачылганда, өстәл янында җәмгыятьнең сәркәтибе бер дәфтәрне карап утыра.

### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Сәркәтиб, соңра җәмгыятьнең Сакчысы.

Сәркәтиб (*үзалдына*). Устав, устав, диләр. Уставның һичбер җитешмәгән җире юк. Бу устав буенча әллә

---

Мәнзарә – күренеш.
Сәркәтиб – секретарь.
Җәмгыяте хәйрия – ярдәм җәмгыяте.
Ысул кадимче – иске карашлы кеше.

нинди зур эшләр кылырга мөмкин. Бары тик тырышырга гына кирәк. Дарелгаҗизин, дареләйтам, вәладәтханә, кыйраәтханә, көтебханә, шифаханә, ашханә, тагы белмим әллә нинди ханәләр ачарга мөмкин. Эш бары әгъзаларның тырышлыгында гына. Әгъзалар чынлап тырышсалар, акча да булыр, эш тә чыгарып булыр иде. Әгъзалар тырышмыйлар. Әле менә инде минем килгәнгә ике сәгатьләп була, ә алар әле һаман килмиләр. Тагы бер ярты сәгать кенә көтәм дә кайтам да китәм. Аларның аена 15–20 тәңкә вазифалары өчен баш ватып, көн уздырып, монда көн буе утырыр хәлем юк... (*Звонок шалтырата.*)

Сакчы керә.

Кара әле, Хафиз, бар әле, капка төбенә чыгып кара әле, килмиләр микән?

Сакчы. Мин баядан бирле капка төбендә торам инде, як-якка карый-карый муеннарым каерылып бетте. Берсе дә килми.

Сәркәтиб. Син соң дәгъватнамәләрне һәммәсенә дә бирдеңме?

Сакчы. Бирдем.

Сәркәтиб. Нәрсә диделәр?

Сакчы. Садрый абзыйның үзен күрмәдем. Асраударына бирдем. Садрый абзыйның җәмәгате баскыч башыннан карап торадыр иде.

Сәркәтиб. Хуш?

Сакчы. «Ул нәрсә ул тагы?» – ди. Идарә мәҗлесенә запискә, дигән идем, ачуланырга тотынды. «Бетмәде инде мәҗлесегез», – ди. «Көн дә, көн дә ул нинди мәҗлес булсын, бүген бармас, бүген безнең парлы кунакка барасыбыз бар. Һәр көн кич анда барып, төн уздырып кайтырга булмас», – ди.

Сәркәтиб. Башкалары нәрсә диделәр?

Сакчы. Касыйм абзыйны күргән идем: «Ярар, бушый алсам, барырмын. Минем, ясигъдан чыккач, бер җиргә туйга барасым бар. Миңа карамасыннар, мәҗлесне ачып, эшкә башлый торсыннар. Мин пртакулга кул

---

Дарелгаҗизин – картлар йорты.
Дареләйтам – ятим балалар йорты.
Вәладәтханә – бала тудыру йорты.
Кыйраәтханә – уку өе.
Шифаханә – больница.
Вазифа – хезмәт хакы.
Дәгъватнамә – чакыру кәгазе.
Ясигъ – намаз.

куярга барып җитәрмен. Бара алмасам, иртәгә пртакул дәфтәрен кибеткә төшерерсең, кул куеп бирермен», – ди.

Сәркәтиб. Ә Рәхим абзый нәрсә диде?

Сакчы. Ул да: «Мин бу көн бара алмам, вакзалга кунаклар озатырга төшәсем бар. Иртәгә пртакул дәфтәрен кертерсең, кул куеп бирермен», – диде.

Сәркәтиб. Алай икән! Ә Фатих?

Сакчы. Фатих абзый бернәрсә дә әйтмәде. «Барыбер, барсаң да аяк туздырып йөрүе генә калыр, җыелмаслар», – диде.

Сәркәтиб. Соң син әйттеңме, бүген бер дә җыелмый калырга ярамый, дип.

Сакчы. Әйттем.

Сәркәтиб. Башкалары нәрсә диделәр?

Сакчы. Ярар, барырга тырышырбыз, диделәр.

Сәркәтиб. Алай икән. Ярый, башка йомыш юк.

Сакчы чыга башлый.

Ә, кара әле, кем, Хафиз, сәгать ничә булган?

Сакчы. Унынчы ярты. (*Чыгып китә.*)

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Сәркәтиб ялгыз.

Сәркәтиб (*үзалдына сөйли*). Унынчы ярты. Сәгать сигездә дип чакырган мәҗлескә әле һаман килгәннәре юк. Бүген инде өченче мәртәбә чакыру, алай да килмиләр. Монда карасы эшнең очы-кырые юк. (*Кәгазьләрне актарып карап.*) Менә монда бер бичарасы, юлга китәргә акчам юк, дип, ярдәм сорый. Гаризасы язылганга нәкъ бер ай да ун көн булган. Әгәр бүген дә җыелмасалар, ул бичарага тагы ун көн көтәргә кирәк булыр. Әгәр дә ул кеше җәмгыятьнең ярдәменә ышанып ятса, язган булса, яз көне, шаять, китәр. Менә монысында, бер бик фәкыйрь хатын урын өстендә үләргә ята, табиб китертергә ярдәм сорый, дигәннәр. Аның гаризасының язылганына да бүген нәкъ бер ай булган. Кем белә, мескен, көткән-көткәндер дә, ярдәм килмәгәч, «ахры, булмас инде» дип, бәлки, күптән теге дөньяга киткәндер! Монда көтеп утырудан бер тиенлек тә мәгънә чыкмас. Кайтырга кирәк. Садрый байның хатыны: «Ул нинди көн саен мәҗлес», – дип әйтә, ди. Кем белә, бәлки, ул шулай көн саен, мәҗлескә барам дип,

---

Табиб – доктор.

өеннән чыгып китә торгандыр. Бервакытны бер гласный шулай һәр көн өеннән: «Мин управага менәм», – дип чыгып китә икән. Бервакыт, кыш узгач, кыш буена кемнең ничә мәртәбә Дума мәҗлесләренә барганлыгын мөселман гәзитләренә язып чыгардылар. Хатыннары гәзитне укып карасалар, теге гласный кыш буе бары ике генә мәртәбә мәҗлескә барган булып чыккан. Шуның шикелле, Садрый абзый да һаман «мәҗлескә барам» дип чыгып китә торгандыр әле. (*Халыкка карап.*) Хуш, сау булыгыз, мин өйгә йокларга кайтам инде. (*Чыгып китә.*)

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Сәркәтиб белән бер идарә әгъзасы.

Тыштан тавыш. Юк, юк, китмә, китмә! Хәзер килерләр. Әйдә, әйдә.

Керәләр.

Сәркәтиб. Соң инде, Насыйр абзый, минем килгәнгә бит ике сәгать булды. Сездән 15–20 тәңкә вазифа алам дип, монда төн буена утырыйммыни?

Әгъза. Хафаланма, хафаланма, хәзер килерләр. Мин, кибет япкач, хатын белән киниматуграфка барган идем, шуңа бераз соңга калдым. Фатих та шунда иде, ул да, хәзер киләм, диде.

Сәркәтиб. Анда башка көнне барсагыз да яраган булыр иде. Сәгать сигездә дип чакырган мәҗлескә унда килгәч, эш ничек барсын?

Әгъза. Бармаса, мин ни эшлим инде? Һаман җәмәгать эше артыннан гына йөреп булмый. Башкалар тырышмагач, мин берүзем генә ни эшлим? Кая, бүген каралырга нинди эшләр бар?

Сәркәтиб. Бүген каралырга тиешле булган эшнең очы-кырые юк. Утызлап гариза бар.

Әгъза. Һу, бигрәк күп икән. Кая соң, башкалар тизрәк килсәләр ярар иде. Бар әле син, тизрәк кайсынаберсенә тилифун белән хәбәр ит әле. Тизрәк килсеннәр.

Сәркәтиб. Ай-һай, килерләр микән? (*Телефон янына бара. Телефонны бора.*) Синтральный? Синтральный? (*Яңадан бора.*) Синтральный? Синтральный? Фу, чурт! Хафиз, Хафиз!

Сакчы керә.

Әллә бу безнең телефон бозылганмы?

---

Гласный – шәһәр Думасына сайланган кеше.

С а к ч ы. Юк, бозылмаган. Кичә генә Кәрим абзый банкы белән сөйләште.

С ә р к ә т и б. Нишләп соң, алай булгач, бер дә хәбәр бирмиләр? (*Яңадан бора.*) Синтральный? Йа Алла! Көчкә килделәр. Зинһар, миңа Садрый Атабаевның кантурын тоташтырыгыз әле? Нәрсә, мәшгуль дисезме? (*Халыкка карап.*) Бу вакытта ул кем белән сөйләшер икән? Алай булса, Хәким Ямашевка тоташтырыгыз. Рәхмәт. (*Шалтырата. Каршыга җавап бирәләр.*) Кайдан бу? Нәрсә? Яким Дадашев? Зинһар, кирәк түгел! Өзегез әле. (*Шалтырата.*) Мин аларга, Хәким Ямашев, дим, ә алар Яким Дадашевка тоташтырганнар! (*Шалтырата.*) Синтральный? (*Шалтырата.*) Синтральный? (*Шалтырата.*) Синтральный? Уф Алла! Хафиз, сәгатьне кара әле, күпме булган?

С а к ч ы. Ун тулып чирек.

С ә р к ә т и б. Уф! (*Шалтырата.*) Синтральный? Синтральный? Ярабби, шөкер, килделәр! Зинһар, дип әйтәм, Хәким Ямашевка тоташтырыгыз әле. Мин сезгә, Хәким Ямашев, дим, ә сез Яким Дадашевка тоташтырасыз. Болай гына аңламасагыз, номерын әйтим: 666 нчы. Рәхмәт. (*Шалтырата. Каршыга җавап бирәләр.*) Кайдан бу? Нәрсә? Өченче часть. Кирәк түгел. Зинһар, өзегез! (*Телефонның трубкасын элеп.*) Менә бәла, 666 нчы урынына 676 нчыны, өченче частьны биргәннәр! Булмас, ахры. (*Маңгаендагы тирләрен сөртеп.*) Моңарчы инде һәммәсенә җәяүләп барып әйтсәң дә булыр иде.

Тыштан аяк тавышлары ишетелә.

Әнә киләләр бугай.

Ф а т и х килеп керә.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ф а т и х һ ә м ә ү в ә л г е л ә р.

Ф а т и х. Әссәламегаләйкем!

Б а ш к а л а р. Вәгаләйкемәссәлам! Әйдәгез, хуш киләсез.

Ф а т и х. Нихәл, мәҗлес таралдымы әллә?

С ә р к ә т и б. Җыелса, таралыр.

Ф а т и х. Мин бер килмәскә дә уйлаган идем дә, ут яктысы күргәч, тукта, кереп чыгыйм, дип кердем, нихәл,ниләргә карар бирдегез? Кая, мин дәфтәргә кул гына куеп китим, эшем ашыгыч.

Ә г ъ з а. Әле мәҗлес булганы юк.

Фатих. Алай булгач, бүген булмас та инде.

Сәркәтиб. Килмәгәч, әлбәттә, булмас.

Фатих. Килмәгәч дип, мин берүзем килеп кенә ни эшлим, башкалар берсе дә килмиләр ич?

Сәркәтиб. Җәмгыятьне тотарга да ябарга. Бүтән бер эш тә юк.

Әгъза. Әнә тагы киләләр бугай.

Себер бае белән Язучы керә.

## БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Шулар ук һәм Себер бае белән Язучы.

Себер бае. Әссәламегаләйкем!

Башкалар. Вәгаләйкемәссәлам!

Себер бае. Мин бүген монда мәҗлес була дип ишеткән идем. Шуңа күрә бер кереп чыгыйм дигән идем. Өлгерә алмадым, мәҗлесегез таралган икән.

Сәркәтиб (*халыкка карап*). Таралыр өчен әүвәл оешырга кирәк әле.

Әгъза. Рәхим итегез, таралмаган әле, хәзер яңа җыелабыз.

Фатих. Рәхим итегез, әфәндем, рәхим итегез! Сез кем буласыз? Кайдан киләсез? Кайда барасыз? Ни белән сәүдә кыласыз? Кем номерына төштегез? Озак торасызмы? Чугунка белән килдегезме?

Себер бае. Ие, чугунка белән килдем. Мин үзем Себер ягында сәүдә кылучы бер кеше булам, хатыным үлгән иде дә, монда өйләнергә дип килгән идем.

Әгъза. Рәхим итегез, рәхим итегез! Ни белән сәүдә кыласыз?

Фатих. Нинди җирдән өйләнмәкче буласыз? Бай кеше кызын алырга ният кыласызмы? Әллә уртача булса да ярыймы?

Себер бае. Минем сәүдәм төрле нәрсә белән. Нинди җирдән өйләнергә туры килер әле, ул кадәресен белә алмыйм. Минем монда бер дә белеш кешем юк.

Әгъза. Читек-кәвеш белән сәүдә кыласызмы? Монда мал аласызмы? Бездә читек-кәвешнең төрлесе бар. Бәһасен дә арзан гына бирербез.

Фатих. Кәләпүш, калфак, бүрек шикелле нәрсәләр аласызмы? Безнең нәрсәләр бик яхшы була.

Сәркәтиб. Менә сезгә кирәк булса – базар! (*Кулын җәеп күрсәтеп.*) Менә инде син эшлә болар белән эшне!

---

Чугунка – тимер юл, поезд.

Ә г ъ з а. Сезнең якка, бәлки, намазлык, комган, сөлге, эскәтер, чалма, чалма бүрек шикелле нәрсәләр дә китә торгандыр?

Ф а т и х. Алары инде аның һәммә кешедә дә табыла; намазлык, комган шикелле нәрсәләр бездә дә бар. Без дә кыйммәт бәһа алмабыз.

С ә р к ә т и б (*халыкка карап*). Хәзер инде конкуренсия дә башланды!

С е б е р  б а е. Әфәнделәр, мин андый нәрсәләр белән сату итмим. Мин урыс арасында сату итәм. Минем төрле нәрсә дигәнем икенче нәрсә. Мин кызыл мал, галантерейный, бакалейный нәрсәләр белән сәүдә кылам.

Ә г ъ з а. Алай булгач, бик яхшы. Менә Зарифка әйтергә кирәк. Ул сезгә гилтаринный малларның һәртөрлесен дә табып бирер.

Ф а т и х. Кызыл малны Вафа хаҗидан алырсыз, ул сезгә очсыз сатар. Акчага алсагыз, ул сезгә скиткәне дә күп ясар.

С ә р к ә т и б (*халыкка карап*). Инде хәзер маклерлыкка да керешә башладылар!

С е б е р  б а е. Юк, әфәнделәр, мин монда мал алырга килмәдем. Мин малны туп-туры Мәскәүдән фабрикантлардан алам, мин монда бары өйләнер өчен дип кенә килдем.

Ә г ъ з а. Алай икән; соң сез нинди җирдән өйләнмәкче буласыз? Бай җирдәнме, уртача җирдәнме?

Ф а т и х. Кыз булсын дисезме, тол булса да ярыймы?

С ә р к ә т и б (*халыкка карап*). Инде хәзер яучылыкка да керештеләр.

Я у ч ы. Байлар, мин сезгә бер сүз әйтим әле, бу безнең якташ кеше; безнең белән бер өяздән. Аңа кызны мин үзем димлим.

Ә г ъ з а. Кемне димлисең? Әнә Җамали хаҗиның кызын димлә, аны бик матур диләр.

С ә р к ә т и б (*халыкка карап*). Чеп-чи ялган!

Ф а т и х. Безнең Әхмәтнең кияүдән кайткан кызы ничек булыр? Әгәр тол дип әйтмәсә, аны димләргә ярый. Бик чибәр кыз.

С ә р к ә т и б (*сәгатькә карап*). Әфәнделәр, мин кайтам. Инде сәгать 11 тулган. Бүген мәҗлес булмас, ахры.

Ф а т и х. Тукта, бераз сабыр ит әле, ул кадәр ашыгып кая барасың?

С ә р к ә т и б. Килмиләр ич.

Ә г ъ з а. Ник, килмәсәләр, без үзебез генә эшне карый алмыйбызмыни? Кая, китер эшләреңне, нәрсәләр бар?

С ә р к ә т и б (*халыкка карап*). Кырырсыз инде сез эшне! (*Әгъзаларга.*) Менә өстәл өстендә һәммәсе дә хәзер.

Ә г ъ з а. Кая, укып күрсәт, нәрсәләр бар?

С ә р к ә т и б. Укудан эш калмас, укырмын. Ләкин әле бит монда устав буенча җитәрлек әгъзалар җыелмаган.

Ф а т и х. Җыелмаса, ни булган? Иртәгә Хафиз кул куйдырыр. Йә, укы. (*Себер баена.*) Без, менә шулай, кеше җыелмаган дип тормыйбыз. Эшне тиздән йөртә бирәбез.

С е б е р  б а е. Бик яхшы, бик яхшы.

С ә р к ә т и б (*кәгазьләрне карап*). Менә монда бер шәкерт укырга дип иганә сорый.

Ә г ъ з а. Ул ни эшләп бездән сорый, ата-анасы укытсын, безнең балаларны бер кеше дә акча биреп укытмый.

С ә р к ә т и б. Фәкыйрь, ди, ятим, ди.

Ф а т и х. Ятим булса, приютка кереп укыр. Бездә артык акчалар юк әле. Йә, икенчесен укы!

С ә р к ә т и б. Алай булса, инде моңа бирмибезмени?

Ф а т и х. Юк, юк, атказ!

Ә г ъ з а. Атказ, атказ!

С ә р к ә т и б (*икенче кәгазьне алып*). Менә монысы, бик фәкыйрь идем, җәмгыятьтән миңа берәр киемлек бирмәсләр микән, ди.

Ә г ъ з а. Ул нинди аңгыра нәрсә ул тагы? Әле күптән түгел генә ураза узды. Шунда байлардан зәкят сорарга ярамаганмыни? Юк, булмас.

Ф а т и х. Йә, башкасын укы!

С ә р к ә т и б (*янә бер кәгазьне алып*). Монысы, юлга акчам юк иде, бераз рәхим итмәсләр микән, ди.

Ф а т и х. Ул ни дигән сүз тагы? Аны монда кем чакырып китергән, килмәсен иде. Андый урыннарга тарата башласаң, монда җәмәгать акчасы түгел, башыңдагы чәчең дә төтмәс. Йә, башкасын укы!

С ә р к ә т и б. Моңа да атказмыни?

Ф а т и х<br>Ә г ъ з а } Атказ, атказ!

С ә р к ә т и б (*янә бер кәгазь алып*). Менә монысында шәһәрнең яшьләре игълан кылалар: «Без җәмгыяте хәйрия файдасына театрлар куеп, әдәбият кичәләре ясар идек, мәсарифыннан артып калган акчасын җәмгыяте хәйриягә бирер идек», – диләр.

С е б е р  б а е. Афәрин, афәрин, сездә дә шундый һиммәтле яшьләр бар икән. Бик файдалы эш.

---

И г а н ә – ярдәм.
З ә к я т – сәдаканың бер төре.
М ә с а р и ф – чыгым.
Һ и м м ә т л е – ярдәмле.

Әгъза белән Фатих һәр икесе тынычсызланалар.

Безнең сәүдә кыла торган җиребездә дә яшьләр ураза бәйрәмендә кыйраәтханә файдасына дип театр уйнаганнар иде. Җиде йөз сум файда иттеләр.

Ф а т и х (*халыкка карап*). Алай икән, бозылган кеше икән! (*Себер баена.*) Җиде йөз тәңкә файда иттеләр дисезме?

С е б е р  б а е. Әйе.

С ә р к ә т и б. Афәрин һиммәтләренә, бик шәп булган икән.

Ф а т и х. Тик тор, син сүзгә катышма! Син ни беләсең, син бит идарә әгъзасы түгел.

Ә г ъ з а. Әйе шул, сиңа катышырга тиеш түгел. Шәпме, түгелме икәнен без үзебез дә бик яхшы беләбез.

Ф а т и х. Һә, җиде йөз тәңкә файда иттеләр диген, ә? Бер көндә җиде йөз тәңкә! Соң, ул акчаны ни эшләттеләр?

С е б е р  б а е. Һәммәсен дә кыйраәтханәгә бирделәр.

Ә г ъ з а. Хәзрәтегез ни әйтте?

С е б е р  б а е. Бернәрсә дә әйтмәде, бик яхшы, диде.

Ф а т и х. Хәрам дип әйтмәдемени?

С е б е р  б а е. Юк, бик яхшы эш, диде.

Ф а т и х (*халыкка карап*). Муллагыз да үзегез шикелле бер азган-тузган нәрсәдер шунда?!

Ә г ъ з а. Муллагыз кайда укыган?

С е б е р  б а е. Элек Казанда укып хәтме көтеб кылгач, хаҗга барып, Мисыр, Истанбулларда йөреп кайткан.

Ф а т и х (*халыкка карап*). Чеп-чи җәдит икән!

Ә г ъ з а. Алай булгач, әйтмәс шул. Мисырда укыганнар алар эшләпә киюне дә дөрес диләр. Урыс суйган итне ашаудан да тартынмыйлар.

С ә р к ә т и б. Хуш, әфәнделәр, бу гаризага ни дип әйтәбез?

Тын.

Ф а т и х. Насыйр, син ни дисең?

Ә г ъ з а. Белмим, ә син ни дисең?

Ф а т и х. Мин бер сүз дә әйтә алмыйм, киләсе мәҗлескә калсын, дим.

Ә г ъ з а. Ярый шул.

С ә р к ә т и б. Әфәнделәр, яшьләр алар бүген үк җавап сорыйлар. Без берсекөнгә әдәбият кичәсе ясыйбыз, әгәр җәмгыяте хәйрия риза булмаса, икенче бер җәмгыять файдасына ясыйбыз, диләр, көтмиләр.

---

Х ә т м е  к ө т е б  к ы л у – мәдрәсә бетерү.

Ф а т и х. Көтмәсәләр, алабия кичәләре белән чәнчелеп китсеннәр! Без аларның хәрам акчаларына калмаган!

Ә г ъ з а. Әлбәттә, әлбәттә, хәрам акчаны алырга ярамый.

Ф а т и х. Сафа хәзрәт Бохарада укып, мөдәррис булып кайткан кеше, белми әйтмәс, мин беркөнне сораган идем: «Һич ярый торган эш түгел, чеп-чи хәрам», – диде. «Дуңгыз ите ни, ул ни – икесе дә барыбер», – диде.

С ә р к ә т и б. Соң бит, безнең җәмгыятьнең сумасы бик аз. Бирәчәкләребез дә бик күп, ә кассада акчабыз бик аз.

Ә г ъ з а. Син белмәгән эшкә катышма. Акчаң аз булса, юрганыңа карап аягыңны сузарсың.

С ә р к ә т и б. Алай булгач, кабул итмибез дип әйтәсезмени?

Ф а т и х, Ә г ъ з а. Атказ, атказ!

Ф а т и х (*сәгатен чыгарып карап*). Һу, сәгать 12 булган! Соңга калына, иртәгә иртәрәк торасы бар. Мин кайтам.

Ә г ъ з а. Мин дә кайтам, әйдә, бергә кайтабыз.

Торалар.

С ә р к ә т и б. Монда тагы 26 гариза бар, аларын ни эшлибез?

Ф а т и х. Атказ! Әй, юк, аларын икенче мәҗлестә карарбыз.

Әгъза белән чыга башлыйлар.

(*Әгъзага бөгелеп, колагына.*) Нихәл, ни эшләттек теге җәдитне?! Авызына бармагын кабып шаккатып карап калдымы? Әйдә, минем белән барасыңмы?

Ә г ъ з а. Кайда?

Ф а т и х. Беләсең инде.

Ә г ъ з а. Әйдә. (*Сәркәтибкә карап.*) Пртакулны яз, иртәгә Хафиз кул куйдырыр. Хуш!

Чыгып китәләр.

С е б е р б а е. Сезнең мәҗлес дигәнегез шушымы инде?

С ә р к ә т и б. Бу гына түгел әле, моннан биш өлеш битәрләре дә була.

С е б е р б а е. Мин бу көн җәмгыять була дигәч, күреп калыйм дип, бу кешене көчләп алып килгән идем. Мин аны бик шәп була торгандыр дип фараз кыладыр идем.

Я у ч ы. Әфәндем, ул яхшы була торган иде дә, әле бу көн карт байларның берсе дә килмәгән.

С ә р к ә т и б. Алар килсә, монда бөтенләй сафура бураннары куба!

С е б е р  б а е. Сезнең бу җәмгыятькә яшьләр бер дә катышмыйлармыни?

С ә р к ә т и б. Катышырлар иде дә, аларга бер дә юл бирмиләр. «Сез – җәдит», – диләр.

С е б е р  б а е. Соң, бу эш үзе дә җәдитләр эше бит?

С ә р к ә т и б. Дөрес, җәдитләр эше. Ул эшне әүвәл җәдитләр башлаган иде дә, соңыннан картлар: «Җәдитләр динне бозып бетерәләр», – дип килеп катыштылар. Яшьләрне төрлечә куркытып, качырып бетерделәр.

С е б е р  б а е. Ярый, хәерле булсын, мин дә әгъза булып язылырмын дигән идем дә, хәзер инде, әгъзаларыгызның «атказ, атказ, атказ»ларын ишетеп, күңелем кайтты. (*Ячыга.*) Шушы икән инде сезнең җәмгыятегез! Әйдә, тизрәк китик. Йә тагы берәрсе, килеп, безгә дә «атказ» ди башлар. Әле мин ашамаган, безнең номерда кухнялар ябылгандыр. Әйдә берәр ресторанга барып ашап кайтыйк. Атказ! Атказ! Атказ! Менә сиңа кирәк булса җәмгыяте хәйрия! Хуш, сау булыгыз!

Чыгып китәләр.

С ә р к ә т и б. Хуш! (*Кәгазьләрен җыештыра.*) Хафиз! Хафиз!

С а к ч ы  к е р ә.

Менә бу кәгазьләрне шкафка биклә. Мин киттем. Иртәгә мин килгәнче кем килсә дә, әйт: «Атказ!» – диген. Хуш, сау бул! Ишеттеңме? Һәммәсенә: «Атказ, атказ, атказ!» (*Чыгып китә.*)

С а к ч ы (*кәгазьләрне алып*). Атказ, атказ! Нәрсәгә җыелган булалар? Мин монда тора башлаганнан бирле һаман бер сүз инде ул: «Атказ, атказ!» (*Чыгып китә.*)

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ МӘНЗАРӘ

### Ресторанда

Зур зал, стена буйларына өстәлләр тезелгән. Берничә өстәлдә ашау-эчү белән мәшгуль б е р н и ч ә  р у с  утырган.

### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

С а д р и,  о ф и ц и а н т,  р у с л а р  в ә д а м а л а р.

С а д р и (*залга кереп, сул тарафтагы өстәлгә утырып*). Әле иртә икән, берсе дә килмәгән. Бәлки, алар җәмгыять мәҗлесенә барганнардыр? Алар килгәнче берәрне эчә торырга кирәк. (*Звонок бирә.*)

Официант килә.

Бер бутылка сыра бир!

Официант. Яхшы. (*Китә.*)

Садри. Җәмгыять бик яхшы сылтау булды әле, андамонда барасы булса, «җәмгыятькә барам» дип чыгып китү бик ансат. Хатын: «Бүген бармасаң да ярар инде. Бик соңга калдың», – ди. Мин: «Юк, бер дә бармый калырга ярамый, карала торган бик кирәкле эшләр бар, мәҗлеснең ахырына барып җитсәм дә, барып калырга кирәк, анда миннән башка бер эш тә булмый», – дип чыгып киттем. Мин инде аларны күптән монда килеп җиткәннәрдер дип торадыр идем, әле килмәгәннәр икән. Узган ел гласныйлыкка сайланырга да йөреп караган идем, булдырып булмады. Әгәр анда сайланган булсам, эш тагы да яхшырак буладыр иде.

Официант бер шешәне китереп куя.

(*Садри шешәне карап.*) Нигә мондыйны, кыйммәтлене китердең? Миңа сталавай кирәк түгел, бабарскийны китер!

Официант. Хәзер ярамый, князь, сәгать унике тулды. Сәгать уникедән соң бездә андый бирелми.

Садри. Ни эшләп тулсын! (*Сәгатен чыгарып.*) Менә бит әле, сәгать уникедән чирек ким.

Официант. Юк, князь, безнең сәгать унике тулды инде. (*Китә.*)

Садри. Каһәр сукканнар, сәгатьләрен юри алга җибәреп куйганнар. Биш тиен көмеш әрәм китте. Алай буласын белгән булсам, мин җәмгыятькә дә кереп чыккан булыр идем. Унике тулганчы, арзан вакытта, бер-икене бушатып калырмын дип ашыга-ашыга килгән идем, булдырып булмады. Көн саен ун тиеннән ул бит елына утыз алты тәңкә була. Утыз алты тәңкә ул нинди булса да бер эшкә ярап куя.

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Шулар ук һәм яшь егет.

Яшь егет (*залга кереп, өстәлләрне күздән кичереп, Садри янына килеп*). Исәнме, Садри абзый!

Садри. Исәнме!

Яшь егет (*урындыкны тартып*). Сезнең янга уты-

---

Бабарский (баварский) – сыра төре (Германиядәге Бавария дигән төбәк исеме белән бәйләнгән).

рырга мөмкинме? (*Урындыкка утыра.*) Монда бер студент килергә вәгъдә кылган иде, килеп җитмәгән икән.

Садри (*халыкка карап*). Менә тагы икенче бәла, бу инде кусаң да китмәс! (*Яшь егеткә.*) Утырыгыз, утыр.

Яшь егет. Студент килгәч тә, мин хәзер китәм. Ялгыз утыруы күңелсез. (*Звонок бирә.*)

Официант килә.

Кая, монда бер стакан китер әле. (*Садрига.*) Бүген бер җирдән ике йөз тәңкә акча аласы бар иде, мин кайтканчы, кибетләр ябылып калган, өлгереп булмады. Садри абзый, миңа иртәгә кадәр ун тәңкә акча биреп торыгыз әле, мин сезгә иртәгә иртә үк, шул ала торган җирдән алгач та, кертеп бирермен.

Официант стакан китерә. Яшь егет бер стакан тутырып эчә дә икенчене салып куя.

Садри (*халыкка карап*). Менә бәла, чистый бүз көясе булды бу! Мин әле монда биш тиен артык китте дип кызганып утырам, ә ул сала да эчә, сала да эчә.

Яшь егет. Минем иртәгә ала торган урыным бар. Ләкин миңа бүген бик кирәк иде. Монда бер кешегә бирәсе бар, бирми калсаң, вәгъдәсезлек була, яхшы түгел. (*Сыраны эчә. Шешәдән яңадан салмакчы була. Шешәнең эчендә беткәнлекне күреп.*) Монда беткән икән. (*Звонок бирә.*) Официант, кая, тагын монда берне китер әле. Садри абзый, зинһар, бүгенгә тыңлап торыгыз әле, мин сезгә иртәгә иртә үк кертеп бирермен.

Садри. Минем янымда ул кадәр үк акча юк.

Яшь егет. Алай икән, миңа бик кирәк иде шул. Булмаса, биш тәңкә генә биреп торыгыз, мин сезгә иртәгә иртә үк бирермен.

Садри. Алай да юк.

Яшь егет. Соң, күпме генә бар?

Официант бер шешә китерә. Яшь егет стаканга салып берне эчә.

Садри (*халыкка карап*). Бер дә бирмичә котылып булмас инде, берәрне бирергә кирәк. (*Яшь егеткә.*) Барлы-юклы ике тәңкә акчам бар, мә, менә берсен бирим.

Яшь егет. Хәерле булсын, ичмаса, өч тәңкә дә юкмы?

Садри. Юк шул!

Яшь егет. Хәерле булсын. (*Бер сумны алып, жилетка кесәсенә кыстыра.*) Иртәгә мин сезгә кибет ачкач та кертеп бирермен. Әле минем сезгә әүвәлге бирәчәкләрем дә бардыр. Аларын да кертеп бирермен. (*Яңадан*

*шешәдән эчеп.*) Мин, теге яктан чыгып, студентны гына карап керим әле. (*Чыгып китә.*)

Садри. Кара син аны, ә! Бер тәңкәлекне чәлде бит! Мин инде аның күзенә кырып салырга сукыр бер тиен дә бирмәгән булыр идем, ярамый. Беркөннәрне тегендә күргән иде: «Бәладән башаяк», – ди. Йә, бирмәсәң, өйдәгеләргә белдереп харап итәр. (*Шешәдән салмакчы була.*) Әле моны да бетергән икән! (*Звонок бирә.*)

Официант килә.

Кая, тагы берне китер! (*Халыкка карап.*) Әүвәлгеләрен дә бирермен дигән була, алырсың инде шайтаннан иман! Әле ярый кесәдә бер тәңкәлек акча бар икән, юк исә өч тәңкәлеге дә эрегән булыр иде.

Официант (*шешәне китереп куеп*). Бу стакан артыкмы?

Садри. Артык, артык, алып китә күр. (*Халыкка карап.*) Йә тагын килеп эчә башлар!

Официант алып китә.

Ул шайтаннан, кая барсаң да, качып котылып булмый. Кайсы ристаранга гына кермә, ул анда була. Өстәл саен килеп эчә дә йөри. Хәерле булсын. Биш тиен урынына егерме мәртәбә биш тиен китте.

Яшь егет (*килеп утырып*). Минем стаканны алып киттемени әле?

Садри. Алып китте. Мин сине чыгып киткән дип торам.

Яшь егет. Ул ни эшләп алай алып китә аны, сорарга кирәк. (*Звонок бирә.*)

Садри (*халыкка карап*). Менә бәла! (*Яшь егеткә.*) Юк, кирәкми, мин хәзер китәм.

Яшь егет. Палужым, минем дә эчәсем килми. Теге студентны гына көтеп утырадыр идем. Хушыгыз әле хәзергә! (*Тора, кесәсеннән бер сумлыкны чыгарып күрсәтеп.*) Китсәң китәрсең, миңа монда бүгенгә җитәрлек булды инде. (*Чыгып китә.*)

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Садри һәм Касыйм.

Касыйм (*залга кереп, Садри янына килеп утырып*). Исәнме, Садри!

Садри. Исәнме!

Касыйм. Әле члиннар җыелмадымыни?

С а д р и. Юк әле.

К а с ы й м. Син җәмгыятькә бардыңмы?

С а д р и. Юк. Ә син бардыңмы?

К а с ы й м. Юк. Минем бүген эшем бар иде. Вакзалга төштем. Син ник бармадың?

С а д р и. Безнең бүген парлы кунакка барасы булды.

К а с ы й м. Кая, миңа да берне әйтергә кирәк. (*Звонок бирә.*) Вакзалда тегене күрдем. Мәскәүгә китеп бара. Бик матурланган икән ул.

С а д р и. Мин әле аны өченчекөн генә күргән идем, бер дә үзгәргән урынын тапмадым.

Официант килә.

Кая, тагын берне китер.

Официант китә.

Син, бәлки, бераз җибәргән булгансыңдыр, шуңар күрә чибәр күренгәндер.

К а с ы й м. Булса бераз булгандыр инде. Кунак озатканда була торган эш.

Официант китерә, эчә башлыйлар.

Йә, тагы сезнең тирәдә нинди хәбәрләр бар?

С а д р и. Ул-бу хәбәр юк. Әле ярый син килеп җиттең. Теге, сиңа каршы очраган нәрсә, сыраны эчеп җанымны чыгара язды.

К а с ы й м. Аңа ни эшкә эчертәсең соң?

С а д р и. Эчертми булмый, беркөн ул мине тегендә күргән иде, эчертмәсәң, ул аннары бөтен дөньяга исемемне чәчеп йөри башлый.

К а с ы й м. Һу, әнә члиннар киләләр.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ш у л а р  у к  һәм Н а с ы й р  белән Ф а т и х.

Насыйр белән Фатих, кереп, килеп утыралар.

Ф а т и х.<br>Н а с ы й р. } Исәнмесез, исәнме!

Ф а т и х. Ник сез җәмгыятькә бармадыгыз?

С а д р и. Барыбер җыелмагандыр бит?

Ф а т и х. Җыелмаса, без үзебез генә эшли белмибезмени? Кая, әйтергә кирәк әле. (*Насыйрга.*) Нәрсә әйтәбез?

Н а с ы й р. Әйтергә кирәк, икене китерсен.

Ф а т и х. Юк ла, ул ярамый, иң әүвәл бик ныгытып нигез салырга кирәк. Аннан соң, өстеннән сипләргә ул

да ярый. (*Звонок бирә.*) Иң әүвәл бик яхшылап бер графинчыкны сындырыйк та, аннан соң аны әйтербез. Садри, ярый бит шулай, ә?

Садри. Ярый шул.

Насыйр. Ярый, китерсен инде алайса.

Официант килә.

Фатих. Кая, син безгә бик шәп итеп закуска белән берне китер әле. Түлке кара аны, закускасы бик шәп булсын.

Официант китә.

Ник монда кеше күз алдына, залга утырдыгыз? Монда бит теләгәнчә җәелеп утырып булмый. Кабинетка кереп утырырга кирәк иде.

Шул арада бер рус белән бер маржа, икенче өстәлгә килеп утырып, ашарга сорыйлар.

Садри. Мин килгәндә, бер кеше дә юк иде, кабинетта ялгыз утыру күңелсез булыр дип монда кердем.

Фатих. Кара әле, Касыйм, тегенең янындагы мәткәне, шәп бит?

Касыйм. Нәгыз икән шул.

Фатих. Без бит әле җәмгыятьтән киләбез.

Садри. Ниләр булды?

Фатих. Анда без берничә төрле эшне карадык. Иртәгә сезгә пртакул кенәгәсен китерерләр, кул куярсыз. Анда теге тар балаклы яшьләр алабия кичәсе ясыйбыз, файдасын җәмгыятькә бирәбез дип прашиния биргәннәр иде, без риза булмадык. Акчаларын башларына чәйнәп яксыннар, аларның хәрам акчаларының бер тиене дә кирәк түгел, дидек.

Касыйм. Шулай шул, бик яхшы иткәнсез.

Насыйр. Анда бер Себер сәүдәгәре килгән иде, ул да алар яклы бернәрсә икән: «Яшьләрегез бик яхшы эш эшләмәкче булалар икән», – ди.

Фатих. Бездәге яшьләр дә бәйрәмдә әллә нәрсәханә файдасына театр куйдылар, ди.

Насыйр. Бер кичтә җиде йөз тәңкә файда иттеләр, ди.

Фатих. Аның авызын бик яхшы гына итеп томаладык.

Насыйр. «Аның акчасы хәрам бит», – дидек.

Фатих. «Сезнең хәзрәтегез андый эшкә ничек риза була?» – дигән идек: «Безнең хәзрәт ул акчаны хәрам дип әйтми, бик яхшы эш дип әйтә», – ди. Аларның муллалары үзләре шикелле, Мисырда укып бозылып кайткан кеше икән.

Н а с ы й р. Мин әйттем: «Мисырда укыган кешеләр алар эшләпә киюне, урысча киенүне дә дөрес дип әйтәләр, урыс суйган итне ашаудан да тартынмыйлар», – дидем.

Ф а т и х. Малаеңның авызы шап итеп капланды!

Көлешәләр.

С а д р и. Нинди нәрсә соң ул, кайдан килгән?

Ф а т и х. Бер малакасус, кызыл авызлы нәрсә шунда, өйләнергә килгән. Кайдагы икәнлеген сорамадык.

С е б е р  б а е  Я у ч ы белән, кереп, икенче яктагы өстәлгә утыралар.

Ф а т и х. Әнә, әнә шул нәрсә. Әле монда да килеп җиткән икән!

С а д р и. Болай үзенең кыяфәте байга охшый.

Н а с ы й р. Өйләнәсе булгач, бай булып күренергә тырышмыйча ярамый бит!

Ф а т и х. Бай булып күренмәсә, аннан ары кыз бирмиләр бит!

## БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ш у л а р  у к  һәм С е б е р  б а е  белән Я у ч ы.

Себер бае звонок бирә. О ф и ц и а н т  килә.

С е б е р  б а е. Кая, безгә ашарга бернәрсә китерегез әле?

О ф и ц и а н т. Рәхим итегез, нәрсә китерик? Менә прейскурант. Рәхим итеп, шуннан карап әйтегез.

С е б е р  б а е (*Яучыга*). Сез нинди нәрсә телисез, беренчегә суп әйтикме, борщмы?

Я у ч ы. Алар нинди нәрсәләр?

С е б е р  б а е. Икесе дә шулпалы нәрсәләр.

Я у ч ы. Анысын беләм, нинди иттән пешергән, балыктанмы?

С е б е р  б а е. Юк, балыктан түгел, иттән.

Я у ч ы. Юк, алай иттән булса, кирәк түгел. Мин урыс ите ашамыйм.

С е б е р  б а е. Ул бит урыс ите түгел, сыер ите. Адәм ите булса, мин дә ашамыйм.

Я у ч ы. Юк, юк, мин ашамыйм. Син үзең аша. Мин берәр нәрсә эчеп кенә утырам. (*Официантка.*) Миңа бер шешә сыра китер.

С е б е р  б а е. Хәерле булсын алайса, мин ашыйм әле. Минем ашыйсым килә. (*Официантка.*) Миңа бер порция

суп китер, тавыктан булсын, икенчегә бер порция ростбиф китер.

Официант. Яхшы, ярар. (*Китә.*)

Икенче официант тегеләр өстәленә бер графин һәм закускалар китереп куя.

Фатих (*закускаларны карап, официантка*). Бу ни?

Официант. Гөмбә.

Фатих. Ә монысы?

Официант. Севрюга.

Фатих. Балыкмы?

Официант. Әйе.

Фатих. Ә монысы?

Официант. Бозау ите.

Фатих. Бозау ите?

Официант. Әйе.

Фатих. Анысын сезгә кем китерергә кушты?

Официант. Аның порциясе шулай инде.

Фатих. Без мөселман бит, ник син безгә андый нәрсә китерәсең? Бар, тиз алып кит. Аның урынына башка нәрсә китер.

Официант. Башка төрле нәрсә бирелми.

Фатих. Бирелмәсә, кирәк түгел, алып кит. Үзең аша.

Официант алып китә.

Фатих. Урыс суйган ит ашарга без җәдит түгел, анысын әнә теге җәдиткә бирер. Ул ашар, чиркәнмәс. (*Төкерә.*) Тфү, җирәнгеч, әле ярый башка киткән вакыт булмады. Мин аның бозау итен башына каплаган булыр идем.

Садри. Безнең өчен Максим трактиры яхшы, аның хәҗәене бик яхшы кеше. Мин, кенәз, мөселманнарга ярамый торган бернәрсәне дә тотмыйм, ди. Анда һәрвакытта закускага тозлы кәбестә, тозлы кыяр, торма, балык – шундый нәрсәләр генә китерәләр. Шуның өчен анда агайэне тулып ята.

Фатих. Моның әле кешесенә очраганы юктыр. Өйрәтерләр иде аны.

Эчәләр. Официант тегеләр өстәленә аш китереп куя.

Ячы. Ничек җирәнмичә ашыйсыз? Мин урыс ашының исен дә яратмыйм.

Себер бае. Без өйрәнгән инде. Безнең тора торган якларда ат итеннән башка мөселман суйган ит тә табып булмый.

Я у ч ы. Ат ите бик шәп була ул. Без аны бик яратып ашыйбыз. Урыс ите ашау гадәте бездә юк. Агай-энедән бер кеше дә ашамый. Әнә күрдең бит, тегеләр закускага китергән итне дә кире җибәрделәр. Ул турыда безнең агай-эне динне бик яхшы тота.

С е б е р  б а е. Алар ни дип ашамадылар?

Я у ч ы. Әйтәм ич, бездә ашамыйлар дип. Хәрам.

С е б е р  б а е. Ә теге графиндагы нәрсә хәрам түгелме?

Я у ч ы. Хәрамын хәрам да инде, әллә ничек урыс ите шикелле түгел. Бәндәчелек инде, андый эшләр генә була ул. Тәүбә кылгач, бетәр.

С е б е р  б а е. Шәп икән!

Ф а т и х. Мәҗлес бик шәп булып китте әле. Тагы берне алдырырга кирәк. Булган-булган берәгәйле булсын. (*Звонок бирә.*)

О ф и ц и а н т килә.

Кая, тагын берне китер.

С е б е р  б а е. Тегеләр баягы җәмгыять членнары түгелме соң?

Я у ч ы. Шулар, теге икесе баягы кешеләр. Болары да члиннар, бая мәҗлескә килмәделәр.

С е б е р  б а е. Мәҗлескә килмәсәләр дә, монда киләләр икән.

О ф и ц и а н т тегеләр өстәленә тагын берне китерә. Эчәләр.

Я у ч ы. Киләләр дип, һәрвакыт та килмиләр инде, бүген шулай туры килгән.

С е б е р  б а е. Бая, әдәбият кичәсеннән килгән акчаны хәрам дигәч, мин аларны бик тәкъва кешеләрдер дип белгән идем. Үз турыларына килгәч, тәкъвалык бер якта торып тора икән. Суфи суган сөймәс, күрсә, кабыгын да куймас, ди.

О ф и ц и а н т ростбифны китереп куя.

Ф а т и х (*бераз кызган, боларга таба борылып*). Ни ди җәдитең? Ни сөйли? Бездә алабия кичәсе ясыйлар, диме?

С е б е р  б а е. Ясаганны, әлбәттә, ясыйлар, дибез шул.

Ф а т и х. Ә без ясамыйбыз, хәрам, дибез!

Н а с ы й р. Без эшләпә дә кимибез, хәрам, дибез!

Ф а т и х. Сезнең шикелле урыс ите дә ашамыйбыз, хәрам, дибез!

---

Т ә к ъ в а – диндар.

С е б е р   б а е. Бик яхшы итәсез. Алай булгач, эчмәскә дә кирәк иде. Ул да хәрамдыр бит?

Ф а т и х. Анысы, анысы ничава, аның юлын без үзебез дә беләбез. Дөньяны менә сезнең шикелле җәдитләр харап итеп бетерәләр. Урысча киенеп, яланбаш йөреп, мөселманны мыскыл иттерәләр.

Дама янындагы рус чыгып китә.

К а с ы й м. Фатих, Фатих, тукта әле, бәйләнүеңне куй әле.

Фатих борыла.

Әнә теге мәткә бушады, син шуны кара. Шәп бит, ә?

Ф а т и х. Ә, бушадымыни? Әйдәгез әле, эчик әле. Мин аны хәзер кулга төшерәм.

С е б е р   б а е (*ашап бетереп*). Берәр стакан чәй дә эчәргә кирәк. (*Официантка чәй китерергә куша.*)

Ф а т и х. Мин аны хәзер кулга төшерәм. Кабинетка кереп утырырбыз. (*Дама янына барып утыра.*) Нихәл, баришна, ни эшләп утырасың? Әйдә безнең янга. Нинди матур, ә? (*Битеннән тотмакчы була.*)

Д а м а (*урыныннан сикереп торып*). Бу нинди безобразие?! Официант!

О ф и ц и а н т (*йөгереп килеп*). Нельзя, князь, нельзя! Бар үз урыныңа!

Себер бае елмаеп-көлеп тора.

Ф а т и х. Төртмә, ник мине төртәсең?

Даманың и р е керә, икенче яктан да б е р н и ч ә   к е ш е керәләр. Араларында Я ш ь   е г е т тә күренә.

Д а м а (*җылаган тавыш белән*). Володя, менә бу татар мине оскорбить итте. Монда килеп утырды да, әйдә безнең янга, ди.

Р у с. Как ул алай сметь итеп монда кеше хатыны янына килә? Официант, бар, чакыр хозяинны, полиция китерсен!

Официант чыгып китә.

С а д р и. Ну, Фатих, бәйләнмәгез, әйдә китик.

Урыннарыннан торалар. Касыйм акча чыгарып өстәлгә куя, чыга башлыйлар.

Ф а т и х. Нигә куркасыз аннан ул кадәр, ул кем булган? Сүз әйттерәсе килмәсә, хатынын монда ир-ат арасына алып килмәсен. Аның монда хатынын алып килгәне өчен кем винават? Мин бер дә курыкмыйм!

Н а с ы й р. Зинһар, юкны сөйләмә. Әйдә, әйдә кайтабыз.

Чыга башлыйлар.

Р у с. Официант! Чыгарма боларны, хозяин килсен!

Ф а т и х. Бер дә синнән куркып чыкмыйбыз, үзебез чыгабыз.

Х о з я и н килә, артыннан О к о л о д о ч н ы й илә Г о р о д о в о й күренә.

## АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Ш у л а р ук һәм О к о л о д о ч н ы й илә Г о р о д о в о й.

Р у с. Вот менә бу татар минем хатынга начар предложение ясаган. Менә болар шаһитлар. (*Кешеләрне күрсәтә.*)

Ф а т и х. Кем белә аны: әллә хатыны, әллә түгел?! Хатыны булса, монда ирләр янына алып килмәсен. Без алып килмибез бит!

О к о л о д о ч н ы й (*Городовойга*). Әйдә, алып кит!

Ф а т и х. Как ул алып китә мине, мин бит думавладилис, мин бит купис. Ни имиет права ул мине алып китәргә!

О к о л о д о ч н ы й. Ну, ну, күп сөйләнмә, әйдә, анда баргач сөйләрсең!

Алып чыгалар. Аның артыннан Касыйм, Насыйр һәм Садри да бик юашланып кына чыгып китәләр.

## ҖИДЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Я ш ь  е г е т, С е б е р  б а е, Я у ч ы һәм О ф и ц и а н т.

Я ш ь  е г е т (*халыкка карап*). Шауламагыз, хәзер миңа тагы бераз имәрлек урын чыкты. Әгәр бераз бөдәмәсә, мин аны бөтен шәһәргә фаш итәрмен. (*Чыгып китә.*)

С е б е р  б а е. Шәп икән эшләрегез, членнарыгыз мәсьәләне бик яхшы хәл кылдылар! Әйдә, без дә кайтыйк инде.

Торалар.

Кадимнәрегез бик шәпләр икән! И бичаралар, инәдән куркып лом йоткан халыклар!

Чыгып китәләр.

П ә р д ә.

## ӨЧЕНЧЕ МӘНЗАРӘ

Клубта.
Клубның бер бүлмәсе. Өстәлләр, урындыклар тезелгән. Бер почмакта лото барабаны куелган. Биш кеше домино уйный. Ике кеше алар янында аяк өстендә басып карап тора.

### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Домино уйнаучылар, Дежурный.

Уйнаучыларның берсе. Йә, чык. Әйдә. Мин сиңа бик яхшы мач бирдем. Яса алты да алты.

Икенчесе. Юк әле, алты да алтылар алар өшкергән әле. Менә мин болай итеп бер дә бер генә ясап торыйм әле. (*Бер шакмак куя.*) Нихәл, шәп булдымы? Шулай итәләр аны. Бик тәмле булыр әле ул.

Өченчесе. Кайдан килеп утырдым синең кул астыңа, әйдә, Әптерәй, куй!

Дүртенчесе. Әйдә, шул көенчә генә, мин дублитын гына куям.

Бишенчесе. Капламадыгыз шул берлене, менә хәзер ала инде ул, син бер дә йөри белмисең!

Беренчесе. Юк әле, алмый торсын, аның җиденчесе менә монда әле. (*Куя.*) Кая, китерегез әле акчаларыгызны! Ха-ха-ха! Ни эшләтте? Сигезенчесен кулыңа тотып калдыңмы? Шулай иттерәләр аны! Кая, китерегез акчаларыгызны, китер, китер!

Икенчесе. Өлгерерсең әле, ул кадәр ашыгып кая барасың? (*Шакмаклар ала.*)

Дүртенчесе. Сайлама, сайлама, алай иттереп сайлагач, һәркем дә отар.

Өченчесе. Монда миңа дүрт дублит килгән. Алай итеп уйнагач, уен буламыни инде ул, китер монда шакмакларыңны! (*Шакмакларны тартып ала.*)

Икенчесе. Кит аннан, кеше алдыннан ни эшкә шакмакларын тартып аласың?

Дүртенчесе. Китер, китер, өләшеп бирәбез.

Читтән карап торучының берсе. Шулай кирәк, шулай, правила буенча өләшергә тиеш!

Икенчесе. Монда правила көтеп торсаң, авызыңны ачып калырсың!

Дүртенчесе. Кара әле, хәерсезне, җыен алтылыкны бер кулга җыеп бетергән!

Икенчесе. Кулыңнан килсә, син дә җый, мин сиңа бер сүз дә әйтмим.

Дүртенчесе. Мин синең шикелле шулер түгел. Син генә ул, һәммә шакмакларны билгеләп бетергән.

Ө ч е н ч е с е. Йә, өләшсәң өләш инде, нәрсәгә вакыт әрәм итеп утырасың?

Б е р е н ч е с е. Кая, син миңа акчаны бирмәдең ич! Әле монда акчагыз ким, кайсыларыгыз бирмәгән?

Ө ч е н ч е с е. Мин башта ук бирдем, әнә ул ун тиенлек мин биргән акча.

Д ү р т е н ч е с е (*өләшә-өләшә*). Мин дә башта ук бирдем, унбиш тиен биреп, биш тиен кайтарып алдым.

Б е р е н ч е с е (*Икенчегә*). Алай булгач, син әле монда бирмәгән.

И к е н ч е с е. Нәрсә? Мин сиңа бая ук әйттем ич, ун тиенең миндә булыр, дип.

Б е р е н ч е с е. Юк, ул алай ярамый. «Динги на кон». Монда һәркем дә синең шикелле акча оттырып утыра.

Б и ш е н ч е с е. Ул һәрвакытта шулай. Вакытында алып калмасаң, эченнән тына да кала.

Ө ч е н ч е с е. Ягез инде, зинһар, тизрәк булыгыз, нәрсә вакытны уздырасыз, кемгә чыгарга?

Б е р е н ч е с е. Хут менә моңа, иң әүвәл акчасын түләсен дә, аннан ары чыгар!

Ишектән Дежурный, кереп, карап тора.

И к е н ч е с е. Исең киткән икән шул ун тиен акчаңа, мә ал, бу кадәр җылак булырсыз икән!

Д е ж у р н ы й. Әфәнделәр, зинһар, бераз кеше төслерәк кылансагыз ла. Бер-берегез белән кычкырышып, клубта тавыш чыгармагыз.

Д ү р т е н ч е с е. Син – дижурный кеше, син карарга кирәк. Сезне бит шуның өчен старшина итеп монда сайлап куйган.

Б е р е н ч е с е. Бу да бит старшина. Старшина була торып, үзе правиланы бозып утыра.

Ө ч е н ч е с е. Иштегез, бу юлы өләшкән булып җыен дублитны миңа тутыргансыз!

И к е н ч е с е. Бер дә шаулама, менә хәзер мин синең бер дублитыңа бирәм. Миндә менә монда чыгарга бер дублит та юк, мәгез сезгә алты да өч!

Ө ч е н ч е с е. Менә, менә анысына рәхмәт, чуен юлы китте! Йә, яса син өч тә өч!

Б е р е н ч е с е. Өч тә өч ясарга аңа ерак әле.

Д ү р т е н ч е с е. Кара әле, валлаһи, бер рәтле нәрсә килмәгән. Әйдә куегыз, мин – пас!

С е б е р б а е белән Я у ч ы, кереп, карап торалар.

### ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Шулар ук һәм Себер бае белән Яучы.

Бишенчесе. Тукта әле, алай булса, мин бик кызык итим әле, өч тә өчне куйыйм! Йә, капла!

Беренчесе. Бик шәп иттең, миндә алтыдан күп нәрсә юк иде. Мә, рәхәтләнегез, алты да буш!

Икенчесе. Сиздек эшеңне, син бушлайга уйныйсың икән! Тора тор әле! Менә ул, өч тә өч булып торсын әле. Куй әйдә!

Өченчесе. Юк миндә, әйдә куй!

Дүртенчесе. Чын хәерсезләр икән, кара әле, валлаһи, биш шакмактан берне дә куя алмыйча утырам. Каплагыз, зинһар, шуның өчлесен, ул өчлегә уйный.

Икенчесе. Шулаймы, уйныйм шул, сайлап ала дигән идең, ник куймадың?

Дүртенчесе. Куярмын әле, бер дә кәпрәймә, өчләләрең белән әллә кая бара алмассың!

Икенчесе. Барганны карап торырсың. Ничек итеп кенә барырмын!

Бишенчесе. Мәгез, бер башын мин әчтем. Мәгез өч тә дүрт!

Беренчесе. Маладис ул эшеңә! Минем дүртле дублит китте.

Дүртенчесе (*Икенчегә*). Нихәл, ни эшләттеләр? Ачасыңмы өчлекне?

Икенчесе. Бер дә ачмый торсын әле! Миндә аннан башкалары да җитәрлек әле! Мәгез дүрт тә алты!

Дүртенчесе. Чын хәерсез икәнсең! Ябыгыз тизрәк шуның өчлесен!

Өченчесе. Шулай итикмени? Мәгез алайса, алты да биш булсын.

Дүртенчесе. Менә монысы ярады, ягез әле, менә сезгә мин биш тә бишле дублитны куеп җибәрим әле!

Бишенчесе. Шулай иттегезмени, тукта әле, алай булса, мин тагы алты да алты ясап җибәрим әле. Йә, каплагыз!

Беренчесе. Мин – пас! Алтылы тәмле булыр әле ул.

Икенчесе. Юк. Мин дә – пас!

Дүртенчесе. Ә, шулаймы, нихәл, пас булдыңмы? Синең шикеллеләрне шулай итәләр аны. Өч тә өч ясап бик кабарынып утырган идең!

Өченчесе. Мин дә – пас!

Дүртенчесе. Икесе дә моның үзендәдер лә инде ул!

Б е р е н ч е с е. Булса, нәрсә карап утырасың инде? Йә, ал инде!

Б и ш е н ч е с е. Уйнамагыз, егетләр. Ике башы да миндә, кая, китерегез акчаларыгызны!

Икенчесе урыныннан торып китә.

Б и ш е н ч е с е. Кая барасың, акчаңны түләп кит!

И к е н ч е с е. Мин уйнамыйм.

Б и ш е н ч е с е. Уйнамасаң уйнамассың. Монда акчаңны түләп кит әле!

Д е ж у р н ы й. Әфәндем, алай ярамый, акчагызны түләп китегез!

И к е н ч е с е. Кит аннан, акчам юк! (*Чыгып китә.*)

Д ү р т е н ч е с е. Уенга кертергә кирәк түгел аны, һәр көнне ул шулай, оттырды исә, акчасын түләмичә чыга да китә!

Ө ч е н ч е с е. Бер дә килешә торган эш түгел инде.

Д ү р т е н ч е с е. Җитмәсә тагы, үзе старшина! Старшиналарыбыз әүвәле үзләре тәртип белмиләр!

Ө ч е н ч е с е. Тәртип белмәгән кешене сезгә сайларга да тиеш түгел.

Б е р е н ч е с е. Сайламыйча, кемне сайлыйсың? Бер кеше дә сайланмый. Акчасызга кемнең хезмәт итәсе килә?

С е б е р  б а е (*Язучыга*). Сезнең бар нәрсәгез дә кызык икән. Җәмгыятегезгә барсаң, анда талаш, клубыгызга килсәң, анда кычкырыш, ресторанларга керсәк, анда җәнҗал! Әллә сез шәһәрегездә талаш, кычкырыш, җәнҗал белән генә тамак туйдырасызмы?

Я у ч ы. Юк ла, алай ук түгел лә, сез генә әле, әллә ничек, шундый вакытларга туры киләсез.

Д ү р т е н ч е с е. Әйдә өләшегез, дүртәү генә уйныйбыз.

Д е ж у р н ы й. Юк, әфәнделәр, сәгатегез тулды инде, уйнарга вакыт бетте!

Д ү р т е н ч е с е. Тулса, икенче сәгатькә алабыз.

Д е ж у р н ы й. Юк, хәзер лото башлана.

Б е р е н ч е с е. Кая, кем белән башлыйсыз? Лотога монда кеше юк ич әле.

Д е ж у р н ы й. Теге якта кеше күп, хәзер керәләр. (*Икенче бүлмәгә чыгып.*) Кая, кем, звонок бирегез, лото сата башлагыз.

Икенче якта звонок тавышы ишетелә. Бүлмәгә х а л ы к керә башлый. Кайсы кайда, кайсы кайда урыннар алып, утыра башлыйлар.

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Шулар ук һәм лото уйнаучы халык.

Лото әйләндерүче (*кычкыра*). Әфәнделәр, лату башлана!

Себер бае (*Яучыга*). Нәрсә ату башлана инде?

Яучы. Юк, бернәрсә дә ату башланмый, лата дигән уен башлана.

Залда тавыш күтәрелә, һәркайсы, бер-берсе белән сөйләшеп, шаулаша башлыйлар. Карта сатып алалар.

Күзлекле бер кеше. Гариф, Гариф, кара әле, син миңа икесе дә бертөслене биргәнсең, кая, берсен алмаштырып бир!

Читтән тавышлар. Юк, юк, алмаштырыш юк, бирмәгез, бирмә!

Себер бае. Сезнең монда тавыш бер дә артильный мунчадан ким түгел икән!

Дежурный (*Себер бае янына килеп*). Әфәндем, сез, ахры, мондагы кеше түгелсездер?

Себер бае. Юк, әфәндем, мондагы түгел, читнеке. Шәһәрегезгә бер эш белән генә килгән идем дә клубыгызны да карап чыгыйм дип кердем. Әле шуны әйтеп торадыр идем, монда сезнең һич кирәкмәгәнгә бик шаулашалар икән.

Тавыш һаман дәвам итә.

Дежурный. Шулайрак шул, нихәл итмәк кирәк. Әле клублар безнең арада яңарак бер эш. Халык ияләнеп җитмәгән, тавышланудан тыйсаң, аннан ары клубны бөтенләй ташлап, килмәс булалар. Шуңа күрә ихтыярлы-ихтыярсыз түзелә инде. Рәхим итегез, утырып карап торыгыз, әле музыка башланырга шактый вакыт бар.

Себер бае, Яучы урындыкларга утыралар.

Серый киемле (*бүлмәнең икенче башында утырган бер кешегә картасын күрсәтеп*). Кәрим, Кәрим, миңа теге кичәге бальшуйны алган карта чыккан.

Почмакта утырган кеше. Шаулама инде. Алайса алабыз, билләһи, алабыз!

Кара киемле берсе. Гариф, синдә 17 ле бармы?

Гариф. Юк.

Кара киемле. Миндә 17 ле икәү. Миндә ике 5 ле, ике 17 ле, ике 36 лы, ике 49 лы бар.

Гариф. Зарар юк. Алар чыга торган сифрлар.

Лото әйләндерүче (*звонок шалтыратып*). Са-

тылган – 28 карта, 7 сум. 70 тиене клубка. Малый – 60, бальшуй – 1 сум 25 тиен.

Халыктан берәү. Ни эшләп алай?

Лото әйләндерүче. Бальшуйга 5 тиен артык.

Халыктан берәү. Ярый, болгат!

Лото әйләндерүче. Беренче уен. Первый – 49.

Серый киемле. Миндә юк.

Гариф. Шауламагыз! Ничек дисең?

Халыктан берәү. 61!

Кара киемле. Шауламагыз әле!

Почмактагы кеше. Тише!

Лото әйләндерүче (*звонок бирә*). 49, 36!

Гариф. Капла, Җәләли, 36 ны, әйттем бит ул чыга дип!

Халыктан берәү. Шауламагыз инде!

Лоточы. 3!

Кара киемле. Гариф, тирный булды!

Лоточы. 23, 14, 59!

Кара киемле. 49 диген!

Лоточы. 16!

Кара киемле. Ах!

Лоточы. 42, 43!

Халыктан берәү. Сана шулай, кырык 4 диген!

Лоточы. 39!

Кара киемле. Гариф, миндә фатир булды.

Лоточы. 34!

Кара киемле. 5 диген, 5!

Лоточы. 12!

Кара киемле. 5!

Лоточы. 4!

Кара киемле. 5!

Гариф. Миндә дә фатир бар!

Кара киемле. Бальшуйдамы?

Халыктан берәү. Болгат!

Лоточы. 6!

Берәү. Готова!

Почмакта утыручы. Нәрсә?

Кара киемле. Каһәр суккан икән! (*Картасын күтәреп бәрә.*) 5 ле фатир ни гомердән бирле торды бит!

Халыктан берәү. Минем дә 60 лы фатир янды.

Икенче берсе. Страхавайт итәрләр аны, ул вакытта янмас иде.

Лоточы (*тулган картаны килеп алып*). Малый. (*Барабан янына барып.*) 6, 14, 23, 36, 42 – дөрес.

Гариф. Шаулама, малый гына китте әле, бальшуйны без алабыз!

Почмакта утырган кеше, урыныннан торып, икенче почмакка барып идәнгә утыра.

Серый киемле. Кәрим, ни эшлисең анда?

Кәрим. Теге урын бик бәхетсез икән. Бары икене генә ябып калдым.

Гариф. Анда барып утырганчы, син менә монда, өстәл астына кереп утыр!

Кәрим. Утырырмын шул, анда синең эшең булмасын!

Лоточы (*звонок биреп*). Икенче уен, малый – 60 тиен, бальшуй – 1 сум 90 тиен.

Халыктан берәү. Тыңлагыз, җәмәгать, яңа көйне әйтә.

Лоточы. 60!

Серый киемле. Әйт шуны!

Гариф. Бая миңа кирәк иде ул. Бая 60 лы фатирым янды!

Лоточы. 51!

Берәү. Үзеңә булсын!

Лоточы. 17!

Кәрим. Үктәбрис!

Гариф. Болгат!

Кәрим. Болгатма, болгатма, харап итәсең, хәзер миндә фатир була!

Лоточы. 9!

Кәрим. Менә, менә монысы ярый.

Халыктан берәү. Нәрсә син анда лыгырдап ятасың?

Лоточы. 13!

Берәү. Яхшылап болгат әле, гел баягыларны әйтәсең.

Лоточы. 29!

Берәү. Менә шулай. Тагы 32 не әйт!

Лоточы. 40!

Берәү. Ә менә монысы ярамады!

Гариф. Шауламагыз инде, зинһар, әллә монда базар дип белдегезме?

Лоточы. 48!

Кәрим. Була, була!

Лоточы. 33!

Кәрим. Айт! 32 дисә...

Лоточы. 32!

Кәрим. Һап! Фатир булды!

Лоточы. 12!

Кәрим. Эһем! (*Урыныннан сикереп торып, барабан янына бара.*)

Лоточы. 11!

Кәрим. Һай!
Лоточы. 4!
Ике җирдән тавыш. Булды, готова!

Халык шауларга тотына.

Гариф. Әйттем бит, алабыз, дип!
Кара киемле. Бальшуймы?
Гариф. Юк, малый. Әй, малай!
Кәрим. Каһәр икән, шунда 3 дип әйтмәде бит, бальшуй буладыр иде!
Халыктан берәү. Ничәле дисең?
Кәрим. 3 ле лә!
Берәү. 3 ле булса, икәү уртаклыйдыр идек.
Гариф. Әйттем бит мин сиңа, өстәл астына кереп утыр, дип, чыгар иде. Малай! Кая, миңа бер стакан чәй, ике сумса китер әле.
Кәрим. Тыгыныгыз инде безнең акчага!
Лоточы. Ике малый – 4, 12, 29, 33, 40, 4, 13, 29, 33, 48 – дөрес. (*Акчаларны китереп бирә.*) Өченче уен, малый – 60, бальшуй – 2 сум 55 тиен.
Гариф. Менә бу юлы бальшуйны алырга расчет бар.
Лоточы. 52!
Берәү. Тукта әле, мин карталарны рәтләмәгән, ничә?
Лоточы. 52, 45, 15!
Кәрим. Болгат!
Лоточы. 53, 34, 20!
Кәрим. Болгат!
Лоточы. 10, 8, 6, 1!
Кәрим. Болгат, дим!
Лоточы. 31!
Берәү. Стоп!
Кәрим. Әбәү!
Гариф. Нихәл, болгаттымы?
Кәрим. Бигрәк тиз. Бары 12 генә шакмак чыккан.
Гариф. Беркөнне теге клубта бары 6 гына шакмак чыкты. Берәү бальшуйны алды.
Кәрим. Анда чыга. Мин дә әле бүген, моннан чыккач, анда барам. Ичмасам, анда барып оттырсаң да стует. Мин беркөн анда 24 тәңкә бальшуй алдым.
Лоточы. Бальшуй! 1, 15, 20, 31, 45, 52! Рәхим итегез!
Берәү. Мә сиңа 5 тиен чәйлек!
Лоточы. Кит аннан, бальшуй алып та 5 тиен генә бирергә!
Кәрим. Син миңа бальшуйны чыгар, билләһи, мин 10 тиен бирәм!
Гариф. Мин 15 тиен!

Серый киемле. Мин 20 тиен!

Халыктан берәү. Кем арттыра, юкмы тагын арттыручы?

Лоточы. Дүртенче уен, малый – 60, бальшуй – 1 сум 25 тиен.

Кара киемле. Хәзер уенның тәме китте инде.

Лоточы. 6, 12, 9, 7, 3, 2!

Кәрим. Бигрәк вактан турый башладың!

Лоточы. 1!

Кара киемле. Менә тагы сиңа, башкаларын яратмасаң!

Серый киемле. Берлеләрнең барын да әйтеп бетерә инде!

Лоточы. 60!

Кәрим. Уһу! Сразы югары менеп китте!

Халыктан берәү. Тише!

Лоточы. 30, 43, 14, 21, 31, 40!

Кәрим. Бол... Болгат!

Кара киемле. Нәрсә кешене куркытып утырасың?

Лоточы. 39!

Хатын-кыз тавышы белән берәү. Давольне!

Гариф. Яна 50 тиен!

Халык шаулый.

Лоточы. 2, 14, 21, 39, 43! Малый. (*Акчаны бирә.*) Актык уен, азы саналмый. 28, 3, 16, 5, 9, 29, 39, 43, 4, 12!

Кара киемле. Шул 12 һаман чыга!

Лоточы. 50, 45, 54, 17, 6, 11!

Берәү. Стоп!

Кәрим. Каһәр икән, тагы шул алды!

Халык шауларга тотына.

Серый киемле. Нигә ул кадәр каты кычкырасың, әллә ишетмәсләр дип беләсеңме? Бигрәк бизабрази кылынасыз!

Берәү. Үзеңә чыкмаганга ачуың киләмени, үзеңә чыкса, үзең дә кычкырыр идең әле!

Ишектән бер дама килеп керә. Халык һәммәсе кинәттән туктап, һәммәсе дә шып булалар, һәркайсы даманы карарга башлыйлар.

Себер бае (*Дежурный янына барып*). Серләрегез мәгълүм булды. Сезнең тавышыгызны туктатырга бер хатын кеше булса җитә икән.

Дама чыгып китә. Халык янә шауларга тотына.

Монда тагы моннан башка берәр эш буламы?

Д е ж у р н ы й. Рәхим итегез! Менә хәзер музыка башлана.

Икенче якта звонок була. Халык чыгып китә.

С е б е р б а е. Аннан соң?

Д е ж у р н ы й. Аннан соң тагы лото уйнала.

С е б е р б а е. Аннан соң?

Д е ж у р н ы й. Аннан соң, аннан соң янә музыка, янә лото.

С е б е р б а е. Башка юк?

Д е ж у р н ы й. Домино уйнала.

С е б е р б а е. Башка юк?

Д е ж у р н ы й. Юк.

Икенче якта музыка уйный.

С е б е р б а е. Әйдә алайса, киттек музыка тыңларга! Лото, домино, музыка! Лото, домино, музыка! Шул өч нәрсәне бергә кушкач, була, ди, клуб!

Чыгып китәләр.

П ә р д ә.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘНЗАРӘ

Базар чатында.

Базар чаты. Халыктан караганда уң һәм сул якта шкафлар, каршыда кибетләр. Шкаф алларында эшсез халыклар җыелып торалар. Базардан халыклар узгалап йөриләр. Уң яктагы шкафта берничә кәләпүшләр, шешәләр, тасмалар вә башка вак-төяк галантерея тартмалары күренә.

### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ш к а ф ч ы, м ө р и т л ә р, х а л ы к, соңра к ә л ә п ү ш ч е к ы з.

Ш к а ф ч ы (*үзенең алдына җыелган мөритләргә*). Бик яхшы иткәннәр, бик яхшы. Мин аларга рәхмәт әйттем. Бу эшегезнең әҗерен, Алла боерса, кыямәттә күрерсез, дидем. Аларның хәрам акчаларын алып, җәмгыятьне мордар ясарга ярамый, дидем. Әдәбият кичәсе, имеш! Анда авыз күтәреп җырлыйлар, ди, сөйлиләр, ди. Җыен кызыл авызлар, чыгып, скрипкә, гармун уйныйлар, ди, кочаклашып биешәләр, ди. Ул нинди әдәбият кичәсе булсын?! Анда нинди әдәп булсын? Ул әдәпсезлек кичәсе ул! Кем дә кем мөселманча итеп, менә шуның шикелле кы-

---

М о р д а р – шакшы.

зыл төймәле казакилар кисә, башына ак бүрек кисә, мыегын сөннәтчә итеп кырып йөртсә, чалбар балагын озын итеп йөртмәсә, чәчен алдырса, өендә идәнгә тезләнеп, кыйблага каршы утырып ашаса, хәзрәтләр алдында тез чүгеп кенә утырса, йөргән чагында да алдына гына карап йөрсә, муллалардан алга чыгып сүз сөйләмәсә, менә шул кеше чын әдәпле кеше булыр.

Халык. Дөрес әйтәсең, мулла Әхмәтҗан, дөрес!

Шкафчы. Ул җәдитләр барысы да кяферләр алар, барысы да җәһәннәмлекләр алар!

Халык. Рәхмәт, рәхмәт!

Шкафчы. Аларның каннары – хәләл, маллары – ганимәт, хатыннары – талак!

Берәү. Шулай укмыни, мулла Әхмәтҗан? Анысын сез белми әйтми торгансыздыр.

Шкафчы (*прилавкага аякларын бөкләп менеп утырып*). Аларның һичберсенең никахлары дөрес түгел. Алар динне мыскыл итеп, кыска киемнәр киеп, аякларына шиблит, башларына картуз киеп, чәчләрен-мыекларын җиткереп, кулларына әллә нинди шәйтан мөгезе шикелле таяклар тотып, ак якалар куеп, корсакларын киереп йөриләр.

Мөритләрдән берсе. Аларның муеннарына игәннәре нәгъләт камыты инде ул, нәгъләт камыты!

Бер сала кешесе тәмәке тартып узып бара.

Шкафчы (*акырып*). Һай, нәгъләт, ташла тәмәкеңне, ташла!

Сала кешесе илтифат итмичә узып бара.

(*Урыныннан сикереп төшеп.*) Ташла, дим, нәгъләт, ташла! Һи, оятсыз! (*Йөгереп барып, авызыннан тәмәкесен тартып алып, аяк астына салып таптап.*) Ничек итеп шулкадәр мөселманнар алдында, базар уртасында тәмәке тартып барасың?! (*Урынына килеп, яңадан аягын бөкләп утыра.*)

Сала кешесе аптырап карап тора да кулын селтәп китә.

Мөритләр. Менә монысы өчен рәхмәт, яхшы иттең.

Шкафчы. Шәригать әмере мәгъруф, нәһи мөнкәр кылырга боерган. Әле ярый ташлады. Ташламаса, мин аның яңагына да менеп төшкән булыр идем.

---

Ганимәт – трофей.

Әмере мәгъруф, нәһи мөнкәр кылырга – яхшы эшкә кушарга, яманны тыярга.

Б е р  м ө р и т. Шулай шул, ник монда мөселманнарны мәсхәрә кылып бара! Әйдә, Ибраһим, чәйгә керәбез, син дә керәсеңме?

Ш к а ф ч ы. Барыгыз, бар, ике дә өчне әйтә торыгыз, мин хәзер кереп җитәм.

Б е р  к е ш е (*шкаф янына килеп*). Әфәнде, миңа бер ярты дюжина гына ак яка кирәк иде.

Ш к а ф ч ы (*бик коры гына*). Юк!

Б е р  к е ш е. Мин мондагы түгел идем, кайдан табарга мөмкин булыр икән?

Ш к а ф ч ы. Кит аннан, кит, кит, кит! Мин нәгъләт камыты белән сату итмим!

К е ш е. Ник, ул нәгъләт камытымыни?

Ш к а ф ч ы. Кит, дим, кит, кит! Кәсафәтең йогар, кит! Сезнең шикелле динсезләр белән сөйләшәсем дә килми!

К е ш е. Сез мине ни өчен мәсхәрә кыласыз? Мин ничек динсез?

Ш к а ф ч ы. Җәдит син, җәдит! Аягыңа кара! Хи-хи-хи!

К е ш е. Синең бар эшең, ахры, шул: кешегә көфер пичәте басып утыру гына булырга кирәк. Әйтәләр иде аны, сезнең базар чатында Көфер почмагы дигән җир бар, дип. Шушы икән инде, ярый, күрдек. (*Китә.*)

Ш к а ф ч ы. Авызы тыгылдымы малаеңның! Хи-хи-хи-хи!

М ө р и т л ә р. Рәхмәт, мулла Әхмәтҗан, рәхмәт, шулай кирәк.

Ш к а ф ч ы. Каһәр төшкән җәдит! Ак яка дип сорап ята бит! Бирермен мин ак якаларыгызны! Үзегез белән бергә ак якаларыгызны җәһәннәмгә салып яндырырмын!

К ы з (*бер төргәк кәләпүш китереп*). Абзый, кәләпүш алмыйсыңмы?

Ш к а ф ч ы. Кызый үзе бик чибәр икән! Кая, китер әле, карап карыйк. (*Кәләпүшләрне карап.*) Моны үзегез эшләдегезме?

К ы з. Әйе.

Ш к а ф ч ы. Апаң бармы?

К ы з. Йә, аласыңмы?

Ш к а ф ч ы. Апаң бармы? Апаң булса, алам. Апаң матурмы?

К ы з. Йә инде, шаярма, алсаң ал, алмасаң, бир кәләпүшләрне.

---

И к е  д ә  ө ч – сәүдәгәрләр жаргоны, «ике чәй, өч пәрәмәч» дигән сүз.

К ә с а ф ә т – каралык, динсезлек.

Бер мөрит. Апасы да, моңа охшаса, чибәр булыр!

Шкафчы. Апаң булса, апаңа әйт, кәләпүшләрен алмыйм, үзен, матур булса, кече хатынлыкка алам, дип әйтте диген!

Кыз. Китер инде! (*Кәләпүшләрне тартып ала.*) Лыгырдап утырасыз шунда, чүбек чәйнәп! Кәләпүш алырга әле синең акчаң юк! (*Китә.*)

Мөритләр. Ха-ха-ха-ха! Ни эшләтте кызый?

Бер мөрит. Үсеп җиткәч, бу әле әллә нинди атчайный кыз булыр!

Шкафчы. Безнең урамдагы Галим кызы ул, аталары үлгәч, кәләпүш эшли башладылар. Тутасы бик нәгыз нәрсә аның. Күкрәкләре менә болай!

Бер мөрит. Монысы да яман булмас. Бер-ике елдан таза гына хайван булыр. Хәзердән үк күкрәкләре калка башлаган!

Ике шәкерт, кыска киемнәрдән, узып баралар.

Шкафчы. Шифырт, шифырт! Итәкләрегезгә абынып егылмагыз! Һи, күмер караклары!

Шәкертләр. Лыгырдама, чухур! (*Китәләр.*)

Мөритләр. Ха-ха-ха! Алай да үзең бер дә тешләми уздырмыйсың!

Бер мөрит. Мулла Әхмәтҗан ул барысын да булдыра.

Халык бар тарафтан йөгерә башлый.

Шкафчы. Нәрсә бар анда? Нәрсәгә йөгерәләр?

Мөритләр ашыгып китәләр. Шкафчы да шкафына аркылы бер таяк куеп китә. Бераздан икенче шкаф янына кешеләр җыела.

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Юан кеше, Нечкә кеше, Сары сакал.

Юан кеше (*шкаф янына сөялеп*). Ишеттегезме яңа хәбәр, әле менә чәй янында укыдылар.

Нечкә кеше. Нинди хәбәр?

Юан. Чалма Афстралияне Макидуниядән куып чыгарган икән.

Сары сакал. Аны инде беркөннәрдә үк укыдылар.

---

Нәгыз – шәп, гүзәл, әйбәт.
Чухур – сатучыларны мыскыллау сүзе.
Чалма – Төркия күздә тотыла.

Афстралия дисезме, нәрсә дисез әле, бер көн эчендә шуның җитмеш мең солдатын кырганнар, ди.

Нечкә. Дөрест сүз булды микән, чалмага әгелчән пумукка бик күп солдат җибәргән икән дигәннәр иде.

Юан. Юк сүз. Әгелчән нишләп солдат бирсен? Чалманың аның үз солдатлары да ничә милиунлап бар бит.

Сары сакал. Чалманың аның кораллары да бик шәп, ди. Аларда менә шушылай беләккә кия торган бертөрле мылтык бар, ди, бер минут эчендә ике йөз тапкыр ата, ди. Һичкем каршы килә алмый, ди.

Юан. Аларга сугышта каршы тора ала торган кеше бу заманда бер дә юк инде. Аларның туплары да бик еракта ала, ди.

Сары сакал. Алар бит бер елны грикләрне дә ни эшләттеләр! Грикләрнең Фисалия дигән зур бер крипечләре бар икән. Ничә милиуннарга төшереп салганнар икән. Ягрупа шул вакытта әйткән иде: «Бу крипечне алты ел сугышсалар да ала алмаслар», – дип. Чалмалар шуны бер көн эчендә алдылар.

Юан. Чалмага каршы аңа кеше чыдый алмый инде. Бисмарк әйткән, ди: «Әгәр дә ун ел эчендә Туртсияне бүлеп алмасагыз, аннан соң пузны булыр», – дип әйткән, ди.

Нечкә. Әле беркөн әгелчәннәргә каршы афганнар сугыш ачканнар, имеш, дигәннәр иде. Бу арада бер дә ул турыда хәбәрләр күренми.

Юан. Юк сүздер ул. Афган хәзер үк сугышмас әле, ул берничә ел хәзерләнер дә аннан соң әгелчәннәргә каршы чыгар. Афган ханы инде ул бик күптәннән бирле Һиндне алырга кыҗрый. «Ни эшләсәм дә эшлим, Һиндне алмыйча туктамыйм», – дип әйтә, ди. Афганнар да алар бик сугышчы халык. Бер тотынсалар, әгелчәннең эшен китермичә бер дә туктамаслар.

Нечкә. Әле соң япун ни эшли, япун?

Юан. Япунның эше шәп аның. Япунның патшасы Микаду мөселманлыкка чыгарга юл эзли икән, ди. «Әгәр дә Чалма риза булса, мин бөтен гасударствам белән мөселманлыкка чыгар идем», – дип әйтә икән, ди.

Сары сакал. Япун патшасы инде ул үзе күптән мөселманлыкка чыккан, ди. Бары тик әле халкын мөселман итә алмаганга гына аптырый, ди.

Нечкә. Юк сүзләр. Патшасы үзе мөселман булгач, аның халкын мөселман итәргә көче җитмәс идемени?

Юан. Юк, тора тор әле, алай бик тиз генә булмый ул. Халык ул пркәшшек түгел. Бу заманда инде пркәшшеккә дә тиз генә сүз тыңлатып булмый. Әле менә пркәш-

шекләр: «Кибетләр иртә белән сәгать сигездә ачылсын да, кич белән сәгать җидедә ябылсын», – дип йөриләр. Атнасына бер көн кибет ябылу гына җитмәгән, аның өстенә син тагы кибетне дә иртә яп. Хәзер инде байлар хуҗа түгел, пркәшшекләр хуҗа. Әүвәлге заманнарда без салкын кибеттә иртә белән сәгать биштән башлап кара төнгә кадәр сату итәдер идек, алай да байга тиз генә ярап булмыйдыр иде.

Сары сакал. Алар шул хәзер клубка барып гуләйт итәргә өйрәнделәр инде. Төне буена клубта утыралар да аннан ары көн буена аңгы-миңге килеп йөриләр.

Нечкә. Губернаторга әйтеп, аларның клубларын яптырырга кирәк иде.

Юан. Бик күп йөреп карадык инде. Булмый, ди. Әле менә бу көн әллә нинди кәмит ясыйлар икән. Аны ясатмаска кирәк дип, пристефкә барган идек, анда закунга каршы килә торган бернәрсә дә булмагач, без тыя алмыйбыз, диде. Ул бит безнең шәригатьтә дөрес түгел, дигән идек, дөрес булмаса, бармассыз, ди.

Сары сакал. Карга карганың күзен чыгармас, ди. Алар инде аңа шатланалар гына.

### ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Шулар ук һәм Шкафчы, мөритләр, соңра Школьник, Мужик, Себер бае, Driver Язучы, кеше вә халык.

Шкафчы килеп, аягын бөкләп утыра. Аның артыннан мөритләр дә киләләр.

Шкафчы. Бик яхшы иттеләр. Этнең бәддогасы төшсә, бөтен кеше һәлак булып бетәр иде.

Бер мөрит. Бервакытны шулай Истанбулда бер солтан урамдагы этләрне җыярга кушкан. Шәһәрдәге бар этләрне җыеп, бер атауга илтеп ташлаганнар. Шуннан соң, этләрнең күз яшьләре тотып, шәһәрдә халык кырыла башлаган. Бик каты ачлык булган. Шуннан соң солтан, тәүбә итеп, этләрне кире кайтарткан. Авыру да беткән.

Шкафчы. Этләрне бер дә бирергә ярамый. Мин һәрвакытта, эт тотучылар килсә, этләрне качырам. Эт үтерсәң, аның афәте бик зур була.

Теге шкаф алдындагы кешеләр дә җыелалар.

Юан. Нихәл, анда нәрсә бар иде? Халык ни эшкә җыелган?

---

Школьник – махсус киемнән йөрүче Татар укытучылар мәктәбе (Татарская учительская школа) укучысы.

Шкафчы. Эт үтерүчеләр килгәннәр. Күмәчче Галәвинең этен тотып алып китәләр дигәндә генә, көчкә генә сызгырып котылдырып калдык. Эт үтерүчеләрнең бөтенләй ачулары кабарды.

Бер мөрит. Кабармый ни, алар бит акчаны эт башыннан алалар. Мулла Әхмәтҗан, син сызгырып бик яхшы иттең. Ахирәттә аның өчен сиңа зур әҗер булыр.

Ике школьник узып бара.

Шкафчы (*иснәштергәләп*). Фу, колак исе чыга. Мәскәү яна!

Юан. Нихәл, егетләр, җилән кысмыймы?

Школьник. Не лай, собака!

Кереп китәләр.

Шкафчы. Менә шулар инде бөтен дөньяны каралтып бетерүчеләр, динсезләр. Боларның кырыгына бер иман да юк инде!

Бер яктан бер Мужик бер тире күтәреп килә. Аның каршысына икенче яктан биш-алты кеше, йөгереп килеп, һәммәсе дә тирегә ябышалар.

Берсе. Ничә тиен?

Мужик. 1 сум 30 тиен.

Берсе. Башыңа капла, әйдәгез, әйдә, сатарга китермәгән ул!

Китә башлыйлар. Бер читтә Себер бае белән Яучы килеп чыгып, карап торалар.

Мужик. Соң, күпме бирәсез?

Берсе. 70 тиен!

Мужик. Юк, алай ярамый.

Берсе. Ну, 75 тиен.

Мужик. 1 сум 10 тиен.

Икенчесе. Әйдәгез, әйдә!

Берсе. Ну, 80 тиен.

Мужик китә.

Ну, 90 тиен.

Мужик. Бирегез акчагызны.

Берсе акча чыгарып бирә. Тирене алалар да кереп китәләр.

Себер бае. Алар ни эшлиләр?

Яучы. Тире алалар.

Себер бае. Ничә мең тире?

Яучы. Юк, бер генә.

Себер бае. Нигә соң бер тирегә ул кадәр җыелганнар?

Яучы. Бездә шулай инде: берсе ала да, калганнары файданы бүлешәләр.

Себер бае. Шәп икән! (*Шкафны күрсәтеп.*) Ә монда халык ни эшкә җыелган? Әллә бу сезнең биржагызмы?

Яучы. Юк, биржа түгел, бу – безнең шәһәрнең могтәбәр кешеләре җыела торган җир.

Себер бае. Анда соң алар ни эшлиләр?

Яучы. Анда төрле сүзләр була.

Себер бае. Әйдә алайса, без дә барып тыңлап торыйк әле. Берәр файдалы сүз ишетербез.

Киләләр.

Әссәламегаләйкем!

Шкафчы. Вәгаләйкемәссәлам сәламен дә, сезгә ни кирәк? Әгәр ак яка кирәк булса, миндә юк, йөрмәгез!

Мөритләр. Ха-ха-ха-ха!

Себер бае. Ник алай дисез?

Шкафчы. Чүлмәкнең тышыннан билгеле. Җәдит икәнлеге әллә кайдан күренеп тора!

Себер бае. Җәдит булгач ярамыймыни? Сез җәдитләргә әйбер сатмыйсызмыни?

Шкафчы. Кит аннан! Кит, кит, кит! Без андый паганый маллар белән сату итмибез.

Себер бае. Хәерле булсын! (*Китә. Яучыга.*) Сезнең могтәбәр кешеләрегез шулармыни инде?

Яучы. Шулармыни дип, болар гына түгел инде, әле монда барысы да җыелып җитмәгән.

Себер бае. Сезнең монда бөтен дөньяга исеме җәелгән «Көфер почмагы» дигән чатыгыз кайда? Килгән көе ул чатыгызны да күреп китик инде.

Яучы. «Көфер почмагы»?

Себер бае. Әйе, узган-барганга эт шикелле өреп кала торган бер почмак бар, диләр иде.

Яучы. Белмим, ул кайсы булыр икән тагы? Аны инде җәдитләр әйтә торганнардыр.

Себер бае. Дөрес, укыганрак яшьләр авызыннан ишеткән идем.

Яучы. Алай булса, шул чатны әйтә торганнардыр инде, монда башка андый чат юк.

Себер бае. Алай булса, бераз сабыр ит әле, шунда кайда булса да сүзләре ишетелә торган бер урынга барып тыңлап утырыйк әле.

Яучы. Ярар.

Бер җиргә утыралар.

Шкафчы. Каһәр суккан нәрсә! Бүген икенче җәдит инде ак яка сорап мыскыл итеп килде.

Сары сакал. Ул ак яка сорамады ич!

Шкафчы. Сорамаса да билгеле инде. Аның башка нәрсә сорау ихтималы юк.

Бер мөрит. Кем соң ул?

Шкафчы. Чурт белә аны! Әфтәх каян килеп ияргән тагы ул җәдиткә?

Бер мөрит. Ә, беркөнне сөйләгәннәр иде, Себердән бер бай өйләнергә килгән, Әфтәх яучы булырга йөри икән дип. Шул нәрсәдер инде алайса.

Шкафчы. Ә, шул нәгъләт икән инде алайса, шул! Бая Фатих әйткән иде, бик кызык иттек, дип. Өченчекөн шул динсез җәмгыятькә кергән, анда теге тар балаклар, әдәбият кичәсе ясыйбыз, файдасын җәмгыятькә бирәбез дип, прашиния биргәннәр икән, бу динсез шунда яшьләрне яклап утырган була, ди. Фатихлар бик яхшы иткәннәр, моның авызын каплаганнар.

Бер мөрит. Рәхмәт аларга, бик яхшы иткәннәр.

Европача киенгән бер кеше таяк тотып узып бара.

Шкафчы. Менә тагы бер җәдит! Шайтан чакырып таягыңны селкеп йөрмә монда!

Җәдит (*туктап*). Нәрсә дисең?

Шкафчы. Исәнме, дим, исән торасыңмы, дим!

Мөритләр. Ха-ха-ха-ха! (*Көләләр.*)

Җәдит. Авызыңа телең сыймыймы әллә? Нәрсә лыгырдаган буласың? (*Килә башлый.*)

Шкафчы (*урыныннан сикереп төшеп*). Кит аннан, кит! Кит, кит! Кәсафәтең йогар, кит! Син кяфер, мордар!

Җәдит (*китә-китә*). Һи, хәбис, зверь!

Шкафчы (*артыннан бара-бара*). Кяфер сез, кяфер! Хи-хи-хи... (*Туктый.*)

Җәдит. Синең шикелле урам этләре бөтен урам буена өреп бара торганнар иде, әле син ул кадәр үк булдыра алмыйсың икән! Һи, падлис. (*Китә.*)

Себер бае. Утыру бушка китмәде. Бер картинаны күрдек.

Шкафчы (*урынына килеп, аягын бөкләп утыра*). Ул җәдитләрнең бар эшләгән эшләре хәрам, ашаганнары хәрам, эчкәннәре хәрам, йөргәннәре хәрам, торганнары хәрам, өсләренә кигәннәре хәрам!

Себер бае (*халыкка карап*). Ә адәм ите чәйнәү, көн буе гайбәт сатып утыру анысы хәрам түгел!

---

Хәбис – пычрак, шакшы.

Бер кеше шкаф янына килә.

Кеше. Кая, миңа бер мыскал гына дару бир әле.

Шкафчы. Нindине бирим, укмаштырганы булсынмы, бармаклысымы?

Кеше. Бармаклысын бир.

Шкафчы чыгарып бирә, акчаны алып сала.

Себер бае. Ул кеше дару белән сату итәмени?

Яучы. Итә.

Себер бае. Кара син аны, үзе кадим булса да аптик тота икән. Мин мөселманнан аптикче юктыр дип беләдер идем.

Яучы. Юк, ул аптикче түгел.

Себер бае. Соң ул нинди дару сата?

Яучы. Дару дип инде, дару түгел. Кеше белмәсен өчен аны шулай дип әйтәләр.

Себер бае. Нинди нәрсә соң ул?

Яучы (*Себер баеның колагына гына*). Әфиун ул, әфиун. Палитсә белмәсен өчен аны шулай дару дип әйтәләр.

Себер бае (*халыкка карап*). Шәп икән! (*Яучыга.*) Соң ул хәрам түгелмени?

Яучы. Ул ни эшләп хәрам булсын! Ул бит аракы түгел, хәрам булса, аны ишан хәзрәт тыяр иде. Ишан хәзрәт аны бик шифалы нәрсә ди. Әледән-әлегә мулла Әхмәтҗаннан берәр кадаклап алдырта. Бу кеше ишан хәзрәтнең бик якын кешеләреннән.

Себер бае. Соң ул исертмиме?

Яучы. Юк, аның һич тә исе сизелми, аны борчак кадәрле генә кабып, артыннан чәй эчеп җибәрсәң, бөтенләй күз аллары яктырып китә. Әле аның тагы икенче бертөрлесе, мәгъҗүн дигәне бар. Анысын ишан хәзрәт үзе җитмеш җиде төрле шифалы нәрсәләрдән ясата. Әгәр инде анысын бер балкашык кабып, чәй эчеп җибәрсәң, бөтенләй бу дөньядан кичәсең. Ахирәт күз алдына килә.

Себер бае. Хур кызлары да күзгә күренәләрме?

Яучы. Әй, син бигрәк инде, арттырып җибәрә башладың.

Шкафчы. Син теге җәдитне монда өйләнергә килгән дисеңме?

Бер мөрит. Әйе, өйләнергә килгән, ди. Укымышлы, урысча да, мөселманча да яза белә торган кыз булсын дип әйтә, ди.

---

Мәгъҗүн – наркотик.

Юан. Андый кыз кирәк булса, мәткә алыр!

Шкафчы. Үзе шикелле татар марҗалары бетмәс әле!

Мөрит. Кызны күреп алам, үзе күренмәсә, патритен күрсәм дә ярый дип әйтә, ди.

Шкафчы. Сурәтне төшерүче дә, төшертүче дә – икесе дә кяфер!

Сары сакал. Сурәт төшерткән кызны алучы? Монысының да аннан артык җире юк!

Ул арада урамның бер башыннан халык йөгерешеп чыгалар. Кибетләрдән дә ак алъяпкыч япкан кибетчеләр, кайсы себерке, кайсы щетка күтәреп, йөгерешеп чыгалар.

Шкафчы. Күсе тотканнар, күсе!

Сикереп төшеп, себерке күтәреп йөгерә, аның артыннан мөритләр дә йөгерәләр.

Тавыш. Ычкындырма, нык тот! Бәр, себерке белән! Өстенә бас! Башына бәр, башына!

Үтерәләр. Берсе койрыгыннан җеп белән өстереп китә. Көлешәләр.

Шкафчы (*килеп, себеркесен куеп*). Әйдәгез, инде чәйгә керик.

Китәләр.

Себер бае. Ярый, моны да күрдек. Шәһәрегезнең шәп кешеләре эт булып өреп калу белән генә канәгатьләнмиләр, мәче булып күсе дә тоталар икән! Әйдә, киттек.

Китәләр.

Читтән тавыш. Кайда куясы бу шәп гарчицаларны?

Икенче бер тавыш. Үзең аша!

Пәрдә.

## БИШЕНЧЕ МӘНЗАРӘ

*Әдәбият кичәсендә җәнҗал*

Бакча сценасы ясалган.

### 1 нче номер

Мәшһүр скрипач сәхнәгә чыгып башын ия. Скрипкада «Ашказар» көен берничә мәртәбә уйный. Халык кул чаба. Скрипач чыгып башын ия. Яңадан «Тәфтиләү» көен уйный. Халык янә кул чаба. Скрипач, яңадан чыгып, җиңел бер көй уйный. Халык кул чаба.

## 2 нче номер

**Рассказчы Фәләнев уйнаячак. Халык көтә. Ул арада партерда тавыш күтәрелә. Уртачарак киенгән, киң сакаллы берәү европача киенгән яшь бер адәмгә бәйләнә.**

Киң сакал. Урын беткәнмени сиңа, нәрсәгә монда кеше хатыны янына килеп утырасың?

Яшь егет. Әфәндем, бит минем урыным шушы. Менә билетым!

Киң сакал. Менә билетым, менә билетым! Чурт кушканмы сиңа монда кеше хатыны янына билет алырга?

Яшь егет. Әфәндем, мин бит белеп алмадым. Минем янымда кем утырасын мин кайдан белим?

Киң сакал. Әфәндем, әфәндем дигән булып тагын монда кеше мыскыл иткән була! Син үзең дә әле күптән түгел генә әфәндем идең әле!

Яшь егет. Ай Алла, абзыкаем, мин бит бу турыда бер дә гаепле түгел. Минем урыным шулай туры килгәч, мин ни эшлим?

Киң сакал. Килгән, килми ни!

Билет караучы (*болар янына килеп*). Әфәнделәр, ни бар? Акрын гына утырсагыз ла, тавышланмасагыз ла!

Киң сакал. Тавышланмагыз дигән була тагы! Нигә монда кеше хатыны янына ир кеше китереп утыртасыз?

Билетчы. Аны бит без утыртмаган, үзе утырган.

Киң сакал. Әнә әйттем бит син үзең утырган, дип!

Билетчы. Ялгыш әйттем, аның билеты шулай инде, сезнең яныгызга туры килгән.

Яшь егет. Бу турыда мин гаепле түгел, әфәндем.

Киң сакал. Тик тор, синнән сорамыйлар! (*Хатынына.*) Әйдә, утыр менә бу якка! (*Хатынын үз урынына утыртып, үзе яшь егет янына утыра.*) Син шул, әйдә алып бар, анда бик күңелле була икән дип алып килдең! Булды менә монда күңелле! Булмый ни! Сиңа монда, яныңда яшь егетләр утыргач, күңелледер шул! (*Билетчыга.*) Нәрсә монда тагы кеше хатыны каршысына килеп калкынып торасың? Әллә хатын күргәнең юкмы? (*Хатынына.*) Капла битеңне! Син монда егетләргә күренер өчен дип килгән икәнсең!

Хатын. Әй, сиңа әйтәм, кеше алдында алай бөһтаннар ягып мине харап итмә инде! Кеше арасында көлке булабыз ич!

Киң сакал. Көлке, көлке, син үзең көлке! Мине

---

Бөһтан – яла.

монда кеше арасында көлкегә калдырдың! Әнә һәммә кеше безгә карап көлеп тора!

Билетчы. Әфәнделәр, зинһар, тавышланмыйча гына утырсагыз ла. Хәзер икенче номер башлана.

Киң сакал. Башлансын, пычагыма да хаҗәте юк! Әйдә, тор, хатын! Минем монда җыен ир-ат арасында сине утыртыр хәлем юк! Һәммәсенең, күзләре тоз булган, безгә карап утыралар. (*Тора.*) Әйдә, әйдә, капла битеңне! Сөртенеп егылма!

Чыгып китәләр. Рассказчы чыга. Урта бер җиргә туктый, сөйли.

### Хатыннар хөррияте*

Рассказчы.

– Көям бирмәк өчен хөрлек, азатлыклар хатыннарга,
Бөтен фикрем, уем шулдыр, карамый көн вә төннәргә.
Бу уйдан кайтасым юктыр, әгәр канлы сугыш булса,
Хатыннар ирке угърында үләрмен мин, үлеш булса.
Хатыннар! Атлагыз алга! Бу юлда шаула, матбугат!
Хатыннарны кысучыларга каршы ач сугыш, ук ат!
Иел, и халкы дөнья! Уртадан юл бир хатыннарга!
Яшә, и галәме өнса! Вакыт хакларны аңларга!
Таралырга вакыт инде чапан атлы болытларга;
Чапаны да, Бохары да ашарга калсын этләргә!
Алар да, ир кеби, шаһлык, хәкимлек намнарын таксын!
Хатыннан көч тәрәкъкый бәхренә күл-күл булып аксын!
Укы, яз, бел, тырыш син, и мөкаддәс яртыбыз безнең!
Кеше булмак өчен иң-иң беренче шартыбыз безнең!

*

– Эшем бар бит, хатын, тиз булсана, бирсәңче чалбарны!
Бу тапланган икән; бир, яхшысы һәм тапсызы бармы?
Кара, монсы да тапланган дидем бит, таплары бетсен!
Шуны чистартмагансың: җә, хатынмы син? Сыер бит син!

Халык кул чаба. Рассказчы кереп китә. Дирижер сәхнәгә чыга.

Дирижер. Әфәнделәр, программада «Мәшһүр җырчы Адамантов җырлаячак» дип язылган булса да, ул, авыру булган сәбәпле, килә алмады. Шул сәбәптән без аның урынына шәһәребезнең мәшһүр музыка һәвәскәрләрен чакырдык. Хәзер 3 нче номер – җырчы Адамантов уры-

---

* Шагыйрь Габдулла Тукаев әдәбиятыннан. – *Г.Камал* искәр.
Угърында – юлында.
Галәме өнса – хатын-кыз дөньясы.
Хәкимлек – философлык.
Намнары – исемнәре.
Тәрәкъкый бәхренә – прогресс диңгезенә.

ына милли музыка һәвәскәрләреннән ясалган оркестр уйнаячак.

Сәхнәгә урындыклар тезә башлыйлар.

Партердан берәү. Далуй, далуй, кирәк түгел безгә аркистр, далуй! Безгә Адамантов җырласын!

Дирижер. Әфәнделәр, шауламый гына утырсагыз ла, әдәбият кичәләре яңа бер эш булганга күрә, безнең халкыбыз, ахры, төшенеп җитә алмый торгандыр.

Партердан икенче берәү. Дөрес! Афәрин!

Партердан берәү. Далуй! Далуй! Кирәк түгел безгә аркистр! Далуй! Безгә Адамантов җырласын! Без башканы тыңламыйбыз! Кирәк түгел!

Партердан икенче берәү. Кирәк булмаса, бар, чык та кит! Нәрсә монда кычкырып утырасың?

Партердан берәү. Чыкмыйм мин. Миңа Адамантов кирәк! Адамантов җырласын! Аркистр кирәкми!

Дирижер. Әфәндем, әйттек бит инде мөмкин түгел дип. Адамантов авырый. Шул сәбәптән аның чыгуы мөмкин түгел.

Партердан берәү. Ул булмаса, кирәкми! Башка кеше җырламасын!

Партердан икенче берәү. Дирижер әфәнде, нәрсәгә ул кешене сөйләтеп торасыз? Аның өчен монда никадәр кеше тәшвишкә төшә. Чыгарыгыз да җибәрегез үзен!

Партердан берәү. Мин ни эшләп чыгыйм? Мин дә монда синең шикелле тыңларга килгән!

Партердан икенче берәү. Чыкмаса, полиция белән чыгарыгыз! Нәрсәгә монда тавыш ясап утыра?

Дирижер. Әфәндем, монда алай тавыш чыгарып, халыкның кәефен җибәреп утырмагыз! Тыңлыйсыгыз килми икән, билет акчагызны кире кайтарып алыгыз да яхшылык белән чыгып китегез!

Партердан берәү. Билет акчасын?!

Дирижер. Әйе, билет акчасын кире кайтарып алыгыз да чыгыгыз!

Партердан берәү. Һә, алай икән! Мин аны сездән бигрәк яхшы беләм.

Дирижер. Соң ник чыкмыйсыз, ник кешене көттерәсез?

Партердан берәү. Соң, соң! Минеке бит билет түгел, кантрамарка!

Дирижер (*көлеп*). Алай икән! Аны каян алдыгыз?

Партердан берәү. Адамантов бирде. Мин җырлагач, бик каты кул чабарсың, диде. Ә үзе монда килмәгән!

Д и р и ж е р. Алай булгач инде, сез акча алмыйча гына чыгып китегез!

П а р т е р д а н  б е р ә ү. Юк инде, туганкаем, мин чыкмыйм! Ярый инде, аркистр булса да ярый, тыңлыйм!

Дирижер кереп китә.

### 3 нче номер

О р к е с т р бер-бер артлы берничә мәртәбә уйный. Х а л ы к кул чаба. Кереп китәләр. Алар кереп китүгә, ишектән к а р т р а к  б е р  к е ш е керә дә әрле-бирле йөри башлый, урындыклар арасыннан бер алга, бер артка таба бара.

К а р т. И Ходаем, и Ходаем! Бар икән күрәселәрем! Шәһәрдә бер дә акыллы кеше калмаган икән инде! Кара инде боларны?! Бары да ахырзаман галәмәтләре! Әхмәди, Әхмәди, кая син? Тиз чык, йөзең кара булган нәрсә! Кая минем углым, кая качырдыгыз? И оятсыз, оятсыз, оялмыйча мәзингә кадәр килгән бит! Кая куйдыгыз минем углымны? Ник берегез дә эндәшмисез? Һәммәсе бергәләшеп минем углымны качырганнар! Җитмәсә тагы, авызларын җырып көлеп торалар!

Яшь егет, урыныннан торып, кача башлый.

Ә, әнә, әнә, кая качасың? Әллә артыңнан җитмәс дип беләсеңме? Мин синең якаңнан өстерәп алып кайтырмын! (*Артыннан бара башлый.*)

Б и л е т ч ы. Әфәндем, сезгә ни кирәк?

К а р т. Кит аннан, Ходай органнар, кит! Минем углымны аздырырга керешкән икәнсез! Мин аңа, өйгә кайткач, күрмәгәннәрен күрсәтермен әле.

Б и л е т ч ы. Абзый, монда андый тәртипсезлекләр ясап йөрмәгез!

К а р т. Кит аннан, кызыл авыз, кит! Мин сезнең барыгызны да аталарыгызга әйтеп кирәгегезне бирдерермен әле!

Яшь егет кулиса артына кача. Карт та, артыннан кереп китеп.

Качма, качма, миннән качып котыла алмассың, мин сине алып кайтмыйча калмыйм.

Яшь егет сценага килеп чыга. Аның артыннан карт та сценага килеп чыгып, яшь егетнең колагыннан тотып.

Һи, оятсыз, оятсыз! Оялмыйча, миннән рөхсәтсез-нисез син монда килеп йөрергә! Әйдә өйгә!

---

К у л и с а – сәхнә арты.

Яшь егетне өстери. Дирижер вә башка берничә кеше, сценага кереп, картның кулыннан егетне коткарырга тырышалар.

Сценадагы кешеләр. Бабай, бабай, бу ни эшегез бу? Монда андый тәртипсезлек чыгарырга ярамый. Әйдә, чык моннан! Үзе дә кайтыр. Барыбер инде уен бетте. (*Картның кулыннан егетне коткаралар.*)

Карт (*халыкка карап, җылаган тавыш белән*). Ягез инде, җәмәгать, әйтегез инде, мин ни хәл итим инде? Ни эшлим инде бу бала белән?! Шулай ук инде, актык углымны да кулымнан алып, мине мәхрүм итеп калдырасызмыни? (*Җыламсырый.*) Тычканга үлем, мәчегә көлке, ди. Җитмәсә тагы, сез авызыгызны җырып көлеп торасыз! (*Чыгып китә.*)

Себер бае (*ложадан*). Җәмгыятегездә – җәнҗал, ресторанда – җәнҗал, клубыгызда – җәнҗал, базарыгызда – җәнҗал, әдәбият кичәгездә дә җәнҗал! Булмас, ахры, өйләнмим мин! Хуш, сау булыгыз! (*Чыгып китә.*)

Музыка марш уйный.

Пәрдә.

# ДӘҖҖАЛ

*Драма 4 пәрдәдә, 5 картинада*

ӘШХАС:

Әхмәт – приказчик.
Фәхерниса – Әхмәтнең хатыны.
Шөҗаг – Әхмәт белән бер байда тора торган приказчик.
Җамали – Әхмәтнең хуҗасы.
Шаһенгәрәй – Әхмәтнең каенатасы.
Сәмигулла – авыл сәүдәгәре.
Хәмди – күрше карчык.
Сабир – коридорщик малай.
Официант, кешеләр, судебный пристав, малайлар һәм фатир вә номер хуҗалары.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Җамалиның конторы. Уртада ишек. Уң һәм сул якта язу өстәлләре, алар өстендә кенәгәләр һәм язу әсбаблары. Өстәл тирәләрендә урындыклар.

### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Шөҗаг ялгыз.

Шөҗаг (*ишектән, бер-ике дәфтәр күтәреп кереп һәм ул дәфтәрләрне өстәл өстенә куеп*). Уф, бу байны тәмам бәреп үтерергә җитәрлек булам. Торган саен шуның кыланышларына ачуым килә. Исе китте инде шул Әхмәткә, белмим, аның кай җиренә кызыга торгандыр? Ни өчен шул самавыр куючы малайга тәрилкә тота торгандыр? Ичмасам, кулыннан юньле генә бер эш килсә икән. Ул бит һичбер эш белми, һичнәрсәдән аның хәбәре юк. Һич булмаганда, дөнья күргән бер кеше булса икән. Ул бит мин мәдрәсәдә торган чагында самавыр куючы бер малай иде. Аена алтмыш тиенгә җалланып безгә самавыр куеп йөри торган иде. Мин мәдрәсәгә кергән чагында, ул яланаягына чабата киеп, урам буенча шул чабатаның киндерәсен өстерәп, урам кибетенә лыштыр-лыштыр бара торган бер малай иде. Әле хәзер инде әллә кем булган.

Имеш, ул хәзер байга якын булган; имеш, ул хәзер бик шәп жалуния ала. Бик исем китә минем аның жалуниясенә. Аның, байның һәрбер кикерүенә дә «ярхәмәкалла» дип, тәрилкә тотып алган жалуниясенә минем бик исем китә. Тфү! Төкерим мин аның жалуниясенә! Мин аның бер ел буена алган жалуниясен, теләсәм, бер көн эчендә алам. Мин, теләсәм, аның бер ел эчендә эшләгән эшен бер көн эчендә эшлим. Мин аның шикелле сукачы мужик малае түгел. Ул нәрсә? Ул – тамагы ач, өсте ялангач бер мужикның малае. Юк, юк, мин ни эшләсәм эшләрмен, аның кул астында кол булып, аңар хезмәт итеп тора алмам. Ничек итсәм итәрмен, аны эштән чыгармыйча, аны юлдан яздырмыйча, аны байның күзеннән төшермичә туктамам. Әле аның мин белгән усаллыкларының меңеннән берсеннән дә хәбәре юк. Мин инде аны юлдан яздыруның, күздән төшерүнең юлларын күптән хәзерләп куйдым. Бүген кибет япкач, минем белән чәйгә керергә риза булды. Мин аны чәй янында ничек итеп эшкә китерергә кирәк икәнлеген бик яхшы беләм. Әгәр мин шул мужик малаен юлдан яздырмасам, исемем Шөҗагетдин дә булмасын! Әһем, әһем, кереп киләләр. (*Утырып, дәфтәрләрен караган булып маташа.*)

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Шөҗаг, Әхмәт һәм Сәмигулла.

Әхмәт (*уң тарафка, контор өстәле янына утырып*). Рәхим итегез, Сәмигулла абзый.

Сәмигулла утыра.

(*Шөҗагка карап.*) Кара әле, энем, бар әле, син, кибеткә чыгып, алачак дәфтәрләрне алып кер әле.

Шөҗаг (*шайтан сыман күз илә бер Әхмәткә, бер халыкка карап, үзалдына*). Һи, бәдбәхет! (*Әхмәткә.*) Ярый, хәзер. (*Янә халыкка карап.*) Күрәсезме, самавыр куючы малай минем белән ничек кылана. (*Әхмәткә карап, янә үзалдына.*) Мин сиңа ничек итеп кирәгеңне бирергә белермен әле. (*Чыга.*)

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әхмәт, Сәмигулла.

Әхмәт. Сәмигулла абзый, мин сезгә мал сатарга бөтен күңелемнән риза. Ләкин сезнең хакта бәгъзе бер сүзләр ишеткәнлектән, бай бераз тәшвишкә төште. Сезнең хак-

та байга әллә нинди сүзләр ишеттергәннәр. Шуннан соң бай миңа әйтә: «Ай-һай, Әхмәт, без аңар сатабыз сатуын да, ул безнең акчаны ябып калмас микән?» – ди. Мин аңа әйттем: «Җамали абзый, ул бит бурычларын һәрвакытта вәгъдәсендә китереп түли, бер дә аксаганы юк, андый сүзләр аның дошманнары ягыннан гына сөйләнгән сүзләрдер. Әгәр дә аның андый яман нияте булса, бу елгы сәүдә начар елны бирәчәкләрен вакытында бирә алмас иде», – дидем.

Сәмигулла. Хәер, дустым, мин сездән мондый начар сүз ишетермен дип килмәгән идем. Әгәр сез шикләнәсез икән, зинһар, миңа бер тиенлек тә мал сатмагыз. Әгәр сез минем эшемнең яхшы барганлыгына ышанмыйсыз икән, ерак җир түгел, минем авылга барып, минем хәлемне күреп кайтыгыз. Миңа кунакка барып кайтыгыз. Мин сезгә атлар җибәрермен. Шунда хәлемнең ничек икәнлеген үз күзегез белән күреп кайтырсыз. Ел никадәр ачлык ел булса да, хәзерге көндә минем һичбер кул-аяк тимәгән егерме биш кибәнем бар. Аның өстенә көз көне ничә мең пот арыш җыйдым. Әгәр сез шикләнәсез икән, миңа бер тиенлек тә мал сатмагыз. Мин сезгә хәзер бурычымны түлим дә кайтам да китәм.

Әхмәт. Юк, Сәмигулла абзый, мин әйткән сүзләргә кәефегез китмәсен. Мин сезгә бу сүзләрне шикләнгәнлектән-фәләннән әйтмим. Мин сезне бик яхшы беләм. Бары тик сезнең хакта байның сөйләгән сүзләрен генә әйтәм. Сезнең хакта һичбер сүзем юк, теләгәнегез кадәр алыгыз.

Сәмигулла (*халыкка таба карап*). Беләм мин синең ничек сөйләгәнеңне. Син бик яхшы эшне сизеп сөйлисең.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әүвәлгеләр һәм Шөҗаг.

Шөҗаг (*ишектән дәфтәрләр күтәреп кереп, бер мәртәбә халыкка, соңра Әхмәткә мәгънәле һәм ямьсез карашлары белән карап*). Менә дәфтәрләр. (*Бераз торып.*) Анда бай миңа ачулана. «Кичә ни өчен Хәйретдингә чәй саттыгыз? – ди. – Җыен тиешле-тиешсез кешеләргә малны өләшеп бетереп, мине харап итеп бетерәсез инде», – ди.

Әхмәт (*дәфтәрләрне карап*). Ярар. Татарга тылмач кирәкми. Эшеңдә бул. Вәлиев өчен Савин пароходына егерме шыр[1] такта чәй төшерттеңме?

Шөҗаг. Юк. Бай алардан задатка алмыйча чәйне төшерергә кушмады.

Ә х м ә т. Нәрсә?

Ш ө җ а г. Задатка алмыйча бай төшерергә кушмады.

Ә х м ә т. Синең анда эшең булмасын. Сиңа ни кушканнар, син шуны эшлә.

Ш ө җ а г (*иреннәрен тешләп, ачулы күзләре белән карап*). Һи, бәдбәхет! (*Тавышын йомшартып, Әхмәткә.*) Абзый бирмәскә кушса да, ул кешегә җибәрикмени?

Ә х м ә т. Җибәр, җибәр, сиңа ни кушканнар, син шуны эшлә.

Шөҗаг Әхмәткә ачулы күзләре белән карап чыгып китә.

## БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ә х м ә т, С ә м и г у л л а.

Ә х м ә т. Сәмигулла абзый, сездә безнең алачак хәзергә көндә 758 сум 95 тиен икән. Сезнең биргән векселегез 800 сумлык. Хәзер инде сез шул бирәчәкләрне түләмәкче буласызмыни?

С ә м и г у л л а. Әйе, шул бирәчәкләрне түләп, тагы бер унике шыр чәй алырга ният бар иде.

Ә х м ә т. Алай икән, Сәмигулла абзый, хәзер бит, үзегезгә мәгълүм, чәйләр кыйбатланды. Сез ала торган сәйлүн чәенең шыры 102 сумга җитте. Шул сәбәптән ул кадәр үк сез теләгәнчә итеп бирергә мөмкин түгел.

С ә м и г у л л а. Миңа бит чәй бик кирәк иде.

Ә х м ә т. Яхшы, алай булса мин сез теләгәнчә итеп эшләргә тырышырмын. Байга да үзем җайлап әйтермен. Хәзер инде сез иске бирәчәкләрегезне бирмәкче буласызмыни?

С ә м и г у л л а. Әйе, менә сезгә тиешле акчагызны да алып килдем. Менә, мә, сезгә акча. (*Акчаны чыгарып бирә.*) Бу көнгә кадәр көткәнегезгә дә рәхмәт инде.

Ә х м ә т. Яхшы, ярый, рәхмәт. (*Акчаны санап.*) Сез әле ничек дисез, яңадан унике шыр чәй алырга ният бар иде дисезме?

С ә м и г у л л а. Әйе, ният шулай иде.

Ә х м ә т. Ярый. Сез бераз утырып торыгыз, мин байга әйтеп кенә уздырыйм, әгәр ул риза булса, бирербез! (*Чыга.*)

## АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

С ә м и г у л л а ялгыз.

С ә м и г у л л а (*Әхмәтнең артыннан карап калып*). Кайдан килеп керде бу йөзе кара нәрсә? Кайчан гына карама, һаман баеның җырын җырлый. Минем өчен

Шөҗаг яхшы иде. Теләсәң күпме алып буладыр иде. Әгәр хәзер эш башында ул булса, бу көнгә кадәр унике генә түгел, кырык ике шырга довериегә кереп булыр иде. Кем килеп әйткән боларга минем эш начарлыкны? Әллә боларның хәбәр ташый торган җеннәре бар микән? Минем өчен Шөҗаг яхшы иде. Аны ничек итеп булса да җайга китереп буладыр иде. Бервакытны Шөҗагны Яфимефкәгә итеп өч-дүрт тәңкәлек сыйлаган идем, малай тәмам балавыз шикелле йомшады. Йөз тәңкә задатка биргәч, сигез шыр чәйне берсүзсез тоттырды да җибәрде. Ә хәзер монысын һич йомшартыр хәл юк. Монысына бертөрле дә май катыштырып булмый.

### ҖИДЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Сәмигулла, Шөҗаг.

Шөҗаг (*ишектән кереп*). Нихәл, Сәмигулла абзый, хәлләр ничек? Бая теге нәгъләт барга күрә, синең хәлеңне сораша алмадым. Син мине инде бөтенләй оныттың, бер дә сыйламый башладың.

Сәмигулла (*үзалдына*). Синең кулыңда куәт калмагач, мин сине пычагыма сыйлыйммыни? (*Шөҗагка карап.*) Нишләп мин сине онытыйм, бер дә онытмадым. Сыйлаудан бер дә эш калмас иде, ләкин чәйне күбрәк сатмыйсыз.

Шөҗаг. Мин сатар идем дә бит, Сәмигулла абзый, эш миндә түгел, һаман белер-белмәс шул Әхмәт, йөзе кара, эшкә каршы төшә. Байга тәрилкә тоткан булып, һәркемне байга яманлап, иске алучыларны тәмам биздереп бетерә инде. Әле менә хәзер дә сезнең турыда сөйли калды: «Аның тәмле сүзләренә карап, күп мал сатарга ярамый», – ди. Бай шуның тасма телләренә ышана.

Сәмигулла. Беләм, беләм, мин, читтә торсам да, эшне бик сизеп торам. Син эшкә баш чагында яхшы иде, алучылар да ияләнеп киләләр иде. Бу Әхмәтегез бик кире бернәрсә шикелле күренә.

Шөҗаг. Кире дигәндә дә инде, моннан артык бер кире булмас. Бөтенләй карышып каткан.

Сәмигулла. Соң сез аны ни эшләп бераз арыш майлары белән чылатып җебетмисез? Аннан соң ул бераз йомшар иде. (*Көлә.*)

Шөҗаг. Булмый бит, Сәмигулла абзый. Мин инде аны йомшартырга бик күптән бирле тырышам.

Сәмигулла. Тырышсаң, булыр әле, син бит эш булдыра алмый торган егет түгел.

Шөҗаг. Мин инде ул турыда кулымнан килгән кадәрле бөтен көчем, куәтем белән тырышам. Мин аңар тышымнан ялтыраган булып күренсәм дә, эчемнән аны бер дә дус күрмим. Сез, Сәмигулла абзый, аны белмисез. Ул бит, мин мәдрәсәдә укыган чагында, авылдан яланөс, яланаяк килеп, безгә самавыр куеп йөргән бер малай иде. Соңыннан эти мине шушы Җамали абзыйга кибетчелеккә бирде. Мин бер ел торгач, ул да хезмәтче малай булып байга ялланды. Соңыннан байга тәрилкә тотып, ялынып-ялманып йөреп, байга ярады. Бай хәзер инде аны доверенный ясады. Мин никадәр яхшы эшләсәм дә, бай мине тәүфикъсыз дигән булып читкә кага башлады. Мин бу ачуымны гомерем буена да онытмам. Ничек итсәм итәрмен, аннан үчемне алмыйча, аны эштән чыгармыйча калмам. Әһем, әһем, кереп киләләр. (*Икенче өстәлгә барып, дәфтәр карап, счет салырга тотына.*)

Җамали белән Әхмәт керәләр.

## СИГЕЗЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әүвәлгеләр һәм Әхмәт белән Җамали.

Сәмигулла (*урыныннан торып, тәгъзыйм белән*). Исәнме, Җамали абзый, исән-сау торасызмы? (*Урын бирә.*)

Җамали. Юк, юк, Сәмигулла әфәнде, урыныгыздан кузгалмагыз. Сез безнең алучы кеше, сезгә кадер-хөрмәт итәргә кирәк. Утырыгыз, утырыгыз.

Сәмигулла утыра. Аның янына Җамали белән Әхмәт тә урындык алып утыралар.

Әле менә Әхмәт, безнең зур алучыларыбыздан Сәмигулла әфәнде килгән, дигәч, сезнең белән күрешергә генә кергән идем. Нихәл соң әле, ни эшләп торасыз? Ни эшләр бетерәсез? Сатуларны яхшы итәсезме?

Шөҗаг астан гына ачулы күзләре белән ара-тирә Әхмәткә карап куя.

Сәмигулла. Әлхәмделилла, Ходайның биргәненә шөкер. Эшләребез бик яхшы бара. Сатуны да бик яхшы итәбез. Бары тик әле менә чәйне генә җиткереп булмый. Авылда алучы күп, бу арада чәй генә бетеп китте. Игенне бу ел, Ходайга шөкер, бик яхшы җыйдым. Елдагыга караганда бу ел җыйган иген ике өлеш күп булды.

---

* Тәгъзыйм белән – хөрмәт белән.

Җ а м а л и. Алай икән, бик яхшы, бик яхшы.

С ә м и г у л л а. «Күп» дигәч тә инде, әллә никадәр күп түгел, безнең үзебезгә күрә күп: бу ел биш мең пот арыш җыйдым. Аның өстенә бу ел, Ходайның биргәненә шөкер, үземнең игеннәрем дә яхшы булды. Әле менә бер дә кулаяк тимәгән егерме биш кибән арышым бар.

Җ а м а л и. Алай икән, алай булгач, эшләрегез яхшы икән.

С ә м и г у л л а. Ходайның биргәненә шөкер, тирәҗүндә дус-ишләрем дә күп. Тирә-күрше һәркайсы: «Сәми абзый, инде син бөтенләй черегән бай булдың», – диләр. Ходай инде яман күздән, хәвеф-хәтәрдән генә үзе сакласын. Авылда да эшләрем бик күп. Әле менә вакытында иске бурычымны бирим дә яңадан чәй алып кайтыйм дип килгән идем. Сәүдәләр яхшы булгач, мужикларга өләшергә чәйне җиткезеп булмый. Шуның өчен бу юлы сездән чәйне бераз артыграк алырга дип килгән идем. Сезгә дә кулдан килгән кадәр хезмәтне итәргә кирәк. Бу юлы инде, шаять, унике шыр итеп бирерсез дип өмид итәм.

Җ а м а л и. Шулайдыр шул, ләкин хәзергә кулда запас азрак. Шуның өчен арттырып бирергә туры килеп бетми. Әнә тагы Әхмәт белән үзегез сөйләшерсез. Ярый, хуш, хәзергә сәламәт булыгыз. (*Чыга.*)

С ә м и г у л л а (*урыныннан торып*). Ярый, хуш, сәламәт булыгыз.

Ә х м ә т. Шулай, Сәмигулла абзый. Мин бай белән сөйләшеп карадым. Ул арттырырга риза булмады. Шуның өчен мин арттырып бирә алмыйм. Әгәр дә иске кридитегез чамасына риза булсагыз, шулкадәр бирербез.

С а б и р (*ишектән кереп*). Әхмәт абзый, сине бер кеше чакыра, монда гына чыгып керсен әле, ди.

Ә х м ә т. Ярый, Сәмигулла абзый, мин чыгып кына керим әле. Сез утырып торыгыз. (*Чыга.*)

## ТУГЫЗЫНЧЫ МӘҖЛЕС

С ә м и г у л л а, Ш ө җ а г.

С ә м и г у л л а. Мин бу Әхмәтегезне болай дип үк белмидер идем, бу бөтенләй бай малына баш ора торган бер кеше икән.

Ш ө җ а г. Һә, сез әле аны хәзер генә белгәнсез. Ул инде минем ничә еллардан бирле үзәгемә үтеп килә. Ул үзенең төлкелеге, үзенең хәйләкәрлеге аркасында байга

ярады. Бай аңа ел саен жалуния арттыра. Ә мин ничә еллардан бирле тырышып-тырмашып хезмәт итсәм дә, бер тиен арттырганы юк. Бай һаман миннән гаеп тапкан булып, минем жалуниямне киметергә генә тырыша. Минем болай калуыма шул Әхмәт сәбәп.

Сәмигулла. Соң син аны ник өскә җибәрәсең?

Шөҗаг. Мин бер дә...

Сабир (*ишектән кереп*). Сәмигулла абзый, сезне Әхмәт абзый чакыра. Үзенә кирәкле чәйләрне сайласын, ди. (*Чыга.*)

Шөҗаг. Мин, Сәмигулла абзый, бер дә аны өскә җибәрәчәк түгел. Ул минем кулымнан эшне алган шикелле, мин дә аның бар эшләрен тар-мар итәрмен. Итәрмен, итәрмен һәм теләгән максатларыма җитәрмен. Әле хәзергә тик көне-сәгате генә туры килми тора.

Сәмигулла. Ярый, ярый, туган, тырыш. Яңадан эш башына менәргә тырыш. Анда мине көтеп тора торганнардыр. Йә берәр нәрсәдән шикләнә башларлар, чыгыйм тизрәк. Хуш, сау бул! (*Чыга.*)

Шөҗаг. Хуш!

## УНЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Шөҗаг ялгыз.

Шөҗаг (*йодрыкларын йомарлап, идән буена йөрергә тотынып*). Үләм, үләм, ачуымнан, көнчелегемнән үләм. Мин аның бу кыйланышларына чыдый алмыйм. Бер самавыр куючы малай синнән өстен, кеше арасында синнән мәкъбүл булып торсын да, син аның аягы астында ялчы булып хезмәт итеп тор, имеш. Юк, юк, мин бу хурлыкка чыдый алмыйм. Ничек итсәм дә итәрмен, аны эштән чыгармыйча, аны күздән төшермичә, аны хур итмичә туктамам! Үз гомеремдә әгәр аны хур итмәсәм, исемем Шөҗаг булмасын! (*Чыга.*)

Пәрдә.

---

Мәкъбүл – ышанычлы, яхшатлы.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Уң якта ике, сул якта ике кабинет ишекләре. Түрдә ике якка китә торган коридор. Уң яктагы кабинетның эче күренә. Анда бер диван, ике урындык. Өстен ак эскәтер белән япкан өстәл. Диварында бер тәрәзә, түрдә – диварда – бер рәсем. Пәрдә ачылганда, мәзкүр кабинетта ике кеше утыра. Коридордагы бер өстәлдә шешәләр, стаканнар тора.

### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ике кеше.

Берсе (*стаканнарга шешәдәге сыраны салып*). Ну, эч әйдә, китәбез.

Икенчесе (*стаканны алып эчеп*). Тагы берәрне әйтмибезмени?

Берсе. Юк, җитәр. Мине мәҗлескә чакырган җир бар, шунда барырга кирәк.

Икенчесе. Ярый алай булса, әйдә, киттек. Минем тагы берәрне эчәрлек урын бар иде барын. Син киткәч, ялгыз гына утыру күңелсез булыр.

Берсе звонок бирә.
Официант килә.

Официант. Ни боерасыз?

Берсе. Кая, күпме кирәк? Акча алыгыз.

Официант. Алтмыш тиен, барин.

Берсе. Мә, алтмыш өч тиен. Өч тиен сиңа чәйлек.

Официант. Спасибо.

Тегеләр чыгып китәләр.

Өч тиен сиңа чәйлек, имеш. Кырдыгыз инде. Өч тиен көмеш өчен монда бүлмә пычратып утыралар. (*Шешәләрне җыеп алып чыга.*)

Шөҗаг, Әхмәт килеп керәләр.

### ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Шөҗаг, Әхмәт.

Шөҗаг (*официантка*). Ну-ка, Яфим, безгә бик шәп бер кабинет бир әле.

Официант. Ә, исәнмесез, менә монда рәхим итегез, бик шәп кабинет, үзе яхшы, үзе аулак.

---

Дивар – стена.
Мәзкүр – бу, шушы, әлеге.

Ш ө җ а г. Яхшы, ярый, әйдә, Әхмәт әфәнде, рәхим итегез.

Керәләр.

О ф и ц и а н т (*халыкка*). Менә ичмасам монысы кеше, чәйлекне яхшы яудыра. (*Кабинетка кереп.*) Нихәл, ни боерасыз?

Ш ө җ а г. Кайда, монда ике шешә сыра китер әле. (*Әхмәткә.*) Әхмәт әфәнде, сез сыра эчә торгансыздыр бит?

Ә х м ә т. Юк, мин сыра эчмим. Миңа чәй генә китерсен.

Ш ө җ а г. Мин сезне сыра эчә торгансыздыр дип торадыр идем. Монда бит чәй бирмиләр.

Ә х м ә т. Алай булгач, миңа куас кына китерсен.

Ш ө җ а г. Әй, куй инде, кеше, балалар шикелле, куас эчеп утыра, имеш. Алай булса, сезгә бер шешә кара сыра гына китерсен.

Ә х м ә т. Ул нинди нәрсә соң ул, исертә торган нәрсә түгелме?

Ш ө җ а г. Юк, аны хатыннар да эчә. Бик җуаш нәрсә ул. Аның бер чиләген эчеп бетерсәң дә бернәрсә дә булмый.

Ә х м ә т. Әй, Шөҗаг, ул минем бер дә белгән нәрсәм түгел, кара аны, андый-мондый нәрсә булып, син мине исертеп, кеше арасында рисвай итә күрмә.

Ш ө җ а г. Алла сакласын, сезгә андый эшне эшләргә! (*Официантка.*) Ну, алай булса, Яфим, бар, син безгә бер шешә кара, бер шешә столовой китер.

Официант чыгып китә.

Кара сыра ул бик шәп нәрсә, ул үзе эчәргә дә бик тәмле, аның өстенә аның кан арттыру өчен дә бик күп файдасы бар. Кан аз кешегә докторлар аны үзләре эчәргә киңәш бирәләр. Аның йорт сырасыннан бер дә аермасы юк, бары тик йорт сырасына караганда тәме тәмлерәк тә, аңа караганда сорты яхшырак.

Ә х м ә т. Алай булгач, соң син аны үзең ни эшләп эчмисең?

Ш ө җ а г. Кайвакытта мин аны үзем дә эчәм, ләкин бер дә башка китми. Бер дә башка китмәгәч, сөйләшеп утырырга хозур булмый. Мәҗлеснең кызыгы югала. Теге, ичмасам, бераз кәефне китерә, сөйләшеп утырырга күңелле була.

О ф и ц и а н т ике шешә сыраны китереп куя.

(*Ике шешәдән ике стаканга салып.*) Ну, Әхмәт әфәнде, берәрне эчеп җибәрик әле!

Ә х м ә т. Мин сиңа ышанам инде, андый-мондый исертә торган нәрсә түгелдер бит?

Ш ө җ а г. Юк, юк. Бер дә андый нәрсә түгел.

Ә х м ә т. Алай булгач, инде моны бисмилла әйтеп эчәргә дә ярый торгандыр.

Ш ө җ а г. Әхмәт әфәнде, инде сез бигрәк арттырып җибәрә башладыгыз. Ахры, сез юри шаярасыз.

Ә х м ә т. Юк, чынлап, шаярмыйм. Бер дә эчкән нәрсәм булмаганга, әллә ни эшләп бик куркам.

Ш ө җ а г. Юк, бернәрсә дә юк, бер дә курыкмагыз, әйдә эчеп җибәрегез.

Эчәләр.

Ә х м ә т. Бу бер дә йорт сырасына охшамый ла, бер яктан караганда, ачы, икенче яктан караганда, төче, әллә нинди әчкелтем-төчкелтем тәмнәр килә.

Ш ө җ а г (*көлеп*). Син, Әхмәт әфәнде, кешене көлдерергә бик оста, әллә нинди кызык сүзләр сөйләп кешене көлдерәсең. (*Икенче шешәне күрсәтеп.*) Менә монысын әйтсәң дә ярый ичмасам әчкелтем-төчкелтем дип, чыннан да менә монысы беренче эчүгә бераз әчкелтемрәк тоела. Ну, Әхмәт әфәнде, тагын берәрне эчик әле. Миңа да сүз башларга бераз күңеллерәк булыр. (*Стаканнарга сала.*)

Ә х м ә т. Тукта әле, ул кадәр ашыкма. Теге эчкәне бераз урынына урнашсын.

Ш ө җ а г. Зарар юк, зарар юк, алайса, бераз торып торсын. Ну, Әхмәт әфәнде, сез миңа шуны әйтегез әле, минем монда сезне алып килүдән дә максудым шул иде: бай минем хакта сезгә ниләр сөйли? Минем шуны бик беләсем килә.

Ә х м ә т. Ни сөйләсен, берни дә сөйләми.

Ш ө җ а г. Әхмәт әфәнде, юкны сөйләмәгез инде. Мин ул сүзгә бер дә ышанмыйм. Миңа сезне сөйләгәнне, мине сезгә сөйләмиме соң?!

Ә х м ә т. Ничек дисең? «Мине сиңа сөйләгәнне»?

Ш ө җ а г. Ие, сезне сөйләгәнне.

Ә х м ә т. Ничек? Әллә сиңа минем хакта берәр сүз сөйләдеме?

Ш ө җ а г. Берәр? Берәр генә түгел, әллә никадәр! Җә, эчик әле. (*Стаканын Әхмәт стаканына чәкештереп.*) Җә, әйдә. (*Эчә.*)

Ә х м ә т (*стаканны эчеп*). Минем хакта сөйләде диген, ә?

Ш ө җ а г. Миңа нәрсә ул турыда ялганларга, мин сезне дус күрәм. Шуның өчен дә, бер-беребезгә серләребезне чишәрбез дип, сезне монда алып килдем.

Ә х м ә т. Йә, Шөҗаг, сөйлә әле, бай минем хакта ниләр сөйли?

Ш ө җ а г. Тукта, хәзер сөйләрмен, бераз гына кәеф килсен. Кәеф килгәч, сөйләргә уңайрак була. (*Яңадан стаканнарга сыра сала.*)

Ә х м ә т. Син, Шөҗаг, бу нәрсәне бер дә исертми дигән идең, әллә шикләнгәнгәме, әллә ничек бераз башка киткән шикелле, колакларым бераз томаланган шикелле булды.

Ш ө җ а г. Ха-ха-ха! Куй юк сүзне, Әхмәт әфәнде. Сабый балалар шикелле кыланасың. Әйтәм бит мин сиңа бернәрсә дә юк дип. Әйдә тот стаканыңны. (*Әхмәтнең стаканына стаканын кагып ала.*) Әйдә эчик.

Эчәләр.

Ә х м ә т. Авыз ияләнә төштеме, монысының тәме әүвәлгесеннән бераз җиңелрәк тоелды. Башка китмәсә дә, тәнне бераз кыздыра торгандыр, ахры. Әллә ничек тәннәрем бераз кызып, җиңеләеп киткән төсле булды.

Ш ө җ а г. Сез инде бигрәк кызык сөйлисез, һәр минут саен яңа бер сүз табасыз.

Коридорга начаррак киенгән и к е  к е ш е керә.

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Коридорда һәм кабинетта.
И к е  к е ш е, о ф и ц и а н т, Ш ө җ а г, Ә х м ә т.

Б е р  к е ш е (*официантка*). Кара әле, официант, Шөҗаг мондамы?

О ф и ц и а н т. Монда, әнә теге кабинетта утыра.

Б е р  к е ш е. Кем белән? Үзе генәме?

О ф и ц и а н т. Юк, үзе генә түгел, мин белмәгән бер кеше белән.

Б е р  к е ш е. Бар әле, син аны монда чакырып чыгар әле.

О ф и ц и а н т. Яхшы. (*Кабинетка кереп.*) Господин Шөҗаг, тегендә сезне ике кеше чакыра.

Ш ө җ а г. Ә, шулаймы? Ярый, хәзер чыга, диген.

Официант чыгып китә.

(*Әхмәткә карап.*) Әхмәт әфәнде, сез бераз гына утырып торыгыз әле, мин аларның кемнәр икәнен генә карап керим, хәзер керермен. (*Коридорга чыга.*)

Ә х м ә т. Бу йөзе кара Шөҗаг мине харап итмәсме икән инде? Хәер, итмәс лә. Үз кешене ни эшләп харап

итсен! Шуны беләсе иде, бай минем турыда ни сөйләде икән?

Бер кеше (*коридорда*). Нихәл, Шөҗаг? Без килдек. Син хәзерме?

Шөҗаг. Сез бераз гына сабыр итегез, хәзер озакламый була. Шунда икенче бер кабинетка кереп утырып эчә торыгыз. Яфим, син боларга минем хисапка өч-дүрт бутылка сыра бир. Үзләрен шунда берәр буш кабинетка утырт.

Официант. Ярый, әйдәгез менә бу бүлмәгә. Бу бүлмә буш. (*Сул яктагы ишектән кертеп җибәрә. Бераздан аларга дүрт шешә сыра да китереп бирә.*)

Шөҗаг (*бүлмә ишеген ачып*). Сез шунда утыра торыгыз. Мин, вакыт җиткәч, үзем сезне эндәшеп чыгарырмын. (*Бүлмә ишеген ябып, официантны бер читкә тартып.*) Яфим, син бик яхшы тыңла, мин хәзер тагын берәр шешә сыра сорармын. Син сыраны керткәнче, кара сыраның эченә бераз гына акны тамызып керт. Әгәр шул эшне булдырсаң, сиңа аннан ары полный чәйлек! Аңладыңмы?

Официант. Аңладым, аңладым.

Шөҗаг. Аңласаң – шул. Мин әйткәнчә иттереп эшлә.

Официант. Ярый, бар, тыныч бул.

Шөҗаг (*ишектән кереп*). Сезне озак көттердем бугай. Тегендә өстәл янындагы иптәшләрдән ике кеше килгән, мине икенче җиргә барырга димлиләр. Юк, мин бармыйм, эшем бар, бик кирәкле сүзләрем бар, дип, аларны җибәрдем. (*Стаканнарга салып.*) Җә әле, әйдә тагын берәрне эчеп җибәрик.

Әхмәт. Син, әкият, тагын эч, тагын эч дип, миңа болай булса бөтен Волга суын эчертеп бетерерсең.

Шөҗаг. Ха-ха-ха... Ну кызык кеше дә соң сез, Әхмәт әфәнде. Шундый кызык сүзләрне кайдан табасыз? Ну, җә, тот әле, әйдә эчик.

Әхмәт. Юк, кирәкми, күпкә китәр, инде мин эчмим. Син бит мине монда сүз сөйләргә дип алып килдең.

Шөҗаг. Хәзер сөйлим, җә, шуны гына эчик әле.

Әхмәт. Ну, әйдә алайса, күңелең булсын.

Эчәләр.

Ну, сөйлә инде алай булса, бай минем турыда ни әйтә? (*Бераз җиңеләйгән сыман булып кәләпүшләрен төзәтеп куя.*) Син, туганкай, моны бер дә башка китми дигән идең диюен дә, монда аз булса да колмак булырга кирәк. Әфиун ашап, чәй эчкән кадәрле әсәр итте. Беләсеңме?

---

Әсәр итү – тәэсир итү.

Мәдрәсәдә торган чагында син миңа менә шуның кадәр генә, ясмык кадәр генә әфиун каптырып чәй эчерткән идең. Ә? Исеңдәме?

Ш ө җ а г. Исемдә, бик исемдә, без бит мәдрәсәдә торганда синең белән бик дус торган идек. Минем дә бераз кәеф ачылып китте, тукта әле, тагын берәрне алдырыйк. (*Звонок бирә.*)

Ә х м ә т. Юк, юк, Шөҗаг, җитте, җитте, мин артык эчмим.

Ш ө җ а г. Җә, юк сүзне сөйләмә, зинһар, бергә-бергә күңелле булыр. Мәҗлес күңелле генә барганда ул нинди сүз ул!

Официант керә.

О ф и ц и а н т. Ни боерасыз?

Ш ө җ а г. Кая, тагы икене китер.

О ф и ц и а н т. Баягычамы?

Ш ө җ а г. Ие, баягыча.

Официант чыгып китә.

Ә х м ә т. Кара әле, Шөҗаг, миңа җитте, мин эчмим. Болай да инде башка китте. Тагы эчсәм, аннан ары бөтенләй җыгылып калырмын.

Ш ө җ а г. Куй, зинһар, юк сүзне. Китерсен әле. Син эчмәсәң, мин эчәрмен.

О ф и ц и а н т шешәләрне китереп коридордагы өстәлгә куя. Шешәләрнең авызын ачып, кара сыраны бер стаканга бераз бушатып, аның урынына акны сала.

Эчү дигән нәрсә ул кайвакытта аз-маз гына булса бераз ярап та куя, аның белән кайгы-хәсрәтләрне бераз таратып җибәрәсең.

Ә х м ә т. Ансы бераз бар! Минем дә әле менә бераз әллә ничек башым бушап киткән шикелле булды.

Официант шешәләрне китереп куя.

Ш ө җ а г. Әлбәттә, әлбәттә. (*Шешәдән салып.*) Менә шуларны бушатыйк та, аннан ары эчебездәге кайгы-хәсрәтләрне бер-беребез белән сөйләшеп бушатырбыз. Җә, эчик әле.

Ә х м ә т. Кара әле, Шөҗаг, мин бер дә белмим бит, моны да эчсәм, бик күп булмасмы соң бу?

Ш ө җ а г. Юк! Бая мин сезгә әйттем ич, моның бер чиләген эчеп бетерсәң дә бернәрсә дә юк, дип. Әйдә эчәбез.

Ә х м ә т. Дөрес әйтәсеңме? Бернәрсә дә булмас дисеңме? Әйдә алайса.

Эчәләр.

Әллә, туганкай, моның монысы тегесенә караганда да куәтлерәкме? Әллә ничек бугазларны чеметтереп төшеп киткән шикелле булды. Тегесенә караганда бераз ачырак та тоелды. (*Шешәләрне чагыштырып карый.*)

Ш ө җ а г (*шешәләрне караган булып*). Юк, барыбер, бер заводныкы.

Ә х м ә т. Ай-һай, бераз башкарак шикелле тоела. Аяклар буенча чымырдап йөри. Әллә ничек җырлыйсы да килә башлады. Тукта әле, туганкай, мин тышка чыгып керим, моның тышка чыга торган җире кайда?

Тора да бераз абына, Шөҗаг торып култыклый.

Әллә мин бераз исергән, әллә аяклар камашкан, әллә нинди дулкындагы көймә өстендә барган шикелле, стеналар, идәннәр тирбәнә.

Ш ө җ а г. Ха-ха-ха... Юк, бернәрсә дә юк.

Коридорга чыгалар.

(*Официантка.*) Әй, Яфим, бу әфәндегә тышка чыга торган юлны күрсәт әле.

Яфим Әхмәтне җитәкләп чыгып китә. Шөҗаг уң яктагы бүлмә ишеген ачып.

Нихәл сез, китмәдегезме? Утырасызмы?

И к е к е ш е бүлмәдән чыгалар.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

И к е к е ш е, Ш ө ж а г, о ф и ц и а н т.

Б е р к е ш е. Нихәл, ни эшлисең, буламы?

Ш ө җ а г (*кулларын сугып, шатланып*). Була! Була дигәндә дә инде нинди генә була. Малайның эше килә башлады. Аяк астында идәннәр тирбәнә, ди. Ха-ха-ха... Шөҗаг булсын да, имеш, ул эшне булдырмасын! Чү, киләләр бугай, барыгыз, барыгыз, керегез, сез шунда утырып торыгыз. Җитмәсә, тагын алдырыгыз. Мин, вакыт җиткәч, сезне үзем чакырырмын.

Ике кеше бүлмәгә кереп китәләр. О ф и ц и а н т килә.

Ну, маладис, Яфим! Бир кулыңны, кеше икәнсең. Сиңа полный чәйлек!

Официант. Как же, как же. Миңа сезнең шикелле чәйлек бирә торган господалар кадерле. Әле сез белеп җиткермисез икән, аны инде бу вакытка кадәр күптән аяктан егып булыр иде.

Шөҗаг. Ну?!

Официант. Дөрес!

Шөҗаг. Ничек?

Официант. Эчә торган стаканына аз гына тәмәке көле салырга да больше ничава!

Шөҗаг. Ну?!

Официант. Дөрес!

Шөҗаг. Маладис, сиңа чәйлекне тагы арттырам. (*Кабинетка керә дә Әхмәтнең стаканына чеметеп тәмәке көле сала.*) Ну, покрайнемере, бу – акыл! Максатыма инде тәмам җитәм. Шатлана-шатлана үчемне алам. Тагын берике мәртәбә шулай сыйлап исерткәләсәң, аннан ары үзе дә тиз өйрәнеп җитәр. Гостиница юлыннан кайтмый башлар. Ничек итсәм итәрмен, мин аны тәмам юлдан чыгармыйча туктамам.

### БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Шөҗаг, Әхмәт, официант һәм ике кеше.

Әхмәт (*коридорга алпан-тилпән кереп*). Официант, бу сезнең пулатыгызга ни булган, бик тирбәнә бу? Әллә сез диңгез өстендә карабта торасызмы? (*Көлә.*)

Официант. Шулай, барин, шулай! Безнең пулат дулкынлы диңгез өстенә салынган.

Әхмәт икенче ишеккә керә башлый. Официант Әхмәтне җитәкләп.

Чү, чү, барин, анда кермәгез, әнә сезнең дварисыгыз тегендә. (*Кабинетка кертә.*)

Әхмәт (*ишектән керә-керә*). Чынлап та, дварис бу, һәр ягын алтын-көмеш белән бизәгән.

Шөҗаг җитәкләп диванга утырта.

Дварислыкка дварис та, ләкин бик дулкынлы дварис.

Шөҗаг (*халыкка карап*). Тагын берәрне җибәргәч, күзеңә җәннәт булып та күренә башлар әле. (*Әхмәткә.*) Ну, Әхмәт әфәнде, әйдә, китәргә вакыт тагын, шуны гына эчик тә, аннан ары кайтырбыз. (*Шешәләрдән сала.*)

Ә х м ә т. Шулай дисеңме? Әйдә, алай булса, чорт возьми, син башка китми дигән идең дә, бу кешене бик кызык итә икән.

Эчәләр.

Әле кайтабыз дамыни инде? Син бит әле миңа бай хакында сөйләмәкче идең. Ну, ярый, тагы сөйләрсең. (*Башын диванның аркасына тери.*) Менә сиңа бишек! Шунда тирбән дә тирбән. Ә син, Шөҗаг... Кая... барасың... ник... бай... турында сөйлә... мисең? (*Сүздән туктый.*)

Ш ө җ а г. Әхмәт әфәнде, ни эшләдең син? Әйдә кайтыйк! Әйдә тор!

Ә х м ә т. Ә?!.. (*Кулын селти, изелеп төшә.*)

Ш ө җ а г (*коридорга чыгып, кул чабып*). Булды, тәмам мин дигәнчә булды. (*Кабинетка карап.*) Кадал, чәнчел, бәдбәхет! (*Сул яктагы бүлмә ишеген ачып.*) Ну, иптәшләр, әйдәгез!

И к е к е ш е чыга.

Ну, әйдәгез, теге тәмам изелде, барыгыз, култыклап алып чыгыгыз да ямщик белән өенә илтеп ташлагыз. Менә сезгә ямщигегезгә акча. Менә чәйлек. Өендә «Каян китердегез?» дип сорасалар, минем белән булганлыгын әйтмәгез. «Кабак идәнендә җыгылып ятадыр иде, частька җибәрмәкче булганнар иде, без, таныган кеше булганга күрә, өенә илтеп куйыйк дип әйтеп китердек» диегез.

Б е р к е ш е. Була, була. Түлке монда чәйлек бик аз.

Ш ө җ а г. Аз булса, икенче вакыт тагын бирермен. Әй, Яфим!

О ф и ц и а н т керә.

Бар, булды. Ямщиккә чыгарып салырга син дә булыш. Мин бу бүлмәдә качып торам, мине күрмәсен. (*Уң як ишеккә кереп китә.*)

Официант белән ике кеше, кабинетка кереп, Әхмәтне уяталар.

О ф и ц и а н т. Әй, князь, әй, барин! Монда йокларга ярамый, бар өеңә кайт! Әйдә, ямщик белән кайтарып куябыз.

Б е р к е ш е. Әхмәт абзый! Әхмәт абзый! Әйдә, өеңә кайт.

Ә х м ә т. Ә?.. Кая?..

Җитәкләп алып чыгып китәләр. Шөҗаг ишекне яртылай ачып, шайтан кыяфәтләре белән карап көлеп кала.

Ш ө җ а г (*алар чыгып киткәч, коридорга кереп, шайтан көлүләре белән көлеп*). Ха-ха-ха! Нишләттем! Мине Шөҗаг диләр. Шөҗаг шулай итеп үч ала ул! Мин әле сине болай гына калдырмам, җиде буыныңа кадәр җитәрмен! Тамырларыңны берәм-берәм суырырмын. Ха-ха-ха! (*Чыга.*)

П ә р д ә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ МӘНЗАРӘ

**Әхмәтнең фатиры. Уртача гына җыештырылган. Уң тарафта диван, өстәл һәм эскәмияләр, түрдә һәм сул тарафта ишек. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә Әхмәтнең хатыны Ф ә х е р н и с а һәм Ш а һ е н г ә р ә й сөйләшеп утыралар.**

#### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ш а һ е н г ә р ә й һәм Ф ә х е р н и с а.

Ф ә х е р н и с а. Нишләтим соң инде, әти, мин инде аны бик күп вәгазьләп, аңар бик күп ялынып карадым. Мин инде аның аягына гына җыгылмадым. Ялындым, ялвардым, һичбер аңар сүземне тыңлата алмадым. Хәзер ул минем алдымда эчмәскә дип вәгъдә куя, шуның артыннан ук өстен киенә дә чыгып китә. Аның иптәшләре ишегалдында саклап торган шикелле көтеп торалар да, аны үзләре белән бергә алып китеп эчертәләр, исертәләр дә ахырдан ямщик белән өйгә китереп ташлыйлар.

Ш а һ е н г ә р ә й. И Раббым, и Раббым, үзең тәүфикъ бир.

Ф ә х е р н и с а. И әтием, мин дә ничә вә ничә мәртәбәләр аның хакында догалар укып карадым, ничә мәртәбәләр нәзерләр әйттем, ничә мәртәбәләр бөтен Коръәнне укып чыктым, шулай да булса бер тиенлек тә файда итә алмадым. Ул һаман да үз юлында йөри. Шул бәдбәхет Шөҗагка катнашканнан бирле, шул Шөҗаг белән йөри башлаган көннән бирле һичбер игә-җүнгә килгәне юк. Әгәр дә шул Шөҗаг булмаган булса иде, ул һичбер вакыт мондый хәлләргә төшмәгән булыр иде. Менә инде хәзер өч ел булды, шул өч ел эчендә мин аның һичбер аек көнен күргәнем юк дисәм дә хата булмас. Һәр көн шул Шөҗаг, йөзе кара, аны котырта да алып чыга, аны төн буенча йөртә дә эт итеп өйгә китереп ташлый, аннан соң ул икенче көнне аның өстеннән көлеп йөри. Хәзер инде

бай үзенең болай итеп йөрүеннән тәмам туйган, ди, бүген яки иртәгә куып чыгарам, дип әйтә, ди.

Шаһенгәрәй. Нәрсә дисең, иртәгә куып чыгарам дип әйтә дисеңме?

Фәхернисa. Ие, бүген яки иртәгә куып чыгарам дип әйтә, ди. Бичара, мескен, шул Шөҗаг аркасында гына харап булды. Шөҗаг, үзе зур приказчик булып калыр өчен, безнекен шул хәлгә китерде. Безнеке, шуны белмичә, һаман шашып йөри. Хәзер инде тормышыбызның бер рәхәте, бер тынычлыгы калмады. Әүвәлдә нинди мөлаем, нинди акыллы, нинди күркәм бер кеше иде. Хәзер, бу эшкә катнашканнан бирле, йөзендә һичбер нур әсәре калмады.

Шаһенгәрәй. И Раббым, и Раббым, мин сезне бу хәлгә калгансыздыр дип һичбер уйламыйдыр идем.

Фәхернисa. Аһ! (*Җыламсырап.*) И әтием! Сез мине шул кешегә бирдегез, мин ул кешене башта чын күңелемнән яраттым, хәзер дә, гәрчә оят булса да әйтим, мәхәббәтем әүвәлгедән ким түгел, аның матур итеп бер каравы минем өчен бөтен дөнья нигъмәтләреннән артык тора. Ләкин, ни хәл итим, хәзер бөтен тормышыбыз шул Шөҗаг аркасында харап булды. Менә инде тәмам бер ел булды, үзенең алган жалуниясеннән бер тиенен дә өйгә китергәне юк. Һәммәсен үз юлына тотып бетерә. Менә инде кичә алты ай булды, фатир өчен бер тиен түләгәне юк, өс-башыбызга бер тиенлек нәрсә ясаганы юк. Бу көнге көндә аш пешерергә – ит, камыр басарга – он, әйбер пешерергә – май, чәй эчәргә – шикәр, мичкә ягарга – утын, самавыр куярга – күмер, сучыга бирергә – акча – бернәрсә дә юк. (*Җылый.*)

Шаһенгәрәй (*җылап*). И кызым, кызым, соң син ни өчен бу көнгә кадәр бу эшләрнең берсен дә миңа әйтмәдең? Син бит минем кадерле кызым идең, мин дә, анаң да сине тәрбияләп үстердек. Без соң сине шундый начар, шундый кабахәт, шундый эштән чыккан бер кеше белән торырсың дип үстердекмени?

Фәхернисa. Әти, мин соң ни эшлим? Зарланып кая барыйм? Бу көнгә кадәр, минем өлешемә чыккан көмешем, дидем дә, риза булып тордым, шул начар күңелсез сүзләрне сөйләп сезнең күңелегезне бозсам, сезне борчысам, сез миңа рәхмәт әйткән булыр идегезмени? (*Җылый.*)

Шаһенгәрәй. Җылама, кызым, җылама, син бит безнең кадерле кызыбыз, без сине андый начар кешегә тап булырсың дип үстермәдек, безнең үз сөягебез үзебездән авыр түгел, әлхәмделилла, минем кодрәтем, сине генә тәрбия итәрлек куәтем бар. Ул синең кадереңне белми

икән, без сине бик яхшы беләбез. Иртәгә үк син безгә кайт, мин сине элек ничек тәрбия иткән булсам, хәзер дә һич авырсынмаенча тәрбия итәчәкмен.

Фәхерниса. Аһ, әтием, мин соң ни хәл итим? Бу хәлләргә ничек итеп түзим?

Шаһенгәрәй. Җылама, кызым, җылама, түз. Сабыр иткән морадына җиткән, диләр. Сабыр итсәң, сиңа Алла морадыңны бирер. Әле соң ул бу вакытка кадәр кайда йөри? Ник кайтмый?

Фәхерниса (*җылаган тавыш белән*). И Раббым!.. Мин аның кайда йөргәнен кайдан белим!

Шаһенгәрәй. Фәхерниса кызым, Фәхерниса, син бер дә кайгырма, әгәр дә ул һаман шул юлдан йөри икән, син бер дә хафаланма, әйдә безгә кайтып тор. Ул үз юлында йөрсен, теләсә, шул юлында йөреп чәнчелеп китсен. Хәзер инде төнлә белән кайтып йөрү яхшы түгел, иртәгә иртә белән үк тор да безгә бар. Аннан ахыргысын мин үзем карармын.

Фәхерниса җылый.

Җылама, кызым, җылама. Ходай кушса, Алла боерса, бернәрсә дә булмас. Син бу көнгә генә сабыр ит тә, иртәгә дә шул хәлендә булса, тот та үзебезгә кайт, зинһар, дип әйтәм, син минем йөрәгемне бозма, җылама, минем хәзер тәкать тотар хәлем калмады. Мин хәзер кайтам, хәлеңне анаңа да сөйләрмен. Син, зинһар, бу көнгә сабыр ит тә, иртәгә өйгә кайт.

Фәхерниса. Соң, әти, мин кешеләрнең сүзләренә каршы ни хәл итеп тәкать итәрмен? Кешеләрнең сүзләренә мин ничек итеп түзәрмен?

Шаһенгәрәй. Хафаланма, кызым, хафаланма, бернәрсә дә булмас. Алла дәрт биргәнгә дәрманын да бирер. Халыкның көлүеннән куркып, үз-үзеңне әрәм итәргә ярамый, зинһар, дип әйтәм, минем күңелемне бозма, мин иртәгә иртә белән үк сиңа ат җибәрермен, син бар нәрсәңне төя дә өйгә кайт.

Фәхерниса (*җылый*). Әй, әтием, әтием, бу эш кеше арасында бик хурлык бит!

Шаһенгәрәй. Кайгырма, кызым, кайгырма, Алла ташламаса, бүре ашамас, диләр. Син ул эшкә бер дә хафаланма, өйгә кайткач, Алла боерса, бик рәхәтләнеп, бик тынычлап гомер итәрсең. Ярый, кызым, хәзергә мин кайтып торыйм.

Фәхерниса маңгаеннан үбә. Фәхерниса да, Шаһенгәрәй дә җылыйлар.

(*Җылаган тавыш белән*). Ярый, кызым, хәзергә сау бул! Авырлыкка бик авыр хәл дә инде, ни эшләмәк кирәк,

бер эш эшләр хәл юк. Мин иртәгә ат җибәрермен, син бернәрсәгә дә карама, төял дә кайт. (*Шаһенгәрәй дә, Фәхерниса да җылыйлар.*) Хуш, сау бул, кызым!

Җылап чыгып китә. Фәхерниса диванга җыгылып җылап кала. Бераз вакыт тын.

### ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Фәхерниса һәм Хәмди.

Хәмди (*ишектән акрын гына кереп*). Әле һаман кайтмаган икән. Бу ир дигән нәрсәгә һич ышаныч юк. Борынгылар әйткәннәр, иргә ышанма, Иделгә таянма дип, бик дөрес сүз. Фәхерниса бичара төн йокыларын йоклый алмыйча һаман аны көтеп утыра, ә ул, йөзе кара, аның кадерен белмичә, әллә кайларда йөри. (*Фәхерниса янына килеп һәм җилкәсеннән сөеп.*) Нихәл, кызым, исәнме?

Фәхерниса (*йокыдан сискәнеп уянган кеше төсле*). Ә, исәнме, Хәмди әби, син икәнсең, күрми дә торам. Әллә ничек йокымсырап киткәнмен.

Хәмди. Шулайдыр шул, бәгырем, шулайдыр. Ул ир дигән нәрсәләрне көтә-көтә көтек булып бетәрсең. Әле Әхмәт кайтмадымыни?

Фәхерниса. Юк әле.

Хәмди. Әле менә безнең Бәдигыльҗамалның кияве Хәйрулла да кайтмаган. Икәү бергә кайгырып утырдык-утырдык та, тукта әле, Фәхернисаның да хәлен белеп чыгыйм дип, сиңа кердем. Хәйрулла кайтмый микән дип тәрәзәдән карап утырадыр идем, сезнең өйдән бер кеше чыгып китте. Мин әйтәм, мөгаен инде, бу Әхмәттер, йөзе кара, бу вакытта инде кая бара икән дип калдым. Әле соң ул кая чыгып китте тагын?

Фәхерниса. Юк, ул үзе түгел иде, әти иде. Минем хәлемне белергә килгән.

Хәмди. Шулайдыр шул, кызым, шулайдыр. Бала дигән нәрсә үзәкне өзә инде ул. Менә минем кызым Сараның да кияве шул төн буенча кайтмый йөри торган иде. Сара шуңа бик хафаланадыр иде. Мин инде, карчык кеше, нәрсә беләм. Шулай да булса, кияү тизрәк кайтсын иде дип, намазлык өстенә утырып догалар кыла торган идем. Һичбер укымаган нәрсәләрем калмыйдыр иде, үзем белгән бер доганы да калдырмыйча укып бетерә торган идем. «Аятел көрси», «колһуалла»ның һичберсе дә калмый торган иде. Бичара, мескенем Сара урын өстендә төн буена бер яктан бер якка әйләнеп, төн буенча йоклый алмый чыгадыр иде. Әле соң синең этиең Шаһенгәрәй ни эшкә дип килгән?

Ф ә х е р н и с а. Юк, бернәрсәгә дә дип килмәгән, узып барышлый хәлләрен генә белим дип кердем, ди.

Х ә м д и. Әллә юк исә син, кызым Фәхерниса, авырыйсың дамы?

Ф ә х е р н и с а. Юк, авырмыйм.

Х ә м д и. Алла сәламәтлек кенә бирә күрсен, авыру бик читен нәрсә. Бервакытны мин шулай йоклап ятадыр идем, бервакытны, ни күзем белән күрим, албасты өстемне бөтенләй каплап алган, әй тырышам, әй тырышам котылырга. Котылып булмый. Шуннан әгузе бисмилләмне әйтеп, өстемне ачып җибәреп карасам, бернәрсә дә юк, имеш, үзем бөтенләй шабыр тиргә батканмын.

Ф ә х е р н и с а. Андый бастырылулар була шул ул.

Х ә м д и. Була, була, бик була. Менә мин үзем бервакытны, Сарадан элекке балама корсаклы вакытымда, бик каты бастырылдым. Соңыннан чалпу да салдырып[2], куркулык койдырып[3] та караган идем, бер дә файдасы тимәде.

Ф ә х е р н и с а (*урыныннан сискәнеп торып*). Һай, капкадан бер кеше керде бугай, безнеке булмасын.

Х ә м д и. Чү, алай булса, мин дә чыгып китим. Йә тагы мине күреп орыша башлар, хуш, кызым. (*Чыгып китә.*)

Ф ә х е р н и с а. Хуш.

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ф ә х е р н и с а ялгыз.

Ф ә х е р н и с а. И Раббым! Мин ни өчен бу кадәр бәхетсез бәндә булдым? Кыз булып үскән чагымда мондый бәхетсезлекләргә очрармын дип һичбер уйламаган идем. Үз гомеремдә кадерле бер кыз булып үстем. Атам-анам мине никадәр кадер-хөрмәт иттеләр. Мине никадәр сөеп үстерделәр. Мине тәүфикълы, талигъле бер егеткә бирәбез дип, Әхмәткә бирделәр! (*Бераз торып.*) Дөрес, без башта бик бәхетле идек, бер-беребезне яратышып бик яхшы гомер итәдер идек. Ах, йөзе кара Шөҗаг! Шул гына, йөзе кара, Әхмәтне юлдан яздырды. Шул гына, йөзе кара, Әхмәтне харап итте. Алланың ләгънәтләре яусын шул бәдбәхеткә! Мине болай рисвай, бу рәвештә харап иткән өчен Аллаһы Тәгалә ул йөзе караның урынын җиде кат җәһәннәмнең төбендә кылсын! (*Диванга ятып җылый, бераз торгач.*) Һаман да кайтмый. Бәлки, ул таң аткан-

---

Т а л и г ъ л е – яхшы киләчәкле, өметле.

чы да кайтмас? Әти миңа нинди авыр сүзләр сөйләде. Мин ничек итеп аның белән бергә торган бу йортларны ташлап китим? Ничек итеп мин бу авыр хәлләргә түзим? И Раббым! Мине бу авыр газаплар белән газаплаганчы җанымны алсаң, мең өлеш артык булыр иде! (*Җылый. Бераздан торып.*) Никадәр көтсәң, никадәр җыласаң да файдасы юк. И Раббым! Минем шикелле арыган, талган бәндәңә мәрхәмәт кыл! (*Утны сүндереп, икенче бүлмәгә чыгып китә.*)

Бераздан ишек дөбердәткән тавыш ишетелә. Фәхерниса, ут яндырып чыгып, ишекне ача. Ишектән алпан-тилпән килеп Әхмәт керә.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әхмәт, Фәхерниса.

Әхмәт (*башыннан бүреген алып*). Мә!

Фәхерниса алып куя.

(*Соңра өстеннән киемен салып.*) Мә! Монысын да алып куй! Нинди яхшы хатын, ә? Ирен бераз гына көтеп торырга да ярамый.

Фәхерниса киемен алып куя.

Фәхерниса. Ашыйсың киләме?

Әхмәт. Ә?

Фәхерниса. Ашыйсың киләме? Сиңа дип аш калдырган идем.

Әхмәт (*диванга җыгылып*). Бар, китер, ашыйм. Ууууу!

Фәхерниса аш китерә. Әхмәт һаман алпан-тилпән килеп, йөзтүбән төшеп, ашарга тотына.

Фәхерниса. Йә, зинһар, җүнле генә итеп аша инде.

Әхмәт (*кашыгын куеп*). Ә хәзер инде минем сиңа ашавым да ярамый башладымыни инде? Уууу! (*Диванга җыгылып йокыга китә.*)

Фәхерниса. Йә инде, дим, зинһар, кеше төсле генә кыйлан инде. (*Уятырга тырыша.*) Әйдә, дим, инде, зинһар, урыныңа барып ят.

Әхмәт сизми.

И Раббым! И Раббым! Менә безнең хәлебез һаман шул инде. (*Утны сүндереп, икенче бүлмәгә кереп китә.*)

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ МӘНЗАРӘ

Шул ук бүлмә, иртә булган. Ә х м ә т һаман да диванда аунап ята.

### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ә х м ә т, Ш ө җ а г.

Ш ө җ а г (*ишектән кереп, шайтан карашы белән якягына караныл*). Әһә, һә! Бик яхшы туры килде әле. Бу малай һаман йокысыннан уяна алмаган икән. Ә мин, мин? Мин андый юк-бар эшләргә генә бирешә торган сорттан түгел. Кичә бергә булдык. Ә бүген һаман аяк өстендә. Бай чыкканчы, күптән кибеткә төшеп, үз эшемдә булдым. Ә бу малайның әле хәбәрендә дә юк, йоклап ята. Синең шикелле малайларны Шөҗаг шикелле кешеләр шулай итәләр аны! (*Әхмәткә мыскыл итеп карап.*) Нихәл, туганкай, ни эшләп ятасың? Синең әле бөтенләй дөньядан хәбәрең юк. Ә мин инде анда эшне баштанаяк төпләп куйдым. Туганкай, инде бик яхшы хәбәрең булсын. Бүген инде минем сине аякка бастыруның актык минутлары! Бай хәзер инде сине расчет биреп чыгарып җибәрәчәк. Мин моннан соң доверенный булачак. Ә син, син? Моннан соң урам буенча җил сызгыртып йөриячәк. Нихәл, самавыр куючы малай? Хәзер инде дөньяны таныдыңмы? Синең шикелле доверенныйларга Шөҗаг шикелле кешеләр шулай итеп дөньяны таныталар. (*Халыкка карап.*) Бай аны чакыртырга дип бер малай җибәрмәкче булган иде. Эш яңадан йә бозылып китәр дип, мин үзем килдем. Хәзер инде аны бай күзенә ничек тә булса тәмам кеше булган кыяфәттә итеп күрсәтергә кирәк. Юлда килгән чагында кеше итеп күрсәтә торган даруны үзем белән алып килдем. (*Кесәсеннән ярты шешә коньякны алып, халыкка күрсәтә. Аны янәдән кесәсенә салып куя. Соңра Әхмәтне төрткәләп.*) Әхмәт әфәнде! Әхмәт әфәнде! Әй, Әхмәт! Тор инде. Сине бай чакыра. Күрәсеңме, хәзер бит инде сәгать тугыз булган! Бай кибеткә төшеп утырды.

Ә х м ә т (*йокы арасыннан*). Ә?

Ш ө җ а г. Әхмәт әфәнде! Бай сине чакыра, әйдә тор инде.

Ә х м ә т (*аңгы-миңге булып торып*). Ә, ни дисең?

Ш ө җ а г. Әйдә тор инде, бай сине чакыра. Әйдә, тизрәк тор, сәгать тугыз булган.

Ә х м ә т (*торып, башын учлап*). Алла, башым!

Ш ө җ а г. Зарар юк, зарар юк, мин синең башыңның авыртасын алдан ук белдем. Бай сине чакыртырга дип бер малай җибәрмәкче иде. Мин, синең хәлеңне белгәнгә

күрә, малайны җибәрмичә үзем килдем. Юлда килгәндә, синең башыңны төзәтергә дип, яртыны да ала килдем.

Ә х м ә т. Ну?

Ш ө җ а г. Чынлап, син үзең генә бит мине якын күрмисең, ә мин сине бик яратам. Әйдә, тизрәк шуны җибәр дә базарга төшәбез. Анда бай сине көтеп тора.

Ә х м ә т. Нәрсә дисең? Бай көтеп тора?

Ш ө җ а г. Ие, бай көтеп тора.

Ә х м ә т. Харап булдык алай булгач, тукта, мин битемне генә җуыйм.

Ш ө җ а г. Зарар юк, зарар юк, җумасаң да ярый, әйдә, тизрәк шуны гына җибәр дә кибеткә чыгабыз. Менә сиңа закускага алма да китердем. (*Алманы өстәлгә куя, коньякны стаканга сала.*)

Ә х м ә т. Кибеттә кемнәр бар? Кеше юкмы?

Ш ө җ а г. Мин чыкканда юк иде. Бәлки, хәзер бардыр. Әйдә, эч тизрәк.

Әхмәт эчә.

Ә х м ә т. Соң инде мин бу кыяфәт белән чыксам, анда кеше арасында көлке булмаммы?

Ш ө җ а г. Юк, юк, бернәрсә дә юк. Тик бераз баш төзәтергә генә кирәк. Әйдә, тагы эч шуны. (*Стаканга калдыгын сала.*)

Ә х м ә т. Күп булыр бит ул?

Ш ө җ а г. Юк, юк, күп түгел, башың гына төзәлер.

Әхмәт эчә, шул вакытта ишектән Ф ә х е р н и с а керә.

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ә х м ә т, Ф ә х е р н и с а, Ш ө җ а г.

Ш ө җ а г (*Фәхернисаны күреп, үзалдына*). Әһем, әһем, әһем. Кайдан бу йөзе караны җил ташлады?

Ф ә х е р н и с а (*Шөҗагны һәм Әхмәтнең эчкәнен күреп*). И Раббым! Кайдан тагын бу шайтан өебезгә керде! (*Ачуланып.*) Бу ни кылануыгыз инде бу? Дәҗҗал! Иремне читтә генә аздыруыгыз җитмәгән икән, тагы монда, өйгә килеп тә аздыра башладыгызмыни инде?

Ш ө җ а г (*шайтан күзләре белән карап*). Нәрсә? (*Әхмәткә.*) Әйдә, Әхмәт әфәнде, әйдә. Анда бай сезне көтеп тора.

Ф ә х е р н и с а. Һи, бәдбәхет, дәҗҗал, мәлгунь!

Ш ө җ а г. Ни дисез? Нәрсә?

Ә х м ә т. Җитәр сиңа, хатын. (*Шөҗагка.*) Әйдә, әйдә, аңар карама.

Чыгалар.

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ф ә х е р н и с а ялгыз.

Ф ә х е р н и с а (*урындыкка утырып, җылап*). И Раббым! Раббым! Ни өчен, нинди гөнаһ шомлыкларыбыз өчен син безгә бу залимне, бу мәлгунь, бу дәҗҗалны җибәрдең? И Раббым! Никадәр күз яшьләре түгә-түгә Әхмәткә тәүфикъ теләдем, аның өчен никадәр догалар кылдым, шулай да догаларымны кабул итмәдең. Инде без ни эшлик, инде без кая барыйк? Шулай ук безне ач-ялангач, кеше арасында хур, рисвай калдырырсың микәнни?

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ф ә х е р н и с а, х е з м ә т ч е.

Х е з м ә т ч е (*ишектән кереп*). Фәхерниса апа!

Ф ә х е р н и с а (*борылып*). Нәрсә?

Х е з м ә т ч е. Мине абзый җибәрде. Анда төяп алып кайтасы нәрсәләр бар, диде.

Ф ә х е р н и с а (*үзалдына*). И Раббым! Раббым! Бу хәлләргә ничек түзим? Ничә еллар бергә торган бу йортны ничек итеп ташлап чыгыйм? (*Җылый. Бераз торып.*) Ни хәл итим? Түзсәң дә читен, түзмәсәң дә читен. Тукта, төзәлмәсме, яхшыланмасмы дип, никадәр вакытлар көттем, һичбер төрле дә алга барган эш күренмәде.

Х е з м ә т ч е. Фәхерниса апа, алып кайтасы әйберләреңне әйт әле, мин чыгарып сала торырмын.

Ф ә х е р н и с а (*үзалдына*). И Раббым! Шулай ук моннан китәргә туры килер микәнни? (*Җылый.*) Уф, һичбер хәл итәр хәл юк! Китсәң дә вай! Китмәсәң дә вай! (*Бераз торып.*) Юк инде, болай итеп торуда һичбер хәер калмады. (*Күзләрен сөртеп, хезмәтчегә.*) Әнә шул сандыкларны алып чык.

Хезмәтче сандыкны алып чыгып китә.

Үз гомеремдә мондый күңелсез эшләр булыр дип һич тә уйламаган идем. Китү, китү, бергә гомер иткән ireңне ташлап китү, бу ни дигән сүз? Бу нинди начар эш? (*Бераз торып.*) Юк, ни булса да булыр, китәм.

Хезмәтче икенче сандыкны алып чыга.

Китәм. Гомерлеккә китәм. Анда рәхәт булмаган шикелле, миңа монда да юк! Тәкъдирем шулайдыр, ни хәл итим?

(*Җылый, ишектән кереп китә. Бераздан башына шәл ябынып чыгып, өенең һәрбер җирләренә карап.*) И минем әүвәлдә рәхәтләнеп, шатланып гомер сөргән, соңыннан минем бәхетсезлегемә, минем хурлыкка төшүемә, минем рисвай булуыма, минем кеше кулына калуыма сәбәп булган йорт! Хуш, сау бул! (*Җылап чыгып китә.*)

Бүлмә бераз вакыт буш тора. Бераздан бик сүрән йөз белән Әхмәт кайтып керә.

## БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әхмәт ялгыз.

Әхмәт (*ишектән кереп, диванга утырып*). Гомереңдә ишетмәгән хур сүзләрне баеңнан ишетче! Бу хурлыкка ничек итеп түзәргә кирәк? Син әле исерек икән, бераздан, айныгач килерсең, бар әле хәзергә кайтып тор, ди. Ах, хурлык, бу, валла, хурлык, моңар ничек итеп түзәргә кирәк? Мин, боерган булса, моның ачуын алмый калмам әле. Фәхерниса, Фәхерниса, кая, минем ашыйсым килә, чәй эчәсем килә! Самавыр китер, ичмасам чәй эчеп бераз ачуымны басыйм. Фәхерниса, Фәхерниса! Әллә юк исә чукрак булганмы? (*Ишекне ачып.*) Фәхерниса, Фәхерниса! Ахры, тышка чыккандыр. (*Диванга килеп утыра.*) Миңа нигә кирәк иде инде ул кадәр эт булып исергәнче эчәргә? Үзем дә шул аңгыра! Ул кадәр күп эчкән булмасам, бай да сизмәс, бернәрсә дә булмас иде. Тукта әле, мондагы сандык кая киткән? Фәхерниса, Фәхерниса, кая син? (*Эзләргә тотына, әрле-бирле йөри, бүлмәләрдән карый.*) Юк, бер җирдә дә юк! Монда икенче сандык та юк. Бу кайда булыр бу? Фәхерниса, Фәхерниса!

Ишектән малай керә.

## АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Әхмәт, Сабир.

Әхмәт (*малайга*). Нихәл, ни йомыш?

Сабир. Мине Фәхерниса апа җибәргән иде, менә бу хатны Әхмәт абзаңа төшереп бир дип. Мин кибеткә төшергән идем. Ул монда юк, өенә кайтып китте, шунда илтеп бир, диделәр. Шуңар күрә монда килдем.

Әхмәт. Кая, бир хатны. (*Малайның кулыннан хатны ала. Аның кулында яңадан икенче бер хатны күреп.*) Ансы тагын нинди хат, ансы кемгә?

С а б и р. Ансы да сезгә. Мин кибеттән чыгып барадыр идем, баегыз чакырып алды да, менә бу хатны да Әхмәткә бир, диде.

Ә х м ә т. Хуш?

С а б и р. Башка йомыш юк. (*Чыгып китә.*)

### ҖИДЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ә х м ә т ялгыз.

Ә х м ә т (*хатның берсен ачып укый*). «Мөхтәрәм хәлялем! Мин синең ничә еллардан бирле әчеп, мине рәнҗетүеңә бу көнгә кадәр чыдап тордым. Инде хәзер тәкать тотар хәлем калмады. Шул сәбәптән мин хәзер, сине ташлап, этиләргә кайтып киттем. Миннән бәхил бул. Хәлялең Фәхерниса». (*Әхмәт күзләрен зур итеп ачып карап.*) Ә? Мине ташлап киткән? Фәхерниса мине ташлап киткән? Бу була торган эш түгел! Мин моңар ышанмыйм! Хурлык бу, хурлык! Хурлык өстенә хурлык! Мин бу хурлыкларга ничек итеп түзим? Ах, мин нинди бәхетсез! Юк! Юк! Фәхерниса юри мине куркытыр өчен генә әйткән, юри мине сынар өчен генә язган! Мин моңар ышанмыйм! Малайга юри ике хат язып биргән дә иң әүвәл берсен укытып, мине кайгыга төшермәкче, икенчесен укытып, мине шатландырмакчы булган. (*Икенче конвертны җырта. Укый.*) «Әхмәт, бу көнгә кадәр мин синең исереклегеңә, синең эчеп йөрүеңә бик күп түздем. Инде син бу көннән соң миңа кирәк түгел. Хуҗаң Җамалетдин». (*Кулыннан кәгазьләр төшеп китә. Диванга егыла. Шул хәлдә бераз ятканнан соң, башын күтәреп, кулын маңгаена куеп.*) Өнемме бу минем, төшемме? Әллә юк исә мин саташаммы? (*Үзен-үзе тоткалап карап.*) Юк, төшем түгел, өнем. Һәрбер гәүдәм җирендә, ләкин хәзер башым гына урынында түгел. Тәкъдир минем башыма бәлане потлап-потлап яудырырга карар биргән икән. Тәкъдир мине ахыр сулуыма кадәр җәберләмәкче була икән. Ярый, булсын, ул үзе теләгәнчә минем башым белән уйнасын!

С у д е б н ы й п р и с т а в белән й о р т х у җ а с ы керә.

Ах, Газраил дә килеп җитте! Бу минем җанымны түгел, малымны алачак Газраил!

Х у җ а. Гаспадин пристеф, менә ул кеше.

П р и с т а в. Яхшы, господин Әхмәт Мөхәммәдевич, без сезнең нәрсәләрегезне язабыз, яки сез хәзер акча бирәсез.

---

Х ә л я л – электә ире хатынына, хатыны иренә дәшә торган сүз.

Ә х м ә т. Ярый, ярый, язygыз! Бар нәрсә дә сезгә булсын, рәхәтләнегез! (*Халыкка карап.*) Бүген минем өчен иң бәхетсез көн икән! Бәланең бөясе җимерелеп, бүген берьюлы мине килеп басты. (*Диварларга карап.*) Хушыгыз, күңелле йортларым! Хушыгыз, мәхәббәтле җиһазларым! Хәзер инде сез минеке түгел! Хәзер инде мин сездән мәңгегә аерылам! (*Урындыкка егыла.*)

П ә р д ә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

**Бик начар һәм кечкенә генә бер номер. Бөтен җиһазы: тәрәзә буенда иске, начар бер өстәл, бер такта урындык, дивар буенда начар бер карават, карават өстендә начар бер матрас, начар бер мендәр белән иске бер одеалдан гыйбарәт. Өстәл өстендә бер кыерчык каткан күмәч белән бер стакан тора. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә бер кеше дә юк.**

### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ә х м ә т ялгыз.

Ә х м ә т (*ишектән килеп керә. Өстендә бик начар бер бишмәт, башында начар тәвәккәл бүрек, начар чалбар һәм иске камзул, бүрке белән бишмәтен чөйгә элеп куеп, караватка утыра. Үзалдына сөйли*). Бәхетсезлегемнең иң ахыр сәгатьләре килеп җитте. Башымның авыртканына һич чыдар хәлем юк. (*Бер кесәсеннән кечкенә бер шешә чыгарып.*) Башымны төзәтергә дип, никадәр йөреп карадым, бер тиен акча табып булмады. Әүвәлдә өстәл янында дус булып бергә йөргән кешеләрнең һичберсе дә хәзер йөземә әйләнеп тә карамыйлар. Еракtan мине күрсәләр, миңа очрамас өчен, күрмәмешкә салынып, урамның икенче ягына чыгып китәләр. Шөҗаг, бәдбәхет, әүвәл дус булып йөргән булды. Инде хәзер йөземә карарга да хурлана. Минем болай булуыма шул йөзе кара дәҗҗал сәбәпче булды. Ул бәдбәхет аздырмаган булса, мин бу хәлгә төшмәгән булыр идем. Шул йөзе кара белән (*шешәне күрсәтеп*) менә бу бәдбәхет аркасында мин бу хәлгә төштем. Шулар аркасында йортымнан, малымнан, хатынымнан, балаларымнан аерылдым, шулар аркасында баемнан чыктым. Шулар аркасында мин бу көнгә, бу мәсхәрәлеккә калдым. Хәзер эшләргә кулымнан бер эш килми. Бер-бер эшкә керешмәкче булсам, «син исерек» дип ялламыйлар. (*Тәрәзә янына барып, терсәкләре белән өстәлгә таянып, тәрәзәдән карап.*) Кешеләр һәммәсе кәеф-сафада, кешеләрнең һәммәсе дә шатланып, шау-шу

килеп, көлешеп, рәхәтләнеп бәйрәм итеп йөриләр. Ә мин, мин монда ач-ялангач утырам. Ике көн инде авызыма бер тәгам капканым юк. (*Өстәлдәге каткан күмәч кыерчыгын шытырдатып ашый башлый.*) Әүвәлдә һәр чәй янында җылы, тәмле ашларым буладыр иде. Янымда хатыным, балам шатланышып сайрап утыралар иде, хәзер инде шушы каткан күмәчне кимерергә калдым. И Раббым! Мин инде шулай һәлак булып дөньядан китәрмен микәнни? (*Җылый.*) Чәем булса, ичмасам, чәй эчеп бераз ачлыгымны басар идем. Инде ике көн булды, фатирга акча бирмисең дип самавыр да бирмиләр. Тукта, тагын бер мәртәбә самавыр сорап карыйм, кызганып, бирмәсләр микән. Бирсәләр, һич булмаганда кайнар суга җебетеп, шул күмәч кисәген ашармын. (*Ишекне ачып кычкыра.*) Сабир, Сабир, кил әле монда! (*Башын ишектән алып.*) Хезмәтче малайларга кадәр хәзер минем сүзләремне ишетмәмешкә салына башладылар. И Раббым! Ачлыктан инде аякларымда да куәтләр калмады. (*Караватка утырып бераз тора. Аннан соң ишек янына барып.*) Сабир, дим, Сабир, зинһар, кил, Алла хакы өчен кил, бер генә сүз әйтәм.

Пычрак алъяпкычлы, начар киемле Сабир керә.

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әхмәт, Сабир.

Сабир (*салкын гына*). Нәрсә кирәк? Ни дисең?

Әхмәт. Алла хакы өчен дип әйтәм, миңа самавыр белән чәй китер. Күрәсеңме? Ачлыктан үләм бит инде! Ике көн ашаганым юк. Зинһар, инде сездә бераз гына шәфкать әсәре булса, мине болай ачлыктан үтермәгез!

Сабир. Мин нишләтим, бай бирергә кушмый бит. Элек номер акчасын түләсен, аннан соң бирерсең, ди.

Әхмәт. Соң, әйтегез инде, зинһар, мин монда шулай ачлыктан үлиммени инде?

Сабир. Ансын мин белмим, бай миңа бирмәскә кушты. Кара аны, аңар самавыр бирәсе булма, әгәр бирсәң, үз өстеңә язармын, штраф салырмын, диде.

Әхмәт. Зинһар, туган, алай булса, баеңа барып, тагын бер мәртәбә минем сүзләремне әйтеп, ялынып сорап кара. Бирмәс микән?

Сабир. Ярый, сорап карармын. (*Чыгып китә.*)

---

Тәгам – азык, аш.

ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ә х м ә т ялгыз.

Ә х м ә т. И Раббым! И Раббым! Бар икән күрәселәрем! Шулай ук инде бу ачлыктан үләрмен микәнни? Бу хәлләргә түзүе бик читен. Әгәр тиз генә үлеп булса, тагы да ярар иде. Бу ямьсез дөньядан, бу кабер газабыннан котылыр идем. Хәзер инде минем бу тормышым тормышмыни?

С а б и р керә.

ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ә х м ә т, С а б и р.

С а б и р. Сорап карадым, бай бирмәскә кушты. Ачлыктан үлмәгәе, миңа дисә шунда бөтенләй кадалып китсен, ди.

Ә х м ә т. Ах, рәхимсезләр!

С а б и р (*караватның матрасын күтәрә башлап*). Тор әле!

Ә х м ә т. Ни эшләмәкче буласың?

С а б и р. Бай алып чыгарга кушты. Кандаласы күбәйгәндер, тышка чыгарып кагып керт, диде.

Ә х м ә т. Тимә, тимә, торсын, аның бер кандаласы да юк.

С а б и р. Мин ансын белмим, бай миңа алып чыгарга кушты. Йомшак караватта ятасы килсә, номер акчасын түләсен, ди.

Ә х м ә т. Ярый, ярый, ал! Матрасыгыз белән чәнчелеп китегез, кирәк булса, бөтенләй караватын да алып чыгыгыз, миңа инде караватның кирәге дә калмады.

Сабир матрасны алып чыга.

БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ә х м ә т ялгыз.

Ә х м ә т. Хәзер инде миңа салкын кабергә кереп, мәңге йокыга барырга гына вакыт җитте. (*Яңадан шешәне кулына тотып.*) Һи, бәдбәхет, минем болай булуыма сез сәбәпче булдыгыз! Сез мине болай харап иттегез! (*Тавышын үзгәртеп, кинәттән.*) Тукта әле, мин ни өчен бу кадәр өметсезләнәм, ни өчен мин бу кадәр кайгырам? Миңа бит бүген яшәргә мөмкин. (*Шешәне күрсәтеп.*) Бу бит

акча тора. Моңар бит, бер кадак икмәк алып ашап, тамакны туйдырырга мөмкин. Хәзер барам да икмәк алып ашыйм. Ачлыктан бүген котылам. Иртәгә тагын ни хәл булса да булыр. Бәлки, иртәгә юлым ачылыр да, бәлки, тагы рәхәт яши башлармын?

Өстен киенә. Ишектән чыгам дигәндә генә, судебный пристав белән номер хуҗасы килеп керәләр. Аларны күреп, каушап.

Ярабби Ходаем! Гомеремдә инде бу Газраилне икенче мәртәбә күрәм.

Судебный. Әхмәт Мөхәммәдиевич...

Әхмәт. Беләм, беләм, әйтмәсәгез дә беләм. Сез инде, ахры, минем актык тамчы канымны суырып алганга кадәр артымнан калмассыз. Китәм, китәм, сез әйтмәсәгез дә китәм. Мәңгегә китәм. Моннан соң бу тормышка яңадан бер дә әйләнеп кайтмаска китәм. Ах, бәдбәхет Шөҗаг! Ах, йөзе кара, дәҗҗал! Минем башыма син генә җиттең!

Пәрдә.

# КАЕНИШ

## Уртача тормышлы кешеләр мәгыйшәтеннән

*Пьеса 1 пәрдәдә, 2 мәнзарәдә*

ӘШХАС:

Габделкәрим – уртача тормышлы сәүдәгәр.
Бәдигыльҗамал – аның хатыны.
Ибраһим – аларның улы.
Зәйнәп – Ибраһимның хатыны.
Гөлҗамал – Габделкәримнең кияүгә бара алмыйча картаеп калган кызы.
Хәмидә – шәһәрдә мәшһүр яучы карчык.
Нәсимә – Ибраһимның кызы, 6–7 яшьләр чамасында.

Вакыйга губерна шәһәрләренең берсендә.

### БЕРЕНЧЕ МӘНЗАРӘ

Уртача гына җыештырылган, уртача гына җиһазлы бер бүлмә. Түрдә һәм ике тарафта берәр ишек. Пәрдә күтәрелгәндә, Ибраһим белән Зәйнәп өстәлдә чәй эчеп утыралар. Ибраһим янына кызлары Нәсимә утырган.

БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ибраһим, Зәйнәп һәм Нәсимә.

Ибраһим (*Нәсимәнең җилкәләреннән тотып һәм аңар матур күзләре белән карап*). Нәсимә, Нәсимә, син мине яратасыңмы?

Нәсимә (*балаларча тавыш белән*). Яратам.

Ибраһим. Әниеңне яратасыңмы?

Нәсимә. Яратам.

Ибраһим. Кайсыбызны күбрәк яратасың, минеме, әниеңнеме?

Нәсимә. Сине дә яратам, әниемне дә яратам.

Зәйнәп елмаеп-көлеп утыра.

---

Мәгыйшәт – тормыш.

И б р а һ и м (*Нәсимәнең аркасыннан сөеп*). Нәсимә инде бик зур кыз булган. Әле мин аңар бик матур, күзен йома торган курчак алып кайтып бирмәкче булам.

З ә й н ә п. Ул инде аны күптән бирле сөйли. Беркөнне Фәхри абзыйларда шундый бер курчак күргән дә әти миңа нишләп шундый курчак алып кайтып бирми, ди.

И б р а һ и м (*Нәсимәсенең аркасыннан сөеп, ачык йөз белән*). И-һи-һи! Шулай дип әйттеңмени, кызым?

Н ә с и м ә. Әйттем.

И б р а һ и м. Ярар, кызым, ярар, алып кайтып бирермен. Син шуның белән уйнарсың. Аннан соң, менә дәү булгач, сине остабикәгә бирербез. Гимназиядә укырсың. Җәме, кызым?

Н ә с и м ә. Җә.

З ә й н ә п. Ул беркөннәрдә үк инде, әни, мин дәү булдым ич инде, мин нишләп сабакка бармыйм инде, дип сорап утырадыр иде.

И б р а һ и м. Шулаймы, Нәсимә бик акыллы ул. (*Аркасыннан сөя.*)

З ә й н ә п. Тагы берне ясыйммы?

И б р а һ и м. Юк, җитте инде. Мин хәзер чыгам, барасы җирем бар. Бүген пристеннән бер кешегә җибәргән наложный платежны алырга төшәм. (*Сәгатен чыгарып карап.*) Уһу, сәгать тугыз булган икән. Нәсимә, мин сиңа бүген күзен йома торган бер курчак алып кайтырмын, җәме?

Н ә с и м ә. Җә.

И б р а һ и м (*урыныннан торып, Зәйнәпкә*). Кара әле, минем бу яулыгым каралган икән, кая, миңа бер ак яулык бир әле. Мин сәгать икедә кайтып җитәрмен.

З ә й н ә п. Ярый, хәзер. (*Яулыкны карап алып бирә.*)

Ибраһим өстен киенә, Зәйнәп аның өстенә җәйге пальтосын киертә.

Кара әле, мин бүген әниләргә барып кайтмакчы идем, барыйммы?

И б р а һ и м. Ярар, ярар, бар.

З ә й н ә п. Мин озак тормам, хәзер кайтырмын.

И б р а һ и м. Ярый, ярый, бар. (*Нәсимәгә.*) Кил әле монда.

Нәсимә килә, һәм аны Ибраһим кочаклап-үбеп, кулларыннан тотып.

Җә инде, хуш, сау бул, җә, мине дә бер үп инде.

Нәсимә үбә.

Хуш, Зәйнәп, син дә.

Маңгаеннан үбә, чыгып китә. Зәйнәп озатып кала. Чәй урынын җыештыра.

З ә й н ә п. Әйдә, кызым, теге якка. Мин хәзер дәү әниләреңә барам. Син шунда уенчыкларың белән уйный тор. Мин хәзер кайтырмын. Аннан сиңа тәмле мәмиләр дә алып кайтырмын, җәме?

Н ә с и м ә. Җә.

Ишектән чыгып китәләр. Сәхнә бераз буш тора.

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Б ә д и г ы л ь җ а м а л, соңра Г ө л җ а м а л.

Б ә д и г ы л ь җ а м а л (*кереп, эскәмияләрне рәтләгән булып*). Мәхәббәтсез, тәмам саруымны кайнатып бетерде инде. Ибраһим кайтты исә, шуның белән чукыр-чукыр чукырдашалар, һәрвакыт тезгә-тез куешып утыралар да әҗе дә гөҗе киләләр. Ибраһимның тәмам башын-күзен әйләндереп бетерде инде. Кайдан алдык шул нәрсәне? Өйләнгәнче Ибраһим «әни» дип тирә-ягымда сырышып-сырмашып йөридер иде, хәзер, шул мәхәббәтсезне алганнан бирле, минем белән бер сүз дә сөйләшми. Үзләренең бүлмәләренә керәләр дә шунда дөмегәләр. Һичбер йорт карау дигән нәрсәләрдән хәбәрләре юк. Белмим инде, нинди әфү-тфүләр белән Ибраһимның башын-күзен әйләндергәндер. Ибраһимның тәмам башын-күзен әйләндереп бетерде. Нәрсәсе белән Ибраһимга бу кадәр ярап тора торгандыр. Аларның нәселләрендә им-том бик күп дип ишеткән идем, башта аңар ышанмаган идем, мөгаен инде, болар Ибраһимга шундый бер эш эшләгәннәрдер. Юк исә Ибраһим ул кадәр үк мөкиббән китмәс иде. Ул инде тагы Ибраһим «Нәсимә» ди дә бөтенләй исе китә, ичмасам, балалары бала төсле булса икән, ул вакытта бер сүз дә әйтмәс идең, бөтенләй бит килениең үзеннән өзелгән дә төшкән. Баласы әллә нинди җиде яттан, җилдән туган бернәрсәдер шунда. Үзе һаман тагын ире янында җалманып йөргән була. Һичбер өй эшләрен карамый. Аңар, иренә ярагач, шул җитә. Менә хәзер дә әле өйне җыештырыйм димәгән. Ташлаган да аналарына чыккан да киткән. Аларның чүпләрен син җыештырып йөрергә кирәк.

Н ә с и м ә килеп керә.

Кит аннан, нәрсә монда лыгырдап йөрисең, бар, чык моннан. Сезнең артыгыздан чүбегезне мин җыештырып йөрергә кирәк.

Нәсимә йөгереп чыгып китә.

Һи, мәхәббәтсез, сөйкемсез! Мин синнән генә түгел, анаңнан да туеп беткән, берегезнең дә төсен күрәсем килми. (*Ишек янына барып.*) Гөлҗамал! Гөлҗамал!

Гөлҗамал (*керен*). Нәрсә, эни?

Бәдигыльҗамал. Әйдә, менә кер монда. Җиңгәңнең чүпләрен җыештыр. Без инде аның чүпләрен җыештырырга калган. Бар, канат алып кер. Менә бу идәннәрне себер.

Гөлҗамал чыгып китә.

Беркөнне Мәрфуга килеп сөйләде: Хәйретдиннәргә ашка барган идем, шунда бүрекче Галәвинең хатыны сөйләп утыра, ди. Инде аларның Гөлҗамалларының азау теше ярганына да ун ел бардыр. Нишләп бер дә аңар кияү чыкмый икән, дип әйтә, ди. Йөзе каралар! Минем алма күк кызым өстенә нинди исемнәр тагып йөриләр бит. Картайган, картаймый ни, болар бары да шул Зәйнәп җылан белән аның анасы чыгарган гына сүзләр. Минем кызым ул – җефәк шикелле кыз.

Гөлҗамал керә.

(*Аңар карап.*) Әйдә, себер, җә тагын җиңгәң, аның кулыннан бер эш тә килми, дип сөйләп йөри башлар. Әле дә ул сине, картаеп беткән инде ул, битләренә җыерчыклар керә башлаган инде, бөтенләй төсләрен салган, карчыклар төсе керә башлаган инде, дип сөйләп йөри, ди.

Гөлҗамал. Кем дисең?

Бәдигыльҗамал. Кем булсын, җиңгәң! Син генә аңар «туганым җиңги» дип исең китеп йөри. Ә ул синең исемеңне бөтен дөньяга чәчеп бетерә. (*Урындыкларны күрсәтеп.*) Менә боларның да тузаннарын сөрт. (*Чыгып китә.*)

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗамал ялгыз.

Гөлҗамал (*идәнне себереп*). Кара син аны, минем турыда ниләр сөйләп йөри икән. Мин әле моңарчы аның йомышларын тыңлап, аның кушкан эшләрен эшләп йөридер идем. Моннан соң чәнчелеп китсен, бер эш тә эшләмәм. Мине, картайган, битенә җыерчыклар кергән, дип әйтә, ди. (*Көзгегә карап.*) Минем кай җирем картайган? Бүген әле бары тик кершән генә матур төшмәгән. Ки-

яүгә китмәгән кеше бер мин генә түгел, әнә теге Фәтхулла Мәһруе миннән ничә яшь олы, мин сабакка йөри башлаган вакытта, ул аю шикелле җиткән кыз иде, әле һаман кияүгә китмәгән.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Бәдигыльҗамал, Хәмидә.

Бәдигыльҗамал (*ишектән башын тыгып, кулы белән селтәп*). Кызым, бар тизрәк чык, бар, яучы Хәмидә карчык килеп килә, үзеңне күрмәсен.

Гөлҗамал йөгереп чыгып китә. Хәмидә керә.

Әйдә, Хәмидә абыстай, әйдә, хуш киләсең. (*Үзалдына.*) Ярабби Ходаем, төкле аяклары белән генә килгән булсын. Мөгаен, Гөлҗамалга яучы булып килгәндер инде. (*Кычкырып.*) Әйдә, Хәмидә абыстай. Менә моннан рәхим ит. (*Диванны күрсәтә һәм кулы белән диванның өстен себерә.*) Әйдә, рәхим ит, рәхим ит!

Хәмидә. Яхшы, яхшы, Бәдигыльҗамал, борчылма, борчылма, утырырмын. (*Утыра.*) Җә, бер дога кылыйк.

Дога кылалар.

Бәдигыльҗамал (*урыныннан торып, ишеккә таба барып*). Кая, кызым, самавырга ут салып кына җибәр әле, Хәмидә әбиең килгән.

Гөлҗамал (*тыштан*). Ярый, хәзер.

Хәмидә. Кара әле, кем, Бәдигыльҗамал, мәшәкатьләнмәгез, мин озак утырырга килмәдем.

Бәдигыльҗамал. Юк, юк, куйсын, куйсын, аның бер мәшәкате дә юк. Бик рәхмәт якын итеп килүегезгә! Эчәрбез әле, эчәрбез. Әллә нигә бер килгән кешене чәй эчертми җибәрергә ярыймы соң? Әле шуны әйтим дигән идем, өйдә җиткән кызның булуы бик уңай эш, үзеңә бер зур иптәш була икән. Менә хәзер йорт эшендә бер дә кайгым юк. Гөлҗамал барысын да эшли: самавырын куя, ашын пешерә, мич ашларын сала, керен уа, идәннәрен җуа, аның өстенә әллә никадәр кул эшләре эшли. Инде, Алла кушып, яхшы урынга гына тап булсын, дим. Кыз баланы гомер буена үзеңдә асрап булмый. Алла хәерле урын насыйп итсен.

Хәмидә. Амин, шулай булсын инде. Әле мин дә шундый бер эш белән килгән идем, киленегез дә өйдә юктыр, ахры.

Б ә д и г ы л ь җ а м а л. Юк, юк, өйдә юк, аталарына киткән. Аның шуннан башы кайтмый инде.

Х ә м и д ә. Аның өйдә булмавы бик яхшы булды әле, сездән шуны сорашырмын дип килгән идем әле. Кода-кодагый булгач, сез белә торгансыздыр инде, киленегезнең сеңлесе нинди нәрсә? Төскә-биткә чибәрме? Яхшы, булган нәрсә микән? Кулыннан эш киләме икән? Мине Хисами Хәйруллаларыннан аңар яучы итеп җибәргәннәр иде.

Б ә д и г ы л ь җ а м а л (*чырайларын сытып, үзалдына*). Әй, конарсыз нәрсә, утырасың шунда лыгырдап, мин аны тагын безнең Гөлҗамалга бер-бер җирдән яучы булып килгәндер дип торам. (*Хәмидәгә.*) Кемнәрдән дисең.

Х ә м и д ә. Хисами Хәйруллаларыннан.

Б ә д и г ы л ь җ а м а л. Тапканнар икән сорар җир. Аны алмасалар, улларына кыз таба алмабыз дип белделәр микәнни? Әллә уллары бераз ни җиттерәк, тиле-милерәк нәрсәме?

Х ә м и д ә. Юк, алай түгел, бик чибәр. Бик тәүфикълы, кулыннан бик яхшы эш килә торган бала.

Б ә д и г ы л ь җ а м а л. Әллә булмаса башка берәр гаебе бармы?

Х ә м и д ә. Юк, андый-мондый һичбер гаебе дә юк.

Б ә д и г ы л ь җ а м а л. Соң, алай булгач, нигә аларга барып җыгылганнар, без монда берсенә сөртенеп бик уңган идек инде. Көне-төне аналарыннан башы кайтмый, һичбер өйне карыйм дими, дөньяның анысы җитешә микән, монысы җитешми микән дими. Ире булгач, шул җиткән. Ире каршында ихахайлана, ире чыгып китте исә, бүлмәсенә керә дә дөмегә дә ята. Без аңа монда хезмәтче булып йөрергә кирәк. Бар белгән эше киенү дә ясану. Бизәнеп, ире каршысында киерелеп торырга гына белә. Ир бөлдергеч хатын. Юк ул, дөньяда алай гына итеп торып булмый. Дөнья булгач, аның җиткән җире дә була, җитмәгән җире дә була, дөнья булгач, аны кайгыртырга да кирәк була.

Х ә м и д ә. Мин берничә җирләрдән сорап караган идем, миңа алай дип яманламадылар. Бик уңган, бик җитез, бик булган кыз, диделәр.

Б ә д и г ы л ь җ а м а л. Булган, булмый ни! Безгә дә аның монсын шулай дип мактаганнар иде. Без, сукырлар, шул сүзләргә ышанып барып сөртендек.

Х ә м и д ә. Ярый алайса, шулай икән. Мин шуны гына сездән сорашыйм дип килгән идем. Ярый, хуш, сау бул!

Б э д и г ы л ь җ а м а л. Ярый, хуш!

Х э м и д э. Алайса, сезнеңчә алар мәгъкуль кешеләр түгел икән?

Б э д и г ы л ь җ а м а л. Әйтәм ич, бер адәм үләксәсенә барып сөртенәселәре килсә, алсыннар!

Х э м и д э (*торып, чыга башлап*). Ярый, Аллага тапшырдык, хуш, сау булыгыз, сезне борчыдым.

Б э д и г ы л ь җ а м а л. Ярый, хуш! Кара әле, сиңа шуны да әйтим, минем бу сөйләгән сүзләремне син тагы кодагыйларга барып әйтә күрмә, алар усаллыкны беткәнче белә торган явыз, начар кешеләр. Әгәр дә мин әйткәнлекне белсәләр, минем күземне дә ачырмаслар, бөтен зәхмәт укларын миңа кадый башларлар. Әле без инде аның берсеннән дә тәмам гаҗиз булып туеп беттек. Ибраһимның тәмам башын-күзен әйләндереп бетерделәр. Хәзер инде Ибраһим безнең улыбыз түгел, алар аны инде үзләренә тәмам кол итеп бетерделәр. Ибраһимның тәмам авызынтелен бәйләп бетерделәр.

Х э м и д э. Җә, ярый, хуш!

Б э д и г ы л ь җ а м а л. Хуш!

Хәмидә чыгып китә. Бәдигыльҗамал бераз ишек ачып озатып кала.

## БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Б э д и г ы л ь җ а м а л ялгыз.

Б э д и г ы л ь җ а м а л (*ачуланып, кулларын селти-селти*). Лыгырдап йөри шунда, үләсе карчык, мин аның андый эш белән килгәнлеген белсәм, бусагамнан аягын да атлатмаган булыр идем. Үләрсең хурланып! Аларның җибер шикелле бер-бер артлы тупырдаган адәм актыгы кызларына кияү чыксын да, синең бердәнбер алма шикелле газиз балаңа кияү чыкмасын, имеш! Ачу китереп лыгырдап килеп йөргән бу карчыгын әйтер идем... Кыйнап чыгарасы нәрсә, бу хурлыкка мин чыдый алмыйм! Үз сүземне итәрмен, Алла боерса, ни эшләсәм эшләрмен, Ибраһимнан буләтчәсен аертырмын! Чәнчелдереп, кадалдырып җибәрермен! (*Чыгып китә.*)

---

М э г ъ к у л ь – яраклы.
Җ и б е р (зверь) – ерткыч.

## АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Габделкәрим, Нәсимә, Бәдигыльҗамал.
Нәсимә кулына бер-ике уенчык күтәреп кереп, бер почмакка утырып уйнарга тотына. Бераздан икенче тарафтан өстенә киенгән көенчә Габделкәрим чыга.

Габделкәрим (*Нәсимәгә карап*). Һа, минем тәти кызым монда икән! Ни эшлисең? Уйныйсыңмы? Уйна, кызым. Кара, аның нинди һәйбәт уенчыклары бар! Бу матур уенчыкларны кайдан алдың?

Нәсимә. Әти бирде.

Габделкәрим. Шулаймы? Бигрәк матур икән. Кил әле, кызым, кил, сине бер сөйим әле. (*Бер урындыкка утырып сөя башлый.*) Һай, минем тәти кызым, акыллы кызым!

Бәдигыльҗамал керә.

Бәдигыльҗамал. Тапкан икәнсең сөяргә бала! Сиңа ни әйтер идем, шул җыен яттан, җилдән туган баланы сөймәсәң, сөяргә башка бала таба алмаган икәнсең.

Габделкәрим. Тукта әле, хатын, син нәрсә саташасың? Әллә син тилебәрән орлыгы ашадыңмы? Нәрсәгә тилерәсең?

Бәдигыльҗамал. Тилердем шул, тилерми ни! Бар, чык моннан, бар, күземә күренмә, күңелемне болгатма! (*Нәсимәне төрткәләп чыгарып җибәрә.*)

Габделкәрим. Син нәрсә котырасың, ни сөйләгәнеңне беләсеңме син? Ул бит безнең балабыз, балабызның баласы!

Бәдигыльҗамал. Булган ди, булмый ни! Җилдән туган нәрсә!

Габделкәрим. Нинди юк сүз бу? Әйтсәнә, зинһар, бу нинди юк сүз?

Бәдигыльҗамал. Бер дә юк сүз түгел. Төсләрен дә күрәсем килми. Торгызмам, Алла боерса, торгызмам! Сүземдә торырмын!

Габделкәрим. Нәрсә торгызмассың?

Бәдигыльҗамал. Киленне торгызмам!

Габделкәрим. Ни өчен?

Бәдигыльҗамал. Шуның өчен!

Габделкәрим. Ничек «шуның өчен»?

Бәдигыльҗамал. Җә, көлеп утырма монда, аларның җибер шикелле тупырдап беткән кызларына кияү чыксын да, безнең бердәнбер алма шикелле кызыбызга урын табылмасын, имеш!

Габделкәрим. Ул сүз каян чыкты әле тагы?

Б э д и г ы л ь җ а м а л. Чыкты шул. Әле менә яучы Хәмидә килгән иде. Мин аны безнең кызыбызны сорарга килгән икән дип сөенеп торсам, ул миннән теге аждаһа җыланның сеңлесен сорашырга дип килгән икән. Ачуымнан җаным чыга язды. Имеш, аларның кызлары кияүгә китсен дә, безнеке калсын, имеш!

Г а б д е л к ә р и м. Шулай шул, хатын, кешеләрнең кызларына яше җитмәс борын ук кияү чыга, ә безнекенә... (*Көлә башлап.*) Солдаттан котылып калганына әллә ничә ел булса да чыкмый. (*Җитди.*) Беләсеңме бу нәрсәдән? Бу бары да синең усаллыгың, синең явызлыгыңнан! Син явыз булганга күрә, безнең тирәбезгә килергә куркалар.

Б э д и г ы л ь җ а м а л (*җылый башлап*). Ярый, ярый. Көлмә миннән, мыскыл итмә мине! Уф, йөрәгем! (*Җылый.*)

Г а б д е л к ә р и м (*ишеккә таба барып*). Җыла, җыла, бераз эчләрең бушар, ачуларың басылыр. Яңгырдан соң тузан да басыла. (*Чыгып китә.*)

## ҖИДЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Б ә д и г ы л ь җ а м а л, соңыннан Г ө л җ а м а л.

Б ә д и г ы л ь җ а м а л (*бераз җылаганнан соң*). Шулай итеп минем каныма тоз сала ул. Аның да шул авызынтелен бәйләп бетергәннәр. Булмас, мин бу хурлыкларга чыдый алмыйм. Аерттырам дигәч аерттырам! Минем сүземә колак та салмыйча чыгып китте. Җитмәсә тагы, миннән мыскыл итеп көлеп ята. Аерттыргач, үзегезнең дә исегез китәр әле. Гөлҗамал, Гөлҗамал, кер әле монда! Нәрсә терәлеп торасың, синең аркаңда мин хурлыклар күрәм.

Г ө л җ а м а л (*кереп*). Нәрсә дисең, әни?

Б ә д и г ы л ь җ а м а л. Терәлеп торма, дим. (*Комод тартмасыннан кәгазь алып.*) Менә яз шуңар. Әнә ал кара савыт.

Г ө л җ а м а л. Нәрсә языйм?

Б ә д и г ы л ь җ а м а л. Мин әйткәнне яз. Хат яз!

Г ө л җ а м а л. Кемгә?

Б ә д и г ы л ь җ а м а л. Әйткәнне көтеп тор. Җә, яз: җаным шикелле күргән сөекле бәгырем Зәйнәпкә...

Г ө л җ а м а л. Кайсы Зәйнәп ул?

Б ә д и г ы л ь җ а м а л. Анда синең эшең булмасын. Миңа кару кайтарма.

Г ө л җ а м а л. Җә, яздым.

Б ә д и г ы л ь җ а м а л. Бик сагынып, бик саргаеп, бер күрергә зар булып, бик күп сәлам, диген.

Гөлҗамал. Яздым.

Бәдигыльҗамал. Кызыма да күп сәлам, диген.

Гөлҗамал. Булды.

Бәдигыльҗамал. Синең белән күптән күрешкәнебез юк, кайчан күрешербез икән, диген. Кайда күрешербез икән, диген.

Гөлҗамал. Яздым.

Бәдигыльҗамал. Язгучы-мәгълүмеңез, диген.

Гөлҗамал. Яздым.

Бәдигыльҗамал. Язсаң, ярый. Китер хатыңны!

Гөлҗамал. Әни, кемгә соң ул хат? Нинди Зәйнәп ул?

Бәдигыльҗамал. Шайтанга. Анда синең эшең булмасын! Бар, син анда үз эшләреңне кара.

Гөлҗамал чыкмыйча тора.

Бар, тагын нәрсә терәлеп торасың? Күзләре алакайган.

Гөлҗамал чыгып китә.

Менә күрерсез әле. Мин сезне ни эшләтермен. (*Як-якка каранып эзләнә. Бераздан кәгазьне комод артына кыстыра.*) Мин әле сезне биетермен. Үз дигәнемне булдырмасам, дөньяда да тормыйм! (*Чыгып китә.*)

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ МӘНЗАРӘ

Шул ук бүлмә.

### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ибраһим, Бәдигыльҗамал.

Ибраһим керменеп өстен чишенә. Кесәсеннән бер гәзитә алып укырга тотына. Бераздан, кулына канат тотып, Бәдигыльҗамал керә.

Ибраһим. Әни, аш тиз буламы?

Бәдигыльҗамал. Хатыныңнан сора! Синең бик сөекле хатының бар бит, шул әйтер. Мин монда синең аш пешерер өчен ялланып куйган асравың түгел. (*Себерә.*)

Ибраһим (*пошынып*). Әни, соң мин сиңа алай ачуланырлык бер сүз дә әйтмәдем ләбаса.

Бәдигыльҗамал. Әллә оялмыйча шундый сүзләр дә әйтер идеңме? Аш пешерергә мин кирәк, самавыр куярга мин кирәк. Монда сезгә картайган көнемдә мин

асрау хезмәтен итеп йөрим. Бармы синең «әни» дип минем белән сөйләшеп утырганың? Бармы синең «әни» дип киңәш-табыш иткәнең?

Ибраһим. Әни,дим, зинһар...

Бәдигыльҗамал. Җикеренмә миңа! Мин, яхшымы-яманмы, сиңа ана. Бар белгәнең хатының. Бар тапканың хатыныңда. Бармы синең мине ана итеп, ичмасам, бер күлмәклек алып биргәнең?

Ибраһим. Җитәр, әни, зинһар, җитәр.

Бәдигыльҗамал. Ә, шулаймыни!.. Туры сүз шулай ачы була ул. Мин сиңа, яхшымы-яманмы, ана. Мин сине тапкан, үстергән. Сине үстергән чагында шулай булырсың да, һаман хатының артыннан өстерәлеп йөрерсең дип үстердеммени?

Ибраһим. Җитәр, дим, җитәр! Әни, зинһар, куй! Минем синең белән бер дә кычкырышасым килми.

Бәдигыльҗамал. Әллә тагы оялмыйча тел кайтарып минем белән кычкырышыр идең дәме? Кычкырыш. Бәддогадан курыкмасаң, кычкырыш. Ана бәддогасын алсаң, бик ерак китә алмассың. Ана каргышы, диләр аңар. (*Канат белән комод артындагы хатны себереп чыгара, бераз йомшак тавыш белән сүзендә дәвам итеп.*) Ана хакы – Тәңре хакы, диләр. Дөньяда бер хатын белән генә эш бетми. Ара-тирә ананы да ригая кыйлырга кирәк.

Ибраһим (*кәгазьне күреп*). Ул нинди кәгазь? Кирәкле кәгазь түгелме?

Бәдигыльҗамал. Кирәкле кәгазь булса, аяк астына ташламассыз. Бездә чүп-чар аннан башка да җитәрлек.

Ибраһим (*кәгазьне алып укый. Агарынып*). Бу ни дигән сүз? «Зәйнәпкә!», «Кызыма!», «Мәгълүмеңез!» Бу ни дигән сүз бу?!

Бәдигыльҗамал (*күрмәгәнгә һәм ишетмәгәнгә салышып, сүзендә дәвам итә*). Көн җый, төн җый, бер яктан җыя барасың, икенче яктан чүпли баралар.

Ибраһим (*каты-каты атлап, әле бер ишекне, әле икенче ишекне ачып*). Әни! Зәйнәп кая?

Бәдигыльҗамал. Мин кайдан белим, үзеңнән сорап киткәндер. Ул миннән сорап йөрми ич.

Ибраһим. Куйсана әле, зинһар! (*Идән буенча тиз-тиз йөрергә тотына.*)

Бәдигыльҗамал. Нәрсә булды тагын, табага төшкән мәче шикелле сикергәлисең?

Ибраһим. Уф! Мин моңар ышанмыйм! Ышанмыйм! Бу була торган эш түгел!

---

Ригая кыйлу – хөрмәт итү.

Б ә д и г ы л ь җ а м а л. Нәрсә ышанмыйсың? Әллә берәр хәл булдымы?

И б р а һ и м. Кит әле, зинһар! (*Диванга барып утыра. Бер кулы белән йөрәген тота.*) Уф!

Б ә д и г ы л ь җ а м а л (*килеп*). Ни булды? Әллә йөрәгеңә бер-бер хәл булдымы? Миндә ишан өшкергән тоз бар, шуны изеп эч, йөрәгең басылып китәр.

И б р а һ и м. Кит, дим!

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ш у л а р у к һәм З ә й н ә п.

З ә й н ә п кайтып керә.

Б ә д и г ы л ь җ а м а л. Әнә килен дә кайтты. Килен, кил әле тизрәк, Ибраһимга әллә нәрсә булды. Йөрәген тотып утыра. Идәннән бер кәгазь алып укыган иде, әллә, Ходаем, юк исә сихерле кәгазь булды микән?

З ә й н ә п (*тиз генә шәлен салып ташлап, Ибраһим янына килеп*). Ибраһим, ни булды сиңа?

Ибраһим эндәшми.

Ибраһим, Ибраһим!

Эндәшми.

Ходаем, ни булды икән моңар?

Б ә д и г ы л ь җ а м а л. Мин дә бер дә белмим. Әллә өшкертеп карыйк микән?

И б р а һ и м (*сикереп торып*). Бернәрсә дә булмаган. Әни, син чыгып тор әле моннан. Безнең сөйләшәсе сүзебез бар.

Б ә д и г ы л ь җ а м а л. Ярый, сөйләшегез, сөйләш. Алай гына булса, ярый, мин чыгам. (*Читкә карап.*) Эшләр пешә. (*Чыга.*)

И б р а һ и м (*Зәйнәпнең кулыннан тартып, бүлмә уртасына китереп, ачу белән*). Кайдан кайтып киләсең?

З ә й н ә п (*куркынып*). Кайдан булсын, әниләрдән.

И б р а һ и м. Кайткан әниләреңнән, кайтмый ни! Уйнашчың яныннан кайттыңмы? Әйт дөресен тизрәк!

З ә й н ә п. Ай Алла, җаным! Ул ни дигән сүзең ул?

И б р а һ и м. «Җаным», «җаным», ышаналар ди синең «җаным»ыңа! Турысын сөйлә, безнең баланың атасы кем? Уйнашчыңмы?

З ә й н ә п. Ярабби Ходаем, бу нинди бәла!!! Бу нинди бөһтан! (*Җылый.*)

---

Б ө һ т а н – яла.

И б р а һ и м. Җыла, җыла, күзләрең чыкканчы җыла, мине җылап ышандыра алмассың. Син мине җиде елдан бирле алдап йөрткән икәнсең, син мине җиде елдан бирле мәсхәрә кылып, өстемнән икенче кеше белән йөреп, аннан булган баланы минем өстемә тагып йөргән икәнсең! Син бәдбәхет икән, син ялганчы икән! Җиде ел мине сөям дип алдаган икәнсең!

З ә й н ә п. Алла хакы өчен дип әйтәм, миңа бөһтан бәлаләр такма. (*Җылый.*)

И б р а һ и м. Бөһтан? Әллә шаһите дә кирәкме? Мә, кирәк булса, укы! (*Хатны битенә ыргытып бәрә.*)

З ә й н ә п (*хатны алып укып, кулыннан төшереп җибәрә дә урындыкка җыгылып*). И Раббым! Бар икән күрәселәрем! (*Җылый.*)

И б р а һ и м (*хатны алып, кесәсенә салып, идән буенча йөреп*). Хәзер инде син миңа кирәк түгел! Үзең дә кирәк түгел, балаң да кирәк түгел. Төялегез дә китегез. Уйнашчың белән бергә рәхәтләнеп торырсың.

З ә й н ә п. Ибраһим җаным, зинһар, мине болай хур итмә. Икебез дә хур булабыз. Валлаһи, минем бер гөнаһым да юк, дошманнар сүзенә карап алданасың! (*Җылый.*)

И б р а һ и м. Мин алданасын алданган инде, җитәрлек алданган. Мине антларың, җылауларың белән генә ышандыра алмассың! Хуш, сау бул! (*Өстенә киенә, чыгып китә.*)

Зәйнәп кычкырып җылап кала.

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

З ә й н ә п, Б ә д и г ы л ь җ а м а л.

Б ә д и г ы л ь җ а м а л (*Зәйнәп янына килеп*). Ни эшкә шаулаштыгыз, ни эшкә бозылыштыгыз, әллә берәр хәл булганмы?

З ә й н ә п (*җылап*). Ни булганын сез миннән яхшырак беләсез.

Б ә д и г ы л ь җ а м а л. Ул ни дигән сүз ул? «Яхшырак беләсез»?

З ә й н ә п. Мине болай хур иткәнегез өчен Аллаһы Тәгалә сезнең үзегезне хур итсен! Миңа мондый бөһтан бәлаләр таккан өчен Ходай сезгә аннан артыграк бәлаләр бирсен!

Б ә д и г ы л ь җ а м а л. Ул нинди каргыш ул, каргышың үз башыңа төшсен! Җиде ел эчендә син минем шактый йөрәк итләремне ашадың. Минем Ибраһимымны

бөтенләй үзеңә багындырып бетердең, Ибраһимны сарыга сабыштырып бетердең! Аш бу сиңа!

Зәйнәп. Син минем җиде ел эчендә башымны ашадың. Күрербез, Алла боерса. Хаклык тотар әле.

Бәдигыльҗамал. Сез – сихерчеләр, сихерегез белән баламның башын-күзен әйләндереп бетердегез! Ир өстеннән ир тотып йөрмәссең. Сез сихерләп өемнән кешеләрне биздереп бетердегез.

Зәйнәп. Әйт, сөйлә, сөйли торган сүзләрегез, яга торган бөһтаннарыгызның берсе дә калмасын. Күп яши алмассың, Алла орыр әле! (*Җылый.*)

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әүвәлгеләр, Габделкәрим, Ибраһим, соңра Гөлҗамал.

Габделкәрим (*ишектән керә-керә*). Алай дуамалланырга ярамый, ашыгу – шайтан фигыле.

Ибраһим (*ишектән кереп*). Мин бер дә дуамалланмыйм, хаклыгы шулай булгач, мин ни эшлим?

Габделкәрим (*өстен салып*). Әйдә, сал өстеңне! Утыр! Хакмы, хак түгелме, анысын менә хәзер тикшерербез.

Бәдигыльҗамал (*читкә карап*). Булып беткән эшкә бусы кайдан килеп катышты тагын?! (*Габделкәримгә.*) Хактыр инде, хак булмаса, бозылышмаслар иде. Сиңа нигә кирәк ир белән хатын арасына керергә? Үз эшләрен үзләре белә торганнардыр инде.

Габделкәрим. Син үзең катышма, тик тор!

Зәйнәп (*җылап*). Әткәй, валлаһи, минем бер тиенлек гөнаһым юк.

Бәдигыльҗамал. Тик тор син дә! Каенатаңа тел ачма! Оятсыз!

Габделкәрим. Әйттем бит мин сиңа катышма дип!

Бәдигыльҗамал. Нишләп катышмаска, Ибраһим минем улым түгелмени ул?

Габделкәрим. Ә минеке түгелмени? Тик тор!

Бәдигыльҗамал. Тормам, минем телемне бәйләп куя алмассың!

Габделкәрим. Хуш, әйт, ни өчен аермакчы буласың? Киленнең нинди гаебе бар?

Ибраһим. Мин ир өстеннән ир тоткан кеше белән ничек итеп торыйм?

Бәдигыльҗамал. Шулай шул, шулай.

Зәйнәп. Ялган!

Габделкәрим. Тик торыгыз. Хуш, син аның шулай ир тотканын кайдан беләсең? Үзең күрдеңме? Яки күргән кешеләр бармы?

Ибраһим. Менә сөйгәненнән алган хаты бар.

Зәйнәп. Монысы да бөһтан, минем һичкемнән хат алганым юк.

Бәдигыльҗамал. Алган, алган! Әнә шул камуд астыннан идән себергән чагында чыкты.

Габделкәрим. Тик тор, синнән сорамыйлар. (*Хатны алганнан соң, укып карап торганнан соң, көлеп.*) И тиле, тиле, бу хат белән хатын аералармы соң?

Бәдигыльҗамал. Ник аермасыннар, аералар шул.

Габделкәрим. Сине тиле дип әйтмичә ни дип әйтим, утыз ел шушы өйдә гомер итеп тә, шул язуның кулын танымагач. Бар, чакыр әле Гөлҗамалны.

Ибраһим чыга башлый.

Бәдигыльҗамал. Чыкма, чыкма, үзем чакырам. (*Чыгарга тели.*)

Габделкәрим. Тик тор, урыныңда гына утыр. (*Үзе торып, ишеккә барып.*) Гөлҗамал, кил әле монда.

Гөлҗамал ишектән керә. Бәдигыльҗамал аңа төрле ишаpәләр кыла, ләкин аны Гөлҗамал күрми.

Менә бу язуны таныйсыңмы?

Гөлҗамал. Таныйм.

Габделкәрим. Моны кем язды?

Гөлҗамал. Мин.

Ибраһим. Алай икән.

Зәйнәп. Йа Алла!

Бәдигыльҗамал. Ул түгел, ул түгел.

Габделкәрим. Ник яздың?

Гөлҗамал, анасыннан куркып, әйтмичә тора.

Әйт, әйт, турысын сөйлә, бер дә курыкма!

Гөлҗамал. Әни кушты.

Бәдигыльҗамал. Юк, юк, ялганлый, ялганлый!

Габделкәрим. Әй, хатын, хатын, ачу итәм дип, шундый начарлыкларны кылырга ярыймы соң инде? (*Ибраһимга.*) Хаклыгың нишләде, җә, хатыныңны бу хатка ышанып аерырсыңмы инде?

Ибраһим. Юк.

Бәдигыльҗамал. Юк, юк, мин бу хурлыкка чыдый алмыйм. Ул сезнең икегезне дә сихерләгән. (*Чыгып китә.*)

Г а б д е л к ә р и м. Килешегез инде, балалар. Моннан соң шатлык белән тату гомер итегез. Мондый эшләрдән соң монда бергә тору уңайсыз булыр. Үз башыгызга рәхәтләнеп гомер итегез. Миннән фатиха!

Б ә д и г ы л ь җ а м а л (*ишекне ачып*). Мин бу хурлыкка чыдый алмыйм, миннән бәддога!

Г а б д е л к ә р и м. Аның базары узды инде.

Н ә с и м ә (*ишектән йөгереп кереп, Ибраһим янына килеп*). Әти, син кайттыңмы?

И б р а һ и м. Кайттым, Нәсимә, кайттым.

Ибраһим Нәсимәне күтәреп ала, Зәйнәп тә килеп кочаклый, икесе ике битеннән үбәләр.

П ә р д ә.

---

Б ә д д о г а – каргыш, ләгънәт.

## КӨНДӘШ

*Комедия 1 пәрдәдә*

ӘШХАС:

Габсаттар – ир уртасы кеше.
Гөлбану – аның хатыны.
Кыз.
Нәгыймә – Габсаттарның кызы.
Әхмәди – Габсаттарның кибетчесе.

Уртача җыештырылган өй.

БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Габсаттар ялгыз, ишектән кереп, өстәл янына килеп утырып.

Габсаттар. Кара син аны, йөзе караны, әрәмтамакны! Кулыннан бер тиенлек эш килми, борынын да җүнләп җыештыра алмый, селәгәй! Ә үзе кызлар белән йөргән була бит! Үләрсең, хурланып үләрсең килешләренә. Җитмәсә тагы, шул башы белән кыз сөйгән булып, кызлардан хат алган булып маташа бит! Һи, замана, замана! Әйтәм аны беркөннәрдә, абзый, минем жалуниямне арттыр, жалуниям өскә-башка да җитми, дигән булып маташкан иде. Ул шул миннән алган жалуниягә кызлар белән гыйшык тотып йөрергә уйлаган икән! Тукта әле, җебегән малай, мин сине өйрәтермен әле, сиңа гыйшык тотуның ничек икәнен күрсәтермен. Тора торып исем китә: шундый җебегән бер малайга нинди кызның күзе төште икән? Шундый малайга бармаса, җүнлерәк адәм, акыллырак, берәр кеше төслерәк кеше беткән иде микәнни? Хәер лә, хәзер инде аның адәм рәтле кешесе дә калмады. Үсеп җитәр-җитмәс, унсигез яшьлек малайларны да солдатка алып бетерделәр, ә сугыш башланганда унҗиде-унсигез яшьтә булган, җиләк шикелле кызлар, чират көтеп, аталарының өйләрендә утыралар. Никадәр яңа законнар чыгардылар. Кызларны да солдатка ала торган бер закон чыгара алмадылар. Әгәр дә андый закон чыгарсалар, иң элек безнең Нәгыймәне тотып бирер идек, кешегә әйтергә дә оят, хәзер инде егерме икегә басты

бит. Хатын биш елдан бирле инде, әле ул уналтыда гына, дип йөри йөрүен дә бит, аның сүзенә карап кына бер дә ышанмыйлар шул. Ичмаса, берәр картрак кешеләрнең хатыннары да үлми, этеп-төртеп булса да берәрсенә сылар идек шунда... Яле, карыйк әле, бу малакасуска нәрсә дип язган булганнар икән? (*Кесәсеннән бер конвертлы хат чыгарып, иснәп.*) Фу! Кара син аны, бөтенләй ислемайга манчылган шикелле! Ахры, моның адикалунның шешәсе егерме тәңкәгә җиткәнлегеннән хәбәре юктыр. Кеше мәт мае алырга акча кызганып йөргән чакта, ансы тагы хатын ислемай белән аңкыткан. Яле, нәрсә яза икән? (*Укый.*) «Сезки җанымнар җаны, гүзәлләр солтаны...» (*Көлеп.*) Пффи! Тапкан гүзәлләр солтаны! Шул чепи күзле нәрсә гүзәлләр солтаны буласы, имеш! «Иске чабата олтаны» дисә бер хәер иде. «Сезне бер күрергә зар вә интизар булып, мең төрле сәламнәремне күндердем. Сезнең нурлы йөзләрегезне бер күрергә зар вә интизар булып, йөзләрем саргайды...» Һи, адәм мәсхәрәсе! Самавыр җизе төсле сары пошлак бер малай нурлы йөзле буласы, имеш! (*Бераз эченнән укып.*) Кара, кара, монда тагы ни дип язган була бит. «Һич тәкать итә алмыйм, сабырым калмады, һәр көн ишекне ачып бер кеше килеп керсә, синнән яучы килдеме икән әллә дип өметләнеп китәм. Үзең яучы җибәрәм, этиләреңнән сине соратам дип вәгъдә кылдың, ә үзең һаман да сәбәпләренә керешмисең. Болай булгач, син мине мыскыл итеп кенә йөри торгансыңдыр. Мин бу эшкә түзә алмыйм, соңгы көннәрдә син безнең тирәләрдә күренмисең, алай булса, мин үзем, аулаграк бер вакыт туры китереп, синең яныңа барам. Мин бүген үк кич белән барып җитәрмен, кич белән мине капка төбендә көтеп тор. Сине чын күңеленнән сөйгән мәгъшукаң дәю белгәйсез. Вәссәлам.

Бакчада гөлләр бетәрме, арасыннан былбыл үтәрме,
Үзеңне күреп сөйләшмәгәч, хатка язып сүзләр бетәрме».

Ах, корчаңгы, корчаңгы! Шул башы белән кыз сөйгән булып, кызлардан хат алган булып маташа бит, ә! Тукта әле, мин ул малакасус малайга кыз сөюнең ни икәнен күрсәтим әле. (*Чыга. Хат өстәл өстендә кала.*)

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлбану ялгыз.

Гөлбану (*ишектән кереп*). Ай күрде, кояш алды дигәндәй, бу карт кайда китте соң әле? Күптән аш вакыты җиткән, ашым кыркуланып бетә инде, һичбер вакы-

тында ашау юк, эчү юк, сату да сату. Сату белән җенләнеп йөри. Һичбер җүнләп өйдә тормый. Ары чаба, бире чаба. (*Хатны күреп.*) Монысы нәрсә тагын? Әллә берәр җирдән парлы кунакка чакырып запискә килде микән? Хәер, юктыр ла, бу кыйбатчылык җылны кемнең кунак уздырып торасы килсен соң? Кунак уздырырга түгел, өйдә тамак туйганчы рәхәтләнеп ашарлык нәрсә дә юк әле. Адәм әйтеп адәм ышанмас бит, сары майның кадагы сигез сум илле тиен, ди, шикәрне әйтмә дә инде. Поты йөз алтмыш тәңкә диме, ике йөз алтмыш диме шунда. Әллә кайчаннан бирле инде рәхәтләнеп, авыз тутырып кызыл кесәл дә ашаганым юк. Ул башкасын әйтмим дә инде, күбекләр, бламажиларның күптән көлләре күккә очты. Бу ни бу? Бу хаттан ислемай исе килә. (*Иснәп.*) Бу прастуй ислемай исе генә дә түгел. Әллә нинди, бай марҗалар сөртә торган ислемай исенә охшый. Алар шундый тәмле ислемайны кайдан табалар икән? Бу көннәрне «томанный»да бер бай марҗа шундый бик тәмле ислемай сөрткән иде. Әллә нинди тәмле канфит исләре килеп тора. Авыздан сулар килерлек. Бу нинди хат икән соң? Бик бай кешедән килде микәнни? (*Ачып.*) Кара, бу кызлар хаты ич! Чәчәкләр дә ябыштырып бетергән бит. Безнекенә моны кем җибәрде икән? (*Таныр-танымас итеп укый.*) «Сезки җанымнар җаны, гүзәлләр солтаны». Ай Алла! Бу кемгә язылган хат соң бу? (*Укый.*) «Сезне бер күрергә зар вә интизар булып, мең төрле сәламнәремне күндердем». Карасана, бу хат кемгә соң бу? «Сезнең нурлы йөзләрегезне бер күрергә зар вә интизар булып мең төрле сәламнәремне күндердем». Бу хат кемгә булыр бу? «Сезнең нурлы йөзләрегезне күрергә зар вә интизар булып йөзләрем саргайды». (*Күзләрен зур итеп ачып, якягына карап.*) Бу хат кемгә булырга кирәк, әллә юк исә безнең Нәгыймәгә берәр җегеттән килгәнме? Юк, юк, булмас, ул алай җегетләр белән йөри торган кыз түгел. Минем багалмасы төсле кызым алай җегетләр белән йөрмәс! Бу, мөгаен, асраулар эше булыр. Кайдан булса да берәрсеннән асрауга килгәндер. Тукта әле, шулай да укып карыйм әле. (*Укый.*) «Һич тәкать тота алмыйм, сабырым калмады, һәр көн ишекне ачып бер кеше килеп керсә, әллә синнән яучы килдеме икән дип өметләнеп китәм». Һи, монысы булмады инде, мин әллә тагы, безнең Нәгыймәгә берәр бай улы гашыйк булып хат җибәрде микән дип торам. Берәр җүләрдән килгән хаттыр шун-

---

Томанный – кино.

да, юк исә, җүләр булмаса, мондый сүзләр язар идемени? Кыз ягыннан җегеткә яучы килгәнне кемнең күргәне бар? Ул кадәр хатлар, яучылар җибәрә-җибәрә этеп-төртеп кияүгә бирмәсәк тә насыйбы чыгар әле. Дөньяда аннан картракларга да кияү чыга. Әлхәмделилла, безнең байлыгыбыз, ашыбыз-суыбыз җитәрлек. Кияү сыйларга да хәлебездән килә. Дер селкетеп, шау китереп туй итмәгәч, туймыни ул? Менә, Ходай боерса, һич көтмәгән җирләрдән менә дигән бай улларыннан яучылар килер әле. Утырган кыз безнеке генә түгел. Шәрәфи Хисамиенең картаеп беткән шадра, бүкән шикелле җуан кызына да ия чыкты әле. Тукта әле, укып бетермәдем, бу кемнән килгән хат булды соң? (*Укый.*) «Үзең яучы җибәрәм, этиләреңнән соратам дип вәгъдә кылдың, ә үзең һаман да сәбәпләренә керешмисең». Ай, сөбханалла! Бу кыздан килгән хат түгелме соң? (*Күзләрен зуррак итеп ачып, уйга калыбрак укый башлый.*) «Болай булгач, син мине мыскыл итеп кенә йөри торгансыңдыр. Мин боларга түзә алмыйм». Кемне әйтә соң бу «мыскыл итеп йөрисең» дип? Әллә юк исә... эстәгъфирулла тәүбә... тфү, тфү, безнең карт шулай картайган көнендә адәм мәсхәрәсе булып өйләнергә йөриме әллә юк исә? Әстәгъфирулла тәүбә... Әстәгъфирулла тәүбә... Алла сакласын... Алла сакласын... язмышың булса, әллә ниләр күрерсең. (*Укый.*) «Соңгы көннәрдә син безнең тирәләрдә бер дә күренмисең». Әстәгъфирулла тәүбә, эстәгъфирулла тәүбә! Карт башы белән шулай җүләрләнеп йөрер микәнни?! (*Укый.*) «Алай булса, мин үзем, аулаграк бер вакыт туры китереп, синең янына барам». Әбәү, әбәү, оятсыз! Кыз башы белән, сакалы биленә җиткән, кызы картаеп беткән бер кеше артыннан ияреп йөрмәсә, кияү бетәр дип белгән иде микәнни? (*Укый.*) «Мин бүген үк кич белән барып җитәрмен. Кич белән мине капка төбендә көтеп тор. Сине чын күңеленнән сөйгән мәгъшукаң дәю белгәйсез. Вәссәлам.

Бакчада гөлләр бетәрме, арасыннан былбыл үтәрме,
Үзеңне күреп сөйләшмәгәч, хатка язып сүзләр бетәрме».

Һи, адәм хуры! (*Хатны ачу белән өстәлгә ыргытып.*) Кеше ирләре артыннан җалманып йөрмәсә, дөньяда ир беткән икән. Шул сөйкемсез картка ялынмаса, дөньяда кияү таба алмам дип белгәндер. Һи, күрер идем, күрер идем, шул нәрсәсенең нинди нәрсә икәнен генә күрер идем. (*Әле бер тәрәзәгә, әле икенче тәрәзәгә барып карый.*) Киче нинди караңгы бит. Күзгә төртсәң күренмәслек. Ярар, Алла боерса. (*Йодрыклары белән тәрәзә яңакларын тукмаклап.*) Бирермен кирәгегезне! Ул килмешәге монда килеп рәхәт күрермен дип белә торгандыр.

Күрсәтермен, Алла боерса, күрмәгәннәрен! Дөньяда мин аны тыныч тотсам, дөньяда исемем Гөлбану да булып йөрмәсен!

Ишектән бик матур итеп киенгән б е р к ы з килеп керә.

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Г ө л б а н у, к ы з.

К ы з (*ишектән кереп, туктап, як-ягына каранып*), Абыстай!

Г ө л б а н у (*сискәнеп китеп, үзалдына*). Тфү, тфү, тфү, әстәгъфирулла тәүбә, әгузе билләһи! Бу ни хикмәт бу? Әлләә шул кыз үзе микән? (*Кызга сонгый якты йөз белән.*) Нихәл, кызым, сезгә ни кирәк?

К ы з. Габсаттар абзыйлар шушында торамы?

Г ө л б а н у (*тамагы карлыгып*). Эхым, кыхым! Ийе, шушында. (*Үзалдына.*) Кара син аны, нинди белмәмешкә салынган булып маташа бит! (*Кызга.*) Сиңа кем кирәк иде соң? (*Үзалдына.*) Кем кирәк икәне билгеле инде, урамда очраша алмаганнар да, монда килгән. Кара син аны, нинди оятсыз!

К ы з. Миңа Габсаттар абзый үзе кирәк иде.

Г ө л б а н у. Үзе дисеңме? (*Үзалдына*). Кара син аны, оятсызны, күзен дә йоммый бит. (*Кызга.*) Нәрсәгә кирәк иде соң ул? (*Үзалдына.*) Нәрсәгә кирәк икәне билгеле инде.

К ы з. Аңар бер йомыш бар иде, үзенә генә тапшырасы бер әманәт тә бар иде.

Г ө л б а н у (*үзалдына*). Бардыр шул. Булмый ни! Нинди йомыш икәнен без бик яхшы beләбез инде аның. (*Кызга*). Нинди йомыш иде? Миңа гына әйтегез.

К ы з. Сез соң аның анасы буласызмыни?

Г ө л б а н у (*үзалдына*). Кара син аны, нинди ачы телле. Әле килеп тә җитмәгән, беренче күрүендә үк нинди йөрәгемә кадый башлады. Ярабби Ходаем, сабырлык бир, тукта әле, ничек итеп кенә булса да түзим. (*Кызга.*) Ничек соң мин алай, бик үк шулай карт күренәммени? Мин әле үземне ул кадәр үк, Габсаттар абзагызның анасы булырлык ук карт дип белмидер идем.

К ы з. Гафу итегез, абыстай, мин сезне чыннан да Габсаттар абзыйның анасыдыр дип белгән идем. Ул бик яшь кеше бит әле.

---

С о н г ы й – ясалма.

Гөлбану (*үзалдына*). Күзләре тәмам тонган икән. Карт белән яшьне дә аера алмый. (*Кызга.*) Алтмышка якынлашып килә торган кеше карт булмыймыни?

Кыз. Габсаттар абзый нишләп алтмышта булсын, ул бик күп булса утыз-утыз биш яшьләрендә генә булырга тиеш иде. Хәер, ансын мин белмим, абый шулай дигәнгә генә әйтәм. Ул аның белән бергә мәдрәсәдә бер хәлфәдән сабак укыган. Минем абый утызда гына әле.

Гөлбану (*үзалдына*). Тәмам акаюы җиткән икән, күзенә ак-кара күренми икән. (*Кызга.*) Ярый, ярый, синеңчә булсын, утызда гына булсын, син аның сакалларын шулай тумыштан кара дип белә торгансыңдыр. Аның сакалын карага буяп йөргәнен белмисең икән. Алай булса, бик яхшы бел: ул илледән узган инде. (*Үзалдына.*) Илледән түгел әле түгелен дә, моңар шулай дими ярамый.

Кыз. Габсаттар абзый илледәме? Сез бигрәк арттырасыз инде. Андый яшь кеше илледә буламыни?

Гөлбану. Ярый, ярый, син шулай алданып йөр, киленне килгәч күрербез.

Кыз. Нинди киленне? Габсаттар абзый өйләнәмени?

Гөлбану. Ахры, өйләнә торгандыр шул, өйләнмәсә, башы-күзе әйләнеп йөрмәс иде.

Кыз (*аптырап*). Кара, безнең һич белгәнебез юк иде, кемне ала?

Гөлбану (*ачулана башлап*). Кемне алсын, ала инде шунда, кем дигәннең үзе, маңлаенда ике күзе. (*Үзалдына.*) Нинди явыз, хәйләкәр! Мин сине биетермен әле. (*Кызга.*) Кем булса да, игелек күрә алмас. Кырмыска түмгәгенә төшкән җылан шикелле үрле-кырлы сикерер.

Кыз. Габсаттар абзыйны андый начар кеше димиләр ич аны.

Гөлбану. Күрсәтер ул начар түгел икәнен! Ул бара торган кыз үзен бәхетле булырым дип белә микәнни?

Кыз (*үзалдына*). Бу Габсаттар абзыйның кеме икән соң бу? Анасы дисәң, анасы үз улын бу кадәр үк яманламас иде. (*Гөлбануга.*) Ни өчен сез алай дисез? Без Габсаттар абзыйны алай начар кеше дип белмибез. Әти аны бик мактап сөйли.

Гөлбану. Нәрсә, мактап сөйли дисеңме?

Кыз. Әйе.

Гөлбану (*үзалдына*). Аңланды. Атасы белән дә эшне алдан ук бетереп куйган икән. (*Кызга.*) Ярый, бар, бар, бара бир! Барыбер игелек күрә алмассың!

Кыз. Кайда барыйм?

Гөлбану. Теләгәнеңә бар.

К ы з (*үзалдына, гаҗәпсенеп*). Әллә бу дивана микән? (*Гөлбануга.*) Нинди теләгәнемә?

Г ө л б а н у. Беләм, беләм, күп телеңә салынып торма, бар, бар! Миннән курыкмасаң, бара бир, мин сиңа ачык дөнья йөзе күрсәтмәм. Минем болайлыгыма карама, мин үзәгеңә үтләшермен! (*Өстенә килә башлый.*)

К ы з (*куркып, үзалдына*). Мөгаен, бу гакылдан шашкан булырга кирәк. (*Каушап.*) Ярый, хуш, сау булыгыз алайса! (*Үзалдына.*) Бу кем икән соң бу? (*Чыга.*)

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Г ө л б а н у ялгыз.

Г ө л б а н у (*урындыкка килеп утырып, акырып җыларга башлап*). Ярабби Ходаем! Картайган көнемдә бар икән күрәселәрем!.. (*Кинәт туктап.*) Тфү! Тфү! Әстәгъфирулла тәүбә! Әйттем исә кайттым! Мин ни эшләп карт булыйм? Алла боерса, Алла боерса, җиде яшьнең муенын өзәрмен әле! Җебегән арыш салмасын! Мин соң андыйларга бирешәмме? Бирешмәм, Алла боерса, бирешмәм! Ул җыланны алып кына карасын, мин аны гомерем буена рәхәт яшәтмәм! (*Ишеккә барып.*) Нәгыймә! Нәгыймә!

## БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Г ө л б а н у, Н ә г ы й м ә.

Н ә г ы й м ә (*ишектән кереп*). Нәрсә, әнкәй? Ник җылыйсың?

Г ө л б а н у (*хатны күрсәтеп.*) Әнә укы!

Н ә г ы й м ә. Әллә берәр кеше үлгәнме? (*Хатны алмакчы була.*)

Г ө л б а н у. Юк, юк, алма, укыма! Кагылма!

Н ә г ы й м ә. Нинди хат соң ул? Әллә берәр кеше үлгәнме, дим?

Г ө л б а н у (*җылый*). Иһи, иһи, үлгән!

Н ә г ы й м ә (*хатны алмакчы булып*). Кем үлгән?

Г ө л б а н у. Юк, юк, алма, укыма!

Н ә г ы й м ә. Юктыр ла, кем үлсен!

Г ө л б а н у. Үлгән, үлгән, мин дә үлгән, син дә үлгән! Атаң да үлгән! Иһи, иһи! (*Җылый.*)

Н ә г ы й м ә (*аптырап*). Ай Алла, әнкәй! Әти хәзер генә монда иде бит.

Г ө л б а н у. Монда иде дә шул, ә менә хәзер юк инде. Ул өйләнә!

Н ә г ы й м ә (*аптырап*). Ә? Ни дисең?

Г ө л б а н у. Өйләнә, өйләнә! Син дә беттең, мин дә беттем. Алачак кызы, белмәгәнгә салынган булып, әле генә монда кереп чыкты.

Н ә г ы й м ә. Юктыр ла, әнкәй, яңлыша торгансыңдыр?!

Г ө л б а н у. Юк, юк, үз күзем белән күрдем, үз күзем белән... Иһи, иһи!

Тышта ачуланган тавышлар ишетелә.

Н ә г ы й м ә. Чү, әти әллә кем белән кереп килә. Синең җылаганыңны күрмәсеннәр. Әйдә теге якка чыгыйк.

Г ө л б а н у (*торып, кызы белән ишеккә бара-бара*). Әй Раббым, бар икән күрәселәрем!

Чыгалар.

## АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Г а б с а т т а р, Ә х м ә д и, Г ө л б а н у.

Г а б с а т т а р (*ишектән керә-керә*). Ахмак, малакасус, симерүең җиткән икән!

Г ө л б а н у (*ишектән башын тыгып*). Ә, болар икән әле. Җиткәндер шул, мал иясенә охшамаса, хәрам була, ди.

Г а б с а т т а р. Оятсыз, шул башың белән син кызлардан хат алып йөрергә!

Ә х м ә д и. Мин сорамаган бит аны, үзе җибәргән.

Г ө л б а н у (*ишектән*). Әллә, Ходаем, ул хуры да кызлар белән йөри башлаганмы?

Г а б с а т т а р. Җибәрер, җибәрер, үзең җибәрмәгәндә, кызлар сиңа хатлар җибәрә, ди.

Г ө л б а н у (*ишектән, үзалдына*). Шулай шул, шулай шул, мулла азса, мәхәлләгә ни сан, ди. Оясында ни күргән – очканда шуны күрер, ди.

Ә х м ә д и. Тәхкыйк менә, чынлап, абзый, мин язмадым, үзе язгандыр.

Г ө л б а н у (*ишектән*). Шулайдыр шул. Безнең карт җүләр дә үзе язмагандыр, теге кызы язгандыр, аның ак сакалына гашыйк булгандыр.

Г а б с а т т а р. Ышанмыйм, ышанмыйм!

Г ө л б а н у (*ишектән*). Мин дә ышанмыйм, ант итсә дә ышанмыйм.

---

Т ә х к ы й к – чынлап.

Ә х м ә д и. Валлаһи, Габсаттар абзый, мин язмадым, үзе язган.

Г ө л б а н у (*ишектән*). Әйе, әйе, Габсаттар абзаң да үзе язмагандыр, теге себерке кыз язгандыр.

Г а б с а т т а р. Ярый, бер юлга калдырам, кара аны, әгәр дә моннан соң да андый эшләрең булса, бер минут та торгызмам. Куармын да чыгарырмын.

Г ө л б а н у (*ишектән*). Ә үзеңне кем куар?..

Г а б с а т т а р. Ярый, бар, юлыңда бул! Ләкин кара аны, аң бул! Бер юлга кичерәм. Бар, чык!

Әхмәди акрынлап, башын түбән иеп чыга.

## ҖИДЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Г а б с а т т а р, Г ө л б а н у, Н ә г ы й м ә.

Г ө л б а н у (*ишектән зәһәрләнеп кереп*). Ә мин, мин кичерә алмыйм. Мине ахыр гомеремдә, картайган көнемдә хур иттең! Иһи, иһи! (*Җылый.*)

Н ә г ы й м ә (*ишектән җылап кереп*). Әткәй, әнкәй, иһи, иһи!

Г а б с а т т а р. Туктагыз әле, сезгә ни булды? Ник җылыйсыз?

Г ө л б а н у. Картайган көнемдә син мине хур иттең! Иһи, иһи!

Н ә г ы й м ә. Иһи, иһи!

Г а б с а т т а р. Тукта, тукта, нәрсәне, кемне хур иткән? Әхмәдинеме?

Г ө л б а н у. Нинди Әхмәдине? Безне.

Г а б с а т т а р. Ничек сезне?

Г ө л б а н у. Мине.

Г а б с а т т а р. Ничек сине?

Г ө л б а н у. Картайган көнеңдә минем өстемнән көндәш алып йөрү килешәмени? Иһи, иһи!

Г а б с а т т а р. Нинди көндәш?

Г ө л б а н у. Ә соң бу хат нәрсә?

Г а б с а т т а р. Бумы?

Г ө л б а н у. Тагы нинди хат кирәк иде соң?

Г а б с а т т а р. Соң син ишетмәдеңмени, әле генә шул хат өчен Әхмәдигә ачуланганны?

Г ө л б а н у (*балалар үпкәләгән шикелле*). Ул хат соң сиңа язылган түгелмени? Ә соң теге кыз ни эшкә килгән?

Г а б с а т т а р. Кайсы кыз?

Г ө л б а н у. Әнә теге, сине сорап килгән кыз.

Габсаттар. Теге күптән түгел моннан чыгып киткән кызмы?

Гөлбану. Әйе.

Габсаттар. Ник, ул мине сорадымыни?

Гөлбану. Сорады шул, Габсаттар абзыйлар монда торамы, ди?

Габсаттар. Соң?

Гөлбану. Миңа, син аның анасы буласыңмы әллә, ди.

Габсаттар. Йә.

Гөлбану. Мин шулай ук карт күренәммени дигән идем, мин сезне чыннан да Габсаттар абзыйның анасыдыр дип белдем, ул бик яшь кеше бит әле, ди.

Габсаттар. Ха-ха-ха! Аңлашылды! Ул, алай булгач, теге Габсаттарны сораган.

Гөлбану. Кайсы?

Габсаттар. Әнә теге, бездән ике өй аркылы Садри Габсаттары, яшь егет.

Гөлбану. Ә, шулаймыни? Ярабби Ходаем! Сиңа нинди шөкерләр генә кылыйм? Нәзерем булсын, җиде атнада җиде газизләр рухына җиде ясин укып багышлармын. Алай булса, син түгел икән алайса? Син өйләнмисең алайса? Иһи, һи, һи!

Пәрдә.

## ӨЙЛӘНӘМ!.. НИК ӨЙЛӘНДЕМ?

*Комедия 2 пәрдәдә*

ӘШХАС:

Ә х м ә т – конторда хезмәт итүче. Беренче пәрдәдә – егет, икенче пәрдәдә өйләнгән.
Н ә г ы й м ә – аның хатыны.
К о р и д о р н ы й.
Г о р н и ч н ы й.
К е р ю у ч ы х а т ы н.
И с м ә г ы й л ь, Н о г м а н, Ш а к и р – Ә х м ә т н е ң и п т ә ш л ә р е.
И м ч ә к б а л а с ы, К е ч к е н ә б е р б а л а – Ә х м ә т н е ң б а л а л а р ы.
К и б е т ч е, С у ч ы, И т ч е, К ү м е р ч е, У т ы н ч ы – а л а ч ы к и я л ә р е.
Г а б д р а х м а н – Әхмәтнең анасы белән бертуган кардәше.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Номерда бер бүлмә. Бүлмәнең җыештырылуы уртача гына.

#### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ә х м ә т ялгыз, соңра К о р и д о р н ы й.

Ә х м ә т (*ишектән кереп, өстен сала-сала*). Менә син бәхетсезлек, яңа гына унике тәңкәгә алган штиблит бөтенләй эштән чыга язды бит. Мин коры җир дип бассам, ул өеп куйган пычрак икән. Чап пычракның уртасына. Штиблитем штиблит кенә түгел иде, харап булды бит. Бүген кич тансавальный вечерга барасым булганга гына кигән идем, бөтенләй харап иттем. Тукта инде, моны әүвәле чүпрәк белән сөртеп бераз киптерергә кирәк тә, аннан ары ваксылармын. (*Звонок бирә дә утырып аягын сала башлый.*) Бөтенләй эштән чыгардым, кичкә кадәр

генә кипсә ярар иде. Кипмәсә, аннан ары эш харап! Бүген кич Нәгыймәгә танса кичәсенә барырга вәгъдә кылган идем, әгәр дә бармасам, Нәгыймә үпкәләр. Ул бүген минем белән тансавайт итәргә дә сүз бирде. Гали һаман миннән син коханочканы тансавайт итә белмисең дип көлеп йөридер иде, менә инде мин бүген күрсәтим аңа үземнең ничек тансавайт иткәнемне! Ул, кәкре аяк, миннән көлеп йөрмәсен әле, түлке менә бу штиблит каһәр сукканның пычракка батуы гына кәефне җибәрде әле. Йә, ярар, яхшылап сөрткәч беленмәс әле.

Ишектән Коридорный керә.

Коридорный. Нихәл, Әхмәт абый, ни йомыш?

Әхмәт. Менә син, туган, шушы штиблитне генә яхшылап сөртеп, тазартып китер әле. Минем бүген барасы җирем бар иде.

Коридорный. Әй, юк, Әхмәт абый, минем эшем ашыгыч, кырыгынчы номерга хәзер самавыр кертәсем бар. Аннан ары утыз бишенче номердан обед сорадылар. Аны керткәч, егерме өченче номерга аптиктән дару алып кайтасы бар. Бай әле дә орыша, сез, ди, һаман-һаман шул кызыл авызларның гына көйләрен көйләп йөрмәгез, ди.

Әхмәт. Мин бит сезгә монда акча түләп торам.

Коридорный. Булса булыр, Әхмәт абый, көндез эш күп вакытта итек чистартып торып булмый инде. Салып калдырырсыз, кич белән чистартып калдырырмын. Түлке бер дә бу арада чәйлек бирмисең әле, әнә анда түбән коридорда, өченче номерда тора торган кеше кибеткә бер кадак алма алырга җибәрсә дә чәйлек бирә.

Әхмәт. Бар, миңа бер чүпрәк кенә китер алайса, үзем сөртермен.

Коридорный. Чүпрәк тә юк, кичә кич кенә һәммәсен дә сыгып кибәргә элеп куйдым.

Әхмәт (*коридорныйның кулындагы пычрак кара тастымалын күрсәтеп*). Әнә, соң ул кулыңдагы кара чүпрәк нәрсә соң?

Коридорный. Нәрсә булсын, тастымал, чынаяк сөртә торган.

Әхмәт. Ә? Тастымал? Чынаякны шуның белән сөртәсезмени?

Коридорный. Ә соң нәрсәгә сөртим, әллә ак платнадан ясаган тастымалга сөртикме? Әле бай шуңа да ачулана, тастымалларны яхшы карап тотмыйсыз, бик тиз черетеп, каралтып бетерәсез, ди.

Әхмәт. Алай булса, бар син щетка гына китер, үзем чистартырмын.

К о р и д о р н ы й. Щетканы иртә белән утызынчы номердагы студент алган иде, ул номерында бикләп киткән, кичсез кайтмый.

Ә х м ә т. Кадалып кына китегез!

К о р и д о р н ы й. Башка йомыш юкмы? (*Чыгып китә.*)

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ә х м ә т ялгыз.

Ә х м ә т (*халыкка карап*). Ул чынаяк сөртә торган тастымал, имеш, әгәр инде, мәсәлән, самавыр сөртә торган тастымал булса, ансы нинди булыр иде икән? Юк инде, болай гына торып эш чыкмый, ничек итеп булса да эшне үзем рәтләргә кирәк. Иң әүвәл менә шушы гәзит кәгазьләре белән сөртергә дә, аннан соң берәр кара кер табылыр әле, ансы белән ялтыратырмын. (*Бер генә ала да, бераз карап.*) Бу гәзит үзе укылмаган икән укылуын да, ярар инде, әллә нәрсә юктыр әле, кичәгесе белән бу көнгесе арасында күп аерма булмас. Кичәгесендә урлаган өчен, исереклек өчен, сәдака сoранып йөргән өчен 78 кеше частка эләккән булса, бу көнгесендә 88 эләккән булыр. (*Чистарта.*) Хәер, өченчекөн праздник иде, праздник көнне исерек күбрәк булганга, күбрәк эләгәләр. Тилиграмнарында да күп хикмәт булмый. Берсендә фәлән җирдә тау ишелгән дип язган булса, икенчесендә поездлар бәрелешкән, вагон юлдан чыккан, фәлән җирдә янгын булган да ике йөз йорт янган дип язган була. Менә минем шуңар исем китә. Гәзит саен әллә ничә кызның, өмидсез гыйшык сәбәпле, ак серкә эчеп агуланганын язалар. Үләргә теләгәч, нигә инде ак серкә эчеп мәшәкатьләнеп үлмичә калырга кирәк тә һәм ни өчен эчәргә кирәк? Бер гыйшык өмидсез булган икән, наплевать! Ансын ташла да, икенчесен сөй! Хәер инде, андый ак серкәләр эчүчеләр арасында матурлары азрак була. Мин шулай берсенең ак серкә эчеп агуланганын ишеткән идем һәм, өйләре дә бездән ерак булмаганга, ул нинди нәрсә икән дип белергә теләгән идем, берничә көннән, теге терелеп чыккач, миңа күрсәттеләр. Илаһи, ни күзең белән күрәсең, дөньяда беренче ямьсез бер кухарка икән, үзе шадра, үзе чепи күзле! Ә гашыйк булган кешесе шул ишегалдындагы бер дворник икән. Ул дворнигы, тегене ташлап, ишегалдындагы икенче кухарка белән йөри башлаган да, шуңар ачу итеп, кухнәдәге ак серкә спиртеннән берәр йотымны йоткан да акырырга, кычкырырга тотынган, шуннан аны балнитсәгә җибәргәннәр дә шуның белән

бөтен гыйшкының эше тәмам булган. Шулай ук менә шушы сөртү белән минем штиблитнең дә эше тәмам булды. Менә бу җирләрендә генә бераз, гәзитләрнең озын фельетоннары шикелле, бетеп җитмәгән, бер-ике чистартырлык ахыры бар барын да, ансын инде кипкәч, щетка да табылгач, иртәгә чистартырмын. (*Кулын юып килеп.*) Йә, хәзер инде ни эшләргә кирәк? (*Тәрәзәдән карап.*) Яңгыр да туктаган, көн аязган. Танса кичәсе бүген шәп булыр әле, җәй буе тик торып, аяклар камашып бетте инде. Бүген, минем шикелле, аякларын язарга килүчеләр күп булыр әле. Тансалар кызык була булуын, бүген бер сөйгәнрәгең белән тансавайт итәсең, икенче көнне икенче – аннан да матуррагы белән тансавайт итәсең, ләкин өйләнмичә генә гел әрле-бирле шататься итеп, җылкы итенә кызыккан малай шикелле генә йөрүнең бер мәгънәсе дә юк. Кич буе әле берсе, әле икенчесе белән тансавайт итеп йөрисең дә, эт шикелле арып кайтып егыласың, аннан соң төн буе тик саташып ятасың. Колак төбендә төн буе «Кек уок»[1] та «Матчиш», «Русский славянский» да «Вальс», ул «Вальс» инде бөтенләй башны әйләндерә. Төн буе бөтен караватың белән тулкын өстендә диңгездә тирбәнгән шикелле ятасың, юк, болай гына йөреп бик күп мәгънә чыкмас, ахры, бер чибәренә ныклап күңел куярга да өйләнергә кирәк. Ләкин кемгә өйләнергә дә кемне алырга кирәк? Бер исәпләгәндә, өйләнү күңелле нәрсә. Тукта әле, өйләнү дигәннән, бернәрсә хәтеремә килде. Тукайның шигырендә өйләнү турысында бер нәрсә бар иде, минем аны яхшылап укып караганым юк иде әле. Өйләнү турысында ул ни яза икән? Әгәр ул да шәп язса, тотарга да карар бирергә һәм өйләнергә кирәк. (*Өстәл өстеннән Тукайның шигырьләрен ала да, актарып табып, караватына арка өсте ятып укырга тотына.*) «Өйләнү – түгел сөйләнү». Дөрес, бик дөрес әйткән, өйләнү, әлбәттә, коры сөйләнү генә түгел, аңа бик күп баш ватарга кирәк. (*Укый.*)

Кара, иптәш, сиңа килдем киңәшкә:
Күз аттым мин бүген бик шәп кәләшкә.

Каплаган да куйган, нәкъ менә мин инде ул. Менә, мәсәлән, мин бүген киңәшкә килдем. Һәм шулай ук мин бүген бик шәп бер кәләшкә, ие, ягъни мәсәлән, инде Нәгыймәгә күз атып торам. (*Укый.*)

Ни дирсең син, әгәр дә мин өйләнсәм,
Кеше төсле урынлашсам, көйләнсәм?

Шәп киңәш сорый. Акыллы сүз әйтә, «Кеше төсле урынлашсам, көйләнсәм» ди. Дөрес шул, бик дөрес, безнең

менә нәрсә бар, нинди рәт бар да нинди көй бар? Штиблитең балчыкка баткан икән, аны үзең чистарт. Ә өйләнгәч инде андый эшләр һич булмый. Иң элек яхшы гына, адәм төсле тора башлыйсың. Иртә белән яңгыр булу ихтималы бар икән, җанашың инде ул вакытта сине озатырга чыккан җирендә көн болытлы икәнне күрә дә, җаным, көн болытлап тора, яңгыр җавып пычратмасын, калушыңны да киеп чык, зунтигыңны да алып чык, ди инде. Син алып чыгасың да, яңгырда чыланудан да котыласың һәм штиблитең дә пычранмый. Әнә бәр тәкъдир пычрана да икән, ул вакытта синең өстеңнән киемеңне салдырып киптерергә элеп куя да, штиблитеңне дә чистарттыра, мондагы шикелле гәзит кәгазьләре белән үзеңә чистартып торырга да кирәк булмый, щетканы да студент номерына бикләп китми. (*Укый.*)

Алай булгач, өйлән, дуст, чикмә ваем,
Матур, якты гомер бирсен Ходаем.

Һәм вакыйган дә бик шәп сүз әйтә, «Матур, якты гомер бирсен Ходаем» ди, бик шәп сүз бит. «Матур, якты гомер!» Ул нинди шәп эш! Ә монда ятканда гомерең түгел, номерың да якты түгел. Тәрәзәсе кечкенә, тәрәзә пәрдәләре тузанга карыш каткан, караңгы. Хәер, инде анысы, түбәнге каттан зуррак тәрәзәле номер алсаң, алай булмас иде булуын да, андый номерлар бик кыйбат шул. Алган жалуниянең яртысын номер өчен бирергә кирәк, ә аннан соң үзеңә расходка тотарга нәрсә кала? Безнең шикелле аз жалуния белән тора торган кешегә өйләнмичә номерда тору бер дә ярый торган эш түгел, өйләнергә кирәк, өйләнергә! Тотам да өйләнәм, бүген үк Нәгыймәгә аулакта гына сүз салам. Ул инде, бәлки, үзе дә миннән, минем авыздан андый сүз кайчан гына чыгар икән дип йөри торгандыр. Тотарга да тәвәккәл кылып әйтергә кирәк, юк исә инде мин әйтмичә, ул үзе миңа әйтмәс. Чынлап та бит Нәгыймә бик мәгъкуль: үзе матур, үзе җитез. Ай, юк, бик тиз үк алай кырт кисеп әйтеп куярга ярамас. Бәлки, ул мин уйлаганча ук булып чыкмас? (*Укый.*)

Шулай димсең? Шулаен ул шулай да,
Ярый ла эш барып торса уңайга.

Бу да дөрес, ие шул, ярый ла эш барып торса уңайга. Әгәр уңайга бармаса нишләрсең? Мәсәлән, ул сине ярат-

---

Бәр тәкъдир – әгәр инде.
Вакыйган дә – дөрестән дә.

мас булса йә син аны яратмас булсаң? Дөньяның эшен белер хәл юк бит, йә булмаса баең урыныңнан куып чыгарыр да, урын таба алмыйча аптырап йөрерсең. Ул вакытта аны кая куярсың? Әле болай, ичмаса, бер башың да бер үзең. Ә син, бар анда, аның тамагын теләсәң кайдан табып туйдыр! (*Укый.*)

> Хатын алмак читен бит һәм мәшәкать,
> Бер алгач, булмый бит шайтанны ташлап.

Афәрин, дөрес! Өйләнү бик читен, бик мәшәкать. Өстәвенә, бер алгач, аның белән аерылышып йөрүе үзе бер читен эш. Хосусән хатынын аерган икән дип сөйләүләре үзе бер килешмәгән эш. (*Укый.*)

> Бөтенләй бәйләнә анда аяк-кул.
> Җүләрлек ул – өйләнмәк гайре мәгъкуль.

Дөрес, дөрес, бик дөрес. Өйләнү вакыйган дә җүләрлек, имеш, аяк-кулыңны үз ихтыярың белән бәйләп куй, имеш. Менә өйлән дә син, Әхмәт, аннан ары танса кичәләренә барып, Сашалар, Машалар белән тансавайт итеп кара, бөтенләй өеңдә буран туздырырлар. (*Укый.*)

> Алайса, көчләми һичкем, өйләнмә,
> «Киңәш бир дә киңәш бир» дип сөйләнмә.

Ярый, син дигәнчә булсын, өйләнмим. Дөрес шул, нигә кирәк үзеңне-үзең хатыныңа кол итеп торырга?

> Шулай димсең? Шулаен ул шулай ла,
> Әгәр дә охшаса ул тулган айга!

Ие, ягъни мәсәлән, минем Нәгыймәм төсле булса, ух, нинди хозур! Әйтерсең лә моны язучы Нәгыймәне күргән дә аңар гашыйк булган. (*Укый.*)

> Фәрештә күк көлеп, алдыңда торса,
> Вә, туптай, киң кочакка ул атылса!

Тәмам, тәмам нәкъ койган да куйган. Нәкъ менә Нәгыймә. Ух, күрсәгез иде сез аның краковяк тансавайт иткән чагында бөтерелгәләп йөргәнен, гүяки менә инде электрик лампасы әйләнәсендә очып әйләнеп йөргән күбәләк шикелле. (*Укый.*)

> Шулай булгач, ничек алмый түзәрмен, –
> Алам, мин, бәлки, рәхәттә йөзәрмен.

(*Сикереп торып, бөтенләй җиңеләеп.*) Алам, алам, һич түзәр хәлем юк! Бүген үк үзенә әйтәм! (*Яңадан килеп ятып, укырга тотына.*)

---

Хосусән – бигрәк тә.
Гайре мәгъкуль – мәслихәт түгел.

Шулай димсең? Шулаен ул шулай да,
Ярый ла эш барып чыкса уңайга:
Хатыннарны сөюче бер матур яшь
Минем ярны сөюдә булса көндәш?

Ие, менә, мәсәлән, Гали шикелле. Ул да аңар бик күзен кыздырып йөри йөргүен. (*Укый.*)

Сөеп китсә хатын һәм ул җегетне,
Читен тормыш: бер айда бар да бетте.

Һәм дөрес әйтә, әгәр андый булса, тот та суел да үл инде. Ләкин инде ансы булмас, матурны кем яратмый? Гали ул үзе Нәгыймә тирәсендә киләп сарып, тәлинкә тотып йөри; мин бар чагында Нәгыймә андый камыт аякка илтифат итәме соң? (*Бераз торып.*) Ләкин ул бит миннән баерак. Әгәр дә ул аның байлыгына кызыкса? Һич белер хәл юк, хатын-кызга ышанып бетәргә ярамый. (*Укый.*)

Алайса, көчләмәс һичкем, өйләнмә,
«Киңәш бир дә киңәш бир», – дип сөйләнмә.

Дөрес, һич кирәге дә юк, өйләнмим дә, кирәкми дә. (*Укый.*)

Өйләнмим, дим, «өйләнмим» – ул матур сүз,
Читен шул дөньяда тормак хатынсыз.

Һәм дөресен дә дөрес, хатынсыз торудан да читен һичбер нәрсә булмас, һич ашавыңның рәте юк, эчүеңнең рәте юк. (*Укый.*)

Ятасың боз кебек салкын түшәктә,
Гүя син бу җиһанга килмешәк лә!

Моннан да дөрес сүз юк инде. Хосусән номерда тору бигрәк читен. Әле хәзер зарарсыз әле, түзеп була, әмма инде кыш көнендә бөтенләй зәмһәрир тәмугсы шикелле була. Номер хазяине үзе номерда тормаганга белми. Утынны янга калдырыр өчен аз ягып, бөтен кыш буе безнең тешләрне тансавайт иттертә. Юк инде ул, өйләнмичә бәхеткә ирешеп булмый. (*Укый.*)

Бүленми эш тә бер мәгълүм вакытка,
Бу хәлләр бик ерак, иптәш, бәхеткә!

Бу сүзнең дә дөреслегендә һич шик юк. (*Укый.*)

Кәләшкә мин бүгеннән яучы салсам,
Озак үтми аның куйнына барсам?

Һәм бүген үк яучы салам. Хәер, миңа яучы да кирәкми,

---

Зәмһәрир – салкын.

турыдан-туры үзем тотам да әйтәм. Ул да кабул итәр, эш тә бетәр. Яучыны форма өчен генә җибәрербез. (*Укый.*)

Җылы куллар белән ул тәнне сарса, –
Бәхет шул, эзләмим мин башка нәрсә!

Бу сүзне инде нәкъ мин булып әйткән. (*Укый.*)

Алай булгач, өйлән, дуст, чикмә ваем,
Җылы, якты гомер бирсен Ходаем.

Мәсьәлә хәл кылынды, өйләнәм. Нәгыймәне алам, бүген үк әйтәм. (*Укый.*)

Шулай ла, ул әгәр дә иркә булса?
Тәкәббер бер кабарган күркә булса?

Нәгыймә ул иркәлеккә иркә дә инде, ләкин алай кабарган күркә түгел. (*Укый.*)

Риза булмый минем тапкан табышка,
Сәбәп булса һаман юк-бар тавышка?

Нәгыймәдә андый эш, шаять, булмас, ул минем бик бай түгел икәнне, минем байда торганымны белә бит. (*Укый.*)

Риза булмый минем алган киемгә,
Төшерсә ул кесә якны кыенга?

Ансы да булмас дип беләм. Шаять, мин тапканга риза булыр. (*Укый.*)

Ире кем? Баймы, юкмы, белми хәлен,
«Китер!» – дип дауласа зәңгәр вә алын?!

Нәгыймә зиһенсез кыз түгел ул, алай дауламас, ул, минем хәлне белер. (*Укый.*)

Шулай, иптәш, алай курыксаң, өйләнмә,
«Киңәш бир дә киңәш бир», – дип сөйләнмә.

Рәхмәт киңәшеңә, мин алай бер дә курыкмыйм. Әгәр инде бераз курку була икән, аннан гына зарар юк. (*Укый.*)

Шулай да бит, ата булмак күңелле,
Бөтенләй шат итә ул хәл күңелне,

Шәп, шәп, бик шәп. (*Укый.*)

Балаң йөгереп менә алга «әти!» дип,
«Китер, әткәй, миңа мәм-мәм, тәти!» дип.

Нинди хозур бит! Аларның шунда идәндә тәгәрәп уйнап йөрүләре үзе дә бер хозур, күңелле эш. (*Укый.*)

Бу хәл, иптәш, җуатмасмы күңелне,
Бөтен рәхәт, хозур шунда түгелме?

Дөрес, әлбәттә, шунда. (*Укый.*)

Алай булгач, өйлән, дуст, чикмә ваем,
Эти булмак насыйб итсен Ходаем.

Бетте, мәсьәлә тәмам хәл кылынды, өйләнәм! (*Сикереп торып китапны өстәлгә куя башлый да.*) Тукта әле, ахырына кадәр укып бетерергә кирәк. (*Укый.*)

Шулай да соң, балаң булса биш-алты,
Өең тулса шулардан һәм каралты?

Тулса соң, аның ни зарары бар, бигрәк яхшы, картайган көндә, алар хезмәт иткәндә, син тик рәхәтләнеп ятарсың.

Шуларны туйдырамын дип тирең түк,
Иел җиргә, дуга төсле, билең бөк.

Монысы да бернәрсә дә түгел, безне этиләр мәшәкать чигеп, тәрбия кылып үстермәгәннәрмени? Аңар карап бер дә ватылмаганнар, бик яхшы торганнар. (*Укый.*)

Алай булса, хатынсыз тор, өйләнмә,
«Киңәш бир дә фәлән бир!» – дип сөйләнмә.

Хәзер бер дә киңәш бир дип сорамыйм, карар бирелгән, өйләнәм, вәссәлам! Әле тик болай, тагы нәрсәләр язгансың икән дип кенә укыйм. (*Укый.*)

Шулай да, ул балалар үссә бар да,
Әгәр дә җир җиләктәй пешсә бар да?
Таянып яшь гакылга һәм дә көчкә,
Керешсә һәрбере бер яхшы эшкә?

Шулай шул, мәсәлән, кайсы адвокат, кайсы доктор, кайсы инженер булып китсә, һич белер хәл юк; мин үзем дә яхшы ук зур кеше булыр идем булуын да, бары тик этиләр укытмаганга гына кантуршик булып калдым. Укыган булсам, мин бу зирәклегем белән әллә нинди шөһрәтле бер кеше булыр идем. Белер хәл юк, бәлки, киләчәктә булып та китәрмен әле. (*Укый.*)

Баеп китсә алар шул эш юлында? –
Итәрләр тәрбия картлык көнемдә.

Анда һич шөбһә дә юк. Әхмәтең ул вакытта түшен киереп, афтамабилләргә генә утырып йөрер. (*Укый.*)

Алай булгач, өйлән, дуст, чикмә ваем,
Тыныч картлык насыйб итсен Ходаем.
Шулай, ләкин киреrә ишсә язмыш?
Үлеп китсә хатын, күп тормый, яңлыш?
Биш-алты яшь бала калса кулыңда –
Менә инде чокыр тормыш юлыңда!

Ансы шулай шулаен да, ләкин бит андый эшләр һәркемгә дә булмый, бүредән куркам дип урманга керми тормыйлар инде. (*Укый.*)

Тынычлык юк аларның борчуыннан.
Колагың тык аларның чыр-чуыннан!

Зарар юк, түзәрбез. Алай бераз гына мәшәкать тә булмагач, тормышмыни ул? (*Укый.*)

Менә, иптәш, бу эшкә аптырыйм мин,
Бу уйны уйлагач та калтырыйм мин!

Юк эштән куркасың икән, алай булгач, син тавык йөрәк икәнсең, ә менә мин бер дә курыкмыйм. Хосусән Нәгыймә хатыным булса, бер дә курка торган эш юк. (*Укый.*)

Алай булгач, куша чорт, һич өйләнмә,
«Киңәш бир», – дип йөдәтмә һәм сөйләнмә!

Дөрес, афәрин! (*Укый.*)

Диим бер сүз, бүтән бер сүз дә катмам:
«Хатын алсаң, кирәк ит көн дә батман!»

Аның белән дә куркыта алмассың, кирәк исә йөз батман булсын, мин карар бирдем, вәссәлам! Өйләнәм дигәч өйләнәм! Менә хәзер бик шәп кенә иттереп киенеп җибәрәм дә тансага барам. Нәгыймәне күрәм, сөйләшәм, риза булса, бүген үк вәгъдә куям. Монда тузан арасында болганып, йөрәккә җон үстереп торыр хәл юк. (*Торып йөри башлый.*) Кара инде бу өстәл өсләрен, бөтенләй тузанга батып беткән, ә өйләнеп тора башлагач, боларның берсе дә булмас! Ялт иткән булыр! (*Звонок бирә.*)

Г о р н и ч н ы й керә.

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ә х м ә т, г о р н и ч н ы й.

Г о р н и ч н ы й. Нәрсә бар?

Ә х м ә т. Нәрсә булсын, кара менә бу тузаннарны! Һич җыештыра алмыйсыз.

Г о р н и ч н ы й. Мин монда кырык номерга берүзем ничек җитешим. Алай бик чиста торасың килсә, өйләнерсең дә хатының җыештырыр.

Ә х м ә т. Ә менә монысы өчен сезгә рәхмәт. Хатын булса, шулай чиста булыр иде диген, ә? Бик дөрес, бик дөрес. Ну, син әле боларны җыештырып ал әле. Аннан ары, өйләнгәч, мин үзем дә сезгә кушмам.

Г о р н и ч н ы й. Минем хәзер эшем бик күп, соңыннан җыярмын.

Ә х м ә т. Мин хәзер чыгып китәм.

Г о р н и ч н ы й. Алай булгач, иртәгә иртә белән җыярмын.

Әхмәт. Ә мин иртә белән иртүк чыгып китсәм?

Горничный. Сез кайткач җыярмын.

Әхмәт. Мин бит кич белән генә кайтам.

Горничный. Кайтсагыз, иртә белән бер вакыт табып җыелыр әле. (*Чыгып китә.*)

Әхмәт. Менә син инде сөйләш болар белән! Юк, болай торып булмый, өйләнәм, өйләнәм! Хәзер үк штиблитләрне чистарттырам, тансавальный вечерга барам. Нәгыймәгә әйтәм, мин бүгеннән башлап хатынлы кеше!

Чыга башлый, ишектә кер юучы хатын очрый.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әхмәт, кер юучы.

Кер юучы. Тукта, ул кадәр ашыгып кайда барасың?

Әхмәт. Шулай, эшем бар, чыгып барам.

Кер юучы. Бу вакытта нинди эш булсын, үзе бәйрәм, үзе кич, гуләйт итәргә бара торгансыңдыр әле!

Әхмәт. Гуләйт итәргәме-юкмы, анда синең эшең юк. Кайда, күпме акча кирәк?

Кер юучы. Бер сум сиксән тиен.

Әхмәт. Ә?!

Кер юучы. Нәрсәсе «ә»? Әле дә арзан алам. Кер юган акча ашарга да чут-чут кенә җитә.

Әхмәт. Бер дә алай түгел инде, юар өчен, күп булса, ун тиенлек сабын, якаларын крахмалларга биш тиенлек крахмал киткәндер, бер дә артык китмәс. Өйләнәм, өйләнәм, болай үземне тереләтә талатыр хәлем юк.

Кер юучы. Өйлән, миңа дисәң, бер түгел, биш хатын ал. Ул чагында хатыннарың тереләтә генә таламаслар, тереләтә тиреңне дә тунарлар. Бабайлар, хатын алсаң ни кирәк, көн дә батман ит кирәк, дигәннәр. Туйдыра-туйдыра җаның чыгар.

Әхмәт (*үзалдына*). Кара, кара, монысына кадәр ниләр сөйләп маташкан була бит! Юк инде ул, Әхмәт алай артын исәпләми эш кыла торган кеше түгел. Ул бик яхшы белеп эшләр. (*Кер юучыга.*) Йә, ярый, мә, акчаңны ал да тизрәк тай. (*Акча бирә.*)

Кер юучы. Ярый, хуш, сау бул. Өйләнсәң, керләреңне башка кешегә бирдермә, безгә бирерсең, без керне пот башыннан хисаплап та юабыз, ярый, хуш! (*Чыга.*)

Әхмәт. Ярый, ярый, бик хуш! (*Кер юучы чыгып киткәч.*) Кара син аны, мине бөтен гомер буена үзләренең

тырнакларында эләктереп тотмакчы булалар бит, аларга шул безнең шикелле хатынсыз кешеләр кадерле, һәммә кеше өйләнеп бетсә, аннан соң аларның ризыклары киселә. Ну, ярый. Китәргә кирәк. Нәгыймә белән тизрәк күрешергә кирәк. (*Чыга башлый.*)

Ул арада ишек шакылдаталар.

Рәхим итегез!

Ишектән Н о г м а н керә.

### БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ә х м ә т, Н о г м а н.

Н о г м а н. Нихәл, иптәш, әллә син берәр җиргә барырга торасыңмы?

Ә х м ә т. Ие.

Н о г м а н. Кайда барасың?

Ә х м ә т. Тансага.

Н о г м а н. Ә? Тансага? Кит аннан, җүләр! Акыллы кеше тансага барамы соң?! Йә утыр әле, йөрмә юк артыннан, кая, туган, минем бик эчәсем килә, самавыр китерт әле.

Ә х м ә т. Әйтәм бит мин тансага барам дип.

Н о г м а н. Барсаң барырсың, мин махсус чәй эчәргә дип килдем, өйдә дә күңелсез, хозәйкә әллә кемнәренә кунакка киткән. Өйдә күңел каралткыч бер бабушкадан башка бер кеше дә юк. Бик эчпошыргыч булганга, тоттым да сиңа килдем.

Ә х м ә т. Әйдә, алай булса, минем белән тансага, чәйне шунда эчертермен.

Н о г м а н. Юк, минем алай бер-ике стакан чәй белән генә тамак туярлык түгел, әле минем бик ныгытып ашыйсым килә.

Ә х м ә т. Алай булса, мин самавыр китертәм, үзең утырырсың да эчәрсең.

Н о г м а н. Юк инде, ансы бик килешеп бетми, кеше номерында мин берүзем генә нишләп чәй эчеп утырыйм?

Ә х м ә т. Алай булгач, мин ни эшлим, мин бит барырга вәгъдә бирдем.

Н о г м а н. Беләм, беләм, нинди булса да бер портнихага вәгъдә куйгансыңдыр әле, бетмәс монда андыйлар. Аларның поты бер тиен.

Ә х м ә т. Юк, иптәш, син алай мыскыл итмә.

Н о г м а н. Йә, йә, кәефең китмәсен, алайса, портниха түгелдер инде, шәбрәктер, модисткадыр, алайса.

Ә х м ә т. Бер дә түгел.

Н о г м а н. Ну, хәерле булсын, бар, бара бир, мин тагы икенче җирдә чәй эчәрлек урын табырмын әле. Бер дә булмаса, харчевнәгә барып эчәрмен. (*Тора.*) Ярый, хуш. (*Чыга башлый.*)

Ул арада ишектән И с м ә г ы й л ь керә.

АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Ә ү в ә л г е л ә р һәм И с м ә г ы й л ь.

Н о г м а н. Кермә, кермә, туганкай, монда кертмиләр.

И с м ә г ы й л ь. Ни өчен? (*Кул бирә.*) Исәнмесез!

Н о г м а н. Ни өчен дисезме? Менә сезнең кавалер тансага бара.

И с м ә г ы й л ь. Тансага? Ерунда! Акыллы кеше тансага барамы соң? Мине дә бер барышня чакырган иде дә, мин бармыйм.

Ә х м ә т. Таптылар бер сүз: ерунда! Сезнеңчә, нәрсә генә ерунда түгел соң?

И с м ә г ы й л ь. Вот менә ерунда түгел нәрсә. (*Бер колода карта чыгара.*) Юлда килгәндә ала килдем. Наверно, мин әйтәм, аларның карталары юктыр. Тукта, мин әйтәм, алып барыйм. Әле ничек соң сезнең бүген бер дә кешеләр юк?

Ә х м ә т. Нинди кешеләр кирәк тагын, әллә притон дип белдегезме монда һаман җыелып карта уйнап ятарга?

И с м ә г ы й л ь (*Ногманга карап*). Сөбханалла, сөбханалла, бу ни булган моңар бүген? (*Әхмәткә.*) Әй син, шәп егет, бу ни булды сиңа бүген, ә?

Ә х м ә т. Берни дә булмаган, әйтәм бит мин сезгә: мин бүген тансага барам дип, һәм барам, уйнамыйм.

И с м ә г ы й л ь. Ну, как хочешь. Ну, түлке бүген карталарның бик шәбен алып килгән идем. Атласный карталар.

Ә х м ә т. Булса булыр. Мин бүген уйнамыйм.

Н о г м а н. Уйнамый ул бүген, бик акыллы кеше булган.

Ишектән Ш а к и р керә.

ҖИДЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ә ү в ә л г е л ә р һәм Ш а к и р.

Ш а к и р (*бик сузып*). Әссәламегаләйкем!

Ногман белән Исмәгыйль шаркылдап көлеп җибәрәләр.

Н о г м а н. Менә тагын бер член. Собрание ачыла.

Ш а к и р (*кулларын биреп*). Әле собрание ачылмады-

мыни? Мин инде соңга калганмындыр дип ашыга-ашыга киләм.

Исмәгыйль. Юк, туганкай, бүген собрание ачылмый.

Шакир. Ни өчен? Әллә бүген бер-бер траурный көнме?

Ногман. Безнең Әхмәт бүген свиданиегә бара.

Шакир. Аның шул булыр инде, ухажер!

Ногман. Хәтта бүген безгә чәй дә эчертмим ди әле.

Шакир. Аның чәе безгә нигә кирәк! Әйдә, ул китә бирсен, безнең монда члennar җитәрлек әле. Муса да хәзер киләм диде. Аннан башка да собрание полный булыр.

Исмәгыйль. Әйдә алайса, без эшкә керешәбез. Әхмәт, әйдә син дә берәр генә кон уйна инде.

Әхмәт. Юк, мин уйнамыйм.

Исмәгыйль. Ну, әйдә, нәрсә уйныйбыз, тёммы, банкамы?

Исмәгыйль.<br>Шакир. } Банка, банка!

Ногман. Кем банковать итә?

Исмәгыйль. Кем старше, шул.

Ногман. Әйдә, ачып сал.

Исмәгыйль (*өләшә*). Девятка, валет, король. Әйдә, Ногман, сиңа өләшергә.

Ногман. Бер сум банка. (*Акча чыгарып сала, өләшә.*)

Әхмәт. Ну, егетләр, хуш, мин киттем. (*Чыга.*)

Тегеләр (*күтәрелеп карамыйча*). Хуш!

Ногман. Йә, сиңа күпмегә?

Исмәгыйль. Ва-банк!!!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Беренче пәрдә белән икенче пәрдә арасында биш ел узган була.

### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әхмәтнең фатиры, уртача җыештырылган.

Әхмәт (*ишектән кереп, өстен салып*). Гаҗәп, үз-үземә исем китә, бу акча дигән нәрсә кайда китә бу? Өченчекөн генә байдан кырык тәңкә акча алдым, ә бүген кесәдә сукыр бер тиен дә калмаган дисәм дә, хата булмас. Аның өстенә тагын бурыч, бурыч, бурыч, һич иге-чиге юк. Контордан чыгып, өйгә рәхәтләнеп туры гына кайтырга да ихтыяр юк. Кайсы гына кибет алдыннан узсаң, аннан

чыгып акча сорыйлар. Акча сорауларыннан куркып, өйгә туры гына кайтасы урынга, әле урамның бер ягына, әле икенче ягына чыгып яки бөтенләй башка урамнан уратып кайтырга туры килә. Инде хәзер шәһәрнең бер ягына барасың булса, бөтенләй икенче ягына таба китеп, шәһәрне бөтенләй әйләнеп чыгарга туры килә. Элек, ичмаса, акчаң бар вакытта, граф булып, ду китереп торадыр идең дә, акчаң беткәч, икенче ай башы җиткәнче тик песи шикелле генә, тавышың-тыныңны чыгармый ятадыр идең, ә хәзер, хәзер белмим инде, ни дип әйтергә дә белмим. Әле утынчы, әле итче, әле күмәчче, әле сучы акча сорап теңкәңне кортып бетерә. Ә син, син, шуларның бәлаләреннән котылыйм дип, көн эшлә дә төн эшлә, алай да көчкә генә тамагыңны туйдырасың, һичбер ал да юк, җал да юк. Инде минем бер ай буладыр иде бугай бер гәзит тә укыганым юк иде. Бүген, тукта әле, нәрсә язалар икән, берәр файдалы эш юк микән дип, бер гәзит сатып алдым. Укып карыйм әле, бераз тынычлап ял да итәрмен, дөньядан да бераз хәбәрдар булырмын. (*Кесәсеннән гәзит алып, диванга сузылып ятып, гәзитне актара башлый.*) Әһә, менә городской театр. Йә әле, анда ни бар? Нәрсә дигән? Буначичның гастроленең актык көне! Мәшһүр җырчы Буначичның гастроленең актык көне! Билетлар бөтенләй сатылып беткән! Ай-яй-яй! Элек Варламов килгән, Давыдов килгән генә түгел, килә икән дигән хәбәрне ишеткәч тә театр кассасына билетка дип йөгерә торган Әхмәтнең бүген Буначичның, бөтен дөньяга мәшһүр Буначичның шәһәргә килүеннән, аның операда иштиракъ итүеннән, хәтта бөтенләй шәһәргә операның килүеннән дә хәбәре юк! (*Бераз торып.*) Хәер, аннан хәбәре булмаса, Әхмәтнең аның урынына хәзер итчеләрнең, утынчыларның, күмерчеләрнең концертларыннан бик яхшы хәбәре бар. Хәзер колак төбендә алар шундый, шундый шәп концертлар бирәләр, шак та катарсың.

Икенче яктан бала җылаган тавыш ишетелә.

Менә, менә хәзер концертлар башланды.

Бала җылаган тавышлар куәтләнә, һәм берничә баланың бердән җылаган тавышлары ишетелә.

Бу ни җитте генә концерт та түгел, бөтенләй хор белән җибәрәләр.

Нәгыймәнең балаларны орышкан тавышы һәм асрау кызның да тавышлары ишетелә.

---

Иштиракъ итү — катнашу.

Шулай, шулай, менә хәзер хорның җитешмәгән җире калмады инде. (*Урыныннан торып, ишекне ачып.*) Нәгыймә! Бу ни тавышлануыгыз инде бу? Нигә җылатасыз инде аларны, нигә карамыйсыз?

Балалар һаман җылый.

Җуатыгыз инде шуларны!

Балалар тагы да катырак акыралар.

Йа Алла! Менә сиңа тагы кирәк булса, тагы да шәбрәге!

Нәгыймә керә.

ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Нәгыймә, Әхмәт.

Нәгыймә (*биләгән бер баланы күтәреп кереп*). Әле син кайтып та җиткән икәнсең, бар икән күрәселәрем, Ходаем! Туйдым инде бу балаларның тавышыннан! Һич сулу алыр хәлем дә калмады инде. Әле берсе акыра, әле икенчесе кычкыра. Син тагын аш хәзерләгез диярсең әле, мә, бераз җуатып торчы шул баланы. (*Баланы Әхмәткә бирә дә чыгып китә.*)

Бала җылый.

ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әхмәт, соңра Нәгыймә.

Әхмәт (*баланы селкеп*). Чү, чү, нәнә, чү, чү, чү! (*Селкетә.*)

Бала аның саен акыра.

Чү, чү, чү! Ә-ә-ә! Менә син агай, моны ни эшләтергә инде? (*Ишек янына барып.*) Нәгыймә, Нәгыймә! Җылый бу! Мә, зинһар, ал!

Нәгыймә (*ишектән кечкенә бер баланы кертеп*). Әнә бар, бераз атаң янынарак кереп тор әле, туйдым инде сезнең тавышыгыздан! (*Ишекне ябып чыгып китә.*)

Бала (*Әхмәтнең итәгенә килепябышып*). Эти, эти!

Кечкенә бала акыра.

Әхмәт (*кечкенә баланы селкеп*). Чү! Чү! Чү!

Бала. Эти, дим! (*Чабуыннан тарта.*) Эти, дим!

Ә х м ә т. Сиңа нәрсә кирәк тагын? Чү, чү, чү!

Б а л а. Әти, дим, абый минем курчагымны ватты! Арбаны миңа бирми, үзе уйный! (*Җылый.*)

Ә х м ә т. Җитәр, җитәр, сабыр ит, арба да булыр, бары да булыр. (*Баланы селкеп.*) Ә-ә-ә!

Бала һаман җылый.

Нәгыймә, дим, Нәгыймә! Мә ал, зинһар, бу баланы, зинһар, ал!

Н ә г ы й м ә (*тыштан*). Сабыр итсәнә, мин ашымны хәзерлимме, баланы карыйммы? Җуат бераз.

Ә х м ә т. Җуат, җуат, җуатырсың боларны. (*Селки.*) Чү, чү, чү!

Ишектән у р а м   к и б е т ч е с е керә.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ә х м ә т, у р а м   к и б е т ч е с е.

К и б е т ч е. Әссәламегаләйкем!

Ә х м ә т. Вәгаләйкемәссәлам! (*Үзалдына.*) Менә тагы бер бәла! (*Балага.*) Чү, чү, чү! (*Кибетчегә.*) Әйдә, Нигъмәтҗан абзый, хуш киләсең! (*Балага.*) Чү, чү, чү! (*Кибетчегә.*) Нихәл, Нигъмәтҗан абзый, ни йомыш? Чү, чү, чү!

К и б е т ч е. Ни йомыш булсын, билгеле инде. Көттем, көттем, килмәдең, бөтенләй күздән югалдың. Акча кирәк.

Ә х м ә т. Чү, чү, чү! Кирәктер шул, ләкин бит әле хәзер минем акчам юк, шуңар күрә сезгә күренергә дә оялып йөрим.

К и б е т ч е. Беләм, беләм, бик беләм. Үзең әйтмәсәң дә качып йөргәнеңне бик беләм. Аша-аша да, аннан соң кач! Шул булдымыни инде эш!

Ә х м ә т. Мин нишләп качыйм, акчам юк, акчам булгач, үзем кертеп бирермен әле.

К и б е т ч е. Кертерсең син, кызыл кар яугач. Яхшылык белән хәзер бирсәң бир, бирмәсәң, мин өстеңнән миравайга бирәм.

Ә х м ә т. Миңа дисәң, аргы ягына кадәр бир.

К и б е т ч е. Ә син шулай икән әле, тукта, мин сине өйрәтермен әле. (*Читкә карап.*) Аны ничек итеп өйрәтәсең инде, әле тик болай, куркытыр өчен генә әйтәм.

## БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Шулар ук һәм с у ч ы.

С у ч ы (*ишектән башын тыгып*). Бай өйдәме?

Ә х м ә т. Өйдә, ни кирәк?

К и б е т ч е (*үзалдына*). Бай, бай, тик акчасы гына юк.

С у ч ы. Бай, сездә биш мичкә су акчасы аласы бар иде. Шуны рәхим итеп кенә биреп җибәрсәнә, хәзер солы да бик кыйбат, ат азыгына да акча җитештерер хәл юк.

Ә х м ә т. Икенче алырсың әле, бүген акчам юк.

К и б е т ч е (*үзалдына*). Бүген юк, иртәгә булачак түгел, ди.

С у ч ы. Бай, дим, зинһар, алай шаяртма әле, биш мичкә акчасы әллә ни түгел бит инде, җыенысы бер тәңкә акча икән, биреп кенә җибәр әле.

Ә х м ә т. Ишетәмсең, бүген юк, дим.

С у ч ы. Кайчан булыр соң?

К и б е т ч е (*үзалдына*). Кызыл кар яугач.

Ә х м ә т. Йә, күп йөдәтмә әле, алырсың, бар чык әле, бар, бар!

С у ч ы. Кума, кума, мин синнән сәдака акчасы сорамыйм бит, үз акчамны сорыйм.

Ишектән и т ч е керә.

## АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Шулар ук һәм и т ч е.

И т ч е. Бирешмә, бабай, бирешмә! Сора, сора, бу заманда сорамыйча бирү дигән нәрсә беткән инде ул. Бигрәк тә менә мондый коры көязләрдә. Кая син, Әхмәт, бу арада бер дә күренмисең лә, итне дә читтән ала башладың бугай, ахры, минем синнән биш сум егерме тиен ит акчасы аласы бар иде. Шуны биреп җибәрче әле.

К и б е т ч е (*үзалдына*). Миңа монда рәт чыкмас, ахры. Үземә дә тизрәк таярга туры килер. Минем дә бер туш ит акчасы бирәсе бар иде, җә миннән дә сорый башлар.

Ә х м ә т (*куркынып һәм тотлыгып, үзалдына*). Ми... ми... минем... башыма кыямәт кубачак көн бүген икән. Инде монысына ни җавап бирергә кирәк? Монысының күзенә карарга да куркыныч. (*Итчегә.*) Ә, кем абзый, зинһар, дип әйтәм, ие, зинһар, дип әйтәм... (*Үзалдына.*) Фу, чорт возьми, монысына ни дип әйтим икән инде, һичбер сүз дә табар хәл юк! (*Итчегә.*) Зинһар, дип әйтәм, кем абзый, әй, Вәли абзый, әй, юк, Гали абзый. Зинһар,

дип әйтәм... Уф, булмый инде. (*Баланы чыгарып бирә дә килеп утыра.*)

Итче. Нәрсә булмый инде, әллә минем акчаны ябып калмакчы буласыңмы?

Сучы. Ие, әллә минем атымның актык азыгын да йотмакчы буласыңмы?

Итче. Мин алай ашатмам, теш казналарыңны җимереп алырмын!

Күмерче килеп керә.

## ҖИДЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Шулар ук һәм күмерче.

Күмерче. Әһә! Үзе дә өйдә икән, кешеләр дә күп икән. Бик шәп булды әле. Хәзер инде оялыр, бирми калмас. (*Әхмәткә.*) Бай, бай, кайда, мин акчага килгән идем, анда тышта атым көтеп тора, эшем ашыгыч, атым китеп бармасын, миңа теге ике кап күмернең генә акчасын биреп җибәрегез әле.

Әхмәт (*ни эшләрен дә белмичә*). Аһ! Аһ! Кабер газабы.

Кибетче. Ие, ие, без менә Мөнкир-Нөнкирләр.

Итче. Җә, күп телеңә салынма, китер акчаны, минем эшем ашыгыч.

Күмерче (*тәрәзәдән карап*). Тпр-р-р-р! Атым китеп бара, кая, тизрәк акчамны биреп җибәр әле...

Сучы (*йөгереп килеп*). Анда минем дә атым бар... Алар тагын тибешмәсеннәр, кайда, тизрәк булыгыз әле, көттермәгез әле.

Бала (*йөгереп килеп, Әхмәткә сарылып*). Әти, әти! Миңа арба алып кайт!

Әхмәт (*сикереп торып*). Чәнчелегез, кадалыгыз! Бетте баш! (*Чыга башлый.*)

Һәммәсе бердән. Тукта, тукта, качма, кайда барасың? Җибәрмә! Кача алмассың!

---

Мөнкир-Нөнкир – газап фәрештәләре.

## СИГЕЗЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ш у л а р  у к  һәм у т ы н ч ы.

У т ы н ч ы. Тукта, ул кадәр кая ашыгып барасың?

Ә х м ә т. Җибәрегез мине, зинһар, җибәрегез!

Һ ә м м ә с е  б е р д ә н. Җибәрмә, җибәрмә! Акчаны биреп китсен!

У т ы н ч ы (*ишеккә аркылы төшеп*). Ие, ие, акчаны биреп кит, ничә ай бит инде, бүген бирәм, иртәгә бирәм дип, һаман алдалап йөртәсең. Рәхмәт сезгә. Аның бирәчәге бар икәнен, бирәчәген бирми йөргәнен сез дә беләсез икән. Инде менә хәзер май числасы, әгәр дә гыйнвар җитсә, бит алганына нәкъ бер ел тула, ә үзе һаман бүген бирәм дә иртәгә бирәм дип алдалап йөртә. Утыны тагын утын гына булса икән, менә дигән, зифа буйлы кызлар шикелле һәйбәт каен утыны иде бит.

И т ч е. Шулай, шулай, итне алганда, теге җирен бирмә, бу җирдән бир дип сайлап алган була, аңар син менә дигән җирен бирәсең, ә ул аны яратмаган була. Яхшы җирен, билдәмәсен бир, ә менә акчага килгәч, бер тиен дә юк.

К ү м е р ч е. Каен утыны утынмыни ул! Менә мин аңар чынаяк шикелле шыңгырдап тора торган нарат күмере бирәдер идем, ә ул аның да кадерен белми, хәзер андый күмерне көтәргә сату түгел, шыңгырдап торган көмеш акчага табуы да читен.

Ә х м ә т (*бер читкә барып утырып*). Инде болардан ничек кенә итеп котылырга?

С у ч ы. Җә, тизрәк булыгыз әле, көттермәгез! Анда минем атым тик тормый.

К ү м е р ч е. Һай, рәхмәт төшкере. Минем ат та тыпырчына башлаган, җә, тизрәк җибәрегез әле.

И т ч е. Җә, син, чибәр егет, нәрсә терәлеп каттың?

Ә х м ә т. Мин хәзер генә сезгә акчаны кайдан табыйм, бераз сабыр итегез, акчам булгач, барыгызга да бирермен.

К ү м е р ч е. Мине генә тизрәк алдан җибәр әле, ат тик тормый, тыпырчына. (*Тәрәзәдән карап.*) Тпр-р-р! Хайван!

С у ч ы. Җә, тизрәк бул! Минем эшем син генә түгел. Тагы биш җиргә су китерәсем бар.

К и б е т ч е. Сезнең эшегез булган шикелле, минем дә эшем күп, тизрәк булыгыз.

ТУГЫЗЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Шулар ук һәм Ногман, Исмәгыйль, Шакир.

Шакир. Әссәламегаләйкем!

Өйдәгеләр. Вәгаләйкемәссәлам!

Ногман. Менә, иптәш, без килдек. Анда бармакчы булдык, монда бармакчы булдык та, артык уңайлы урын таба алмадык.

Исмәгыйль. Мин әйтәм, мөгаен, дим, Әхмәт, дим, өйдә, дим. Әйдә, мин әйтәм, Әхмәткә барабыз, дим. Әхтәри ярырбыз, дим, какрас, мин әйтәм, минем күптән түгел генә алган атласный әхтәриләрем бар, дим. (*Кесәсеннән карта чыгара башлый.*)

Әхмәт (*чыраен сытып*). Куй әле, зинһар, андый юк эшләрне! Кил әле менә монда. (*Бер читкәрәк тартып китереп.*) Туганкай, менә монда эшләр начар әле. Күрәсеңме менә бу кешеләрне? Болар менә барысы да миннән алачакларын сорарга килгәннәр.

Исмәгыйль. Алачакларын?! (*Тегеләргә борылып карый.*) Соң?

Әхмәт. Шул, менә мине баядан бирле инде акча сорап йөдәтәләр. Бирмәсәң, чыкмыйбыз, диләр. Син инде, туганкай, карта уйнарга да килгән булгач, акча да алып килгәнсеңдер инде, зинһар, миңа бер ун-унбиш сум гына акча биреп тор. Мин тиздән бирермен.

Исмәгыйль (*бик каушап*). Әй, юк, туганкай, юк, мин бары тик уйнарга, болай, вакыт уздырырга гына дип, аз гына акча алып килгән идем. Миндә юк, әнә син Ногманнан сора, аның акчасы күп булырга кирәк. Әле монда килгәндә генә тәмәке алганда бишлек алмаштырды. Янында башка кәгазьләре дә күренәдер иде. Мин юри, бу юк-бар акча белән генә уйнарга бармыймы икән дип күземне төшердем, аның акчасы күп. (*Куллары белән кирегә селтәп, кесәләрен капшап.*) Юк, туганкай, юк, юк. (*Кирегә чигенә.*)

Әхмәт. Бигрәк инде син, кешене шундый вакытта да поддержать итмисең.

Исмәгыйль. Юк бит, булмагач ни эшлим?

Әхмәт, өмиден өзеп, Шакир янына бара.

---

Әхтәри ярырбыз – карта уйнарбыз.

(*Исмәгыйль бөтенләй артка чигенеп, үзалдына.*) Мин үзем монда биш-ун тәңкә эләктереп булмасмы, пальтоны чөйдән алырлык эш чыкмасмы дип йөрим. (*Юка пальтосын күрсәтеп.*) Кара моны, үтәли җилләр сызгыра. Кесәдә бөтенләе биш тәңкә акча бар, аны да биреп, үзем авызымны күтәреп калыйммыни?! Мин үзем әле шул биш янына берәр бишне эләктереп булмасмы, кышкы пальтоны алып кайтыр идем дип йөрим, ә ул мине актык акчадан колак кактырмакчы була. Моннан ничек тә тизрәк сызарга кирәк. (*Кеше күрмәгән арада чыгып китә.*)

Күмерче (*үзалдына, тәрәзәдән карап*). Ай-һай, ат кына китмәсә ярар иде, кайдан килеп чыкты бу нәрсәләр? (*Әхмәткә.*) Кайда, минем ат тик тормый, мине тотмагыз әле, җибәрегез!

Кибетче. Сезнең эшегез булган шикелле, минеке дә күп, анда минем кибет тә ябык әле.

Әхмәт. Хәзер, хәзер, сабыр итегез бераз. (*Шакирны бер почмакка китереп, акрынрак.*) Кайда, туганкай, синең акчаң бардыр, миңа бер ун тәңкә генә акча биреп тор әле, боларның гына авызларын тыгылдырып чыгарып җибәрим әле, аннан соң мин сиңа тиздән, берничә көннән үк табып бирермен.

Шакир (*каушабрак*). Ә? Ни дисең? Акча?! Минем, туганкай, үземнең дә эшләр синекеннән артык түгел, әле мин карта уйнарга да синнән сорап торырмын дип килгән идем, менә, ышанмасаң, кара! (*Портмонетын күрсәтеп.*) Күп булса, алтмыш-җитмеш тиен акча бар.

Ногман (*үзалдына*). Бу, мөгаен, берәм-берәм чакырып китереп, акча сорый торгандыр, ахры. Йә миннән дә сорап, актык биш-ун тәңкәдән дә колак кактырыр. Яхшы чакта тизрәк таярга кирәк. (*Акрын гына чыгып китә.*)

Әхмәт. Зинһар, дип әйтәм, Шакир, тыңла әле. Йә, зинһар, шундый, кешенең тәмам җыгылган вакытында дуслыгыңны күрсәт әле.

Шакир. Юк, дим, юк. (*Кире-кире чигенеп.*) Булмый, һич булмый, мөмкин түгел, хуш, сау булыгыз, мин киттем. (*Чыга.*)

Әхмәт. Шакир... ул да китте... Ногман! Ах, йөзе кара икән, ул да чыгып сызган. (*Диванга җыгыла.*)

Күмерче. Кайда, туган, мине җибәр әле, минем атым тик тормый.

---

Пальтоны чөйдән алу – ломбардтан, закладтан алу.

С у ч ы. Бай, бай, мине дә, зинһар, тотма әле, минем суга барасым бар.

К и б е т ч е. Минем дә анда, ишек төбендә, инде әллә никадәр кеше җыелгандыр.

И т ч е. Җә, син, егет, тизрәк бул. Нәрсәгә монда кешене көттереп торасың?

К ү м е р ч е (*стенадагы сәгатькә сузылып*). Бирмәсәң бирмәссең, миңа шул җитәр. (*Алмакчы була.*)

К и б е т ч е (*өстәлдә тора торган самавырга ябышып*). Миңа да шул ярар.

С у ч ы (*өстәлдәге лампага тотынып*). Хатын күптән бирле бер шарлы лампа алып кайт дип даулыйдыр иде. Әйдә рәхәтләнсен, миңа да шул ярар.

И т ч е (*карап торып*). Егетләр, сез ни эшлисез, ул ни эшләвегез?

Ә х м ә т (*сикереп торып*). Сез, ни эшлисез сез, ул ни эшләвегез?

К и б е т ч е. Ни эшләү булсын, алачагыбызны алабыз.

И т ч е. Ә миңа нәрсә?

К и б е т ч е. Нәрсә булсын, бар, теләсәң, син дә ал.

И т ч е. Чынлап та, болай карап торып кына булмас, ахры. (*Ары-бире каранып.*) Ә! Менә монда машина бар икән, миңа да шул җитәр. (*Өстәл астыннан машинаны тартып чыгара.*)

У т ы н ч ы. Ә миңа нәрсә?

Ә х м ә т. Караул! Йортымны талыйлар!

Н ә г ы й м ә (*йөгереп кереп, теге кешеләрне күреп*). Ах! Харап булдык!

Б а л а л а р (*йөгереп чыгып*). Әти, әти! (*Әхмәткә сарылалар, җылыйлар.*)

Ишектән Г а б д р а х м а н керә, мондагы күренешне күреп, шаккатып карап тора.

## УНЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Ш у л а р у к һәм Г а б д р а х м а н.

Г а б д р а х м а н. Әссәламегаләйкем!

Тегеләр һәммәсе карап торалар. Кайберсе кулындагы нәрсәләрен урыннарына куярга маташалар.

Ә х м ә т (*Габдрахманны күреп, оялып*). Ах! Абый! (*Башын ике кулы эченә алып.*) Харап булдым!

Габдрахман. Бу ни хикмәт бу? Әллә фатир күченәсезме?

Әхмәт (*аптырап, ни әйтергә дә белмичә*). Ә, эм, ни... юк... болай гына... тегеләй генә...

Габдрахман. Нәрсә болай гына? Нәрсә тегеләй генә? (*Теге кешеләргә.*) Нәрсә, сез ул нәрсәләрне ни эшләтәсез? Аларны кайда алып барасыз?

Итче. Менә Әхмәтнең бирәчәге бар иде дә, без азрак акча сорарга килдек.

Габдрахман. Ә ул нәрсәләрне ник алдыгыз?

Күмерче. Акча бирмәгәч ник алмаска!

Сучы. Кеше алгач ярар әле дип, менә моны мин дә алдым. (*Лампаны күрсәтә.*)

Кибетче. Ие, ие, алар алгач, ие, мин дә...

Габдрахман (*итчегә*). Ә сез?

Итче. Кеше алгач, мин дә инде өлешсез калмам.

Габдрахман. Әхмәт, бу ни эш бу?

Әхмәт эндәшми.

Габдрахман (*кесәсеннән бумажнигын алып*). Кайда, кемгә күпме?

| | | |
|---|---|---|
| Сучы | (*һәммәсе бергә*). | Биш мичкә. |
| Күмерче | | Ике кап. |
| Итче | | Пот та унҗиде. |
| Кибетче | | Күмәч, икмәк, он, тоз, чәй, шикәр. |
| Утынчы | | Ике сажин. |

Габдрахман. Туктагыз! Ул кадәр бердән кычкырмагыз. Сумасын әйтегез. (*Сучыга.*) Йә, сиңа күпме?

Сучы. Биш мичкә.

Габдрахман. Мин сиңа күпме, дим?

Сучы. Әйтәм бит, биш мичкә.

Габдрахман (*ачуланып*). Беләм, барысы күпме?

Сучы. Биш мичкә.

Габдрахман. Тфү! Ничә тиен?

Сучы. Ә, эм, бер тәңкә.

Габдрахман. Шулай диген, мә, ал! (*Егерме бишлек кәгазь акча бирә.*)

Сучы (*акчаны әйләндергәләп*). Бай... бу күпмелек соң?

Габдрахман. Күпмелек булсын, егерме бишлек.

Сучы. Әй, юк, аңар юк. Мин атымны да 18 гә генә алдым, анда да сигез тәңкәсе бакыр иде.

Габдрахман. Кайда, кайсыгызда бар?

Һәммәсе портмонеларын актаралар.

К ү м е р ч е. Миндә юк.

К и б е т ч е. Миндә дә юк.

И т ч е. Мәгез, рәхим итегез!

Г а б д р а х м а н (*итчегә*). Сиңа күпме? Мә! (*Кибетчегә.*) Сиңа күпме? Мә! (*Һәммәсенә бирә.*)

С у ч ы (*лампаны алып чыга башлап*). Ярый, рәхмәт!

Г а б д р а х м а н. Ул лампаны кая алып барасың?

С у ч ы. Тфү, тфү, оятлы булырмын икән! Мин инде аны үземнеке булды дип белгән идем, хатын, күргәч, шатланыр дигән идем. (*Чыга.*)

К ү м е р ч е. Бик һәйбәт шыңгырдап торган өч кап нарат күмере бар. Яратсаң, алып кал. Бик шәп күмер. (*Чыга.*)

К и б е т ч е. Күмәч, икмәкне читтән алма. (*Чыга.*)

Ә х м ә т. Ах, ник өйләндем, нигә дип өйләндем?

П ә р д ә.

# Кушымта

*(Вариантлар һәм тәрҗемә)*

## БӘХЕТСЕЗ ЕГЕТ

### Драм

*Алты пәрдә илә тәэлиф иделмешдер*

МӘҖЛЕС ИЯЛӘРЕ:

| | Яшьләре |
|---|---|
| Кәрим әфәнде – кара сакаллы, тулы гына йөзле купис | 52 |
| Җәмилә ханым – ак, түгәрәк йөзле; Кәрим әфәнденең зәүҗәсе | 48 |
| Закир – кара мыеклы, урта буйлы; Кәрим әфәнденең угълы | 24 |
| Камилә – Кәрим әфәнделәрнең асравы | 15 |
| Мансур – Кәрим әфәнденең агасы, чал сакаллы, ачык йөзле | 59 |
| Сәгыйть әфәнде – Өфедә бер бай купис, кызыл сакаллы | 45 |
| Мәрьям ханым – матур гына, кара кашлы, Сәгыйть әфәнденең зәүҗәсе | 42 |
| Гайшә – Сәгыйть әфәнденең сеңлесе, тол хатын, ирдән калган | 37 |
| Әхмәт – Сәгыйть әфәнденең угълы | 18 |
| Гали – Кәрим әфәнденең белеше, бер сәүдәгәр, сары сакаллы | 43 |
| Камали – Закирнең белеше, жулик, шадра йөзле, зәңгәр күзле | 35 |
| Гайни – Закирнең мәхбүбәсе, кара кашлы, уртача буйлы | 22 |
| Мәрфуга – Мансур аганың зәүҗәсе | 55 |

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Пәрдә ачылыр

Кәрим әфәнденең йорты. Өйнең залында уң тарафта бер яхшы диван (кәнәфи). Диванның алдында зур өстәл. Өстәл өстендә чынаяк һәм башка чәй әсбаплары. Сул тарафта бер конторный өстәл, аның өстендә шарлы лампа, кара савытлары, берничә дәфтәр, берничә китап һәм гәзитләр. Конторка янында берничә стул (урындык); стулларның аргы башында, ишеккә таба тарафта, бер бүлмә ишеге һәм ишек төбендә бер шкаф; анда әнвагъ төрле йорт әсбаплары. Конторка алдындагы бер стулда, конторкага таянып, Җәмилә ханым утыра.

Җәмилә (*үз-үзенә сөйләп әйтә*). И Ходаем! Ата-анасына изгелеге тияр дип, өмид итеп баланы үстер инде! Ике көннән бирле кайтканы юк! Белмим, кайда йөри

---

Зәүҗәсе – хатыны.
Мәхбүбәсе – сөйгәне.
Әнвагъ – төрле-төрле.

торгандыр? Моннан элек тә, бер мәртәбә шулай җугалып, әллә нинди фахишәләр янында йөреп, өч көндә ике йөз тәңкә бетереп кайткан иде. Бар, ул баладан өмид ит инде. Анда нинди хәер булсын инде. Андай баланың булганыннан булмаганы мең өлеш артык; атасы монда карт башы белән дөнья көтеп йөри. Ә аның исенә дә кереп чыкмый торгандыр әле. Атасы аның өчен никадәр акчалар сарыф кылып укытты. Кара, ул, аның кадерен белмичә, ниләр эшләп йөри. Соңыннан исенә төшәр төшүен, әмма ул чагында кайгыртуның файдасы булмас. Соңыннан үзең дә белерсең белүен, әмма эш узар. Үзең теләсәң нишлә идең шунда, кешене монда, кеше арасында бәднам ясыйсың. Атасының никадәр ачуы килсә дә, һаман, кызганып, аны табып булмас микән дип чыгып киткән иде, нишли торгандыр. И, куйсана! Ул соң атасы күрерлек йирдә булырмы? Бер әллә нинди эштән чыккан йирдә ята торгандыр. Уһ Алла!.. Ни хәлләр булыр икән инде? Минем өчен дә, атасы өчен дә бер хәсрәткә туган нәрсә инде! Менә инде шундай баланы тугдыр һәм үстер дә, аннан изгелек тә көт, уһ Алла!.. Моның өчен йөрәкләрем парә-парә булып бетте, һич булмаса атасы да табып кайтса ярар иде. И Илаһым, күр хәлемне! Бераз мәрхәмәт әйлә. Йа Алла! Аңар да үзең инсаф бир!

Конторкага башын куеп, егълап утырганда, кыңгырау шалтырар.

(*Бүлмә янына барып, ишеген ачып, әйтә.*) Камилә! Бар, ишектә кеше бар, чыгып ач.

Бүлмәдән Камилә чыгып ишекне ача. Кәрим әфәнде кайтып керә. Камилә өстеннән киемен салдырып ала, Җәмилә самавыр китерергә куша. Камилә самавырны китерә. Кәрим әфәнде – диванга, Җәмилә стулга чәй эчәргә утыралар.

Җәмилә. Закирне тапмадыгызмы? Яки берәр хәбәр ишетмәдеңезме? Мин баядан бирле үземнең кайда утырганымны да белмәдем. Бу бик зур хәсрәт булды: уйлыйуйлый әллә нинди фикерләргә киттем. Бераз егълап та алдым. Бала булгач, начар булса да кызганыла икән. Ахыры ни булып калыр инде. Мондый эшләр нәселебездә дә һич булган нәрсә түгел иде, бик гаҗәп инде. Аллаһы Тәгалә инсаф бирмәсә, кеше әйтү белән генә булмый икән, һич үгет тә тәэсир итмәде.

Кәрим. Аның өчен кайгырып һич файда юк. Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән кермәс, аңар биргән үгетне бер эткә бирсәң, ул да бераз әдәпләнер иде. Бу

---

Бәднам – яманатлы.

инде бөтенләй, иясен талаган эттән дә начаррак, үзенә калса инде ул бик килешә дип белә торгандыр. Яхшы эш булса, аны шәригатьтә дә мәнгы кылынмас иде. Аны шул, кешене эштән чыгара торган нәрсә булганга күрә дә мәнгы кылынган. Андай эш белән эштән чыккан никадәр кешеләр бар? Шул юлда йөреп бар дәүләтләреннән аерылып, ахырында адәм мәсхәрәсе булып, хәтта ахырында гомер буенча сәдакага йөреп үлгән кешенең очыкырые юк. Андай эшкә керешкән кеше кеше була алмый инде ул.

Җ ә м и л ә. Ансы шулай шулаен да, алай булса да, бала булгач, кызганыла икән. Соң сез аның тугърысында бер хәбәр дә ишетмәдеңезмени?

К ә р и м. Габдрахман күреп калган, үзенең йөри торган нәрсәсе булса кирәк, бер бәдбәхет, эштән чыккан фахишә берлән извозчикка бүген иртә белән сәгать уннарда утырып вакзалга таба киткәннәр. Шул этен озаткач кайтмас микән инде? Ул нәрсәсе бер-бер йиргә китә торгандыр. Аның киткәнен күреп калаем дип, эварә булып йөри торгандыр.

Җ ә м и л ә (*башын селкеп*). Һәр ни булса булсын! Аллаһы Тәгалә хәерен насыйб итсен! Бу нәрсә тәмам йөрәгемә яра салып бетерде инде! Хәер! Безнең үземездә дә бераз гаеп бар. Инде аның яше 24 кә йиткән. Безгә тиеш иде бер яхшы гына йирдән кыз алып бирергә; хатынына мәхәббәте булса, бәлки, андай эшләргә катышмас иде. Ата-анага да тиеш әүвәле баланың тәрбиясен җиткезергә, аннан соң изгелек өмид итәргә. Ахрысы, бит атаның балада ничә хакы булган шикелле, баланың да атада өч хакы бар. Әүвәле яхшы исем куймак, аннан соң гыйлем үгрәтмәк, аннан соң нәселе яхшы җирдән өйләндермәк. Дөрест, без икесен кылдык кылуын да, әмма өченчесен эшләмәдек.

К ә р и м. Хәер инде, ансы бар. Атта гаеп булган шикелле, тәртәдә дә гаеп бар. Әмма инде хәзер эш узды: үлгәннән соң тәүбә юк, дигәннәр. Хәзер аңар яхшы йирдән ничек ышанып кыз бирсеннәр? Начар йирдән алсаң, һаман шул начарлыгында булыр, рәткә кермәс. Бәлки, хатыны начар тугъры килсә, җүри үч итеп әүвәлгедән дә арттырыр. Хәер инде, өйләндермичә торып булмас, өйләндерергә тиеш, башы исән булып кайтсын гына, аны орып-сугып булмый, уйлап караса, үзе дә белерлек.

Җ ә м и л ә. Хәзер аның акчасы беткәндер инде, кайтмыйча әллә ни эшли алмас.

---

М ә н г ы  к ы л ы н м а с – тыелмас.
Э в а р ә – мавыгып, алданып. – *Г.Камал искәр.*

Кыңгырау шалтырар.

К а м и л ә (*чыгып ишек ача да кереп әйтә*). Абыстай! Мансур абзый килгән, керсенме?

Җ ә м и л ә. Бар, әйт, керсен! Керсен! Монда ят кеше юк.

Камилә чыгып әйтә, М а н с у р әфәнде килеп керә.

М а н с у р. Әссәламегаләйкем! Сәламәтләрмесез?

К ә р и м. Вәгаләйкемәссәлам! Әйдә, абый, рәхим итегез! Бик яхшы килдеңез, Закир өчен дә бик эчебез пошып торадыр иде, бик яхшы булды. Әйдәгез, диванга утырыңыз.

Мансур әфәнде – диванга, Кәрим әфәнде белән Җәмилә ханым стулга утыралар.

К ә р и м. Бу Закирнең югалуы бик зур борчу булып китте. Бүген вокзалга таба киткәннәрен күреп калганнар икән күрүен дә, әмма аннан соң нишләп йөри торгандыр, бер дә белгән кеше юк.

М а н с у р. Әле сез белгәнегез юкмыни? Мин сезне белә торганнардыр дип торадыр идем һәм инде ни фикердә торалар икән, белим дип килгән идем.

К ә р и м. Әллә сез берәр хәбәр ишеткән идеңезме?

М а н с у р. Бая сез миңа әйткәннән соң ук, Ситдыйк миңа килеп әйтте: Кәрим әфәнденең угълы Закир бер нәрсә белән Өфегә кадәр билет алып утырып киттеләр, диде. Ул анда кеше озата барган икән, шунда күргән. Мин аңар әйткән идем сезгә килеп әйтергә, әйтмәдемени?

К ә р и м. Юк. Монда бер кеше дә килгәне юк.

М а н с у р. Мин соң аңар килеп әйтергә кушкан идем. Ул нишләп килеп әйтмәгән икән, инсафсыз нәрсә?

К ә р и м. Йә инде, киткән булгач, аның килеп әйтүендә ни файда? Барыбер аны кире кайтарып булмый. Аның соң акчасы да юктыр ич, ничек китте икән?

Җ ә м и л ә. И!.. Этлеккә калгач, таба алмас дип беләсеңмени?! Әллә кайлардан тапкандыр әле!

К ә р и м. Абый! Моны ни эшләтергә кирәк икән инде? Ул анда эшкә керә алмас, аны монда ничек тә булса кайтарырга кирәк, анда калдырырга ярамый. Юк исә ул анда тәмам эштән чыгып бетәр. Ни эшләтик икән инде?

М а н с у р. Синең соң Өфедәге Сәгыйть Сабитов белешең түгелме? Шуңар тилиграм бирергә кирәк. Ул аны күрер дә яхшылык белән генә кайтырга кушар, яхшылык белән кайтмаса, этап белән дә кайтартмый булмас, анда ул тәмам әрәм булып бетәр. Шуннан яхшысы юк. Сабитовка тилиграм бир дә, ул аны йибәрер.

Кәрим. Раст... Шулай кирәк. Минем инде зиһенем таралып бетте, бернәрсә дә исәпли алмыйм.

Җәмилә. Соң, үзегез Өфегә барсаңыз ничек булыр икән? Сабитов бай кеше, ул аның артыннан йөрисе килмәс бит.

Кәрим. Ник йөрмәсен, дустлыкны шушындай эш вакытында да күрсәтмәсә, кайчан күрсәтер, аш ашаганда гына һәркем дә дуст була. Ул дуст булса, шушындый вакытта эш күрсәтсен. Аның артыннан үзенең йөрүе дә һич шарт түгел. Кибетчеләрен йибәрер дә эзләтер, һәм миңа хәзер анда барып йөрергә дә ярамый. Әүвәле никадәр расхут чыга, аннан соң монда никадәр эштән калырга кирәк. Тилиграм йибәрүдән яхшысы юк. Мин аңар хәзер тилиграм языйм. (*Конторка янына барып утырып, тилиграм язарга тотына.*)

Мансур. Хуш, сәламәт булыңыз, мин кайтыйм. Аллаһы Тәгалә шатлык насыйб әйләсен.

Кәрим. Абый! Туктаңыз, мин дә хәзер тилиграм язып бетерәм дә базарга чыгам, бергә чыгармыз.

Ул арада кыңгырау шалтырар. Җәмилә Камиләгә куша.

Камилә (*чыгып ишек ача да кереп әйтә*). Абзый! Сезне Гали абзый чакыра, монда чыгып керсен әле, ди.

Кәрим. Бар, әйт, монда керсен.

Җәмилә чыгып китә. Камилә чыгып әйтә дә, Гали әфәнде килеп керә.

Гали. Әссәламегаләйкем!

Кәрим. } Вәгаләйкемәссәлам, әйдәңез, хуш киләсез,
Мансур. } әйдәңез, диванга утырыңыз.

Кәрим – диванга, Мансур стулга утыралар да дога кылалар.

Кәрим. Гали! Сәламәт йөрисезме, ни хәлеңез бар, сату итәсезме?

Гали. Әлхәмделиллаһ, бертөрле иткәләп ятамыз. Мин сезгә бер йомыш белән генә килгән идем, сез угълыңыз Закиргә миннән акча барып алырга үзеңез кушкан идеңезме?

Кәрим. Юк. Ник? Әллә сездән акча алдымы?

Гали. Көлеп кенә әйтәсезме?

Кәрим. Юк... Аллам сакласын, көлеп әйтмим. Әле ике көннән бирле кайтканы да юк. Хәзер дә Өфегә качып киткән дип ишетәмез. Шуның өчен әле менә

---

Насыйб әйләсен – насыйп итсен.

Сабитовка тилиграм язып торадыр идем, сез килеп керденез.

Гали. Кичэ ул миннэн, сезнен пичэтенез басылган бер язу белэн килеп, өч йөз тэнкэ акча алып китте. Бер, шиклэнеп, бирмэскэ дэ уйлаган идем дэ, сезнен пичэтенез булганга ышанып биреп йибэрдем. Мин анын андай холыклы кеше икэнен һич белмидер идем. Менэ кэгазе. (*Кэгазен өстэлгэ чыгарып сала.*)

Аны Кэрим белэн Мансур карыйлар.

Кэрим. Вакыйган минем пичэт. Моны ни эшлэтергэ кирэк инде? Ах, инсафсыз нэрсэ! Тизрэк Сабитовка тилиграм бирергэ кирэк, акчасын бетермэс борын, тизрэк күрсен. Гали! Сез кайгырмагыз, менэ хэзер тилиграмны язам да бергэ базарга чыгармыз, шунда бирермен.

Тиз-тиз телеграмманы яза да, кэгазен кесэсенэ тыгып, өстенэ киемен кия дэ, өчэүлэп чыгалар. Артларыннан Камилэ ишек биклэргэ чыга.

Пэрдэ төшэ.

## ИКЕНЧЕ ПЭРДЭ

### Пэрдэ ачылыр

Сэгыйть Сабитовнын йортында гостинный зал, бик мөзэйян һэм йорт эсбаблары мөкэммэл. Сабитовнын зэүҗэсе Мэрьям, Сабитовнын сенлесе Гайшэ бер хикаять китабы укып утыра, һэм Сабитовнын угълы Эхмэт бер өстэл янында язу язып утыра.

Мэрьям. Гайшэ! Бая син кем үлгэн дигэн иден, сүзгэ алданып ишетми калдым?

Гайшэ. Гали абзыйнын хатыны үлгэн ич.

Мэрьям. Ай Алла... Эле беркөн генэ Мэстүрэ абыстайларда ашта, Касыйм абзый хатыны Маһруйнын һаваланып йөрүеннэн көлеп, безнен ирлэребез кеше шикелле киендерэ дэ белмилэр, тик череп ятабыз шунда, һэм бу ел эле бер мэртэбэ театрга да алып барганы юк, дип утырган иде. Бичара, бик яшь иде, без эле аннан ничэ яшь олуг булсак та, дөньяга алданып йөрибез. Үлем исебезгэ дэ кереп чыкмый. Эй үлем! Бик гаҗэп нэрсэ инде, бер дэ сорап килми һэм күзгэ күренми. Һич уйламаганда ала да китэ. Озак авырды микэн?

---

Вакыйган – чыннан да.
Мөзэйян – бизэлгэн.
Мөкэммэл – бик җитеш.

Г а й ш ә. Өч кенә көн авырган.

М ә р ь я м. Алла йирен җәннәт кыйлсын. Нинди авыру иде икән?

Г а й ш ә. Бер дә сорашмадым.

Ә х м ә т. Әни! Театрга да алып барганы юк дип кемне сөйләдеңез? Безнең әти дә, ахры, онытты бугай, бер айдан бирле алып барганы юк.

М ә р ь я м. И, җүләр нәрсә, тагын театрга баруны сөйләп торасың. Бигрәк кабергә баруны сөйләргә кирәк. Әнә анда Галиулла абзыйның хатыны үлгән әле.

Ә х м ә т. Аллаһ Тәгалә йирен җәннәт итсен, кайчан үлгән?

М ә р ь я м. Кичә.

Ә х м ә т. Дөньяда чагында бернәрсә дә исәпләмичә йөрибез дә, әмма ахирәткә баргач ниләр булыр? Минем театрга бару дигән сүзем дә гаеп түгел, анда никадәр гыйбрәтләр бар: начар юлда йөргән кешеләр ниндәй эшләргә очраганын һәм дөньяда ниндәй хурлыкларга төшкәннәрен күз алдында күрсәтәләр. Кешеләр гыйбрәт күзе белән карасалар, ихлас күңелләре берлән тыңласалар, андай начарлыктан сакланырлар, дөньяда шундай начарлыклардан саклансалар, ахирәттә бәхетле булырлар һәм зур дәрәҗәләргә ирешерләр. Шуннан артык үлемне искә төшерү ничек булсын инде тагы. Әллә аны, үлемне искә төшерү, үлемнән курку дигәч тә, мич артына кереп качу дип беләсезме? Үлем өчен азык хәзерләү дигән сүз ул! Үлем өчен азык хәзерләү начар эшләрдән саклану, яхшы эшләрне эшләү берлән була. Инде театрга барсаң, начар эшләр эшләгән кешеләр ничек булганын күз алдына китереп күрсәтәләр. Бу гыйбрәт түгелме? Һәм үлемне искә төшерү түгелме? Гыйбрәт күзең белән карасаң, анда шактый гыйбрәтләр бар. Ул теге, үзләре театрның төсен дә күрмәгән кешеләрнең «Акчаларын кая куярга белмичә, театрларга барып, уен-көлкегә сарыф кылып бетерәләр. Ахирәттә ни җавап бирерләр икән» дигән сүзләренә колак салырга ярамый, мин әле театрга ничә мәртәбә бардым! Бер дә уен-көлкене күргәнем юк. Һәм һич көлеп тә кайтканым юк, барган саен һәрбер төрле гыйбрәтле эшләр күреп, үзең шундый булсаң, ни эшләрсең дип, күңелләрем тулып егълап кайтам, һәм анда биргән акчаларымыз да йилгә китми, анда җыелган акча белән фәкыйрьләрне, мәктәп вә мәдрәсәләрне тәрбия кылалар. Дөрест, менә ат кәмитләренә баруны бик мактап булмый, анда биргән акча йилгә (бушка) китә дисәң дә ярый, чөнки анда көлкедән башка вәгазьләнерлек һич гыйбрәт булмый!

Мәрьям. Юк, мин тегеләй генә әйтәм. Гыйбрәт күзең белән карасаң, кайчан гыйбрәт булмасын, һәм һәркем ниятеннән таба, үз ниятең яхшы булса, гыйбрәтләнерлек һәм үлемне искә төшерерлек нәрсәләр бар инде барын...

Ул арада кыңгырау шалтырар.

Бар, Әхмәт, син генә чыгып ачсана, Мәфтүхәнең эше бардыр.

Әхмәт чыгып ача, Сәгыйть әфәнде килеп керә. Әхмәт өстеннән киемен ала.

Мәрьям. Бар, Әхмәт, Мәфтүхәгә әйт, чәй хәзерләсен...

Сәгыйть. Сез үзеңез эчкән булсаңыз, хәзерләмәсен, мин чәй эчеп кайттым, хәзер бик соңга да калынган. (*Сәгатен карый да.*) У-у!.. Сәгать унбер тулган икән, ятырга бик вакыт, бик күп утырылган.

Мәрьям. Кая барган идеңез соң?

Сәгыйть. Кичә Питрпавылның Гомәр әфәнде килгән иде, шуның нумирына акча алырга барган идем, сөйләшеп утыра торгач, шактый вакыт узып киткән. (*Һәмишә үзе йөри-йөри өстен чишенә һәм кесәсеннән бумажнигын чыгарып, мең ярым тәңкә акчаны санап, тимер шкатулкага салып куя.*)

Ул арада Әхмәт һәм Гайшә дә икенче бүлмәгә чыгып китәләр.

Мәрьям. Алай исә инде чәй хәзерләмибез, без дә яңа гына эчкән идек.

Сәгыйть. Юк, кирәк түгел, бик күп эчелгән.

Мәрьям. Кәрим абзыйның угълын тапмадыңызмы?

Сәгыйть. Юк. Кәрим абзыйдан тилиграм килгәненә бер атна булды инде. Монда килгән булса, бер күренмәсә бер күренер иде. Һәр көнне кибетчеләрне йибәреп, һәрбер нумирларны эзләттердем, һич таба алмыйлар. Ахры, монда килмәгәндер. Дәхи бер көн эзләтергә кирәк тә тилиграм бирергә кирәк, алар бик хәбәр көтеп тора торганнардыр. Ятырга кирәк инде.

Өстләрен чишенеп, утны кысып, бер бүлмәгә кереп китәләр. Алар кереп бераз торганнан соң, залның сул тарафындагы тәрәзә ачыла да, Кәрим әфәнденең угълы Закир берлән бер жулик килеп керәләр дә, анда-монда баргалап йөриләр дә, шкафны ачып, алтын, беләзек, вә алка, вә брошка

---

Һәмишә – һаман.
Дәхи – тагын, янә.

шикелле алтын нәрсәләрне алып һәм өстәл өстендәге шкатулканы алып чыгып китәләр. Тәрәзә ачык кала. Бераздан урамда «Берсе теге якка таба китте! Әнә! Әнә! Икесе дә...» вә ма әшбәһе залик сүзләр ишетелә. Каравылчы шакылдаткан һәм свисток тавышлары ишетелә. Ул арада кыңгырау да еш-еш, бик каты шалтырый. Сәгыйть әфәнде, Мәрьям ханым, Гайшә ханым һәм Әхмәт уянып чыгалар. «Ни бар? Бар, ишекне чыгып ач, әллә пожар бармы?..» дип сөйләшәләр, Мәрьям утны күтәрә. Әхмәт ишек ачарга чыгып китә. Сәгыйть тәрәзәдән карамакчы булып бара.

Тәрәзә ачык. Әллә юк исә кеше кергәнме? Тәрәзә ни эшләп ачык? Нәрсәләрне караңыз!

Мәрьям. Шкаф та ачык! Ай Алла! Монда алтын беләзекләр дә юк.

Әхмәт (*йөгереп керә дә*). Эти! Ишек төбендә политсәйскийләр!.. Өйгә ике кеше кергән икән...

Гайшә. Ай Алла, монда шкатулка да юк.

Сәгыйть. Тукта, чыгып карыйм. (*Өстенә кия башлый.*)

Пәрдә төшә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Пәрдә ачылыр

Бер начар гына нумирда Закир һәм иптәше жулик Камали, өстәл янына берсе стулга, берсе караватка утырганнар.

Закир. Соң син ни эшләп кичә килмәдең? Мин монда төн буенча йоклый алмадым. Кайчан гына килеп тоталар икән дип яттым.

Камали. Кайда ул монда килү! Өйгә дә көчкә генә кайтып йиттем. Чүт-чүт килеп тотмадылар. Арттан ике урамга чикле килделәр. Әле ярый урамда фанарлар юк иде. Караңгыга күрә югалттылар. Анда ничек килмәкче буласың, уйлап кара?

Закир. Әле ярый синең кулыңда бернәрсә дә юк иде. Минем кулда бит шкатулка. Ул ярты потлап бар. Арт урамга кадәр йөгердем. Аннан монда чикле ике чакрым бар, тәмам килә-килә җан тирләрем чыгып бетте!

Камали. Йә, әйдә, аны күп сөйләп файда юк. Әйдә, давай бүләбез, сиңа алка йитәме?

Закир. Ул ни дигән сүз? Тукта, әүвәл шкатулканы ачып карыйбыз, анда ни бардыр.

---

Вә ма әшбәһе залик – шуңар охшаган.

К а м а л и. Син аны ачып эчендәге нәрсәләрен алгансыңдыр әле?

З а к и р. Дуракмы әллә син, миндә аны ачарга ачкыч бармыни?

К а м а л и. Соң моны ничек ачабыз?

З а к и р. Тотабыз да ватабыз.

К а м а л и. Әйдә, давай!

Шкатулканы ватып ачалар да акчаны алалар.

З а к и р. Күпме?

К а м а л и. Нәрсә күпме, мә йөз тәңкәсен, калганы миңа.

З а к и р. Ай-яй, акыллы баш! Китер, саныйбыз.

К а м а л и. Нәрсәсен саныйсың, әнә ал йөз тәңкә, әле сиңа алтын нәрсәләр дә кала, артык бер тиен дә бирмим.

З а к и р. Нинди бирмәү ул! Китер, икебезгә уртак.

Камали. Кит аннан! Ачуны китерсәң, тагын бер тиен дә бирмәм. (*Чыгып китә башлый.*)

З а к и р. Бер дә йибәрмәм. Китер, китер, кайда бармакчы буласың? (*Якасыннан барып тота да борып ега.*)

К а м а л и. Мә алайса, бар, ал барын да, мин палитсәгә барам да явит итәм, син әле монда шулай кеше өенә кереп, акча урлап йөрисеңмени? Жулик! (*Акчасын ыргытып, Закирне төртеп җибәрә дә торып чыгып китә башлый.*)

З а к и р. Камали! Тукта, тукта! Мә, ал!

Камали килә.

Йә, иптәш, биш йөз тәңкәсен бир инде!

К а м а л и. Мә алайса! Бик исең киткән, безнең аның шикеллене күргәнебез бар. Тагын кирәк булырбыз әле, мәгәр ул чагында без булмабыз! (*Акчаны бирә дә ачуланып чыгып китә.*)

З а к и р (*акчасын шкатулка эченә ыргытып ташлый да үзалдына сөйли*). Барсана, җәһәннәмнең аргы ягына кадәр, йитәрлек хурлыкка төшердең инде. Кирәк булырмын әле дигән була тагын, монда бик кирәклегең бар иде. Ай, бу шкатулканы кеше-кара керсә күрмәсен. (*Карават астына тыгып, чемоданы белән каплап куя да стулга килеп утыра. Анда бераз фикердә торганнан соң, янә үзенә сөйли башлый*). Уһ Алла!.. Үзең дә бик яхшы түгел, беләсеңме, нинди эшләр эшләдең? Әүвәле атаңның

никадәр акчасын бетердең, аннан Гали абзыйның өч йөз тәңкә акчасын алып качып китеп, аны да бетердең, аннан соң нинди жуликларга катышып, атаңның беренче дустының өенә кереп, никадәр нәрсә, никадәр акчасына зыян китердең, аның да үзеңә бары биш йөз тәңкәсе генә эләкте. Уһ Алла! Инде бу эшләр соңында ышан, рәткә керә алмассың! Һәм ата-анаңны да никадәр хәсрәтләргә төшердең, беләсеңме? Алар синең өчен ниндәй кайгыра торганнардыр? Бераз гына уйларга кирәк иде, бу эш синең шикелле кешегә һич килешә торган эш түгел. (*Егълый башлый. Бераз егълаганнан соң, янә сөйләргә тотына.*) Синең бу хурлыкларга төшүеңә сәбәп нәрсә, беләсеңме? Синең болай булуыңа сәбәп – бер фахишәнең сүзенә ышанып йөрүең. Ул инде сиңа никадәргә төшкәндер, өченче ел өч йөз тәңкәләп бетердең, узган ел мең тәңкәләп бетергәнсеңдер. Бу ел дәхи никадәр! Ул акчалар кем кесәсеннән чыккан? Бары да атаңныкы. Син үзең атаңа изгелек китерер чагында, атаңа зыян китереп йөрисең. Болай йөреп ничек эшкә кермәкче буласың, җә? Бераз уйларга кирәк иде! Ни эшкә кирәк сиңа монда өстерәлеп йөрергә? Кайтудан яхшысы юк. (*Күп заман уйга калып утыргандин соң, исәпкә килә*). Тукта, әүвәл теге нәрсәгә барырга кирәк, ни эшләр икән? Бу эшләреңә сәбәп булган нәрсә – шул эт, йөзе кара. Әүвәлге алдалавы гына җитмәгән, сиңа барам, минем этиләр Өфедә, анда баргач никах укытырмыз дигән булып алдалап алып килде. Аның сүзенә ышанып килгән мин дә шул дурак! Кайда монда аталары, кайда тагы миңа бару, бары алдалап кына йөри, дуңгыз. Үзенең монда белешләренең исәбе дә һәм хисабы да юк, бу йөзе караны атып үтермәсәң, һич котыла алмассың. Ул эт, дуңгызны үтерүдән башка яхшысы юк. Барыйм әле, менә хәзер, фәлән генә, төгән генә дип алдаларга тотынмас микән, кирәген бирермен, миннән калганнарга гыйбрәт булсын, башым бетсә бетәр. (*Сумкасын ачып, револьверын алып кора да кесәсенә тыгып, өстенә киемен киеп бераз фикер кылып тора.*)

Атып үтерүдән яхшысы юк, әлбәттә, атып үтерәм, ачуымны гына китерсен. (*Чыгып китә.*)

Пәрдә төшә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Пәрдә ачылыр

Уртачарак ике бүлмәле бер өй, өстәл янында, көзге каршысында Закирнең мәгъшукасы Г а й н и бизәнеп тора.

Г а й н и (*көзгегә карый да үз-үзенә әйтә*). Ии-һә-һә-һи! Бик чибәр бит, ии-һә-һә-һә-һи! (*Үз-үзенә әйтә.*) Ни тагын көлеп яткан буласың, кем өчен болай чибәрләнәм дип беләсең? Менә килеп җитәр әле Закирең. Бу кадәр конарсыз нәрсә булыр икән. Күземә чуаш төсле күренә башлады менә, билләһи!.. Котылырмын дип монда килсәм, арба артына таккан дегет лагуны шикелле һаман артымнан һич калмыйча ияреп йөри. Тәмам теңкәмне кортып бетерде инде; казан төбе шикелле каралып, борыннарын, кашларын җыера да килә дә керә, килә дә керә, чисти туеп беттем инде, бер кабар җирем дә калмады. Тагын бер мәртәбә килмәс микән, типкәләп чыгарырмын, бар икән бер гарьсез нәрсә, һич сүккәнне дә белми.

Ишек шалтырар.

Һи, йөзе кара, шул нәрсә килгәндер әле, башы да бетмәде, ичмаса, котылыр идем. (*Ишекне барып ача.*)

З а к и р керә.

Г а й н и. И, бу мәхәббәтсез икән әле, котыласым булмады тамани синнән дә.

З а к и р. Ник мәхәббәтсез дисең? Минем сиңа ни зыяным тигәне бар?

Г а й н и. Ник әйтмим, иртүк кеше тормас борын да син килеп керәсең, кеше яткач та син йөрисең; котыла алмам микән дип монда килдем, анда һаман артымнан ияреп йөрисең. Моннан ары монда керәсе булма! Бер тиенлек тә кирәгең юк!

З а к и р. А! Ярый, яңа белешләр хәзерләгән икәнсең! Минем дә сиңа бик исем китми, синең дә миңа кирәклегең юк инде.

Г а й н и. Кирәклегем булмаса да, мин синең артыңнан ияреп йөргәнем юк әле. Син минем артымнан дегет лагуны шикелле тагылып йөрисең.

З а к и р. Әле минем иярүемнән көлеп йөрисеңмени? Әй бәдбәхет! Йөзең кара! Үзең бит, падлис, Өфедә минем этиләр бар, анда баргач сиңа барырмын, шунда никах укытырмыз дип әйтүче. Әле хәзер мыскыл итеп ятасың...

Г а й н и. Сиңа соң эт барсынмыни, синең шикелле күмерче чирмешләр монда бетмәгән, мин сиңа барганчы бер күмерче чирмешкә барырмын.

Ишек шалтырар. Гайни чыгып китә.

З а к и р (*үз-үзенә әйтә*). Күрәсеңме бу ана дуңгызны? Ниләр сөйләп яткан була? Менә ышанып кил инде аның сүзенә! Әллә кем булган булып, күкрәкләрен киереп сөйләшкән булып ята бит, и хур! Косарсың килешеннән. Миннән котыла алмассың, мин бүген сине җәһәннәмгә җибәрмичә китмәм, синең башыңа җитәргә күп кирәк түгел, менә шушы гына. (*Кесәсеннән револьверын чыгара башлый да, яңадан тыгып куеп, янә сөйли.*) Әле анда ишек төбенә бер-бер сөйгәне килгәндер, минем башыма йитмәкче булган шикелле, аның да башына йитмәкче була торгандыр. Син безнең башка йиткәнче, Алла боерса, без синең башыңа йитәрмез, аннан соң синең мәкереңнән һәркем имин булыр. Күрәсеңме?..

Г а й н и керә.

Кем килгән? Яңа белешләреңме?

Г а й н и. Кем булсын, әни. Син барга күрә кермәде. Күршеләргә кереп китте. Бар кеше дә синең шикелле рөхсәтсез кеше өенә басып керми.

З а к и р. Ялганлама! Әни дип ялганлап яткан буласың тагы, килгән анаң, килмичә калмас, бер сөйгәнең килгәндер әле!

Г а й н и. Йә, күп сөйләп торма монда, бар, үкчәңне күтәр, монда эслидең дә булмасын! Кешене хатының дип белдеңмени? Сүгеп яткан буласың, бар, чык моннан, бар! Бар! Бар! Бер минут та торма. Монда теләсә кем килер, анда синең эшең булмасын. Моннан соң монда аягыңны да басма!

З а к и р. Бер дә китмәм, мине куалап чыгара алмассың. Миңа никадәр акчалар тоттырып монда китердең, беләсеңме?

Г а й н и. Тотсаң, минем өчен түгел, үзең өчен. Бар, чык! Чык! Яхшылык белән чыкмасаң, палитсәгә тоттырам да йибәрәм. Ятап белән кайтасың килә торгандыр.

З а к и р. Кычкырма миңа! Кулыңнан килсә, бар, теләсәң ни эшлә, мин синең башыңа йитмичә чыкмам.

Г а й н и. Хәзерләгәннәр иде сиңа баш! Китмисеңме, телеңә салынып торган бул әле, ничек чыгарырга белермен тагы.

З а к и р. Ул сүзләрең белән кемне куркытмакчы буласың? Менә мин чыкканчы син чыгып тор әле. (*Кесәсеннән револьверын чыгарып атып та җибәрә.*)

Гайни егылып үлеп кала. Закир икенче бүлмәгә йөгереп керә дә, тәрәзәне ватып, чыгып кача. Ул арада револьвер тавышын стеналары тоташ күршеләре ишетеп, ишектән җыелып керә.

П ә р д ә т ө ш ә.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Пәрдә ачылыр

Закирнең нумиры. З а к и р кайтып керә. Ап-ак агарган, төсләре киткән, аяклары һәм бөтен гәүдәсе калтырый. Караватка утыра да үз-үзенә сөйләргә тотына.

З а к и р. Уһ Алла!.. Уһ! Уф!.. Бары да гөнаһның шомлыгы!.. Өеңдә генә ятсаң, начар эшләргә катышмасаң, атаң-анаңның әйткән вәгазьләрен тотсаң, мондай бәлаләргә дучар булмаган булыр идең. Шул фахишә артыннан йөреп, мондай бәлаләргә очрадың; дөрес, ул фахишәдән котылдың котылуын да, икенче бәласенә килеп тотылдың. Шул эт өчен үзеңне унбиш ел катрга җибәрсәләр, аннан вулни посилиниегә җибәрсәләр, гомерең буенча хурлыкта йөрерсең; андай хур булып йөрүдән үлгәнең мең өлеш артык. Моннан соң кайда инде сиңа ата-аналарыңны күрү? Кайда тагын башка кардәш-ыругларыңны күрү? Бары да китте. Менә хәзер килеп үзеңне басарлар да тотып алып китәрләр. Әй мескен, гомереңдә бер мәртәбә бер пот нәрсә күтәрмичә үскән кулларыңа, аякларыңа агыр зынҗырлар салып йирләр казыткanda ул хурлыкларга ничек чыдарсың? Миңа булган хәлләрне башка кешеләр белсәләр иде, мондай эшләргә гомерендә бер мәртәбә катышмаслар иде. Ай, шул белмәүчелек харап итә! Шул өч көнлек ләззәткә алданып, бөтен гомереӊ буенча хурлыкка төш инде. Йә, инде нәфесеңнең теләгән нәрсәләрен тәмам урынына китердең. Менә хәзер нәфесең артыннан йөрүнең файдасы күренде, моннан соң, тәмам кыямәт булганчы, кеше өстендә синең исемең булыр. Бу яхшы исемме? Бер дә әйтмәсләр гыйбадәт юлында үлгән дип, дөньяда гына шулай сөйләсәләр, бернәрсә дә түгел иде, ахирәткә баргач, анда сиңа ниләр күрсәтерләр? Бу эштән сиңа коты-

---

К а т р – каторга.
З ы н җ ы р – чылбыр, богау.

лырга һичбер вәҗһе юк инде, йә шул унбиш ел катрны өстеңә йөклисең, йә үзеңне-үзең атып үтерәсең!.. Синең инде монда таба киткәнеңне ничә кеше күреп калгандыр, хәзер килеп тоталар. Үземне-үзем атып үтерүдән яхшысы юк. (*Револьверын алып атмакчы була да янә сөйләргә тотына.*) Ай!.. Җан дигән нәрсә бик кадерле! Бер дә үләсе килми! Үләсе килми килүен дә, тотып алып судит иткәндә, атаңның, анаңның яралы йөрәкләре өстенә яңадан яра салырсың. Юк! Кайчан булса да бер үләрсең, ул кадәр хурлыкларны күргәннең соңында үлүдән хәзер үлүең мең өлеш артык. (*Атмакчы була да янә сөйләргә тотына.*) Юк! Артын исәпләми тиз генә үзеңне һәлак итәргә ярамый. Бәлки, белмәсләр әле, котылырсың. Бераз тәүбә-истигъфар кыйл, килеп тота башласалар, анда да вакыт узмас. (*Револьверын өстәлгә куя да стулга утырып егъларга тотына.*)

Ул арада ишекнең аргы ягында: «Өстенә кара кием кигән, кыскарак кына кара кәзәки кигән, башына каракүл бүрек кигән мыеклы егетнең монда кереп киткәнен күреп калганнар. Ул кайсы нумирдә?» – «Әнә сигезенче нумирдә». – «Хәзер өйдәме?» дигән сүзләр ишетелә.

З а к и р. Ах! Харап булдым, сигезенче дип мине әйтәләр. Килеп тоталар.

Сикереп торып, револьверын ала да ишек төбенә таба бара башлый. Ул арада ишекне тарта башлыйлар.

Эш бетте, актык сулуым икән, әткәй-әнкәй, сез сәламәт булыгыз!.. (*Күкрәгенә ата да егылып үлә.*)

Ул арада револьвер тавышын ишетеп, ишекне ватып пристав һәм башка кешеләр керәләр.

П ә р д ә  т ө ш ә.

## АЛТЫНЧЫ ПӘРДӘ

### Пәрдә ачылыр

Кәрим әфәнденең йорты. К ә р и м  ә ф ә н д е, М а н с у р  ә ф ә н д е, Җ ә м и л ә  х а н ы м һәм М ә р ф у г а  х а н ы м чәй эчеп утыралар.

М а н с у р. Юк, юк, дөньяның һич яхшылыгы калмады, һәммә кеше бертөрлегә әйләнеп бара, дөньяда фәсад

---

В ә җ һ е – юл.
Т ә ү б ә - и с т и г ъ ф а р  к ы й л у – гөнаһлардан тәүбә итү.
Ф ә с а д – бозыклык.

бер сезнең угълыгызда гына түгел, замана бик бозылып бетте. Менә кеше дип торган кешеләрдә дә һич ышаныч калмаган. Үзләренә бер-ике тиен файда китерерлек эш булса, хәзер кырык төрле ялганнар ялганларга тотыналар. Ул инде бертөрле генә кешеләрне сөйләргә дә юк. Бер тиен өчен ант итү дисеңме, кеше хакына керешү кирәкме? Сөйләп бетергесез инде. Ул үзеңә килмәгәнгә генә беленми. Сезнең угълыгыз түгел, аннан артык никадәр эшләр эшләгән кешеләрнең хисабы да юк. Әле менә үземезнең күз тотып торган кешеләребездән дә күбе шундый эшләр белән мөбтәля булып та, инсафка килделәр. Закир дә шулар шикелле инсафка килмәс микән әле? Аллаһы Тәгаләдән инсаф бирсен дип дога кылырга кирәк. Бик хафаланмаска кирәк, хафаланып һич файда итеп булмый.

Кәрим. Шулай инде, һаман кайгырып һич файда юк. Алай да һич хәбәр килмәгәч, әллә нинди эшләргә дучар булмаса ярар иде дип, күңел һаман тәшвиштә тора. Сәгыйть әфәнде дә һич хәбәр йибәрмәде. Инде безнең тилиграм биргәнгә дә тугыз көн булды, һич булмаганда, таба алмаса да бер хәбәр йибәрергә кирәк иде, таба алмаган булсалар, берәр эш карар идек.

Җәмилә. Алар аны күргәннәре юк, бәлки, танымый торганнардыр. Исемен генә белү белән аны таба алмаслар. Ул анда үзен әллә нинди исемдә йөртә торгандыр.

Мансур. Әйе шул, анда бер-бер аны таный торган кеше булса, яхшы булыр иде, бәлки, табар да иде.

Кәрим. Мин үзем анда барсам ничек булыр икән?

Мансур. Үзегез барсаңыз бик мәслихәт булыр иде булуын да шул, эшләреңез кала торгандыр.

Кәрим. Мин аннан бер атнада әйләнеп кайтырмын, бер атна эчендә әллә никадәр эшләр булмас әле, булса тагын, миннән башка да сату итә белерләр әле. Вакыйган, барсам ничек булыр икән?

Җәмилә. Болай күңелләр тынычсызланып торганчы барып кайтсагыз яхшы булыр иде булуын.

Кәрим. Тукта! Аллага тапшырып барырга кирәк, Аллаһ Тәгалә җүн бирер әле. Базарга чыгып керәем дә, кичке пуез белән китәрмен.

Чәй янынnan торалар да, Кәрим әфәнде өстен киенеп чыга башлый. Ул арада кыңгырау шалтырый. Камилә чыгып ишекне ача да телеграммчы килеп керә: «Менә сезгә тилиграм бар!»

---

Мөбтәля булу – дучар булу.

К ә р и м. Китер монда! (*Телеграммага кул куя да телеграммчыга чәйлек бирә. Телеграммчы чыгып китә. Мансур әфәнде, Җәмилә ханым һәм Мәрфуга ханым тыңлап торалар. Кәрим әфәнде телеграмманы кычкырып укый.*) «Угълыңыз монда килгән, үзенең сөйгәнен атып үтергән. Килеп тота башлагач, үзен атып үтергән. Безнең мең ярым акча һәм алтын нәрсәләремез угырланган иде, аны да угырлаучы угълыгыз икән, нумирыннан чыкты. Үзегез тиз килеп җитегез. Сәгыйть Сабитов».

Телеграмманы ишеткәч тә Җәмилә ханым егъларга тотына да ул арада һушы китеп егыла.

К ә р и м.<br>М а н с у р.<br>М ә р ф у г а. } Һай! Харап булды! Нишләдең, духтыр китерергә кирәк!

К ә р и м. Бар, абый, тизрәк духтырга! Һай! Харап булды!

Мансур докторга йөгереп чыгып китә, ул арада Җәмилә ханым бер-ике мәртәбә сулый да җан тәслим итә.

К ә р и м.<br>Мәрфуга. } Һай! Үлде! Бөтенләй тыны да бетте!

П ә р д ә т ө ш ә.

Драм тәмам була.

*

## Ихтар.

Хуш, әфәндем! Укыдың да рәхәтләнеп көлдең, башка берәр нәрсә аңладыңмы? Бер дә көләргә ярамый: Закир ниндәй яхшы кешенең баласы иде. Начар эшләргә кереште дә ахырында үзен һәлак итте. Бер дә андай хурлыкларга төшәсе килмәде. Әмма ни эшләсен? Башы башлангач, котылырга бер дә юл юк. Начарлыкның башы гына башланмасын, аннан соң ул сине ничек хурлыкка төшерергә белер.

Бәгъзе кешеләр бу китапны бигрәк урам телендә чыгарган икән дип көләрләр, бәлкем. Әмма ни зыян? Көлсеннәр. Дәхи дә, шундый бар кеше дә аңларлык урам телендә булган китаплар булучылыгы насыйп булсын. Ярый ла бар кеше дә галим булып җитсә, ул чагында фарсыча һәм гарәпчә чыгарсак та зыян юк.

---

Җ а н т ә с л и м и т ү – җан бирү, үлү.
И х т а р – искәрмә.
Б ә г ъ з е – кайбер.

## ӨЧ БӘДБӘХЕТ

### 1

Уртачарак ике бүлмәле бер өй. Шкаф, өстәл, урындыклар – һәркаюсы тезүле. Бер аяклы киерге янында Сәрбиҗамал исемле бер хатын чигү чигеп утыра. Бераз утырганнан соң, кулына бер төенчек тоткан Мөгълифә исемле бер карчык ишектән килеп керә.

Мөгълифә (*акрын гына әйтә*). Исәнме, кызым! Сәламәт торасыңмы?

Сәрбиҗамал. Аллага шөкер! Үзең сәламәт йөрисеңме? Нихәл, әби, ни йомыш?

Мөгълифә. Бик яхшы гына. Көмеш beләзекләр бар, алкалар да бар, бер хәтфә камзул бар – сәңа кирәк булмасмы?

Сәрбиҗамал. Китер, күреп карыйм. Кайда, ниндәй алкаларың бар?

Мөгълифә. Менә бер яхшы алтын алка бар. Үзе бик яңа. Иясе акча кирәккә генә сата.

Сәрбиҗамал карый.

Сәрбиҗамал. И әби! Бу алкаң Нух заманындук булгандыр, күптән мудадан чыккан нәрсә бу. Кайда, башка бераз чибәррәкләре юкмы?

Мөгълифә. Кара, бу бик чибәр нәрсә ич. Үзе яңа. Әле аны былтыр гына ире бүләккә алып кайткан.

Сәрбиҗамал. И, мондай нәрсәнең бүләклеге ни, ние ни. Бервакытны безнеке дә шундай мудадан чыккан нәрсә алып кайткан иде, бер мәртәбә дә такмадым. Ярты бәясенә саттым. Йөриләр шунда акча әрәм итеп. Һичбер вакытта килешә торган нәрсә алып кайтмыйлар. Ичмаса, үзең чыгып алсаң, нәрсәнең матурын, күңелеңә ошаганын карап аласың.

Мөгълифә. Сөйләмә инде, аларга һич ышаныч юк. Үзләренең нәрсәне танып ала белмәүләре генә йитми, өстәвенә, күңеленә ошаганын чыгып алсын дип, хатыннарына ихтыяр да бирмиләр.

Сәрбиҗамал. Әстәгъфирулла тәүбә! Көферлегем килмәсен, мин соң андай ихтыярыма бирмәгән ирдә то-

раммы? Аларның бар әйткәннәренә колак сала китсәң?! Алар гомереңдә бер мәртәбә урамга да чыгарга кушмаслар, әле алар өйдә торганда да эчем пошып бетә. Бер шул ярминкәләргә киткән чагында гына бераз тынычлап торасың. Теләгән бакчаларыңа барасың. Ул инде өйдә дә торып, теләгән йирләреңә дә йибәрмәгән ирләрдә торуы әҗәлдер. Ирләре өйдә тора торган хатыннарның ничек йөрәкләренә җон үсеп бетми икән?

Мөгълифә. Әле синең ирең Гайнетдинме?

Сәрбиҗамал. Син кайдан беләсең аны?

Мөгълифә. Белми ни! Минем шәһәрдә танымаган кешем юк. Әле ирең кайда соң синең?

Сәрбиҗамал. Ярминкәдә...

Мөгълифә. Әллә башка ярминкәләргә дә йөриме?

Сәрбиҗамал. Аның җүнләп өйдә торганы юк! Берсеннән кайта да икенчесенә китә, ел буена бар җыены ун-унбиш көн өйдә тора торгандыр.

Мөгълифә. Әбәү! Бу яшь башың белән ничек ул ун-унбиш көнгә канәгать кылып торасың? Мин булсам, гомеремдә бер чыдап тора алмас идем.

Сәрбиҗамал. Чыдамыйча ни эшләр идең?

Мөгълифә. Аерылыр идем.

Сәрбиҗамал. Аерылгач, соң ул ун-унбиш көннән дә коры каласың ич. Ярар иде лә аннан яхшырак иргә барсаң, аннан соң ия чыкмаса ни эшләрсең?

Мөгълифә. И, куй, зинһар! Яшь тә булсаң, матур да булсаң, ия чыкмыймы соң? Аны аерылмастан элек үк күңелеңә ошаганын табып куясың. Минем сиңа исем китә бу кадәр матурлыгың, бу кадәр яшьлегең белән чыдап торуыңа.

Сәрбиҗамал. Минем үземнең дә бик уема төшә ул төшүен дә, яхшы кеше тугъры килмәс дип куркам, бер минут та тормас идем.

Мөгълифә. Бик зур нәрсәгә аптырыйсың икән.

Сәрбиҗамал. Аптырамый ни, иреңнән аерылмаган чагыңда, мин сиңа барам дип ничек вәгъдә куясың? Аерылгач тагын тугъры китерә алмасаң?

Мөгълифә. Күңелеңдә булса, аны булдырырга бик асат.

Сәрбиҗамал. Ничек?

Мөгълифә. Бакчаларга чыккалап йөрсәң, бик тиз аны табарга.

Сәрбиҗамал. Бакчаларда шул анда бер дә ышанырлык кешеләр күренми.

Мөгълифә. И! Син аны миңа гына куш, мин хәзер табып бирермен, мин шундай сезнең шикелле гомерләре

бушка уза торган кешеләргә, күп кешегә ия табып бирдем. Үзләре дә хәзер рәхмәт укыйлар, сине дә, Алла боерса, шундый кешегә табып биререм. Үзең дә гомер буенча рәхмәт укудан бушый алмассың. Әле менә минем килүем дә шуның өчен иде, беркөнне үзеңезне синтралный бакчада бер бик яхшы гына бай кеше күреп гашыйк булган. Үзенең хатыны үлгән, һич тынычсызлар кешесе юк, берүзе генә, һәм үзе бик яшь.

Сәрбиҗамал. Кем соң ул?

Мөгълифә. Мәхмүд Хәсәневне белмисеңме син? Олы урамда ике йирдә магазины бар: берсе красный мал магазины, берсе гелтаринный.

Сәрбиҗамал. А! Беләм, беләм! Шулмыни теге яңарак кына сакал чыгып килә [торган] матур гына егет?

Мөгълифә. Шул, шул, бик мәслихәт кеше, аңар барсаң, үзең дә гомер буенча рәхәттә торыр идең.

Сәрбиҗамал. И әби, юк сүз сөйлисең. Ул соң безгә карый торган кешеме, җүри мыскыл итеп кенә әйтә торгандыр.

Мөгълифә. Куй, зинһар! Ни эшләп җүри әйтсен! Аңар ышанмасаң, менә миңа ышан, бу карчык башым белән ялган сөйләп йөрмәм, мин инде аның тәмам җәясен тартып бетердем, чын ихласы белән сөйли, син бары үзеңнең ирең белән генә эшеңне кара, мин үзем барын да булдырам.

Сәрбиҗамал. Анысы да бик читен эш, тик торганда ничек тавыш чыгарырга кирәк?

Мөгълифә. Бигрәк юк нәрсә өчен аптырыйсың, мин булсам иде синең урыныңда, тынын да чыгартмас идем. Син әле уеңны гына (исәбеңне генә) яхшы беркет, аннан соң үзем өйрәтермен.

Сәрбиҗамал. Әле син алай дисең диюен дә, аны бер мәртәбә күрергә кирәк, болай итү белән генә булмый.

Мөгълифә. Кемне? Мәхмүдне дисеңме?

Сәрбиҗамал. Әйе.

Мөгълифә. Әй! Дәртең генә булсын, аны сиңа күрсәтүе бернәрсә дә түгел. Менә иртәгә синтралный бакчага чык, мин аңар да чыгарга кушармын, шунда күрешерсеңез.

Сәрбиҗамал. Бая да әйттең шуны, ул синтралный бакча дигәнең кайсы төш соң ул?

Мөгълифә. Ай Алла, син тагы шуны да белмәскә! Өченче көнне әле барган идең. Аннан элек тә мин сине анда ничә мәртәбә күрдем.

Сәрбиҗамал. А! Шулмыни? Аның ни исемле икәнен белмидер идем. Иртәгә ни вакытта чыгыйм соң анда?

М ө г ъ л и ф ә. Өйләдән соң сәгать өчләрдә чыксаң ярар. Әмма бераз киенебрәк чык, кешенең күңеле төшәрлек булсын.

С ә р б и җ а м а л. Ярар алайса. Син тагы кешегә сөйләшеп йөри күрмә.

М ө г ъ л и ф ә. Алла сакласын! Юк сүзне сөйләшә күрмә, аның шикелле бер-ике генә сүз эчемә сыяр әле.

С ә р б и җ а м а л. Сине бигрәк коры йибәрдем инде, самавыр да куймадым, гаеп итеп китә күрмә.

М ө г ъ л и ф ә. Аның шикелле юк-бар өчен дә гаеп итәргә ярыймы соң? Алла боерса, эш пешсә, берьюлы сыйларсың.

С ә р б и җ а м а л. Инде тырыш кына. Аннан соң, Алла боерса, гомер буенча онытмам.

М ө г ъ л и ф ә. Ярый алайса, мин аңар да әйтермен. Син дә шул сәгать өчләрдә чыгарсың. Хуш! Сау булып тор хәзергә!

С ә р б и җ а м а л. Хуш, сәламәт бул! Ахыры хәерле булсын.

Мөгълифә чыгып китә, Сәрбиҗамал озатып кала.

## 2

Центральный бакчада кешеләр узгалап йөриләр. М ө г ъ л и ф ә белән С ә р б и җ а м а л сөйләшеп утыралар.

С ә р б и җ а м а л. Инде сәгать дүрт булгандыр. Бик озак торды, әллә юк исә килми микән?

М ө г ъ л и ф ә. Килер әле. Кибеткә чыгасым бар дигән иде ул. Кибеттә берәр эш булгандыр.

Ул арада б е р к а р т к е ш е белән б е р я ш ь к е н ә х а т ы н узып китәләр.

С ә р б и җ а м а л. Әле син мине әйтәсең. Менә бу бичара яшь башы белән карт кешедә ничек чыдап тора икән?

М ө г ъ л и ф ә. Чыдамыйча ни эшләсен, әле ярый дәртле кеше икән, карт булса да, күңел ачарга алып чыккан.

С ә р б и җ а м а л. Әнә теге күренә торган шул түгелме соң?

М ө г ъ л и ф ә. Кайда?

С ә р б и җ а м а л (*кулы берлән төртеп күрсәтеп*). Әнә теге юлдан килә.

Мөгълифә, ак яулык чыгарып, борыннарын сөрткән булып, үзләрен күрсәтә.

М ә х м ү д (*кереп, борылып килеп җитә дә яннарына килеп утыра, бераз торып, сөйләшергә тотына*). Исәнме,

әби, мин сезнең хәтерецезне калдыра яздым, бик озак тордым.

Сәрбиҗамал (*көлемсерәп*). Көтеп алган кунак кадерле була ул, бер зыян да юк. Сезне дә көтмәгәч, без кемне көтәрмез! Илтифат итеп килүеңезгә рәхмәт.

Мәхмүд. Кунаклык кунак иясе кабул итсә генә була ул. Үзлегеннән генә килсә, аннан кадерсез кеше дә булмый.

Сәрбиҗамал. Сез чакырылып кына килү түгел, барып алырга лаек кеше сез. Безнең болай сезне кимсетүемез дә бик зур гаеп.

Мәхмүд. Гаеп дисәң, анысы безнең тарафта күбрәк, үземез вәгъдә куйдык та соңга калдык.

Сәрбиҗамал. Анысы бер дә гаеп түгел, әмма кунак булган кешенең чакырган кешесенә генә дустлыгы зур булсын.

Мәхмүд. Кунакка чакырылып та, үзеңнең күңелеңдә дустлык булмаса, аннан да зур гаеп булырмы? Күңелеңдә мәхәббәт булмаса, ул мәҗлескә ничек оялмыйча барырга кирәк!

Сәрбиҗамал. Шул мәхәббәтемез зур булганга күрә дә, илтифатыңызны кабул күреп, мәҗлесеңезгә килдек. Әмма кабул кыйлуыңыз ни рәвешчә булыр.

Мәхмүд. Мең җанымыз белән кабул күрәмез һәм моннан соң да никадәр морадларыңыз булса, барысыны мең җан һәм тәнемез илән кабул итәрмез.

Сәрбиҗамал. Морадларымыз бар иде барын, әмма бер яктан үзеңезнең кабул кыйлмау ихтималы, икенче яктан кунак итүемезгә аркылы төшә торган нәрсәләр булган өчен, тәмам аптырап торам.

Мәхмүд. Бу сүзеңездән морадыңыз кем була? Төшенә алмадым.

Сәрбиҗамал. Кем икәне билгеле инде аның.

Мәхмүд. Бу сүзеңезгә караганда, безнең әбигә әйткән сүзләремне кабул күрмәс күк күренәсез.

Сәрбиҗамал. Мин әле әбинең әйткән сүзләренә тәмам ышанып бетә алмадым, дөрест булса, кайда ул кабул итмәгән!

Мәхмүд. Аркылы төшә торган кешеләр бар дигәнгә күрә генә әйтәм.

Сәрбиҗамал. Сүзеңез дөрест булса, барын да булдырырмыз, безнең якта туктaлу булмас, үзеңез генә туктaлмаңыз.

---

Морад – теләк.

М ә х м ү д. Мин сез кабул итмәссез дип кенә шөбһәдә торадыр идем. Юк исә минем һич сүземнән кайту ихтималым юк.

М ө г ъ л и ф ә. Инде минем өстән эш төште, бер-берегезгә күрештердем, хәзер эш үзеңезгә калды. Бер-берегезнең күңеленә охшарлык булса, эш, шаять, озакка китмәс, аларны миннән башка да күрерсез.

М ә х м ү д. Ул ни дигән сүз, монда синнән башка ничек эш булсын инде, башын башлагач, эшне ничек тә тәмам итәргә тырышыңыз, синнән башка безнең бер эш тә эшләр хәлемез юк.

М ө г ъ л и ф ә. Бәлки, үзеңез генә дә эшне булдырырсыз дип кенә әйтәм. Әгәр кушсаңыз, баш өсте, ни әйтсәңез, шуны кабул күрәм (итәм).

С ә р б и җ а м а л. Бу сездән башка була торган эш түгел. Сез очлап чыгармаганда, безнең кулдан гына килми. (*Сәрбиҗамал сискәнеп китә дә.*) Ах! Харап булдык, Габдерәхим абзый килә... Йөзе кара икән... Әйдә, әби! Тизрәк!

М ө г ъ л и ф ә. Хуш, Мәхмүд, хәзергә!

Китәләр. Мәхмүд утырып кала. Ул арада Габдерәхим әфәнде килеп җитә.

Г а б д е р ә х и м (*узып барганда Мәхмүдкә ачуланып карап*). Хәер, кеше хатыннарына катыша беләсез икән! Мин артыгызга төшәрмен! (*Узып китә.*)

## 3

Гайнетдиннең йорты, С ә р б и җ а м а л өстәл янында кайгырып, түбән таба карап утыра, ул арада ишектән М ө г ъ л и ф ә керә.

С ә р б и җ а м а л (*аяк өстенә торып каршы ала*). Әйдә, әби, хуш киләсең! Тәмам сагындырып бетердең син, килүең-китүең юк, әллә качтымы икән дип торам.

М ө г ъ л и ф ә. Килеп булмады шул, өч көн башымны да күтәрә алмыйча яттым.

С ә р б и җ а м а л. Мин сиңа кичә кеше йибәргән идем, өйдә юк дип кайтты.

М ө г ъ л и ф ә. Кичә бераз күңелләрем ачылсын дип йөрергә чыккан идем, ирең кайттымы әллә?

С ә р б и җ а м а л. Өченчекөн үк кайтты ул.

М ө г ъ л и ф ә. Соң ни эшләшеп торасыз әле? Ул-бу юкмы?

С ә р б и җ а м а л. Ни булсын, кайтканнан бирле йөзенә күтәрелеп караганым юк.

М ө г ъ л и ф ә. Соң бер сүз дә чыгарганың да юкмы әле?

Сәрбиҗамал. Сез дә бер мәртәбә дә килмәдеңез. Ничек итеп башларга да белгәнем юк әле.

Ул арада Гайнетдин кайтып керә, йөзләре кызарган, ачуы кабарган, ишектән килеп керә дә, бер сүз эндәшмичә, өстен чишенә.

Гайнетдин (*Мөгълифәгә таба карап*). Бу кемең?

Сәрбиҗамал. Мөгълифә әби.

Гайнетдин. Нинди әбиең ул? Ни эшкә килгән? Кем рөхсәте берлә монда кергән?

Сәрбиҗамал. Асламчы, нәрсәләр сатарга кергән.

Гайнетдин. Синтралный бакчадагы белешең түгелме? Һи, дөнья корткычлар! (*Аягын тибеп кычкыра.*) Бар! Тиз чык моннан! Йөзең кара булган нәрсә, карт шайтан. Кеше өенә хуҗа булып йө...рер...гә, кеше котыртып... җәһәннәмлек нәрсә.

Мөгълифә, куркып, тиз генә чыгып китә.

Сәрбиҗамал. Бер дә гөнаһсыз йиргә кеше рәнҗетә...

Гайнетдин. Кычкырма миңа! Беләм мин сезнең кем икәнеңезне! Бар! Тиз алып кил агаларыңны.

Сәрбиҗамал (*акрын гына*). Ни эшкә алар?

Гайнетдин. Ни эшкә икәнен килгәч күрерсең, бар тизрәк! Бар! Бар! Бар! Күп мыгырдап торма, йөзең кара, бәдбәхет, эт нәрсә, ир кирәк булган икән. Һи, тәмуг кисәве...

Ул арада ишекне ачып ике кеше килеп керәләр.

Гайнетдин. Әйдә, Шаһи абзый. Әйдә, Габдрахман абзый, хуш киләсез!

Габдрахман. Әссәламегаләйкем! Сәламәтләрмесез?

Гайнетдин. Вәгаләйкемәссәлам! Үзеңез сәламәтләрмесез?

Габдрахман, Шаһи, Гайнетдин урындыкларга утыралар да дога кыйлалар.

Гайнетдин. Бар, син нәрсә терәлеп торасың тагы, тиз алып кил!

Сәрбиҗамал чыгып китә.

Габдрахман. Ни эшләдегез сез? Ачуланасың.

Гайнетдин. Йөрәгеңә төшкәч, ачуланырсың, ирләре өйдә тормагач, хуҗа кирәк була башлаган. Инде үзләре теләгән кешеләргә барсыннар. Җәһәннәмнең аргы ягына кадәр китсеннәр, хатынны кеше берлән уртаклыкка алмыйлар...

Ул арада ишектән хәзрәт килеп керә. Аяк өстенә торалар.

Хәзрәт. Әссәламегаләйкем!

Өчесе дә. Вәгаләйкемәссәлам! Әйдәгез, хәзрәт!

Хәзрәт урындыкка утыра, дога кыйлалар да, ул арада Сәрбиҗамалның агалары килеп керәләр.

Гайнетдин. Хәзрәт, без сезне бик мәшәкатьләп бетердек, әмма ни хәл итәсең, дөнья булгач, төрле хәлләр булгалый.

Хәзрәт. Мин сездән бер дә сәбәпләрен сорашмадым, ник болай эшлисез? Юк-бар нәрсә өчен генә ачу килгән булса, килешергә тиеш иде.

Гайнетдин. Юк, тәкъсир, килешерлек кенә эш түгел. Әле менә Габдрахман абзыйларга да сөйләп торадыр идем. Хатынны кеше [берлән] уртаклык өчен алмыйлар.

Хәзрәт. Һай, бик начар эш икән. Шулай ук ят кешеләр берлән ихтилат* кыйлганмы?

Гайнетдин. Ихтилат кылу түгел, аргы ягына барып чыккан. Бер шунда дәргяһдан сөрелгән Мәхмүд исемле нәрсә белән бакчада сөйләшеп утырганнарын Габдерәхим абзый күргән.

Хәзрәт. Мин сезгә кайчаннан бирле әйтә килдем, үзегездән башка хатыннарыгызны урамнарга, бакчаларга чыгарып йөртмәгез дип, аны тыңламыйсыз, бар да шул үзегездән башка чыгарып йөртүдән, үз ихтыярларына куюдан килгән нәрсә.

Гайнетдин. Үзебез өйдә чагында әле дә йөртмимез йөртүен. Үзебез өйдә булмаганда бик иркенлиләр.

Хәзрәт. Үзегез өйдә булмаганда янына бер ышанычлы карчык калдырып китәргә кирәк, ялгызын гына калдырмаска кирәк.

Гайнетдин. Бу чагында ышанычлы карчыклар табуы да бик читен. Бу эшләрнең дә булуы карчыклардан килгән. Бер йир корткыч карчык шундай эшләр эшләгән.

Ул арада ишектән Сәрбиҗамал белән анасы килеп керәләр дә икенче бүлмәгә чыгып китәләр.

Гайнетдин. Йә, хәзрәт! Дәфтәрегезгә языгыз: мин инде аны бер талак баен белән талак кылдым.

Хәзрәт. Тиешле булган мәһәре бирелгәнме?

---

* Ихтилат – катышу. – *Г.Камал искәр.*

Дәргяһдан сөрелгән – бусагадан куылган; биредә: «каргыш төшкән», «ышанычын югалткан» мәгънәсендә.

Талак баен – дини йола буенча яңадан кушылмаслык итеп хатын аеру.

Г а й н е т д и н. Тәмам бирелгән, тәкъсир!

Х ә з р ә т. Әйт, күпме?

Г а й н е т д и н. Ике йөз тәңкә.

Х ә з р ә т. Кайда соң әле ул, монда күренсен...

Бүлмәдән Сәрбиҗамал чыга.

Х ә з р ә т. Син үзеңә тиешле мәһәреңне тәмам алып бетердеңме?

Сәрбиҗамал эндәшмичә егълап тора.

Х ә з р ә т. Хәзер инде егълауның вакыты узган, хәзер егълау белән генә иреңне ышандыра алмассың, ниятең яхшылыкта булса, әүвәлдә андай эшкә катышмаска кирәк, йә, әйт әйдә, мәһәреңне алып бетергәнме?

С ә р б и җ а м а л *(егълабрак)*. Бетердем.

Х ә з р ә т. Башка дәгъваләреңез юкмы?

С ә р б и җ а м а л. Юк.

Х ә з р ә т. Иреңнең ни әйткәнен ишеттеңме?

С ә р б и җ а м а л. Ишеттем.

Хәзрәт тәмам сорашып дәфтәргә яза да, Габдрахман, Шаһи кул куялар. Гайнетдин бераз сәдака бирә дә, хәзрәт исәнләшеп чыгып китә. Алар чыгып киткәч, Сәрбиҗамалның агалары да, ямщик алып килеп, нәрсәләрен төяп алып, барысы да чыгып китәләр. Алар киткәч, Габдрахман белән Шаһи да исәнләшеп чыгып китәләр.

## 4

Мәхмүднең йорты. Яхшы гына йорт әсбаплары. Һәйбәт бер өй. Өстәл янындагы кәнәфигә утырган М ә х м ү д бер китап карап утыра. Ишектән лакее килеп керә.

Л а к е й. Ишектә Мөгълифә әби бар икән, керсенме?

М ә х м ү д. Әйт, керсен.

Лакей чыгып китә дә, М ө г ъ л и ф ә килеп керә.

М ә х м ү д. Әйдә, әби, хуш киләсең, шатлык хәбәрләр китерә торгансыңдыр, ахры. Йөзләрең бик ачык.

М ө г ъ л и ф ә. Китермәскә ярыймы соң? Без катышкан эш булмый калмый инде ул. Үзеңез сәламәт торасызмы?

М ә х м ү д. Аллага шөкер, беркөе торып торамыз. Әллә эшләр уңайланамы?

М ө г ъ л и ф ә. Безнең эш бетте инде, иреннән аерылды. Хәзер эш сездә генә калды да. Гыйддәт тутырасы бар. Аннан соң мәкъсуд тәмам төгәлләнә.

---

Г ы й д д ә т т у т ы р у – ирсез калган хатыннарның икенче иргә бармый торырга тиешле булган вакыты.

М ә к ъ с у д – омтылыш, теләк.

М ә х м ү д. Кара, алайса, эшләр яхшыланган икән, ничек алай бик тиз асат кына аерылган?

М ө г ъ л и ф ә. Беркөнне безнең бакчада утырганны күргән кеше иренә сөйләгән дә, шуңар ачуы килеп кайткан да аерган.

М ә х м ү д. Бигрәк яхшы булган икән! Менә, әби, алайса, сәңа бераз бездән сөенечкә сәдака. (*Биш тәңкә чыгарып бирә.*) Эшләр булса, боерган булса, сәне хур итмәмез. (*Көлемсерәп әйтә.*) Түлке син аңар безгә чикле бүтән кеше табып бирмә.

М ө г ъ л и ф ә (*көлемсерәп*). Гаҗәп түгел, без кеше табарга өйрәнгән кеше, тагын шулай сәнең күк матур хатын эзли торган кеше чыкса, бик ерак китмәс.

М ә х м ү д. Ә... һә... Алайса, сәнең ният яхшылыкта икән. Табып кына кара, хәзер ул безнеке инде. Мин аннан ары сәне ни эшләтә белермен.

М ө г ъ л и ф ә. Ярый, рәхмәт, безне бик зурладыңыз инде, тынычлык белән торырга насыйб булсын. Әле тик үзеңез көлеп сөйләгәнгә генә әйткән сүзем. Кайтыйм инде. Берәр йомыш төшсә, тагын килермен әле.

М ә х м ү д. Тукта, ул кадәр ашыгып кая барасың? Менә хәзер чәй эчәрмез.

М ө г ъ л и ф ә. Юк, рәхмәт! Барасы йирләрем бик күп, икенче килермен.

М ә х м ү д. Үзем анда барсам, миннән качмас бит инде ул?

М ө г ъ л и ф ә. Хәзер ни эшләп качсын инде?

М ә х м ү д. Бәлки, берәр йомыш төшсә, сез килми торсаңыз, барып та кайтырмын әле.

М ө г ъ л и ф ә. Ярый, хуш, хәзергә сәламәт булып торыңыз, мин кайтыйм.

М ә х м ү д. Хуш, сәламәт булыңыз.

Мөгълифә чыгып китә.

(*Үзалдына шатланып сөйли башлый.*) Ах-ах-ха-ха! Ниндәй үткен карчык, бер әйтү белән эшне булдырды, һе! Акчаң булса бар да була, бел аны. Ул булдырмый, акча булдыра. Ну! Хәзер инде эшләр бетте. Гыйддәте тизрәк тулса ярар иде, аннан ары тәмам эшләр пешәр иде. Хәер, бик ашыгырга ярамый, ашыккан ашка пешкән, сабыр иткән морадына йиткән. Һи, моңар чикле ни карап тордым икән, шул корым карасы берлән гомер уздырдым, әле ярый үлде. Үлмәгән булса, бөтен гомерем бушка узган булыр иде.

Ишектән л а к е й керә.

Л а к е й. Абзый! Гомәр абзый керә.

М ә х м ү д. Ярый.

Ул арада Гомәр әфәнде килеп керә.

Г о м ә р. Әссәламегаләйкем!

М ә х м ү д. Вәгаләйкемәссәлам! Әйдә, абый, хуш киләсез, сәламәт йөрисезме?

Г о м ә р. Вәгаләйкемәссәлам! Үзеңез сәламәт торасызмы?

М ә х м ү д. Бик әлхәмделилла!

Мәхмүд, Гомәр урындыкларга утыралар да дога кыйлалар. Мәхмүд торып китә дә самавыр китерергә куша. Гомәр кесәсеннән бер гәзит чыгарып укырга тотына.

Абый, гәзиттә нинди хәбәрләр язалар?

Г о м ә р. Әле бу гәзитне укыганым юк. Бик гыйбрәтле хәбәрләр язгалыйлар. Бер көнге гәзиттә язганнар иде Япун белән Кытай вакыйгасын. Япунның кул астында кырык милиунлап халык бар. Кытайның кул астында дүрт йөз милиунлап халык бар. Шулай булса да япуннар кытайларны җиңгәннәр. Менә мәгърифәт кешене ни эшләтә!

Болар сөйләшкән арада, лакей самавырны китереп куя һәм чәй эчә башлыйлар.

Әле моннан ун ел электәрәк кенә япунның исеме дә беленгәне юк иде. Ә хәзердә япуннар мәгърифәт тәхсил кыйлып, бөтен Яурупа гыйндендә могтәбәр булдылар, һәрбер йирдә сәүдәгәрләре йөреп тора. Никадәр электрикләр, никадәр тилиграфлар ясадылар. Ул гәзитләренең очы-кырые юк. Безнең мөселманнар да мәгърифәт тәхсил кыйлырга тырышырга кирәк иде. Аннан соң, сатулары уңайланып, баерлар иде.

М ә х м ү д. Сату итсәләр, болай да баерлар әле.

Г о м ә р. Баерлар! Өеңдә генә ятып кырырсың эшне!

М ә х м ү д. Өйдә генә ятмасыннар, чыгып сату итсеннәр, чит шәһәрләргә барып, загранитсәләргә чыгып сату итсеннәр. Аларны кем тыя?

Г о м ә р. Кем тыйсын, наданлык тыя! Моннан нәрсәне алып китеп, чит йиргә алып барып, бер тәңкәгә алган нәрсәне илле тиенгә сатсыннармы?

М ә х м ү д. Ни эшләп алай, файда итеп сатарлар.

Г о м ә р. Сатарлар, сатмый ни! Җәгърафия дә белмәсәң, кайдан нинди нәрсәләр чыкканын белмәсәң, урманга

---

М ә г ъ р и ф ә т т ә х с и л к ы й л у – белем алу.

Г ы й н д е н д ә м о г т ә б ә р б у л у – каршында игътибарлы, ышанычлы булу.

утын ташыган шикелле булса, итәрсең файда. Менә моннан Мәскәүгә яки Лодзага мануфактурный мал алып бар да сат. Файда итә алырсыңмы?

М ә х м ү д. Анда ничек файда итсеннәр? Мәскәү белән Лодзаның үзеннән чыга ул мануфактурный маллар.

Г о м ә р. Менә шул шул, әүвәл кай йирдән нинди нәрсә чыкканын белергә кирәк тә аннан соң барырга кирәк. Аны белергә җәгъърафия кирәк, җәгъърафия – мәгърифәтләрнең бер кисәге. Менә мәгърифәт кирәк икән.

М ә х м ү д. Мин әле бер дә белгәнем юк, җәгъърафия дисеңме? Ул ниндәй гыйлем соң?

Г о м ә р. Их-һа-һа! Җәгъърафия диген яисә география, ул ниндәй гыйлем икәнен мин сәңа әйтием алайса. Ул шундай гыйлем: аның белән дөньяда ниндәй йирләр бар, ниндәй сулар, ниндәй таулар, ниндәй мәмләкәтләр, ниндәй кешеләр бар икәнен һәм кай йирдән ниндәй нәрсәләр чыга һәм кайда ниндәй нәрсәләр эшләнә – шуларны белеп була. Һәм ул гыйлемне өйрәнсәң, җир йәелеп киткән тигез нәрсә дә, һич кырыена барып йиту мөмкин түгел дәюп, үзеңнән кеше көлдермисең, Мәхмүд! Күп сүз озайтып файда юк, андый сүзләрне башка вакытларда сөйләшермез. Хәзер ниндәй фикердә торасың? Өйләнү кирәк булыр күк күренә. Берәр йиргә сүз салып караганың юкмы әле? Болай гомер буенча өйләнмичә тора алмассың. Әйткән йирләрең булмаса, үзем сәңа бик чибәр йирдән кыз сорамакчы булам.

М ә х м ү д. Берәр йир бар иде.

Г о м ә р. Нинди йир? Бай кешеме? Кем кызы?

М ә х м ү д. Кыз кеше түгел, болай үзе бик матур һәм яшь.

Г о м ә р. Ничек, ире үлгәнмени?

М ә х м ү д. Юк, аерылган.

Г о м ә р. Кем соң ул? Бик юкка чыккан түгелме? Әллә ниндәй юкка чыккан кеше булып, нәселемезгә кеше арасында оят китererлек кеше булмасын.

М ә х м ү д. Әле яңарак кына аерылды, ире түбән урамда, кем йортындадыр исә, иясен белмим, фатир тора. Гайнетдин исемле.

Г о м ә р. Шулмени? Ул бик яхшы хатын булмаска кирәк. Мин әле аны ишеттем, бер кеше берлән йөреп, иренә әйткәннәр дә, шуның өчен аерган дип. Ул кеше өстенә исеме чыккан хатын, аннан яхшылык күрә алмассың. Аның йөземезгә оят китерүе бик кариб, андый ирләр сайлый торган хатын сәңа канәгать кыйлып тормас.

---

К а р и б – ерак йөрмәс.

Мәхмүд бик кызарып китә.

Гомәр. Әллә берәр хәл бармы, бик кызарып киттең? Минем бу әйтүем ярамадымени?

Мәхмүд. Бернәрсә дә юк.

Гомәр. Соң ник кызарасың?

Мәхмүд. Сезнең яратмаганлыгыңыздан гына кызарам, бәлки, безгә килгәч, алай булмас дип әйтәм.

Гомәр. Һи, юк сүзне сөйлисең, оясында ни күргән – очканында шуны күрер, дигәннәр. Әллә ул йөргән кешесе дә син идеңме? Бик күңелеңә ошаган кук күренә.

Мәхмүд. Мин булучылыгы кирәк түгел аның.

Гомәр. Алай булса, инде син бик яхшы аңла: гадәт китмәс, чир китәр, дигәннәр. Ярлырак чагында үзен-үзе тыя алмаганны, сәңа килгәч кенә тыелмас. Синең дәүләтең дә чибәррәк, сиңа яхшы гына йирдән кыз бирерләр, гомерең буенча рәхәттә торырсың. Әгәр матур кирәк дип әйтсәң, дөньяда матур ул гына түгел, яхшы нәселле баерак йирдән дә табып була. Һәм тәрбиядә үскәч, әдәпле дә булыр. Ул нәрсәне алып һич файда итә алмассың. Бары кеше арасында йөзеңә оят кына китерерсең, элеккеге ирен яратмыйчы кеше эзләп йөргән шикелле, сәңа килгәч тә синнән матуррак кешене эзләүдән бер дә туктамас, мин сине кызганып әйтәм, әгәр башыңда бераз гакылың булса, белергә тиеш, керүдән әүвәл чыгуыңны исәплә, дигәннәр, һәр эшнең ахырын исәпләргә кирәк, соңыннан, эш узгач, үкенүдә файда булмас. Ничек булса да кеше булырга тырышырга кирәк. Аңар вәгъдә куйганың юктыр бит әле?

Мәхмүд. Вәгъдә куйган идем куюын да, алай да эш узмаган әле, кайтарырга ярый.

Гомәр. Алай булса, син бер дә юк белән чугалма, менә, Алла боерса, үзем сүзләр салгалап карыйм, иншалла, яхшы йирләрдән бирерләр.

Ул арада сәгать бишне суга.

Гомәр. У! Сәгать биш булган икән, китәргә кирәк, чакырган йир бар иде.

Мәхмүд. Ярый алайса, мин кире кайтарам инде.

Гомәр. Кайтар, кайтар. Ул сәңа һич мәслихәт кеше түгел.

Дога кыйлалар да, Гомәр исәнләшеп чыгып китә.

Мәхмүд (*үзалдына сөйләргә тотына*). Гомәр абзыйның да әйтүе бик дөрест, ул соң, җүнле булса, мәнем бер әйтүем берлән ышанып иреннән аерылыр идеме? Бик дө-

рест, бик дөрест. Гомәр абзый бик белеп әйтә ул, бер әллә ниндәй белмәгән кешенең сүзе белән иреннән аерылу гакыллы кешенең эше түгел. Ул, ирен яратмаган шикелле, мине дә яратмас. Дөньяда миннән матур, миннән бай беткәнмени? Һәм мәнем шикелле гакылсыз, кеше хатынына карап йөрүче беткәнме, миңа бер дә дураклanырга ярамый, яхшырак кеше дә бетмәс әле. (*Бераз фикердә тора да, аннан соң әйтә.*) Тукта, йөрәкемә чыдап булмый, эш бетеп торсын, хәзер үк әйтеп кайтыйм. (*Өстен киенә дә чыгып китә.*)

## 5

Уртачарак бер өйдә Сәрбиҗамал ялгызы гына утыра. Үзалдына сөйли.

Сәрбиҗамал. Бу нишләп килми икән инде? Ярты сәгатьтән барырмын дип йибәргән иде дә, әллә бөтенләй алдалап йөри инде? Бик йөрәкләрем дә сәерләнеп тора. Әллә берәр эш буламы, юк исә бу кадәр күңелемә һичбер вакытта курку төшкәне юк иде. Тукта, самавыр куйыйм. Мөгълифә әби дә килер, бераз сөйләшеп тә утырырбыз, ичмасам, бераз эч пошуы басылыр. (*Самавыр куярга тотына.*)

Бераздан соң ишектән Мөгълифә килеп керә.

Сәрбиҗамал. Йә, әби, бераз көттердең соң, көтә-көтә җаным чыга язды, ярты сәгать ярты ел күк тоелды.

Мөгълифә. Зыян юк, шатлык хәбәрләр әйтсәм, күңелләрең ачылыр әле. Бая гына Мәхмүдкә барып кайттым. Сәнең аерылганыңны әйткән идем, шатлыгыннан урынында тора алмый. Миңа сөенечкә биш тәңкә сәдака биреп чыкарды. Ишектән барып керүемә бөтенләй күтәреп алгандин ким итмәде. Инде тизрәк гыйддәтең генә тулсын. Аннан соң гомер буенча рәхәтләнерсең.

Сәрбиҗамал. Эчем пошу белән бөтенләй ни эшләремә дә белмичә торадыр идем. Бу сүзең белән генә бераз күңелләрем ачылды. Башка сүзләр сөйләмәдеме?

Мөгълифә. Юк, мин анда бик аз гына утырдым, башка сүз сөйләшерлек ара булмады әле, монда килмәкче булды.

Сәрбиҗамал. Кайчан?

Мөгълифә. Белмим, кайчан килер. Әниләрең кайда соң сәнең?

Сәрбиҗамал. Габдулла абый, җиңги, әни бу көн авылга кайтып киттеләр. Сафа абый базарда, ул кич белән генә кайта.

Ул арада ишектән М ә х м ү д килеп керә. Мөгълифә белән Сәрбиҗамал аяк өстенә торалар.

М ө г ъ л и ф ә. Сөйләгәнне генә көтеп торган икән. Әйдә, улым, хуш киләсең.

М ә х м ү д. Исәнме, әби, сәламәт торасызмы?

М ө г ъ л и ф ә.<br>
С ә р б и җ а м а л. } Аллага шөкер!

С ә р б и җ а м а л. Әби юри генә әйтә торгандыр дигән идем, хәер, ялганламаган икән, әйдәгез, түрдән утырыгыз.

Мәхмүд, Мөгълифә, Сәрбиҗамал урындыкларга утыралар. Мәхмүд күңелсезләнеп, бер дә сөйләшмичә утыра.

Берәр төштә хәтерегез калдымы, бер дә сөйләшмисез?

М ә х м ү д. Сезнең үзегезгә генә сөйлисе сүзләр бар иде.

Бу урында никадәр озак, бер ярты сәгать кадәр сөйләсәләр дә, бик оста сөйләгәнлекләреннән аңлый алмадым, шуңарга күрә бу урында бу кадәре белән икътифа кылдык. Бунын соңында Мөгълифә үзләрен генә калдырып, исәнләшеп чыгып китте. Мәхмүд белән Сәрбиҗамал чәй эчә калдылар.

С ә р б и җ а м а л. Бая Мөгълифә әбигә дә әйтергә ярамаган сүзләрегез нинди сүзләр иде? Әллә нинди сүзләр күк тоеп, эчем пошып тора.

М ә х м ү д. Бик яхшы сүз түгел түгелен.

С ә р б и җ а м а л. Ничек?

М ә х м ү д. Гомәр абзыйга сезне алуны мәслихәт иткән идем, кабул күрмәде.

С ә р б и җ а м а л. Анын сүзенә карыйсызмы?

М ә х м ү д. Карамыйча ни эшлисең, атамыз урынына калган кеше, анын сүзен тотмыйча булмый шул.

С ә р б и җ а м а л (*бик кызарып, ачулары кабарып китә дә*). Хәер, әби әйткәч тә, фикеремә килгән иде ул. Шул ахырзаманда ни уйласаң, башыңа килә дигән сүзләр бар да раст. Зыян юк, безгә дә үзебез шикелле кеше табылыр әле.

Бер дә ачуланганын белгертмәде, үзе эченнән уйлады: «Инде алай алмаучылыгын билгеле булды, миңа да авызымны ачып йоклап торырга ярамый, ичмаса, күзем күрмәс. Ул башка хатын алып тора башласа, ничек чыдап торырсың?» – дип, эче ут шикелле янып, икенче бүлмәгә чыгып, янында яшереп, бер шешә алып килеп урынына утыра да сүз башлап әйтә.

Ул соң Гомәр абзыегыз шундый ук сезгә хуҗа булырлык кешемени, сүзеннән чыга алмыйсыз?

---

И к ъ т и ф а к ы л у – чикләнү.

М ә х м ү д. Безнең этинең энесе ул. Һәм аның сүзеннән чыкмаска этинең васыяте дә бар.

С ә р б и җ а м а л. Алай, аннан башка эш күрерлек булмагач, әүвәлдә үк безне ышандырмаска кирәк иде, мин дә торган көе шул иремдә торыр идем.

М ә х м ү д. Ни эшлисең, күрәчәккә каршы булган инде.

Икенче якка таба борылып кайгырып утыра башлады. Ул арада Сәрбиҗамал да, форсат табып, шешәдәге агудан беразын Мәхмүднең стаканына сала. Аннан янә сөйләргә тотына.

С ә р б и җ а м а л. Әйдә инде, алдагын кайгыртып файда юк, алмасаң алмассың, ичмаса бу мәҗлестә бераз ачык йөз белән утырыңыз, әйдә, чәеңезне эчеңез әле, белер хәл юк, бәлки, насыйб булса, алып та куярсыз. Ни булса да Алланың тәкъдирен күрерсез.

М ә х м ү д (*гаять эче пошып, сүз сөйләргә тәкате калмаенча күзләреннән яшьләре килеп, чәйнең эчендә нәрсә барлыгыннан бер дә хәбәре булмаенча эчә дә әйтә*). И җаным! Инде һич сөйләр хәлем калмады, тәмам күңелләрем тулды, гаеп итмәңез, гаеп бездә, рөхсәт биреңез, мин кайтыйм. Менә расхутыңызга тотарсыз. (*Егерме сум акча чыгарып бирә дә чыгып китә.*)

Ул чыгып киткәч, Сәрбиҗамал ни эшли? Аны да әйтик. Мәхмүд чыгып киткәч, үзалдына сөйләргә тотына.

С ә р б и җ а м а л. Ах, кызулык берлән артын исәпләмиче ни эшләр эшләдем бит, үзенең гыйшкы бар икәнлеге көн кук күренеп тора. Әгәр дә мәхәббәте булмаса, ул кадәр кайгырыр идеме, бичара? Күзләреннән яшьләре тәгәрәп-тәгәрәп төшә. Мескенне юк йиргә әрәм иттем, миңа да бу дөньяда торудан ни файда, кеше өстенә исемем чыгып беткәч, мине кем алыр? Инде миңа да аның шикелле булудан яхшысы юк. (*Йөрәкләре янып, күзеннән яшьләр түгә-түгә, стаканга агуны салып эчеп җибәрә. Агуны бернәрсә белән дә катыштырмаганлыктан, йөрәгенә барып ябыша да калтырап егылып китә, тәмам телдән калып бер-ике мәртәбә ухлап кычкыра да җан тәслим итә.*)

## 6

Мәхмүднең өе. М ә х м ү д стулга утырган, күкрәкен тотып утыра. Ул арада ишектән л а к е й белән Г о м ә р  ә ф ә н д е килеп керәләр.

---

Җ а н  т ә с л и м  и т ү – үлү, җан бирү.

Г о м ә р (*Мәхмүднең янына килеп әйтә*). Нихәл, Мәхмүд? Ни эшләргә очрадың?

М ә х м ү д. Ух! Хәзер аны сорар вакыт түгел! Тизрәк духтырны... Ух! Ух! Һай, йөрәкем... яна йөрәкем. Зинһар, тиз...

Г о м ә р. Бар, Хәйри, тизрәк доктор алып кил!

Лакей йөгереп чыгып китә.

Г о м ә р. Кем болай эшләде?

М ә х м ү д. Ух! Һай, йөрәкем! Теге йөзе... Уһ! Теге, теге йөзе кара... Уһ, абый, тизрәк тот! Ух, җыгылам.

Гомәр тотып алып диванга яткыра.

Г о м ә р. Теге вәгъдә куйган нәрсәме?

М ә х м ү д. Әйе. Уһ Аллам, абый, зинһар, су... Һай, җана эчем!

Гомәр тиз йөгереп су китерә. Ул арада Мәхмүд телдән кала. Суны китереп эчертмәкче була. Мәхмүднең һич авызын кыймылдатырга кодрәте калмый. Гомәр егъларга тотына, янында кәлимәи шәһадәт тәлкыйн кыйла башлый. Ул арада ишектән д о к т о р белән л а к е й килеп тә керәләр. Мәхмүд бер-ике мәртәбә сулап күзләрен әйләндереп карый да җан тәслим итә.

И н т и һ а.

---

К ә л и м ә и ш ә һ а д ә т т ә л к ы й н к ы й л у – иман сүзләре әйтү.
И н т и һ а – ахыры, тәмам.

## КЫЗГАНЫЧ БАЛА

*(Өч фасылдан гыйбарәт театр уены)*

МӘҖЛЕС ИЯЛӘРЕ:

Гата бәк – унтукыз яшендә табия (докторлык гыйльме укыла торган мәктәп) нең унынчы сыйныф (класс) шәкертләреннән бер екет.
Шәфыйка – ундүрт яшендә бер кыз.
Хәлил бәк – Шәфыйканең атасы.
Таһирә ханым – Шәфыйканең анасы.
Шәрифә ханым – күрше хатыны.
Табендә – асрау.
Доктор.

### БЕРЕНЧЕ ФАСЫЛ

Матур гына бер бүлмә.

#### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Шәфыйка (*ялгызы гына*). Күңелемнән кош шикелле нindәй гаҗәп хәлләр үтә! Гаҗәп, мин нindәй кеше, зиһенемдә үзем аңлый алмаслык дәрәҗәдә хыяллар булсын, бу нindәй эш? Ике ай әүвәл бу вакытларда нindәй тәмле-тәмле йоклыйдыр идем. Ике ай булды, күземне ачып караңгылыгын күрми калган һич төн юктыр. Бик яхшы! Гата монда булганда иртәрәк торыйм. Никадәр иртә уянсам да, һич зарары юк. Йә бер сәгать йөзен артыграк күререм. Йә бер сәгать уянуын көтәрмен. Әмма ул мәктәптә булган вакытта!.. Кемне күрермен? Кемне көтәрмен? Бара-бара һич шөбһәм калмады: сөю дигән нәрсә шушы икән. Яхшы, мин әниемне дә сөям. Ник һәр кичне күземне йомгач төшемә керми? Атамны сөям. Ник үзе өйдә булмаганда гәүдәсе күз алдында йөрми? Бер көннәрне мәктәпкә китте. Бер айсыз килмәслеген бик яхшы белә торып, әллә килә микән диеп, тиле кеше шикелле минут саен тәрәзәдән карыйм. Әти белән әни килешемнән берәр нәрсә сизеп шөбһәгә төшмәсеннәр дип

куркып, янә тәрәзәдән башымны алдым. Хәлемне аннан яшерүчелегем дә янә бер бәла! Аңласа – хурлануымнан, аңламаса – кайгымнан үләм. Аh! Бу мәхәббәттән башка бернәрсә дә түгел. Әлбәттә, мәхәббәт бу, мәхәббәт! Кичә Табендәгә, кеше ничек сөя диеп сора, дидем. Ни җавап бирсә дә ярый. Син яшь бала, сөюне кайдан беләсең? димиме? Һи, бәдбәхет, мин яшь бала, имеш, сөюне беләсе түгел икән. Синең шикелле әүвәле яңакларым ябышсын, борыннарым кипсен дә, аннан ары сөюне өйрәнермен. Шулаймы? Сәгать алты да булды. Һаман уянмаган. Икенде йитмәс борын янә китәчәк. Тагы мин бичара бер ай көтеп торачак. Ичмаса, бер, ике көн булса да йөзен туйганчы күрү насыйб булмый... Никадәр җаным егъламакчы була! Аh! Тагын әни күзләремнең кызарганын күрер дә кыямәт кубарыр... Аh! Килә. Аның аяк тавышы. Менә... аягының тавышын ишетер-ишетмәс йөрәкләрем уйный башлады.

### ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ш ә ф ы й к а, Г а т а  б ә к.

Ш ә ф ы й к а. Сез идеңезме? Йөрәгем уйнады.

Г а т а  б ә к. Мин бик акрын килгән идем.

Ш ә ф ы й к а. Зыян юк, зыян юк, уйнап кына әйтәм.

Г а т а. Мине куркыттыңыз... Һава бик салкын. Җаным, таң вакытында ни эшләп болай юка күлмәк берлән генә утырасыз? Алла сакласын, суык тисә, ни эшләрсез, без ни хәл итәрбез, кулларыңызда да эсселек бар. Тукта, шәлеңезне килтерим.

Ш ә ф ы й к а (*үз-үзенә*). Тагы бар йиремә ут тоташты. Ул да йитмәсә, кулларыма да эсселек бәрде. Һич үз-үземне тота алмыйм. (*Гатага.*) Чү! Ул кадәр аптырама, бүлмәдән ишетерләр дә чыннан ук авыру дип белерләр.

Г а т а. Алла күрсәтмәсен! Сез ни эшләп авыру буласыз? Мин ничек торырмын? Сезгә киләсе авыру, теләсә, мең кат булсын да миңа килсен! Авыру духтырларга килешә.

Ш ә ф ы й к а (*йөрәкләнеп*). Куй! Үз-үзеңә андай нәрсәләр юрама!

Г а т а. Ник аңар эчеңез поша? Мин сезгә дога кыйлам.

Ш ә ф ы й к а. Миңа андай дога кирәк түгел. (*Үз-үзенә.*) Мин дә тилеме нәрсә? (*Үзен җыебрак, Гатага.*) Машаллаh, сез миннән артык йоклыйсыз.

Г а т а (*кайгырыбрак*). Бу көн hич йокламадым.

Ш ә ф ы й к а. Һич йокламадыңмы? Бу вакытка кадәр урыныңда ни эшләп яттың?

Г а т а. Мин... мин дәрес карадым.

Ш ә ф ы й к а. Хәйләкәр! Ничек дәрес карадың? Бүлмәңдә китабың юк ич.

Г а т а. Бүлмәмдә... дөрест, китап юк иде. Миңа китап кирәк түгел, мин укыган сабакларымны урынымда күңелемнән үткәрәм, сез... сез минем бүлмәмә кайчан кердегез?

Ш ә ф ы й к а. Мине әллә үзең шикелле дип беләсеңме? Синең урыныңа, рәхәтеңә карамыйча минем күзләремә йокы керерме?

Г а т а. Аһ...

Ш ә ф ы й к а. Ни эшлисең?

Г а т а. Сөенечемнән күңелемә бер гаҗәп хәл килде, күз алдымнан матур-матур нурлар оча. Бичара Гатаны шулкадәр үк күңелегезгә китерәсезме?

Ш ә ф ы й к а (*үз-үзенә*). Гакылым яңлыш йөрми. Ул да минем хәлемдә... Хәзер белермен... әлбәттә, белермен. (*Гатага.*) Ул кадәр күңелемә китерүем күпме? Ничә елдан бирле карендәшләр шикелле бергә үстек. Бер-беремездән һичбер вакытта зарар күрмәдек. Мин синең шикелле хәйләкәр түгел, тугъры сөйлим. Мин дә бу көн йокламадым, һаман сине исәпләдем.

Г а т а. Минеме?.. Мине исәпләдегезме?.. А... мин һәр кичне ни эшлим, һич түшәктә дәрес укылганны күргәнең бармы? Сине исәпли-исәпли төсең шулкадәр зиһенемә урнашты, әгәр бер айдан соң сурәтеңне язсам, һичбер сызыгында да яңлышмам.

Ш ә ф ы й к а. Хыянәт, син зиһенеңнән сурәтләр ясау берлән маташасыңмени? Бу ел дәресләреңне бетереп духтыр булып чыгуыңны һич уйламыйсыңмы? Мин дә ундүрт яшьне тултырам. Хәзергә кадәр, Шәфыйка яшь әле дип, безне бер-беремездән аермыйлар иде. Берничә айдан соң безне бергә калдырырлар дип уйлыйсыңмы?

Г а т а (*сүзен бүлеп*). Һай, юк... юк... Хәтеремә андай күңелсез эшләр китермә! Алла хакы өчен, куй! Юк исә мине харап итәрсең.

Ш ә ф ы й к а. Ник ул кадәр өтәләнәсең? Дөньяда кем кемнән аерылмаган?

Г а т а (*үзен җыебрак*). Сиңа аерылу җиңел булырмы? Уйлап кара! Үзеңне белгәннән бирле бергә торамыз.

Ш ә ф ы й к а. Үземезне белгәннән бирле әни берлән дә бергә идең түгелме? Менә әниемнән аерылдың, өч елдан бирле сиңа күренми, ни өчен бернәрсә дә эшләмәдең?

Г а т а. Эшләмәдем... эшләмәдем, чөнки... ул башка, сез башка, сезнең белән иптәш күк идек.

Ш ә ф ы й к а. Мәктәптә никадәр иптәшләрең бар. Һичбереннән аерылмадыңмы? Чынлап, менә моннан алты ай электә Әхмәттән аерылдың, бер-берегезне карендәш шикелле күрәдер идегез, ни өчен бернәрсә дә эшләмәдең?

Г а т а. «Ни өчен бернәрсә дә эшләмәдең? Ни өчен бернәрсә дә эшләмәдең?» дип сорый-сорый тәмам аптыратып бетердең, һичбер кеше җавап табып бетерә алмас, ике еллык дәресләрдән берьюлы имтихан биргән идем, анда да бу кадәр аптырамаган идем.

Ш ә ф ы й к а (*тырышыбрак*). Чынлап ук җавап таба алмыйсыңмы? Әллә... әллә тапкан җавапларыңны әйтәсең килмиме?

Г а т а. И җаным! Ни эшләп әйтәсем килмәсен?

Ш ә ф ы й к а. Һичбер нәрсә юкмы? Чынлап әйтәсеңме?.. Зинһар, әйт... чынлап әйтәсеңме?

Г а т а. Мәрхәмәтсез! Бу көй әллә мине инде харап итмәкче буласыңмы?

Ш ә ф ы й к а. Кил! Монда кил, яныма... утыр! Минем дөньяда синнән башка хәлемне сөйләрлек кешем бармы? Моңарчы, куркып, атам-анамнан саклаган нәрсәләремне сиңа сөйләмимме? Күңелемдә бер хәл бар. Аны да сиңа сөйләрем – бары ул хәл синнән килде. Чара синдә, синнән телим, алай да әүвәл сорасы нәрсәләремә тугъры җавап бир. (*Ныгытыбрак.*) Зинһар, минем башым өчен тугъры җавап бир!

Г а т а. Алла, Алла!

Ш ә ф ы й к а. Хәтереңдәме? Моннан ике ай элек... тәмам ике ай элек. Шул вакыттан бирле ике мәртәбә мәктәптән кайттың. Монда шушы бүлмәдә бер хикәят китабы укыган идең, исеңә төштеме? Теге бер пашаның бер кызы бар икән, күршесенең угълы аны сөя икән, соңыннан кызны башка кешегә биргәннәр дә, ул бала үзен-үзе үлтергән, аннан соң кыз да һәлак булган. Тагы да исеңә төшмәдеме? Шул вакыт, хикәятнең шушы төшенә килеп йиткәч, мин: «Сөбханалла, бер кыз теләгән кешесенә бармау белән һәлак булыр», – дигән идем.

Г а т а. Дөрест.

Ш ә ф ы й к а. Шул вакытта син үзеңне-үзең тота алмадың, күзеңдә бер тамчы яшь күренә башлады, битеңдә, качарга урын эзләгән шикелле, акрын-акрын әрле-бирле йөри башлады. Менә хәзердә дә йөзеңдә нәкъ шуның шикелле тагы бер тамчы яшь йөри.

Г а т а. Уф...

---

Б у к ө й – шулай итеп.

Ш ә ф ы й к а. Чү... тарылма! Мине тыңла! Мин сине шул көннән бирле бөтенләй башка төрле күрә башладым. (*Кулларын бик каты кысып.*) Кайчан гына булсын, йөзеңә карасам, күзләрең мине югалтканлыктан үләр төсле кайгылы булып торалар. Нindәй генә килешеңә карасам, миңа «Синнән аерылсам, үләм» дип әйткән шикелле торалар. Мине сөясең бит, шулаймы?

Г а т а. Йибәр! Зинһар... Алла хакы өчен мине йибәр!

Ш ә ф ы й к а. Тыңла! Әле бетермәдем. Ул көннән бирле күзләреңә карасам, йөрәгемнең кайгылылыгы күзеңә төшкән дә, шуның өчен бу кадәр әлсерәп торган күк күренәсең. Хәлеңне исәпләсәм, «Гатадан аерылсам, үләрмен» дип ант итүдән башка хәтеремә һичнәрсә килми. Шулай булгач, сине сөям түгелме?

Г а т а. Аһ Раббым, мин ниләр эшләдем! Мине бу кадәр рәхмәтеңә лаек күрдең? Бары моңар булган мәхәббәтем белән дә үземне һәр кешедән артык бәхетле дип беләдер идем. Хәзердә мине сөйгәнлеген ишетәм. Үз агызыннан ишетәм. Сөям, Шәфыйкам! Сине сөям, дөньяда никадәр сөю булса, шулкадәр сине сөям!

Ш ә ф ы й к а. Сөясеңме? Сиңа мәхәббәт нindәй хәлләр китерә? Сөйлә! Сөйлә! Карыйм.

Г а т а. Ни төрле хәлләр китерәме? Һич вакытларым берсе-берсенә охшамас... Кайчан син яныма килсәң, гәүдәләремнең һәрберсе аерым-аерым яна башлый, гүяки өстемә кайнар күлмәк кидерәләр, янымнан китсәң, җаным тәнемнән чыга. Чыкканлыгын һәр йирем аерым-аерым сизәр. Һәр ягым тетри башлый, йөрәгем йиреннән куба да аркамнан чыгар төсле тора. Кайсы көннәр була: юлыңда үлеп тә, сине башым очында егълап утырганыңны күрүдән дә зур бер дәүләт таба алмас төсле уйлар зиһенемнән үтә. Соңыннан синең егълавыңны уйлыйм да сине кызганганлыгымнан үзем дә кайгыра башлыймын, дөньяда никадәр матур нәрсәләр күрсәм, синең берәр йиреңә охшатам. Соңыннан күргән нәрсәмнең берәр йирендә кимчелек табам да, ул да күземнән төшә, бары күңелемдә син генә каласың. Төшемдә сине күрмәм микән дип йокларга ятам да синең сурәтеңне күз алдымнан югалтырмын дип куркып торам, һәр хәлемне һич әйтү мөмкин түгел, ничек сөйлим?

Ш ә ф ы й к а. Сөйлә, җаным, сөйлә! Белгәнең кадәр сөйлә.

Г а т а. Кайчан гына сине күрмәсәм яисә исәпләмәсәм, күңелемә, зиһенемә бер юклык, бер караңгылык килер. Гүя үз-үземнән югалганмын да, үземне бер ят кеше ши-

К а р ы й м – «тыңлап карыйм» мәгънәсендә.

келле күрәмен, соңыннан бөтенләй хәтеремдә син буласың, үлем түшәгендә торган авыру шикелле, бөтен дөнья минеке була. Гүя тәнемә баштан аякка кадәр бер рәхәт, бер тереклек килер.

Шәфыйка. Аһ! Мин никадәр тырыштым, күңелемнән узган уйларны бертөрле җыеп та, үз-үземә аңлата алмадым. Син, белмим, ничек итеп көчең йитте дә сөйли белдең, әллә синең телең минем күңелемдәме? Аңладым, җаным, хәзер тәмам аңладым, бән дә сине сөям!

Гата. Андай сүзләр сөйләмә! Мине сөенечемнән үлтерерсең. Зыян юк, сөйлә! Сөйлә, кешегә дөньяда мәхәббәт сүзен сөеклесенең агызыннан ишетеп тә сөенеченнән үлүдән дә артык бәхетлелек булырмы?

Шәфыйка. Соң, мәхәббәт мондый нәрсә булгач, ни өчен аннан бу кадәр шикаять кыйлалар? Кешенең йөрәген яндыра икән, гакылын ала икән, һәлак булуына сәбәп була икән, мин мондый ләззәт өчен һәлак булсам да һич үкенмим, җаным! Алла арттырсын! Мондай белүең бар, һәрнәрсәне сөйли аласың, миңа да өйрәтсәнә, мәхәббәт ниндәй нәрсә? Кешеләргә бу дәүләт кайдан килә? Син хәким (духтыр) кеше, бундай нәрсәләрне сез белмиче кем белер?

Гата. Җаным! Без тәндә булган авыруларны гына белер өчен тырышамыз. Рухта (җанда) булган ләззәтләрне кайдан белик?

Шәфыйка. Ай! Мәхәббәт рухтамыни? Алайса, ул ахирәткә дә безнең белән бергә китәчәк.

Гата. Әлбәттә!

Шәфыйка. И, ике дөньяда мине Гатадан аермаган Раббым! Сиңа ниндәй шөкерләр әйтим! Һай! Җаным, эти килә. Тиз янымнан аерыл! Шунда берәр нәрсә укы! Безне бер йирдә күрмәсен.

### ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әүвәлгеләр һәм Хәлил бәк.

Хәлил бәк. Балалар! Бик иртә торгансыз. Монда ни эшлисез?

Шәфыйка. Китап укыймыз, этием.

Хәлил бәк. Йә әле! Ни укыйдыр идеңез? Карыйм.

Гата. Яңа чыккан бер мәҗмуга, әфәндем...

Хәлил бәк. Анысын беләм. Кай йирен укыйсыз? Мин дә тыңлыйм.

---

Шикаять кыйлу – зарлану.
Мәҗмуга – җыентык (китап).

Г а т а (*китапның бер җирен ачып*). Америкадәге вәхшиләр.

Х ә л и л б ә к (*сүзен кисеп*). Куй, угълым! Нигә кирәк ул Америкадәге вәхшиләр? Шуның фиһристен кара! Эчендә берәр кызыграк нәрсә юкмы?

Г а т а. Еланнарның тереклеге...

Х ә л и л б ә к. Уз әйдә! Агач ашасыннар...

Г а т а. Байлык сәбәпләре...

Х ә л и л б ә к. Анысы безгә түгел, укысак та файдасы юк.

Г а т а. Мәхәббәт! (*Үз-үзенә.*) Бу нindәй эш!

Ш ә ф ы й к а (*Гата белән бервакытта*). Сөбханалла!

Х ә л и л б ә к. Мәхәббәтме? Укы, күрик, аның өчен ни дигән булганнар икән?

Г а т а (*укый*). «Дөньяда мең төрле мохтаҗлык, мең төрле мәшәкать, мең төрле бәла, мең төрле ачы, мең төрле авыру, мең төрле үлем – бары да адәм угыллары өчендер...»

Х ә л и л б ә к. Шулмы мәхәббәтнең тәгърифе?

Г а т а (*укый*). «Аллаһы Тәгаләнең колларына бу кадәр бәлаләргә каршы дөньяда бары бер рәхмәте күрелсә, ул да мәхәббәттер».

Х ә л и л б ә к. Хәзер бераз сүз төслерәк булды...

Г а т а (*укый*). «Гомернең мәшәкатьләре чигелсә, һәммәсе мәхәббәт өчен чигелер. Тереклекнең бер ләззәте булса, ул да мәхәббәттер, вә мәхәббәт никадәр зур ләззәттер ки, адәм угыллары җәфаларында да бер башка ләззәт таба, мәхәббәт берлән гомер иткән кешеләр, ничек гомер итсәләр дә, һаман сөенерләр. Мәхәббәт өчен үлгәннәр, ничек үлсәләр дә, риза булырлар. Сез хәзер, бәлки, мәхәббәт нидән була икән дип уйларсыз. Анысы нигә кирәк? Күңелеңездә мәхәббәт юкмени, булдырырга тырышыңыз! Бармы? Булса, як-ягыңызга караңыз, йирләрне – һәрвакыт яз, күкләрне һәрвакыт шәфәкъ вакыты итеп күрерсеңез, яфраклар күз алдыңызда җанланган шикелле булыр. Бер сандугач сайраса, сезгә күңелеңездәге булган серләреңезне сөйләгән кук тоелыр. Күз алдыңызда ниндәй болыт күренсә, бер күлмәк сурәтенә керер, сезгә хыялмыял сөйгәнеңезнең күкрәкләрен, беләкләрен ачып күрсәткән шикелле булыр. Бераз гына ялгыз торасызмы? Шул вакыт йоклап караңыз, әлбәттә, сөйгәнеңез төшеңезгә керер. Юлыңызда берәр куркынычка очрыйсыз-

---

Ф и һ р и с т – эчтәлек.

Т ә г ъ р и ф – аңлатма, билгеләмә.

мы? Һич курыкмаңыз, туп-тугъры барыңыз, әлбәттә, һәрвакыт сөйгәнеңезнең кальбендә бер сакчы фәрештә күрерсеңез. Үзең үлгәннән соң кабереңнең өстендәге чәчәкләр кан берлә яисә күз яше берлә чыланырлык бер сөекле юлдаш табылучылык дөньядан рәхәт китү өчен никадәр зур куәттер! Дөньяда кем бар? Сөйгәне берлән бер түшәктә бер минутта үлү өчен бөтен тереклеген фида итмәслек кеше...»

Ш ә ф ы й к а. Уф...

Х ә л и л  б ә к. Ни булды, кызым?

Ш ә ф ы й к а. Кайдан белим, этием! Әллә ниндәй нәрсәләр йөрәкләремне селкетә башлады.

Х ә л и л  б ә к. Мин дә ниндәй кеше? Килдем дә балаларның кәефен боздым. Кызым! Берни дә булмас, син курыкма, бераз китеп бакчада йөрсәң, хәзер бетәр. Шулай түгелме, Гата? Йөрәк селкенү бер хәстәлек түгелдер бит?

Г а т а. Хәер, әфәндем...

Х ә л и л  б ә к. Кызым! Әнә Гата да минем сүземне сөйли! Хафаланма, утырыңыз! Сез утырыңыз да Америкадәге вәхшиләреңезне укыңыз! (*Чыгып китә.*)

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ш ә ф ы й к а, Г а т а.

Ш ә ф ы й к а. Аһ! Аз гына калды, бөтенләй җыгылып китә яздым. Инсафсыз! Мине әти күз алдында егълатаегълата аякларыңа төшереп, дөньяда мине рисвай итмәкче идеңме?

Г а т а. Мин үз иркем белән укыдыммени?

Ш ә ф ы й к а. Ничек укыганыңны белмисеңмени? Соңындагы сүзләрең!.. Гүя авызыңнан чыккан сүзләр һәммәсе бер ялкын шикелле йөрәгемә кабынды. Алла сакласын! Сиңа берәр хәл булып, үземне һәлак иткән булсам, ничек булыр иде? Әле дә күз алдымнан шундый бәлаләр очып-очып китә башлады. Тор, җаным, тор! Бар, мәктәпкә кит! Юк исә йә үз-үземне һәлак итәрмен, йә башка берәр хәл булыр, икемез дә хур булырмыз. Бар, җаным, бар!

Г а т а (*кайгырып*). Әле берничә сәгать вакыт бар барын, әмма сез кушкач...

Ш ә ф ы й к а. Җаным! Алла хакы өчен миңа мәрхәмәт ит! Һич тәкать тотар хәлем калмады. Син дәресең белән дә вакыт үткәрерсең, минем синең сурәтеңнән башка һич

---

К а л ь б (*калеб*) – йөрәк.

җуанырлык нәрсәм юк, алай да һаман аерылуыңа сабыр итәм. Тор, җаным! Ай, тукта, миңа киткән чагында сагынмаклык өчен бернәрсә дә калдырмыйсыңмени?

Гата. Ни телисең, җаным, әйт! Бирәм.

Шәфыйка. Сачеңнән беразын кисеп алсам, фурмысы бозылырмы?

Гата. Бозылса!.. Күк җимерелмәс әле.

Муенын сузар, Шәфыйка сачен кисеп алыр.

А!.. Мин... мин бернәрсә дә сорамыйммени?

Шәфыйка. Толымымны...

Гата (*кайгырып, сүзен кисеп*). Толымыңызнымы?

Шәфыйка. Белдем, белдем, синең үзеңнеке шикелле булсын түгелме? Сез инде каршысына нәрсә алмыйчы бер кешегә дә әйбер бирмәссез? Җүри әйтәм! Ал, җаным, ал! Ул сач кисәге никадәр бәхетле, һәрвакыт синең белән бергә йөри...

Гата сачен алып чыгып китә. Шәфыйка кулындагы сачне үбеп, егълап мендәргә каплана.

Пәрдә төшә.

## ИКЕНЧЕ ФАСЫЛ

### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Башка бер бүлмә. Хәлил бәк, Таһирә ханым.

Хәлил бәк. Ханым! Син алай дисең диюен дә, әле кыз ни эшләр, аны күрдеңме?

Таһирә. Аның хәлен нәрсә күрәсе? Бераз назланды, бераз егълады. Ул кадәр генә булмыймени ул? Атасы-анасы сине кияүгә бирәбез дисә, кайсы кыз сөенеч күрсәтер? Шәфыйка ул кадәр тәрбиясезмени ул? Бездән оялмаска. Атасыннан, анасыннан аерылырга ничек шатлансын? Шәфыйка ул кадәр мәрхәмәтсезмени бездән аерылуга кайгырмаска! Әфәндем, сезгә бу арада әллә ни булды? Кызның өйдән китүен уйлыйсыз да гакылыңыз башыңыздан чыга. Ул киткәнгә карап баласыз калырмызмени? Аллага тапшыр. Ул китсә, Гали юкмени? Хәзер ул да инде ун яшенә йитте.

Хәлил бәк. Алай түгел, ике күзем. Шәфыйка сау булсын, рәхәт булсын! Кайда булса да китсен, мин анысын исәпләмим. Ул баланың никадәр эчле икәнен үзең беләсең. Кияүгә бирүне сөйләгән вакытта, бармыйм дигәненә, егълаганына карамадым, әмма, белмим, син күз

төшерденңме? Синең көчләгәнеңне күрде дә, кайгырып-кайгырып, миңа күзләрен томыратып карады. Мин дә бер җавап бирмәгәч, йөзенә бер караңгылык килде. Күзләре тонды. Әле хәзердә дә шул төсе һаман бар. Хәзер дә көннән-көн ябыга, һич күзен йирдән алмый. Йөзенә әллә ниндәй караңгылык капланган, ундүрт яшендә бер бала синнән дә, миннән дә туйган. Башына әллә нинди эшләр килмәсә ярар иде. Аның күңелендә, әлбәттә, берәр мәхәббәт булырга кирәк.

Т а һ и р ә. Алла, Алла! Ул яшьтәге бала сөюне кайдан белсен? Ундүрт яшендә булган балаларны да теләсә кемгә барсыннар дип үз ихтыярына куйыйкмы? Аннан ары ата белән ана нигә кирәк? Инде шулай ук Шәфыйка итченең угълына сөям дип әйтә икән, тотыйк та шуңар бирикмени?

Х ә л и л  б ә к. Касаплар угълына димим, әмма үзенең тиңдәшләреннән берсен сөйсә, аңа бирмәенчә, синең кырык яшендәге пашаңа биримме?

Т а һ и р ә. Андый юк-бар сүз сөйләп утырма. Паша кырык яшендә буласы, имеш. Юк!.. Әнә булсын да, Шәфыйканең барасы кешесе кырык яшенә йитмәсмени? Үзенең тиңдәшен ул кайдан табып сөйсен? Без дә аның сөйгәнен кайдан табып бетерик? Юк сүз сөйлисез.

Х ә л и л  б ә к. Менә хәзер Гата...

Т а һ и р ә (*сүзен кисеп*). Мин беләм, синең бар теләгәнең дә шул Гатага бирү. Аның бер үксез бала икәнлеген бер дә исәпләмисез, ахры? Үзеңнең карендәшең булганга күрә, тәрбия кыйлып үстерденң, Шәфыйка белән карендәш шикелле тордылар. Аңар биреп ничек яхшылык күрергә кирәк? Якынын алып кемнең рәхәт күргәне бар? Аннан ары ничек көн күрерләр дип беләсең? Гата мәктәптән йөзбашы булып чыгачак түгелме? Ул йөзбашының жалуниясе нигә йитә? Кызыңны аңар биреп әрәм итмәкче буласыңмы?

Х ә л и л  б ә к. Духтырлар яхшы акча табалар алар! Гатаның да үткенлеген белмисеңмени?

Т а һ и р ә. Авырулардан акча алудан Алла сакласын!

Х ә л и л  б ә к. Алса, авыруны авыру иткән өчен алмый, сәламәтләндергән өчен ала...

Т а һ и р ә. Сәламәтләнмәгәннәрдән алмыймы?

Х ә л и л  б ә к. Алса, анда да хезмәте өчен ала.

Т а һ и р ә. Мин андый мәшәкать белән табылган акчаны сөймим.

Х ә л и л  б ә к. Соң, нинди акчаны сөясең? Күктән яуганнымы?

Т а һ и р ә. Хәер, мин артык белмим.

Хәлил бәк. Бу үпкәләшә торган урын түгел. Мин киңәш итеп әйтәм: Гата хәзердә йөзбашы булса ни зыян, гомер буенча, кыяматкә кадәр йөзбашы булып тормас, ул тәрбия кыйлырга көче йиткәнгә кадәр балалар да безнең белән бергә торырлар. Хуш! Хәзер ничек дисез? Сездән дә бер сүз ишетик.

Таһирә. Соң, сез кызның Гатаны теләгәнлеген кайдан белдеңез?

Хәлил бәк. Белгәнем юк, зиһенемә шундый бер шөбһә килде дә сөйләдем.

Таһирә. Хәзер Шәфыйкане чакырырмыз да сорармыз. Ул вакыт сөйгәненең барлыгын-юклыгын да, пашага барасы килгәнлеген-килмәгәнлеген дә белерсез.

Хәлил бәк. Алла бирсен дә, эш син әйткәнчә булсын.

Таһирә. Шәфыйка! Шәфыйка!

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әүвәлгеләр һәм Шәфыйка.

Шәфыйка (*тыштан*). Әфәндем!

Таһирә. Кызым, монда кил әле!

Шәфыйка (*бүлмәгә кереп*). Ни дисеңез?

Таһирә. Кил, кызым! Менә монда утыр! Әле этиең белән пашаны сөйләп утырадыр идек.

Шәфыйка. Әнием! Шәфыйкаңездән инде шулкадәр үк туйдыңызмени? Көне-төне мине өйдән чыгарып ташлаудан башка һичбер исәбеңез юк.

Таһирә. Ул ни дигән сүз! Дөньяда кемнең ата-анасы балаларыннан туяр? Без синең китүеңне теләсәк, синең рәхәтең, синең дәүләтең өчен телимез. Мин синең анаң булгач, әлбәттә, сине дөньяда иң зур кешенең хатыны итеп күрүне телимен, ул гаеп түгел. Син үз күлмәкләреңне үзең тегәсең, кулыңа кергән инәләрнең һәрберсе минем йөрәгемә кадалган шикелле була. Шулай булгач, сине байлык эчендә, каршыңда хезмәткәрләр, асраулар торган хәлдә күрүдән ни өчен шат булмыйм? Хәзердә Аллаһы Тәгалә шундый бер дәүләт бирде, андай дәүләтне меңнән бер кешесенә дә насыйб итмәс. Паша сине күргән дә матурлыгыңны күреп кызыккан, үзеңнең укымышлы булганыңны ишеткәч, мәхәббәте тагы да арткан, һич тынычсызлар кешесе юк, берүзе генә. Яшь көенчә шулкадәр зур байның сөекле хатыны буласың. Кырык кеше хезмәтеңдә кул кушырып торырлар. Кырык кеше ни кушсаң шуны эшләрләр, моннан да артык тагы ни кирәк?

Ш ә ф ы й к а. Аһ! Табендә шикелле хезмәтчеңез булган булса идем дә, мондай мине өйдән чыгаруыңызны ишетмәсәм иде.

Т а һ и р ә. Чү, кызым! Андый сүзләр сөйләмә! Атаң ишетсә, әллә ниләр әйтер. Әле дә синең өчен гауга чыкара язды.

Ш ә ф ы й к а. Әтием...

Х ә л и л б ә к. Кызым! Мин бернәрсә дә сөйләмәдем. Бары, Шәфыйка пашаны яратмый бугай, бәлки, күңеле башка бер кешене тели торгандыр, үзенә карап эш итәрмез, дидем.

Ш ә ф ы й к а (*үзен җыебрак*). Әтием! Менә ул ниндәй кеше! Сездән баш тартып, үз белдекемчә йөрергә. Андый сүзне сездән һич ишетермен дип белмидер идем.

Х ә л и л б ә к. Кызым! Мин кайдан белим? Дөньяда кеше башына төрле эшләр килә. Ул бик зур эш түгел. Мәсәлән, урамда берәр кеше күргән булырсыз.

Ш ә ф ы й к а. Әтием! Ни эшләп мине андый сүзләр белән борчыйсыз?

Х ә л и л б ә к. Менә, фаразан, олугъ урамдагы Ихсан... бик матур егет... Һәр көнне тәрәзә алдыннан узып китә.

Ш ә ф ы й к а. Алла үзе белә! Гомеремдә бер мәртәбә йөзенә күтәрелеп тә караганым юк.

Х ә л и л б ә к. Җаным, дөньяда ниләр булмый. Мәсәлән... безнең Гата... ни вакытлардан бирле бергә торасыз, бәлки...

Ш ә ф ы й к а (*бик тырышып үзен җыеп, акрын гына*). Гата минем карендәшем түгелмени? Аңар күз төшәргә...

Х ә л и л б ә к. Ул ни эшләп карендәшең булсын?

Ш ә ф ы й к а (*бер дә үзгәрмәенчә*). Бик беләм, карендәшем ул.

Т а һ и р ә (*Хәлил бәккә*). Күрдеңезме инде? Ниндәй юк уйлар уйлыйдыр идеңез.

Ш ә ф ы й к а (*үз-үзенә*). Уф... йөрәгемдә бу кадәр куәт бар дип белмидер идем. Ничек ярылмый!

Х ә л и л б ә к. Кем белә? Дөньяда бүтән кеше дә бетмәгән.

Ш ә ф ы й к а. Валлаһи, һичбер кешене исәпләгәнем юк.

Х ә л и л б ә к. Бик яхшы, әнә аналы-кызлы теләсәңез нәрсә сөйләшеңез, анысына минем гакылым йитми, мин катышмыйм. (*Чыгып китә.*)

---

Ф а р а з а н – мисал итеп алганда, әйтик.

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Шәфыйка, Таһирә.

Шәфыйка. Әнием!

Таһирә. Нәрсә, кызым?

Шәфыйка. Күңелемдәге серләремне сөйләргә рөхсәт бирәсезме?

Таһирә. Нindәй сер? Сөйлә, карап карыйм.

Шәфыйка. Ачуланмаслыгыңызга ант итеңез, сөйлим.

Таһирә. Кызым, сөйлә! Валлаһи, ачуланмам, минем йөрәгемне бозма.

Шәфыйка. Сез минем этигә сөйләгән сүзләремә ышандыңызмы?

Таһирә. Ни эшләп ышанмыйм? Әллә ялган сөйләгән идеңезме?

Шәфыйка. Әйе!

Таһирә. Ни өчен?

Шәфыйка. Этидән оялдым да, сезнең хәтереңез өчен.

Таһирә. Соң! Этиеңдән оялмасаң, минем хәтеремне сакламасаң, нәрсә сөйләмәкче идең?

Шәфыйка. Хәзерге сүземне әйтмәкче идем... Сөям, әнием.

Таһирә. Кемне?

Шәфыйка. Гатаны...

Таһирә. Кызым! Син әллә шаштыңмы? Ул ни дигән сүз? Әле хәзер генә «ул минем карендәшем» дигән идең. Ничек оста ялганларга өйрәнгән! Ундүрт яшендә бер бала сөю дигән сүзне сөйләп ята! Ярабби! Ни әйтергә дә аптырадым. Юк! Егълама, кызым! Егълама! Кил монда! Кил, яхшы, яхшы гына сөйләшик тә, барысына да бер чара табармыз. Ул бер алдану гына ул, кызым! Бетәр, бетәр!

Шәфыйка. Хәер, әнием, бетми. Мин инде никадәр куәтем булса, барын бер йиргә җыеп бетерергә тырыштым, сездән курыктым, бетмәде. Сез дә бетерүне телисез. Белмим, минем нәрсәмнән курка торгансыздыр? Сезнең морадыңызда минем рәхәтем түгелме?

Таһирә. Кызым, бетәр әле! Ул бер бала бит әле. Паша да бик матур, паша да бик яшь, бары утыз сигездә генә, утыз сигездә, яшь әле, яшь, кызым! Никяхтан соң аңларсың, мәхәббәт никяхтан соң килә.

Шәфыйка. Ник ул кадәр көчлисез? Кызыңызны шулай бер дә кызганмыйсызмени? Үлтерсәңез – риза! Валлаһи, билләһи, пашага барырга риза түгел.

---

Морад – теләк, максат.

Т а һ и р ә. Ярабби! Бу балага да хәлемезне белгертикмени? Зарар юк, сөюне белә, дөньяның хәлен дә белсен, ни зыяны бар? Кызым! Син атаңның әүвәлге дәүләтен беләсеңме? Ниндәй зур бай идек. Белсәң, сүзләремне яхшырак аңлар идең. Хәзердә фәкыйрьләндек, аена утыз тәңкә белән көн кичерәмез. Зарары юк, кичерерсең дә, әмма атаңның биш мең тәңкә бурычы бар, бурыч иясе үлде, хәзердә варислары сорыйлар. Никях була калса, паша сиңа атаңның викселен алып бирмәкче була. Хәзер аңладыңмы инде? Ул кадерле атаңның казаматта ятуына, минем кайгыдан үлүемә, энеләреңнең урамда яланаяк йөрүләренә риза буласың килерме?

Ш ә ф ы й к а. Аһ, әнием! Әнием! Бераз гына сабыр ит, хәлемне җыяем – сезне казаматтан, үлемнән, фәкыйрьлектән мин коткарачакмы? Мине шуның өчен пашага бирмәкче буласызмы? Җаным фида булсын! Риза, моннан соң ни кушсаңыз, шуңар риза. Бары бер генә сөйлисе сүзем бар, кабул итеңез! Минем пашага киткәнемне Гата тоймасын, Алла хакы өчен тоймасын!

Т а һ и р ә. Тойдырмам, кызым, тойдырмам! Син хафаланма, бетәр, җаным, дөньяда һәрнәрсә бетәр. Берничә көннән онытырсың, Алла боерса. Киләчәктә үзең дә сөенерсең, миңа рәхмәт укырсың. Дөньяның һәр хәле узар. Син үзең күңелне юатырга берәр нәрсә тап. Мин урамга чыгам, аннан аларга хәбәр бирермен, викселне алырлар!

Ш ә ф ы й к а. Кит, әнием, кит! Мин үземне ничек тә җиңәрмен, минем өчен хафаланма.

Таһирә чыгып китә.

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ш ә ф ы й к а, соңыннан – Г а т а.

Ш ә ф ы й к а. Уф... Кешенең рәхәте бала вакытта гына икән, аннан соңгысы кабер газабы икән, җәһәннәм уты икән. Китапта мәхәббәтне кем сөйләгән булса да, ялган сөйләгән. Аллаһы Тәгалә мәхәббәтне бәлаләргә каршы бирмәгән, бәлаләрне мәхәббәткә каршы биргән. Аһ! Гата бүлмәсендә ялгыз ятсын да, мин башка бер кешенең куенында ятыймчы? Юк, юк! Тагы гакылым башымнан китә, тагы гәүдәмнең һәр йире калтырый. Мин китим дә, хафасыннан Гатаны үлтеримме? Әнием! Әнием! Юлыңызда гомерем фида булудан мин бик разыймын, бу яшемдә үлү дәрәҗәсендә сөеп тә мәхрүм калуым кемнең күңеленә килер? Гата... Гата... Минем хәлемне ишеткәндә син

ни диярсең? Мең төрле ләгънәтләр әйтерсеңме? Теләсәң ни әйт! Җаным, теләсәң ни әйт! Синнән аерылмакчы булам бит, минем бу кадәр газаплар күргәнемне белсәң, нинди хәлләргә керерсең?

Г а т а (*ишектән керебрәк*). Әллә сезне борчыдыммы?

Ш ә ф ы й к а (*үз-үзенә*). Гата... бер иде, икәү булды. И Раббым! Әллә инде бар газабыңны миндә тәҗрибә кыйлмакчы буласыңмы? (*Гатага.*) Сез хәзер кайдан килдеңез?

Г а т а. Мәктәптән... Сезгә сөенче китердем. Берничә айдан безне бер-беремездән аерырлар дигән идең. Күрик инде, аерырлармы? Җаным, инде мин хәзер кеше булырмын, кичәге имтиханда беренче булып чыктым. Хәлфәләрем һәммәсе, Гата бөтен мәмләкәттә беренче хәким булыр, диделәр. Бу ел комиссия имтиханына мине йибәрәләр. Назыйр әфәнде вәгъдә кыйлды. Дәресләрем беткәч, дварис духторлыгына алачаклар. Караңыз, бу көн дәрес көне була торып, өйгә сөенче итәргә барам дигәч, рөхсәт бирделәр. Шәкертләрдән кайсыларына мондый дәрәҗәләр бирелгәне бар?

Ш ә ф ы й к а (*көчләнеп кенә*). Былтыр бу кадәр үк алда түгел идең.

Г а т а. Былтыр минем сиңа мәхәббәтем болай ук бар идеме? Безнең шикелле уку белән маташучыларга мәхәббәтнең никадәр ярдәм иткәнен беләсезме? Безгә ни рәхәт бар, ни йокы бар, ни дөньяның хәлен тикшерү бар, бары дәрес тә син генә. И, зиһенемә килгән яктылык сурәтең, бөтенләй бер кояш шикелле күренеп, күңелемне яктыртадыр. Аерылганнан бирле өч көн булды түгелме? Бәлки, өч сәгать йокы йоклаганым юктыр. Алай да бер йирем армады. Менә әманәтең дә монда... күңелемнең өстендә... бер мәртәбә йөземә сөртәм... бер мәртәбә исним, иснәгәч, никадәр арган булсам да, яңадан җан кергән шикелле була да, дәресләремә тырышамын, җаным, синең өчен тырышамын.

Ш ә ф ы й к а (*үз-үзенә*). Уф... Таш булу кеше булудан мең өлеш артык икән!

Г а т а. Вакыт уза. Хәлил бәк тиз килми торгандыр. Аннан сөенечне сез алырсыз, мәктәпкә китмичә ярамый, бәлки, ай башына кадәр килә алмам, кеше булырга китәм. Синең хакыңда кеше булам. Синең өчен кеше булып чыгам.

Ш ә ф ы й к а. Гата!..

Г а т а. Ни дисең, җаным?

---

Х ә к и м – укымышлы, галим кеше.

Н а з ы й р – мөдир, идарәче.

Ш ә ф ы й к а (*муенына салынып, йөзен, күзен кат-кат үпкәннән соң*). Бар, җаным, бар! Алла сәламәтлек бирсен! Алла ярдәмчең булсын!

Г а т а. Ни эшләп ул кадәр пошынасың? Бөтенләй аерылачак кеше төсле маташасың.

Ш ә ф ы й к а (*сүзен бүлеп*). Кит! Алла хакы өчен кит, минем хакым өчен кит! (*Үз-үзенә.*) Ярабби, берәр нәрсә табып әйтсәм иде... (*Бераз төзәтенебрәк, Гатага.*) Чыдый алмыйм, берәр эш эшлим, серебез тоелыр. Килмә! Ай башына чикле килмә! Тагы берәр нәрсә телисеңме? Ал! Үп! Теләсәң кай төшемнән үп тә кит!

Гата кайгылы гына килеп кулыннан үбә дә кире чигенә.

И Раббым, мин шулхәтле газапларыңа чыдый торган колыңмени?

Г а т а (*ишектән кире кайтып*). Әлбәттә, синдә бер эш бар, миңа гына сөйләмисең.

Ш ә ф ы й к а. Кит, дим, кит! Әллә, мине сөйләтеп, серләремне сөйләгәнгә үкендерергә тырышасыңмы?

Г а т а. Юк! Пошынма, җаным! Синдә күңелсезлек күргәч, ни өчен пошынмыйм? Алай да һаман муенымны бөгәм, ни кушсаң, шуны эшлим, сөенә-сөенә китәм, менә китәм, менә... киттем.

Ш ә ф ы й к а. Аһ! Бу йөрәгемдәге чәнчүләр мине үлтерер, иртәдән бирле йөрәкләрем парә-парә килеп тора. (*Шыңшып еглап мендәргә каплана.*)

П ә р д ә  т ө ш ә.

## ӨЧЕНЧЕ ФАСЫЛ

Башка бер бүлмә.

### БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Ш ә ф ы й к а, д о к т о р, Ш ә р и ф ә.

Ш ә р и ф ә. Әфәндем! Баланың хәле ничек?

Д о к т о р. Авыр, абыстай! Бик авыр, Алла белер. Ахры, бу көн кич юлчы булыр. Мин гомеремдә мондый каты чихуткә күргәнем юк иде. Егерме биш көн эчендә бичараны бетерде дә китте.

Ш ә р и ф ә. Кичә анасына алай дип әйтмәгән идеңез лә, зарары юк, дигән идеңез.

Д о к т о р. Газиз балаң үләр, ахры, дип, ана булган кешегә әйтергә ничек тел барсын, безнең эшемезнең иң

зурысы да хәстәнең якыннарының күңелен җуату. Белер хәл юк, кайсы үләр дигән кешеләр дә үлми кала, Алла үзе теләгәнен кыйлыр!

Таһирә килеп керә.

## ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әүвәлгеләр, Таһирә, соңыннан – асрау, Хәлил бәк.

Таһирә. Әфәнде! Бер-ике көннән бирле мин баланың хәлен бик яратып бетермим. Көненә өч-дүрт мәртәбә шабыр тир эчендә ята. Йөткерүенең һич очы юк. Аллага тапшырдык инде.

Доктор. Бераз зәгыйфьлеге көчлерәк. Ул сез күргән нәрсәләр бар да шуннан. Бик кайгырмагыз! Яшь кеше, бу яшьләрдә андый авырулар бик күп була.

Таһирә. Бик әлсерәп ята.

Доктор. Юк! Әле хәзер генә бераз изрәде, әле бер ун минут кына бик һәйбәт сөйләшәдер иде.

Асрау (*килеп керә*). Бу квитансә абзыйга икән.

Таһирә (*квитанцияне ача*). Виксел икән. Аңа каршы Шәфыйканең бу хәлдә булуын кем уена китергән. Ярабби! Бу бәлане бездән бүтән төрле алырга да көчең йитә! Һай! Минем бу ике күзләремә туфрак тулган булса иде дә, бу көннәрне күрмәгән булсам иде.

Шәфыйка. Аһ!.. Әни, ул кулыңызда нинди кәгазь? Виксел килдеме әллә? Әлхәмделилла, чиккән мәшәкатьләрем бушка китмәде. Викселне паша йибәргәнме? Яхшы кеше икән, Алла, нинди морады булса, бирсен. Миңа хәзер дә бик зур куаныч булды.

Таһирә. Кызым! Зинһар, андай нәрсәләрне исәпләмә, анаңны бераз кызган! Һай! Алла җанымны алсын!

Шәфыйка. Әнием! Ни өчен үз-үзеңә ул кадәр юк эшләр җурыйсың, безне ятим калдырмакчы буласыңмени?

Хәлил бәк (*ишектән кереп, докторга*). Ничек?

Доктор. Зарарлы түгел.

Хәлил бәк (*аптырап, башын селкеп*). Минем баладан өмидем киселә.

Доктор. Алла сакласын! Сез өйнең хуҗасы булып ул кадәр хафалангач, хатын-кызга ни калды?

Таһирә (*Хәлил бәккә квитанцияне күрсәтеп*). Мәңез.

Хәлил бәк (*квитанциягә күз йөртеп, учында йомарлап җиргә ыргыта да*). Хәерле булсын!

Доктор. Шәфыйка! Иншалла, хәлеңез яхшы булса кирәк?

Ш ә ф ы й к а. Аллага шөкер! Ничек икәнемне сез миннән яхшырак беләсез.

Д о к т о р. Бернәрсәңез дә юк, җаным. Бераз ясдыкка таянып утырмыйсызмы?

Ш ә ф ы й к а. Утырыйм!

Һәркем урын янына килә, ястыкны төзәтәләр.

(*Торып утыра.*) Әти! Бу көн әле мине сөймәдеңез! Шулай кешене үбәргә, кочарга өйрәтәләр дә, соңыннан шулай читтән генә салкын-салкын карап торалармени?

Х ә л и л  б ә к. Сөйдем, җаным, кызым! Машалла, хәзер бераз яхшылангансың. Рәхәтсез түгелсеңдер бит?

Ш ә ф ы й к а. Түгел, әтием! Ясдыкка таянгач, тагы да бераз рәхәтләндем. Шәрифә абыстай, сез дә мондамени? Кара, синең гүзәл Шәфыйкаң ниндәй хәлләргә керде.

Ш ә р и ф ә. Аллага әманәт, җаным! Кәефсезлек... Иншалла, терелерсең. Назик тәннәрең яңадан гөл шикелле булыр.

Д о к т о р (*сәгатькә карап*). Рөхсәт бирсәңез, кайтыр идем?

Х ә л и л  б ә к. Кич белән килерсезме икән?

Д о к т о р. Хаҗәт юк, әфәндем! Кирәкле даруларны язып калдырдым, ничек итеп эчертәсен дә өйрәттем, Аллага әманәт! Шәфыйка ул кадәр янында саклап торырлык ук түгел. (*Үз-үзенә.*) Кич белән килеп аның җеназасын күриммени?

Ш ә ф ы й к а. Сез дә бераз чыгып торсаңыз ярар иде, бераз йоклап алыр идем.

А с р а у. Ялгыз читен булмасмы?

Х ә л и л  б ә к. Кит! Тиле, тагын син борчыма, чыгабыз, кызым, чыгабыз!

Ш ә ф ы й к а. Әни!

Т а һ и р ә. Ни дисеңез, кызым!

Ш ә ф ы й к а. Сез бераз тормыйсызмы?

Т а һ и р ә. Торыйм, ике күзем!

## ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Т а һ и р ә, Ш ә ф ы й к а.

Ш ә ф ы й к а. Беләсезме? Бу көн Гата киләсе.

Т а һ и р ә. Аһ!

Ш ә ф ы й к а. Хәлемне бичарага тойдырмакчы түгел

---

Н а з и к – нәфис.

идеңез, вәгъдәгез хәтереңездән чыкмагандыр бит? Мин бу хәлләргә килеремне белдем дә һаман да вәгъдәмдә тордым.

Таһирә. Тойдырмам, кызым! Һай, нәгъләт төшкән икән, тагы кайдан хәтереңә килде?

Шәфыйка. Мин үземнең хәлемнең авырлыгын беләм. Мине кайда булса да бер йиргә китте диегез. Аны берәр эш белән кайда булса да йибәрегез. Ни эшләсәгез дә эшләгез, бер чара табыгыз! Яныма килмәсен. Тагы бер тапкыр күрә калсам, чыдый алмам, аннан ары сез дә тәкать тота алмассыз, берәр эш эшләрмен. Минем өчен күзеннән бер тамчы яшь чыкканын күрсәм, һич чыдый алмам, үләрмен, йөрәгемне парә-парә итәр дә, үләрмен.

Таһирә. Йибәрермен, кызым! Чарасын табармын, ике күзем. Алла хакы өчен, алай күңелсезләнеп карап, минем йөрәгемне яндырма! Менә хәзер китәм дә әйтеп куям, чарасын табармын. Син бераз ят, бераз гына рәхәтлән, анаң сиңа корбан булсын!

Шәфыйка. Ятам, әнием! Ятам! Сез минем рәхәтем өчен тырышсагыз, минем әйткән сүземнең бер чарасын табыгыз!

## ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Шәфыйка (*ялгыз, бераз торыбрак*). Уф! Йә бүген кич, йә иртәгә бөтенләй аерылырга вакыт җитте. Шулаймы? Доктор мине йоклый дип белде дә Шәрифә абыстайга барын да сөйләде. Бары миңа гына әйтмиләр. Бары эти белән әнигә генә сөйләмиләр. Дөньяда кешене алдалау да бер зур юаныч икән! И Раббым! Колың Шәфыйкагә ахырында да газап бирерсеңме икән инде? Моннан ике ай электә бер кеше минем бүген чихуткә ясдыгында ятып үлүемне сөйләгән булса, ышаныр идем микән? Ничек ышаныйм, бик яшь идем. Мондый чәчәкләр ике-өч көн эчендә шиңә дә китә, мондый кошлар ике-өч ел эчендә һәлак була. Никадәр миннән кечкенә балалар үләдер иде, ул үлем минем башыма килер дип белмидер идем. Әтием атласлар белән төрергә кыймаган бу тәннәр иртәгә катыкаты кәфеннәргә чорналачак!.. Әнием авыртыр дип кысып тотарга кызганган тәннәр иртәгә кара туфракларда ятачак... Гатамның үбәргә кыймаган йөзләрне иртәгә кортлар, чаяннар ашар... Ярабби, атасын казаматтан коткару өчен җанын фида кыйлган колыңа мәрхәмәт кыйл! Ярабби, анасына, карендәшләренә фәкыйрьлек килмәсен өчен кабергә кергән бичараны кызган!.. Аһ! Үлем! Гата-

дан ничек аерылырмын? Аh! Дөньяда да аерым... ахиръткә кадәр аерылу... Иншалла! Үлгәнемне ишеткәч, бәлки, кызганмас. Мине ташлады, Алла да үзен куандырмады дияр дә мине бөтенләй хәтереннән чыгарыр. Аh! Юк... юк... мин Гатадан аерылыйм да, сурәтем дә аерылсынмы? Мин Гата өчен үлим дә, ул мине сүзендә тормады дип уйласын да минем артымнан бер тамчы да күз яше түкмәсенме? Мин Гатаның мәхәббәте белән үлим дә, актык сулуымда, ичмаса, бер мәртәбә йөзен күрмәенчә үлимме? Тиле шикелле, әнигә дә «миңа күрсәтмәгез» дип әйтеп куйдым. Бер мәртәбә йөзен күрим дә, аннан ары, теләсә, мең җаным юлында фида булсын! Аның кочагында үлим дә, аннан ары, теләсә, бөтенләй ахирәттә дә терелтмәсен (терңезмәсен); телим, күрермен, әлбәттә, күрермен! И Раббым! Бераз әҗәлдән сакла, бер минут булса да йөзен күрим, үзеңнең каршыңа нәүмиз итеп китермә. Күзләрем караңгылана, гәүдәмдә куәт калмый. Үлем, үлем яныма якынлаша. Ахры күрә алмыйм, ахирәткә хәсрәт белән китәм. Аh! Әнием! Әнием!.. (*Ястыгына егылыр, һушы китәр.*)

## БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Шәфыйка, Хәлил бәк, Гата бәк.

Хәлил бәк. Кил, угълым, кил! Табендәгә бу арада әллә ни булган аңар! Җүләрләнмәкче була торгандырмы? Ни эшли торгандыр? Иртәдән бирле җыен юк-бар эш белән чугала. Шәфыйка бер йиргә дә китмәгән, угълым.

Гата. Авырумы?

Хәлил. Һәм бик авыр. Карасана, бөтенләй изелеп ята.

Гата. Аh!

Хәлил бәк. Тагы яңа гына кияүгә дә бирдек.

Гата. Кияүгә бирдегезме? (*Үзенә-үзе.*) Баланы үлгерделәр... Баланы мин үлтердем. (*Янына килеп, куәте киткән хәлдә, акрын гына тамырларын тотып карар. Утырып рецепт язар.*) Әфәнде, шуны аптиккә биреп йибәрмисезме? Хәзер ясатсыннар да китерсеннәр.

Хәлил бәк. Йибәрим, угълым! Бәлки, Аллаһы Тәгалә синең аркылы шифа бирер.

Гата. Иншалла, иншалла! Әгәр ни эшли дип сорасалар, тәҗрибә кылып карый дисеннәр. Дару бик куәтле, бәлки, бирмәсләр.

Хәлил бәк. Бик яхшы, угълым! Ярабби! Син хәлемезгә ярдәм ит! (*Чыгып китә.*)

Г а т а (*киемен салып ташлый да*). Газап күрә торган җанга гәүдә нихәтле читен булса, газап эчендә булган тәнгә дә кием шулхәтле читенлек китерә... Мондай ундүрт, унтукыз яшьләрендәге балаларга бу кадәр зәхмәтләр китереп дөнья ни эшләмәкче була икән? Уф!

Ш ә ф ы й к а (*кулларын җәеп, тормакчы булып*). Гата!.. Гата... Аһ! (*Гата янына килеп җитмәс борын янә хәле китеп егылыр.*)

Г а т а (*тамырларын тотып*). Әле... әле тагы бер-ике сулу суласы бар. Агызы уң якка чалшайган... күзләре тонган... Аллаһы Тәгалә авырулыгына да матурлык биргән. Күргән кеше чихуткәсенә дә гашыйк булыр.

Ш ә ф ы й к а. Җаным! Синме? Җаным! Күземә күренәсеңме? Төшем түгелдер бит, көнемдер? Янымда син утыра торгансыңдыр бит?

Г а т а. Шәфыйкам! Җаным! Шәфыйкам!

Ш ә ф ы й к а. Җаным! Тагы никадәр гомерем калды? Сине бер-ике сәгать күрә алырмынмы? Аһ! Хәлем китмәсә иде дә, йөзеңә туйганчы карасам! Туя-туя!

Г а т а. Аллага тапшырдык.

Ш ә ф ы й к а. Ялганламыйм, доктор сөйләде. Бая мине йоклый дип белеп, баш очымда, кичкә йә нитәр, йә йитмәс, җуату кирәк түгел... Синең өчен... аһ... синең янында димәкче идем лә. Синең янында үләм, сөенәм, син саклан, борчылма! Син саклан, җылама! Юк исә мине ахирәттә дә рәхәтсез итәрсең. Саклан, саклан, синең өчен үлде дисәләр, һич ышанма. Авырганлыктан гына. Тәкъдир шулай икән.

Г а т а (*кулына бер кечкенә шешә тотып кергән асраугa*). Китер, тиз бул. (*Шешәне алгач.*) Бар, эшеңә кит! Йөрмә монда! (*Шешәдәге даруны авыруның баш очындагы чынаякка сала.*)

Ш ә ф ы й к а. Ул дару минекеме?

Г а т а. Юк, җаным! И бичара бала! Сине бер карт кешегә бирделәр дә, минем өчен чихуткә булдың, үләсең. Шулаймы?

Ш ә ф ы й к а. Аны сиңа кем әйтте?..

Г а т а. Үзең җан бирергә маташасың, алай да Гатаны кызганасың. Гата хафаланмасын, Гата җыламасын диеп, күңелеңнән һаман җуата торган сүзләр исәплисең. Һәр сулуың тереклекеңнең бер зур кисәген алып китә, әҗәл йөрәкләреңне тетә. Газраил зифа буйларыңны тырнаклары белән каптырган, алай да һаман Гатаны исәплисең. Ахыры, Гатаны синнән соң дөньяда торыр, синең кара туфракларда ятуыңа чыдар дип белә торгансыңдыр, шулаймы? (*Чынаяктагы суны эчә дә, чынаякны җиргә бәреп вата.*)

Ш ә ф ы й к а. Һай, ни эшләдең?

Г а т а. Мин синең юлдашың түгелмени? Юлга хәзерләндем. Кайда, миңа түшәгеңдә урын бир. Курыкма! Кем күрсә дә күрсен, үлем түшәгенә Алладан башка кеше катыша алмас. Минем гомерем синеке кадәрле дә калмады, бары җан биргән вакытта синнән ерак булмыйм!

Ш ә ф ы й к а. Җаным! Гатам! Әллә үзеңне зәһәрләдеңме? Гатам! Бу бәлаләрнең барысы да минем өченме? Кара, күр инде, бу бәдбәхет Шәфыйка синең башыңаниләр китерде!

Г а т а. Мин йөзе кара Табендәнең сүзенә ышанып мәктәпкә киткән булсам, хәзер башыма киләсе эшләр ул вакытны башыма килер иде. Син бер ай туфракларда яткан булыр идең дә, минем аннан һич хәбәрем булмас иде, соңыннан тояр идем дә үземне һәлак итәр идем, балнитсәгә итәрләр иде. Аннан ары синең белән бергә үлү түгел, синең өчен [үземне] үлтерә алмас идем. Безне бер-беремездән аермакчылар идеме? Бу кадәр берләшкән ике күңелне Алладан башка кеше аера алмаслыгын һич уйламаганнар, ахры, Алла да һичбер вакытта аермас. Дөрест, йир өстендә бергә йөрү насыйб түгел икән дә, йир астында ятачак икәнбез... Бу дөньяда берләшә алмаган икәнбез дә, кыяматтә берләшәчәк икән, аның ни аермасы бар? (*Хәйран булып йөзенә карап торганнан соң, кочаклап, төрле җиреннән үбеп.*) Минем өчен татлы җаныңны фида кылдың! Минем өчен кыйммәтле ата-анаңнан аерыласың! Шөкереннән фида кыйлырга үземнең газиз башымнан башка һичнәрсәм юк, ни хәл итим?

Ш ә ф ы й к а. Җаным! Шәфыйка дөньяда синең өчен үлми кем өчен үлсен? Кил! Җаным, дөньяның кайгыларын, хафаларын шул дөньяда ук калдырыйк. Без инде хәзер дөньяның иң актык стансасында мөсафир булдык. Үземезнең мәхәббәтемездән, кавышуымыздан, рәхәтемездән башка бернәрсәне дә исәпләмик! Аһ! Кайда китте безнең бер-беремезгә серләремезне белгерткән көннәр? Дөньяда гомерне теләгәндә, шушындый гомер теләсеннәр. Кайда китте ул синең укыган китабың, мәхәббәтне ничек һәйбәт сөйләгән иде. Кара! Мәхәббәт дөньяның һәрбер мәшәкатьләрен оныттырмыймы? Менә үләмез, безне белгәннәр һәммәсе безнең арттан җылап калырлар. Без көлә-көлә үләбез. Сөйлә! Дөньяда бер-берсен чын ихлас белән сөешкән ике кеше өчен бергә яшәүдән, бер минутта үлүдән дә артык тәмле нәрсә таба алырсыңмы?

Г а т а. Аһ!..

Ш ә ф ы й к а. Ни эшлисең?

Г а т а. Бу агу... Бөтенләй һәр тамчысы бер аждаһа шикелле кубара. (*Күкрәген күрсәтеп.*) Шул төшләремне

кубара... Аждаһа... аждаһа... тешләре утынмыдыр, нидәндер? Тешләгән йирләреннән кан да ага, очкыннар да чәчелә... Аһ! Агу түгел, ут... яндырды... эчемне бөтенләй яндырды, уһ... Ярабби, җәһәннәмне ахирәттән алып, минем йөрәгемә куйдыңмы әллә?

Ш ә ф ы й к а. Гата! Миңа шул хәлләреңне күрсәтер өчен яныма килдеңмени? Болай секунт саен бер мәртәбә мине үлтергәнче кулыңны эчемә тыгып йөрәкләремне кубарып алсаң, мең өлеш артык булыр.

Г а т а. Чү, җаным! Кайгырма! Мин сине ул кадәр җәфалауны телимме? Җиңә алмыйм, әчелеген җиңә алмыйм... Аңла!.. Аңла! Никадәр каты газап... Синең өчен чигәм дә, алай да түзә алмыйм. Синең яныңда чигәм дә, алай да синнән саклый алмыйм, саклый алмыйм! Уһ!.. Иң нечкә тамырларыма хәтле урыннарыннан берәм-берәм кубалар... Купкан саен, бер мәртәбә җан биргән шикелле. Белмисең... Би... Бик куәтле... зәһәр... иде... Уһ! Бүтән ни сорасам, аптикче бирмәгән булыр иде... Бәлки, бирер иде?.. Андый вакытта кем исәпли... Шушы хәтеремә килде... Узар, узар... хафаланма! Үлем хәле... җан ачысы тиз узар... дөнья кайгысы шикелле гомер буена бармас. Уһ! Хәзер дә минем өчен егълыйсыңмы? Күзләрең канланды, күзләреңнең яшьләре тагы тыйлыкмый. Кил! Кил! Уһ!.. Бетте, ни булса да бетте!.. Ачы да калмады, җан да калмады. Күзләрем караңгыланды. Синә карыйм да, һич күрә алмыйм. Үләм! Каршымда син булмасаң, һич сүз дә сөйләмәс идем. Кил, бер мәртәбә сачләреңне исним. Бәлки, гәүдәмә куәт керер дә, йөзеңне бер мәртәбә күреп калырмын... Уһ... Китәм. Артымнан күп торма! Мине... мине көттермә. Уһ!.. Шәфыйкам, үләм. Синең... синең юлыңда үләм. (*Егыла да шул вакытта ук җан тәслим итә.*)

Ш ә ф ы й к а. Гата! Гата... (*Сулуын тыңлый, тамырын тотып карый.*) Китте... китте... Җаным китте... (*Сикереп караваттан төшә.*) Килегез! Килегез!!! Анда кеше юкмени? Ишетмисезмени?

## АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Әүвәлгеләр. Бер-берсе артыннан Х ә л и л  б ә к, Т а һ и р ә, Ш ә р и ф ә, Т а б е н д ә.

Т а һ и р ә. Ни эшлисең, кызым?

---

Тыйлыкмый – тыелмый.

Ш ә ф ы й к а. Караңыз! Әнә... Гата... Гата үзен-үзе зәһәрләде, минем өчен зәһәрләде. Без бер-беремезне сөядер идек. Мин... мин... аныкы... мин аның хатыны, пашаныкы түгел. Пашаның хатыны булмам. Кеше теләсә ни сөйләсен. Икемезне Аллаһы Тәгалә бер-беремез өчен тугъдырткан, тугъдырткан вакытта ук беремезне беремезгә биргән, кияү өйләрен җәннәттә хәзерләгән. Күрәм, менә... менә күзем белән күрәм: кара туфрак түгел, һәр ягына гөлләр тезелгән, һәр ягына... Әтием, кил, бер мәртәбә мине үп, кил, миннән риза бул! Әнием! Әнием! Саклан! Саклан! Минем өчен кайгырмаңыз! Бәлки, минем өчен туй итеңез! Кадерле кызың бүген килен булачак. Менә... менә ирем ята, мине аңар Алла биргән, Алла... Һичкем аера алмас, һичкем Алланың хөкеменә каршы тормас!.. Җаным! Киявем!.. Мине чакырасыңмы? Киләм! Киләм! (*Түшәккә егылып.*) Кара! Кара! Яныңа килдем дә!.. Шәфыйка, ахирәттә дә кемне күрерсең? Барам! Соңга калмам! Курыкма! Курыкма! Аһ!.. Минем шикелле үлү нинди күңелле! Әгәр белсәңез, дөньяда бер минут та торасыңыз килмәс иде. Кара йөзенә! Нинди нурлар! (*Гатаны кочаклап, йөзен иснәп җан тәслим итә.*)

Х ә л и л б ә к (*килеп, тамырларын тотып, сулуын тыңлаганнан соң*). Кызганыч бала! И Раббым! Безгә бу көнне дә күрсәттеңмени? (*Таһирәгә.*) Хатын! Үзеңнең ничек икәнеңне белдеңме инде?

Т а һ и р ә. Куйсана! Зинһар, син дә кешене орышырга вакыт таптың! Кызым бу хәлдә ятканда синең сүзләрең колагыма керерме? Кызым... атасын бурычтан коткару өчен шәһид булган кызым...

Х ә л и л б ә к. Аһ!.. Аһ!..

П ә р д ә т ө ш ә р.

## АҢЛАТМА ҺӘМ ИСКӘРМӘЛӘР

### Галиәсгар Камалның революциягә кадәрге иҗаты

Галиәсгар Камал – «татар драма әдәбиятының атасы, татар сәхнәсе өчен аның башлап тууыннан 16 нчы елларгача үзенең әсәрләре белән зур байлык бирә килгән, «Бүләк өчен», «Беренче театр» кебек комедияләр белән татар әдәбияты тарихында мәңгелек урын алган»* язучы.

Г.Камалның татар культурасы тарихында тоткан урынын Галимҗан Ибраһимов әнә шулай билгеләде.

Галиәсгар Камал 1879 елның 6 гыйнварында (искечә 1878 елның 25 декабрендә) Казанда үз кул көче белән көн күрүче Галиәкбәр Камалетдинов гаиләсендә туган. Үзе авыр хезмәт белән ярлылыкта гомер кичергән Галиәкбәр агай, балаларын да шушы хәлдә калдырмас өчен, төрле юллар эзләп караган һәм моннан котылу юлы бары укуда гына дигән нәтиҗәгә килгән, һәм ул Галиәсгарне, аннан соң аның энеләрен дә мәдрәсәгә биргән. Үзенең кайда һәм ничек укуы турында Г.Камал соңыннан болай яза: «Мин 1900 елга кадәр элек «Госмания», аннан «Халидия», аннан, 1893 елдан башлап «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә һәм аның янындагы русский класста укып, яз һәм җәй көннәрендә китапчы Мөхәммәтҗан Кадыйров дигән кешегә ялланып, Хан, Мәкәрҗә һәм Буа ярминкәләренә барып, кышын шулардан алган хезмәт хакы акчасы белән укыдым»**.

Г.Камал шәкерт чакта ук әдәбият, театр белән мавыга, рус спектакльләренә йөри (ул вакытта әле татар театры булмый). «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә татар мәгърифәтчеләренең йогынтысы бик көчле була, бераздан биредә укыган шәкертләрнең күпчелеге үзләре дә шушы юлда актив эш башлап җибәрәләр. Шулар арасында Г.Камал иң күренеклесе, иң талантлыларның берсе була.

Яшь язучыниләр белән рухланып яши, нәрсәне алга сөрә һәм нәрсәгә каршы чыга – болар барысы да 1898 һәм 1899 елларда язылган «Бәхетсез егет», «Өч бәдбәхет» драмаларының, «Сабир хәзрәт» хикәясе һәм «Кызганыч бала», «Баштан үткән бер эш» исемендәге тәрҗемә әсәрләренең эчтәлекләреннән ачык күренә. Бу әсәрләр Г.Камалның гына түгел, XIX йөз азагындагы татар прогрессив яшьләренең дөньяга карашын, политик позицияләрен өйрәнү өчен шактый киң материал бирә ала. Аларда үз чоры өчен иҗтимагый әһәмияте булган, халык язмышы белән бәйле мәсьәләләр күтәрелә.

---

* Татарстан хәбәрләре. 1921. 6 май.
** Совет әдәбияты. 1931. № 5. 89 б.

Иҗатының башлангыч чорында ук Г.Камал әдәбиятның барлык төп жанрларында үзенең көчен сынап карый. Пьесалар белән бер үк вакытта хикәяләр дә иҗат итә, пьесалар һәм прозаик әсәрләр тәрҗемәли, бераздан шигырьләр яза башлый, әдәби тәнкыйть өлкәсендә эшчәнлеген башлап җибәрә.

Беренче әсәре булган «Бәхетсез егет»тә Г.Камал яңача укучы яшьләрне уңай геройлар итеп күрсәтә. Алар – Г.Камалның үзе кебек үк, театрга йөреп, заманның культурасы белән таныша башлаган, алай гына да түгел, сәхнә сәнгатен яклап, аның файдалы якларын башкаларга аңлата торган алдынгы кешеләр. «Минем театрга бару дигән сүзем бер дә гаеп түгел, анда никадәр гыйбрәтләр бар: начар юлда йөргән кешеләр ниндәен эшләргә очраганын һәм дөньяда ниндәен хурлыкларга төшкәннәрен күз алдында күрсәтәләр». Драманың уңай герое Әхмәт авызыннан әйтелгән бу фикер шул чорда, XIX йөзнең соңында, татар театрын оештыру юлында ясалган беренче адымнар турында рус матбугатында басылган хәбәрләр һәм шул уңай белән барган бәхәсләрнең бер чагылышы булып яшь мәгърифәтченең шушы вакыйгада үзенчә катнашуы, сүз әйтүе иде.

«Өч бәдбәхет» драмасында автор ике туганны – укыган Гомәр белән укымаган Мәхмүдне каршы куеп сурәтли. Гомәр: «Безнең мөселманнар да мәгърифәт тәхсил кылырга тырышырга кирәк иде», – дип белдерә һәм уку-белемнең файдасын мисаллар белән раслый.

«Сабир хәзрәт» хикәясендә исә Г.Камал бу мәсьәләләрне тагы да җитдирәк итеп күтәрә. Хикәядә хатын алу-алыштыру белән мәшгуль Сабир хәзрәт халыкны надан калдыруда төп гаепле кеше итеп күрсәтелә. «Бу хәзрәт мәктәп вә мәдрәсә илә иштигальне файдасыз, биһүдә вә мәшәкатьле санап, һичбер вакыт аның мәхәлләсендә мәктәп булганы юк иде», – ди автор. Хикәянең соңында хәзрәт оятка кала, авылыннан качып китә, тәүбәгә килә, һәм автор аңардан шундый сүзләр әйттерә: «Мөселман кардәшләремә гыйбрәт булсын, анлар милләтләрен онытып, тиешсез эш берлә вакыт качырмасыннар».

«Баштан үткән бер эш» хикәясендә акчага, исәп-хисапка нигезләнеп төзелгән гаиләләрнең таркалуы сурәтләнә; «дөньяда байлыктан да артык һичнәрсә булмаганлыгы»на инанган бер байның фәлсәфәсе фаш ителә.

Акчага табынып, байлык артыннан куып кешелеген югалткан типлар, буржуаз җәмгыятьнең хас сыйфаты буларак, Г.Камал иҗатында зур урын ала, бу тема аның беренче әсәрләреннән үк башлана.

Язучы иҗат иткән тискәре типлар – һәрвакыт акча коллары, аларның бөтен максатлары байлык җыю. Чөнки «Өч бәдбәхет»тәге Мәхмүд сүзе белән әйткәндә: «Акчаң булса, бар да була, бел, аны ул (биредә яучы күздә тотыла. – *Ред.*) булдырмый, акча булдыра».

«Кызганыч бала» драмасында да геройларның язмышы акчага бәйләнгән. Кызганыч бала – Шәфыйка – этисенең бурычларын түләү

---

М ә г ъ р и ф ә т  т ә х с и л  к ы л у – белем алу.
И ш т и г а л ь – шөгыль.
Б и һ ү д ә – буш эш.

өчен, үзен бер карт байга корбан итәргә мәҗбүр була һәм шул кайгыдан авырып вафат була.

Г.Камалның беренче әсәрләре үк татар әдәбиятының алдынгы, халыкчанлык традицияләре рухында язылган. Аларда заманы өчен әһәмиятле иҗтимагый проблемалар күтәрелеп, XIX йөзнең соңында татар җәмгыятендә барган искелек һәм яңалык көрәше үзенчәлекле чагылышын таба.

Әлбәттә, әдәби эшләнеше ягыннан бу әсәрләр әлегә шактый йомшак. Әмма боларда ук инде яшь авторның драматурглык таланты ачык күренә: ул драматик сюжет кору, конфликт һәм диалог төзүдә сәләтен күрсәтә, халыкка аңлаешлы саф татар телендә яза.

1900 елда Г.Камал, имтиханнарны уңышлы тапшырып, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлап чыга. Үзенең истәлекләренә караганда, нәкъ менә шушы елда аңа икенче бер зур сынауны үтәргә туры килә. Заманындагы күпләр уйлаганча, Галиәкбәр агай да, ярлылыктан котылу өчен, улын дин хезмәтенә билгеләргә тели. Әмма атасының күптәнге хыялын җимерү ничек кенә кызганыч булмасын, Галиәсгар мулла булудан катгый төстә баш тарта. Ниһаять, яшь мәгърифәтче шул заман шартларында үзе өчен иң кулай булган һөнәр – китап бастыру һәм тарату эше белән шөгыльләнергә әтисенең ризалыгын ала.

Г.Камалның 1901 елда оештырган «Мәгариф» көтебханәсендәге эшчәнлеге ул чор өчен әһәмиятле бер яңалык һәм зур хезмәт булып тора иде. Монда эшләгән дәвердә ул үз заманының алдынгы кешеләре белән якыная, татар революционерларының эшләренә катнашып китә, үзенең көтебханәсен алар бастырып чыгарган китаплар, брошюра, прокламацияләрне саклау, тарату, төрле урыннарга җибәрү урынына әйләндерә.

Мәсәлән, 1907 елда «Мәгариф» көтебханәсен полиция тентегән вакытта татар большевиклары – «уралчылар» чыгарган «Безнең якында булдырырга теләгән нәрсәләремез һәм төп максудымыз» (Оренбург, 1907. Г.Сәйфетдинов тәрҗемәсе) исемле брошюра табыла. Ул «эчтәлеге буенча һичшиксез җинаятьчел», «яшәп килә торган режимны көч белән бәреп төшерергә өндәүче» дип бәяләнә, һәм шуның өчен Г.Камал хөкемгә тартыла*.

«Мәгариф» көтебханәсенә җитәкчелек итү белән бергә, Г.Камал актив рәвештә журналистика белән дә шөгыльләнә, газета һәм журналлар чыгаруны оештыра. 1906 елда ул «Азат» газетасында эшли, ул тукталгач, үзе «Азат халык» исемле газета чыгара башлый.

Г.Камал бу газетаның нашире генә түгел, үзе дә анда имзасыз мәкаләләре, язмалары белән актив катнаша. Моның шулай икәнен түбәндәге бер фактта күреп була. «Бәянелхак» газетасы «Азат»ның 1906 елның 7 февралендә «Кая китте иреклек?» исемендә чыккан баш мәкаләсен рөхсәтсез-нисез күчереп, үзгәртеп, үзендә бастырып чыгара. Бу уңай белән Г.Камал «Газета караклыгы»** дигән мәкаләдә «Бәянелхак»ның бу эшен фаш итеп чыга, «Кая китте иреклек?» – мин язган мәкалә, аны урлап

* Татарстан дәүләт үзәк архивы. 1 ф. 1 тасв. 504 эш. 78 б.
** ЦГИА. 776 ф. 21 тасв. II бүлек. 71 сакл. б. 3–4 б.

һәм бозып басып чыгарганнар», – ди. Әлеге мәкаләдә Г.Камал азатлыкка, иреккә дан җырлый, үзен шулар өчен көрәшүчеләр сафында күрә.

Шундый рухтагы мәкаләләрне бастырганы өчен «Азат» һәм «Азат халык»ның берничә саны патша цензурасы тарафыннан конфискацияләнә һәм 1906 елда Г.Камал хөкемгә тартыла*.

1914 елда Г.Камал «Йолдыз» газетасында эшләгәндә, аның редакторы булып калган чорларда, патша хөкүмәтенә каршы килә торган мәкаләләр бастыруда гаепләнеп, яңадан судка бирелә**. «Вакыт» газетасында «Галиәсгар Камал эше» исемле мәкаләдә бу судның барышы һәм нәтиҗәсе турында язылa: «Г.Камал әфәндене алты ай крепостька хөкем итәчәкләрен, бу хөкем 16 мартта катгый сурәттә игълан ителәчәген белдерделәр».

Г.Камал – күпкырлы талат иясе. Ул Казандагы беренче сатирик журнал «Яшен»не оештыра һәм әдәбиятта сатирик юнәлешнең үсүенә киң юл ача. Шунда үзе һәм язучы, һәм карикатурист – рәсемнәр төшерүче булып катнаша. Бу журналда Г.Тукайның сатирик таланты ачыла. «Яшен» ябылгач, Г.Камал «Ялт-йолт» сатирик журналында шундый ук юнәлештә эшен дәвам иттерә. Ул татар хәрефләрен камилләштерүдә катнаша, матур язу буенча китаплар чыгара. Театр афишаларын матурлап чыгарырга кирәк булса, аны да Г.Камал эшли. Аның бу өлкәдәге эшчәнлегенең икенче яктан да әһәмияте зур: ул Г.Камалның әдәби иҗатын тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Мәсәлән, «Ялт-йолт»ның 1910 елның 3 нче санында чыккан бер карикатурада соңыннан «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясенең атаклы герое булып киткән Шкафчының тормыштагы прототибы Мөхәммәтҗан карт маймыл, яңалык дошманы, кара көч итеп сурәткә төшерелгән: «Ысул кадимче пивнойда», «Казан Печән базары чатында политика мәҗлесләре», «Шәрекъ» клубында лото-котел уеннары», «Ысул кадимченең... театр илә мөхарәбәсе» кебек үткен карикатураларда да Г.Камал комедияләренең күп кенә образлары һәм күренешләре тасвирланган. Алар әлеге әсәрләрнең шул чорга хас булган типик хәлләрне чагылдыруына өстәмә бер деталь булып торалар.

Нинди генә өлкәдә булмасын, Г.Камал бөтен көчен, зур талантын биреп эшли. Шуларның мөһиме татар милли театрын булдыру эше иде. Бу мәсьәлә шул чорның алдынгы җәмәгатьчелек тарафыннан көн тәртибенә куелган иң зур, культура өлкәсендәге иң җитди чараларның берсе иде. Мәгълүм булганча, бу юлда ике кара көчкә каршы – патша хөкүмәтенә һәм урындагы реакционерларга каршы каты көрәш алып барырга туры килде. Г.Камал бу темага «Беренче театр» исемле махсус комедия, «Безнең шәһәрнең серләре»ндә аерым күренешләрне багышлый, аның тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге дә башлыча шушы темага карый. Мәсәлән, 1913 елда «Аң» журналы шул чорның күренекле эшлеклеләренә «Яңа елда ни телисез?» дигән сорау белән мөрәҗәгать итә. Галиәсгар Камал: «Милли театрыбызның мәдәни бер шәкелгә керүен, хал-

---

* ЦГИА. 776 ф. 21 тасв. II бүлек. 71 сакл. б. 3–4 б.
** ЦГИА. 776 ф. 21 тасв. II бүлек. 87 сакл. б. 33 б.
Мөхарәбә – сугыш.

кыбызның театрга җитди күз белән карый башлавын, театр сәнгате гражданлык алып, уйнаучыларның да, театрга язучыларның да күбәюен һәм камилләшүен телим»*, – дип җавап бирә.

Г.Камал «Сәйяр» труппасында кирәк чагында режиссер булып эшли, артист булып сәхнәгә чыга, үзенең һәм башкаларның әсәрләрен сәхнәләштергәндә, режиссерларга якыннан торып ярдәм итә. Ул татар театры тарихында актерлар династиясен башлап җибәргән чын мәгънәсендәге сәхнә эшлеклесе иде. Аның театр эшенә бирелгәнлек үрнәге энеләре Габдулла һәм Габдрахман, сеңлесе Зәйнәпне дә сәхнәгә алып килде. Соңыннан аның улы Әнәс тә сәхнә эшенә күп көч куйды: драматург булуы өстенә ул сәләтле режиссер һәм артист иде, күп еллар колхоз-совхоз театрларында эшләде.

Г.Камал татар театрын үстерү юлында тагын бер мөһим эш башкарды. Ул, оригиналь сәхнә әсәрләре язу белән генә чикләнмичә, милли театр тарихында зур урын тоткан рус һәм дөнья классикларын тәрҗемә итү эшенә нигез салды. Г.Камал тәрҗемәләренең төп үзенчәлеге шунда: ул күп вакытта эстетик дәрәҗәсе югары булган әсәрләрне генә тәрҗемә итә. Моны күрү өчен ул тәрҗемә иткән әсәрләрнең кайберләрен монда санап үтик: А.Н.Островский – «Яшенле яңгыр» (1914); Мольер – «Саран» (1915), «Ирексездән табиб» (1916), «Скапен хәйләләре» (1924); Н.В.Гоголь – «Ревизор» (1916); Г.Хәмид – «Һинд кызы» (1918); А.Южин-Сумбатов – «Лачыннар һәм козгыннар» (1918); Е.Карпов – «Эшчеләр бистәсе» (1919) һ.б.

Әлбәттә, Г.Камалның классик драматургия белән булган бәйләнеше гади тәрҗемәгә генә кайтып калмый. Иҗатының иң үскән чорында ул классиклар тәҗрибәсенә актив мөрәҗәгать итә, аеруча Н.Гоголь иҗаты белән кызыксына, хәтта аны комедия өлкәсендә үрнәк итеп куя. Бу аеруча И.Богдановның «Помада мәсьәләсе» комедиясе уңае белән язган мәкаләсендә ачык чагыла**. Г.Камалның М.Горький иҗаты белән танышлыгы да бик иртә башлана. Мәсәлән, 1907 елда басылган «Бәхетсез егет» драмасы (икенче варианты)ның 3 нче пәрдәсе «Кояш чыга да, бата да» исемле җыр белән башлана. Юл астында автор «Бәетнең мөхәррире – М.Горький, мөтәрҗиме – Сәгыйть Рәмиевтер» дигән аңлатма бирә.

Кыскасы, XX йөз башындагы татар культурасы өлкәсендә нинди генә әһәмиятле башлангыч яки вакыйга булмасын, ул теге яки бу дәрәҗәдә Г.Камал исеме белән бәйләнгән. Бу сыйфат гомумән шул чорның барлык күренекле эшлеклеләренә хас дияргә мөмкин. Аларның һәммәсен дә социаль тигезлек, милли азатлык, үз халкының һәм барлык башка халыкларның бәхете өчен көрәш рухландыра иде. Г.Камалның бөтен эшчәнлеге, шул исәптән әдәби иҗаты да менә шушы шартларда үсеп, шушы идеаллар белән сугарылган иде.

Г.Камал драматургиядә, нигездә, ике жанрда иҗат итте. Әгәр «Бәхетсез егет», «Уйнаш», «Дәҗҗал», «Каениш», «Көндәш», «Өйләнәм!.. Ник

---

* Аң. 1913. № 22. 379 б.
** Йолдыз. 1907. 19 март.
М ө т ә р җ и м – тәрҗемәче.

өйләндем?» кебек әсәрләрендә буржуаз җәмгыять тудырган фаҗигале хәлләрне һәм образларны гәүдәләндергән булса, «Беренче театр», «Бүләк өчен», «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре»ндә ул шул ук тормышның көлке якларын ачып салды.

«Бәхетсез егет»тә (1907) шул чордагы башка күп кенә язучылар иҗатында чагылган яшь буын проблемасы, аның язмышы үзәк урында тора. 1905 ел революциясе нәтиҗәсендә яулап алынган политик һәм культура өлкәсендәге мөһим казанышлар татар җәмгыятенең яңа чорга, яңару чорына кергәне турында сөйли иде. Бу беренче уңышларны үстерү өчен актив көрәшчеләр, халыкчанлык рухында тәрбияләнгән кешеләр кирәк иде. Югарыда әйтелгәнчә, Г.Камал да мәгърифәтчеләр башлап җибәргән бу көрәшкә үзенең һәм җәмәгать эшчәнлеге, һәм беренче әсәрләре белән катнашып килә. Аны иң элек яшьләр арасында барган хәрәкәтне, көрәшне чагылдырган конфликтлар үзенә тартты. Бер якта яңалыкка, хезмәткә хәзерләнгән, укып белем алу турында кайгырткан алдынгы яшьләр – Әхмәт һәм Гайшә Сабитовлар хәрәкәт итә. Алар иҗтимагый тормышның җитди мәсьәләләре турында уйланалар, татар хатын-кызларының авыр хәле һәм аларның ирләр белән тигезлегенә ирешүе турында кайгырталар, балалар тәрбиясе мәсьәләләрен күтәрәләр. Аларга каршы бөтен яшәешләрен шәхси теләкләргә багышлаган, җәмгыять өчен файдалы эштән бөтенләй читләшкән Закир һәм аның дус-ишләре куела. Закирның әтисе дә әнә шундый: ул җәмәгать эшләренә катнашмыйча гына төрле культура чараларыннан (мәсәлән, мәктәп салырга ярдәм итәргә кирәк булганда) читтә калырга, бары үзе өчен генә яшәргә тырыша. Әнә шул шартларда тәрбияләнгән Закир, тормышта зур максатлары булмау аркасында, җиңел юл белән китә, җинаять эшли һәм һәлак була. Бу яктан пьесаның ике варианты арасында зур аерма бар. Һәм болар драматургның биш-алты ел эчендә нинди юнәлештә үсешен күзәтү ягыннан да бик кызыклы. Беренче вариантта «Закир ниндәй яхшы кешенең баласы иде, начар эшләргә керештe дә ахырда үзен һәлак итте» дип, бөтен гаеп аның үзенә генә кайтарып калдырылса, соңгы вариантта инде егетне шушы хәлгә китергән шартлар башкача ачыла; әтисенең начар үрнәге, әнисенең башта ук тәрбия эшенә бөтенләй җавапсыз караvы, укыту эшләренең рәтсез булуы, гомумән, кешеләрне тирәләп алган мохитнең начар тәэсире – барысы да исәпкә алына. Хәзер инде Закир «ниндәй яхшы кеше баласы» иде дип макталмый. Аның әтисе дә, сәүдәм кала дип, улын авыр хәлдән коткару өчен берни эшләми, ә әнисе, кешеләрдән начар сүзләр ишетмәс өчен, үз улының бөтенләй юкка чыгуына да риза.

Әмма автор Закирны яклау ягында тормый, яшь буынның җаваплылыгын һич тә киметми. Ул аны җанлы характер итеп сурәтли, кайгыларын да, шатлык-өметләрен дә, тискәре һәм уңай якларын да үзенчәлекле детальләр аша күрсәтеп бирә.

Драма Сабитовның халыкка карап әйтелгән шушы сүзләре белән тәмамлана: «Дөньяда баланы бигрәк тә ата-ананың тәрбия кыла белмәве харап итә». Әмма бу сүзләр әсәрдән алынган тәэсирне бөтен тулылыгы белән ачып бетерә алмыйлар. Болай яшәү белән риза булмаган автор аны үзгәртү юлларын да шуның белән генә чикләп куймый. «Бәхетсез егет» драмасының икенче варианты мәсьәләләрне киңрәк ала, нәтиҗәдә

укучы һәм тамашачы Закир кебекләрне юлдан яздырган сәбәпләрнең иң олысы яшәп килгән иҗтимагый шартлар икәненә ачык төшенә.

«Бәхетсез егет» татар драматургиясенең реалистик юнәлештә үсүен күрсәткән әһәмиятле бер әсәр булды. Моны замандашлары ук шулай бәяләде: «Ушбу бер-ике ай эчендә, – дип язды күренекле театр тәнкыйтьчесе Г.Кәрам, – нәшер улынган китаплар арасында хили дикъкать уланы, шөбһәсез, мөкаддәр мөхәррирләребездән Г.Камал әфәнденең «Бәхетсез егет» исемле театр китабыдыр. Кирәк – фикер, кирәк зәмин җәһәтеннән, бу көнгә кадәр нәшер ителгән театр китапларының иң гүзәле вә иң мөкәммәледер. Теле гаять садә вә ләтыйф, вә тасвир итдеге вакыйгасе хәят вә мәгыйшәтемезгә бик якындыр. Әсәр бәгъзе бер сүзләрендә Максим Горькийгә тәкълид итдеге хис улынмактадыр»*.

«Бәхетсез егет» турында башка газеталарда да мәкаләләр басыла. Мәсәлән, 1908 елның башында Уральск шәһәрендә «Сәйяр» труппасы тарафыннан «Бәхетсез егет» драмасы сәхнәгә куелгач, «Әлислах» газетасы түбәндәгечә язып чыга: «Уральскида 12 гыйнварда Г.Камал әфәнденең «Бәхетсез егет» нам пьесасы уйналды... Башта театр уйнатмаска гариза биреп йөргән мөтәгассыйб татарлар, пьесада аталары бирмәгән гүзәл нәсихәтне ишеткәч, ихтыярсыз: «Яшәсен театр!», «Яшәсен яшьләр!» дип кычкырырга мәҗбүр булдылар. Халык бик күп килгән иде»**.

Әсәр әдәби эшләнеше ягыннан да, артист уены өчен материал булара та бик отышлы була. Г.Камал үзе драмага кереш итеп язган «Бер-ике сүз»ендә «Бәхетсез егет»нең яңа вариантын сәхнәдә уйнарга яраштырып эшләвен әйтеп үтә. Һәм, чыннан да, әсәр театр сәхнәсе үзенчәлекләрен күздә тотып иҗат ителгән. «Пьесада пәрдәләр бер-берсеннән нә озын вә нә кыска улып, сәхнәнең техникасына тәмамилә муафикъ уларак тәкъсим вә тәртиб улынмышлардыр... Бундан дәхи мөхәрирнең театр гыйльменә ашналыгы аңлашылмактадыр»***, – дип яза шул ук «Әлислах» газетасы.

«Бәхетсез егет» драмасында куелган проблемалар бер татар җәмгыятенә генә хас булмыйча, башка кайбер тугандаш халыклар сәнгате күтәргән мәсьәләләр белән дә аваздаш иде. Шуның аркасында ул, мәсәлән, азәрбайҗан театры сәхнәсенә дә күтәрелә, шул чорда Көнчыгышта атак-

---

* Йолдыз. 1907. 14 июнь.
** Әлислах. 1908. 21 гыйнвар.
*** Шунда ук.

Хили – байтак, яхшы ук.
Мөкаддәр – хөрмәтле.
Зәмин – нигез.
Садә – гади.
Ләтыйф – матур.
Хәят вә мәгыйшәт – тереклек һәм яшәеш.
Тәкълид – ияру.
Мөтәгассыйб – фанатик, киребеткән.
Тәмамилә муафикъ уларак тәкъсим вә тәртиб улынмышлардыр – тәмам туры китереп кисәкләргә бүленеп эшләнгән.
Ашналык – танышлык.

лы булган артист Х.Араблинский 1909 һәм 1911 елларда аны үзенең бенефисына куя.

Тиздән Г.Камал әсәрләре чит илләргә дә мәгълүм була. 1914 елда «Төрек сүзе» газетасында «Төрек дөньясында театр» исемле мәкаләдә шундый сүзләр язылган: «Шималь төрекләре – татарлар... яңа пьесаларның юклыгына шикаять итәләр. Хәлбуки шималь төрекләренең Галиәсгар Камал кеби халык әдипләренең халык телендә язылмыш бернічә пьесалары Истанбул теле белән язылып, Төркиядә сәхнәгә куелса, йөз мәртәбә уйналса, биля ялыктырмаслар иде»*.

Г.Камалның 1910 елда язылган «Уйнаш» драмасын «Бәхетсез егет»нең үзенчәлекле дәвамы дияргә мөмкин. Бу драмада кешенең бәхет, мәхәббәт турындагы табигый теләкләре белән бөтен нәрсәне сату-алуга корган җәмгыять законнары арасындагы конфликт үзәккә алына. Сәүдәдән башка бернәрсәне белмәгән, бөтен тормышын шуның артыннан куып үткәрә торган Әхмәтҗан, үзенең хатыны Сәрбиҗамалны йорт каравылчысы хәлендә калдырып, читтә йөри.

Ләкин Сәрбиҗамал бу «хезмәт» белән генә канәгатьләнеп яшәргә теләми, аның да кешечә, кешеләр белән аралашып яшисе килә. Әмма бу табигый теләк-омтылыш реаль чынбарлык белән бәрелешкә кереп челпәрәмә килә. Тормыш тәҗрибәсе булмаган, бозыклыклар турында уена да китермәгән беркатлы Сәрбиҗамал оста куелган тозакка эләгә. Азып-тузып йөргән Әнвәр бай, акчага сатылган Мөгълифә ярдәмендә бәхетле, яңача тормышлар вәгъдә итеп, аны алдый, сөяркә итеп тотмакчы була. Әмма Сәрбиҗамал мондый тормышны кире кага. Саф күңелле хатын матур хыяллары җимерелүне бик авыр кичерә, аның язмышы фаҗига белән тәмамлана. Әнвәр исә «акча бетмәсә, Сәрбиҗамаллар бетмәс» дигән сүзләр әйтеп сәхнәдән чыгып китә.

Акча темасы, бөтен җәмгыятьне кулда тотып, кешеләр арасындагы кешеләрчә мөнәсәбәтләрне юкка чыгарган шул «сары шайтан» мәсьәләсе Г.Камал әсәрләрендә төп темаларның берсе иде. Бу драмада да ул бик кискен куелган.

Соңрак язылган «Дәҗҗал», «Каениш», «Көндәш», «Өйләнәм!.. Ник өйләндем?» кебек әсәрләрендә дә Г.Камал буржуаз җәмгыятьнең кешелексезлеген, шул җәмгыять рухы белән сугарылган һәм, димәк, кешелектән чыгарылган типларны сурәтләвен дәвам итте һәм укучыда, тамашачыда шул тәртипләргә каршы нәфрәт, протест тәрбияләде. Бу җәмгыять гади генә бәхетләргә лаеклы кешеләрнең дә тормышын боза, кешеләрне бер-берсенә дошман итә, үзе өчен генә, кеше исәбенә яшәү чире йоктыра.

Г.Камал – татар драматургиясендә комедия жанрының төп идея-эстетик принципларын билгеләп, аңа нигез салган язучылардан берсе. Ул комедиягә зур бурычлар йөкләде, искелеккә, кара көчләргә каршы көрәштә аны әһәмиятле корал дип санады. Менә шуның өчен дә ул бу жанрда язган әдәби әсәрләр белән генә чикләнмичә, Г.Тукай белән

---

* Төрек сүзе. 1914. № 10.

Ш и м а л ь – төньяк.

Б и л я – бер дә.

бергәләп 1908 елда «Яшен» исемендә махсус сатирик журнал чыгара башлады һәм яңалык дошманнарына каршы көрәшне бермә-бер көчәйтеп җибәрде.

«Яшен» журналының беренче саны чыгуын һәм аның идея юнәлешен иң әүвәл Ф.Әмирхан җитәкчелегендәге «Әлислах» газетасы котлады: «Г.Камал әфәнде әсәрләрендә, хосусән «Беренче театр»да үзенең оста көлүче икәнен күрсәткән… мөхәррирдер… Иске тормышның инсанны кыса вә изә торган икәнен татып белгән вә шуны сизә башлаганнан бирле шуңа каршы җивад илә мәшгуль булган затдыр. Ул үзен газаплаган иске тормыштан үч алырга вә аның әшәкелеген башкаларга да ачык күрсәтеп, аннан яшьләрне биздерергә керешкән вә моның өчен дә иң якын юл – көлке журналы чыгаручылыкта күргәндер»*.

Г.Камалның сатира өлкәсендәге эшчәнлеге әнә шулай башлана, һәм аның беренче адымнарын ук җәмәгатьчелек зур кызыксыну белән каршылый.

Г.Камал комедияләре үз чорындагы актуаль мәсьәләләрне, иҗтимагый тормышта булган реаль вакыйгаларны сәхнәгә күтәрүе белән аерылып торалар. «Беренче театр» (1908) комедиясенә язган рецензиясендә Ф.Әмирхан бу үзенчәлекләрне аеруча билгеләп үтә: «Бу комедия нәкъ шул театр мәсьәләсе кайнаган вакытта чыгуы белән бигрәк әһәмиятледер. Татарча театрга мохалиф үз кыланышларын шул ук татар театрында барып күрсеннәр»**.

Театрны булдырмас өчен патша самодержавиесенә татар карагруһлары актив ярдәм иткәннәр. Милли азатлык хәрәкәтенең бер чагылышы булган театрга каршы кара көчләр кулга-кул тотышып бергә барганнар. Димәк, театр өчен көрәшү бер үк вакытта һәртөрле прогресска дин исеменнән каршы чыгучы реакцион көчләрне фаш итү дә иде. Һәм ул татар җәмгыятендәге иске белән яңалык арасындагы каршылыкларны аеруча тирән ачып күрсәтә. Бер төркем Казанның иске фикерле муллалары дин исеменнән театрны тыю турында хәтта 1909 елда да фәтва чыгарып, «Мәгълүмат» журналында бастырып тараталар. Г.Камал бу көрәшләрдә демократик көчләрнең барыбер җиңеп чыгачагына нык ышана һәм әлеге «фәтва»чыларның берсе булган Хәмзәләрнең, ни генә кылансалар да, барыбер юлдан алынып ташланачакларын ачык күрә. «Беренче театр» әнә шул алдынгы көчләрнең яңа уңышлар яуларга сәләтле булуын раслый.

Комедия һәр урында сәхнәдә яратып уйнала, аңа рус җәмәгатьчелеге дә игътибар итә. Мәсәлән, татар культурасының үсешен кызыксынып күзәтеп барган Вл.Гордлевский (соңыннан күренекле академик – тюрколог) «Беренче театр» спектаклен Мәскәүдә күргәч, 1911 елда «Русские ведомости» газетасында махсус мәкалә язып чыга***.

---

* Әлислах. 1908. 14 август (Борһан Шәрәф мәкаләсе).

** Әлислах. 1908. 10 июль.

*** «На сцене идет веселый фарс Камала «Беренче театр» («Первое представление»), списанный с живых лиц, где выведен старик – враг театра. Покатываясь со смеху над бессильной злобой старика, зритель прекрасно сознает жизненность типа». (Русские ведомости. 1911. 29 ноябрь.)

М о х а л и ф – каршы кешеләр.

Х о с у с ә н – бигрәк тә.

И н с а н – кеше.

Җ и в а д – сугыш.

Г.Камалның «Бүләк өчен» (1909) исемле комедиясе реализм юлындагы эзләнүләрнең тагын да бер уңышлы җимеше булды.

Драматург төп игътибарны комедиянең баш герое булган Хәмидәнең эчке дөньясын һәрьяклап ачу, фаш итүгә юнәлтә. Хәмидә – иске гаиләдәге гадәт-тәртипләрнең көзгесе булырдай дәрәҗәдә тулы эшләнгән образ. «Менә шул кыска пьесада Г.Камал... бөтен татар тормышының әсассыз, гаилә башында торучыларның да «мисез» икәнлекләрен күрсәтеп өлгерә. Бу китаптагы татар хатыны – тәмам тәмамилә безнең тормыштагы гаилә бәхетсезлегенең башлыгыдыр. Ул үзенең тәрбиясезлеге белән баласының бәхет-сәгадәтенә тырышачак урында юк кына нәрсә өчен аның бөтен сәгадәтен җуярга хәзер тора. Ни өчен? Әйтергә дә оят: бер асыл күлмәк өчен!.. Гомумән алганда, Г.Камал әфәнденең бу әсәре дә хәзерге татар галәмендә беренче комедиялардән саналырлык булып чыккан...»* Г.Камал әсәрләренең барысына да төпле фикерләр әйтеп килгән К.Бәкер комедиягә әнә шундый бәя бирә.

Г.Тукай драматургның әдәби эшчәнлегенең 10 еллыгын (1910) бәйрәм итү уңае белән язган мәкаләсендә, аның шуңа кадәрге хезмәтләренә тирән анализ ясап, «Бәхетсез егет» белән беррәттән «Бүләк өчен»дәге Хәмидә образын әдәби эшләнеше ягыннан үрнәк итеп куйды. Ул, «Бүләк өчен» комедиясенең сәхнә тарихына, аның тамашачыга ясаган тәэсиренә игътибар итеп, болай ди: «Бүләк өчен» уйналып пәрдә төшкәч, бөтен халык күңелендә бу уеннан калган гүзәл бер хис аларны үз-үзләрен бөтенләй онытттырганга, бөтен залга тәбрик һәм кул чабу тавышлары яңгырады»**.

Әлбәттә, «Бүләк өчен», «Беренче театр» әсәрләрендәге күренешләр тамашачыны көлдереп кенә калмаган. Моны Ф.Әмирханның «Бүләк өчен» әсәрен берничә еллар буе сәхнәдә күреп килгәннән соң язган сүзләре бик ачык күрсәтә. «Мөхәррирнең урта кул Казан татарлары тормышын, хосусән бу сыйныфның хатын-кыз тормышын бик яхшы белүе бу комедиядә бик ачык күренә. Моны караганда көләсең, ләкин бу көлү җиңел вә шаян көлү түгел, бәлки авыр вә кайгылы көлү»***.

«Беренче театр» һәм «Бүләк өчен» Г.Камалның сатирик талантын башлап ачкан әсәрләр булып, моннан соң язылган «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре» кебек зур күләмле комедияләренә кереш хезмәтен дә үтиләр иде. «Беренче театрда иҗтимагый эшчәнлек өлкәсендәге тискәре күренешләр сурәтләнә башлаган булса, «Безнең шәһәрнең серләре»ндә бу тема бөтен киңлеге белән ачылды, ә «Бүләк өчен»дәге һәрнәрсәне үз теләкләренә буйсындырырга омтылучы дуамал Хәмидәдә тупланган тискәре сыйфатлар «Банкрот»тагы Сираҗетдин образында символ дәрәҗәсенә күтәрелердәй бер бөтенлек алды.

Г.Камал әсәрнең нигезенә үз чорында һәм кайбер дәүләтләрдә хәзер дә бик нык таралган күренешне – бөлү, банкротлыкка очрау вакыйгасын алып, бу вакыйганы башка бик күпләр язганча (әйтик, А.Н.Ост-

---

* Йолдыз. 1909. 23 сентябрь.
** Г.Тукай. Әсәрләр. 1977. 4 т. 93 б.
*** Йолдыз. 1912. 21 октябрь.
Әсассыз – нигезсез.

ровскийның «Үз кешеләр – килешербез» әсәрендәге кебек) фаҗига планында түгел, бәлки сатира, мыскыллап көлү планында хәл итә. Шул нигездә ул гаҗәп оригиналь, үзенчәлекле сюжет төзи. Г.Камал башта ук, вакыйгада катнашучыларга кыскача характеристика биргәндә, Сираҗетдин Туктагаевның бер төп сыйфатын әйтеп китә: «Сираҗетдин Туктагаев – заһирдә бик суфи күренә торган сәүдәгәр». Комедиядә менә шушы үзен динле, изге, әдәпле кеше дип таныткан, шул җәмгыятьнең терәге булган типның чын йөзе ачыла. Ул чынында зур аферист, комагай, икейөзле, алдакчы кеше булып чыга; башын диванага салып, башкаларны да шуңа ышандыру өчен, әллә нинди түбәнлекләргә тәгәри, өйдә генә түгел, урамнарга чыгып йөри, тирә-якка фаш була. Мәгълүм булганча, әсәрнең төп өлешендә Сираҗетдин акылдан шашкан итеп күрсәтелгәнгә, ул башка персонажлар белән бәйләнешкә керә һәм сөйләшә алмый. Әмма автор аның характерын ачу өчен бу күренешләрдә драматургиядә кабул ителгән бүтән алым куллана: ул Сираҗетдиннан «үзалдына», «читкә карап» сүз әйттерә, шунда аның эчке кичерешләре дә, максатлары да ачыла бара. Ул вакыйгаларга үзенчә катнаша, аларга аңлатмалар бирә, яңа хәйләләр кора. Сираҗетдин үз җәмгыятендәге тәртипләрне, гадәтләрне бик яхшы белеп эшли, ул шуларга таяна һәм ялгышмый. Мәсәлән, авыруны доктор расларга тиеш. Шул вакытта гына Сираҗетдин уенны отачак. Үзенең авыруын тикшертеп кыланган вакытта, доктор белән ул бик тиз уртак тел таба – җаен туры китереп, аңа зур акча төртә. Докторның исә моңа исе дә китми. Димәк, ул инде аңа өйрәнгән. Бу моментта бернинди гаҗәпләнү, көтелмәгән хәлдән аз гына вакытка булса да аптырап калуның эзе дә юк, бөтенесе алдан ук килешеп куелган кебек бара. Менә шулар әлеге тәртипләрнең бик нык урнашкан икәнен аеруча оста ача да.

Комедиянең финалы төп фикерне тагы да көчәйтә. Әсәр Сираҗетдинның кинәт терелүе белән тәмамлана. Менә шушы кеше ышанмаслык тизлек белән терелү тарихы җәмгыятьнең асылын тагын да тирәнрәк гәүдәләндерә: биредә бар нәрсәне сатып алып була; намус, вөҗдан кебек төшенчәләр онытылган, кешеләр түбән җанга әйләнгән, һәммәсе күрәләтә алдауга корылган, бу – тормыш законы булып әверелгән.

Комедиядә шул чорның чынбарлыгы, төрле төркемнәрнең уй-теләкләре, мохите дә киң сурәтләнә. Болары күбрәк хатын-кызлар катнашкан күренешләрдә ачыла. Алар хәбәр иткән күптөрле мәгълүматлар нигезендә шәһәр сәүдәгәрләренең җанлы тормышы алга килеп баса. Шул җөмләдән андагы гаилә мөнәсәбәтләре дә, туганлык, дуслык, ир-хатын арасындагы бәйләнешләрнең дә үтәдән-үтә ялган нигезгә корылган булуы ачыла.

Шушы хәлләргә төшеп, түбәнлекләрнең чигенә җитеп алынган акчалар нигә, нинди максатларга хезмәт итәчәк соң? Автор бу мәсьәләне бик әһәмиятле дип исәпли һәм аңа аерым игътибар итә. Комедиянең финалында, бөтен вакыйгаларга үзенчәлекле нәтиҗә ясап, ул Сираҗетдинның үзеннән бу сорауга менә нинди җавап бирдерә: «Эш пеште! Бер

---

З а һ и р д ә – тыштан караганда.

минут эчендә йөз дә сигез мең сум файда! Хатынны җибәрәм, яшь хатын алам, йорт салам, афтамабил алам. Типтерәм дөньясында!»

Г.Камал, мондый режимның нигездән череклеген, халыкка дошман булуын күрсәтеп, демократик көчләрнең протест тавышына кушыла. Менә шул сыйфатлар аркасында «Банкрот» әсәре әдәбиятта югары идеялелек, реализм өчен барган көрәштә, яңа гына ныклап аякка басып килгән театрлар репертуарында да иң зур урынны алып, милли сәхнә сәнгате үсешендә күренекле роль уйнады.

«Банкрот» белән бер чорда «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясе языла. Автор киң иҗтимагый күренешләрне, кайбер төркем кешеләрнең яшәү, баю юлларын яшерү өчен төзелгән һәм, шулай булгач, сатира өчен аеруча күп материал бирә торган төрле «җәмгыять»ләрнең, «комитет»ларның ишеген ача.

«Безнең шәһәрнең серләре» композицион яктан драматургның башка әсәрләреннән аерылып тора. Автор һәр пәрдәгә аерым исем биргән, димәк, аларны һәрберсен мөстәкыйль әсәр дәрәҗәсенә куйган һәм шуңа ярашлы рәвештә сюжетын да төзегән. Комедиядә вакыйгалар барысы да җәмәгать урыннарында бара. Һәм аларның төп асылын сәнгатьчә гәүдәләндерү өчен шушы мохиттән алынган бер яки берничә иң характерлы образ-тип күрсәтергә кирәк була. Чөнки һәр оешманың үз герое гына ул оешманы тулы килеш күз алдына бастыра ала. Әсәрнең композициясе, менә шушы таләпләргә буйсындырылып, үзенең бурычын бик уңышлы үти. Кешеләр монда тулысынча корсак өчен генә яши торган хайванга әйләнгән; яңалыкка, белемгә, матурлыкка омтылу яки иҗтимагый интереслар – алар өчен чит нәрсә. Сираҗетдин кебек, бу әсәрнең «каһарманнары» өчен дә бер генә изге нәрсә дә юк. Алдашу, урлашу, мораль таркалганлык – боларның барысы өчен дә уртак сыйфат. Мәсәлән, «Җәмгыяте хәйрия»гә гадел кешеләр, кеше хәленә керә белә торган затлар сайланырга тиеш. Г.Камал, реаль чынбарлыктан алып, аларны иң түбән әхлаклы бәндәләр итеп сәхнәгә чыгара.

«Безнең шәһәрнең серләре»ндәге иҗади ачышларның берсе шкафчы Әхмәтҗан образы белән бәйләнгән. Драматург бөтен искелек, кирелекнең символы булып әверелгән һәм Печән базары дигән исем белән тарихка кергән социаль күренешне шушы образ ярдәмендә сәхнәгә чыгара. Әхмәтҗан образының прототибы булганлыгы мәгълүм. Ул – Печән базары чатында сату итүче Мөхәммәтҗан Хафиз Әхмәдев дигән кеше. Бу бәндә үзенең реакционлыгы, кабахәтлеге белән дан алган. Февраль революциясеннән соң аның патша охранкасы провокаторы булып торганы фаш ителә. Ул – татар театрын тыйдыру өчен дә күп йөргән кеше.

Г.Тукай иҗат иткән Кисекбаш образы никадәр явызлык һәм әшәкелекне үзенә туплаган булса, Г.Камалның Әхмәтҗаны бер ягы белән дә аңардан калышмый. Г.Камал аны сәүдәгәр итеп кенә түгел, искелек сакчысы итеп тә күрсәтә, башкалар аңа «мулла Әхмәтҗан» дип дәшә, һәм ул чынлап торып дин сафлыгы өчен көрәшүче булып кылана. Әмма ул үзе бик түбән, бозык адәм. Әхмәтҗанның зур политика турында олы кыланып, һаваланып сөйләгәннәре бу образның сатирик яңгырашын тагын да көчәйтәләр. Менә шундый икейөзле типлар, әсәрнең беренче пәрдәсендә күренгән Фатих, Насыйр, әлеге Әхмәтҗаннар тышкы яктан

суфи булып күренергә газапланганда, бигрәк тә көлке, чын сатирик образ булып алга басалар.

Комедиядә революциягә кадәрге татар буржуа җәмгыятенең нинди хәлдә булуы, кемнәрдән гыйбарәт икәнлеге, нинди максатлар тотып яшәве һәм хезмәт халкына ни дәрәҗәдә чит, дошман булганлыгы тулы ачыла. Г.Камал бу әсәрендә дә игътибарны социаль мәсьәләләргә юнәлтә. Әсәрнең реаль тормыштагы вакыйгалар белән бәйләнгән булуы аның әһәмиятен тагын да арттыра. Үз әсәрләренең шушы үзенчәлеге турында Г.Камал соңрак болай дип белдергән иде: «Тамашачылар, типларның тормыштан алына икәнлеген аңлап алып, мещан һәм татар сәүдәгәрләре арасындагы төрле яшерен серләрне миңа ташый башладылар. Яшерә алмыйм, язган нәрсәләремнең күбесендә мин шулардан файдаландым». Әлбәттә, болар барысы да Г.Камалга үз әсәрләрендә заман сулышы белән сугарылган, тормышчан, чорының актуаль мәсьәләләрен күтәреп чыгарга ярдәм итә.

«Безнең шәһәрнең серләре» 1911 елның 11 ноябрендә «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәгә куела һәм шуннан соң репертуардан төшми уйналып килә.

Комедия сәхнәгә куелгач, реакцион көчләр бердәм тавыш күтәрәләр, авторы Г.Камалга каршы төрле провокацияләр, турыдан-туры һөҗүмнәр оештыралар; барлык «прототиплар» (Мольерча әйткәндә, оригиналлар) баш калкыта, сәхнә политик көрәш аренасына әйләнә. Г.Тукай, Г.Ибраһимов үзләренең мәкаләләрендә «Безнең шәһәрнең серләре»н Печән базары Казанының көзгесе дип, аны реаль чынбарлыкны дөрес сурәтләгән, югары идеяле, сәнгать ягыннан оста эшләнгән чын реалистик әсәр дип бәяләделәр. «Галиәсгар Камал әфәнде татар тормышының начар җирләреннән көлүендә дәвам итә, – дип язды Г.Ибраһимов. – Ул бу елларда мөтәхәссис драматург кыяфәтенә кереп бара. Бер-бер артлы әсәрләре агыла. Сәхнәдә һәрбере кульязмадан ук куела башлап, туктаусыз бара бирә. Ул бу ел үзенең «Безнең шәһәрнең серләре» илә бөтен дөньяны көлдерде»*.

Г.Камал драматургиясе татар әдәбияты һәм театр тарихында реализм принципларының ныгуына зур өлеш кертте. Аның әсәрләрендәге образларны уйнап, берничә буын татар артистлары сәхнә осталыгына өйрәнделәр.

Г.Камал иҗатының иң әһәмиятле үзенчәлеге аның заман рухы белән тирән сугарылган булуында һәм халыкчанлыгында. Моны үз чорының матбугаты, тәнкыйте, күренекле язучылары аның һәр яңа әсәре чыккан саен бертавыштан әйтә киләләр, шушы сыйфатлары өчен аларны хуплап каршылыйлар, ә театр труппалары исә һичбер кичекмәстән үз репертуарына ала баралар.

Г.Камал иҗатының һәм иҗтимагый эшчәнлегенең шушы сыйфатын иң башлап Г.Тукай бәяләде. Ул 1910 елда Г.Камалның әдәби һәм җәмәгать эшчәнлегенә 10 ел тулу уңае белән болай дип язды: «Г.Ка-

---

* Йолдыз. 1912. 22 гыйнвар.

Мөтәхәссис – оста.

мал – «гаммәи халык алдында күп сәнәләр хезмәт иткән бер кеше», «эше халык файдасына булды».

Г.Камал карашынча, аның әсәрләрендә чагылган тормыш мәңгелек түгел. Ул мондый тормышның үзгәрәчәгенә, әлеге типларның бетәчәгенә, җәмгыятьнең прогрессына ышанып карый һәм бу турыда ачыктан-ачык язып чыга: «Заманнар узган саен, халыкның табигате, әлбәттә, башкачарак. Бу көндәге кыяфәтләр бетеп, аның урынына икенчеләре киләчәктер»*. Дөрес, Г.Камал әлеге үзгәрешләргә тигезлеккә бару юлларын халыкның табигате үзгәрү белән бәйләп карау ягында тора. «Башкача» тормыш киләчәгенә ышану, шуны якынлаштыруга үзенең бөтен эшчәнлеге һәм иҗаты белән булышу Г.Камалны заманының алдынгы көрәшчеләре сафына куя иде. Октябрь революциясе һәм Гражданнар сугышы чорындагы эшчәнлеге белән Г.Камал күңеленең кемнәр ягында булганлыгын тагын бер кат бик ачык итеп күрсәтте.

Г.Камал әсәрләренең эчтәлеге тормыштан, үз заманы өчен типик булган вакыйгалардан алынган. Шушы мөһим сыйфатлары аркасында, Г.Камал иҗаты XX гасыр башындагы татар драматургиясенең идея-эстетик принципларын билгеләп, шул чорның бөтен әдәби процессына зур йогынты ясый.

Алдарак әйткәнчә, Г.Камал күп кенә әсәрләренең эчтәлеген тормышта булып үткән чын вакыйгалардан алган. Бу алымның бигрәк тә драматургиянең һәм театрның башлангыч чорында кулланылуы бик табигый. Чөнки әле язган китапның, куелган спектакльнең һич тә дөньяда булмаган, уйлап чыгарылган бер нәрсә түгел, ә чын тормыш көзгесе икәнен исбат итәргә дә кирәк иде. «Беренче театр», «Безнең шәһәрнең серләре» кебек комедияләрендә Г.Камал тормыштагы прототипларны сәхнәгә күтәреп, әнә шул максатларны да күздә тота иде. Аның әсәрләре кайбер урыннардагы конкрет кимчелекләрне камчылау өчен корал итеп файдаланылган. Бу исә әсәрнең реаль тормышка нигезләнеп язылган булуын раслый торган факт, һәм мондый хәлләр бөтен җәмгыять өчен әһәмиятле булган вакыйгалар сурәтләнгәндә генә мөмкин.

Шулай итеп, Г.Камал иҗаты XX йөз башындагы алдынгы татар әдәбиятына хас булган халыкчанлык, реализм һәм замандашлык рухы белән сугарылган булып, милли культура тарихында, аеруча театр сәнгатен үстерүдә әһәмиятле урын тота һәм совет чорында, яңа культура төзегәндә аның традицияләре, ул иҗат иткән рухи хәзинә уңай роль уйнавын дәвам итә.

Әдәби иҗатында зур активлык күрсәтү белән бергә, Г.Камал җитди теоретик эзләнүләр дә алып бара, матбугат битләрендә яңа реалистик сәнгать өчен көрәш җәеп җибәрә.

Аны аеруча берничә мәсьәлә кызыксындыра. Шулар арасында заман темасы һәм реализм мәсьәләләре, комедия жанрының үзенчәлекләре турындагы фикерләре аеруча игътибарга лаек.

Г.Камал үзенә кадәр барлыкка килгән комедияләрне күздән ки-

---

* Йолдыз. 1908. 19 март.

Гаммәи халык – халык массалары.

Сәнә – ел.

черә, аларның төп принципларын билгеләргә тырыша. Ул татар теленә тәрҗемә ителгән «Ревизор», «Өйләнү» (Н.Гоголь), «Кыз сорау» (А.Чехов) кебек күренекле әсәрләрне аерым урынга куеп карый. Әмма әсәрләр арасында уртакул, юктан көлдерү өчен генә язылганнары да күп, һәм алар еш кына театрлар репертуарына да килеп керәләр. Шуларның характерлыларыннан берсе булган «Хат болгатты» исемле водевильне алып, Г.Камал аңа шундый бәя бирә: бу әсәрне куюдан максат тамашачыларны көлдерү булганлыктан, театр бу максатка ирешә ирешүен, әмма бу көлү мәгънәле көлү түгел. Мондый комедияләргә каршы автор шул вакытларда татар телендә басылып таралган, югарыда әйтелгән тәрҗемәләр белән бергә үзенең замандашлары И.Богдановның «Помада мәсьәләсе» комедиясен, Г.Коләхмәтевнең «Яшь гомер»ен һәм Ф.Әмирханның «Яшьләр» драмасын үрнәк итеп ала. «Помада мәсьәләсе» комедиясе турында язганда, Г.Камал Гогольнең «Ревизор» һәм «Өйләнү» исемле комедияләрен хәтергә төшерә. Бу ике әсәрне ул тәнкыйть ителергә тиешле булган типларны камил осталык белән һәрбер типның килешмәгән җирләреннән көлә белеп көлгәне өчен югары бәяли. «Яңа мөхәррирләребездән Идрис әфәнде Богдановның язган «Помада мәсьәләсе» исемендәге комедиясе дә, – дип дәвам итә Г.Камал, – минем каршымда шуңар мөшабиһдер. Бу комедиядә, кеше көлдерер өчен дип, һичбер урынсыз сүзләр язылмаган. Ләкин комедиядә тасвир ителгән кыяфәтләрнең һәрберсенең табигать вә кыланышлары һәм шул кыланышлары өстенә үзләренең үзләренә бик зур хөсне заннары илә сөйләгән сүзләре һәм гарыз кыйлган фикерләре хәкыйкатән дә көленечтер»*.

Аның карашынча, эшләре, сүзләре һәм табигатьләре белән көлке булган типлардан көлү – чын комедиянең бурычы.

Г.Коләхмәтевнең «Яшь гомер» драмасына карата язган мәкаләсендә исә Г.Камал драматургиядә характерлар типиклыгы, характерлар реализмы турында сөйли. Мәсәлән, Гали белән Зөләйха мөнәсәбәтләрен тикшереп, ул алар арасындагы мөнәсәбәтләрдә типиклык күрми, берсенең белемле интеллигент, ә икенчесенең иске карашларда катып калган гади бер бай кызы булуы болар арасында иптәшлек, дуслык хисләре туугa комачауларга тиеш дип белдерә. Ә инде Вәли белән Йосыф образларының язылышына Г.Камалның карашы башка. Ул аларда социаль анализ ягыннан анык эшләнгән образлар күрә, аларны «тәмам тәмамән бер сыйныф халыкка хезмәт итүчеләр» дип бәяли; икенчедән, аларның «җанлы сурәтләр» булуын билгеләп үтә, индивидуаль сыйфатлары булуын аерым алып күрсәтә. Шуңа мисал итеп Йосыфның участокта кыланышлары, Гали өендә чакта үзләренә дошман берәүне кыйнаугa шат-

---

* Г.Камал. Әсәрләр. 1951. 2 т. 218 б.
Мөшабиһ – охшый.
Кыяфәт – монда: «образ» мәгънәсендә.
Хөсне зан – үзе турында матур фикер.
Гарыз кыйлу – әйтү.
Хакыйкатән – чыннан да.

лану күренешләрен китерә, болар «бик урынлы, бик табигыйдер» дип өсти*.

Шулай итеп, әдәби әсәрдән иң башта тормышчанлык, «вакыйгъга татбигъ», «вакыйгъга мотабикъ» булу, «табигый булу» таләп ителә, шулар үлчәү итеп алына.

Бу мәсьәлә Ф.Әмирханның «Яшьләр» драмасы басылып чыгу уңае белән яңадан күтәрелә, типларның тормыштан алынган булуына аеруча игътибар ителә: «Хикәянең тасвиры хили гүзәл, һәм анда тасвир ителгән яшьләрнең типлары бу көндә Казанда мәүҗүд типлардыр. Хәтта һәр язылган әсәрләрне «бу фәлән кеше хакында язылган икән» дип тәэвил кыйлырга яраткан кешеләргә «бу фәлән бай балалары хакында язылган икән» дип әйтерлек дәрәҗәдә якын тормыштан алынган типлардыр...»**

Г.Камалның турыдан-туры театр сәнгатенә, актерлык эшчәнлегенә караган хезмәтләре дә аерым игътибарга лаек. Аның реалистик театр сәнгате өчен алып барган көрәше үз чоры өчен бик әһәмиятле роль уйнады һәм фикерләренең күбесе бүген дә әле үзләренең актуальлеген җуймаганнар.

1929 елның язында җәмәгатьчелек Галиәсгар Камалның илле еллыгын хөрмәт белән билгеләп үтә. Шуңа багышланган кичәдә чыгыш ясап, Г.Камал сүзен шулай тәмамлый: «Мин язган чакта әсәрләремнән болай зур мәгънәләр чыгарырлар дип уйламаган идем. Мин күңелемә нәрсә килсә, шуны яздым. Шулай да тормыштан читкә чыкмаска тырыштым»***.

Г.Камалның әнә шулай «тормыштан читкә чыкмыйча» язылган реалистик комедияләре һәм драмалары, ул нигезләгән традицияләр татар драматургиясен үстерүгә зур уңай йогынты ясадылар. Аның бу әсәрләре, Октябрь революциясеннән соң иҗат ителгәннәре белән бергә, татар совет әдәбияты һәм культурасы тарихына зур мирас булып керәләр, аның нигезен тәшкил итәләр.

*Бәян Гыйззәт*

---

* Йолдыз. 1908. 5 май.
** Г.Камал. Әсәрләр. Казан, 1951. 2 т. 239 б.
*** Кызыл Татарстан. 1929. 21 апрель.
Вакыйгъга татбигъ – тормышка чагыштырылу.
Вакыйгъга мотабикъ булу – тормышка туры килү.
Хили – бик.
Тәэвил кыйлу – юрау.

**Драма һәм комедияләр**

9 бит.

**Бәхетсез егет.** Драманың беренче варианты 1898 елда язылып, 1900 елда Казанда Кәримевләр типографиясендә басылган. Автор аны 1907 елда яңадан төзәтеп эшләгән, һәм ул шул ук елның җәендә Казанда «Мәгариф» көтебханәсендә аерым китап булып басылып чыккан. Соңыннан «Г.Камал әсәрләре»нең 1925, 1929, 1935, 1942, 1950, 1969 елгы басмаларына кергән.

Төзәтелгән беренче басмасына (1907) автор тарафыннан түбәндәге сүз башы бирелгән:

**«Бер-ике сүз**

Моннан тукыз ел мөкаддәмдә «Бәхетсез егет» намендә театру тарзында бер рисалә язып, исемсез уларак нәшер идтермеш идем. Тиздән театрулар уйналыр вә театру тарзында язылан әсәрләр мәукыйгы тамашага куелыр өмидләре ул вакытларда юк иде; шул сәбәптән мәзкүр рисаләме мәукыйгы тамашая вазгы идәрлек дәрәҗәдә итеп язу хәтеремә биля кәлмәмеш иде. Шимди бу сәнәдә татарча театрулар башланды. Бер кәррә фикреме сарыф кыйлмыш улдыгым шу әсәр бәсбөтен мәйданнан югалмасын диярәк, рисаләмне ислях идәргә керештем вә шимдики хәленә китердем. Ибтидасыннан тукыз сәнә кәчтекдән соңра, мәзкүр әсәреме икенче мәртәбә кариэләремә гарыз идәргә муаффәкъ булдым. Әсәрем кариэләре вә тамашачылары гыйндендә мәкъбүл улырмы, юкмы – у кадәресе мөстәкъбальдә күреләчәктер.

*Г.Камал».*

Заманының вакытлы матбугаты әсәрне бертавыштан уңай бәя биреп каршылый. Шулар арасында Г.Кәрам (Йолдыз. 1907. 24 июнь), К.Бәкер («Казакъ») («Әлислах» 1908. 15 сентябрь), Татарин-театрал (Волжско-

---

Мөкаддәмдә – элек.
Намендә – исемендә.
Театру тарзында – «пьеса формасында» мәгънәсендә.
Рисалә – әсәр, китап.
Нашер идтермеш – бастыру.
Мәукыйгы тамашага – сәхнәгә.
Мәзкүр – бу.
Вазгы идәрлек – куярлык.
Биля – бер дә.
Шимди – инде, хәзер.
Сәнә – ел.
Кәррә – кат, кабат.
Фикреме сарыф кыйлмыш улдыгым – уйлаган.
Бәсбөтен – бөтенләй.
Ислях идәргә – төзәтергә.
Шимдики – хәзерге.
Ибтидасыннан – башлануыннан.
Кәчтекдән – үткәннән.
Кариэләремә гарыз идәргә муаффәкъ булдым – укучыларыма тәкъдим итүгә ирештем.
Гыйндендә мәкъбүл – алдында кабул ителгән.
У кадәресе мөстәкъбальдә – ул кадәресе киләчәктә.

Камская речь 1908. № 143), Г.Тукай (Йолдыз. 1910. 22 ноябрь) мәкаләләре, Бакуда чыккан «Баку» (1911. 10 июнь), «Каспий» (1911. 12 июнь) газеталарында материаллар һәм хәбәрләр басыла. Имзасыз басылган мәкаләдә «Вакыт» газетасы (Оренбург, 1907. 9 июнь) шулай яза: «Әсәрнең төзәтелгән вариантында «тасвир итдеге мәгыйшәтне мөхәррир хәзерге вакыткарак күчермештер (мәсәлән, гимназистка, бунларның хатыннарга мөсават хакында бәхәсләре – һәммәсе соңгы көннәр мәгыйшәтеннәндер). «Бәхетсез егет» тамашага куелыр өчен язылмыш татар әдәбиятында хәзергә кадәр беренчелек урынын тотарга лаектыр».

Г.Камалның әдәби эшчәнлегенә 10 ел тулу уңае белән «Сәйяр» труппасы тарафыннан бирелгән адреста бу әсәргә шундый бәя бирелә: «Үзегезнең 10 еллык хезмәтегез аркасында безнең театрыбызны юлга салырга Сез сәбәп булдыгыз. Сезнең язган әсәрләрегез шул мөддәт эчендә сәхнәдән чыкмыйча дәвам итте. Сезнең әсәрләрегездән «Бәхетсез егет» бүген утыз җиденче мәртәбә сәхнәгә куеладыр».

«Бәхетсез егет» драмасы «Сәйяр» труппасы тарафыннан басылып чыккан елны ук сәхнәгә куярга хәзерләнә. Әмма 1907 елның 31 августында Мәкәрҗә ярминкәсендә (ул ел саен Нижний Новгород шәһәрендә август-сентябрь айларында җыела) күрсәтеләчәге турында хәбәр бастырылса да, цензура рөхсәте булмау сәбәпле, ул көнне башка спектакль уйнала. Беренче тапкыр «Сәйяр» аны 1908 елның 12 гыйнварында Уральск шәһәрендә чакта сәхнәләштерә (Әлислах. 1908. № 6). Кәрим бай ролендә – Г.Кариев, Гайни – С.Гыйззәтуллина, Камали – Ә.Кулалаев, Җәмилә – Ф.Шаһимәрдәнова, Закир – В.Мортазин, Сабитов ролендә Г.Гайнуллин уйный. Казанда «Яшьләр труппасы» 1908 елның мартында куя: Кәрим – Ширалиев (Гафур Коләхмәтев), Гайни – Галиева, Җәмилә – Шәмсетдинова, Гайшә – Мурадова (Суфия Коләхметова).

1909 елның язында әсәр Бакуда азәрбайҗан театрында да куела. Закирны Х.Араблинский башкара; икенче тапкыр Х.Араблинский аны үз бенефисына 1911 елның 10 июнендә сәхнәләштерә. 10 июньдә чыккан «Баку» газетасы бу турыда түбәндәгеләрне яза: «Сегодня, 10 июня, в последний раз в этом сезоне, в театре Тагиева мусульманскими драматическими артистами в бенефисе главного режиссера труппы Х.Араблинского представлена будет в первый раз новая пьеса Али Аскера Камала, казанского драматурга, «Несчастный юноша», в переводе на азербайджанское наречие Д.Буняд-Заде. Пьеса ярко характеризует современную жизнь мусульманской молодежи и имела большой успех в Казанском и Оренбургском театрах»*. 12 июньдә чыккан «Каспий» газетасы Закир

* «Бүген, 10 июньдә, бу сезонда соңгы мәртәбә Тагиев театрында труппаның баш режиссеры Х.Араблинский әфәнде бенефисына мөселман драма артистлары тарафыннан беренче тапкыр буларак Казан драматургы Галиәсгар Камалның «Бәхетсез егет» әсәре сәхнәгә куелачак. Азәрбайҗан теленә тәрҗемәчесе Д.Буняд-Задә. Бу пьеса мөселман яшьләренең бүгенге тормышын бик көчле сурәтли. Ул Казан һәм Оренбург сәхнәләрендә зур уңыш казанды».

Мөсават – тигезлек.

Мәгыйшәт – тормыш.

Мөддәт – вакыт.

ролендә чыгыш ясаган Х.Араблинскийның уенын болай бәяли: «В роли Закира выступил бенефициант, в ярких красках передавший все переживания юноши»*.

1916 елның 18 ноябрендә әсәр Уфада «Нур» труппасы тарафыннан да куела (Закир – Г.Казанский, Кәрим – Л.Аитов, Гайни – С.Гыйззәтуллина). Спектакльгә карата язылган рецензиядән күренгәнчә (Тормыш, 1916. 23 ноябрь), һәм «Нур» труппасында, һәм Азәрбайҗанда куелганда, әсәргә үзгәреш кертелгән булган: «Китапка караганда, Закир Гайнине яхшы ук салкын кан белән, үзенең нишләгәнен аңлап үтерә (соңыннан үкенүе икенче эш). Шуның өчен Казанский атып үтермичә, Араблинскийга тәкълид итеп, буып үтерүе гайре табигый чыкты».

Текст, нигездә, 1907 елгы басмадан алынды.

[1] *Чалпу да әйләндереп алдым.* – Иске ырым: авыру тиз терелсен дип, дога яздырып куму.

[2] *Ният уку* – дини йола: берәрсе авырса, дога, Коръән укыту.

[3] *Килен сөя бару (яки аклашу)* – кызны егеткә бирергә риза булгач, ике яктан да эти-әниләре җыелып киңәшү, бүләк бирешү.

54 бит.

**Беренче театр.** 1908 елның җәендә Казанда «Гасыр» нәшриятында басылып чыккан. Беренче тапкыр сәхнәгә шул ук елның августында Мәкәрҗә ярминкәсендә куелган (Йолдыз. 1908. 28 август). Спектакльнең премьерасында Г.Камал үзе дә була. Хәмзә образын Г.Кариев иҗат итә.

Әсәргә матбугатта югары бәя бирелә. Ф.Әмирхан (Әлислах. 1908. 10 июнь) «Беренче театр» исемле мәкаләсендә болай яза: «Беренче театр» – бер пәрдәле көлке, Казанның тәҗвидче мөтәрәкъкыйләре мәгыйшәтеннән алып язылган әсәр. Галиәсгар әфәнде бу әсәрен хосусый бер гаиләнең мәгыйшәтеннән алып язган булса да, урта буржуазный классның психологиясен бик яхшы төшенгәнлегеннән, комедиянең каһарманнарына бик оста сурәттә гомумият бирә вә, шулай итеп, бу кыска комедиясен гомуми, ярым «мөтәррәкъкый» купецларыбызның мәгыйшәт вә дингә нәзарларының бер бик тугры көзгесе итеп чыгарадыр. Комедиянең баш каһарманы Хәмзә бай – җәннәт ачкычын үз кулына тотып, аныңча йөрмәгән кешеләрнең берсен дә анда кертмәскә мөтәкәффил булган мөттәкый – үзенең бик көлке хосусиятләре белән комедиядә бик ачык тасвир ителәдер. Моның тәрбиясе нәтиҗәсе булган балаларының хосу-

---

* «Закир ролендә бенефис иясе үзе уйнады. Ул яшь егетнең барлык кичерешләрен ачык буяулар белән сурәтләде».

Китапка караганда – «китаптан аермалы буларак» мәгънәсендә.

Тәкълид – ияреп.

Тәҗвидче мөтәрәкъкыйләре мәгыйшәтеннән – үзләрен прогресс яклы дип йөртүчеләр тормышыннан.

Нәзар – караш.

Мөтәкәффил – җаваплы, үз өстенә алучы.

Мөттәкый – динле, тәкъва.

сиятләре дә бик көлке сурәттә күрсәтелә». Моннан башка К.Бәкер (Әлислах. 1908. 13 ноябрь), Кермэ (Русские ведомости. 1911. 21 октябрь), Вл. Гордлевский (Русские ведомости. 1911. 29 ноябрь) мәкаләләре, «Кояш» (1912. 14 декабрь), «Вакыт» (1908. 31 май; 1912. 29 декабрь), «Әлислах» (1908. № 41) һ.б. газеталарда материаллар басыла.

Утызынчы еллар башында Г.Камал шушы әсәре нигезендә оперетта язу уена килгән һәм беренче пәрдәсе өстендә эшли дә башлаган. Ул «Совет әдәбияты» журналының 1935 елны чыккан 6 нчы санында басылган (шушы басманың 2 нче томыннан карагыз).

Текст 1908 елгы басмадан алынды.

[1] *Бүләк багу* – туйга әзерләнгән бүләкләрне карау өчен җыелу.
[2] *Сак җиң* – кыска җиңле хатын-кыз күлмәге.
[3] *Плашкига чыгу* – электә шәһәрдә күңел ачарга чыгу.
[4] *Санат* – сенатор сүзеннән үзгәртелгән, биредә: «түрә» мәгънәсендә.
[5] *Мәсих* – дини йола буенча читек өстеннән су йөгертү.
[6] *Пласкатель* – сакал-мыек кырганда сабын күбеге ясый торган савыт.
[7] *Ясигъ* – йокы алдыннан укыла торган соңгы (бишенче) намаз.

71 бит.

**Бүләк өчен.** 1909 елда Казанда «Мәгариф» көтебханәсендә аерым китап булып басылып чыккан һәм шул ук елның сентябрендә «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәгә куелган. Әхмәтҗан ролендә – Габдулла Кариев, Габдуллаҗан – В.Мортазин. Әсәр турында матбугатта Ф.Әмирхан (Йолдыз. 1912. 20 октябрь), К.Бәкер (Йолдыз. 1909. 23 сентябрь), Г.Тукай (Йолдыз. 1910. 28 ноябрь) мәкаләләре һ.б. материаллар басыла.

Г.Камалның 10 еллык юбилеена багышланган мәкаләсендә Г.Тукай әсәрне шулай бәяли: «Ошбу сәнә 5 ноябрьдә «Новый клуб» залында «Сәйяр» мөселман артистлары тарафыннан Галиәсгар әфәнденең 10 сәнәлек әдәби вә милли каләм хезмәте шәрәфенә аның «Бәхетсез егет» драмасы илә «Бүләк өчен» комедиясе куелды... Галиәсгар әфәнденең бу ике әсәре чын татар тормышыннан бик белеп алынган тасвирлар булып, хосусән «Бүләк өчен»дәге, угылын өйләндерә торган татар хатынының халәте рухиясен белү, аның издиваҗ кеби олугъ бер эшкә ничек бер уенчык кына итеп караганын күрсәтү вә шул хатын авызыннан кыз атасы тарафыннан киләчәк бүләкләрне «Әлхәм» укыган кеби яңлыштырмый, гармонично санату фәкать Галиәсгар әфәнденең нечкә хиссенә вә тирән күрүенә генә хас бер эш булганга, аннан соң «Сәйяр» труппа артистларының сәхнәдә һәрвакыт, һәр җирдә, һәр шәһәрдә күрсәтәчәк ма биһил-ифтихарлары шушы Галиәсгар әфәнде әсәрләре булганга, шул

---

С ә н ә – ел.
Ш ә р ә ф е н ә – хөрмәтенә.
Х о с у с ә н – бигрәк тә.
И з д и в а җ – өйләнү.
М а б и һ и л - и ф т и х а р – мактаныч.

сәбәпле алар күп уйналганга, бу әсәрләрне уйный белүдә артистлар бөтенләй мөтәхәссис булып киткәнгә, табигый, уен яхшы чыкты».

Текст 1909 елгы басмадан алынды.

[1] *Кәбен бирнәсе* – туй булгач бирелә торган актык бүләк.

[2] *Иҗабе кабул* – алдым-бирдем ясау (кызны вәгъдәләшеп кую).

84 бит.

**Уйнаш.** 1910 елда язылган һәм шул елның декабрь аенда «Сәйяр» труппасы тарафыннан Казанда сәхнәгә куелган. 1911 елның сентябрендә Казанда «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрәкәсе» тарафыннан аерым китап булып басылып чыккан. «Сәйяр»дә Мөгълифә ролен – Г.Болгарская, Сәрбиҗамалны – С.Гыйззәтуллина, Әнвәрне Г.Кариев уйный.

Әсәр турында «Вакыт» газетасында (1910. 9 декабрь; 1911. 6 гыйнвар; шул ук елның 6 сентябрь; 1912. 29 июль), «Йолдыз»да (1911. 5 декабрендә) мәкаләләр һәм хәбәрләр басыла.

«Уйнаш» китабында зур шәһәрләрдә акчалы, әмма мәгърифәтсез гаиләләр эчендә бик еш очрый торган хәлләр тасвир ителә... Изгелек вә явызлык, бәхет вә бәхетсезлек акча бәһасенә йөртелә, акчага һәрнәрсә сатып алып була дип ышанганга, алар әллә никадәр семьяларның намусын пычрата вә сәгадәтен җимерәдер. Аның карашында кешеләр икегә бүленәләр: берсе – хуҗалар, икенчеләре – малайлар, коллар», – дип яза, мәсәлән, «Вакыт» газетасының хәбәрчесе Ш.Яров*.

Текст 1911 елгы басма буенча алынды.

[1] *Җәдитләр* – биредә: «яңача уку яклы кешеләр» мәгънәсендә.

[2] *Талакы хәсән* – дин буенча яңадан кушылу рөхсәт ителә торган рәвештә хатын аеру.

[3] *Талакы бидгый* – дин буенча яңадан кушылу рөхсәт ителми торган рәвештә аерылу.

[4] *Гыйддәт нәфәкасы* – аерылган йөкле хатынга билгеле бер вакыт дәвамында ярдәм итеп тору.

113 бит.

**Банкрот.** 1911 елны язылган һәм шул ук елның 4 ноябрендә кулъязма текст буенча «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәгә куелган. Шул ук елда «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрәкәсе» тарафыннан Казанда аерым китап булып басылып чыккан. (Бу турыда «Йолдыз» газетасында 1911 елның 8 декабрендә хәбәр бар. Әмма китапның тышлыгында «1912 ел» дип куелган.) «Банкрот» спектаклен тамашачы зур кызыксыну белән каршы ала. «Сәйяр» куйган спектакльдә Сираҗетдин Туктагаевны – Г.Кариев (соңрак Ә.Кулалаев та кушыла), Җамалетдинны – Үзбәк (Кәрим Тинчурин), Василий Дмитриевичны – В.Мортазин, Докторны – Ә.Кулалаев, Нәгыймәне – З.Баязидский, Гөлҗиһанны Г.Болгарская уйныйлар. Бу әсәрне сәхнәгә әзерләү уңае белән «Йолдыз» газетасы (1911.

---

Мөтәхәссис – оста.

* Вакыт. 1911. 6 гыйнвар.

1 ноябрь): «Мәзкүр уеннарны тамашага куючы «Сәйяр» труппасы үзен халыктан яраттыру өчең бик тырыша», – дип яза. Г.Кәрамның спектакль турында язган рецензиясендә (Йолдыз. 1911. 8 ноябрь) шундый сүзләр бар: «Галиәсгар әфәнде бу әсәрендә вакыйганы бик оста тасвир итә белмеш вә моның илә бәрабәр пьесаның әшхасын бик табигый вә көлкеле итеп күрсәтмештер. Мөхәррир әфәнде үзенең мәһарәте каләмиясе вә истигъдаде табигыясе сәясендә боларның бер-беренә аерым бер хосусият, башка бер әһәмият бирә. Шул сәбәптән булырга кирәк, Камал әфәнденең әсәрләре кальбебезгә бик якын хис ителә, аның кешеләрен һәммәбез бертигез аңлыйбыз, бер дәрәҗәдә ләззәт алабыз».

Текст 1911 елгы басма буенча алынды.

[1] *Шартлау* – бөлү, банкротка чыгу.

[2] *Мәскәү өсте* – Мәскәү ярминкәсе вакыты.

[3] *Зәкят* – дини налог; сәүдәгәрләр килеренең кырыктан бер өлеше, башкаларныкыннан йөздән бер өлеше алына торган мәҗбүри салым.

[4] *Нәзер-нияз* – дини йола; берәр теләккә ирешү өчен дога кылдыру.

[5] *Хуҗа Баһаветдин* – XIV гасырда Бохара шәһәре тирәсендә яшәгән суфи, динчеләр аны изге кеше дип йөрткәннәр.

[6] *Куркулык* – дини йола: кеше авырганда, берәр нәрсәдән курыккан дип, шул авыру янында кургашын эретеп салу.

[7] *Пирәшләү* – пәрәмәч белән чәй эчү.

154 бит.

**Безнең шәһәрнең серләре.** Автор үзе комедияне «5 пәрдәлек мәнзарә» (ягъни күренеш-картина) дип билгеле. 1911 елда язылган һәм 1913 елда Казанда «Гасыр» нәшрияты тарафыннан аерым китап булып басылып чыккан. 1911 елның 11 ноябрендә «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәгә куелган. Беренче пәрдәдә «Җәмгыяте хәйрия» әгъзаларын – Г.Кариев һәм Ә.Кулалаев, Сәркәтибне – В.Мортазин, Сакчыны З.Баязидский уйный. «Базар чатында»гы күренештә Шкафчы Әхмәтҗан – Г.Кариев. «Әдәбият кичәсендә җәнҗал» пәрдәсендә Карт – Г.Кариев, Киң сакал – Ә.Кулалаев, Яшь кеше – В.Мортазин, Киң сакалның хатыны – Г.Болгарская, партердан берәү – З.Баязидский.

Әсәр турында матбугатта Г.Кәрам (Йолдыз. 1911. 8, 18 ноябрь), Аксакал (Кояш. 1914. 16 гыйнвар), Г.Ибраһимов (Йолдыз. 1912.

---

Мәзкүр – элеге, югарыда әйтелгән.

Әшхас – катнашучылар.

Мәһарәте каләмия – язу осталыгы.

Истигъдаде табигыясе сәясендә – табигый таланты аркасында.

Хосусият – үзенчәлек.

Калеб – күңел.

22 гыйнвар), Г.Тукай (Ялт-йолт. 1912. 1 гыйнвар) мәкаләләре һәм бәяләре басыла.

Г.Тукай болай яза: «Былтыр Галиәсгар Камал безнең шәһәрнең серләрен чит шәһәрләргә сөйләде дә куйды. Электә чит шәһәрдә йөргәндә, синең яныңа киләләр дә:

– Казан ничек? Халкы ничек? Андагы «Шәрекъ клубы» ничек? Фәлән ничек? – дип йөдәтеп бетерәләр иде. Әлбәттә, эчләреннән Казан вә аның мөтәгалликатенә бик мактаулы җавап көтәләр иде.

– Бирмәсәң – оят, бәдбәхеткә, бирсәң – кыен.
Ул акчаны тапкан бит ошбу муен, –

дигән шикелле, Казан вә казанлылар тугърысында ялганлап, сүз белән сүи истигъмаль итәсе килми иде. Ялганламасаң, аларның хөсне заннарын бозу була иде. Менә хәзер аларга «Безнең шәһәрнең серләре» – укысыннар да белсеннәр, кемнәр барын күрсеннәр».

Текст 1913 елгы басмадан алынды.

200 бит.

**Дәҗҗал.** 1912 елда язылган һәм шул ук елда Казанда «Сабах» көтебханәсе нәшрияты тарафыннан аерым китап булып басылып чыккан. 30 мартта «Сәйяр» труппасы әсәрне Г.Камал бенефисына сәхнәгә куя (Әхмәт – Г.Кариев, Шөҗаг – В.Мортазин, Фәхерниса – С.Гыйззәтуллина). Әсәр турында «Йолдыз» газетасында (1912. 1 апрель) – Һатиф, «Вакыт»та (1912. 8 май) Ш.Мостафи мәкаләләре чыга һәм «Ялт-йолт» журналында (1912. 13 июнь) Г.Тукайның уңай карашы белдерелә.

Текст 1912 елгы басмадан алынды.

[1] *Шыр* – чәй йөртә торган әрҗә.
[2] *Чалпу салдыру* – 359 биттәге искәрмәне карагыз.
[3] *Куркулык койдыру* – 362 биттәге искәрмәне карагыз.

232 бит.

**Каениш.** 1912 елда сәхнәгә куелган. 1913 елда Казанда «Гасыр» нәшриятында аерым китап булып басылып чыккан.

Текст 1913 елгы басмадан алынды.

248 бит.

**Көндәш.** 1918 елда Казанда «Алга» көтебханәсе нәшриятында басылып чыккан.

Текст шул басмадан алынды.

---

Д ә җ җ а л – дини риваять буенча дөнья беткәндә мөселманнарга каршы чыгачак бер явыз зат; ул, музыка уйнап, халыкны үзенә ияртәчәк, имеш, аңа караган кешеләрнең башларына мөгез чыгачак, имеш.

258 бит.

**Өйләнәм!.. Ник өйләндем?** 1915 елның сентябренә тәмамланып, беренче тапкыр 1916 елның 11 ноябрендә «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәгә куелган. 1918 елда Казанда «Алга» көтебханәсе нәшриятында аерым китап булып басылып чыккан. «Сәйяр»дә Әхмәт ролендә Г.Кариев уйный. Спектакльгә рецензия язган З.Нуркин әсәр турында болай ди: «Комедия, шөбһәсез, Г.Камал әфәнденең башка комедияләре кебек үк рухлы, кызыклы бер әсәрдер. Мөхәррирнең характерный гыйбарәләрне эләктерүдәге мәһарәте монда да ачык күренә» (Йолдыз. 1916. 14 ноябрь.)

Текст 1918 елгы басмадан алынды.

[1] *Кек-уок* – Америка негрлары биюе.

**Кушымта**

*(Вариантлар һәм тәрҗемә)*

283 бит.

**Бәхетсез егет (беренче вариант).** 1900 елда Казанда басылып чыккан. Автор пьесаның 1907 елда басылган икенче вариантка керешендә болай яза: «Моннан тукыз ел мөкаддәмдә «Бәхетсез егет» наméндә театру тарзында бер рисалә язып, исемсез уларак нәшер идтермеш идем». Димәк, әсәр 1898 елда язылган. Г.Камал үзе исән чакта һәм соңыннан чыккан җыентыкларда, һәм тикшеренүләрдә дә бу әсәр 1898 елда язылган диелә. Калган мәгълүматлар китап тышлыгында түбәндәгечә күрсәтелгән: «Яшь егет һәм кызларга нәмунә (үрнәк). «Бәхетсез егет», драм, алты пәрдә илә тәэлиф иделмешдер. Басмасына рөхсәт вирелде Санкт-Петербургта 18 июльдә 1898 елда. Басма улынды Казанда Торговый дом борадәран Кәримевләрнең матбагасында, 1900 елда».

Китап барлыгы 20 биттән гыйбарәт, авторы яки псевдонимы күрсәтелмәгән. Сәхнәгә беренче мәртәбә Казанда 1903 елда «Шимбәчеләр» түгәрәге тарафыннан куелган («Татар театры». 1906–1926. Казан, 1926. 26.) һәм Чистайда 1906 елны уйналган (Таң йолдызы. 1906. 24 ноябрь).

Текст 1900 елгы басмадан алынды.

300 бит.

**Өч бәдбәхет.** 1900 елда басылып чыккан. Китапның тышлыгында өстәмә шундый мәгълүматлар бар: «Бик кызык бер роман. Күп йөрүче хатын, явыз карчык, кеше хатынына тамгы кыйлучы. Мөәллифе – Г.Казани».

---

*Мөкаддәм* – элек.
*Наменд*ә – исемдә.
*Театр тарзында рисалә* – пьеса рәвешендә әсәр.
*Тәэлиф итүче* – язучы.
*Тамгы кыйлучы* – аздыручы.

«Бу китап басма улынмыштыр Казанда Чирков варисларының Фазылҗан вә Фазылгаллә́м Әхмәтҗановларның хәраҗаты илән 1900 елда».

«Басмасына рөхсәт вирелде Санкт-Петербургта 4 мартта 1900 елда».

Китапта вакыйгада катнашучылар исемлеге бирелмәгән, һәм шулай ук әсәр пәрдәләргә бүленмичә, күренешләргә саннар гына куелган. Китапның күләме 32 бит.

Текст шуннан алынып басыла.

317 бит.

**Кызганыч бала.** Титул биткә шундый искәрмә бирелгән: «3 фасылдан гыйбарәт театр уены. Мөтәрҗиме – Г.Казани. Бу китапның басмасына рөхсәт вирелде Санкт-Петербургта 26 июньдә 1900 елда». Әсәр 48 бит күләмендә басылган. Прогрессив төрек язучысы Намикъ Кәмал әсәре. Ул беренче тапкыр 1901 елда – Бакчасарайда, 1904 елда Казанда куела. 1906 елның 22 декабрендә «Гыйшык бәласе» исемле комедия белән икесе татар театры сәхнәсен ачкан көндә уйнала. 1909 елдан азәрбайҗан театрында куела башлый; игъланнарында әсәрнең авторы «А.Казани» дип күрсәтелә*.

Текст 1900 елгы басмадан алынды.

---

* Хөсәен Араблинский (Актерның тормышы һәм эшчәнлегенә караган документлар җыентыгы). Азәрбайҗан телендә. Баку, 1967. 54 б.

Х ә р а җ а т ы  и л ә н – чыгымнары исәбенә.

Ф а с ы л – бүлек.

М ө т ә р җ и м – тәрҗемәче.

## ЭЧТӘЛЕК

Редколлегиядән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

**Драма һәм комедияләр**

Бәхетсез егет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Беренче театр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Бүләк өчен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Уйнаш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Банкрот . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Безнең шәһәрнең серләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Дәҗҗал . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 200
Каениш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 232
Көндәш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 248
Өйләнәм!.. Ник өйләндем? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 258

**Кушымта**

Бәхетсез егет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 283
Өч бәдбәхет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 300
Кызганыч бала . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 317

Аңлатма һәм искәрмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 341

Литературно-художественное издание

**Камал** Галиасгар
(**Камалетдинов** Галиасгар Галиакберович)

**СОЧИНЕНИЯ**

Издание второе, исправленное и дополненное

В трех томах

Том 1

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Камал** Галиәсгар
(**Камалетдинов** Галиәсгар Галиәкбәр улы)

**ӘСӘРЛӘР**

Төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басма

Өч томда

1 том

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Г.Г.Зиннәтуллина, Г.М.Хәбибуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 1.06.2010.
Форматы $84 \times 108\ ^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 19,32.
Тиражы 2100 д. Заказ О-702.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jaһat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.